Зөлфәт Хәким

Легионер

Татарстан
китап
нәшрияты

Зөлфәт Хәким

Легионер

Роман, повестьлар, хикәяләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2011

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-44
Х86

Хәким, З.З.

Х86 Легионер : роман, повестьлар, хикәяләр / Зөлфәт Хәким. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 367 б.
ISBN 978-5-298-02126-5

Танылган язучы, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты З.Хәкимнең әлеге китабында кеше язмышлары аша ил, җәмгыятьнең тирән фаҗигасен сурәтләгән «Легионер» романы, заманча аһәң белән сугарылган «Курку», «Баян турында бәян» повестьлары, юмористик һәм сатирик хикәяләре урын алды.

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-44

ISBN 978-5-298-02126-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Хәким З.З., 2011

ЛЕГИОНЕР

РОМАН

1

Каяндырерактан җыр яңгырады. Күз күрмәс арадан тонык кына ишетелгәнгә күрә, бу нәгъмәнең күңелдә шөбһә уятырдай аһәңе бар. Кемнеңдер газабы, калкулыкларны уза-уза, әрәмәләр аша, чиксезлекне дәгъвалап җәйрәгән су өстеннән очып, яшәешнең иң очына барып ялганырга тели. Бу моң кайдадыр эреп юкка чыгадыр, гаип буладыр дип һич кенә дә ышанасы килми. Җан газабы туып, тулып, сыкрап чыккан икән инде, димәк, аның сыеныр урыны бар, ул бөдрә талларга барып куна, суга иңеп дулкыннарга сеңә, Кызылъяр авылының халкы күчеп урнашкан сөзәк тау итәгенә мәңгелек сагыш булып сарыла.

Шәфәкъ халәтенә аваздаш бу җырда гомер чикләренә кадәр сакланырлык хәсрәт белән бергә сүз шатлыгы, моң куанычы, хис тантанасы бар. Гади генә җыр кебек югыйсә, әмма аның яңгырашы, бәгырьләрне чынбарлыктан үзе белән каядыр аулакка алып китеп, җелегеңә үтеп керә.

Җыр ишетелми башлагач та, ул тәмамланмагандыр шикелле тоела, бер яңгырагач исә, һичшиксез, дөнья буйлап мәңге агыладыр дип ышанасың. Таулар, кыялар, урманнар аша, дәрьялар, диңгезләр өстеннән очып кайчан да булса ул бу тарафларга кире әйләнеп кайтыр һәм моң сутларына сусап җирсегән җанны тагын әллә ничәнче кат иркәләр кебек...

Бу тарафтан сусаклагычның аргы ягы бөтенләй күренми.

Еракта, су белән күк тоташкан якта, инде дөнья тәмамланадыр шикелле. Чөнки бу авылның халкы инде бер «ахырзаман»ны кичерде. Авыл, шул авылның зираты су астында калды, әрәмәләрне, болыннарны, басу-кырларны су басты.

Су күтәрелер алдыннан Кызылъяр авылын ашык-пошык тау итәгенә күчерделәр.

Афәттән качарга теләп үрмәләгәндәй, «яңа» авыл тауның итәгеннән алып өскә, калкулыкка таба салынган. Кызылъяр кешеләренең йөзләрендә бүгенгәчә сөйләп-аңлатып бетермәслек сагыш сарысы саклана. Гүяки су төбендә халыкның үткәннәре белән бергә киләчәккә алып барырдай куәте калган, алай гына да түгел, әйтерсең лә авылдашларның гәүдә-тәннәре, тормыш-көнкүрештә кыймылдаулары исән, әмма кешене кеше итүче, сүз белән әйтеп булмый торган бер иң кирәк нәрсәне коткара алмаганнар. Тау итәгенә барып сыенган авыл элекке исеме белән – Кызылъяр дип аталса да, чын Кызылъярның җанын су йоткан, менә шуны һәрбер кеше белә, аңлый, әмма бернишләтә алмый.

Су буенда төрле тарафтан һәм авылның үзеннән дә күренеп торган бер ачык урын бар. Монда таллар да, иркенрәк булсынга, читкә табарак үрчергә тырышканнар кебек. Шушы төштән су биләмәсен күзәтергә бик уңай. Әнә ул, авыл баткан урын. Тегендәрәк зират иде. Ул тирәдә әле шактый вакыт Югары очның биек-биек тупыллары, су өстеннән ябалдашларын калкытып, авылдашларга соңгы сәламнәрен биреп тордылар. Отыры алар да юкка чыкты.

Сагынып еларга, хатирәләрнең яктыракларын барлап елмаерга, үткән гомердәге хаталар, гаеп-гөнаһлар өчен тәүбә итәргә, су төбендә калган әби-бабайлар кабере өчен ярлыкау сорарга кешеләр шушы урынга йөри. Су баскан тарафларга карап, һәркем үзенекен уйлыйдыр, күңелендә һәммәсе гаепләне эзлидер, ләкин барысының да фаҗигасе уртак булганлыктан, аерым алганда, беркем беркемгә күңелендә үпкә-шелтә сакламый, чөнки гөнаһ һәркемдә бар.

2

1941 елның июнь аенда, явым-төшемнәр үз вакытында килеп, һавасы әлсерәтмәслек, чамалы эсселектә торуга карамастан, Нәгыйм агай аягы сызлап бимазаланды. Герман сугышыннан алып кайткан бу ярадан котылыр чара юктыр, ахрысы, гомер азагына кадәр түзәргә язгандыр дигән уй белән ул инде күптән килеште. Нигә соң әле чалт аяз көнне аяк сызларга тотынды, нишләп әле бу авырту тирәнгә, үзәккә үтеп җан сызлавына әверелә? Бу тикмәгә түгел.

Өч йөз хуҗалыклы Кызылъяр авылы дүрт төп урамнан һәм шул урамнарның икесеннән тармакланган дүрт тыкрыктан тора иде. Югары оч үргәрәк сузылганга, Түбән оч, әлбәттә, түбәндәрәк урнашканга шулай аталалар иде. Кәрим очы революциягә кадәр яшәгән Кәрим бай исеменнән калган дип сөйлиләр, ә Бакалы очы авыл яныннан агып ятучы инеш үзенең чыганагын алган сазлыклы урынга барып тәртелгәнгә күрә шул атаманы алган, имеш. Тыкрыклар да исемнәрдән мәхрүм калмаганнар: Текә тыкрык, Мортаза тыкрыгы, Аулак тыкрык, Чишмә тыкрыгы.

Түбән очтан тармакланган Чишмә тыкрыгы көмеш сулы чишмәгә алып бара, бу тыкрыкның үзендә йортлар юк, як-ягында ике хуҗалыкның читәннәре сузылган. Тыкрык башында уң якта Хәлиуллалар йорты, сул якта Нәгыймнәрнеке.

Авыл халкының күбесе шушы тыкрыктан чишмәгә суга йөри. Һәр урамның үз коесы бар, ләкин эчәргә, аш-суга чишмә суы кирәк, көянтә-чиләк күтәргән кызларның, киленнәрнең Чишмә тыкрыгыннан беркайчан өзелгәне юк.

Яббар, бакча артыннан әкрен генә аксап кайтып килүче атасының күзенә чалынмас өчен, капылт кына капкадан чыкты да Чишмә тыкрыгыннан томырылып йөгерде.

Нәгыйм кече улының тыкрыктан җан-фәрманга чабуын күреп эндәшмәкче иде, кире уйлады, моңсу гына елмаеп куйды. «Ни арада үсеп җиттеләр! Кыз-кыркын белән чуала башлады кечесе дә». Ни гаҗәп, йөрү аякларның сызлавын киметте. «Хәрәкәттә – бәрәкәт», дип юкка әйтмиләр. Ул тагын тыкрык читәне өстеннән Яббарның такыр башын абайлады – бу юлысы малай кирегә таба йөгерә иде. «Нәрсә әрле-бирле чабасың?» дип кычкырмакчы иде дә, көчен кая куярга белмәгән малайга аваз салып, болай да чамалы хәлне бетереп торуны кирәксенмәде, үзалдына гына: «Ут капкандай чапмасаң, тиле!» – дип, өйгә таба атлады. Белә лә ул малаеның ни сәбәптән үзен кая куярга белми чапкынлавын. Кызлар шулай йөгертә алар. Әмма аларны чамалабрак ярятырга кирәк, кирәгеннән артык гашыйк булу да бигүк дөрес түгел, бөтенләй алар көенә бию һич ярамый.

Яббар инде әллә ничә мәртәбә тыкрык буйлап астан өскә ары-бире чапты. Ниһаять, ул чишмә суы инешкә әверелеп бормаланган төшкә барып хәл алырга туктады. Аннары, аптырап, таллык тирәсеннән урады, үрелеп-үрелеп, түземсезлек белән тыкрыкны күзәтте. Берничә кат, инеш аркылы сикереп чыгып, үзләренең йөри торган урыннарын әйләнеп килде – беркем юк.

Кулларын як-якка матур итеп болгый-болгый килүче Фатыйманы күргәч, аның эченә җылы йөгерде, өстән авыр йөк төшеп, берничә мизгел эчендә канатлар үсеп чыккандай булды.

Әйтерсең лә аларга кемдер махсус җыр багышлады – Кәрим очы ягыннан гармун авазы ишетелде, күп тә үтмәде, бер моңлы тавыш гармунга кушылды:

Әйдә, дустым, су буена,
Монда күңел тарсына;
Аккан суларның көенә
Әйтер сүзем бар сиңа.

Бу нәгъмә яшьләрнең хисләрен тагы да җилкетебрәк җибәрде. Әбелхәят кочагында саф сулы чишмә, шул чишмә моңына тиң җыр, ике йөрәкнең бер серле көйгә тибүе – бу халәт аларның икесен генә түгел, бәлки авылны, авылны гына да түгел, ә бәлки бөтен дөньясын бер бишектә тибрәтте. Бәхеттән ярылыплар гына китә күрмәсен инде бу йөрәкләр!

Шулай да Яббар кызны шелтәсез калдырмады:

– Нишләп бик озак?

Фатыйма әле һаман еш-еш сулый иде, тиз генә җавап бирә алмый торды.

– Өйдән чыгып китә алмый аптырадым, – диде ул, ниһаять. – Әнкәй чыгармый. Көчкә күндердем. Бер сәгатькә генә җибәрде. Җитмәсә, теге силсәвит Хәлиулланың малае очрап бәйләнде.

Яббарның йөзе ачудан аксыл төс алып, суырылып калды:

– Әнсарның сиңа күзе төшкән, ахрысы. Бәйләнәме?

– Бәйләнә, – диде Фатыйма, караңгыланып. – Кая барасың, ди. Әйдә очрашыйк, ди. Иртәгә тегермән янына килергә куша.

Яббар тешләрен кысып йодрыгы белән ботына сукты:

– Мин аны бәреп үтерәм!

– Берүк сугыша күрмә аның белән! – диде Фатыйма, котсыз калып. – Төрмәгә тыгып куярлар үзеңне. – Ул егетнең күзләренә тутырып карады. – Мин барыбер синеке инде, Яббар.

Яббарда ярсуның әсәре дә калмады:

– Ике көн генә күрми тордым үзеңне, ике ел күрмәгән шикелле тоелды.

– Мин дә сагындым сине, – дип пышылдады Фатыйма.

Бигрәк чибәр кыз шул Фатыйма. Авылда аңа кызыгып йөрүчеләр күп. Урта буйлы, туры, төз гәүдәле, һәр кигән күлмәге, һәр бәйләгән яулыгы сылу йөзенә шундый килешеп тора. Төсбиткә ул әнкәсенә охшаган – кара чәчле, кара кашлы, кысыграк күзләре елмайганда бөтенләй йомыла шикелле. Мондый кызлар үзбәкләрдә дә, төрекмәннәрдә дә очрый. Яббарның СССРдагы халыклар турында бер китап күргәне истә, анда татар кыяфәтле бик чибәр кызлар бар иде.

Әйе, Фатыймага бик күпләр гашыйк, әмма Яббар аларның берсеннән генә азрак шүрли – Әнсардан, чөнки аның атасы авыл җитәкчесе.

Алар чишмә тирәсеннән, күпне күреп, кирәгеннән артыгын сөйләшә торган көянтә-чиләкле хатын-кыз күзеннән ераккарак китәргә ашыктылар.

Инешнең аръягында калкулык, биек булмаса да аны никтер тау дип атыйлар, анда менгәч, бер тарафта Идел елгасы җәйрәп акканын күреп хозурланасың, икенче якта күз алдында ямь-яшел болын хәтфәсе җәелә. Кызылъяр авылы яшел бишектә тирбәлә сыман – як-ягында калкулыклар, тагы да түбәндәрәк Идел, аның түр ягында тагын бер тау бар, анысы шактый биек, ул Аулаш тавы дип атала. Егет белән кыз, беравык тирә-якка карап күкрәк тутырып сулап торганнан соң, кулга-кул тотышып болынга таба йөгерделәр.

– Бигрәк сәер, бер авылда бер-беребезне сагынып яшибез, – диде Яббар, туктап хәл алгач.

– Нишлик соң? – диде кыз. – Мин үзем сәгать саен очрашып торырга да риза. – Ул башын читкә борды. – Алай текәлеп карама, оялам.

Яббар, иркен сулап, бөтерелә-бөтерелә тирә-якны күзәтте:

– Карале, Фатыйма, нинди гүзәллек!

Шуннан соң ул инде шактый биек булып үскән үлән арасына чалкан ятты.

– Тагын нинди гүзәллек абайладың инде шушы бакалы, сазлыклы төбәктә? – диде Фатыйма, аның янына утырып.

Яббар сикереп торды:

– Мондый ямьле табигать безнең якларда гынадыр.

– Әллә нинди бай табигатьле мохитләр бардыр әле, күргәнебез

генә юк, – диде кыз, көлеп. – Чит илләрдә әллә нинди ямьле урыннар бардыр.

Яббар иңеннән кочып алгач, кызның тәне буйлап эсселе-суыклы дулкын йөгереп үтте, егетнең хәрәкәтләре шуннан ары узмаганны аңлагач кына аңарда киеренкелек кимеде.

– Юк, безнең ил кебек ямьле илне, безнең туган як кебек гүзәл якны бер җирдә дә табу мөмкин түгелдер, – диде Яббар, илһамланып. – Менә тирәнрәк сулап кара әле – нинди генә сихәтле хуш исләр юк монда! – Ул тирән сулыш алып күрсәтте. Аңа карап Фатыйма да күкрәгенә һава алып күзләрен йомды. Мөмкинлектән файдаланып, Яббар кызны битеннән үбеп алды. – Безнең авылыбызның исеме дә таң калырлык бит – Кызылъяр!

Фатыйма рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

– Уф, нәрсәсе таң калырлык инде?! – Кичке һаваны яңгыратып көлә-көлә, ул болын буйлап йөгерде. – Кызылъяр! Бигрәк таң калырлык икән!

Яббар аны куып тотты, кочагына алды, кайнар итеп үпмәкче булды. Кыз кинәт башын читкә борды, егетнең иреннәре аның колагына туры килде. Кыз тагын кычкырып көлеп җибәрде.

– Кытык килә, – диде ул, көлүдән кинәт туктап.

– Фатыйма, – дип пышылдады Яббар.

– Ә? – диде кыз, дер-дер калтырап.

Шул вакытны калкулык артыннан таныш аваз яңгырады. Аның кем икәнен икесе дә аңладылар, чөнки бу тавышны башка беркемнеке белән дә бутау мөмкин түгел. Үзенең яраткан шаян, мәгънәсез җырын җырлый-җырлый килүче кеше, һичшиксез, Әнсар иде.

Алма бирдем, алмадың,
Янчыгыңа салмадың;
Ике дөнҗа бер морҗа бит,
Нигә куна калмадың?

Карурманда – карама,
Араталыкка бара;
Урманнары бик карамы –
Ерагайды бит ара.

Алмалар пешеп җиткән,
Берсен өзәрсең микән?
Үзәкләрең өзелгәндә
Ничек түзәрсең икән?!

Карурманда – карама,
Араталыкка бара;
Урманнары бик карамы –
Ерагайды бит ара.

Тауга менгәч, Әнсар беравык күкрәген киереп тирә-якны күзәтеп торды. Егет белән кызны абайлагач, тизрәк шулар янына ашыкты. Яббар сизенде – бүген алар сугышмый калмаслар, мөгаен. Әнсар Яббардан буйга аз гына тәбәнәгрәк, ләкин тазарак, киңрәк җилкәле.

Яббар үзе дә, ябык булуга карамастан, нәселдән эре сөякле, шактый куәтле. Әнсар көчлерәк инде анысы, сүз дә юк. Әмма аның егәре түгел, ә авыл советы рәисе малае булуы ныграк каушата.

Әнсарның зәп-зәңгәр күзләре чамадан тыш майланган, килеп җитәрәк ул мәгърур кыяфәт белән авызын чалышайтты:

– Кая таба абына-сөртенә йөгерә дисәм, шушы ялан тәпиле, ыштансыз Яббар янына чапкан икән.

Яббар базынып йодрыгын төйнәде:

– Телеңне тый, мөртәт!

Фатыйма Яббарның беләгенә ябышты:

– Кызма. – Аннары ул Әнсарга туп-туры карап ярып салды: – Әйе, шуның янына йөгердем, анда синең ни эшең бар?!

Әнсар купайланып якынрак килде, мыскыллы елмаю белән Яббарга карап:

– Нәрсә анда кулларыңны җәя-җәя сайрадың? – диде.

– Ни кирәк сиңа? – дип җикерде Яббар. – Ычкын моннан яхшы чакта!

– Тыпырчынма, мәхлук! – дип ысылдады Әнсар. – Болынга син хуҗа түгелдер бит? Син үзең миңа монда саф һава сулап йөрергә комачаулыйсың.

– Әнсар абый, ник болай пырдымсызланасың син? – диде Фатыйма, Әнсарның узынуына җен ачуы чыгып.

– Мин бит, гүзәлем, синең белән түгел, менә бу алама белән шулай сөйләшәм, – дип җавап бирде Әнсар.

Яббар түземлеген тәмам җуйды:

– Фатыйма! Бар син кайта тор! – диде ул боерулы тавыш белән. – Үтенеп сорыйм, бар!

– Яббар! – дип еламсырады Фатыйма.

– Бар, дидем мин сиңа! – дип кабатлады Яббар.

Фатыйма, борылып карый-карый, авылга таба йөгерде.

Әнсар аңа:

– Фатыйма, авыл башында көт мине! – дип кычкыргач, Яббар, чыгырыннан чыгып:

– Тәмам җелегемә үттең, кабахәт! – дип дошманына кизәнде.

Әмма Әнсар читкә тайпылып калды, ә Яббар үзенең кизәнү көче белән чак кына йөзтүбән аумады. Әнсар сугарга җыенган иде, җитешалмады, Яббар аның күлмәген түш турысыннан йомарлап тотты, тегесе исә моның бугазына ябышты. Бер-берсен ега алмый интеккәннән соң, Әнсар Яббарны ычкындырып этеп җибәрде, шул ук уңайга аягына китереп сукты. Яббар үлән арасына барып төште. Әнсар аның өстенә ташланырга дип килгәч, Яббар аңа кушаяклап китереп типте, теге ике-өч адым артка чигеп егылды. Әмма Яббар торып баскан арада, Әнсар инде аягында иде. Алар шактый вакыт бер-берсенә кизәнеп бөтерелә-бөтерелә тирә-юньдәге үләнне таптап бетерделәр. Әнсар Яббарның яңагына суга алды, касыгына да тибәргә өлгерде, Яббар да дошманының маңгаена шәп кенә кундырырга җай тапты. Бермәлне алар бер-берсенә ташланып көрәшергә

тотындылар, җаен китереп, бер-берсенә йодрыклап та биргәләделәр, битләр тырмалып бетте, күлмәкләр ертылды, әллә нинди сүгенү сүзләре яңгырады. Әле берсе, әле икенчесе аста калып әүмәкләшә торгач, тәмам хәлдән тайдылар. Әнсарның егәрлерәк икәнлегенә Яббар тагын бер тапкыр инанды, әмма бу залимгә аяусыз каршы торырга тиеш, бирешергә һич кенә дә исәбе юк иде. Фатыймасы өчен, сөйгәне алдында оятка калмас өчен ул үләргә дә әзер.

Еш-еш сулап, тирләп-пешеп, канга буялып ике дошман әле һаман бер-берсенә ташланырга җай эзләп таптанганда, тау ягыннан кычкырдылар:

– Җитте сезгә!

Егетләр, сугышудан туктап, тавыш килгән якка борылып карадылар. Аларга таба Яббарның абыйсы Сәет, аның артыннан җанфәрманга Фатыйма йөгерә иде.

Чит кешеләр түгел икәнне күргәч, дошманнар янә бер-берсенең бугазына ябышты.

Йөгереп килеп җитүгә, Сәет белән Фатыйма сугышучыларны араларга тотындылар. Фатыйманың йөзе елый-елый шешенеп беткән иде.

– Җитте инде сезгә! – диде ул, елаудан үкерүгә күчеп.

Сәет энесеннән дә калкурак гәүдәле, эре сөякле, таза булмаса да, егәр буенча Әнсардан өстенрәк иде.

– Кодрәтегез шулхәтле ташып торамыни! – дип кычкырды ул, сугыш чукмарларының арасына кереп. Ул башта Әнсарны йолкып атты, аннары энекәшен читкә этеп җибәрде.

Моңарчы бер дә оятка, хурлыкка калуның ни икәнен белмәгән Әнсар Фатыйма каршында мондый кыяфәттә басып торуына чиксез гарьләнде, үзен бик кимсенгән, мыскылланган итеп тойды.

– Ә-ә-ә, абыең килеп җиттеме! – дип үкерде Әнсар, борыныннан аккан канны күлмәгенең ертык җиңе белән сыпырып.

– Мин үзем килдем! – диде Сәет.

Әнсар әле һаман кыҗрап Яббарга якынаерга чамалады, җай чыгу белән тагын берәрне булса да тондырырга ниятләде:

– Без бергә-бер сугышабыз, тыгылма!

Сәет яман усал кыяфәт белән аның юлына аркылы төште һәм баскан җиреннән аз гына да тайпылмады:

– Менә сугышырмын мин сиңа! Син аннан өч яшькә олырак!

– Шулай булгач, буталып йөрмәсен, – диде Әнсар, карлыккан тавышында көч югалганын сизеп. – Маңка!

Яббар абына-сөртенә дошманына таба ыргылды:

– Кем маңка?!

– Җитте инде, булды, тынычлан! – дип, Фатыйма аның беләгенә асылынды.

Сәет энесенә кизәнде:

– Тик кенә тор син дә! – Аннары, Әнсарга якын ук килеп, җөмләләрен теш арасыннан сытып чыгарды: – Син, Әнсар, атаң авыл персидәтеле булгач та бик масайма әле.

– Әтинең ни катнашы бар монда?

– Без бит күршеләр, – дип нотык укырга кереште Сәет. – Нишләп гел сугышырга гына торасың соң син – йә минем белән, йә энекәшем белән.

– Без күршеләр түгел! – дип җикерде Әнсар. – Безнең йортлар арасында тыкрык бар.

– Хәзер инде синең белән энем арасында Фатыйма да бар, шулаймы?!

Әнсар берничә җирдән ертылган күлмәгенә каерылып карыйкарый авыр адымнар белән китеп барды. Ун адым чамасы ары киткәч, ул борылып хәленнән килгәнчә аваз салды:

– Ярар, сөйләшербез әле! Җыен алама! Мескеннәр!

– Бар, бар, юлыңда бул! – дип кычкырды Яббар. – Син ул мескен!

Сәет тагын энесенә кизәнде:

– Тик кенә тор, телеңне тый, сарык бәрәне! – Фатыйманың да монда икәнен искә төшереп, ул энесен читкә йолкып алып китте. – Кил әле монда. Син кайчан кеше көлдерүдән туктыйсың, чукынчык малай?!

Яббар кыз ишетмәслек тавыш белән:

– Кем кеше көлдерә?! – дип, абыйсына каршы әйтте.

Сәет аны җилтерәтеп тагы да арырак алып китте.

– Шул Фатыйма өчен күпме сугышырга була инде сиңа! Хәзер инде Әнсар белән чәкәләшәсең!

– Нишләп соң ул безне гел үчекли, көлә, мыскыл итә?! – дип шыңшыды Яббар, кара янган күз төбен бармагы белән капшап.

– Фатыймага күзе төшкән аның, аңламыйсыңмы әллә?

– Беләм. Фатыйма минеке!

– И-и-и, бичара, синеке... – дип көлемсерәде абыйсы. – Әнсарның кем малае икәнен оныттыңмыни? Әйдә кайтабыз!

– Соңрак кайтырмын.

Сәет җил-җил атлап китеп баргач, Яббар үлән арасына чалкан ятты.

«Югалды кичнең яме. Әнсарга бирешмәдем бирешмәвен, тик менә абыйның килеп тыгылуы хурлык та, хәзер нишлисең инде? Әнсар, кабих, нишләтергә сине?.. Ә икенче караганда, ярый абый килеп чыкты әле. Әнсарны берәр ничек каты гына өркетеп булмас микән? Фатыйманы мин аңа барыбер бирмим. Үлсәм үләм, ләкин Фатыймамны бирмим. Фатыйма үзе дә мине ярата, ул беркайчан Әнсарныкы булмаячак», – дип уйлады Яббар.

Фатыйма аның янына килеп утырды, күрәсең, кыз үзен гаепле сизә, шуңа күрә бер сүз дә катмый, тып-тын гына Яббарга карап тора.

Яббар чыраен сытып аһылдап куйды.

– Авыртамы? – диде кыз, Яббарның шешеп чыккан күз төбенә саклык белән генә бармак очын тидереп.

Яббар кинәт торып утырды:

– Юк! Пүчтәк! Син миңа шуны әйт: ник абыйны чакырдың?

– Синең абыең үзе чишмә янында йөри иде.

– Нишләп йөри иде ул анда?

– Белмим. Ул, мөгаен, Әнсарның безнең арттан киткәнен чамалагандыр да, сугышасыгызны сизенгәндер. – Фатыйма ягымлы итеп елмайды. – Ә син, Яббар, маладис. Мин сине болай ук көчледер дип уйламаган идем. Мин синең белән горурланам. Әнсарга шактый гына биргәнсең.

– Ташла, – диде Яббар, тән сызлавыннан бераз янтаеп.

– Нык авыртамы?

– Юк! – дип кырт кисте Яббар.

Фатыйма, егетнең кәефен күтәрәсе килеп, шаяруга күчте:

– Ярар инде, силсәвит малае Әнсар белән курыкмыйча сугышканны хәзер генә ирененңне асылындырып утырма.

Яббар тешләрен кысып ни әйтергә белми торды:

– Менә шул силсәвит малае булуы ярдәм итә дә инде аңа, – диде ул, бер уч үлән йолкып, беләгендәге юеш дымлы балчык пычрагын сөртеп.

Көтмәгәндә Фатыйма Яббар кырыена тезләнде дә битенең сыдырылган түшеннән йомшак итеп үбеп алды. Сугышканда сер бирмәгән егет бу мәлне югалып калды, кинәт бөтенләй башка халәткә күчүен тойды. Шундук вөҗүде буйлап яңа дулкын йөгерде. Бик бәхетле кеше түгелме соң ул бүген – дошманына бирешмәде, сөйгән кызы янәшәдә, ул аны ярата, әле генә битеннән үпте!

– Мине ачуланмыйсыңмы? – диде кыз.

– Ни өчен ачуланырга тиеш мин сине?! Син үзең миңа үпкәли күрмә шушындый тамаша күрсәткәнебез өчен.

Фатыйма елмаеп карап торды-торды да, тыела алмыйча, болынны яңгыратып көләргә тотынды.

Яббар аның кулын тотып туктатты:

– Ник көләсең?

– Кыяфәтең... – диде Фатыйма, көчкә тыелып.

Кызның күңел шатлыгы шундук йокты – Яббар да пырхылдап көлеп җибәрде:

– Синең аркада.

– Сугышма. Мин сиңа сугышырга кушмыйм бит! Кыяфәте! Уф, үләм!

Егет белән кыз ямь-яшел болын түшәгендә ауный-ауный рәхәтләнеп көлгәндә, инде караңгы төшеп килә иде.

3

Нәгыйм агай ишегалды уртасындагы арбаны ике куллап селкетеп карады. Соңгы вакытта какчаланган эре сөякле зур гәүдәсен авырлык белән янтайтып аксый-аксый, аның тирәли бер әйләнеп чыкты. Әллә арбаның төзеклеге канәгатьләнерлек түгелгәме, әллә аяк сызлавы көчәйгәннәнме, әллә кече улының сугышып кайту-

ыннанмы аның бүген бөтенләй кәефе юк иде. Барысы бергә җыеладыр инде, мөгаен. Хатыны Әминәнең койма буенда вакытлыча урнаштырылган иске өстәлгә тагарак куеп шалтор-шолтыр савыт-саба юуы да ачуын китерде.

Кадалып китсен арбасы, улының сугышып кайтуында да баш бетәрлек фаҗига юк, яшь чакта кем төрткәләшми инде. Менә печән өсте алдыннан гына аяк сызламасын иде ул. Бу авырту да мәңгелек түгелдер, анысы да бер басылыр. Әчтә, үзәктә бәгырьгә таш асып куйганнармыни – нишләп болай авыр соң, бу кадәрле үк газапланырлык кайгы-хәсрәт тә юк лабаса.

Тән сызлавы көн бозылуга була, диләр, ә җан ярасы нинди давылга?..

Капка киерелеп ачылгач, Әминә сискәнеп китте. Тыкрык башындагы уң як күршесе Зәкия икән.

Озын гәүдәсен яшь чактан ук кечерәйтебрәк күрсәтәсе килгәннән бераз бөкрәеп йөрүче, кара-сары чырайлы, күп белүче, күп күрүче Зәкия гел шулай тота да килеп керә инде ул.

– Саумысыз! – дип исәнләште күрше хатын, килеп кергән уңайга Нәгыймгә таба кызу-кызу атлап, ләкин барып җитмәде, нәрсәнедер искә төшергәндәй, борылып, койма буена Әминә янына юнәлде.

– Аллага шөкер, Зәкия, үзең саумы! – диде Әминә, күршесенең абаланулы кыяфәтеннән сәерсенебрәк.

– Берәр чүлмәгеңне биреп тормассыңмы икән, – диде Зәкия, яшькелт күзләрен як-якка йөгертеп. – Бер кушуч маема урын табалмыйм.

– Бирәм, күрше, бирәм, – диде Әминә, йомышның гадилегенә һәм гадәтилегенә куанып. – Безнең барыбер бу арада маебыз да юк, ач без хәзер. – Тастымалы белән күршесенә бирәсе чүлмәкне сөртә-сөртә өстәп куйды: – Нишләргә дә белгән юк.

Зәкия, арба тирәсендә кайнашучы Нәгыймгә карап:

– Тормышлар рәтләнер анысы... – диде. Аннары, Нәгыйм дә ишетсен өчен, кычкырыбрак сөйләшергә тотынды: – Мин шуны әйтмәкче идем әле. Әминә, син ачуланма... Синең малайларың... Алар икәүләшеп минем бердәнбер улым Әнсарны кыйныйлар.

Әминә, чүлмәкне өстәлгә куеп, калтырана башлаган кулларын тастымалга сөртте.

– Сугышуын сугышалардыр, ә менә минем улларымның синең Әнсарыңны кыйнауларына ышанмыйм, – диде ул. – Авыл җитәкчесе Хәлиулла малаен ничек курыкмыйча кыйнасыннар ди алар!

Зәкия ата кешегә таба борылды.

– Хәлиулла малае дип тормыйлар шул менә, – диде ул, иреннәрен юкартып.

Әминә, ярдәм сорагандай, иренә карап, тыныч кына:

– Әнсар үзе гаепле түгел микән соң? – дип куйды.

– Минем улым әйбәт тәрбия алган бала, кешегә беренче булып кул күтәрә торганнардан түгел, – дип ярып салды күрше хатын.

Әминә ни әйтергә дә белмичә иренә карады, Нәгыйм үзе исә, дөньядан ваз кичкәндәй, арба тирәсендә мәш килде, әйтерсең лә аңа малайларның сугышуы гына түгел, аналарның хафаланулары да тәэсир итми, ник шунда ике хатын үзләре бер-берсен тукмакларга тотынмыйлар.

Әминә Зәкиянең әрләвеннән, шуның белән бергә иренең битарафлыгыннан аптырап, үзе дә сизмәстән, инде күптән юып сөртеп куелган савытларны яңадан сулы тагаракка тутырырга тотынды:

– Ничек инде авыл җитәкчесенең малаена беренче булып минем малайлар кул күтәрсен?!

Зәкия бераз сүрелде шикелле, әмма тавышында ачуы бар иде әле:

– Бүтән кабатланмасын өчен әйтәм, Әминә. Үпкәләмә... – Шуннан соң ул, инде капка янына җиткәч, Нәгыйм ишетми калмаслык итеп кычкырып әйтте: – Малайларыгызны тыегыз!

Аның артыннан капка шапылдап ябылгач, Әминә:

– Чүлмәкне оныттың бит, – дип, койма артына эндәште.

Койманың теге ягыннан Зәкиянең:

– Кирәк түгел! – дигәне ишетелде.

Нәгыйм хатыны янына килде.

– Зәкия ник кергән? – диде ул, ике хатынның сөйләшкәнен ишетмәгәнгә сабышып.

– Чүлмәк сорап, – диде Әминә, ябылган капкага карап каткан килеш.

Нәгыймнең башын җүләргә салып, ишетмәгән булып кылануы йөрәк сыкравын көчәйтте. Әмма ир кешегә тавыш күтәрергә күнекмәгән хатын, бөтен ачынуын эчендә саклап, тагын үз эшенә тотынды.

– Чүлмәк сораган иде түгелме соң?

– Кире уйлады, ахрысы, кирәк түгел, дип чыгып китте, – диде Әминә боек кына.

Хатыны тагарактагы суны бакча ягына барып түгеп килгәннән соң, Нәгыйм:

– Ашарга нәрсә әтмәллисең соң инде бүген? – дип сорады.

– Берни калмады, – диде Әминә кайгылы тавыш белән. – Нишләргә дә белмим.

– Умачлык та он юкмы?

– Юк.

Нәгыйм:

– Берәрсеннән алып торырга кирәк, – дип, аксый-аксый арбасына таба юнәлде.

– Тагын кешегә ялынабызмы? – дип уйга калды Әминә.

– Сәвит влачы кырып-себереп талагач, хәтта хәер сорашсак та бернинди оятын күрмим! – диде Нәгыйм нәфрәт белән. Аның чыгып торган яңак сөякләре агарып китте. Ап-ак чәчле кешенең чырае агару нык тәэсир итә, бер кешенең кыяфәтендә ак төснең күзгә күренеп күбәюе аңлатып булмый торган көчле тәэссоратка ия иде.

Әминә, котсыз калып, койма ярыгыннан урам якка карап алды:
– Кычкырып әйтмә инде, берәрсе ишетсә...

Нәгыйм арбада яткан чүкечкә үрелде, аны әйләндергәләп карады да шакылдатып кире урынына ташлады:

– Ач булсалар да, малайларың куәтләрен кая куярга белмиләр, сугышып йөриләр. Әнә Зәкияләрнең ашарларына бар! Чүлмәк сорап кергән! – Шуның өстенә ул хатыны ишетмәслек кенә итеп мыңгырдап сүгенеп куйды. Әйтер сүзе беткәч, кызулык белән арба тирәли бер әйләнеп чыкты да хәл җыярга лапас авызы янындагы бүкәнгә барып утырды.

Шулчакта сарай артыннан, үрә башлаган чыбыркысын тотып, Яббар пәйда булды. Нигез буендагы бүрәнәгә утырып, торымнан торымга борынын лыштырдатып тартып, ул чыбыркысын үрергә тотынды.

Нәгыйм улы янына килде, аның тырышып чыбыркысы белән мәшгуль булуын күзәтеп торды.

– Күз төпләрең шәмәхәме? – диде ул усал тавыш белән.

Яббар дәшмәде.

– Хәлиулла малаеның да яңагы шешкән, маңгае сыдырылган. Бусы миннән! – дип, улының такыр башына чап иттереп учы белән сугып җибәрде.

Яббар чак кына арткарак чайкалып куйды, бөреште, тагын сукмагае дип, муенын ике иңбашына батырыбрак торды, бермәл шул халәттә утырганнан соң, башын аска иеп, чыбыркы үрүен дәвам итте.

Әминә инде сугышып болай да шактый җәрәхәтләр алган улын кызганып куйды, иренең игътибарын җәлеп итеп, улына бүтән суктырмас өчен эндәште:

– Атасы, Сәет нишләп һаман кайтмый икән?

Нәгыйм кече улына тагын бер яман караш ташлады да:

– Кайтыр, – дип, аксый-аксый ишегалды буйлап атлады.

Ул күрмәгәндә, Әминә Яббарга елмайды. Хәер, аның әнкәсе шундый мөлаем кеше, ул һәрвакыт елмайган төсле. Аның йөзендәге күз-борын-авыз сызыклары табигатьтән матур һәм дөрес сызылган, мөлаемлыгы күзләренең һәр карашында, күкрәгеннән чыккан һәр сулуында бар.

Изге кеше бу әнкәй! Нык ярата ул Яббарны. Кече бала булганга һәм үзенә охшаганга күрә шулай якындыр инде ул аңа. Төс-битне Яббар әнкәсеннән алган – кара чәче, үсә төшкәч, чигә турыларында бераз бөдрәләнә башлый, кысыграк күзле.

Изге кеше бу әнкәй!

– Нәсимәне озата китмәде микән? – диде Әминә, эшен тәмамлап.

– Озатса да, Казанның үзенә кадәр үк китмәгәндер әле.

– Ышан аңа, – дигән булды Яббар, сүз башка якка борылганга куанып.

Нәгыйм:

– Олылар сүзенә тыгылма! – дип җикеренеп малаена тагын берәрне барып чәпәмәкче иде, кире уйлады, ахрысы, бары тик йодрыгын селкеп өстәп куйды: – Артыңны кысып тик кенә утыр, мөртәт!

Әнкәсе бигрәкләр дә акыллы, йомшак күңелле кеше шул аның, әнә тагын атасының игътибарын икенчегә юнәлтте:

– Кашаф мәрхүм кызының буйга җиткәнен дә күрә алмады.

– Әйтмә дә-ә-ә, – дип, сарай почмагына сөялде Нәгыйм. – Вафатына ике елдан артык вакыт үтеп китте инде.

– Шул салкын тигәннән киттемени соң ул?

– Үпкә бик нәзберек нәрсә бит. Үпкәдән йөрәгенә бәргәндер.

Әминә, тагаракны чирәмгә куеп, өстәлдәге юешне чүпрәк белән сөртеп алды:

– Ярый әле кызы Нәсимә бик әдәпле, акыллы булып җитлегеп килә. Казанда укырга да керсә, анасы Тәслимәгә олы куаныч, зур ярдәм булачак, Аллаһы боерса.

– Яшерен-батырын түгел, мин үзем Сәетебезнең шул Нәсимә белән чуалуына каршы, – диде Нәгыйм, хатынына таба килеп.

– И-и-и, бик әйбәт кыз бит. Тәрбияле, әдәпле нәселдән. Аның курчак кебек чибәрлеге түгел, күңел матурлыгы кирәк.

– Анысы да дөрес, – диде Нәгыйм. – Әнә чибәр кыз артыннан йөреп, кече улыңның күз төпләре кара яна.

Яббар алга табарак иелә төште, әйтерсең лә аңа таба очкан нindidер бер авыр нәрсәнең баш очыннан гына үтүен теләде.

Әминә улына карап ягымлы тавыш белән:

– Фатыйма да бик әйбәт кыз, – дип куйды.

Әнкәсенең бу сүзе Яббарның йөрәгенә сары май булып ятты. Аның йөзе яктырып китте, күз алдына Фатыйманың зифа буйсыны, көләч йөзе килеп басты.

– Атасы гына холыксыз, – диде Нәгыйм салкын тавыш белән.

Әминә, эчтән генә «Синең үзеңнең дә холкың алама» дип уйласа да, иренә исә:

– Бөтен кеше дә бертөсле әйбәт булмый инде, – дип җавап кайтарды.

Нәгыймне, дөресен әйткәндә, Фатыйманың төпчек кыз булуы күбрәк сагайта иде. Ата-анасының назыннан башка тагын абыйсы тарафыннан иркәләү татып үскән кыз көйсезрәк була ул. Моны авылның кеменнән сорасаң да, шулай җавап бирер.

Нәгыйм улы янына килеп утырды, сызлаудан туктамаган аягын ике куллап угалап алды.

– Улым, шуны әйтәсем килә: влачтагы кеше малае белән сугышып ахыры начар тәмамланмагае.

– Әти, ярар инде, – диде Яббар, тыңкышланып.

Нәгыйм тагын кыза башлады:

– Ярар түгел! Үз тиңеңне эзләргә кирәк. Фатыйманың атаанасы бай, хәлле кешеләр. Ул кызга байтак егетләрнең күзе төшеп йөри... Үзеңнең көчеңнән килгәнне чамаларга кирәк.

Әминә өйалды ишеген ачкан иде инде, иренең соңгы сүзләрен ишеткәч ишекне япты да улының икенче ягына килеп утырды:

– Атасы, ә безнең Яббарыбыз башкалардан ким-хурмыни?

– Мин әйткәндә тыгылмый тор! – дип җикерде Нәгыйм хатынына. – Хәлиулла малае белән сугышканы өчен берәр җәза бирми калмаслар әле менә. – Аннары тыныч кына әйтеп куйды: – Ярар, унсигез яшьтәге гыйшык-мыйшыклар үтә ул.

Атасының соңгы җөмләсе Яббарга ачулануга, хәтта сугуга караганда да авыррак тәэсир итте, ул капылт кына торды да ишегалды уртасына басты, үзәгенә җыелган барлык үпкә-нәфрәтләрен җыеп, кизәнепме-кизәнеп чыбыркысын шартлатып карады. Шуннан соң:

– Булган бу! – дип куйды.

Чыбыркы шартлавыннан атасы да, әнкәсе дә сискәнеп киттеләр. Әминәнең, курыкса да, йөзе яктырып куйды, газиз баласына соклањып, яратып карады. Нәгыйм исә:

– Ишегалдында шартлатма, тиле! – дип бакырды, чыбыркы тавышыннан куркып сискәнгәне өчен ачуы килеп.

Капка кинәт гадәттәгедән кискен киерелеп ачылды. Узышчыдай тирләп-бөртеп Сәет килеп кергәч, өчесе дә шаңкаеп калдылар. Аның өйалды янында торган чиләк төбендәге суны күтәреп, голт-голт итеп өңере, изүе буйлап агыза-агыза су эчкәнен көтеп торганнан соң, Әминә урыныннан кузгалып сыкрап куйды:

– И Ходаем, бер-бер хәл булмагандыр бит?

Сәет, тыны кабып, сүзен әйталмый торды. Ниһаять, тирән сулыш алып, чиләкне җиргә куйды:

– Бер-бер хәл генә түгел монда! Хәлләр яман!

Нәгыйм, бүрәнәдә утырган килеш:

– Нәрсә бар?! – дип сорады. – Син дә берәрсе белән тәпәләштеңме әллә?!

– Сугыш башланган! – диде Сәет, сугышның нәрсә икәнен үзе татыган атасына карап.

Нәгыйм торып басты, шундук йөзеннән төс качты:

– Нинди сугыш?

– Герман сугыш башлаган, – диде Сәет, көлмәгән төймәләп.

– Кем әйтте? – дип төпченде Нәгыйм.

Сәет җиңе белән юеш маңгаен сыпырды:

– Радиодан, Мәскәүдән әйткәннәр. Гитлер сугыш башлаган.

– Нәрсә була инде хәзер? – диде Әминә, әле иренә, әле яман хәбәр алып кайткан олы улына карап.

– Сугыш башлангач хәлләр мөшкел инде ул, – диде Нәгыйм, бу яңалыкның чынлыгына әле барыбер тәгаен үк ышанасы килмичә.

Әминә йорт почмагы белән койма арасындагы ачыклыктан килүче кешене абайлады:

– Хәлиулла килә. Безгә, ахрысы.

Нәгыйм Яббарга ямьсез итеп карап куйды:

– Әйттем мин сиңа, улы белән сугышканың өчен болай гына калдырмаслар дип.

– Саулармы! – дип исәнләште Хәлиулла, капкадан керүгә үк. Аның кыяфәте бик борчулы иде.

– Аллага шөкер, күрше, – дип каршылады аны Нәгыйм.

Әминә тиз генә өйгә кереп китүне хуп күрде. Сәет энесен кул ишарәсе белән әйдәп урамга алып чыгып китте.

Хәлиулла тиз генә чыгып шылган егетләр артыннан карап калды, аннары барып арбага җилкәсе белән терәлде:

– Хәлләр начар бит, Нәгыйм күрше.

– Нишлик соң? – диде Нәгыйм, аксый-аксый күршесенә якынрак килеп.

– Бернишли алмыйбыз, көтәбез инде нәрсә килеп чыгасын.

Нәгыйм күршесенең ни турында сөйләшергә җыенуын әле төшенмәде, кичә малайларның бәргәләшүе хафага салганмы аны, әллә сугыш башланган дигән хәбәрме?

– Аллага тапшырдык инде, – диде ул, Хәлиуллага түгел, аның баш очыннан өскәрәк – лапас түбәсенә карап.

– Син теге Герман сугышында катнашкан кеше, шуңа күрә сиңа керәсе иттем, – диде авыл советы рәисе. – Ни уйлыйсың, нимес бу юлысы ничегрәк булыр икән?

Нәгыйм авыр сулап куйды:

– Нимес көчле ул.

– Бездән дә көчлерәк микәнни?

Нәгыйм, авыл җитәкчесенең чыраена туп-туры карап:

– Без ач-ялангач, – диде. – Теге сугышта да ачлы-туклы идек.

– Аның каравы бездә армия, корал көчле. Син артык кискен бәя бирәсең, күрше.

– Алайса, ник сорыйсың?

– Кемнән сорыйм инде тагын. Тик менә бу сүзләреңне башка кешегә әйтмә, яме. Алып китүләре ихтимал.

– Син бит монда влач, – диде Нәгыйм коры гына. – Син монда иң куркыныч кеше.

– Алай димә, күрше!

– Кешенең актык ризыгын талап алып чыгучыларның берсе син бит.

– Мин – коммунист. Миңа өстән кушалар. Безнең ачлык вакытлыча ул. Без – яңа тормыш, яңа строй төзергә тотынган халык.

– Нимес синең яңа тормыш төзергә маташуыңа төкерә ул, – диде Нәгыйм, сөйләшүдән туеп.

Хәлиулла күршесенең кирелеген яхшы белгәнгә күрә сүз көрәштереп тормады.

– Ярый, киттем мин, – дип, капкага таба юнәлде. Капканы ачар алдыннан борылып сорап куйды: – Күрше, озакка булыр микән бу сугыш?

– Шайтан белгәнме инде аны, – дип җавап бирде Нәгыйм.

4

Авыл халкы телендә гел сугыш кына хәзер. Әтиләр, абыйлар фронтка китә тордылар. Уртак кайгы, уртак бәла белән яшәүче авылдашлар Совет Армиясе өчен бар көчләрен куеп эшкә җигелделәр. Кызылъярдан егерме дүрт атны фронт өчен алып киткәч, хәлләр тагы да авырайды. Атбагар Ибраһимның үзен дә алдылар сугышка. «Ат добыры»нда калган алты ат белән унбер колынны карарга Нәгыймне билгеләделәр. Аның кебек сугышка яраксызлар, хатын-кыз һәм үсмерләр җилкәсенә төште фронт өчен дәүләт таләп иткән фәрманнарны үтәү. Армиягә икмәк кирәк, икмәк!

Бер караңгыдан икенче караңгыга, көне-төне бил бөкте авыл халкы. Иген амбарларында, фермада, басу түрендә, ындыр табагында, әвендә, сушилкада, алачыкта эш берөзлексез кайнап торды.

Көндез дә, төнлә дә кул арбалары белән көлтә ташып хәлдән тайган үсмерләр, билләрен дә турайта алмас дәрәҗәгә җитеп борчак эскертләгән аналар яуга киткән ир-атка авыррактыр, аларның өлеше ачырактыр дигән уй белән яшәделәр, эшләделәр һәм, язмыш биргән сынау никадәре генә күтәргесез булмасын, барысына да түзәргә әзер иделәр.

Сугыш бик күп нәрсәне, бик күп төшенчәләрне, бик күп кешеләрне тигезләп ташлады.

Сугышны үзләре күреп, кан коеп кайткан агайлар гына түгел, аны ата-бабаларының бәяннарыннан белүчеләр дә илгә нинди афәт килгәнен аңлыйлар иде.

Кызылъярдан сугышка китүче икенче төркемдә Сәет белән Әнсар да бар иде.

Чишмә тыкрыгының ян-як күршеләре яуга китеп баручы уллары Сәет белән Әнсарны йортлары тирәсендә тоткарларга тырышып кат-кат кирәкмәгән сораулар бирделәр, биштәрләрен әллә ничә мәртәбә капшап-актарып, үгет-нәсыйхәт укып вакытны сузу сәбәпле, авыл үзәгенә таба атларга һаман ашыкмадылар.

– Улым, теләсә кайсы пуля астына башыңны тыкма, – диде Нәгыйм, Сәет ишетерлек кенә итеп. – Саграк булырга тырыш.

– Ярар, – дип баш какты Сәет, пулялар астында үзен һич тә күз алдына китерә алмаган килеш.

Әминә улының беләгендәге салам чүпләрен кулы белән сак кына сыпырып төшерде:

– Исән-сау әйләнеп кайт, улым. Исәнлегеңне көн саен Ходайдан сорармын.

– Намаз укыган саен сора, әнкәй, – диде моңарчы шактый вакыт сүз катмаган Сәет.

– Ярар, улым, ярар, – диде ана, еламсырап. – Хат яз. Гел язып тор.

Әнсар, Әминә янына килеп, иңбашына аскан биштәрен калкытып җайлабрак куйды да:

– Әминә апа, гаепләрем булса, гафу үтенәм, яхшы итеп искә алырга тырышыгыз инде, – диде.

– Нинди гаепләр инде ул, Әнсар! – диде Әминә, күрше егетне аркасыннан сөеп.

Зәкиянең дә улына башкалар әйтә торган гап-гади теләге генә бар иде:

– Улым, үзеңне сакла.

– Ярар, әнкәй, ярар, – диде Әнсар, ата-ананы барыбер тынычландыра алмый торган шушы сүзләрне инде әллә ничә тапкыр кабатлап.

– Хат яз, буш вакытың чыгу белән яз.

– Язармын, әнкәй. Исән-сау торыгыз. Кайгырмагыз. Тиздән кайтып җитәрбез. Чирләмәгез.

– Ярый әле ике күрше бергә китәләр, – диде Нәгыйм Хәлиуллага.

– Әйе, бер-беренә терәк булып барырлар, – дип баш какты Хәлиулла.

Сәет, аталарының сүзен ишетеп:

– Фронтта да бергә булсак иде, – дип куйды.

Яббарның Сәет абыйсы белән ыгы-зыгыда түгел, аерым, җитди итеп, егетләрчә хушлашасы килде, шуңа күрә ул олылар тынычрак калган мәлне чамалап, бөтенләй үзенә хас булмаган көр тавыш белән:

– Абый, сау бул! – диде.

Абыйсы аның кулын каты иттереп кысты:

– Хуш, энекәш! – Шуннан соң, елмаеп, тавышын башкалар ишетмәслек итеп кенә өстәп куйды: – Фатыйманы ычкындырма! Якларга мин юк хәзер.

– Әнсар абый да китә бит, – дип, сабыйларча шатлык белән әйтеп ташлады Яббар.

– Авылда Әнсардан башка да әллә нинди бөркетләр бар, – диде Сәет, күзләрен челәйтеп. – Барысы да сугышка китеп бетмәсләр.

Яббар кәпрәебрәк:

– Минем өчен борчылма, абый, – дигәч, шаяру тәмамланды.

– Энекәш, хуҗалыктагы эшнең авыры сиңа төшәчәк инде, – диде Сәет, кулын Яббарның иңенә куеп.

– Түзәрбез, – диде Яббар җитди кыяфәт белән. – Син дә тиздән әйләнеп кайтырсың, Алла боерса.

Абыйсы тагы да олыгаеп киткән кебек булды. Болай да зур һәм абруйлы иде аның өчен абыйсы, хәзер исә яуга китеп баручы олпат баһадирга әйләнде.

Шуның белән беррәттән Яббар шаккатып үзенә яңалык ачкандай булды – абыйсы әтиләренә нык охшаган икән. Нишләп элегрәк болай аермачык күренмәгән икән? «Тач әти икән абыем – шундый ук эре сөякле, зур гәүдәле, гәүдә ныклыгы аркасында ябыклыгы да күзгә ташланып тормый. Сикертмәле озынча борыны белән шакмаклы олы иягенә хәтле нәкъ әти инде», – дип уйлады ул.

– Нәрсә уйга калдың? – диде аңа Сәет, елмаеп.
– Сугышны күз алдына китерә алмыйм, – дигән булды энесе.
– Аны күз алдыңа китерергә маташма. Без барып күрсәк, шул җиткән.
Урамнар кисешкән үзәктән аларга таба кычкыра-кычкыра йөгерүче малайларны күреп, тизрәк урам уртасына юнәлергә кирәклекне аңладылар.
– Әйдәгез, безне ашыктыралар, ахрысы, – диде Әнсар.
Яббар Әнсар янына килеп басты һәм йөзенә карамас өчен башын аска иеп:
– Сау бул, Әнсар абый! – диде. – Исән-сау әйләнеп кайт!
– Кайтырбыз! – диде Әнсар, аның кулын кысып. – Хуш!
Алар, җыйнаулашып, авыл үзәгенә табан киттеләр.
Хәлиулла, Әнсар белән янәшә атлаганда:
– Бик салынып төштең шикелле, улым, – дип канәгатьсезлек белдерде. – Бәлки әле, сез барып җиткәнче сугышы да бетәр.
Әнсар исә, як-ягына каранып:
– Фатыйма күренми, – дип куйды.
– Җыела торган урында көтәдер. – Хәлиулла башкалар ишетми микән дип артына борылып карады. – Озатырга вәгъдәсе булмагандыр бит? Аның күңеле Яббарга ятыш түгелме соң? Әйдә, ярар, синең күзең төшкән дип, кызлар артыңнан йөгереп килми инде алар. Тапканың кайгырыр сәбәп. Үзе сугышка китеп бара, үзе... Билгеле, мин-минлегең үзебезнең нәселнеке ансы... Ярый, алданрак барыйм әле, мин бит инде күптән шунда булырга тиеш. – Шул сүзләре белән ул тиз-тиз атлап төркемнән аерылды.
Авыл үзәгенә җитүгә, Зәкия иренә килеп эндәште:
– Әнсарыбыз тәмам котсыз калды, балакаем.
Хәлиулла кул селтәде:
– Сугышка китәм дип кайгырмый ул, әнә теге Яббар белән йөрүче Фатыйманың килмәвенә борчыла.
– Килмәсә ни! – диде Зәкия ачу белән. – Кирәге барие. Кыз ошый дип инде... Йөрсен шул Яббары белән. Кем кызы әле ул шулхәтле!
Кузгалыр вакыт җитте. Сугышка китүчеләрне Казанга кадәр озатырга теләүчеләр дә шактый булып чыкты. Араларында Яббар да бар иде.
Гармун сыздырып уйнап җибәрде. Җанны телгәләп җыр яңгырады.

Әнкәй мине тапкан-баккан,
Ак биләүгә биләгән лә;
Гомере булсын дип теләгән,
Бәхете булсын димәгән.

Биек тауның башларыннан
Герман таяк ташлаган ла;
Без бәхетсез бала үскәч,
Герман сугыш башлаган.

Ике ана – Зәкия белән Әминә – китүчеләр күздән югалып, озатучылар таралып беткәч тә әле шактый вакыт авыл башында басып тордылар.

– Син мине гафу ит инде, Әминә, – диде Зәкия, еламсырап.

– Ни өчен?

– Улларыбыз сугышканга ачуланып кергәнем өчен.

Әминә күз яше аша елмайды:

– И-и-и, Зәкия, никләр ачуланыйм. Берүк исән булсыннар. Үзара сугышулары гаеп түгел инде – малай-шалай бит. Менә утлы сугышка барып керүләре яман.

– Әйтмә дә инде, әйтмә дә.

– Берүк исән-сау гына әйләнеп кайтсыннар, Ярабби!

Көнбатыштан искән салкын җил ике ананы тизрәк авылга куып кертергә теләгәндәй кыжрап-кыжрап исте, отыры ул тагы да көчәйде, вак кына яңгыр сибәләгәннән соң, кар бөртекләренең уйнаклаганы күренде. Бу – табигатьнең көз кышка таба авышканда котылгысыз кабатлана торган кар күрсәтү мәле иде. Әйтерсең лә дөньяда миллионлаган корбан дәгъвалаган мәхшәр башланмаган һәм табигатьтә һәрнәрсә үз урынында калган да үз көенә ошбу яшәештә катнаша.

5

Кызылъяр авылына беренче похоронка кырык беренче елның августында ук килеп җитте. Габдрахман абыйның уртанчы улы геройларча һәлак булган дип авыл халкы чат саен, адым саен сөйләшкәндә, көзгә таба тагын алты похоронка өстәлде. Күп тә үтми, беренче яралылар да кайта башлады.

...1942 елның гыйнварында Кызылъярдан тагын сигез кешене сугышка алу фәрманы килде.

– Менә, улым, сиңа да чират җитте, – диде кече улы Яббарны берәр кайчан яуга озатасын күз алдына да китерә алмаган ана.

Инде күптән киенеп куйган булсалар да, өй җылысын ташлап чыгып китәргә ашыкмадылар.

Нәгыйм бүреген инде әллә ничә кат киеп, янә салып, маңгаендагы тирен шул бүреге белән сыпырды:

– Яшь булсаң да йөзгә кызыллык китермәссең дип ышанам. – Аның тавышындагы кырыслык гадәттәгедән дә көчлерәк яңгырады. Унсигез яшьлек малай белән фронтка киткәндә шулайрак сөйләшү фәтвалырактыр дип уйлады, ахрысы.

– Борчылма, әти, – диде Яббар, никтер атасына түгел, анасына төбәлеп.

Нәгыйм торып тәрзәдән тышка карады:

– Әнә Сәет абыең нинди хатлар яза. Коточкыч сугыш! Мәхшәр! Сиңа унсигез генә бит әле, шул яшьтән чын солдат бул инде!

– Бәлки, абыеңны очратырсың, – дип елмаерга тырышты Әминә, шәлен ике куллап яңак турыннан рәтләп.

Нәгыйм сәкегә утырып баш чайкады:

– Ай-һай, көньяктан төньякка сузылган фронтларда ничекләр очрашмак кирәк?! Әле бит бергә киткән Сәет белән Әнсар да төрле фронтларга эләккәннәр.

Яббар атасының күкрәк турысын угалап утыруын күреп, аны йөрәге авырткан килеш районга кадәр үк озата бармаска үгетләп күндерде.

Ата-аналары, авылдашлары белән хушлашканнан соң, никрутлар, атлы чаналарга утырып, район үзәгенә юл тоттылар. Яббар Фатыйма белән бергә-бер калып хушлашырга өлгерде. Аларның каравыл йорты артында күзгә-күз очрашуларын авылдашлар күрми калмадылар, әлбәттә. Авылдашлардан читенсенмичә Яббар кызны кат-кат кысып кочаклады, кып-кызыл битеннән кайнар иреннәре белән үпте. Бу минутларда Яббар үзенең яшьлеге, дөресрәге, балалыгы белән сугышка китеп баруын да онытты. Бәхетле иде ул бу мизгелләрдә. Дөнья өстенә афәт килсә дә, барыбер бәхетле иде. Чөнки аның Фатыймасы бар. Үлем дә, башка төрле фаҗигаләр дә, хәсрәт-кайгылар да аларны читләтеп узар кебек тоелды. Башкалар үлеп беткән сурәттә дә, ул – унсигез яшьлек малай – исән калыр кебек, чөнки аның Фатыймасы бар, Фатыйма белән гомер юлыннан кулга-кул тотышып атлыйсы бар, бәхетле гаилә корып балалар үстерәсе бар!

«Хушыгыз! Хуш, әти! Хуш, әнкәй! Хуш, Фатыйма! Дошманны тиздән җиңеп кайтырбыз!»

Атлы чаналар бормалы юлдан китеп күздән югалгач, Әминә сыктанып әйтеп куйды:

– Туйганчы ипи дә ашамаган балаларны сугышка керт инде, ә!

– Сугыш ул сорап тормый – ачмы син, тукмы! – диде Нәгыйм, гадәттәгечә кырыслык белән. – Сугыш ул үзе ач – аның үзенә ит кирәк. Кеше ите.

Әминә, иренең ачулануына игътибар бирмичә:

– Тамаклары туйганчы ашамаган малайларны ничек сугышка кертмәк кирәк! – дип кат-кат кабатлады. – Яббар бөтенләй бала гына бит әле ул.

Дөньяның кай тарафыннандыр җыр ишетелде.

Каерма, җил, каерма, җил,
Каерма җилкапкамны;
Кайгыдан боек өемне
Кайлардан җил тапкандыр.

Аерма, җил, аерма, җил,
Аерма уйларымнан;
Аркылама, аралама,
Арынмам бу зарымнан.

Кайгырма, җил, кайгырма, җил,
Кайгырганыңны күрәм;
Җилкапкамны каера җил,
Мин кайгырганга күрә.

6

1943 елның кышы иртәрәк килде шикелле. Әллә сугыш кайгысы тәэсирендә көннәр кинәт салкынайдымы, әллә инде табигать үзе тизрәк дөньяларны ак төс белән капларга ашыктымы? Бу ак төсләр ачлыкны, җаннардагы шомны, куркуны ничек бассын икән?! Әллә нинди зәһәр бураннар дулап, похоронкаларны күз күрмәс тарафларга алып очырган суррәттә дә, кайгы-хәсрәтне нинди давыллар бәгырьләрдән кубарып алсын икән?

Ел фасылының кодрәтеннән киләме соң кайгыны җиңү? Шул ук вакытта аз-маз гына, ара-тирә килгән шатлыкларга да комачаулый алмый табигать алмашынулары. Өметне бит аны тыю мөмкин түгел!

Кышның чалт аяз көнендә, күктә кояш балкып, җир йөзендә ак төс җемелдәгәндә кайдадыр ап-ак карлар канга, корымга, пычракка буяладыр дип ничекләр ышанмак кирәк?!

Әминә, көянтә-чиләк асып, акрын гына адымнар белән су алып кайтып килгәндә, тыкрык башында Фатыйма күренде. Көянтәсенең баш-башындагы чиләкләрен чайкалмасынга куллары белән тотып, кыз шулай ук уйчанланып кына атлый иде. Әминәне күргәч, Фатыйма каушады, салкыннан алсуланган битенең кызыллыгы кинәт куерды. Ул тар сукмакта юл биреп читкәрәк тайпылды. Аннан:

– Исәнме, Әминә апа! – диде оялып кына.

– Исәнме, кызым! – Әминә кызның уңайсызлануын абайласа да, аны туктатып сөйләшәсе килде. – Туктале, кызым.

– Нәрсә, Әминә апа? – диде Фатыйма, башын аска иеп кенә.

– Мин беләм, Яббар сиңа хатлар яза.

Фатыйманың тавышы калтырап чыкты:

– Яза, Әминә апа.

– Син җавап хатлары яз инде, кызым, яме. Вакытың булган саен яз, яме, балакаем.

Фатыйма кыюланып башын күтәрде.

– Мин язам, Әминә апа, – диде ул, туп-туры карап. – Язам.

– Рәхмәт, кызым!

Бу кадәре ягымлылыктан, җылы караштан кызның йөрәге ярсып тибә башлады. Үз кызына карагандай карый аңа бу Әминә апа. Шундый якын, кадерле кеше бит ул. Яббарның анасы бит ул. Яббар әнисенә охшаган. Күз карашы да әнисенеке. Шунысы гаҗәп: Фатыйма үзе дә Әминәгә охшаган ич – кысыграк күзле, түгәрәк йөзле, җыйнак борыны тулы иреннәре өстендә шулкадәре «дөрес» һәм матур урнашкан. Шуңа күрә дә бик күпләрнең «Сез Яббар белән пар килгәнсез, хәтта төс-битләрегез дә охшаш» дигәннәре бар.

– Ярый, Әминә апа, мин суны алып кайтып китим инде, – диде Фатыйма, чак кына ишетелерлек итеп. – Өйдә эш күп.

Әминә көянтәсен җайлар өчен иңбашын калкытыбрак куйды:

– Бар, кызым, бар.

Фатыйма тиз-тиз атлап тыкрыктан төшеп киткәч тә, Әминә әле шактый вакыт аның артыннан елмаеп карап торды. Бер урында кыз таеп китеп чак кына егылмый калды һәм, Әминәнең әле һаман карап торуын сизеп, борылып карады.

Шуннан соң гына Әминә өйгә таба атлады. Бите буйлап тәгәрәп төшеп авыз читендә тоз тәме тараткан күз яше өмет яшәп яткан күңелдән саркып чыккан иде. Капкадан чыгып килүче ире елаганын күрмәсен өчен, ул тиз генә өйгә кереп китәргә ашыкты.

Иртәнге якта күрәгәннән соң кар яумады диярлек, болай аз гына уйнаклап алды. Шулай да Нәгыйм агач көрәген тотып урамга чыкты, кыймылдыйсы килә иде аның, хәрәкәт кирәк, хәрәкәт, тик торганда уйлар ныграк бимазалый. Селкенгәләп алу барыбер чак кына җиңеләйтә. Капка төбендә як-якка арчылган кар өемнәрен салмак кына хәрәкәтләр белән текә итеп киртләп йөргәндә, күршесе Хәлиулла күренде.

– Нихәл! – дип эндәште ул ерактан ук, Нәгыймгә таба килгәндә.

Нәгыйм эшеннән туктап, бүреген калкытыбрак куйды:

– Илдә ничек, бездә шулай инде.

– Аяк сызлыймы?

– Карлы-буранлы көннәрдә күзгә йокы да керми. Бүген ярыйсы әле. Көне әйбәт.

Бу вакытта, көянтә-чиләкләрен күтәреп, Фатыйма тыкрык башына менеп җитте. Ике агайның күзенә чалынмый гына узып китәргә теләгән иде дә ул, ләкин аны абайлап алдылар.

– Әнә Фатыйма су алып кайтып килә, – дип куйды Хәлиулла.

Фатыйма агайлар ягына бер мизгелгә генә караш ташлап исәнләште:

– Исәнмесез!

– Исәнме!

– Исәнме, Фатыйма!

Соңгы вакытта башка авылдашлары кебек үк им-томнарга нык ышана башлаган Нәгыйм канәгатьлек белдерде:

– Улларыбыз турында сөйләшергә торганда тулы чиләкләр белән кайтып килүең бик әйбәт.

Аның бу сүзләре кызның болай да ярсыган күңеленә ялкын өстәде, чиләкләре авыр булуга карамастан, ул адымнарын кызулатты һәм тиз арада урам чатында юк булды.

Хәлиулла кыз киткән якка караган килеш авыр сулап куйды:

– Их, күрше, күрше. Без исәнен исән дә, менә улларыбыз ничек икән анда?

– Белгән юк инде. Хатларыннан гына тәгаен төшенү мөмкин түгел шул.

– Алар бит без кайгырмасын дип тә күп нәрсәне язмыйлар.

– Анысы да бар инде. Кемнәр уйлаган 1915 елда герман снарядыннан гарипләнеп калып... улларым да тагын герман белән сугышыр дип.

– Мәңге сугышты бу каһәр суккан нимес! – диде Хәлиулла, ачынып. – Гел сугыша да сугыша! Нәрсә җитми бу нимескә, ә?!

Нәгыйм әңгәмәдән туя башлады, чөнки әңгәмәне кай якка гына борма, барыбер сүз фәкать бәла-каза, кайгы-хәсрәт турында бара. Хәер, ил өстендә афәт йөргәч ни хакында сөйләшмәк кирәк. Шулай да хәрәкәтләнү мәслихәт, сөйләшү җиңеләйтми Нәгыймнең күңелен. Хәрәкәт кирәк, хәрәкәт.

– Хәленнән килсә, барысы да сугыша, күрше, – диде ул, көрәк сабын кысып тотып. – Кеше сугышмый тора алмый!

Нәгыйм кыр-кырыйдагы кар өемнәрен тигезләргә тотынгач та әле Хәлиулла беркавым дөнья хәлләрен барлап гәп куертырга маташты, әмма күршесенең пәрвайсызлыгын күргәч, хушлашып, үз йортларына таба китеп барды.

7

Инде өченче ел сугыш бара. Кызыл Армия Көнбатышка таба һөҗүмен дәвам итсә дә, дөньяда купкан мәхшәрнең кайчан да булса бетәсен беркем белми.

Бөтен ил кебек, Кызылъяр авылы да көтә сугышның азагын. Тыныч-имин яшәешне көтә авыл.

Нәсимә, укуын тәмамлап, туган авылы Кызылъярга укытучы булып кайтты. Фатыйма белән очрашкан саен, Нәсимә аны апаларча якын итеп, хәтта туганнарча сөйләшә. Фатыйма ояла, читенсенә, ә шулай да күңеленнән ул моңа чиксез шатлана. Авылдашлар гына игътибар итмәсен, ике килен-килендәш сыман йөриләр, югыйсә әле кияүгә чыкмаганнар үзләре, диюче ачы телләр дә бар. Авылда төрле кеше яши шул. Авылдашлар күз-колагыннан беркайчан беркемнең котылганы юк.

Нәсимәнең абыйсы Фәрукны күптән түгел сугышка алдылар. Фатыйманың атасы Нургалине – кырык беренче елның азагында, абыйсы Кыямны кырык икенче ел көзендә алып киттеләр. Ике кызның һәрьяктан уртак серләре дә, уртак сагыш-хәсрәтләре дә җитәрлек. Нәсимәнең сеңелләре Фәйрүзә белән Сәвия дә Фатыйманы үз итеп, якын итеп әллә каян исәнләшәләр, хәл-әхвәлләрне сорашалар. Бигрәк ачык күңелле, әйбәт кызлар шул алар!

Хәтта Нәсимәнең анасы Тәслимә белән Фатыйманың анасы Саимә дә, кызларының егетләре абыйлы-энеле булганлыктан, ул хакта бөтенләй сүз катмасалар да, соңгы вакытта бер-берсенең саулык-сәламәтлекләрен ешрак, җентеклəбрәк сорашалар.

Кайда гына күреп алмасын, Нәсимә Фатыйма янына килми калмый. Хәлләрен сораша, кызның оялуын чын күңелдән ошатып, аның кәефен ничек тә булса күтәрергә тырыша – йә кызык сүз әйткән була, йә сугышка кадәр Сәет белән йөргәндәге кызык вакыйганы сөйли, йә берәр шаян такмак җырлап куя.

Иң еш очраша торган урын, әлбәттә, чишмә буе. Авыл халкын котылгысыз очраштыра торган урын – су ала торган җир.

Алтын көзнең иң иркә чоры иде. Алар тагын су алганда очраштылар.

– Исәнмесез, Нәсимә апа! – диде Фатыйма тыйнак кына.

– Исәнме, Фатыйма! – Нәсимә, гадәттәгечә, аны кызыксынып күзәтте. Авылдан беркая чыкмаган сабый гына шул әле бу кыз, дип уйлап куйды ул, әнә ничек бите кызарды. – Нишләп син миңа «сез» дип эндәшәсең?

Фатыйма тартынып иңнәрен калкытты:

– Әллә тагы.

Тыкрык тар булганлыктан, Нәсимә алдан, Фатыйма аның артыннан атлады. Тыкрык башына менеп җиткәч, Нәсимә туктады да сынаулы караш белән текәлеп сорады:

– Яббарны көтәсеңдер бит?

– Көтәм, – диде Фатыйма, кинәт кыюланып. – Ә сез... син?

Нәсимә моңсуланып китте:

– Сәетнеме? Көтәм. Әле шушы көннәрдә генә хаты килде. Җиңәбез дип яза. Ләкин сугышның кайчан бетәсен әйтмәгән. Кырык дүртенче ел бит инде. Өч елдан артты...

Фатыйманың тавышында курку сизелде:

– Яббардан хатлар килми. Курка башладым. Исән микән?

– Исән, исән! – диде Нәсимә, елмаеп. – Мондый чибәр кыз көткәч, нишләп үләргә тиеш ди ул. Син көт, Фатыйма. Зарыгып көткән кешең исән кала ди.

Фатыйманың эченә җылы йөгерде:

– Рәхмәт сиңа, Нәсимә апа!

– Ни өчен?

– Җылы сүзең өчен.

Нәсимәгә – уңга, Фатыймага сулга барасы иде. Сөйләшәсе килә, аерылышасы килми генә бит. Ләкин озак торырга да ярамый. Тыкрык башының бер ягында Нәгыйм абыйлар, икенче ягында Хәлиулла абыйлар. Күрерләр дә әллә ниләр уйларлар.

– Безгә кич утырырга кил, – диде Нәсимә, аның халәтен аңлап.

Фатыйма башын читкә борды:

– Оялам.

Нәсимә гаҗәпләнгән булып кыланды:

– Ник? – Аннары якты елмайды.– Ә-ә-ә, аңладым, аңладым... Әле егетләре кайтмаган килеш үк үзләрен килендәшләр кебек хис итәләр дип уйлаулары ихтимал. Шуннан куркасыңдыр.

Фатыйма, читенсенеп:

– Әй, Нәсимә апа, ярар инде, – диде дә китә башлады.

Нәсимә көлеп җибәрде:

– Бар, бар, тизрәк алып кайтып куй суыңны. Чиләкләрең дә бик зур, авырдыр.

– Сау бул, Нәсимә апа!

– Сау бул! Шулай да, вакытың булса, кич утырырга кил.

– Тырышырмын.

8

Сентябрьнең актык көнендә авылның әле теге, әле бу очында малай-шалай тавышы яңгырады:

– Әнсар абый кайткан!

– Хәлиулла абыйның улы сугыштан кайткан!

– Әнсар абый яраланып кайткан!

– Хәлиулла Әнсары сугыштан кайткан!

Авыл җитәкчесенең сугыштан кайткан каһарман улын, мөгаен, авылдашларның барысы да шул ук көнне күргәннәрдер. Кемдер авыл җитәкчесенең өенә үк керергә базса, калганнары Әнсар үзе капка төбенә тәмәке көйрәтергә чыккач аның белән килеп күрешү бәхетенә иреште.

Өлкән лейтенантның түшендә бер орден, өч медаль ялтырый. Тәмәкене авызына кабуы, шырпы сызулары, һәрбер хәрәкәте, кыймылдавы кызыгып туймаучы малай-шалайны сокландырды, көнләштерде. Сугышта кемедер булган һәрбер кеше килеп, минекен күрмәдеңме, безнекен очратмадыңмы, дип сорамый калмады. Кайберләре сугыш турында әллә нинди төпченүле сораулар биреп теңкәсенә тиде.

Иң беренчеләрдән булып күрше малае белән Әминә килеп күреште.

– И-и-и, Әнсар балакай! Кайтып җиттеңме! – Ул Әнсарны аналарча аркасыннан сөеп, сугыш керткән үзгәрешләрне аермачык күреп бик озак карап торды.

– Исәнме, Әминә апа!

– Чын ир кеше булып кайткансың, – дип, Әминә елап ук җибәрде.

Әнсар тәмәке төпчеген ташлап күн итеге белән таптады.

– Сәет хат язамы?

Әминә яулык почмагы белән күзен сөртеп алды:

– Сәеттән күптән түгел хат алдык. Менә Яббардан хат-хәбәр юк. Ут йотып ятабыз.

– Язмыймы? – диде Әнсар, кинәт кырысланып. – Ояладыр, бәлки.

Әминә аптырап китте:

– Кемнән?

– Болай гына әйтүем. Нәгыйм абый өйдәме соң?

– Калага киткәние, менә-менә кайтып җитәргә тиеш. – Нәкъ шул вакытта ул урам башында Нәгыймне шәйләп алды. – Әнә кайтып та килә инде, Алланың рәхмәте яугыры.

– Сәламәтлеге ничек соң?

– Элеккечә, йөрәге тынгы бирми, – диде Әминә, көрсенеп. – Һава бозылса, аягы сызлап җәфалана.

Нәгыйм адымнарын кызулатты, ул инде Хәлиулла малаеның кайтканын ишеткән, Әминәсе белән сөйләшеп торучының һичшиксез Әнсар икәнлеген аңлаган иде.

– Әнсар бит бу! – дип кычкырды ул ерактан ук. Кызурак атлаган саен, ул ныграк аксады, ләкин сугыштан кайткан күршесенең тизрәк кулын кысарга ашыкты. – Кайтып җиткән бит!

Әнсар аның каршысына атлады:

– Ул хәтле йөгермә, Нәгыйм абый. Мин бөтенләйгә кайттым, беркая да качмыйм.

Алар кочаклашып күрештеләр. Нәгыймнең ябыгып, бәләкәйләнеп калганын күрсә дә, Әнсар аңа:

– Бер дә үзгәрмәгәнсең, Нәгыйм абый, – дигән булды.

Нәгыйм күрше егетен артка чигә-чигә җентекләп күзәтте.

– Һай, маладис, һай, маладис! – диде ул, башын чайкап. Күршесе өчен горурлануы аның ихластан икәнлеге аермачык иде. – Әфисәр булып кайткан. Орден-медальләр белән. Ну, маладис, күрше! Бөтенләйгә кайттың инде алайса?

– Әйе, Нәгыйм абый. – Әнсар аһ-ваһлардан, төче мактау сүзләреннән туйган иде инде, шуңа күрә сүзне икенчегә борасы итте. – Йөрәгеңне саклыйсыңмы соң?

– Сакласаң да, сакламасаң да, минем йөрәк кылтый-мылтый инде ул, әйтеп тә торасы юк. Аякны беләсең инде. Синең өчен күңел куана. Аллага шөкер, исәнлектә кайткансың. Шушылай тере килеш бер күрешү бәхет түгелмени?!

– Шулай, Нәгыйм абый, шулай.

– Син дә яралангансың дип ишеткәниек, – диде Нәгыйм, төпченүдән читенсенсә дә, егетнең кай төше яраланганын беләсе килеп.

– Булды, Нәгыйм абый, эләкте.

– Шуңа комиссовать иттеләрме?

– Әйе. Госпитальдә яттым. Авыр операцияләр кичердем. Ике снаряд кыйпылчыгын алдылар, ә менә өченчесе күкрәгемдә калды. Вакыт-вакыт сызлап куя.

Иренең ничәмә еллар сугыш ярасыннан бимазалануын күреп яшәгән Әминә тагын еламсырады:

– Әй балакай, балакай. Алла ярдәм бирсен инде берүк үзеңә.

Нәгыйм исә:

– Алып булмадымыни анысын? – дип кызыксынды.

– Алырга куркыныч, диделәр. Бәлки, озакка сузыла торган операция дип маташасылары килмәгәндер. И Нәгыйм абый, госпитальдәге мәхшәрне күрсәң син! Хәер, син госпитальләрне, лазаретларны күргән кеше.

– Менә хәзер без синең белән ике күрше – ике раненый, икебез дә нимес снарядыннан, – диде Нәгыйм, һич кенә дә шаярмыйча, авыз чите белән көлемсерәгәндәй итеп.

– Мин госпитальдән соң тагын фронтка җибәрүләрен сораган идем. Кире кактылар, фильтрация лагеренда должность тәкъдим иттеләр. Взвод командиры булып шунда хезмәт итеп алдым. Төрле предательләр, дезертирлар сортировать итеп йөрдек шунда. – Әнсарның йөзе кинәт караңгыланып китте. – Теге кыйпыл-

чык торымнан торымга тынгы бирми, яңгыр яуса да, кем әйтмешли, буран чыкса да, көн караңгыланса да сыкрарга тотына. Ул службадан да комиссоваться итәргә туры килде. Менә инде кайтып та җиттем.

– Исән калуың әйбәт, улым, – диде Әминә.

Нәгыйм әллә хатынының сүзен хуплап, әллә тәндәге кыйпылчыкның нинди куркыныч нәрсә икәнен аңлаганны күрсәтеп баш какты.

– Ул кыйпылчык мәңгегәме инде хәзер? – диде ул, яра турында сөйләшүдән нindидер сәер бер рәхәт тойган сыман.

– Минем әле өметем бар – еллар тынычлангач, иркенләп, берәр ничек алып булмасмы дим. Бик оста хирурглар бар бит.

– Бирсен Ходай, бирсен Ходай, – диде Нәгыйм. Ул авыр сулап куйды. – Безнең малайлар кайчан кайтырлар инде. Сәеттән хатлар килә, ә Яббарның нишләптер хәбәре юк.

Әнсарның чырае аксылланып китте:

– Яббар, Яббар... Аның хәбәре килми калмас инде... – Ул Нәгыймгә беравык текәлеп карап торды. – Килер! – Нәгыймнең пошаманлануын күргәч, Әминәгә борылды. – Кинәт теге лагерь искә төште – андагы тоткыннар, андагы буталчык, фаҗигале язмышлар... Әллә нинди кайгылы, кара хәбәрләр йөри ил буйлап.

– Дезертирлар күпме? – диде Нәгыйм, чак кына ишетелерлек итеп.

– Дезертирлар да, нимес ягында сугышкан предательләр дә бихисап. Теге лагерь бердәнбер түгел бит ул, андый лагерьлар беләсеңме күпме?!

– Предательләр дә күпмени?

– Коточкыч. Әле бит нимесләр военнопленныйлардан легионнар дип аталган хәрби частьлар оештырдылар. Үзебезнең кешеләр, нимес формасы киеп, безгә каршы чыктылар, әле һаман да сугышалар. Дивизияләп-дивизияләп. Генерал Власов бөтен армиясе белән безгә каршы сугышты.

– Власовны ишеткәниек...

– Оккупациядә күпме кеше нимескә хезмәт итте! Oho-ho!

– Тотылган предательләрне нишләтәләр? Атарга хөкем итәләрдер инде?

– Барысын да түгел. Минемчә, атып үтерсәләр җиңелрәк булыр иде – сатлыкҗанның үзенә дә, ата-анасына да, балаларына да, туганнарына да.

Әминә, бу авыр әңгәмәдән туеп, җан ачысы белән:

– И Ходаем, ник тыныч кына яшәми бу кешеләр, ә! – дип куйды.

– Похоронка килмәсә, хәбәрсез югалды дигән кәгазе киләме икән? – дип кызыксынды Нәгыйм.

– Кайчан ничек. Төрлечә була.

– Яббарның ни хаты, ни хәбәре юк, – дип уйга калды Нәгыйм. – Похоронка килмәгәе дип гел куркып ятабыз.

– Әй, Нәгыйм абый, похоронкасыннан түгел, башка хәбәрдән курык син, – диде Әнсар, кинәт тавышын күтәреп.
Нәгыйм сагаеп калды:
– Нинди хәбәрдән?
– Болай гына әйтәм инде. Әллә нинди хәбәрләр килүе ихтимал.
Капка ачылды, Зәкия, чыгып, Әминә белән Нәгыймгә бөтенләй игътибар бирмичә, Әнсарга эндәште:
– Улым, мунча әзер.
– Ярый, мунча кереп чыгыйм әле мин, – дип, Әнсар тиз генә капкадан кереп китте.
Нәгыйм, уйга калып, үз турларына таба юнәлде.
– И-и-и, Зәкия, бәхетле кеше син – улың кайтып җитте, – диде Әминә, чын күңелдән күршеләре өчен куанып.
– Аллага шөкер, – дип җавап бирде Зәкия коры гына. – Яббарыңнан хәбәр юкмы?
– Юк шул, күптән юк инде.
Зәкия Нәгыйм ягына күз кыры белән генә карап пышылдады:
– Бәлки, аңа хат язарга ярамыйдыр?
Әминә аптырап китте:
– Нишләп аңа хат язарга ярамасын!
– Хәбәрсез югалды дигән язу да килмәдеме?
– Юк шул, андые да юк.
Зәкия, тыкрык ягына күз ташлап:
– Тизрәк дөресен белүең хәерлерәк шул инде, – диде дә, капканы каты ябып, ишегалларына кереп китте.
Нәгыйм күңеленең тынгысызлануын яшермәкче иде, чөнки Әминә аның борсалануын күрсә, тагы да авыррак булачак – хатынның күз яшьләре, сыктавы җанны тагы да катырак ашаячак.
Әмма ана күңеле бик сизгер шул. Ишегалдына керү белән үк ул үзе сүз башлады:
– Әнсар безнең белән ничектер сәер сөйләште кебек.
– Фатыйманы яратадыр, – диде Нәгыйм, бер дә исе китмичә.
Әминәне курку биләп алды:
– Нәрсәдер әйтергә тели, ләкин әйтми шикелле.
– Нәрсә әйтергә теләсен ул? Нидән чыгып андый шик-шөбһәгә биреләсең әле?
Әминә, каядыр бәрәңге бакчасы түренә карап:
– Яббар турында сүз каткач, әллә ничегрәк итеп җавап бирде, – диде.
Нәгыйм, өйалды ишеген ачып кергәндә:
– Оныттыңмыни бер кызны бүлешә алмый борыннарын канатышып йөргәннәрен?! – дип куйды.
– Зәкия дә сәер сөйләште бит.
– Ул бит үз малаеның анасы. Шул Фатыйма аркасында дим мин сиңа. – Нәгыйм кинәт кызып китте: – Нинди кеше соң син! Бигрәк артыгын сизгер күңелең! Әллә нәрсәләрдән шик эзлисең!
– Ярар, ярар, кызма, – диде Әминә тыныч кына.

9

Әнсар Фатыйма белән очрашып сөйләшергә күп тапкыр ниятләп карады, әмма кыз төрле сәбәпләр табып йә ашыгып китеп бара, йә күргәч качу ягын карый. Фатыйма тагы да чибәррәк хәзер, тәмам җитлеккән. Күзләре генә сагышлы, йөзе дә сулыгыбрак тора.

Очрашып, күңелдәге серләрне, хисләрне ачып салырга җай таба алмагач, Әнсар кызның суга кайчан, нинди вакытта йөрүен чамалый башлады. Ул инде моны хәзер төгәл белә.

Бүген Әнсар бераз салмыш, кәефе күтәренке. Фатыйманың тыкрыктан төшеп киткәнен ул качып кына карап торды. Су күтәреп кайтканда туктатып сөйләшергә мөмкин. Аннары, чиләкләрен күтәрешеп, ярдәм иткән булып кыланырга да мөмкин.

Фатыйма тыкрыктан менеп килгәндә, Әнсар җырлый-җырлый аның каршысына атлады:

> Алмалар пешеп җиткән,
> Берсен өзәрсең микән?
> Үзәкләрең өзелгәндә
> Ничек түзәрсең икән?
>
> Иске шырпы кабы,
> Яңа ырпы кабы;
> Читегем яңа иде,
> Төбе төште тагын.

Нәрсә нык тәэсир иткәндер – мәгънәсез җырмы, әллә Әнсарның очравымы – кызның йөзендә шом чагылды, бу шөбһәне Әнсар әллә каян ук абайлады.

– Исәнме, Фатыйма! – дип сәламләде ул вәкарьлек белән.

Фатыйма туктарга мәҗбүр булды, чөнки Әнсар нәкъ аның каршысына килеп басты.

Кыз оялып кына Әнсарга карап алды да башын аска иде:

– Исәнме!

– Нишләп хатларыма җавап бирмәдең?

Фатыйма башын читкә борды:

– Яздым бит... бер җавап хаты.

– Син бит «Бүтән язма!» дигән хат җибәрдең. Нишләп шулкадәре өнәмисеңдер инде сәвит офицерын, белмим!

– Әнсар абый, син офицер да, күкрәкләрең дә орден-медальле, ләкин күңелемдә башка кешене йөртәм бит, – диде Фатыйма, кыюлыгын җыеп.

– Кемне?

– Мин Яббарны көтәм.

– Ай-яй озак көтәргә туры киләчәк синә аны.

Фатыйма, Әнсарга туры карап:

– Сугыш тиздән бетәчәк бит, – диде.

Әнсар күзләрен челәйтте:

– Сугыш бетүен бетәр дә ул... – Ул кызга текәлеп карап торды. – Яббар хат язамы соң? Дөресен әйт!

– Хатлары килми башлады шул, – диде Фатыйма хафалы тавыш белән. – Исән генә булсын инде, Ярабби.

– Исән ул! – диде Әнсар авыз чите белән генә.

Фатыйманың йөзе яктырып китте:

– Мин дә шулай дип ышанам. Фронт ерагайган саен хатлар авыррак киләдер инде ул.

Әнсарның кыяфәте кинәт усалланды:

– Юк, аның хатлары килмәүнең сәбәбе фронт ерагаюда түгел. – Аннары таләпчән тавыш белән өстәде: – Син бар, суыңны кайтарып куй да чишмә янына кил, мин сине шунда көтәрмен.

– Минем вакытым юк, Әнсар абый, – диде Фатыйма, сискәнеп, һәм китә башлады.

Әнсар аны каты иттереп беләгеннән эләктерде, ә тавышына исә ягымлылык төсе кертергә тырышты:

– Бераз вакыт тап инде. Сугыштан кайткан кешегә якты йөз күрсәтсәң ни булган. Бик сагындым сине. Яббар турында да бәян итәр сүзем бар. Әйе, фронтлар Европага таба күчте, тик менә Яббар гына бөтенләй башка тарафларга ерагайды.

– Әллә исән түгелдер дип әйтмәкче буласыңмы? Исән ул, исән!

– Исәнен исән, – дип авызын чалышайтты Әнсар. – Тик аның исәнлеге кемгә кирәк?! Исән булуына, бәлки, үзе дә шат түгелдер инде.

– Яббар турында берни дә белмисең, юри әйтәсең син.

– Беләм. Яббарның хәзер кайда икәнен дә беләм мин.

Фатыйма котсыз калды:

– Яралымы әллә ул? Кул-аяклары өзелмәгәндер бит?

– Юк, бернәрсәсе дә өзелмәгән, – диде Әнсар битараф тавыш белән. – Бар, суыңны кайтарып куй да кил, барысын да сөйләрмен.

– Син юри әйтәсең, мине чишмә янына китертер өчен. Яббар турында да берни белмисең, ышанмыйм мин сиңа!

Әнсар, беравык Фатыйманың күзләренә карап торганнан соң:

– Мин аны кайтыр алдыннан күрдем, – диде.

– Алдыйсың!

– Мин аны күрдем! – дип кабатлады Әнсар.

Фатыйма Әнсарның алдамаганын күңеле белән тойды – нәрсәдер белә Әнсар Яббар турында. Белә, белә, белә!

– Чын әйтәсеңме? – диде ул, куркып кына.

– Бар, дим, суыңны кайтарып куй да кил! – дип боерды Әнсар көр тавыш белән. – Сөйлим.

– Хәзер киләм, – диде Фатыйма һәм көянтә-чиләкләренең авырлыгын бөтенләй сизмәгәндәй кызу-кызу атлап китте.

Күп тә үтмәде, тыкрык башында суга баручы Нәсимә күренде. Әнсарның күңелендә янә шатлык урын алды.

– Ничек хәлләр, Нәсимә? – диде ул, шат тавыш белән кычкырып.

Нәсимә елмаеп аңа таба якынлашты:
– Ярыйсы. Үзеңнең хәл-әхвәлләрең ничек?
– Алай ук начар түгел инде, яу кырында ятып калмагач, сөенергә генә кирәк. Менә күкрәктәге снаряд кыйпылчыгы гына кайвакыт тынгысызлый. Ну, бирешергә исәп юк алай.
– Син бирешә торган егет түгел, – диде Нәсимә ихластан.
Әнсар эчке канәгатьлек белән тамак кырып куйды:
– Рәхмәт... дөрес бәяләвең өчен. Балалар укытасыңмы?
Нәсимә авыр сулап куйды:
– Укытам. Әле беренче елым, шуңа күрә бик авыр.
– Син акыллы кыз, тиз ияләшерсең.
Нәсимә, күзләрен кылпакландырып:
– Рәхмәт дөрес бәя биргәнең өчен, – дигәч, икесенә дә кызык булып китте, рәхәтләнеп көлешеп алдылар.
– Сәет белән элемтә бармы соң? – дип кызыксынды Әнсар серле тавыш белән.
– Хат алышабыз.
Әнсар тәмәкесен тирән иттереп суырды да читкә ташлады:
– Анысы да адашмаса ярар иде инде.
Нәсимә аптырап китте:
– Аңламадым?
– Юк, болай гына, – диде Әнсар, еракка карап.
Фатыйма җан-фәрманга йөгереп килгән җиреннән, Нәсимәне күреп, тыкрык башында туктап калды. Нәсимә аңа ачулы караш ташлады да тыкрык буйлап чишмә буена төшеп китте.
Фатыйма аңлатырга теләгәндәй эндәшеп карады:
– Нәсимә апа! Мин...
Ләкин Нәсимә борылып та карамады.
– Ник калтыранасың? – диде Әнсар, Фатыйма килеп җиткәч.
– Нәсимә апа синең яныңа килүемне күрде. Әллә ниләр уйламагае.
Әнсар, күкрәген киереп:
– Уйласа ни, – диде. – Орденлы-медальле офицер янына килергә гарьләнәсең мәллә?
– Әнсар абый, минем шаярып-нитеп торырга вакытым юк, – диде Фатыйма. – Син Яббар хакында нидер әйтмәкче идең бугай. Әйт тә, миңа тизрәк кайтырга кирәк. Бигрәк кеше суга йөри торган тыкрыкта торабыз. Тыңлыйм.
Әнсар кызның кулын тотмакчы булды:
– Минем исә синең чишмә чылтыравыдай тавышыңны озаграк тыңлыйсым килә.
Фатыйма кулын бермичә артка таба чигенде:
– Син Яббар турында нидер әйтмәкче идең.
– Мин сине бик сагындым! – диде Әнсар, пышылдауга күчеп.
Фатыйма, түземлеген җуеп:
– Син юри әйтеп мине китерттең, күрмәгәнсең син аны, – диде дә кире борылмакчы булды.

Әнсар кызны кулыннан эләктереп алды:

– Син аз гына булса да мине юксынмадыңмы соң?

Фатыйма каушаудан куырылып ук калды:

– Юксынмадыңмы дип... Сугыштагы һәрбер авылдашымны юксындым мин, ләкин... Җибәр, Әнсар абый!

Фатыйма кискен хәрәкәт белән егетнең кулыннан ычкынды.

– Минеке буласың килмимени? – диде Әнсар өстенлек белән.

– Нишлисең син, Әнсар абый! Минем көткән кешем бар. Мин Яббарны көтәм!

– Ай-һай озак көтәргә туры киләчәк, – диде Әнсар чәнчүле тавыш белән.

Фатыйма Яббар турында яман хәбәре юктыр, Әнсар алдаган дип тынычлана башлады.

– Сугыш тиздән бетәчәк, диләр, Әнсар абый.

– Сугыш бетәр бетүен, – диде Әнсар, күзләрен челәйтеп. – Сугыш беткәч кенә кайтмаячак әле ул.

Фатыйманың күңеле тагын ярсый башлады:

– Син мине елатасың хәзер, – диде кыз, дерелди башлаган ияген учы белән каплап. – Нишләп кайтмасын?!

– Хатлары да килми икән сиңа.

– Килә! – дип җикерде кинәт Фатыйма. – Мин юри әйттем! Хатлары гел килеп тора! Әле күптән түгел хат алдым!

– Сәер! Ничек инде? Ата-анасына да, беркемгә дә язмый, сиңа гына яза булып чыгамыни?!

Фатыйма, Әнсарга туп-туры карап торганнан соң, эсселе-суыклы булып китте:

– Син нәрсәдер беләсеңме әллә чынлап та?

– Белә-ә-әм, – дип салкын елмайды Әнсар.

– Белсәң әйт!

– Син аны һаман яратасыңмы?

Фатыйма бите буйлап тәгәрәгән күз яшен яулык почмагы белән сөртеп алды:

– Яратам, Әнсар абый. Яратуның бер гаебе дә юк. Яратам! Көтәм!

– Ярар, әйтәм, – диде Әнсар, кинәт усалланып. Аның чырае хәтта бераз тартылыбрак та калды. – Күрдем мин аны. Исән ул. Яраланып госпитальдә ятканнан соң, мине тылга җибәрделәр. Фильтрация лагеренда отряд командиры булып хезмәт иттем. Анда төрле дезертирлар, сатлыкҗаннар, фронтта җинаять кылганнар, самострелллар, ягъни үзләренә үзләре атып яраланучылар, легионерлар, ягъни немес ягында сугышучылар, башка төрле әсирләр, арестантлар җыйналган иде. Менә шуларны фильтрация лагерьларында тикшереп-нитеп, һәрберсенә тиешле җәзасын бирәләр инде. Мин шунда күрдем Яббарны...

Шуннан соң ул хәбәрнең кызга ничек тәэсир иткәнен аңларга тырышып зур дикъкать белән карап торды.

Фатыйма исә, Яббарның исән булуына чиксез куанып, анымоны уйларга җитешмәде.

– Ул анда ничек килеп эләккән?

– Анда эләгүе сәер түгел, – диде Әнсар, яңа кабызган тәмәкесен тирән итеп суырганнан соң. – Нимес ягына чыгып безгә каршы сугышуы сәер.

– Дөрес түгел! Ялган! Миңа фронттан хатлар язды ул.

– Һәм берзаман хатлары килми башладымы? – диде Әнсар, сабыр гына тәмәкесен тартып.

– Әйе, – диде Фатыйма, башын иеп.

– Менә шул. Бер вакытны легионерларны алып килделәр. Бер таныш кешегә күзем иярде. Бер-беребезне таныдык. Игътибар белән карасам – Яббар! Легионер булган ул.

– Нәрсә соң ул «легионер»?

– Әсир төшкәч, дошман формасын киеп үзебезгә каршы сугышучы. Легионлап-легионлап оештырылганнар алар. Яббар да нимескә плен төшкәч, алар ягында сугышырга ризалык биргән. Имеш, аннары фронттан безнең якка чыгып качар өчен. Шулай дигән булды инде... Алар бөтенесе кулга алынгач шулай диләр. Имеш, хәйлә белән үзебезнең якка чыгар өчен.

Фатыйма кинәт хәлсезләнеп китте:

– Бәлки, Яббар булмагандыр ул?

– Без бит аның белән сөйләштек. Кызганып, әле бер буханка ипи, күп итеп махорка бирдем мин аңа.

Фатыйманың һаман ышанасы килмәде:

– Ул бит тәмәке тартмый иде!

– Сугышта тарта башлаган инде, күрәсең. Әле мин аны авылдаш, күрше итеп җылырак баракка билгеләдем.

– Хәзер кайда соң ул?

– Аны инде хөкем иттеләр. Алты ел биргәннәр. Хәзер Себернең төньягында кышкы наратлар кисәдер, мөгаен.

– Ни өчен алты ел бирделәр соң аңа, сугыштагы кешегә?

Әнсар кыжрап тәмәкесен ташлады:

– Изменник Родины булганга, сатлыкҗан булганга күрә!

– Ышанмыйм! – дип кычкырды Фатыйма.

Әнсар як-ягына карап куйды да әкрен генә тавыш белән:

– Мин дөресен сөйләдем, – диде. – Ышануың-ышанмавың үз ихтыярыңда.

Шуннан соң ул, күкрәген угалап, сак адымнар белән кайтып китте.

Фатыйма тыкрык коймасына капланып елап җибәрде:

– Йә Ходам!

Нәсимә башта ачулы кыяфәт белән генә үтеп китмәкче иде, шулай да туктап кызга эндәшәсе итте:

– Авыр әңгәмә килеп чыктымы әллә?

– Әйе:

– Күңелле булмас инде ул, бер егетне сугыштан көтеп, икенче

бер кайтканы белән очрашкач, – дип битәрләп ташлады Нәсимә.

Фатыйма көчкә һушына килде, башындагы яулыгын салып, күз яшьләренә чыланган битен сыпырды:

– Әйтәм бик усал карап киткәниең. Нәсимә апа, мин сиңа хәзер аңлатам. Әнсар абый, Яббарны очраттым, аның турында әйтәсе сүзем бар, диде, шуңа күрә генә килдем мин аның янына. Син әллә ниләр уйлагансыңдыр инде.

– Яббарны күргәнмени? – дип гаҗәпләнде Нәсимә.

– Күргән.

– Исәндер бит?

– Исән.

– Исән булгач сөенергә кирәк, – диде Нәсимә, елмаеп.

– Ни әйтергә дә белмим, – диде Фатыйма, хафаланып.

– Анда, фронтта, берәрсенә өйләнмәгәндер бит?

– Юк ла. – Әйтим микән, юк микән дип беравык икеләнеп торганнан соң, Фатыйма әйтергә булды: – Яббарны сатлыкҗан дип алты елга төрмәгә утыртканнар ди.

– Сатлыкҗан дип?!

– Әйе. Әнсар абый шулай диде.

– Юри әйтәдер, – диде Нәсимә, бер дә исе китмичә генә. – Каян белгән ди ул аны?

– Госпитальдән соң Әнсар абый беркавым ниндидер лагерьда хезмәт иткән. Төрле предательләрне аралый торган лагерь ди. Легионерларны алып килгәннәр. Аларның кем икәнен беләсеңме син?

– Беләм, ишеткәнем бар.

– Шулар арасында Яббарны күргән. Ипи, махорка биргән, җылы баракка урнаштырган Яббарны.

Нәсимәнең дә кыяфәтендә курку чагылды:

– Һаман шунда микән соң ул?

– Юк, ди, төньяк тарафларында, ди.

Нәсимәнең һаман да әле ышанасы килмәде:

– Ялган түгел микән?! Әнсар бит сиңа кызыгып йөри, әллә шуңа күрә уйлап чыгарды микән?

– Кызыгып йөрсә дә шундый коточкыч ялганны ничек уйлап чыгарсын инде. Андый ук кабахәт кеше түгел бит ул!

– Исерек бит.

– Күңелем ниндидер бәлане сизенеп йөргәние аны...

– Ышанма! – диде Нәсимә, катгый итеп. – Ышанмый тор!

– Ышанасым килми, әлбәттә. Әллә Әминә ападан сорарга микән?..

Нәсимә кырт кисте:

– Юк! Әминә апаларга әйтеп ташлый күрмә... әлегә. Сөрт тизрәк күз яшьләреңне, әнә бу тирәдә кемнәрдер йөри. Мин киттем, суымны алып кайтыйм. Бу юлысы су кирәктән түгел, синең Әнсар янына йөгерүеңне күреп, ачудан килгәнием. Тынычлан,

ачыкларбыз барысын да. Елама, сеңлем! – Бер-ике адым атлагач, ул борылып карады. – Коелып иңәргә ашыкма!

Бераздан Фатыйма да әкрен генә тыкрыктан өскә таба атлады. Әнкәсе җырлый торган җыр исенә төште.

Яулыгымның чите белән
Авызымны капладым,
Тын алырга да базмыйча
Әкрен генә атладым.

Авазың ишетмәмме дип
Туктадым. Өнсез торам...
Нинди яулык белән каплыйм, –
Җаным җыларга тора.

Нәкъ минем турыда бу җыр, дип уйлады ул.

Фатыйманың тыкрыктан менеп җитүе булды, капкадан кулына бидон тотып Әминә чыкты.

– Исәнме, Әминә апа! – диде ул, бу юлысы аз гына да читенсенмичә.

– Исәнме, кызым! – дип елмайды аңа Әминә.

Алар, сөйләшергә сүз табалмыйча, бер-берсенә карап тордылар.

– Кая җыендың, Әминә апа? – диде Фатыйма, тизрәк бу авыр тынлыктан котылыр өчен.

– Керосинга, – диде Әминә, бидонны җиңел хәрәкәт белән чак кына алга чайкалтып. – Бар микән, белмисеңме?

– Белмим. Әминә апа, мин сорарга базмыйча озак йөрдем...

– Тыңлыйм, кызым? – диде Әминә, сагаеп.

– Яббардан хат киләме?

– Юк шул, юк, утлар йотып ятабыз. Алай-болай сиңа килмәгәндер бит?

– Күптәннән юк, – диде Фатыйма боек тавыш белән. – Ә сезгә бернинди хәбәр дә килмәдеме?

Әминәнең күзләрендә курку чагылды:

– Нинди хәбәр?

– Каушама, Әминә апа, – дип тынычландырырга ашыкты кыз. – Теге куркыныч хәбәр турында сорамыйм мин.

– Нинди хәбәр тагы?

Фатыйма, ни әйтергә белми торганнан соң:

– Яраланып госпитальдә ятуы ихтимал, – диде. – Җиңел генә яралангач та хат язуы авыр булырга мөмкин бит. Исән ул, Әминә апа, исән. Күңелем сизә. Исән ул.

Әминә күз алларының караңгыланганын тойды:

– Аллага тапшырдык инде.

– Әйдә, керосинга барасыңдыр бит, – диде кыз, Әминә апасы белән бергә урамнан барырга тартынмыйча.

Әминә, әкрен генә башын чайкап:

– Юк, мин кереп ятып торыйм әле, – диде. – Хәл бетеп китте. –

Шуннан соң ул башын түбән игән килеш капкаларыннан кереп китте.

«Акылсыз мин, башсыз! – дип битәрләде үзен Фатыйма, урамнан атлаганда. – Ник сүз кузгаттым!»

...Күп тә үтмәде, бидон күтәреп, Нәгыйм үзе керосинга барырга чыкты. Нәкъ шул вакытта Хәлиулла үз турларына коелган сары яфракларны җил-җил кизәнеп себерке белән себерә иде.

Нәгыйм алар турына җиткәч, ул себерүдән туктады:

– Сәлам, күрше!

Нәгыйм:

– Вәгаләйкемәссәлам! – дип кенә үтеп китмәкче иде, күршесе сүз башлады:

– Карале, Нәгыйм, Яббар турында запрос ясатмыйкмы соң? Кирәк дип тапсаң, мин районнан запрос ясаттырам, нинди дә булса хәбәр килми калмас.

– Туктале, сугыш бит инде әнә кайда, бөтенләй читтә бара, – диде Нәгыйм, күршесенә таба атлап. – Почтага да йөрү авырдыр. Көтик әле. Алдан ук кеше мәшәкатьләп запрослар ясап йөрмик.

– Тизрәк дөресен белү үзегезгә әйбәтрәк булыр дип әйтүем, – диде Хәлиулла, сынаулы караш белән карап. – Билгесезлектән дә яманрак нәрсә юк бит.

– Анысы шула-а-ай, – диде Нәгыйм, сузып. – Инде әллә нәрсәләр уйлап бетердек.

Хәлиулла себеркесен әйләндереп, дык-дык иттереп сабы белән җиргә какты:

– Әгәр һәлак булса, похоронкасы килер иде.

– Бәлки, хәбәрсез югалгандыр да, командованиесе әле табылыр дип көтәдер.

Хәлиулла:

– Белгән юк инде, – диде дә себеркесе белән бер-ике тапкыр селтәнеп тузан куптарып алды.

– Әсир төшмәде микән? – диде Нәгыйм, көненә мең тапкыр башына килгән уйларына бирелеп.

Хәлиулла, Нәгыймгә якын ук килеп, битенә терәлеп диярлек күзләрен елтыратты:

– Вәт-вәт, әсир төшкәндер ул, – диде. – Запрос ясатыйк!

– Кая, Германиягәме?

Хәлиулла, «хе-хе-хе»ләп көлеп алганнан соң:

– Германиягә түгел инде, – диде.

– Әсир төшкәнен белсәләр, частеннан хәбәр бирмәсләр идемени?!

Хәлиулла як-ягына карап тавышын әкренәйтте:

– Үзебезнең төрмәләрдән, лагерьлардан эзләтергә кирәк түгел микән улыңны?

– Син нәрсә! – диде Нәгыйм, ачуланып. – Минем улымны нишләп аннан эзләргә тиешләр?!

Хәлиулланың бер күзе кысылды:

– Дөнья хәлен белеп булмы-ы-ый. Дезертирлык көчле ди бит.

Нәгыйм кызып китте:

– Син, күрше, теләсә ни сөйләп торма, яме! Минем улым ничек дезертир булсын!

Хәлиуллага исә күршесенең кайнарлануы берничек тә тәэсир итмәде шикелле.

– Дезертирлык кынамыни, – диде ул, себеркесен әйләндергәләп карый-карый. – Әсир төшеп немес ягында сугышучылар да күп ди бит.

Болай да күңелне ярсыта торган әңгәмә иде, күршесенең соңгы сүзләре Нәгыймне тәмам чыгырыннан чыгарды:

– Мин сине авыл җитәкчесе дип тормам! Не сметь минем белән – Герман сугышы инвалиды белән алай сөйләшергә!

Хәлиулла исә тынычлыгын һич кенә дә җуймады:

– Кычкырма, кычкырма, синең йөрәгең рәтле түгел. Сиңа әле киләчәктә сәламәтлек бик кирәк булачак. Мин сиңа запрос ясатырга ярдәм итмәкче идем, ә син... Мин сезнең билгесезлектә ятуыгызга борчылам, аңлыйсыңмы!

Нәгыйм:

– Син минем өчен борчылма! – дип китә башлагач, Хәлиулла:

– Кызма, тынычлан, – диде. – Сиңа бигрәк тә хәзер пыр тузынырга ярамый. Гомергә холкың алама булды, хәзер инде бераз йөгәнләргә туры киләчәк. – Аның тавышында Нәгыймне өнәмәве аермачык яңгырады. – Моңарчы бик күп нәрсәләр гафу ителде. Герман сугышы инвалиды дип тә, күрше хакына да. Күпме сүктең сәвит влачын, коммунистларны. Ә бит мин сине күптән Себергә озаттыра ала идем.

Нәгыйм инде шактый ара киткәч туктап борылды:

– Мин хәзер дә яратмыйм сәвит влачын! – диде ул нәфрәт белән.

Хәлиулла берничә адым аңа таба атлады.

– Ха! Менә тот! – дип кычкырды ул. – Хәзер инде влачны сүгә алмассың! Хәзер син Яббар атлы кече улың исән-сау калсын дип Ходайдан сорап ятарга тиешсең. – Ул кыҗрап себерке сабын ике куллап шатырдатып кысты. – Ходайга ялварудан тыш әле син сәвит влачы алдында тезләнеп йөрергә мәҗбүр булачаксың!

Нәгыйм әрләшүнең бер файдасы юк икәнне аңлады, йөрәк турысына кулын куеп йөзен чытты.

– Ике улымны да сугышка озатып, мин тагын тезләнеп тә йөрергә тиешме?! – диде ул басынкы тавыш белән. – Әнсарың белән минем Яббарым бер кызны бүлешә алмадылар, шуңа кузгатасың син мондый әңгәмәне. Малаеңны тизрәк шул Фатыймага өйләндерер өчен.

Хәлиулла күршесенең хәлсезләнүен күрде һәм авызын кыйшайтып елмайды:

– И-и-и, күрше, бигрәк вакланасың. Кыз-кыркын беткәнмени!

Бигрәк тә хәзерге вакытта. Минем герой улыма барча кызлар кызыгып йөри. – Нәгыйм китеп баргач, Хәлиулла аның артыннан кычкырды: – Запрос ясатмыйк инде алайса?

Нәгыйм җавап бирмәде. Ул гадәттәгедән ныграк аксый иде. Хәлиулла беркавым аның авыр атлап баруын күзәтеп торды да, ике учын да төкереклəп, себеркесе белән җил-җил селтәнергә тотынды. Капка төбе чиста иде инде аның, ләкин ул кемгәдер, нигәдер ачу иткән сыман себеркесе белән җирне чыжылдатып тырмады да тырмады. Нәгыймгә исә болай да әрнегән бәгырен тагы да ачыттырып себеркенең каты чыбыклары белән сыдыралар кебек тоелды.

10

Ниһаять, 1945 елның май аенда килде ул миллионлаган кеше зарыгып көткән хәбәр.

– Сугыш беткән!
– Җиңү, җиңү!
– Нимес капитулировать иткән!
– Сугыш бетте!
– Фашистларны җиңдек!
– Сугыш беткән! Сугыш беткән!

Авылның һәр урамына, һәр тыкрыгына шатлык тулды. Уртак кайгы-хәсрәт йотып яшәгән, бар афәтне ерып чыккан авыл халкын уртак бәйрәм, уртак бәхет әсир итте.

Озакламый дошманны җиңгән солдатлар демобилизация буенча кайта башладылар. Барысы да түгел. Бик күпләр яу кырында ятып калды. Кайтканнары арасында яралылар күп, гариплəнеп кулсыз, аяксыз кайтучылар да бар иде. Шатлык, кайгы, өмет – барысы бергә кайтты яу кырларыннан – киләчәккә тәэсир итәр өчен, яңа буыннарга йогынты ясар өчен, тарихи чорларны бер-берсенә төйни-төйни ялгар өчен, кешеләр хәтерләрен җуймасыннар дип, кеше икәнлекләрен онытмасыннар иде дип...

Сәетнең Берлинга кадәр барып җитеп исән-имин кайтуы Нәгыймнәр йортын бәхетле италмады. Бу өйгә инде олы һәм сәер кайгы кереп, шактый вакыт яшәп ята иде.

Өй түрендәге сәкедә утны-суны кичкән ил баласы – чын иргегет – түшендәге бер орденын, дүрт медален ялтыратып, тып-тын гына утырды.

Әминәгә авыр бу тынлык. Аның улы белән сөйләшәсе килә. Аның олы улы өчен куанасы, кече улы өчен өметләнәсе килә иде.

Мич буенда боегып басып торган ап-ак яулыклы ана улына эндәште:

– Нәсимәне күрдеңме соң әле?
– Күрдем.

Нәгыйм ян сәкене шыгырдатып торып утырды:

– Нәсимә беләме?

– Кеше сөйләшкәч, ишеткәндер инде, – диде Сәет. – Тик без ул хакта әлегә үзара сүз катмадык.

– И Ходаем, ниләр күрергә язган икән, ә! – диде Әминә газаплы тавыш белән, сыктанып. – Әй балакаем, балакаем! Анда аларны җәзалыйлардыр инде?

Нәгыйм аңа ямьсез караш ташлады:

– Шыңшыма әле, болай да җан сыкрый! Бәлкем, Әнсар юри генә әйтәдер, Фатыймага өйләнергә теләгәнгә.

– Ничек инде һаман юри әйтсен! – диде Сәет. – Яббар кайтса ялганы ачыкланасын аңламыйммыни ул!

– Бәлки, Яббар һәлак булгандыр да, бу хакта Әнсарга мәгълүмдер, – диде Нәгыйм, һаман өметен җуярга теләмичә. – Ә шундый коточкыч яланы Фатыйма Яббарны онытсын өчен әйтәдер.

Әминә килеп ире кырына утырды:

– Әнсар ул кадәре үк әшәкелеккә барыр микәнни?!

Нәгыйм, гадәттәгечә, ачу билгесе итеп, башын кинәт читкә борды:

– Һи-и-и, аның Хәлиулла малае икәнен онытма син. Хәтерләмисеңмени, Яббар белән дә, Сәет белән дә гел сугышып үсте бит.

– Әй, бала чактагы сугышулар инде ул, – дип кул селтәде Әминә.

– Хәлиулла районнан запрос ясатты, – диде Нәгыйм. – Көтик, нинди җавап килер.

Әминә әле фаҗиганең тирәнлегенә төшенеп җитмәгән иде, ул балакаеның чыннан да исән-сау булуын Ходайдан сәгать саен, минут саен сорады.

– Хат язмый шул, балакай, – диде ана, сүзләрен көйгә салыбрак сузып.

– Куркадыр, ояладыр, – диде Сәет, тәрәзәдән тышка карап.

Нәгыйм уйга калды:

– Аларга хат язарга ярамыйдыр. Язсалар да, хатларын җибәрмиләрдер.

Сәет үзенә урын тапмыйча әрле-бирле йөренергә тотынды:

– Белмим, әйтә алмыйм. Андый төрмәләрдә, Аллага шөкер, утырганым юк.

Кулына нindидер кәгазь тотып Хәлиулла килеп кергәч, өйдәгеләр шактый вакыт тын да алырга куркып тордылар. Хәлиулла үзе дә түземлекне сынагандай бер сүз дәшми әкрен генә ишек катындагы урындыкка утырды. Аннары һәммәсенә текәлеп карап чыкты.

– Яман хәбәр алып кердең, ахрысы, күрше, – диде Нәгыйм, курку хисе белән бергә, ниһаять, төгәл мәгълүмат алгач бераз тынычлану насыйп булмасмы дигән өмет хисен дә тоеп.

– Яманмы-яхшымы, үзегез өчен үзегез хәл итәрсез. Яббарыгыз Магадан тарафларындагы лагерьларның берсендә утыра икән. Алты елга хөкем ителгән булган – легионер дип, ягъни сатлыкҗан буларак.

Әминәнең җан ачысы ярылып чыкты:
– Әй Ходаем, әй балакаем!
– Шыңшыма! – дип җикерде Нәгыйм. – Синең генә йөрәк әрнимени!
Хәлиулла кәгазьне сузды:
– Менә монда лагерьның адресы да, бөтенесе дә, ни өчен утыртылганы да, барысы да язылган.
Әмма кәгазьгә кагылырга берсе дә базмады. Ниһаять, Сәет килеп кәгазьне алды да тавышсыз гына укырга тотынды.
Хәлиулла шул арада тизрәк чыгып китү ягын карады.
Аның артыннан ишек ябылгач, Сәет тешләрен шыгырдатты, чак кына сүгенеп җибәрмәде.
– Ах, селәгәй, селәгәй! – диде ул, кыжрап, кәгазьне нишләтергә белмичә. Аптырагач, аны бөгәрләп идәнгә ташлады. – Оят! Хурлык! Позор!
Әминәгә бу хәбәр бөтенләй көтелмәгәнчә тәэсир итте.
– Исән булуы хәерле, – диде ул, шатланып.
– Исән булуы, исән булуы! – дип кычкырып җибәрде Нәгыйм. – Исән булырбызмы-юкмы, белмим.
Сәет түр башына утырып өстәлне йодрыгы белән төйде:
– Берлинга кадәре барып җиттем, кан койдым... Сатлыкҗаннарны, куркакларны строй алдында атып үтергәннәрен дә күргәнем бар... Ә менә үз йортымнан изменник чыгар дип уема да килмәгәние. Кайтса, бәреп үтерәм!
Нәгыйм аңа да җикерде:
– Артык нык кызма әле син! Безнең йортта хәзер шул бербереңне үтерү генә җитмәгәние!
– Әллә нинди коточкыч сүзләр сөйләргә ашыкмагыз, – диде Әминә ялварулы тавыш белән. – Яббарның үзен күреп, аны тыңлап карамадыгыз бит әле.
– Минем аны күрәсем дә килми! – диде Сәет һәм тагын торып әрле-бирле йөрергә тотынды.
– Алай каты бәгырьлеләнмә, улым, – диде Әминә, ягымлы итеп. – Сугыштан исән-сау кайттың. Ходайга рәхмәт укып, кешеләргә миһербанлылык күрсәтү турында уйларга кирәк. Аллага шөкер, сугышы да бетте. Яббар дучар булган фаҗигане кичеп чыгарга да Ходай ярдәм итәр.
– Нәсимәгә ничекләр әйтермен бу хакта? – дип ыңгырашып куйды Сәет.
Әминә улына елмаеп карады:
– Яратса, аңа игътибар итмәс инде ул.
Нәгыйм исә карчыгына усал иттереп карады.
– Яратса!.. – диде ул, үчекләп. – Сөйләшүе...
Әминә улы Яббарның исәнлегенә бик куанды һәм шундук бала измышы өчен кайгыру аңарга яңа төрле сулыш бирде.
– Әй балам, әй балам! – дип, гел укый торган догаларын укырга керешті ана.

11

Яббар хезмәт иткән батальон урман белән авыл арасын тиз вакыт эчендә үтәргә тиеш иде. Ник кирәк булган ул авыл? Урманда гына урнашсалар ни булган? «Центр» армияләр группасының бу юнәлештә янә һөҗүмгә әзерләнәсен беләләр иде бит югыйсә. Ара җиде-сигез чакрым чамасы иде. Яртысын үтүләре булды, авианалет башланды. Батальон төрле якка сибелеп җиргә сеңде. Шул налеттан соң да кире урманга борылырга мөмкин иде ләбаса. Юк, никтер авылга таба барасы иттеләр. Авыл ягыннан берничә дошман танкы күренде, аннары пехота. Оборона алырга команда яңгырады. Батальонның инде яртысы гына калган иде. Немец танклары туктады, пехоталары җиргә ятты. Тагын авианалет башланды. Инде аңлашылмый иде – нинди коралдан, кайдан, кем тарафыннан аталар. Батальонның калдыклары кире урманга йөгерде. Немецлар мотоцикллар белән куа чыктылар. Яббар белән янәшә йөгерүче урыс егете Долгополов кычкырды:

– Яббар, винтовкаңны ташла, бәлки, атмаслар.

Яббар винтовкасын ташламады. Аның башында уйлар өере кайнады. Борылып атарга кирәк. Затворны тартырга кирәк. Җитешеп булырмы? Патронникта патрон бар. Фриц аны шундук атып егачак. Ул Долгополовның башын тотып каерылганын, аннары чалкан килеп төшкәнен күрде. Ни булса ул, кинәт борылырга да атарга! Шулвакытта Яббар нindидер түмгәккә абынып егылды. Артында дошман бармы-юкмы – ул әле белми ятты. Борылып карарга куркып шактый вакыт ятты ул. Винтовкасы да читтәрәк иде, үрелергә кирәк, буй җитәргә тиеш. Хәзер коралга сузылсам, атып җибәрерләр дип тә уйлады. Ниһаять, Яббар борылып карарга булды. Ун адым чамасы арттарак немец солдаты карабинын төзәп басып тора иде. Ул мотоцикл рулендә булмаган, утырып кына килгән, әнә мотоцикл урман ягына таба чаба, кемнедер куа иде. Күп икән мотоцикллар, кыр буйлап әле тегендә, әле монда чапкынлыйлар. Бу немец махсус төшеп калган – Яббарның башына җитәргә дип. Юк, Яббар винтовкасын эләктереп алырга җитешә алмаячак. Әле атып буламы-юкмы, соңгы вакытта винтовкасы да күп тапкыр осечка бирде.

– Schteht auf! Фстафай!

Яббар торып басты.

Шул вакытны урман ягыннан пулемет сиптерә башлады. Немец кычкырып җибәрде, аннары алпан-тилпән килеп әле алга, әле артка берничә адым ясагач, карабинын кулыннан төшереп, ике куллап эчен тотты да җиргә йөзтүбән капланды. Ерак түгел тагын мотоцикллар күренде. Яббар актык көченә тузанлы төтен арасыннан шәйләнгән әрәмәгә таба йөгерде.

Әрәмәдә ул караңгы төшкәнче утырды. Атышу, шартлау тавышлары инде күптән ерагайды, ул тавышлар тонык кына булып ара-тирә яңгырап куя.

Төнге салкын үзәккә үтә башлагач, Яббар кузгалырга булды. Һәр тарафта дөм караңгылык. Бу тирәдән тизрәк ерагаерга омтылды ул, аяклары кая тартты, шунда таба атлады, кая барганын белмичә барды да барды.

Таң беленә башлагач, батальоннары белән керергә тиеш булган авылга икенче яктан әйләнеп килеп чыкканын аңлады. Бик озак һәм бик ерак киткән шикелле иде, ләкин әйләнеп йөргән күрәсең. Авылга керергә базмады, кире борылды – каршы тарафта да урман күренде. Тизрәк шул урман эчендә югалырга кирәк.

Кинәт авыл этләре ярсып өрергә тотындылар. Яббар адымнарын кызулатты. Әмма ерак китә алмады, арттан, иртәнге томанлы тынлыкны дер селкетеп:

– Стой! – дигән тавыш яңгырады.

Яббар туктады. Урысча эндәштеләр. Немецлар түгел. Аңа таба йөгергән тавышлар ишетелде. Яббар әкрен генә борылды. Шунда аның йөрәге жу итте – йөгереп килүче ике кешенең беләкләрендәге бәйләренә төште аның күзе. Полицайлар болар.

– Руки вверх! – дип боерды берсе, биш-алты адым кала туктап винтовкасын төбәгәч.

– Выверни карманы! – дип җикерде арттагыраты, карабинын әзерлектә тотып.

...Аны авылга алып барып яртылаш янган йорт кырындагы дөм караңгы сарайга кертеп яптылар. Анда инде тоткыннар бар иде. Ишек катына баскан килеш ул колак салып тыңлап торды. Сарай түрендә берәү авыр итеп ыңгырашып куйды. Икенче якта кемдер, аның ыңгырашуына ачуы килеп булса кирәк, яман әшәке итеп сүгенергә тотынды. Яббар шул баскан урыныннан ары китмичә җир идәнгә чүгәләде.

Инде көн җитеп, сарай стенасының ярыкларыннан бераз яктылык саркылгач, тоткыннар арасында парашюты белән сикереп әсир төшкән летчик, ике партизан һәм Яббарның ротадашы Синицын фамилияле Оренбург егете бар икәне ачыкланды. Ыңгырашучы летчик булган икән – аның аягы сынган. Сүгенүче кеше партизаннарның берсе булып чыкты, ул летчикның ыңгырашканына гына түгел, үзенең иптәшенә дә гел сүгенеп, аның белән талашып ятты. Алар, ризык юнәтергә дип, урманнан авылга килгәннәр. Һәм ул үзенең иптәшен, син котырттың авылга барырга, дип, аты-юлы белән сүгенеп каргый да каргый. Синицынның хәтта ыңгырашырлык та хәле юк, фәкать торымнан торымга гыжылдап авыр сулап куя. Ул каты яраланган: бавыры ягыннан кан саркып тора, чырае мәет төсендә иде.

Аларның барысын да тышка алып чыктылар. Анда инде авыл халкы җыелган иде. Летчикны, басып тора алмавы сәбәпле, сарай стенасына сөяп утыртып куйдылар. Обер-лейтенант – чандыр гәүдәле, ләкин калын тавышлы немец – үз телендә халыкка

мөрәҗәгать итте, янындагы тылмач тәрҗемәсен ирештерде. Атнаун көн элек авылда партизаннар булган. Киткәндә ут төртеп киткәннәр. Алты йорт, каралты-кура янган. Халыктан бу биш кеше арасында таныш чырайлар бармы дип сорадылар. Авыл кешеләре теге ике партизанны гына таныдылар. Аларның икесен дә шундук халык алдында атып үтерделәр. Летчик белән Синицынны кире сарайга яптылар, ә Яббарны, обер-лейтенант фәрманы буенча, читтәрәк торган йөк машинасына таба алып киттеләр. Машинаның әрҗәсендә сигез әсир бар иде инде – аларның икесе Яббар хезмәт иткән батальоннан, калганнары таныш түгел иде.

12

Вакыт арасы озынлыгы-кыскалыгы белән түгел, ә бәлки шул вакыт эчендә ниләр булып, адәм балаларының башына ни төшкәне белән үлчәнә. Дөньялыктагы кайбер вакыйгалар кешене тиз арада шулкадәре үзгәртә ки, хәтта үзгәреш аны элекке халәтен оныту дәрәҗәсенә җиткерә.

Фатыйманың атасы сугыштан кайтмады. Үлем хәбәрен алып килгән кәгазьгә бик озак ышанмый йөрделәр, әмма вакыт узган саен, хәбәрнең әллә нинди ләренә күнәсең икән ул. Холыксыз, тузынучан атасы Фатыйма өчен бөтенләй башкача хәтерендә саклана. Бер дә авыр холыклы булмаган икән аның атасы, бик ягымлы, бала җанлы кеше булган ул. Фатыйманың абыйсы Кыям сугыш беткәнче трудармиядә хезмәт итте. Шундый шук егет иде, бөтенләй сөйләшми торган, үзенә бикләнүчәнгә әйләнеп кайтты. Фатыйма Яббарны сагынды, көтте, аның өчен нык кайгырды. Ләкин Яббарның яманаты чыгу кызны каты куркытты. Ниндидер зур хата, ялгышлык киткәндер, әмма кайчан да булса ул төзәлер, юылыр дигән өмете дә яшәде аның күңелендә. Өмет уты сүнмәсә дә, Яббарның Себердәге лагерьда утыруы, авылдашларның аны сатлыкҗан дип атавы авыл кызының котын алды. Ул Яббарны онытырга тырыша башлады. Әнсар да шактый ягымлы итеп аның артыннан йөрергә тотынгач, туганнары: «Пар килгәнсез, шул кешегә чыгарга кирәк», – дип өндәделәр.

Ләкин беренче мәхәббәтен онытып булмасын Фатыйма белә дә, аңлый да иде. Инде кайчаннан бирле йөрәк «Яббар!» дип тибә. Онытылырлык булса, инде кайчаннан бирле якын, кадерле кеше булыр идемени ул?! Ничек онытасың аны? Мәхәббәт өчен вакыт та, ерак аралар да берни түгел икән ләбаса. Ярату, сөю өчен хәтта үлем дә көчсез бит. Үлем синең сөйгәнеңне алып китә ала, әмма аңа булган мәхәббәтне үтерү үлемнең хәленнән килми!

Фатыйманың ерак лагерьга Яббарга хат язу теләге бар иде. Гафу үтенеп, язмыштан узмыш юк дигәнрәк фикерләр белән язмакчы иде ул аңа. Бу хакта Нәсимә белән киңәшләшергә булды. Чөнки Нәсимә инде Сәеткә кияүгә чыккан иде. Нәгыймнәрнең

килене бит ул хәзер, ә алар гаиләсеннән Нәсимәдән кала кем белән киңәшләшә алсын?!

Әтисе Кашаф, үпкәсенә салкын тиеп, 1939 елны дөнья куйгач, абыйсы Фәрук сугышта һәлак булгач, әнисе Тәслимәнең ышанычы һәм таянычы булып Нәсимә калган иде. Нәсимә авылга укытучы булып кайткач, сеңлесе Фәйрүзә дә кызыгып укытучылыкка укырга китте, иң кече сеңлесе Сәвия әнкәсе яныннан китәргә теләмәде, фермада сыер савучы булып эшли башлады.

Вакыт үтә торды. Фәйрүзә, укуын тәмамлагач, Казанда кияүгә чыкты һәм башкалада калды. Сәвияне күрше район егете алды.

Нәсимәне Сәеткә чыкмаска үгетләүчеләр күп булды. Әлбәттә, Яббар аркасында. Әнкәсе дә каршы килде. Мөгаен, холкы белән атасына охшаган мәрхүм абыйсы да каршы булыр иде. Ә менә сеңелләренең икесе дә, Нәсимә апаларын нык яратканга һәм аның Сәетне ничек яратканын күреп-аңлап йөргәнгә күрә, аларның өйләнешергә теләүләрен хупладылар.

Нәсимәнең туганнары арасында Сәеткә чыгуга каршылары булса да, кызны сорарга килгәч, ачыктан-ачык каршылык күрсәтмәделәр. Яббарның яманаты тирә-якка таралса да, моңарчы Нәгыймнәр нәселе дә, Әминәләр нәселе дә Кызылъярда яхшы дан тотучылардан иде. Сәет тә булдыклы, яхшы егет, Нәсимә үзе дә ак-караны аера белүче, укымышлы һәм ясаган адымы өчен җавап бирергә әзер кыз бала, шулай булгач, ничек фатиха бирмисең?!

Алар өйләнештеләр. Сәет Кызылъярдан алты чакрым ераклыкта урнашкан МТСта механик булып эшли башлады, Нәсимә Кызылъяр авылында балалар укытты.

Фатыйма киңәш сорап килгәч, Нәсимә алай бик озак уйланып тормады.

– Син хат язып Яббарга зур удар ясама инде, – диде ул язмыш юлларының чатында боегып басып торган Фатыймага. – Ул барыбер кайчан да булса бер кайтмый калмас, шулчагында гафу үтенерсең. Ә Әнсарга килгәндә... Син аңа кияүгә чыгарга тиеш, минемчә. Алар хәлле нәсел, Әнсар да бик төпле, акыллы егет. Өстәвенә ул укырга да җыена икән. Әле аның алга китеп зур кеше буласын күрәселәребез бардыр. Синең, сеңлем, башка чараң юк, чык Әнсарга.

13

Вакыт өчен нәрсә ул җирдәге сугышлар, аның җәрәхәтләре! Сугыш беткәнгә биш ел узды. Тагын шулай ук узачак, тагын, тагын...

1950 елның вакыт өчен әһәмияте бар микән? Мәңгелек өчен, бәлки, юктыр да.

Ә аерым кешеләр өчен? Кеше язмышы өчен?

Әминә казан астына ут ягып яңа бәрәңге пешереп маташканда, Нәгыйм сәкедә киез итеккә олтан салып утыра иде. Сәет үзенең

уй-хатирәләренә бирелгән, кашларын җыерып уйга калган, өстәл башында ашарга пешкәнне көтеп тып-тын гына утыра.

– Нәсимә бик озак кайтмый бүген, – диде Нәгыйм, без белән итек төбен каезлап.

Киленнең кайчан кайтуына беркайчан да игътибар бирмәгән картның сүзенә Әминә гаҗәпсенеп куйды. Соңгы вакытта кирәгеннән артык бежекләнә башлады карты, холкының катылыгына юк-барга бәйләнүе дә өстәлде.

– Эше күптер, – диде Әминә. – Мәктәпне чистарталар, буйыйлар, яңа уку елына әзерлиләр.

Сәет тә телгә килде:

– Эш күп анда. Укучыларның ата-аналарын, укытучыларның туганнарын да чакырдылар. Мин бармадым инде. Ачуланмаслар әле. Балалары укырга барасы кешеләр булышсын. Җитмәсә, Әнсар да мәш килеп йөри анда.

Нәгыйм стенадагы кадакка җепне бәйләп сумала белән ышкырга тотынды.

– Маладис егет булып чыкты бу Әнсар! – диде ул, чын күңелдән сокланып. – Силсәвит рәисе булып сайлангач, мәктәбен дә, китапханәсен дә – барысын да карарга тотынды. Һәр эштә үзе башлап йөри бит, малай.

– Атасы урынына менеп утыргач, очып йөри, очып, – дип өстәде Сәет.

Нәгыйм җепне кадактан ычкындырып янә сәкегә барып утырды, итек табанына олтанны куеп карады:

– Соң, сайладылар бит инде. Җитәкчелек нәселләрендәдер, күрәсең.

Сәетнең тавышында ачу аермачык яңгырады:

– Атасын учетчик итеп билгеләргә оялмады. Фатыйманы китапханәче итеп куйдылар.

– Хәлиулла – күп еллар буена авылны җитәкләгән кеше, кем итеп калдырсалар да ярый, – дип сүзгә кушылды Әминә. – Әнсарның канатланып эшкә тотынуы күбрәк гаилә бәхетеннән ул. Фатыймасы да бик уңган, малайлары да шундый матур булып үсеп килә.

– Нәрсә, әнкәй, минем Нәсимә Фатыйма шикелле үк уңган түгелме әллә? – диде Сәет, ярым шаярып.

Әминә килеп улын аркасыннан сөйде:

– И-и-и, улым, гел кирегә алырга гына торасың. Киленнән шундый уңдык. Нәсимәбез менә дигән. Сүзгә төртелеп утырма инде. Аллага шөкер.

– Туктале, алга таба нишләр, – диде Нәгыйм, итекне идәнгә куеп.

– Минем янда Нәсимәгә бәя биреп утырмагыз, яме, – диде Сәет. – Мин югында сөйләшегез.

– И-и-и, улым, холкың нәкъ атаңныкына охшый башлаган икән – сүз әйтергә дә ярамый.

Нәгыйм билен язар өчен чак кына иеленкерәп куйды:

– Нәрсә, холкым аламамы минем?

– Алама түгел, алама түгел, алама димәдем бит. Нәсимәбез, укытучы булса да, кул кушырып, мин интилигинт дип утырмый, шуңа сөенәм.

– Килен мин укытучы дип утырса, нәрсә була инде ул.

Сәет бәрәңгенең пешеп чыкканын көтеп тормады, бер кисәк ипине яртылаш кабып ашарга тотынды:

– Нәсимәбез дә әйбәт, үзебез дә начар түгел, ә шулай да барыбер бөтен авыл безгә кырын карый. Мине механиклыктан чыгарып атмагайлары әле.

Нәгыйм, аралыкка кереп юынгычның телен шылтырата-шылтырата кулын юып чыккач:

– Ник, син үз эшеңне җиренә җиткереп башкарасың түгелме соң? – диде.

– Белмим, – диде Сәет, ашый-ашый. – Изменникның абыйсы булганга күрә чыгарып томырмаслар микән – гел шуны уйлап йөрим, җан тыныч түгел. Әнсар абруйлы кеше, сүзе үтә, МТСта да аны бик ихтирам итәләр. Фронтовик буларак, сатлыкҗаннарны күралмый. Өстәвенә бала чакта ук мине дошман итә иде.

– Механиклыктан чыгармаслар, – диде Нәгыйм, кулын тастымалга сөртеп. – Яббар аркасында Әнсар сиңа ник каныксын икән? Инде Фатыймага да өйләнде бит.

– Өтерманнан бер генә дә хат язмады, балакаем, – диде Әминә, күз төпләренә яулык почмагын тигезеп. – Әллә инде монда бүтән кайтмаска микән исәбе?

Нәсимәнең өйалды баскычы янында аяк киемен салып маташканын ян тәрәзәдән күргәч, Әминә бик сөенде – килен янында сөйләшү башкарак юнәлеш алачак, шуңа аның нәкъ менә хәзер кайтып керүе әйбәт.

Уңдылар алар киленнән. Өлкән улының бәхете бар икән, сөбханалла. Нәсимә тулы гәүдәле, буйга да, тазалыкка да таманлыктагы, бигүк чибәр булмаса да, эчке гүзәллекә ия булган сөйкемле зат иде. Ачык коңгырт чәчле, зәңгәр күзле, төскә-биткә мари кызларына тартым киленен Әминә үз кызыдай яратып кабул итте. Нәсимә беренче карауга гел авыр эшкә җигелергә әзер торучы яшь хатынны хәтерләтә, әмма аның акыллы күзләрен күргәч һәм дә шул күзләрнең тирәнлегендә уйчан ягымлылыкны барлагач, аны таныш булмаган һәрбер кеше бу һичшиксез йә врач, йә укытучы дип уйларлык иде.

Өйгә керү белән үк, Нәсимә:

– Уф, шул буяу исеннән башым әйләнә, – дип, бераз хәл алырга урындыкка утырды. – Ниһаять, бүген барлык парталарны буяп бетердек.

– Саф һавага ешрак чыгарга кирәк, – диде Сәет нотыклы тавыш белән. – Буяу исеннән аңыңны җуюың да ихтимал.

– Ярый әле кайбер укучыларның ата-аналары килеп ярдәм итте.

– Менә анысы әйбәт булган, – диде Әминә, кинәт кәефе күтәрелеп. – И-и-и, бигрәк яхшы кешеләр бар авылыбызда.

– Шулаен шулай да... – диде Нәсимә, боегып. – Тик менә Яббар турында сораштырып теңкәгә тиделәр.

Нәгыйм сәкегә барып утырды:

– Сораштыралармы?

– Сораштыралар.

Нәгыймгә тизрәк киленнең моңа мөнәсәбәтен белү кирәк иде.

– Син нәрсә дидең? – дип сорады ул.

– Бернәрсә дә белмим дип җавап бирәм.

– Дөрес әйткәнсең, – дип хуплады Нәгыйм. – Шулай җавап бирә торган бул.

Нәсимәгә карата да авыл халкының мөгамәләсе чак кына сизелерлек салкынайды, моны ул әлегә үзе генә сизә, әмма укытучы башың белән андый карашны тою бик читен. Бу хакта өйдәгеләргә аның моңарчы сүз катканы юк иде, хәзер исә:

– Бөтенләй усал карауччылар да бар, – дип әйтеп салды.

Сәет киеренкелек белән гәүдәсен калкытты:

– Кем усал карый?

Нәсимә шундук ник әйткәненә эчтән генә үкенеп куйды.

– Әй, юк, шулай тоела гынадыр, – диде ул һәм тизрәк кулына бер-бер эш табар өчен каенанасы янына юнәлде.

– Усал карауччы яки авыр сүз катучы булса, кайт та миңа әйт, – диде Сәет. – Ул маңка малай легионда булган дип хатыным да, мин дә җавап тотарга тиеш түгелбез.

– Кызма әле, улым, болай да авыр бит, – дип ялварды мондый авыр әңгәмәләрдән тәмам туйган анасы.

– Юк, Сәет, кайберәүләрнең кырын каравы табигый, – диде Нәсимә, үзенә эш табалмыйча Әминә тирәсендә таптанып. – Чөнки гади авыл кешеләре арасында укытучыны яратмаучылар гел була инде ул. Өлкән яшьтәге укытучыларның да әйткәне бар: авыл кешеләре арасында укытучыларны яратмаучылар күбрәк тә дип.

– Юу-у-у-к, анысы кырын караулары хак. Бөтенебезгә кырын карыйлар. Минем механик булып эшләвемә ник ачулары килә дип уйлыйсыз? Чөнки предательнең абыйсы андый эштә эшләргә тиеш түгел дип саныйлар.

– Эшен тырышып башкарган кешегә кырын карасалар ни, карамасалар ни, – диде Әминә, казаннан бәрәңге алырга җыенып.

Нәсимә, аның кулыннан савытны алып:

– Кая, әнкәй, үзем әзерлим, – диде. – Син утыр.

Нәгыйм сәке буендагы итеккә тибеп җибәрде дә өстәл янына түргә утырды:

– Их, Яббар, Яббар! Шуны әйтәсем килә: безне бөтен авыл дошман итәргә хаклы. Чөнки илебез шундый коточкыч сугыш кичерде. Авылыбыздан гына да күпме кеше һәлак булып калды,

күпме кеше гарипләнеп кайтты... – Ул авыр иттереп башын чайкады. – Ну түлке, ну түлке! Башка шушындый фаҗига төшсен әле, ә!

– Ярсыма, Нәгыйм, болай да йөрәгең авырта, – диде Әминә, килен алып килгән бәрәңгене өстәл уртасына күчереп.

– Ярсымасам да авырта ул минем.

– Әнсар да мәктәптә күренгәндер? – дип кызыксынды Сәет.

Нәсимә самавырның кайнап чыкканын көтеп торган җиреннән җавап бирде:

– Ул да шунда иде. Әле парталарны да ташышты. Фатыймасы да килде, анысы буяулар әзерләп, рамнарны буяп йөрде. Әнсар соңрак мәктәп ишегалдындагы бүрәнәдә күкрәген тотып утырды. Чырае ап-ак иде.

– Күкрәгендә кыйпылчыгы бар бит аның, бичаракайның, – диде Әминә кызганулы тавыш белән. – Әй Ходаем, бар кешегә җитәрлек тиде инде бу каһәр суккан сугышлардан.

Нәсимә, самавырны өстәлгә куйгач, Нәгыймгә эндәште:

– Әти, син нишләп бәрәңге ашамыйсың?

– Аппетитым юк. Миннән башка гына ашагыз. Улым, әйдә, капкала да, сарай идәнен рәтлибез.

– Аны яңадан җәяргә кирәк, – диде Сәет, бәрәңге ашый-ашый.

Нәгыйм читкә карап көрсенеп куйды:

– Такта каян аласың?

Нәсимә үзе дә табын янына утыргач, Әминә аңардан:

– Фатыйма Яббар турында сорашмадымы соң? – дип кызыксынды.

Нәгыйм, карчыгына кырын карап:

– Синең Яббарың Фатыймага ник кирәк инде хәзер?! – диде.

– Фатыйма сорамады, – диде Нәсимә. – Әнсар гына «Яббар шушы арада кайтырга тиеш бугай?» дип куйды.

Сәет ашаудан туктады:

– Син ни диден?

– Әйе, шулай бугай, дидем.

Нәгыйм кашларын җыерып уйга калды:

– Анысы ни инде... Ничегрәк плин төшкән, ничегрәк немескә хезмәт иткән – боларны ачыкласаң, бәлки, Яббарның гаебе ул хәтле үк түгелдер.

– Алты ел тикмәгә бирделәр микәнни, – диде Сәет, алдына куелган чынаякны алгарак этәреп. – Аннары бер ноктага текәлеп әйтеп куйды: – Алай дисәң, нахакка рәнҗетелгән, хәтта гаепсез килеш расстрелга киткән очраклар да күп.

Нәгыйм киленнән читенсенеп тормыйча, ачыктан-ачык сөйләшергә керешге:

– Чын изменник булса, расстрел бирми калмаслар иде. – Аннары өстәп куйды: – Легионга кермичә булмый иде микәнни, бүтән чара күренмәде микәнни?

– Рухы сыеграк булгандыр, курыккандыр, – диде Сәет.

– Кешенең яшисе дә килә бит, ничек инде курыкмасын, – диде анасы. – Немесләр атабыз дип куркытканнардыр.

– Куркытып легионер ясамаганнардыр инде. Үз теләкләре белән, җан саклар өчен легионнарга кергәннәрдер.

– Син, Сәет, энеңне алдан ук бигрәкләр каты хөкем итеп утырасың, – диде Нәсимә. – Әти дөрес әйтә, аның ни сәбәпле әсир төшүе дә роль уйный бит. Пленда ачтан үлмәс өчен легионга кергәндер.

Сәет чәен эчеп куйды:

– Ачтан үлмәс өчен сатылырга кирәкме?! Синең абыең сугышта һәлак булып калды. Аның да, бәлки, җан сакларга мөмкинлекләре, җае булгандыр. Һәлак булган бит!

Нәсимәнең шундук бите буйлап күз яше тәгәрәп төште:

– Шул абыйсыз калганга, үлемнең ни икәнен белгәнгә, энең турында алай сөйләштерәсем килми.

Нәгыйм урыныннан кузгалды:

– Ярар. Ничек булган шулай булган инде. – Ул Сәеткә дәште: – Ашадыңмы?

– Ашадым, – диде Сәет. – Ашамыйча да тук булырсың монда.

– Киттек, сарай идәнен рәтлибез.

14

Алар чыгып китәргә җыенганда, ишек ачылды. Керүче әллә үзе тып-тын гына кердеме, әллә аның капканы ачканын, өйалдына аяк басканын кызу әңгәмә аркасында сизмәделәрме, бусагада какча гәүдәсенә иске бушлат кигән кеше пәйда булгач, өчесе дә сискәнеп киттеләр.

Хәер сорашучымы бу, юлдан арыган мосафирмы? Битендә җәрәхәтләрдән хасил булган җөйләр сузылган, күзләре нindидер мәңгелек куркудан акаебрак торалар шикелле.

Ул күгәргән иреннәрен чак кына кыймылдатып аваз салды:

– Исән-саулармысыз!

Аны беренче булып әнкәсе танып алды:

– Яббар! Улым!

Өйдәгеләр тораташ булып катып торган арада, Яббар тагын исәнләште:

– Исәнмесез!

Сәет, энесеннән күзләрен алмыйча, түр сәкегә барып утырды:

– Исәннәр, күргәнеңчә.

Яббар атасына карады:

– Исәнме, әти.

Нәгыйм, башын аска иеп:

– Исәнме, – диде дә Сәет янына барып урнашты.

Яббар әнкәсенә карап елмаймакчы иде, әмма елмаю урынына аның иреннәре генә кыймылдап алды, ияге дерелдәп куйды. Күңелендә аз гына кыймылдаган шатлыгын әнкәсенә күрсәтәсе ки-

леп, карлыккан тавышына наз төсмере кертергә тырышып эндәште:

– Исәнме, әнкәй!

Әминә, ниһаять, көчкә һушын җыеп, әле һаман ишек катында басып торган улына таба атлады:

– Улыкаем, балакаем, җанкисәгем кайткан! – Ана ике куллап улының каты яңакларын сыпырды. – Кайтып җиттеңме, балам!

– Кайтып җиттем, әнкәй.

Әминә кече улының маңгаендагы тирән булып буй-буй сызылган җыерчыкларга игътибар итте. Карап торуга кырык бишилле яшь бирерлек иде Яббарга.

– Сине бит бөтенләй танырлык түгел, – диде Әминә, улының бөтенләй башка кешегә әверелеп кайтуыннан җаны сызлый башлаганны тоеп.

– Танымасалар, бәлки, яхшырактыр, – дип куйды Нәгыйм.

– Әйтмә дә, – дип җөпләде аның сүзен Сәет. – Исем-фамилияңне дә үзгәртеп кайтырга идең.

Әминә ире белән олы улының Яббарга карата каты бәрелүләрен күреп котсыз калды:

– Сәет, улым, ник алай дисең?! Энең кайткан бит, күрмисеңмени! Сөенергә кирәк. Ә син, атасы...

– Сөенергәме, көенергәме, белгән юк инде, аптыраган, – дип, аның сүзен бүлде Нәгыйм.

Әминә, Яббар тирәсендә бөтерелеп, аны башыннан аягына кадәр күзәтте:

– Сез нәрсә! Яббар улым кайткан бит. – Улының күзләренә карап, ана кеше мең сорауга берьюлы җавап алырга теләде, әмма, баласының күз карашындагы газапны күреп, ана котсыз калды. – Нишләп болай картаеп кайттың, улым? Абыеңнан да олырак күренәсең.

– Күп вакыт узды шул, әнкәй, киткәнемә ун ел бит инде.

– Әйе шул. Киткәндә сабый гына идең әле син.

Яббар өй эченә күз йөгертте – таныш исләр, таныш әйберләр, бала чактан ук таныш нәрсәләр, якын кешеләр... Әмма шатлык урынына тирән сагыш, авыр кайгы хөкем сөрә – йортта да, күңелдә дә.

– Ничек яшәп ятасыз? – диде Яббар, анасына карап.

– Синең турыда хәбәр килгәч ничек яшәргә тиеш без, үзең уйлап кара! – диде Сәет. – Әгәр инде уйларлык акылың калган булса!

– Туктале син, Сәет, ник алай каты бәреләсең! – диде Әминә, ачыргаланып. – Үз туганыңны дошман итеп утырасың.

Нәгыйм, идәнгә текәлгән килеш:

– «Изменник Родины» дигән яманат белән утырып чыктыңмы? – диде.

Яббар, беравык дәшми торганнан соң:

– Әйе, шулай, утырып чыктым, – дип, атасына таба атлады. – Әти, мин изменник түгел!

– Легионер булгач, кем буласың инде син?! – дип җикерде Сәет. – Аннары тикмәгә утыртып куймаганнардыр бит?

– Мин үзебезнең якка чыгар өчен легионга кердем. Котылырга бу бердәнбер чара иде. Башкача исән калмас идем.

– Пленга ничек эләктең? – дип кычкырды Сәет.

Яббарның өйдә дә сорау ала башлауларыннан җаны әрнеде.

– Миңа моны инде мең мәртәбә сөйләргә туры килде, – диде ул, чак кына ишетелерлек итеп.

– Син аны допрослап утырма инде, – диде Әминә. – Энең кайткан бит, аңлыйсыңмы?

Сәет торып басты:

– Энем... Авылыбызда бердәнбер сатлыкҗан бар – Яббар! Шуны аңлыйсыңмы соң син!

– Мин сатлыкҗан түгел, абый! – диде Яббар ялварулы тавыш белән.

– Кем соң син?! – диде Сәет, кыҗрап. – Легионер булгач, сатлыкҗан булмый кем буласың соң син?! – Ул Яббар каршысына килеп басты. Әйе, үзгәргән, бик нык үзгәргән энесе, сугышка кадәрге Яббар түгел инде бу. Сәет тыныч кына сорап куйды: – Ничек яшәргә уйлыйсың хәзер?

– Белмим, – диде Яббар. Аннары атасына карап эндәште. – Нишлим соң?

Әминә өчен улларының сөйләшүе әллә ни әһәмияткә ия түгел, ананың күңелендә шатлык барыбер өстенрәк, баласы, кече улы исән, ул кайтты, менә ул каршысында басып тора. Нәгыймнең дә, Сәетнең дә Яббарны болай ямьсез каршы алулары тиз арада үтеп китәргә тиеш дип уйлады ул, аның хәтта бу хакта шиге дә юк иде. Сөйләшерләр, аңлашырлар, Яббар әллә нинди зур җинаять кылмагандыр әле. Кара эшләр кылырдай, җинаять юлына басардай, мәңге юылмаслык әшәкелекләр эшләрдәй баламыни соң аның Яббары! Әминә, ягымлы елмаеп, Яббарны җиңел генә түргә таба этте:

– Аягөсте торма, улым, уз түргә, үзең туып үскән йорт бит бу.

Нәсимә, өйдәге халәттән борчылып, кучкар янында тора иде. Яббар, аны күреп алгач:

– Мин Нәсимә булам, – диде ул. – Хәтерлисеңдер?

– Хәтерлим, нишләп хәтерләмәскә, – диде Яббар.

– Нәсимә – безнең киленебез, улым, – диде Әминә ягымлы тавыш белән.

– Бик әйбәт, – диде Яббар, елмаеп. Елмайганда да аның күзләре шулай ук чарасызлыктан акаебрак калды. – Исәнме, Нәсимә!

– Исәнме!

Яббар нишләргә белми торганда, Әминә аңа кабаланып урындык китерде:

– Утыр әле, улым, утыр. Менә монда яктырак. Әйбәтләп карыйм әле үзеңне. Сине күрмәгәнгә күпме вакыт узды бит. Улым, улы-ы-ым! Сине дә күрер көннәр бар икә-ә-ән!

Өйгә кайткач ата-анасының, абыйсының алдында басып тору-

ның авырлыгын күз алдына китерә иде ул, әмма болай ук газаплы булыр дип кемнәр уйлаган?! Әнкәсе нык картайган, әле аның яше алай ук күп түгел ләбаса. Әнә яулыгы кырыннан ап-ак чәчләре күренеп тора. Тәбәнәкләнеп, бәләкәйләнеп калган газиз әнкәсе. Минем өчен кайгырган, мин картайттым аны дигән уй Яббарның башыннан чыңлап узды.

– И әнкәй, – дип кенә әйтә алды ул.

Аның башка әйтер сүзе дә, еларга күз яше дә юк иде.

– Димәк, җан саклар өчен дошман ыстанына бастың? – дип бәйләнүен дәвам итте Сәет.

– Мин дошман ягына басмадым. Үзебезнең якка чыгар өчен легионга кердем. Бездә әсирләрне изменниклар һәм сатлыкҗаннар дип атый торган приказларны беләсеңдер бит? Инде әсир төшү белән үк үз илебездә дошман саналдык бит без! Шулай була торып та, хөкем итәрләр дип курыкмыйча, ни булса ул дип, үз ягыбызга качтык бит...

Нәгыйм авыр гына кузгалып, гадәттәгедән ныграк аксый-аксый ишек катына юнәлде.

– Боларны ничекләр кемнәргә аңлатмак кирәк! – диде ул һәм: – Хәзер инде нәселебезгә мәңге юылмаслык тап төште, – дип, ишекне шапылдатып ябып чыгып китте.

Өйдә авыр тынлык урнашты.

15

Легионер булса да, Яббар бик күп нәрсәне белми һәм аңламый иде шул.

Утызынчы еллар ахырында Германиядә нацистлар партиясенең (НСДАП) тышкы сәясәт эшләре бүлеге Россиядәге милли хәлләрнең торышы хакында мәгълүматлар җыюны көчәйтте.

1938 елның язында абвер шефы адмирал Канарис Россиядәге Гражданнар сугышында Колчакның, Деникинның, Врангельның, Юденичның җиңелү сәбәпләрен анализларга куша. Булачак сугышта Россиянең инкыйлабтан соңгы хәлләре хакындагы мәгълүматлар абвер өчен бик мөһим иде. Бу мәсьәлә белән шөгыльләнүче белгечләр үз отчетларында акларның тар-мар ителүен ике төп сәбәпкә бәйлиләр: беренчесе – башка милләтләрнең мәнфәгатьләрен инкарь итү, урыс булмаган милләтләрне санга сукмау, аларның проблемаларына күз йому, икенчесе – җир мәсьәләсенең хәл ителмәве.

Бу мәгълүматлар Адольф Гитлерга тәэсир иткәндерме-юкмы – әйтүе кыен, бу анализ нәтиҗәләре алга таба калыкмый кебек, ә шулай да СССРдагы милли сәясәткә игътибар кимеми. Киресенчә, милләтләр язмышын, милләтара мөнәсәбәтләрне җентекләп өйрәнү максаты белән, национал-социалистик партия кысаларында Германиянең Тышкы эшләре министрлыгы ярдәмендә Көнчыгыш бүлеге оештырыла (Oststelle). Ошбу бүлек Идел буе татарлары белән дә ныклап торып кызыксына башлый.

Гомумән, СССРга каршы сугышка әзерләнгәндә, Германия тарафыннан киң колач белән пропаганда сугышына әзерлек бара иде инде.

Сугышның беренче көннәреннән үк Кызыл Армия частьларына радио, громкоговорительләр, листовкалар аша, плакатлар, брошюралар белән тәэсир итү башлана. Максат бер генә – кызылармеецларның рухын какшату, вермахт гаскәрләренә каршы сугышуларын туктату һәм Германия ягына чыгу. Барлык мөмкинлекләрне файдаланып, «яңа тормыш хакына, кешеләрчә яшәү өчен» большевикларны юк итәргә өндиләр.

Сугыш башланган көннәрдә үк СССРның төрки халыклары турында Галимҗан Идриси зур документ туплый. Аның фикеренчә, СССРның төрки халыклары бердәм һәм Германиянең һөҗүмен алар яклаячак. Вәләкин аның чамадан тыш артык оптимизмы акланмый.

Оккупацияләнгән җирләрдә немецлар бик күп төрле халыклар белән очраша. Кайбер халыклар турында немецларның хәтта ишеткәннәре дә булмаган икән.

Германиядә «Көнчыгыш территорияләр китапханәсе» дигән китап сериясе чыга башлый. Бу брошюралар СССРның аерым территорияләренә генә түгел, аерым халыкларга, милләтләргә дә багышлана. Мәсәлән, «Көнчыгыш территорияләрдәге халыклар» дигән китапта Идел буе һәм Урал тирәсендәге халыклар хакында да бүлекләр бар.

Ә бит нацистларның җитәкчеләре сугышка кадәр СССР халыклары белән хәрби һәм сәяси хезмәттәшлек турында уйламаганнар иде. Сугыш башланып, Германия өчен ситуация яхшы якка үзгәрмәгәч, Германия җитәкчеләре хәрби теләктәшлек хакында сүз башлыйлар һәм СССРның төрле милләт вәкилләреннән Көнчыгыш легионнарын төзү идеясен күтәрәләр. Бу хәрби формированиеләрне төзү максатын Германия сугыш башында ук куя. Германиянең Тышкы эшләр министрлыгында махсус утырыш була. Әлеге утырышта доброволецлардан торган берләшмәләр төзү һәм аларны СССРга каршы көрәштә файдалану мәсьәләсе карала.

Германиянең СССРга һөҗүме дошманга иң беренчеләрдән булып каршылык күрсәтүче совет гаскәрләре өчен чын катастрофага әйләнә. 1941 елның ноябренә, Альфред Розенберг мәгълүматларына караганда, әсирләр лагеренда 3 млн. 600 мең кызылармеец исәпләнә. Аларның яртысыннан артыгы исән калмый.

1944 елның 1 маенда әсир кызылармеецларның саны 5 млн. 163 381 кеше була.

1945 елның февралендә, немецларның бер учреждениесе әйтүе буенча, совет әсирләре 5 млн. 734 528 гә җитә. Германия тарихчылары әйтүенчә, барлыгы 5 млн. 750 мең кеше әсир төшә, аларның 3 млн. 300 меңе үлә.

1941 елның августында Сталин 270 нче номерлы приказга кул

куя. Бу фәрманда әсир төшкән һәрбер кызылармеец дезертир һәм сатлыкҗан дип санала.

Шулай итеп, әсирлектәге кешеләр үз иле тарафыннан дошман дип таныла һәм икеләтә фаҗигагә дучар булган әсир кызылармеецлар бер яктан да иганә күтмиләр.

1917 елдан соң большевиклар җитәкчелеге 1899 һәм 1907 елгы Гаага конвенциясенең карарларын танымыйлар. Анда хәрби әсирләр турында да закон кабул ителгән була. Әсирләрнең яшәү шартлары 1929 елгы Женева конференциясендә дә тикшерелә, әмма Советлар Союзы бу халыкара документка да кул куймый.

Нәтиҗәдә халыкара хокукларның нормалары совет әсирләренә карата кулланылмый, аларга Сталин нормалары гына кала. Сталин фашист лагерьларында иза чигүче хәрби әсирләрне сатлыкҗаннар дип атый һәм алар яшәргә хаклы түгел дип саный.

Халыкара Кызыл Хаҗга берничә тапкыр мөрәҗәгать итү дә булышмый.

Германия 1941–1942 елларның кышында совет җитәкчелегенә хәрби әсирләр хакында тагын берничә тапкыр килешү төзергә тәкъдим итә. Әмма Мәскәү бу тәкъдимне кабул итми.

Бәлки, бу фашистларның яхшы булып кыланулары да булгандыр, чөнки алар Кремльнең үз әсирләрен гафу итмәячәгенә инде инанганнар. Гитлерның ихласлыгы шулай ук шик тудыра. Ләкин ничек кенә булмасын, Германия тарафыннан мондый тәкъдимнәр рәсми рәвештә ясала, СССР җитәкчелеге тарафыннан исә алар инкарь ителә.

Совет җитәкчелегенең мондый мөнәсәбәте фашистлар тарафыннан да безнең әсирләргә вәхшилекне көчәйтте. Әсир кызылармеецлар коточкыч шартларда тотыла – ачык һавада, ач-ялангачлыктан һәм төрле чирләрдән алар меңәрләп-меңәрләп үләләр. 1941–1942 елларның кышы бик салкын була. 1941 елның декабрендә көн саен немец лагерьларында 2500 ләп кеше үлә.

Польшадагы төрки халык вәкилләре тупланган Ченстохово лагеренда 30 000 кешедән 2000 е генә тифтан котылып кала.

Әсирләрне, табигый ки, исән калу өмете, котылу хыялы ташламый.

Хәрби әсирләр лагерьларында инде 1941 елның җәй азагында һәм көзендә Германиянең Көнчыгыш министрлыгы тарафыннан махсус вербовка командалары эшли башлый. Кайберәүләр бу мөмкинлектән файдаланырга омтылалар. Чәнечкеле тимерчыбык белән чолганган җир кисәгендә кәкрәеп үләргәме, әллә... Бик күпләре исән калып кире үзебезнекеләр ягына чыгу хәйләсе белән яшиләр. Дөрес, инде коммунистлар режимына нәфрәте уянып, фашистларга ихластан хезмәт итәргә атлыгучылар да шактый була, шулай да дошман киемен кияргә ризалашучыларның күбесе җан саклар өчен бу адымга бара.

Сугыш дәвам иткән саен, әсирләр саны арта, фронтның теге

ягыннан качып чыгучылар ишәя. Немецлар ягына үз теләкләре белән чыгарга омтылучылар да күбәйгәннән-күбәя бара.

1941 елның башында һәм 1942 ел буена вермахт байраклары астына СССРның төрле милләтеннән унар-унар мең кеше җыйнала. Шулардан ашык-пошык Көнчыгыш легионнарын төзиләр – Азәрбайҗан легионы, Әрмән легионы, Идел-Урал легионы, Грузин легионы, Төньяк Кавказ легионы, Төркестан легионы. Сугыш башланганнан соң, күп тә үтми, әсир татарларны махсус лагерьларга башка төрки әсирләр белән бер вакытта туплый башлыйлар. Шулай да Идел-татар легионы (яки «Идел-Урал легионы») иң соңыннан төзелә.

Көнчыгыш легионнардагы пропагандага дини төсмер кертүнең бигүк уңышлы булмавын нацистлар тиз аңлыйлар. Отчетларның берсендә Германия җитәкчеләренә мондый фикер тәкъдим ителә: «Советлар Союзындагы мөселманнар өчен милли мәсьәлә дини мәсьәләгә караганда әһәмиятлерәк. Татарларның 20–30 процентының гына дини үзаңы бар, калганнары – индифферент мөнәсәбәттә. Алар арасында муллаларның эшчәнлеге кәмит күренә, элекке заман, кадимчелек билгесе буларак кабул ителә. Татарларның лидерлары үзләре дини тәрбияне хупласалар да, барыбер дини мәсьәләләр һәрвакыт арткы планга күчә. Алга исә милли мәсьәләләр калкып чыга. Татарларга, җир эшкәртеп яшәүче крестьяннарга дини фанатизм бөтенләй хас түгел. Аларга ислам байрагы астында үзебез теләгән тәрбияне бирү мөмкин булмас, мөгаен».

1942 елның беренче июлендә төрле инстанцияләргә төзеләчәк легионнар турында документлар таратыла, анда Идел-татар легионы хакында да сүз була.

1942 елның 1 августында Гитлерның штаб-квартирасыннан штаб начальнигы Кейтель имзасы белән инде төзелгән легионнарга тагын бер легионны оештырып кушарга фәрман чыга – Идел буе татарларыннан, башкортлардан, татарча белүче чувашлардан, марилардан, удмуртлардан һәм мордвалардан оешырга тиеш була ул. Фәрман буенча, бу халыкларны аерып, махсус лагерьларга туплап, вербовка эшен активлаштырырга да кушыла.

Соңрак төгәлрәк күрсәтмәләр дә чыга:

1. Татарлардан, башкортлардан һәм татарча сөйләшүче Идел буе халыкларыннан легион төзергә.

2. Төркестан легионына теркәлгән татарларны Идел-татар легионына күчерергә.

3. Әсир татарларны кичекмәстән башкалардан аерырга һәм Седльцедәге лагерьга күчерергә (Варшава – Брест тимер юлы линиясендә урнашкан).

4. Төзелгән легионны партизаннарга каршы көрәштә файдаланырга тәкъдим ителә.

Шулай итеп, Идел-татар легионында – Уфа татарлары, Казан татарлары, башкортлар, татарча белүче чувашлар, марилар, удмуртлар, мордвалар туплана.

Идел-татар легионы 1942 елның 21 августында Радом янындагы Едлинода төзелә башлый, ә инде шул ук елның 6 сентябрендә легионга байрак тапшырыла һәм командиры итеп олы яшьтәге тәҗрибәле майор Оскар фон Зеккендорф куела.

Идел-татар легионының беренче батальоны – 825 нче батальон – 1942 елның ноябрь азагында формалаша, 1943 елның гыйнвар – февраль айларында исә 826 нчы һәм 827 нче батальоннар төзелә.

825 нче батальон пехота батальоны буларак туплана, аның составына штаб, штаб ротасы, тагын дүрт рота керә. Барлыгы бу батальонда 900 гә якын кеше була.

Яббар шушы батальонга эләгә...

Аның легионга керү теләге тиз генә тумады. Лагерьга пропаганда эше белән махсус кешеләр килә башлагач, әсирләр арасында легионга керергә кирәк дип сүз катучылар шактый булды. Кайберләре: «Безне инде илебездә болай да сатлыкҗан дип саныйлар, нимес формасын кисәк, ичмаса, исән калырбыз, ә аннары инде күз күрер», – дигән фикерне алга сөрделәр. Совет властен чын-чынлап дошман итүчеләр дә табылды. Легионга кереп, аннары беренче мөмкинлектә үк ничек булса да үзебезнекеләр ягына чыгарга тырышырга кирәк диючеләр бу ниятләрен иң ышанычлы кешеләре арасында шыпырт кына уртаклаштылар. «Фашист киеме кигәнче, үлү яхшырак!» – диючеләр дә булды. Бу турыда бөтенләй сөйләшергә теләмәүчеләр дә бар иде. Бу хакта сөйләшү түгел, хәтта уйларга хәле калмаганнары да шактый иде.

Хезмәттәшлек өчен кандидатуралар сайлап йөрүче пропагандистлар килгәч, Яббарда өмет уянды. Ул инде, бүтән беркайчан да ата-анасын, Фатыйманы, туган авылын күрмәм дип, үлем көтеп ята иде. «Әнә бит пөхтә киемле, ыспай кыяфәтле кешеләр килеп ягымлы итеп сөйләшәләр, фронттагы хәлләрне аңлаталар, араларында татарча сөйләшүчеләр дә бар. Ни гаҗәп, алар бит чын татарлар! Шулар ярдәмендә берәр ничек хәйләләп булмасмы?.. Легионга язылып, фронтка килгәч, үзебезнең якка качу мөмкинлеге тумый калмас. Ә анда инде ничек тә аңлатып булыр сатлыкҗан түгеллегемне, әсирлектән котылып үзебезнең якка чыгар өчен генә дошман киемен киюемне... Ничек тә котылырга кирәк, анда үзебезнекеләр хәлгә керерләр, аңларлар әле». Яббар кебек уйлаучылар шактый иде.

Лагерьдан лагерьга йөреп легионга керергә өндәүчеләрнең берсен әсирләр яхшы беләләр иде инде. Шәфи Алмас атлы кеше иде ул. Аның белән Яббар да танышты.

Әсирләр сафы алдыннан әкрен генә атлап барганда, Шәфи Алмас Яббар каршында туктады.

– Син кайдан? – дип сорады ул татарча.

Яббар әйтеп бирде.

– Кешечә яшисең киләме?

– Килә.

– Моның өчен большевикларны һәм аларның режимын юк итү зарур. Бу көрәштә синең кебек егетләрнең ярдәме кирәк. Керәсеңме легионга?

Яббар, турыдан-туры большевикларга каршы көрәшү хакында сүз башлангач, котсыз калды. Бу бит үз иленә каршы көрәшергә ризалык бирү була...

– Мин уйларга тиеш, – дип җавап бирде ул.

Шәфи Алмас надзирательләрнең берсенә немец телендә нидер әйтте, надзиратель Яббарга карап баш какты.

Әсирләрне тараткач, Яббарны баракка охшаган бер корылмага алып килделәр. Шунда аның белән Шәфи Алмас сөйләште. Яббар аның шома итеп, акыллы фикерләр кулланып сөйләвен игътибар белән, вакыт-вакыт сокланып, хәтта таң калып тыңлап утырды. Шәфи Алмас большевикларны күралмавын, СССРда халыкларны изүче режим урнашканын җөмлә аралаш ассызыклап сөйләде дә сөйләде.

Аның чын исеме Габдрахман Гибадулла улы Галиуллин икәнлеге, 1885 елны Татарстанда, Дөбъязда туганлыгы мәгълүм булды. Сәүдәгәр буларак, Мәскәүдә, Казанда, Оренбургта кибетләр тоткан. Гражданнар сугышы вакытында Төркиягә киткән, егерменче елларда хәтта бераз Мәскәүдәге Төрек илчелегендә эшләп алган. 1928 елдан Германиядә яши, йортлар, биналар тоткан һәм сәясәт белән шөгыльләнмәгән диярлек. Сугыш башлангач, немецлар аны «Интеррадио»га радиопропаганда эшенә алалар.

Шәфи Алмасның Сталин режимына карата нәфрәтенең сәбәбен Яббар еллар узгач кына тәгаен аңлаячак...

Яббар аны дикъкать белән тыңлап утырды. Ул инде легионга керергә карар кылды, ләкин һич тә Шәфи Алмас үгетләгәнгә түгел. Ата-анасы, Сәет абыйсы, Фатыймасы яшәгән илгә каршы сугышырга җыенмый Яббар. Аңа бу әсирлектән котылырга һәм үзенең туган иленә качып кайтырга кирәк.

Шәфи Алмас аңа текәлеп карап торды:

– Синең күзләрең бик сагышлы. Мондый моңлы күзләр туган илен нык сагынучыда гына булырга мөмкин. Син тиздән азат ителгән ватаныңда яшәячәксең, – диде аннан.

16

Туып үскән якның җылысын, балачагы узган төбәкнең яментәмен, чит җирләрдә чакта үләр дәрәҗәгә җитеп сагынган табигатьнең аһәңен җаны-тәне белән ничек кенә эстәргә тырышса да, авылдашлары дошман итеп карагач, Яббар туган җирендә басып торудан рәхәтлек тою түгел, хәтта күңел тынгылыгына да ирешә алмый җәфаланды.

Авылдашлары белән аралашырга омтылып карады ул. Әмма аны чит-ят иттеләр, очрашкач әйткән сүзенә коры гына җавап биреп яисә, бөтенләй дәшмичә, аның яныннан тизрәк китү ягын

карадылар. Шулай да аның белән гәпләшергә, дөресрәге, төрле авыр сораулар биреп төпченергә тырышучылар бар иде барын, андыйлардан исә Яббар үзе кача торган булды. Аңларга, хәленә керергә теләүчеләр дә юк түгел иде дә... Ләкин Кызылъярдан йөз алтмыш кеше сугыш кырларында ятып калды, ике кеше хәбәрсез югалды, күпмесе гарипләнеп кайтты, шулай булгач, ничек акласыннар да ничек якласыннар аның бу хәлдә калуын?!

Тора-бара ул үзе авылдашларының күзенә чалынмаска тырыша башлады. Ә өйдәгеләрдән, туган-тумачадан кайларга качып котылмак кирәк! Телисеңме-юкмы, бер түбә астында йоклыйсы, күз карашлары белән очрашырга да, сүз катарга да туры килә.

Бердәнбер кеше аңардан баш тартмады, бердәнбер олы җан иясе аны элеккечә яратты – әнкәсе. Әминә өчен улы Яббар сатлыкҗан да, легионер да, дезертир да, тюремщик та түгел, барыбер ул аның баласы, яраткан улы иде. Кече улының газаплануын күреп, ана үзе дә нык иза чикте, баласын бимазалаган хәсрәтнең аз гына өлешен булса да үзенә аласы килеп, аның белән утырып ягымлы иттереп сөйләште, аркасыннан сөйде, җылы, назлы сүзләр әйтте.

Беркөнне Нәгыйм белән Сәет урманга араталыклар әзерләргә барырга җыендылар. Яббар ишегалдында аларга эндәште:

– Мин дә барыйм әле сезнең белән.

– Йөрмә! – диде атасы, кул селтәп.

– Әти, миңа берәр эш куш инде ичмаса, – диде аңа Яббар.

Нәгыйм тавык кетәклегендә тавыкларга көрпә болгатып маташкан Әминәгә ымлады:

– Әнә анаң кушсын.

Балта, бау алып, Нәгыйм белән Сәет чыгып киттеләр.

Яббар лапаска кереп утын яра торган бүкәнгә утырды. Ул көннәр буе шулай ялгызы, кеше күзенә чалынудан качып, үз уйларына чумып утыра бирде.

Әминә кулына ябышып калган көрпәне сыпыра-сыпыра улы янына килде:

– Кайгырма, улым. Аларның ачуы бервакыт басылыр.

– Мине бөтен авыл күралмый, – диде Яббар хәлсез тавыш белән. – Миннән хәтта җирәнәләр. Китәргә туры килер, ахрысы. Туган авылымда яшәргә мөмкин түгел микәнни?! Мин, бәлки, туган ягымны артык нык сагынганга шушындый бәлагә дучар булганмындыр да.

– Китмә, улым. Болай да инде бик озак көттем. Мин сине бик сагыначакмын. Китмә. Түз. Халык ул усал да, миһербанлы да.

Анасы өйгә кереп киткәч, Яббар шактый вакыт үзенең караңгы уйларына чумып утырды. Бермәлне ул бөтен вөҗүде буйлап ниндидер дулкын йөгереп үткәнен тойды. Күңел ниндидер яңа төрле җиксенү белән аны урамга әйдәде.

Ул капканы гадәттәгечә кысып кына ачты һәм тыкрыкка таба, көянтә-чиләкләрен асып, Фатыйма узып барганын абайлады.

Дөнья чайкалып куйды, күз аллары томанланып китте. Фатыйма бит бу! Фатыйма! Үзгәргән ул. Ә шулай да гәүдәсендә дә, йөрешендә дә якын, кадерле чалымнар калган, якынрак килсәң, мөгаен, төс-битендә дә сөеп туймаслык мөлаемлык саклангандыр.

Аны ниндидер көч капкадан этеп үк чыгарды. Аяклары үзләре атладылар. Биш-алты адымнан соң ул якынаерга базмыйча туктап калды.

Бу вакытта Фатыйма инде тыкрык башына җитте, аның адымнары никтер авырайды, чиләкләр буш булуга карамастан, иңнәрендә зур йөк авырлыгын тойды. Арттан кемнеңдер карап торуын сизде ул. Фатыйма туктады, ләкин борылып карарга җөрьәт итмәде. Шулай беравык торгач, Яббарның якынрак килүен теләгәндәй, әкрен генә адымнар белән тыкрык буйлап атлады.

Яббар аны тыкрык уртасында куып җитте.

– Ничек хәлләр, Фатыйма? – диде ул, көчкә сулыш алып.

Фатыйма, авылдашларының күзәтүеннән куркып, як-ягына карады.

– Ярыйсы, – диде ул, чак кына ишетелерлек итеп.

Сугышка озатканнан соң Фатыйманың әле аны якыннан күргәне юк иде. Яббарның кыяфәтен, йөзен, күзләрен күргәч, аның тизрәк китеп барасы килде шикелле, ләкин шул ук вакытта аны ниндидер бер хис урынында калырга мәҗбүр итте. Шул Яббармы соң бу? Йөрәкләрне җилкендереп үзенә гашыйк иткән шул егетме соң бу? Фатыйма аны кызганып чак кына елап җибәрмәде. Ләкин хәзерге минутта елау Яббарның җәрәхәтле җанын тагы да ныграк әрнетер дип, Фатыйма үзен тыярлык көч тапты. Шулай да аксылланып киткән бите буйлап ике күзеннән ике яшь бөртеге тәгәрәп төште.

Алар шактый вакыт бер-берсен күзәттеләр. Юк, алар инде башка кешеләр, бер-берсенә тартылу да юк шикелле, нәрсәдер сүнгән, үлгән... Икесенең дә күңелендә әйтеп булмаслык тирән сагыш кына күз яшьләре булып атылырга тора.

– Әйбәттер хәлегез, – диде Яббар карлыккан тавыш белән. – Улыгыз үсеп килә. Гаиләгез тулы. Бик нык үзгәргәнсең. Чибәрлегеңне исә һич кенә дә җуймагансың.

Фатыйма ни әйтергә белми торды, үзенең бәхетле булып күренүеннән хәтта оялып, читенсенеп куйды, Яббар алдында үзен гаепле сизде.

– Син дә бик нык үзгәреп кайткансың, – диде ул боек тавыш белән.

– Үзгәрдем. Миндә бөтен нәрсә үзгәрде. Минем өчен дөнья үзе үзгәрде.

– Нишләргә җыенасың?

Яббар елмайгандай итте:

– Миннән бөтен кеше шулай дип сорый: нишләргә җыенасың? Китәргә туры килер.

– Кая?

– Белмим, – диде Яббар, Фатыймага текәлеп. – Син шундый

чибәр! Син хәзер гел башкача гүзәл. Бәхетле икәнең әллә каян күренә.

– Хәлләремне үзем генә беләм, – диде Фатыйма сагышлы тавыш белән. – Бәхетлеме, юкмы икәнлеген дә кеше үзе генә белә.

Яббарның күңелен якты хатирәләр дер селкетте. Фатыйма белән кулга-кул тотышып болыннарда йөгереп йөргәннәр иде бит алар. Фатыйма хәзер аныкы түгел. Ул инде моннан ун ел элеккеге Фатыйма да түгел. Ул җитлегеп олыгайган, ул инде үзе ана кеше. Күрше йортка килен булып төште ул хәзер. Янәшә генә югыйсә, ә инде бөтенләй ерагайды. Чит кешенеке ул.

– Шуны әйтәсем килә. Бик сагындым сине, – диде ул, халәтен ничек аңлатырга белмичә. – Һич кенә дә мәхәббәтем сүрелми. Хәтта бәгыремә асылынган бәла дә сине яратуымны баса алмый. Син уфтанасыңдыр инде, шушы сатлыкҗан белән йөргәнием бит яшь чакта дип.

– Син сатлыкҗан түгел, – диде Фатыйма, аның тоныкк күзләренә карап.

– Бөтен авыл шулай ди бит.

Фатыйманың тагын бите буйлап күз яше тәгәрәп төште:

– Ә мин сиңа ышанам. Син инде халык алдында җитәрлек күп акландың, түбәнсендең. Кирәкми, җитәр. Син мескенләнгән саен, алар сине ныграк басачаклар.

Яббар Фатыймадан мондый сүзләрне ишетермен дип һич кенә дә уйламаган иде.

– Дөрес әйтәсең, – диде ул, кинәт җанланып. – Димәк, син миңа ышанасың?

Фатыйма тагын як-ягына каранып куйды да, башын аска иеп:

– Минем күңелемдә син элеккеге якты йөзле, олы йөрәкле, әйбәт егет булып калдың, – диде. – Тик... миңа бик очрамаска тырыш инде. Әнсарның ачуы килә. Кайвакыт, бераз салып алса, көнләшүе чыгып куя. Әле беркөнне: «Теге изменник Родины кайткач, сәерләнеп, сүрелеп калдың», – дип бәйләнде.

Яббар башын аска иеп уйланып торды.

– Их, Фатыйма! – диде ул, башын күтәреп. – Югыйсә арабызда нибары бер тыкрык кына хәзер. Ләкин ерагайдык бит берберебездән!

Фатыйма кешеләр күргәнче китәргә ашыкты.

– Якынайсаң да, ерагайсаң да, халык әйтмешли, язмыштан узмыш юк, – диде ул, кузгалганда.

– Әйе, халык әйтә ул, – диде Яббар, торган урынында калып. Һәм кинәт өстәп куйды: – Яшь чагыбызны өзелеп сагынам!

Фатыйма туктап борылды:

– Мин дә. Ләкин үтте китте инде ул чаклар, язмыш үзенекен итте. Әгәр дә якты йөз күрсәтмәсәм яисә читләтеп узарга тырышсам, ачуланма. Ирем көнләшкәнгә генә түгел... Мин авыл халкының ихтыярына буйсынырга мәҗбүр инде. Авыл сиңа ничек

караса, мин дә шулай карарга тиеш булам. Татарның гап-гади бер хатын-кызы мин.

Яббар, тыкрыктан менеп, кая барырга белми аптырап торды, аннары үзләренең читәне буендагы чирәмгә йөзтүбән капланды. Җан сызлавы белән бергә юкка чыгарга иде, иңәргә иде, сеңәргә иде шушы җиргә. Ишетерләр, күрерләр дип уйламыйча, ул сулкылдап елады.

Үзләренең бакчасында түтәл утап маташкан Зәкия аны читән өстеннән үрелеп-үрелеп күзәтте. Аннары эшен ташлап, кызу-кызу адымнар белән ишегалдына үтте, шыгырдатмас өчен саклык белән генә капкаларын ачып урамга чыкты. Яббарның гәүдәсен калкытып, коймага терәлеп утырганын күргәч, Зәкия, барган җиреннән шып туктап, бермәл генә басып торды да Яббарны танымаган булып кыланып якынрак килде:

– Яббар, синме бу?

– Мин булмый кем булсын тагы, – диде Яббар, аңа карамыйча гына.

– Нинди исерек аунап ята дип торам.

– Мәет ята дип уйламадыңмы?

– Әстәгъфирулла! – дип кулын селтәде Зәкия. – Шулай диләрмени! Шуны сорамакчы идем, авылда калмакчы буласыңмы?

Яббар аның соравыннан көлемсерәп куйды:

– Зәкия апа, ник соң син «Бу дөньяда калмакчы буласыңмы?» дип кенә сорамыйсың?

Зәкия, кыяфәтенә ясалма курку чыгарып:

– Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла! Нишләп сүзне гел андыйга борасың? – дигән булды.

– Гел бертөрле сорауларны ишетәм: нишләмәкче буласың, ничек яшәргә җыенасың, авылда каласыңмы, китәргә җыенмыйсыңмы?

– Тагын ни дип сорасыннар инде?!

– Син, Зәкия апа, алай карама миңа.

– Ничек?

– Җирәнүле кызгану белән.

– Ялгышасың.

– Син, гомумән, безнең гаиләгә карата ничектер салкынайдың. Әнкәйне дә хәзер элеккечә якын итмисең. Әнкәйнең ни гаебе бар, ник аның белән аралашмый башладың?

– Сез үзегез кыргыйландыгыз, – диде Зәкия акланып.

Килененең тыкрыктан менеп килүен күргәч, ул аңа:

– Фатыйма, нишләп бик озак йөрисең? – дип кычкырды. – Чыгып киткәнеңә бер сәгать бардыр.

– Кая бер сәгать булсын инде! – диде Фатыйма үпкәле тавыш белән.

Фатыйма, Яббар ягына карамаска тырышып, сулга каерылды, Зәкия, җил-җил атлап, аны кертергә дип капканы ачты.

Яббар, коймага сөялгән килеш, үзенең караңгы хатирәләренә чумып әле бик озак утырды.

17

825 нче батальонны фронтка озату тантанасы 1943 елның 14 февралендә узды.

Оркестр тавышы, җилфердәгән байраклар, күңел тулы курку катыш өмет, күз карашларын билгесезлеккә төбәгән легионерлар... Фронтка китүчеләр алдында чыгыш ясаучылар шактый иде. Яббар бигрәк тә Берлиннан Едлинога доклад белән килгән профессорның чыгышын яхшы хәтерли. Ул урысча да, татарча да вата-җимерә, авыз кырыйларын күбекләндереп, вакыт-вакыт ярсуга күчеп сөйләде дә сөйләде. Мондый чыгышлар ясап шомарып беткән бу пропагандистның һәрбер җөмләсе тавышының сирәк очрый торган бай тембры белән бергә нык тәэссоратка ия иде. Ул бик оста, урыны-урыны белән тетрәндергеч итеп большевикларны юк итәргә өндәде, Гитлер татар дәүләте төзиячәк, дип каткат тәкрарлады.

18 февраль төнендә батальон Витебскига килеп җитте, шуннан Суражск шоссесы буенча Белыновичи авылына таба юл алды. Батальонның төп өлеше Көнбатыш Двинаның сул ягындагы Гралево авылында урнашты.

Батальон оешкан вакыттан бирле үк легионерлар арасында үзебезнекеләр ягына – Совет Армиясе ыстанына чыгу турында берөзлексез пыш-пыш килүләр туктамады. Ләкин арада чын сатлыкҗаннар да бар иде. Сталин режимына каршы көрәшергә ихластан ризалык биреп корал алганнар янында мондый сүз сөйләү үлемгә тиң. Инде берничә кеше шулар аркасында харап та булды. 900 кешенең 70 кә якыны немецлар (болар – батальонның командирлар составы) һәм ихластан дошман ягына чыгып Совет Армиясенә каршы сугышырга теләк белдергән сатлыкҗаннар булганлыктан, легионерлар арасында шомлы, аңлашылмаслык атмосфера хөкем сөрүе табигый иде.

Партизаннар актив хәрәкәт иткән тарафларга якынайган саен, үзебезнекеләр ягына чыгу теләген батальон легионерларының күбесе белдерә иде инде. Таҗиев, Рәхимов һәм Мөхәммәтов фамилияле кешеләрнең партизаннар ыстанына чыгуны оештырачакларын Яббар ишетеп кенә белә иде, роталар арасында элемтәне исә махсус кешеләр тәэмин итеп торды. Яббар бер икеләнүсез тизрәк үзебезнекеләр янына качу турында хыялланды.

21 февральдә легионерлар тарафыннан партизаннар белән элемтәгә керү өчен дүрт парламентер җибәрелә. Партизаннар үзләренең шартларын куялар: беренчедән, партизаннар ягына күчәр алдыннан батальон немец офицерларыннан торган командный составны юк итәргә, шуннан соң Сеньково, Гралево, Сувары авылларындагы немец гарнизоннарын тар-мар китерергә тиеш. Икенчедән, легионерларга партизаннар ягына өч төркемгә бүленеп күчәргә кушыла. Өченчедән, партизаннар ыстанына чыкканнан соң, легионерлар коралларын ташлап, боеприпасларын парти-

заннарга тапшырырга тиеш булалар. Бу шартларны, әлбәттә, партизаннар үзләренең куркынычсызлыгы өчен куялар.

Сөйләшүләр барышында карар кабул ителә – 22 февральдә 23 сәгатьтә легионда гомум восстание күтәрелергә һәм легион кораллары, боеприпаслары, җиһазлары белән партизаннар ягына чыгарга тиеш.

Кызганычка каршы, батальондагы немец офицерлары фетнәчеләрнең планнарын сизәләр һәм, баш күтәрер вакытка бер сәгать калгач, восстаниенең җитәкчеләре Таҗиев белән Рәхимов кулга алына. Штаб ротасының командиры Хөсәен Мөхәммәтов, үзен аямыйча, шул хәлиткеч вакытта җитәкчелекне үз өстенә ала. Немец офицерларын үтереп, төрле авылларда урнашкан подразделениеләргә сигнал бирелә, һәм восстание башлана. Бары тик икенче ротаның ике взводына гына хәбәр итә алмый калалар.

Партизаннар бригадасының командиры Бирюлин шул ук төнне партизан хәрәкәтенең төп штабына хәбәр итә: «...Безнең якка 506 кеше чыкты, үзләре белән өч 45 миллиметрлы пушка, 6 станоклы пулемет, 4 батальон минометы, 22 кул пулеметы, 430 автомат, 76 пистолет, 26 ат һәм башка күп нәрсәләре бар. Легионерлар Захаров һәм Бирюлин җитәкчелегендәге партизан отрядларына беркетелделәр...»

Партизаннарга кушылган легионерлар шундук вермахт армиясенә каршы сугышта катнашалар. Бигрәк тә 1943 елның 28 февралендә блокададан чыкканда каты сугыш була.

Смерш контрразведкасы батальонның партизаннар ягына чыгу тарихын, сәбәпләрен, нечкәлекләрен җентекләп тикшерә. 1943 елның июнь азагында Подольск шәһәрендә урнашкан 174 нче спецлагерьның контрразведка бүлеге начальнигы майор Кирсанов һәм шул ук лагерьның контрразведка начальнигы Сизов Мәскәүдә урнашкан партизаннар хәрәкәтенең Белоруссия штабына 825 нче батальонның безнең якка чыгуы турында отчет җибәрәләр: «...Подольскидагы спецлагерьда милләтләре буенча татар булган элекке кызылармеецлар бар. Алар әсирлектә чакта немецлар оештырган Идел-татар легионына хезмәткә кергәннәр һәм партизаннарга каршы сугышырга җибәрелгәннәр...»

1943 елның 2 июлендә партизаннарның Белоруссия штабы хәбәр итә:

«...Батальон партизаннар ягына чыкканнан соң, аның составы партизан отрядларына таратылды һәм легионерлар немец оккупантларына каршы сугышта катнашалар...»

Әйе, легионерларның 825 нче батальоны партизаннар ягына чыккач, аның составының зур өлеше төрле отрядларга таратыла. Ләкин кайберәүләр бик җентекле тикшерү, допрослар аша үтәргә тиеш була. Аларны Подольскида урнашкан фильтрация лагерена алып киләләр. Монда шик астына алынган легионерлар төрле сәбәп белән эләгә – тәрҗемәи хәлләрендәге мәгълүматлардагы чуалыш аркасында, кемнеңдер шикаяте нәтиҗәсендә, үзен тоты-

шы белән сәер күренеп, ничек һәм нинди шартларда дошманга әсир төшүен исәпкә алып. Кыскасы, төрле-төрле сәбәпләр табып тикшерү үтәләр.

Яббар да эләкте бу лагерьга. Партизаннар отрядындагы НКВД вәкиле аңарга мондый сорау биргән иде:

– Легионга иң беренчеләрдән булып кемнәр керде?

Яббар белә иде ул кешеләрне. Ләкин әйтмәскә булды һәм болай дип җавап бирде:

– Мин, каяндыр агитаторлар килеп әйдәгәннән соң, исән калып, үзебезнекеләр ягына чыгар өчен, легионга керергә карар кылдым. Ә легионга кергәндә, анда кеше күп иде инде, мин кемнәр беренче кергәнне әйтә алмыйм.

– Синең дустың Башкортстаннан Хәнәфиев иң беренчеләрдән булып немец формасын киярга өндәгән бит, моны белмәдеңмени?

Әйе, Башкортстан егете Хәнәфиев Габделбәр белән Яббар дуслар иде. Легионга кереп исән калу һәм фашистлардан котылып үзебезнең ыстанга чыгу турында алар бергәләп хыялланып йөрделәр. Әле Яббар икеле-микеле йөргәндә үк, Габделбәр катгый карар кылып, легионга беренчеләрдән булып язылган иде.

Әмма Яббар, Габделбәрнең язмышы өчен куркып, дөресен әйтмәскә булды.

– Без якын дуслар түгел идек. Йоклый торган урыннарыбыз янәшә иде. Мин аның кая, ник, нинди оешмага язылганын беркайчан да сорамадым, үзенең дә әйткәне булмады. Аның беркемне дә өндәгәнен яки легионда яхшы булачак дип сүз катуын ишетмәдем. Ялгышмасам, без легионга бер тирәдәрәк кердек, ләкин бер-беребезне үгетләп түгел.

Аның мондый җавабын НКВД вәкиле ошатмады. Чөнки Хәнәфиев Габделбәр өстеннән бик күп шикаятьләр, күрсәтмәләр җыелып, шактый материал тупланган иде инде. Аны хөкем итәчәкләрендә шик юк иде. Хәнәфиев өстеннән күрсәтмә бирмәгәне өчен, Яббарны да фильтрация лагерена озаттылар.

Күпмесен хөкемгә тартканнардыр, ничәсен кире партизан отрядларына кайтарганнардыр, Яббарга мәгълүм булмады. Ә аның үзен исә, ике атна чамасы кат-кат допрос алганнан соң, егерме дүрт кешедән торган элекке легионерлар төркеме белән янә Бирюлинның партизаннар бригадасына илтеп тапшырдылар.

18

– Күрше! Туктале!

Яббар Хәлиулланың тавышын ишетеп туктады, аның салмак кына атлап килүен сабырлык белән көтте.

– Нәрсә, Хәлиулла абый? – диде Яббар, юньле әңгәмә булмасын алдан ук сизенеп.

– Күптән синең белән ихластан сөйләшәсем килә, – диде Хәли-

улла, маңгаендагы тирен кул арты белән сыпырып. – Моңарчы һич кенә дә җай чыкмады.

– Минем ише белән сөйләшергә теләгәнең өчен рәхмәт инде. Дөрес, синнән җылы сүз ишетмәячәгемне дә алдан ук белеп торам.

– Ярар, сүз башланмаган килеш шыңшырга тотынма әле, – диде Хәлиулла. – Мин сиңа начарлык теләмим ләбаса. Мин шуны сорамакчыем... Әгәренки легионга кермәгән булсаң, үтерерләр иде микәнни?

– Нимесләрме? Бәлки, үтерерләр иде... Белмим... Минем тизрәк үзебезнекеләр ягына качасым килде.

Хәлиулла чыраена ясалма борчылу чыгарды:

– Менә ышанмыйлар шул! Бер дошман киемен кигән кешегә ышанасылары килми шул.

Яббар төссезләнгән күзләре белән читкә карады:

– Син минем ныграк газаплануымны телисеңме, шуңа бу турыда сүз катасыңмы?

Хәлиулла усал гасабилык белән кызу-кызу сөйләргә тотынды:

– Юк, миңа, киресенчә, синең бимазалануыңны күрү авыр. Менә сиңа алга таба нишләргә икән дигән сорауга бергәләп җавап табып булмасмы дигән идем. Син, минемчә, авылга кайтып дөрес эшләмәдең. Беркавым читтә яшәгәч кайтырга идең.

– Мин авылымны, туган ягымны сагындым, – диде Яббар, ишетелер-ишетелмәс итеп, гүя ул аны кемгәдер түгел, ә үз-үзенә генә әйтте. – Әнкәйне сагындым. – Ул Хәлиуллага туры карап өстәп куйды: – Әнкәйне бүтән күрә алмам дип куркып, легионер киемен кидем дә инде мин.

– Сине хәзер кайда нинди рәтле эшкә алырлар икән? Шулай да, уйлавымча, авылда калмасаң яхшырактыр.

– Мин сиңа комачаулыйммы? – диде Яббар, кинәт кызып. – Мин кайтканнан тормыш бозылдымы? Син әйткән киңәшләрне әллә ничә кат ишеттем бит инде. Мин үзем инде меңләгән вариантларны башымнан уздырдым!

Аларның сөйләшеп торуларын Әнсар койма ярыгыннан күзәтте. Яббарның җикергәнен ишеткәч, ул атылып урамга чыкты. Аның җил кызулыгы белән килеп җиткәнен сизми дә калдылар.

– Әти, сине әнкәй чакыра, бар, өйгә кер, – диде ул атасына, эчке ярсуын яшерә алмыйча.

Хәлиулла Яббарга:

– Олы кеше сүзенә колак салсаң, үзең өчен яхшы булыр дип уйлаган идем, – диде дә өйләренә таба юнәлде.

– Рәхмәт! – дип кычкырды Яббар аның артыннан усал тавыш белән. – Миңа яхшылык теләп әйтмисең син сүзеңне!

Әнсар атасының капкадан кереп киткәнен көтеп торды да Яббарны түшеннән йомарлап тотты:

– Син нишләп тавышыңны күтәрәсең, ә?

– Миңа бернинди киңәш тә, үгет-нәсыйхәт тә кирәкми, – диде Яббар тыныч кына.

– Моннан ары минем әтигә җикермә! – дип кычкырды Әнсар, Яббарның битенә төкрекләрен чәчеп. – Аңладыңмы?!

– Син миңа бала чактагы сыман бәйләнергә маташасың. Берегез дә миңа килеп вәгазь укымагыз! Нотыкларыгызның кирәге юк – миңа да, сезнең үзегезгә дә! Миңа киңәшләр бирүегез ул фәкать мине күралмавыгыздан. Миңа карата булган нәфрәтегездән!

– Син – изменник Родины!

– Мин изменник түгел!

Әнсарның ярсуы тәмам бәреп чыкты:

– Син бук! Һаман акланмакчы буласыңмы?! Тикмәгә утыртмадылар сине! Изменник Родины!

Яббар куркудан түгел, ачудан, эчендә кайнаган давылдан калтырана башлады:

– Мин бүтән беркайчан да, беркем алдында да акланмаячакмын! Кешене аңларга теләмәүләре аркасында анда лагерьлар тутырук. Анда тикшерүчеләр нәкъ менә син хәзер миңа ышанмаган шикелле ышанмыйлар. Бәлагә дучар булган миллионлаган кешеләрнең сүзенә колак та салмыйлар, хөкемгә тарталар, таптыйлар, бетерәләр, юк итәләр.

Әнсар муенындагы кан тамырларын бүртереп кычкырырга тотынды:

– Мин Туган ил алдында, партия алдында үз бурычымны намус белән үтәдем, дошманны көнбатышка кудым, яраланып, офицер званиесендә, орден-медальләр белән кайттым. Минем кебекләр синең ишеләргә беркайчан ышанмаячаклар, һәрвакыт хөкем итәчәкләр! Аңладыңмы, изменник?!

Бу вакытта Нәгыйм белән Сәет урманнан кайтып киләләр иде. Алар капка төбендә Әнсар белән Яббарның якалашуын ерактан ук шәйләделәр. Сәет Әнсарның Яббарга нинди сүзләр әйткәнен дә аермачык ишетте.

– Бу кадәре нәфрәтең белән тончыга күрмә, – диде Яббар тыныч кына.

– Авылда эзең дә булмасын! – дип акырды Әнсар, йодрыкларын төйнәп. – Мин сиңа монда барыбер тормыш күрсәтмәячәкмен!

Шулчак аңа Сәет ерактан ук эндәште:

– Силсәвит рәисе булсаң да, синең кешене авылдан куарга тулы полномочиең юк!

– О-о-о, бала чактагыча энекәшеңне яклыйсыңмы? – диде Әнсар, кайтып килүчеләргә таба борылып.

– Аны яклаучы юк, сиңа да монда командовать итәргә ирек бирүче юк, – диде Сәет коры гына.

– Влач кешесе белән ызгышма инде, – дип пышылдады Нәгыйм, улына терсәге белән төртеп.

Сәет кинәт атасына җикерде:

– Ызгышса! Без бит бөтенебез дә сатлыкҗаннар түгел!

– Син дә энең белән бергә бер бәйдә китмәгәең, – диде Әнсар, Сәетнең кулындагы балтадан бераз шүрләп.

– Китмәм, – диде Сәет, аз гына да курыкмыйча. – Мин – Берлинга барып җиткән кеше. Яббар җәзасын алды, аның газабы гомере буена җитәрлек. Синең бугаз киереп кычкыруыңнан бернәрсә үзгәрмәячәк. Яббарга авылда калу зуррак кайгы китерәме, әллә китүме – кем белгән?

Нәгыйм, матавыкның зурга китүеннән куркып, тизрәк Яббарга эндәште:

– Яббар, бар, анаңа кереп әйт әле, самавырны куйсын.

Яббарга шул гына кирәк иде дә, ул капылт кына капкадан кереп китте.

– Әти, бар син үзең дә кереп кит әле, – диде Сәет басынкы тавыш белән, атасына җикергәненә үкенеп.

– Мин керермен, – диде Нәгыйм, авыр сулап. – Балакайлар, сез икегез дә дошманны җиңеп кайткан егетләр. Үзегездәге дошманлыкны да җиңегез инде! Сез бит ир кешеләр.

Аның күзләре дымланды. Җиңе белән күз яшьләрен сыпырды. Тагын нидер әйтергә теләде, ләкин сүз табалмады, кулындагы бауны иңенә асып, Сәетнең кулындагы балтаны алды да капкадан кереп китте.

Сәет белән Әнсар беравык, сүзсез калып, бер-берсенә карап тордылар.

– Яббар безнекеләргә бер тапкыр да атмаган, – диде Сәет тыныч кына.

Әнсар көлемсерәп куйды:

– Аның сүзенә ышанасыңмы?

Сәет Яббар кайтканнан бирле беренче тапкыр энекәшен яклап сүз әйтте:

– Ышанам. Син ул, авылдашың була торып, шуны исбатларга булышмагансың. Синең бит ничек тә булса ярдәм итәргә мөмкинлекләрең булгандыр.

– Фильтрация лагерендамы?! – диде Әнсар, гаҗәпләнеп. – Син нәрсә! Анда берничек ярдәм итү мөмкин түгел. Ярдәм итә алсам, үземне дә изменник дип шуларның этабы белән җибәрерләр иде. Әле мин аңа ипи белән махорка биргәннән соң да бер атна куркып йөрдем, берәрсе начальствога әләкләп үземне кулга алмаслармы дип.

– Без күршеләр булсак та гел чәкәләшеп үстек. Алга таба да шулай дәвам итәр микәнни? Олыгаймадык микәнни?

– Без күршеләрмени? – диде Әнсар. – Безнең арада тыкрык бар бит. Ә хәзер инде тыкрык кына да түгел. – Ул авызын чалышайтып ямьсез иттереп көлде. – Күршеләр... Безнең арада хәзер – oho-ho!

Ул куен кесәсеннән папирос алып капты. Аннары чалбар кесәсеннән шырпы кабын чыгарып селкетеп карады. Кап буш бул-

ганга, ул аны читкә ташлады да, папиросын авызына капкан килеш, тиз-тиз атлап, үз өйләренә таба китеп барды.

Сәет ишегалдына кергәндә, Яббар лапас буендагы бүрәнәдә утыра иде.

– Абый, чынлап та, нишлим икән? – диде ул, Сәет аның янына килеп утыргач.

– Теләсәң нишлә! – диде абыйсы.

– Асылыныйм микән әллә?

– Үзеңә кара.

– Әнкәй кызганыч.

– Менә шул шул! – диде Сәет ачу белән.

Яббар абыйсына таба борылды:

– Абый, мин сатлыкҗан түгел, ышанасыңмы?

– Әсир төшеп, фашист формасы кигәнсең, яңадан фронтка килгәнсең... Шулай булгач, синең сатлыкҗан түгеллегеңә кем ышансын?

– Абый, мин бит фронтка килү белән үк үзебезнекеләр ягына чыктым!

– Ә ник әсир төштең?

– Ничек инде...

– Ник качарга тырышмадың? Ник йөгермәдең? Йөгерсәң, аткан булырлар иде, хәзер оят, хурлык кичереп ятмас идек, бимазаланмас идек.

– Их, абый! Син дә ышанмыйсың. Бала чакта син бик гадел идең, абый. Гаебем булса, әрли идең, хәтта тәпәләп тә ала идең. Берәр яхшылык эшләсәм, мактый идең. Син минем өчен һәрвакыт олы һәм абруйлы булдың. Минем өчен син хәзер дә шулай ук абруйлы, тик кая китте синең гаделлегең?! Хәтерлисеңме, син бер тапкыр су буенда күн каеш тапкан идең. Мин аны малайларга мактанып күрсәтергә алып чыктым. Аннан җыелышып урманга киттек. Каешны шунда онытып калдырганмын. Кайткач, син мине бик каты ачуландың да, бар кире урманга, каешны алып кайт, дип куып чыгарып җибәрдең. Мин елый-елый киттем. Ярты юлны узгач, син мине кызганып куып җиттең. Күзләреңдә яшь иде. Шунда синең мине нык яратуыңны тойдым, абый. Син, мине кочаклап: «Энекәш, ни пычагыма ул каеш, караңгы төшеп килә, әйдә өйгә», – дидең. Кайткач әле миңа сыбызгы бүләк иттең. Ул сыбызгыны мин бүген өй базында таптым. Мин аны югалткан идем, базга төшкән булган икән. Егерме ел яткан базда, череп беткән.

Сәет энесенең сөйләгәне тәэсирендә ни әйтергә белми торды. Аның үзенең дә тамагына төен тыгылды. Күңеле тәмам җебеп киткәнче коры гына әйтеп куйды:

– Синең аркада беребезгә дә көн булмаячак. Кайтмаска иде сиңа.

– Кайтмас идем... Әнкәй бар бит.

Сәет, каядыр югалып торган усаллыгын тагын барлап:

– Син хәзер аның иң зур кайгысы инде! – дип, урыныннан кузгалды.

Өйалды ишеген ачыйм дигәндә, ул энесенең лапаска йөгереп кереп киткәнен шәйләде. Сәет аның артыннан лапаска атылды. Яббар инде эленеп торган бауны алган, калтыранган куллары белән элмәк ясап маташа иде. Сәет бауны тартып алмакчы иде, Яббар читкә тайпылды. Аннары бавын тоткан килеш лапастан чыгып йөгерде. Сәет аны сарай артындагы тирес өеме янында куып тотты, чалып егып бауны тартып алмак булды. Ләкин Яббар бауны ычкындырмады.

– Җибәр! – дип ыңгырашты Яббар, абыйсының кулыннан азат булыр өчен бәргәләнеп.

Сәет аның кулын каера алмый җәфа чикте:

– Нишләргә җыенасың? Тинтәк!

– Асылынам! – дип үкерде Яббар аста яткан килеш.

– Менә асылынырмын мин сиңа! – диде Сәет, ниһаять, бауны талап алгач.

Яббар шашынып тирес саламында аунады:

– Яшисем килми!

Сәет, бауны беләгенә урый-урый:

– Әнкәй бар бит, җүләр! – диде. – Әнкәй барлыгын оныттыңмы әллә?! Асылынсаң, ул нишләр?!

– Нишлим со-о-о-оң?! – дип үкерде Яббар, абыйсына күзләрен акайтып.

Сәетнең күңелендә аз гына кыймылдый башлаган кызгану хисе урынына тагын рәхимсезлек урын алды:

– Син инде җайлы гына үлеп китү ягын карама. Хәзер инде ахыр чиккә кадәр үзеңнең хәсрәт йөгеңне күтәреп барырга тиешсең! Котылмакчы буласыңмы? Ә без бу хурлыктан ничек котылырбыз?

– Абы-ы-ы-й!!! – дип улады Яббар, чалкан ятып.

Абыйсы исә аның елаудан туктаганын көтеп торды да:

– Авылдан кит! – диде.

19

Яббар партизаннар отрядына кире эләгүенә куанып туймады. Хәзер инде сатлыкҗан дигән яманаты да юылыр, легионер булганы да тора-бара онытылыр. Бәлки, ата-анасы, Фатыйма, туган-тумача, авылдашлар бөтенләй белми калырлар дошман киемен киеп йөргәнен. Сугыш дәвам итә. Үлем куркыта куркытуын, ләкин әле күптән түгел кичергән халәте үлемнән дә яманрак түгел идемени?!

Хәер, легионга кермәгән булса, бәлки, бүген бу дөньяда йөрмәс иде инде. Бүген исә аның җанын өмет җылыта – сугыш тәмамлангач, ул, Алла боерса, Туган илгә, Кызылъярга кайтып, ата-анасы, Фатыймасы белән очрашачак.

Ләкин хыялдагыча гына булып чыкмады шул. Хата дисәң, хата түгел, аң томаланды дисәң, алай әйтү дә дөрес микән... Югыйсә отрядта аңа партизаннарның мөнәсәбәте яхшы иде, чөнки ул төрле заданиеләрдә үзен батыр, оста сугышчы итеп күрсәтте. Инде аның легионга үзебезнең якка чыгу хәйләсе белән кергәнлегенә шикләнүче юк иде, аны сатлыкҗан дип беркемнең кычкырып атаганы ишетелмәде. Дөрес, кырын караучылар бар иде, әмма андый гына өнәмәүләр дошман итүмени инде ул? Биографияләренә бөтенләй тап төшмәгән партизаннарның да үзара мөнәсәбәтләре төрле вакытта төрлечә иде әле.

Отрядта үз урынын табып, үзен Ватан өчен кан коярга әзер сугышчы итеп таныткач, тагын кулга алырлар һәм хөкем итеп ерак Себергә җибәрерләр дигән уй Яббарның башына да килмәгән иде. Соңыннан ул үзен нык битәрләде, үкенде, уфтанды шикелле, ләкин шул ук вакытта башкача мөмкин түгел иде дигән уй-фикер белән килешеп яшәде.

Нәрсә этәрде аны, нинди көч әйдәп чыгарды урман авызыннан ул немецны күмәргә?.. Ник атты соң ул аңа?! Атмаска да мөмкин иде бит. Аткач, ник барып карарга, ник күмәргә тотынды соң?..

Болай булды ул хәл. Яббарны Пилипенко фамилияле бер украин егете белән урман авызында каравылга куйдылар. Чигенеп баручы немец полкының калдыклары, урманнан чыгып, Калинковичи авылындагы гарнизоннары белән кушылдылар. Аларны эзәрлекләп баручы партизаннар да урман эчендә таралыптаркалып калганнар иде. Отряд командиры алдан кечкенә бер төркемне урман авызыннан немецларның Калинковичидан кайсы тарафка китүләрен күзәтергә җибәрде. Урманда берән-сәрән калган фашистларны юк итү белән мәшгуль булганлыктан, партизаннар бер юнәлештә җыйнала алмый интектеләр. Күзәтергә җибәрелгән төркемнең җитәкчесе Яббар белән Пилипенконы урман авызында калдырды, калганнары кире урман эченә кереп киттеләр.

Калинковичи авылында ыгы-зыгы купты. Фрицлар ашыгалар. Аларны юк итәргә тиешле дивизия шактый еракта әле, ләкин якында гына, урманнарда яшәп, утны-суны кичеп оста сугышырга өйрәнгән тәҗрибәле партизаннар һөҗүм итәргә торалар. Немецларның аларга каршы торырлык көчләре юк инде бу тирәдә. Алар тизрәк качып үзләренең төп гаскәрләренә кушылырга ашыгалар.

Авылдан уннан артык йөк машинасы, берничә танк, җиде-сигез броневик, йөкле атлар, мотоцикллар чыкканы күренде. Берникадәр вакыт узгач, шау-шу, техника тавышы, командалар ишетелми башлады – немецлар киттеләр.

Пилипенко, бу хакта кичекмәстән отряд командирына хәбәр итәргә кирәк дип, Яббарны үзен генә калдырып, урман эченә йөгерде.

Ун-унбиш минут чамасы вакыт үткәч, Яббар бер йөк машинасының кире авылга таба килгәнен абайлады. Авыл белән ур-

ман арасында ярты чакрым ара бар, кайчандыр иген кыры булган, ахрысы, монда. Авыл өстәрәк урнашкан, кырга чыга торган юл авыл кырындагы шактый текә калкулыктан аска таба китә. Күптән түгел яңгыр явып узганлыктан, машина юлдан кырга таба төшмәде, туктады. Машина арбасыннан берәү сикереп төште дә кырга йөгерде.

Урман ягына – үзенә таба йөгереп килүче дошманны күреп, Яббар аптырап китте. Күрәсең, фрицлар партизаннарның бу тирәгә үк килеп җиткәннәрен белмиләр. Чөнки алар үзләре кичә генә урман эчендә иде. Шуңа күрә курыкмый-нитми килә немец урманга таба. Коралсыз. Ник килә икән ул? Яббар каушабрак артка борылып карады – юк, Пилипенко да, башка иптәшләре дә күренми, урман гына үз көенә шаулап тора. Яббар винтовкасының затворын саклык белән генә тартты.

Ләкин немец, кыр уртасында туктап, нәрсәдер эзләргә тотынды.

Нәрсә эзли икән ул? Берәр серле мәгълүматлы документларнымы? Әллә үзенең берәр документынмы? Пүчтәк кенә нәрсә артыннан кире килмәс иде.

Машина яныннан кул болгый-болгый кычкыра башладылар.

Атаргамы, юкмы? Бер немецның урман белән авыл арасындагы кырда нидер эзләгәнен командирга барыбер әйтергә кирәк булачак. Ник ычкындырдың, ник атмадың, дип теңкәгә тиячәкләр.

Ә теге машина монда килсә һәм фрицлар урманны капшый башласалар?.. Атарга да, машина монда килә башласа, качарга кирәк булыр. Әллә атмаскамы? Тигезеп буламы, юкмы бит әле.

Менә немец иелеп җирдән нәрсәдер алды. Тапты, ахрысы, эзләгән әйберсен. Нәрсә икән ул?

Немец, кулын болгый-болгый иптәшләренә кычкырып, шатлыклы аваз бирде. Аңа җавап итеп машина ягыннан тавышлар ишетелде.

Шулвакытта Яббар мылтыкны төбәп атып җибәрде. Немец инде үзләренекенә таба бер-ике адым атлаган иде. Ул кинәт туктады, бермәл тораташ булып катып торды. Тагын берничә адым авылга таба атлады да урман ягына борылып карады. Шуннан соң Яббар аның чалкан ауганын күрде. Тиде.

Машина монда таба кузгалса, Яббар урман эченә йөгерергә әзер иде. Әмма машина кузгалды да, урманга таба түгел, килгән юлыннан китеп барды һәм тиз арада күздән югалды. Партизаннар инде урман авызына ук килеп җиткәннәр дип уйладылар, ахрысы, хәтта кырда ятып калган иптәшне дә килеп алырга җөрьәт итмәделәр.

Яббарның окоплардан күп тапкыр дошман ягына атканы бар, ләкин тигезгәне, берәрсен үтергәне булды микән – күргәне дә, белгәне дә юк иде. Ә хәзер ул менә аермачык белә – кеше үтерде ул. Бәлки, исәндер фриц? Бәлки, яраланган гынадыр. Урыныннан кузгалып, ул әкрен генә урманнан чыкты һәм, винтовкасын әзер

тоткан килеш, кыр уртасында яткан дошман гәүдәсенә таба атлады.

Немецлар туктап торганнар икән бу урында. Мөгаен, ял итәр өчен түгел, ә бәлки тирә-яктагы обстановканы өйрәнеп үзләре өчен мөһим карар кылыргадыр, инде нишләргә, кайсы тарафка юл тотарга, авылга керергәме, урманда урнашыргамы, әллә төп гаскәрләргә кушылыр өчен марш-бросок ясаргамы? Монда чүпчар, тәмәке төпчекләре, тушенка банкалары, иске гәҗит кисәкләре, саргаеп беткән листовкалар, кеше хаҗәтеннән калган күп төрле пычраклыклар бар иде.

Немец тере түгел иде. Яббар аның чалкан ауганын аермачык күргән иде. Күрәсең, җан биргәндә ул әле җирдә аунаган – гәүдәсе иләмсез кыяфәттә кәкрәйгән, әйтерсең лә аны, башыннан һәм аякларыннан тотып, сыгарга теләгәндәй боргалаганнар. Яңагын җиргә куеп нәрсәдер тыңларга теләгән дә сыман, шул ук вакытта сыңар күзе күк тарафыннан ни дә булса абайларга тырышкан кебек акайган. Пуля җилкәсенең калак сөяге астына тигән.

Яббар үтергән немец утыз-утыз биш яшьләрдәге унтер-офицер иде. Аның янында яткан чүпрәк төргәкне чишеп карагач, Яббар аңлады – унтер-офицер үзе өчен бик кадерле булган фоторәсемнәрне һәм өйдән килгән хатларны төшереп калдырган да шуларны алырга дип кире килгән.

Фоторәсемнәр арасында берсе аеруча игътибарны җәлеп итте. Анда олы яшьтәге ир кеше белән хатын-кыз. Алар алда урындыкларда утыралар. Ир кешенең алдында ике-өч яшьлек малай. Артта шушы унтер-офицерның әле бөтенләй яшь чагы, кырыенда ап-ак йөзле чибәр ханым. Бу рәсемгә карагач, шундук аңлашыла: рәсемдә аның ата-анасы, хатыны, атасының алдында онытгы, ягъни моның баласы. Бик кадерле карточка булган инде бу, шуңа күрә берәр солдатны җибәрәсе урынга үзе кире килгән.

Озак карап торды Яббар фоторәсемгә. Аның башы чайкалып китте. Ник атты ул бу немецка? Китсен иде үзләренекеләр белән. Бәлки, исән калып Германиясенә кайтып җитәр иде. Гаиләсен, ата-анасын күрер иде. Хатынын, улын кочагына алыр иде.

Яббар мәетне җайлап чалкан яткырды. Күзләрен йомдырды. Һәм, ике дә уйлап тормыйча, каешындагы сапер көрәген алып, кабер казырга кереште.

Каберне бигүк тирән казый алмады ул, хәле тиз бетте. Мәетне казылган чокырга сөйрәп төшергәч, фоторәсемнәр белән хатларын чүпрәгенә төреп аның күкрәге турысына – кителе эченә тыгып куйды.

Шул вакытны ул урман ягыннан үзенә эндәшкән авазларны ишетте. Күп тә үтмәде, ул казыган кабер тирәсендә партизаннар аптырап басып торалар иде инде.

– Нишлисең? – дип сорады отряд командиры.

– Мин кеше үтердем, – дип җавап бирде Яббар, немецны күмәкүмә.

– Син урман авызында каравылда торырга тиеш идең. Ник чыктың?

– Бу нимес кырга килеп әйберләрен эзләп йөрде, мин аны атып үтердем.

– Ник соң син аны күмеп ятасың?

– Ә кем күмсен аны?

Яббарның сәерлегеннән барысы да таң калдылар.

– Бәлки, син аны атып үтергәнеңә дә үкенәсеңдер әле? – диде Пилипенко.

Яббар дәшмәде.

– Кадерле кешесемени, өф-өф итеп күмеп ята! Легионда чактагы танышыңмы әллә?

– Юк, таныш түгел, – диде Яббар, кабер өстендәге балчык өемен көрәге белән тигезли-тигезли.

Шул ук көнне партизаннар Калинковичи авылына керделәр. Вакытлыча авыл мәктәбендә урнашкан штабка Яббарны партизаннар бригадасының НКВД вәкиле каршысына алып килделәр. Кыска гына допростан соң Яббарны нindидер келәткә бикләп куйдылар, ә икенче көнне Гомельгә баручы «полуторка»га утыртып ике конвоир сагы астында Гомель шәһәренә озаттылар. Вакытлыча гына оештырылган мондагы фильтрация лагере Подольскиныкыннан нык аерылып тора иде. Тегесе аның предварительный тикшерү өчен, сортировка өчен генә файдаланылса, Гомельдәгесе исә инде контрразведка тарафыннан нык тикшерелүчеләрне җыйнаган лагерь иде. Вакытлыча дип төзелсә дә, мондагы хәлләрне күргәч, бу мәхшәрнең чиге-азагы буласына ышанырлык түгел иде.

Контрразведка капитаны коры сөякле, урта яшьләрдәге кеше, папиросын күзләрен чекерәйтеп суыра-суыра, башта бик озак нидер күчереп язды. Аннары сорау алу башланды. Яббарның исем-фамилиясен, ата-анасының исемнәрен сорашканнан соң, кыскача тәрҗемәи хәлен, ничек әсир төшүен, нинди шартларда легионга керүен, аннары ни сәбәпле партизаннар ягына чыгуын тәфсилләп сөйләтте.

Шуннан соң капитан Яббарның немец офицерын атып үтерү вакыйгасына ныклап тукталды.

– Димәк, син урман авызында берүзең калдың?

– Әйе.

– Синең иптәшең Пилипенко фашистларның килүе хакында командирыгызга әйтергә дип үзе кузгалдымы, әллә син тәкъдим иттеңме?

– Үзе тәкъдим ясады, мин килештем, шуннан соң китте.

– Немецларның соңгы машинасы киткәч үк урманнан чыктыңмы?

Яббар инде йөзенче кат кабатлагандыр:

– Машиналар китеп ун-унбиш минут чамасы үтте. Бер машина авыл янына кире борылды. Шул тарафтан берәү кыр буйлап килде.

– Сине абайлапмы?

– Юк инде, ничек күрсеннәр, мине күрерлек түгел иде, мин бит урман эченнән күзәтеп яттым. Чыкмадым, күренмәдем.

– Ник кумәргә булдың син дошман офицерын?

– Машиналары китеп баргач, тере түгел микән дип барып карадым мин аны.

– Бәлки, сез элек аның белән очрашкансыздыр?

– Ничек инде?

– Бәлки, сез аның белән монда махсус очрашкансыздыр? Бәхәсләшеп яки үзеңә бездән шик төшмәсен өчен атып үтергәнсеңдер?

– Юк.

– Бәлки, син фашистлар белән гел элемтәдә торгансыңдыр?

– Сез нәрсә инде! Мин легионнан котылып үзебезнекеләр ягына чыкканга сөенеп туймадым. Ничек мин дошман белән элемтәдә торыйм?!

– Ник кумәргә булдың соң син аны?

– Соң, кеше бит...

– Фашист унтер-офицерын кеше дип атыйсыңмы? Бәлки, син атмагансыңдыр аңа? Берәр башка партизан урман эченнән аткандыр?

– Юк, мин атып үтердем аны.

– Син аның белән легионда танышкан идеңме?

– Кем белән?

– Атып үтергән унтер-офицер белән.

– Юк, минем аны беркайчан да күргәнем юк иде.

Допрослар көн саен озын-озак дәвам итте.

Яббарны монда тагын бер тетрәнү көткән икән – шушында ул авылдашы, күршесе һәм көндәше Әнсар белән очрашты...

20

Яшәү дәвам итте. Кызылъяр авылы да үзенең дөньяви мәшәкатьләрендә кайнады. Ил сугыштан соңгы еллар сынавын да үтәргә тиеш иде. Беркайчан рәхәт, тулы канлы тормыш күрмәгән авыл халкы барыбер әле һаман да өмет белән яшәде. Коммунистлар партиясенең авыл кешесен санга сукмый торган, хәтта аңа паспорт бирмичә «крепостной» итеп тоткан вәхши идеологиясенә дә сабыр, тырыш, буйсынучан авыл халкы ышанырга теләде, бүген авыр булса, иртәгә рәтле тормыш башланыр, хәзер без интексәк, балаларыбыз юньле тормыш күрер дип гомер сөрде.

Үз дәүләтен югалтып дүрт йөз ел яшәгән, илгә бихисап корбан биргән татар авылының яшәү рәвешен яхшыртыр өчен мөмкинлекләре дә, барып мөрәҗәгать итәрдәй, иганә сорардай инстанциясе дә юк иде.

Яшәү дәвам итте.

Адәм баласы өчен тормыш авырлыкларыннан да авыррак йөк бар – җан газабы.

Яббар һаман авылдашларына күренмәскә тырышты. Ул хәтта урамга, бала чагы үткән инеш буйларына, болынга төнлә генә чыга башлады. Авыл халкы белән аралашырмын дигән өмете бар иде аның, ләкин тора-бара аңлады – сугышта һәлак булганнарның туганнары бар чагында, сугыштан гарипләнеп кайткан ир-егетләр исән вакытта, бала чактан таныш, якын булган кешеләр белән уртак тел табу мөмкин түгел.

Нәгыймгә кече улының фаҗигасе нык тәэсир итте, беркөнне аны өянәге тотты. МТСтан машина алып Сәет аны район больницасына алып китте. Сырхауханәгә ятып дәваланып алырга кирәк, диделәр.

Яббар атасы янына больницага барды. Сигез кешелек палатада алар ни турында сөйләшә алсыннар инде. Атасының кырынмаган аксыл-зәңгәрсу йөзенә карап, Яббар үз йөрәгенең дә кысып-кысып чәнчеп алганын тоеп бик озак утырды. Нәгыйм, улына шактый вакыт карап ятканнан соң, күгәргән иреннәрен чак кына кыймылдатып:

– Улым, син бар кайт инде, – диде.

Атасының 1942 елдан соң беренче мәртәбә «улым» дип әйтүен ишетү Яббарның күңелен ташкын белән тутырды. Күзләрдән ургылып агарга торган яшьләрен көчкә тыеп, ул:

– Әти, терел, зинһар, яме, – диде дә палатадан атылып чыкты. Коридордан барганда инде аның күз яшьләре битен, муенын чылатып бетергән иде.

«Улым, диде. Кит, димәде. Күренмә, димәде. Кайт, диде. Улым, диде, кайт, диде. Рәхмәт, әти! Кичер, әти! Ярлыка!»

Авылга кайтып киткәнче, ул бик озак район үзәгенең урамнары буйлап йөрде. Аңлатып булмаслык халәттә онытылып йөрде ул – ниндидер өмет күкрәк түрендә сулкылдады. Яшәргә кирәк. Гомер алда әле. Дөнья бөтенләй караңгыланырга һәм барлык кешеләр дошман булырга тиеш түгел. Ул бит инде җәзасын алды. Аны кешеләр легионер булганы өчен хөкем итәргә тиеш түгелләр. Аның бит зуррак гөнаһы бар, ул кырык дүртенче елның көзендә кеше үтерде. Ике баласы, хатыны төшкән фотосурәтне алырга дип килгән немец кешесен үтерде. Менә бит аның иң зур гөнаһы. Кешеләр аның ул гөнаһын белсәләр, вакытлыча дошман киемен кигәне өчен, бәлки, битәрләми дә башларлар...

Кызылъярга ул төнлә генә кайтып керде.

...Икенче көнне өйдә әнисе белән икесе генә калгач, Яббар:

– Әти бүлнистә озак ятар микән? – дип куйды.

– Янына баргач ник дуктырлардан сорамадың соң? – диде анасы.

– Курыктым.

– Нәрсәсеннән курыктың инде аның?

– Врачлар минем легионер булганымны беләләрдер шикелле тоелды.

– Каян белсеннәр инде алар, улым!
– Инде кая гына барсам да, бөтенесе беләләрдер кебек.
– Юк, юк, улым, сиңа шулай тоела гына. Ә атаңа килгәндә... Берәр ай дәваланыр әле ул. – Әминә авыр сулап куйды. – Йөрәк белән интекте инде гомергә.
Яббар:
– Хәзер инде минем аркада да интегә, – дигәч, өйдә авыр тынлык урнашты. – Әнкәй, синең әле бер тапкыр да сораганың юк... – дип, тагын сүз башлады ул.
– Нәрсә дип?
– Нимес ягына чыктыңмыни дип.
Әминә, дымлы күзләре аша елмаю нуры сирпеп, сәкедә бөкрәеп утырган улы янына килде:
– Син бит минем улым, нишләп мин синең җәрәхәтләрең өстенә җәрәхәт өстим ди. Исән-сау булуыңа куанып туя алмыйм, балакаем. Синең исән калуыңны көн саен Ходайдан сорадым бит мин. Догаларым, фөрьядларым кабул булды.
– Яу кырында ятып калуымны тели торган догаң юк идемени соң синең, әнкәй? – диде Яббар, ачынып.
– Ни сөйлисең син, улым! – диде Әминә, Яббарны такыр башыннан сыпырып. – Мин ничекләр түзәр идем, әгәренки син чит җирләрдә үлеп калсаң?!
– Ә болай сатлыкҗан исемен йөртүемә түзәрсеңме?
– Нинди сатлыкҗан инде син, улым! – дип көлемсерәде Әминә. – Бөҗәкне дә кызгана торган бала идең бит син. Табигатьне, туган авылны яратучы малайга ничек андый ямьсез исем тагылсын. Кемне, нәрсәне саттың соң син?
Яббарның күңеле талпынып куйды:
– Беркемне дә, бернәрсәне дә сатмадым!
– Шулай булгач...
– Беркемгә, бернәрсәгә хыянәт итмәдем! Тик ничек исбатларга соң моны?
– Ышанырлар, улым, түз, ышанырлар.
Яббар әнкәсенең кулын ике учына алды:
– Димәк, син миңа ышанасың?
– Ничек ышанмаска. Син бит минем балам. Син бит минем иң яраткан улым.
Яббарның күңеле тулды:
– Әнкәй, син бит миннән баш тартмаучы бердәнбер кеше.
Әминә, арткарак каерылып, улының терсәген капшады:
– Күлмәгеңнең җиңе ертылган. Сал, тегеп куйыйм. Кайда эләктердең икән?
– Кичә мин бакча артыннан кайттым. Читән буенда кыштыр-кыштыр нәрсәдер йөри. Карасам, керпе икән. – Ул көлеп куйды. – Бала-чага сыман, шуны якыннанрак карыйм дип, җиңемне читән чыбыгына эләктереп ертканмын.
Яббар күлмәген салып әнкәсенә бирде дә тәрәзә янына барып басты.

Шунда Әминә улының җилкәсенә карап котсыз калды:

– И-и-и, балакаем, тәнең гел җөйләрдән, яралардан гына тора икән. – Ул Яббарның аркасын тәрәзә яктысында җентекләп карарга тотынды.

– Монысы нинди яра, улым? – дип, бармагы белән төртеп сорады ана. – Снаряд кыйпылчыгыныкымы?

– Юк, кыйпылчыкныкы өстәрәк. Иңбашына якынрак. Аның эзе, ни гаҗәп, чак кына беленә. Ә бу җөй – штык эзе. Әсир төшкәч, кызык өчен бер фашист штык белән төрткән иде.

– Снаряд кыйпылчыгын кайда алдырдың соң син?

– Концлагерьда. Кул астындагы әйберләр ярдәмендә бер хирург – белорус кешесе алды. Үзе үлде ул аннары. Ачтан үлде.

Әминә бармагын улының җилкәсе буйлап йөртте:

– Бусы?

– Анысы концлагерьда бер сакчы үткен көрәк кыры белән сукканнан калды. Фамилиясе Крутт иде. Кырырга куелган казан эченә кереп басканым өчен. Безне, алты меңгә якын әсирне, башта тимерчыбык белән уратып алынган бер зур мәйданда тоттылар. Сакчылар үзләренә аш пешергән зур-зур казаннарны, бушагач, безгә кертеп куялар иде. Казан төбенә янып ябышкан ризыкны, төрткәләшә-төрткәләшә, җитешкәнчә, кем ничек булдыра, шулай кырып ашый идек. Берсендә этешә-төртешә торгач, ялгыш казан эченә кереп бастым. Шунда Крутт көрәк белән сукты.

– Ә менә бу җөйләр?

– Болары Магадан янындагы лагерьда, үзебезнең конвоирлар эше. Әле аягымда эт тешләгән эзләр дә бар.

Әминәнең куллары салынып төште:

– Әй, балам, ниләр өчен шушы кадәр иза чиктең соң син?

– Шуннан соң яңа газаплар чигәргә язган икән бит әле.

– Нинди газаплар?

– Хәзер миңа туган ягымда, өзелеп сагынган туган авылымда кешеләрчә яшәү мөмкин түгелдер инде.

Әминәнең бите буйлап күз яше тәгәрәп төште:

– Тора-бара онытырлар, улым.

– Юк, әнкәй, онытмаслар. Үзем бимазаланган гына җитмәгән, кешеләрнең нәфрәте аска бөгә, сыта, изә. Мин үземә кул салыр идем... тик, әнкәй, син бар.

Әминәнең коты очты:

– Әстәгъфирулла! Ни сөйлисең син! Авызыңнан җил алсын!

– Мин үземнең башымнан кичергәннәрне, ничек җәзалаганнарын ни өчен кешеләргә ачыктан-ачык сөйлим дип уйлыйсың? Бәлки, ышанырлар һәм кичерерләр дип. Легионер булган да, кыска гына вакытта булса да рәхәттә яткан икән дип уйламасыннар өчен. Ләкин миңа барыбер ышанмаячаклар.

Әминә улының җилкәсен кулы белән сак кына сыпырды:

– Ышанырлар! – Аннары ул сәке башындагы күлмәккә ымлады. – Әнә атаңның күлмәген киеп тор.

Яббар әнкәсенең сак кына хәрәкәтләр белән күлмәгенең җиңен типчүен күреп шаккатты. Әйтерсең лә ана җаны-тәне җәрәхәтләнгән улының күлмәген дә инә белән тишеп, яраларын әрнетүдән курка...

Бераздан Нәсимә кайтты.

– Әнкәй, чәй эчеп алыйк әле, ашарга аннары әзерләрбез, – диде ул, нәрсәгә тотынырга белмичә кучкар тирәсендә таптанып.

– Кызым, самавыр кайнаган ул, өстәлгә генә куясы бар, – диде Әминә, инә җебен төйнәп.

– Әйдә, Яббар, чәй эчәргә, – диде Нәсимә, чәй табыны әзерләп.

Килен кешенең мондый мөгамәләсе Яббарга гына түгел, ананың да күңеленә хуш килде.

Яббар елмаеп өстәл янына утырды:

– Ярый чәй бар әле!

Әминә Яббарның күлмәген сәке башына салды да:

– Сез эчә торыгыз, мин намаздан соң эчәрмен, – дип, намаз укырга җыена башлады.

– Яббар, сиңа сөтләп ясыйммы? – диде Нәсимә.

Яббар, читенсенеп кенә:

– Сөтләп, – диде.

Шул вакытны Сәет кайтып керде. Хатынының Яббарга чәй ясаганын күреп, ул беравык ишек катыннан кузгалмый басып торды.

– Менә Сәет тә кайтып житте, – диде Нәсимә, шатланып. Аннары шаярып өстәп тә куйды: – Мактап йөрисең икән. Чәй ясыйммы?

Сәет борын төбенә генә мыгырдады:

– Яббарга чәй ясаганны, үз иреңә генә ясарсың инде. Аңа сөтләп ясагач, миңа да сөтләп ясарсың, шәт.

Иренең өстәл янына утырып Яббарга усал каравыннан Нәсимә нык каушады.

– Бик кәефсезләнеп кайткансың әле, – диде ул, иренә чынаяк куйганда.

Әминә, өйдә кубасы давылны сизенеп, кулындагы комганны аралыкка куйды да казан тирәсендә нидер эзләгән булып кыланды.

Сәет алдына куелган чынаяктагы чәйгә карап торды да, Яббарга текәлгән килеш, усал тавыш белән хатынына мөрәҗәгать итте:

– Син Яббарга чәйне куерак яса, сыек ясагансың түгелме...

Нәсимә утырган урыныннан әкрен генә торып басты:

– Нәрсә булды, Сәет?

– Тагын бер тапкыр аңа чәй эчерткәнеңне, ашатканыңны күрсәм... үзеңә үпкәлә! – диде Сәет, йодрыгы белән өстәлгә сугып.

– Сәет, нишләвең бу! – диде Нәсимә, җәһәт кенә өстәл сөртә торган чүпрәк белән түгелгән чәйне сыпырып.

Сәет чайпалып түгелгәннән соң яртылаш кына калган чәен шопырдатып эчеп куйды:

– Мине эшемнән алырлар, ахрысы.

Әминә әкрен генә өстәл янына килеп утырды:

– Эшеңнән? Ник алай?

– Эшемнән чыгаруларын көткәнием инде анысы. Эшен табармын. Элекке дусларым минем белән аралашмый башладылар – менә шунысы начар.

– Чын дусларың аралашырлар, – диде Нәсимә. – Сиңа артлары белән борылучылары, димәк, чын дуслар булмаган.

Кайтканнан бирле моңарчы абыйсы белән кирле-мырлы сөйләшкән Яббар башын аска игән килеш әйтеп куйды:

– Нәсимә миңа чәй ясамаса, сиңа җиңелрәк булыр идеме?

– Тынышны чыгарма, үләксә! – дип ярсып кычкырды Сәет һәм сикереп торып чынаяк төбендә калган чәйне Яббарның битенә сипте.

– Сәет, табын яны бит бу! – диде Әминә, ачыргаланып. – Ник дулыйсың! Атаң бүлнистә яту җитмәгән, бөтенебез дә авыруга сабышсын дисеңме! Ничек оялмыйсың – анаң каршында, табын янында...

Сәет кискен хәрәкәтләр белән ишеккә таба юнәлде.

– Берегезне дә күрәсем килми! – диде ул һәм ишекне бәреп чыгып китте.

– Чыннан да, кайтасыларым калмаган икән, – диде Яббар, беркавым битендәге юешне күлмәк җиңе белән сөртеп. – Ә уйлап карасаң, хәзер инде китеп югалсам да барыбер, эти әйтмешли, нәселгә тап төште. Кайтмаган булсам да сезгә кырын карарлар иде. Авылдашларым мине аңларлар дип өметләнгән идем. Шуңа күрә кайтырга җөрьәт иттем мин.

Нәсимә, Сәетнең кая таба киткәнен күрергә теләп, тәрәзәгә карады.

– Авылдашларга үпкәли алмыйсың инде, Яббар, – диде Нәсимә. – Күпме күз яше, күпме кан, күпме кайгы-хәсрәт, күпме югалту кичерде халык. – Ул елап җибәрде. – Минем Фәрук абыемның каберен дә күрә алмыйбыз бит менә.

Нәсимәнең Фәрук абыйсын искә алып елаганы күп булды, ләкин бу юлы Әминәгә дә, Яббарга да аның күз яшьләре, әйткән сүзләре аеруча авыр тәэсир итте.

– Мин беркемгә дә үпкәләмим, – диде Яббар. – Хакым юк. Ә син ничек уйлыйсың, әгәр дә мин үземне сатлыкҗан дип танысам, кешеләрнең шулай диюләренә күнсәм, авыл халкының миңа мөгамәләсе яхшырырмы?

– Белмим, – диде Нәсимә, нишләргә белмичә як-ягына карап. Шулай да Яббарга җавап бирергә кирәк дип тапты. – Синең эчке кичерешләрең, синең шәхси халәтең берәрсен кызыксындырадыр дип уйлыйсыңмы әллә? Яманатлы даның синең үзеңнән тормый лабаса.

Яббар башын какты:

– Дөрес әйтәсең.

Нәсимә Сәет өчен нык борчылып беркавым тәрәзәдән тәрәзәгә йөрде дә:

– Кибеткә барып кайтыйм әле, – дигән булып өйдән чыгып китте.

– Әнкәй, берәр көнне авыл халкы җыелган җирдә тезләнеп ярлыкауларын сорыйммы? – диде Яббар.

Әминә сискәнеп китте, беравык улына карап торды, аннары әкрен генә торып басты да бөтенләй үзенә хас булмаган каты тавыш белән:

– Юк, улым, тезләнмисең дә, ярлыкау да сорамыйсың! – диде.

Яббар әнкәсенең олы якка кереп намаз укыганын көтеп урыныннан кымшанмыйча утырды. Әминә намазын тәмамлап кече якка чыккач, Яббар китәргә катгый карар кылуын белдерде.

– Кая китәсең, улым? – дип сорады ана.

– Район үзәгендә ишетеп кайттым: Куйбышев янында, Великие Луки дигән урында, зур гидростанция төзеләчәк ди. Электр чыгара торган станция. Бик зур төзелеш, имеш, эшчеләр бик күп кирәк икән. Шунда барып урнашырга исәбем бар. Алсалар инде...

21

1952 елның язы башка язлардан нәрсәсе белән аерылып торгандыр, әйтүе кыен. Язлар алар гел бертөрле килә – ташулары белән, табигатьнең яңаруы белән, өмет белән. Кешеләр язмышлары гына төрлечә керә язларга. Һәр кеше үзенең кайгы-хәсрәте белән, үзенең тәкъдиренә язылганы белән атлый елларның котылгысыз үзгәргән фасылларына.

Апрель тәмамлангач унбиш-егерме көннән алмагачлар чәчәк атачагын уйлап, табигатьнең яшәреп, яңарып китәчәген күзаллап, Нәгыймнең тән сыкраулары кимиячәгенә ышанып, улы Яббарны күрәсенә өметләнеп, Әминә лапастан баз өстенә кадәр үк аркылы сузылган бауга яңа юган керләрне элеп маташа иде. Капка ачылуыннан Әминә сискәнеп китте, якты уйлар мизгел эчендә юкка чыктылар.

Зәкиянең капкадан килеп керүеннән үк Әминәнең кәефе кырылды. Аңардан ихласлык белән әйтелгән җылы сүз беркайчан ишетмәссең, ул башлаган әңгәмә һәрвакыт Әминәнең күңел җәрәхәтләренә тоз сипми калмый. Шуңа күрә соңгы вакытта Зәкия белән аралашмаска тырыша ул.

Аның, гадәттәгечә, кем әйтмешли, «фурмы» өчен генә:

– Нихәлләрең бар, Әминә? – диюенә ул да керләрен элә-элә, салкын гына:

– Аллага шөкер, Зәкия, – дигән булды.

– Чирләп алдың, ахрысы? – диде Зәкия, Әминәнең йөзен җентекләп күзәтеп.

– Булды бераз. Рәтләндем инде. Үзең ничек?

– Ярыйсы, – диде Зәкия. – Урын өстендә үк ятып алдың бугай? – дип төпченүен дәвам итте ул.

– Әйе шул. Мин чирлим дә, тиз арада терeләм дә... Мин үзем өчен түгел, күбрәк Нәгыйм өчен борчылам. Аның сәламәтлеге ныграк какшаган. Үзен сакламый. Духтырлар биргән даруларны да эчми.

– Алай икән. Йөрәк белән шаярырга ярамый. Яббар кайгысы да өстәлгәндер инде.

Әминә, керләрдән бушаган тазын куярга дип, өйалды баскычына таба юнәлде:

– Бардыр инде.

Зәкия аңа иярде:

– Шуны сорамакчы идем... Яббар күренми... Кайда ул?

Бу юлысы Яббар турында сүз башлану Әминәне сөендереп җибәрде.

– Яббар зур төзелештә эшли, – диде ул горурлык белән. – Куйбышев янында гис төзелә. Бик зур буа буылачак, ди.

Зәкия, Яббарның кайда икәнен белгән килеш, аптыраган булып кыланды:

– Алай икә-ә-ән. Кем булып эшли инде ул анда?

– Башта гади эшче иде. Хәзер шоферга укыган, машинада эшли башлаган.

– Алай икә-ә-ә-ән...

Күршеләре белән соңгы вакытта аралашмаса да, Әминәнең Әнсарга рәхмәт сүзе бар иде:

– Әнсарыгызга рәхмәт яусын инде... Сәетебезне эшендә калдырганы өчен.

Зәкия, читенсенгән булып кыланып:

– И-и-и, Әминә, минем Әнсарым үз авылдашын, күршесен кыерсытуга бармас инде ул. Тәрбиясе андый түгел.

– Рәхмәт яусын.

– Маладис инде ул минем Әнсарым. Кеше сүзенә карамады, авыл халкы кырыслана дип тормады, Сәетегезгә җил-яңгыр тигезмәде.

– Кеше сүзе дисең... Анысы инде, Яббар өчен Сәет җавап тотарга тиеш түгел. Яббарның үзенә дә чиксез авыр. Безнең Сәетебез дә бит сугыштан орденнар белән кайтты...

– Шулаен шулай да, Әминә, халык бит ул, ай-яй. Аерым бер кешегә тукып аңлатып була, ә кешеләр бөтенесе бергә җыелса, һич кенә дә аклана да, аңлата да алмыйсың.

– Ансы шулай, – дип килеште Әминә.

– Хәтта авыл халкының чит җирләргә китеп урнашкан туган-тумачалары да, Сабантуйга кайткач, гөр китереп синең Яббарың турында гына гәпләштеләр бит.

Әминәнең йөзе саргаеп китте:

– Син авырткан җәрәхәтләргә кагылмый калмыйсың инде... бигрәк тә соңгы вакытларда.

– Мин бит булганны гына сөйлим, Әминә. Үзем уйлап чыгармыйм.

– Ярар, ярар, рәхмәт барысы өчен дә.

Зәкия, Әминәнең тәмам шәлберәеп киткәнен абайлап, сүзне икенчегә борып, тормыш-көнкүрешкә бәйле вак-төяк турында сөйләшкән булды да чыгып китте.

Әминә барыбер рәхмәтле иде күршеләренә. Сәетне, сатлыкҗанның абыйсы дип, чак кына эшеннән алмадылар бит. Кемнеңдер берәр туганына эш кирәк булгандыр инде. Энесе «изменник» дигән сылтау бик яхшы сәбәп бит. Имештер, Әнсар МТСта баш инженер булып эшләүче әшнәсеннән Сәеткә тимәүләрен үтенгән.

Әминә элгән керләре янында бик озак уйга чумып, боегып басып торды. Аны авыл халкының үзләренә карата мөгамәләсе түгел, Яббарны – сөекле улын – чит-ят итүләре нык бимазалады. Яббарны дошман итмәсеннәр өчен, ул үзе әллә нинди җәзаларга да ризалашыр иде, мөгаен.

Ана йөрәге үзенең баласына әллә нинди яманат тагуларын, аны дошман күрүләрен кабул италмады, аның акылына, аңына сыярлык түгел иде бу хәл. Юкка, нахакка рәнҗетәләр улымны, диде ул һәм бу вәхши гаделсезлек белән мәңге килешмәячәген гел искәртеп торды. Бөтен дөнья Яббарга арты белән борылган суратттә дә, бөтен дөнья аның улын дошман итсә дә, анасы аңардан беркайчан да, бу дөньяда да, тегесендә дә баш тартмаячак. Ана өчен нәрсә ул «легионер» дигән җанга ятышсыз сүз? Ана өчен «изменник», «предатель», «сатлыкҗан» дигән төшенчәләр нәрсә ул? Балачага бер-берсен үртәгәндә генә кулланыла торган сүзләр түгелме соң алар? Улының ничек авылны яратканын, табигатькә ничек таң калуын, аның нечкә күңелле, олы җанлы, игелекле бала булып үскәнен үзе генә түгел, авылдашлары да күргән ләбаса! Үз карынныннан чыгып күкрәк сөтен имгән баласына ни өчен әллә нинди ямьсез кушаматлар тагуларын ана белә һәм аңлый шикелле, әмма шул ук вакытта беләсе дә, аңлыйсы да килми. Моның белән ана мәңге килешмәячәк һәм күнмәячәк!

Яббар кебек әдәпле, игелекле, нечкә күңелле бала үз яшьтәшләре арасында юк иде!

22

Куйбышев ГЭСы төзелеше турында Яббар беренче тапкыр радиодан ишетеп белде. Шунда китү теләге бер мизгелдә туды шикелле. Тизрәк китәргә, китәргә, китәргә! Авылдан ераккарак, таныш-белешләрнең күз карашларыннан арырак олагырга кирәк. Әнкәйне сагынгач, авылны юксынгач, яшертен генә, бөтенләй үк яшертен булмаса да, тып-тын гына кайтып китәргә дә мөмкин ләбаса. Тормышны корырга кирәк, алда гомер бар, аны яшәми кая куясың?! Бу дөньяда Ходай җан биргән икән, димәк, үз урының да бардыр бит инде.

Еллар узгач, энциклопедияләрдә бу ГЭС турында шаккатарлык мәгълүматлар укырга мөмкин булачак. «В.И.Ленин исемендәге плотина белән ясалган Куйбышев сусаклагычы РСФСРның Куйбышев, Ульяновск өлкәләренең, Татарстан АССР, Мари АССР һәм Чуваш АССР территорияләренә җәелгән. Сусаклагычны су белән тутыру 1955 елдан алып 1957 елга кадәр дәвам итә. Мәйданы – 6450 кв. км, күләме – 58 куб. км, озынлыгы – 580 км, киңлеге – 30 км, уртача тирәнлеге – 9 м, иң зур тирәнлеге – 39 м».

Эшчеләр поселогында, ГЭС төзүчеләрдән тыш, нефтьчеләр дә, баржалар ремонтлаучы бригадалар да яши иде. Яббарга соңгы еллар эчендә беренче тапкыр бәхет елмайгандай итте – гидромонтажчылар бригадасына грузчик итеп алдылар һәм бер озын иске баракның иң кырый бүлмәсендә урын да бирделәр. Шунысы куанычлы булды: ул килгәндә, монда үзләренең бригадиры урыс агае Арсений Михайлович кына яши иде. Дядя Арсен (Яббар аңа беренче көннән үк шулай эндәшә башлады) Яббарны эштә дә, бүлмәдә дә җылы каршылады. Яббар аңа үзе турында барысын да сөйләргә җөрьәт итмәде. Әмма бригадирга ничектер тиз арада аның турында барысы да мәгълүм булды. Бригадасында шундый биографияле кешенең булуы Арсенийны бераз пошаманга калдырды, Яббарга карата шундук кырысланды, тик шулай да аны бригадада калдырды һәм Яббарның легионда булганын, нинди статья буенча утырганын беркемгә дә сөйләмәде.

Ике ай чамасы узгач, Арсений Михайлович, әллә легионерны бригадасыннан ераккарак җибәрәсе килгәннән, әллә чынлап та яхшылык теләп, Яббарга шоферлар курсына укырга керергә тәкъдим итте.

...Курсларын тәмамлап, имтиханнар биргәннән соң, төрле оешмалардан шоферларны эшкә чакыручы вербовщиклар килде. Аз сүзле, йомыкыйрак, укытучы-инструкторлар әйтүе буенча, бик тырыш курсант Әүһәдиев Яббарны тәбәнәк буйлы, төптән юан бер агай үзенә шофер итеп урнашырга чакырды.

Бу базык кеше зур начальник булып чыкты. «Гидромонтаж» оешмасының бетон капланмалар белән тәэмин итү бүлеге җитәкчесе Стыков Захар Федорович Пермь кешесе иде. Соңгы вакытта шоферлардан уңмаганга күрә, ул үзе автошколага кеше эзләп килгән икән.

Яббар затлы машина руленә утырып, зур кешене йөртергә насыйп булуына хәтта сөенергә дә курыкты, чөнки әле һаман бу бәхеткә ышанып җиталмады, күз тиюе бар дип пошаманланды. Шул ук вакытта, кем икәнемне белгәч, бу эштән куулары ихтимал дигән коточкыч уй да аңа тынгылык бирмәде.

Аңа зур барактагы тулай торактан урын бирделәр. Алар бу бүлмәдә дүрт шофер бергә яшәсәләр дә, барысы берьюлы җыелганнары булмады диярлек, чөнки алар сменалы эштә иде.

Яббар үзенең кем икәнлеген, нинди хәсрәте барлыгын, нинди җан газабы белән яшәвен Захар Федоровичка үзе сөйләргә булды.

Куйбышевтагы киңәшмәдән кайтканда, начальнигының кәефе күтәренкелектән файдаланып, нәкъ менә хәзер ачам серемне дип, Яббар машинаны юл читенә туктатты да үзе турында сөйләргә тотынды. Ләкин, ни гаҗәп, Яббарның начальнигы инде барысын да белә икән.

– Нишлисең бит, тәкъдиреңә шулай язылгач, – диде Захар Федорович, Яббарның агарып каткан чыраена карамаска тырышып.

Шуннан соң ул, машинадан чыгып, багажниктагы сумкасыннан колбаса белән ипи алып килде.

– Әйдә капкалап алыйк, – диде ул, якты елмаеп.

– Мине эштә калдырасызмы?

– Син бу турыда бөтенләй кайгырма. Әйбәт кенә эшлисең бит, эшлә. – Паузадан соң өстәп куйды: – Башка беркемгә дә сөйләмә. Кирәкми.

Тамак ялгап юлга кузгалгач, Захар Федорович хатынының бертуган абыйсы турында сөйләде. Ржев янындагы чолганыштан котылып чыккан булган ул. Аны дезертир дип хөкем иткәннәр. Шуннан аның турында бер хәбәр дә юк икән.

– Инде ничә ел узды, исән булса кайтыр иде, исән түгелдер, – дип тәмамлады Захар Федорович сөйләвен.

Яббарның күзләреннән яшьләр тәгәрәде. Ул тагын машинаны юл читенә туктатты. Аның рульгә капланып туйганчы елаганын Захар Федорович бер сүз дәшми тыңлап утырды.

...Көн артыннан көн үтте. Төзелеш кайнады да кайнады. Әллә кайсы тарафлардан җыелган эшчеләр, белгечләр, инженерлар, галимнәр Идел елгасын буар өчен бөтен аңнарын, белемнәрен, көчкуәтләрен җиктеләр. Зур төзелешләргә хас күтәренкелек вә илһам күңелләрдә урын алды, җилкендерде, канатландырды. Күпме язмышлар үзара чуалышып, күпме гомерләр үз юнәлешен тапты. Күпме яшьләр шушында очрашып гашыйк булдылар, гаилә кордылар.

Комплектлау участогындагы Роза исемле татар кызы белән Яббар эшли башлаган атнада ук танышты. Инде утыздан узган ир-егет белән табельщица булып эшләүче егерме ике яшьлек кыз арасында шундук күңел аваздашлыгы сизелде. Розаны чибәр дип әйтерлек түгел, әмма чын хатын-кызларга хас нәзакәтлелек аның күз карашында, һәр хәрәкәтендә чагылып тора иде. Аз сүзле, тирән сагыш чалымланган чырайлы тыйнак егет хакында Роза, ниһаять, җитди кеше очрады, кияүгә чыгардай кешегә юлыктым дип уйлады.

Ул Куйбышевта эшчеләр гаиләсендә туып үскән, туган телендә начар гына сөйләшүче татар кызы иде. Аның Куйбышевта ата-анасы, заводта эшләүче бер абыйсы, әле мәктәпне тәмамлап кына килүче сеңлесе, тагын төрле якын һәм ерак туган-тумачалары бар иде.

Яббар белән Роза эш ыгы-зыгысы арасында көн саен очрашу җаен эзләделәр. Мәхәббәт иде бу, чын мәхәббәт иде!

Өйләнешү турында сүз чыккач, Яббар бераз акча җыярга, торак мәсьәләсен хәл итәргә кирәклеген кузгатты һәм алар әле ашыкмаска карар кылдылар.

Яббар башта үзе турында Розага барысын да сөйләү бик мөһим дип уйлады. Һәм озакка сузмыйча, беркөнне Роза белән поселок клубында кино караганнан соң, кызны тулай торагына озатканда, ул үзенең сугыш вакытында легионда булганын, лагерьларда утырганын бәйнә-бәйнә сөйләде.

Аның ачы бәяны, әлбәттә, Розага каты тәэсир итте, әмма кызның Яббарга мөнәсәбәте үзгәрмәде, ул аны барыбер яратты. Яббар исә моңа куанса да, сөйгән яры аның фаҗигасен бигүк тирәнтен аңлап бетерми дигән уйдан арына алмады һәм Розадан атаанасына, туганнарына бу хакта сөйләмәвен үтенде. Роза серне сакларга вәгъдә бирде.

Яббарда мәхәббәт белән беррәттән яңа өмет уянды. Аңа башкаларга караган кебек, кешегә санап караучылар барлыкка килер сыман тоелды. Әлегә бары тик анасы гына аны элеккечә ярата лабаса! Атасы да, Сәет абыйсы да кичермиләр. Нәсимә, хатынкызларча кызганып караса да, Сәеттән куркып, аңа якты йөз күрсәтмәскә тырыша. Нәсимәнең туганнары исә Яббарны белергә дә, танырга да теләмиләр. Фатыйманың туганнары аны кызганалар һәм шул ук вакытта кызларының Әнсарга чыгуына шатланып туймыйлар. Авылда күршеләр йөз чөерәләр, авылдашлар исәнләшмиләр – нәфрәтләре әллә ничә чакрымнан бәреп тора. Хәзер аның Розасы бар, Розаның туганнары бар...

Әмма бер уй җанын куырып-куырып ала – кайчан да булса Розаның туган-тумачасы аның тәрҗемәи хәлен белми калмас бит. Бу дөньяда нәрсәне яшерү мөмкин соң?!

Ярый, алга таба күз күрер. Иң мөһиме, булдыра алган адымны ясады ул – бергә тормыш юлыннан атлыйсы кешегә үзенең авыр серен ачты.

23

Тагын ике ел гомер узып китте. Шул ике ел гына да әллә нинди зур вакыйгалар алып килде. Иң әһәмиятлесе 1953 елны булды – «халыклар атасы», «бөек юлбашчы» Сталин үлде. Күпме кеше шатланды, күпмесе кайгыга батты: моны кем санаган да кем үлчәгән?! Тик менә даһи юлбашчы бу дөньядан киткәнгә бер елдан артык вакыт узды, ә урман ягыннан кояш элеккечә көн саен чыга, кич белән тау артында гадәттәгечә бата. Шулай ук ел фасыллары берсен берсе алмаштыра. Менә бит әле яздан соң тагын җәй килде.

Авыл халкының сәясәттә хәбәре юк. Кайдадыр ерак шәһәрләрдә кемнәрдер Сталин үлгәннән кайгыга батып, кайсылары, ки-

ресенчә, тиран бу дөньядан киткәнгә чиксез шатланып, киләчәккә зур өметләр баглап яшәсә, авылда исә авыр хезмәттән бөгелгән крестьян, ялсыз-бәйрәмсез, караңгыдан караңгыга кадәр эшләп, үзенең шәхси тормышында очны очка ялгап, дәүләт планын изге санап, гадәттәгечә көн күрде.

Тиздән печән чабар вакыт җитә.

Нәгыйм инде яз башыннан бирле кече яктагы сәкедә ята. Торып йөри алса да, хәле тиз бетә, сулышы каба, йөрәк үз турысында гына түгел, калак сөяге астында, иңбашларында үзен сиздереп авырта.

Ул казан тирәсендә чуалган карчыгы белән килененә аһылдап эндәште:

– Быел печән дә чаба алмам микәнни?

– Нинди печән чабу инде сиңа, – дип җавап бирде Әминә. – Ят, берни турында уйлама.

Әминә казан астына утын алырга чыгып киткәч, Нәгыйм ишек катында иске ботинкасының куба башлаган төбен рәтләргә маташып утыручы Сәеткә шыңшып эндәште:

– Болай эшсез яту дөрес түгел. Эшкә яраксыз яту бик яман нәрсә икән.

– Бер сыерлык кына печән әзерләрмен әле, – диде Сәет, ботинка табанын без белән каезлап. – Йөрәгеңне сакла.

Әминә кулына иске бүрек тотып килеп керде. Соңгы вакытта аның йөзендәге сагышта ниндидер усаллык төсмере дә катнаша, ул күзгә күренеп кырысланды, хәтта күзләрендә көтмәгәндә нәфрәт очкыннары чагылып-чагылып ала. Авыл кешеләренең, хәтта туганнарының да Яббарга начар мөгамәләсе ананы нык үзгәртте.

Әминә ишек катында мыш-мыш килеп үз эше белән мәшгуль булган Сәеткә карап торды, аннары, өй эченә узып, сәкедә ятучы карты янына килеп басты.

Нәгыйм башын калкытты:

– Нишләп сөмсерең коелган? Нинди бүрек ул кулыңда?

– Лапас түбәсендә Яббарның бала чагында кигән бүреген таптым, – диде Әминә. Ул бүрекне әйләндергәләп карады, иснәп алды, шуннан соң мич башына илтеп куйды. Ул, аралыктан чыкмыйча, бик озак тып-тын гына елады.

Нәгыйм яткан җирендә боргаланып алды:

– Яббар, Яббар... Әйбәт кенә яшәп, ару гына эшләп ята микән?

– Арудыр, арудыр, – дип, ата-анасын тынычландырырга ашыкты Сәет. – Ул эштән курка торган малай түгел. – Һич кенә дә төзекләнмәгән сыңар ботинкасын шапылдатып идәнгә ташлады, торып, кулларын чалбарына ышкып сөртте. – Әле менә күрерсез, ул тернәкләнеп китәр, ә мин аска таба тәгәрәрмен.

Әминә күз яшьләрен сөртеп аралыктан чыкты, өстәл янындагы урындыкка барып утырды.

– Бәләкәй чакта Аулаш тавыннан чана шуа идегез, – диде ул, хатирәләргә бирелеп. – Бер тапкыр Яббар бүреген шунда югалтып кайтты.

Нәгыймнең исә Сәет әйткән сүзләр колагында чыңлый иде. Әминәнең сүзләренә ул бөтенләй ригая бирмәде.

– Син, Сәет улым, аска тәгәри торган егет түгел, – диде Нәгыйм, улы белән ихластан горурланып. – Бирешмә.

Сәет аралыктагы юынгычның телен шылтыр-шылтыр китереп, кулын юа-юа хатынына эндәште:

– Нәсимә, пешәме инде?

Өйдәгеләрнең әңгәмәсен бер сүз катмый тып-тын тыңлап маташкан Нәсимә:

– Хәзер токмачын салам, – дип, кабалана башлады.

Әминә моңсу тавыш белән һаман сүзен дәвам итте:

– Шулкадәре ачуланган идем балакаемны бүреген югалтып кайтканы өчен. Яланбаш кайтканы өчен кызганасы урынга, бик каты тиргәп ташладым баланы. Җилтерәтә-җилтерәтә тауга җитәкләп алып киттем үзен. Эзли торгач, таптык. Тау итәгендә карга күмелгән булган. Кар эченнән колакчыны чак кына күренеп ята.

– Печәнне чүмәләләп урынында калдырсак та була, – диде Нәгыйм, Сәет килеп сәке кырына утыргач.

Улы башын чайкады:

– Юк, әти, алып кайтып куйсак яхшырак, ни дисәң дә, печән йортка кайтса гына синеке санала ул.

Әминә һаман үзенекен сөйләде:

– И-и-и, белсәгез иде Яббарны, балакаемны ничекләр сагынганымны!

Өйдә тынлык урнашкач, Нәгыйм сорап куйды:

– Киткәненә күпме булды?

– Дүртенче ел инде, – диде ана.

Нәгыйм аһ-ваһ килеп стенага борылып ятты:

– Илле дүртенче ел бара диген инде, ә! Сталин үлгәнгә дә бер елдан артып китте. Узган гомер – аккан су, ди.

Капка тавышы ишетелгәч, барысы да сагаеп калдылар. Соңгы вакытта аларга керүче сирәк, алар үзләре дә йомылыбрак яши башлаганнар иде.

Өйалды ишеге шыгырдагач, Сәет, кем керә икән дип, каршы чыкмакчы иде, ләкин шул вакытны өй ишеге киерелеп ачылды да бусагада Яббар пәйда булды. Иңендәге капчыкны, кулындагы чемоданны идәнгә куеп, ул ишек катында шактый вакыт елмаеп басып торды. Яббар нык үзгәргән, кыяфәтенә бераз рәт кергән шикелле, ләкин чәче нык агарган, күзләрендә тирән моңсулык, елмаюында да әйтеп бетергесез сагыш чагыла иде. Өйдәгеләр тып-тын калдылар. Нәгыйм торып утырганда гына сәке такталары шыгырдап тынлыкны бозып куйды.

Мөгаен, Яббар шушылай бусагада гына басып торырга да әзер иде, ата-анасын, абыйсын күрү бәхетеннән артыгы кирәк түгел иде лә аңа. Аның өстендә өр-яңа кәчтүм-чалбар, эчтә ап-ак күлмәк, аягында калын табанлы ботинка, чал чәчен матур итеп кырыйга

тараган, гәүдәсе дә турайган, кайткандагы кебек бөкрәеп тормый – үзгәргән, нык үзгәргән Яббар, яхшы якка үзгәргән.

– Исәнмесез! – диде ул, күкрәк тутырып. Аның исәнләшүе үзенең ыспай киеменә бик тә туры, тәңгәл килеп яңгырады.

Әминә кулларын сузып улына таба атлады:

– Улым, әле генә сине искә алдым бит мин! Кайттыңмыни, балакаем!

Әнкәсенә аркасыннан сөяргә җайлырак булсын өчен, Яббар бераз иеленкерәде.

– Исәннәрмесез, – дип, тагын бер кат исәнләште Яббар. – Абыйсы белән кул биреп күрешкәннән соң, атасы янына килде. – Чирлисеңме әллә, әти?

Нәгыйм салкынаеп киткән кулын улына сузып күреште:

– Йөрәк келтер-мелтер бит инде минем.

– Исәнме, Нәсимә.

– Исәнме, – диде Нәсимә, Яббарны җентекләп күзәтеп.

Әминә куанычтан тәмам югалып калды, улы урындык алып мич буена утыргач, аның тирәсендә нишләргә белми бөтерелеп йөрде:

– Бигрәк озак кайтмадың бит, улым.

– Эш бик каты, – диде Яббар. – Бөтенләй ялсыз эшләдек соңгы вакытта.

– Гис төзеләме? – дип сорап куйды Нәгыйм.

– Төзелә.

Сәет, энесенең яхшы өс киемен гаҗәпсенебрәк күзәтеп утырганнан соң:

– Отпускы алып кайттыңмы? – дип кызыксынды.

– Әйе. Мин хәзер бер зур нәчәлникнең шоферы булып эшлим. Кырыс булса да, хәлгә керә торган, гадел, яхшы кеше.

Кече улының киләчәк язмышына бернинди өметләр багламый башлаган Нәгыймгә хәл кереп китте.

– Нинди машинада эшлисең? – дип сорады ул, Яббарның машина йөртүче булып киткәненә әле тәгаен ышанып җитмичә.

– «Москвич»та.

– О-о-о, хәтә-ә-ә-әр! – диде Нәгыйм, шаккатып.

Нәсимә ягымлы итеп Яббарга эндәште:

– Мактап кына йөрисең икән – әле генә аш пешеп җитте.

Яббар сикереп торды да кабаланып ишек катындагы чемоданны ачты, аннары капчыгында актарынырга тотынды:

– Туктагыз әле, ашарга утырганчы бүләкләремне өләшим. Күчтәнәчләрем дә бар. Әти, син тельняшка яратасың бит. Менә сиңа тельняшка.

Нәгыйм тәмам терелеп китте, Яббарның кулыннан бүләкне алганнан соң, алдына куеп, озак итеп сыпыра-сыпыра әйләндергәләде:

– Рәхмәт. Тәнгә иң рәхәт нәрсә шушы. Рәхмәт.

Яббар чемоданыннан ачык төстәге чуклы шәл алып әнкәсенә сузды:

– Әнкәй, сиңа шәл.

Яббар шәлне әнкәсенең иңенә үзе салды. Әминә исә, оялып кына көзге каршына килеп:

– И-и-и, улым, бик кыйбаттыр бу, бигрәк затлы шәл бит, – диде.

– Кыйбат түгел, кыйбат түгел, әнкәй. Аны табуы гына авыр – дефицит. Минем нәчәлнигемнең һәркайда танышлары, дуслары күп, шуның аша алдым мин аны. – Ул, капчыгыннан фуражка алып, Сәеткә елмайды: – Сиңа, абый, менә нинди фуражка. Размеры синеке. Киеп кара әле, таман микән?

Сәет фуражканы теләр-теләмәс кенә алды:

– Рәхмәт.

– Кая, киеп кара инде, – диде аңа Нәгыйм.

Сәет:

– Тамандыр, тамандыр, – дип, фуражканы киде дә хатынына таба борылды.

– Шулхәтле килешә, – диде Нәсимә, сокланып. – Таманмы?

– Таман, таман, – диде Сәет, фуражканы салганнан соң әйләндергәләп карап.

Шуннан соң Яббар чемоданнан ал чәчәкле яулык алып Нәсимәгә сузды:

– Монысы сиңа, Нәсимә.

Нәсимәнең йөзе шатлык катыш каушаудан кып-кызыл булды.

– Рәхмәт! – диде ул, читенсенеп, һәм, өйдәге ыгы-зыгыдан файдаланып, яулыкны тиз генә каядыр яшереп тә куйды.

Яббарның капчыгыннан тәмле-тәмле күчтәнәчләр дә чыкты – кәгазьгә төрелгән хәлвә, шикәр, кәнфит, печенье, берничә банка куертылган сөт.

– И-и-и, улым, шушы хәтле күчтәнәчләр белән кайтмасаң! – диде Әминә, өйгә кергән бәйрәмнән тыны кабып. – Болай ук расход тотмаска идең.

– Һи, әнкәй, шундый зур ГЭС төзеп тә күчтәнәчләр белән кайтмагач! – диде Яббар, якын кешеләрен куандыра алганга үзен бәхетле тоеп.

Нәсимә табын әзерләде. Ашарга утырдылар. Әминә кече улыннан күзләрен алмады.

– Эшең бик авыр түгелме, улым? – дип кызыксынды ул.

Яббар җавап бирергә дә өлгермәде, Нәгыйм сүзгә кушылды:

– Эш җиңел булмый инде ул, бигрәк тә андый стройкада!

– Түзәрлек, әнкәй, – диде Яббар, анасына ягымлы карап. – Инде мин күргәннәрдән соң теләсә нинди эш авыр тоелмас.

– Син анда кайда, ничек яшисең соң? – дип сорады Сәет, кайнар ашын агач кашык белән болгатып.

– Жигулевск дигән кечкенә шәһәрдә. Поселок сыман, җыйнак кына шәһәрчек. Ул күптән түгел Отважное белән Моркваши авыллары урынында төзелде. Анда ГЭС төзүчеләр генә түгел, нефть эзләүчеләр дә яши. Баракта урын бирделәр – тулай торак дип атала.

– Ул яңа шәһәрчек стройканың үзеннән еракмы соң? – дип кызыксынды атасы.

Бу әңгәмә Яббарның күңеленә хуш килде. Ул хәтта ашау турында да онытты, якын кешеләренең сорауларына рәхәтләнеп җавап биреп утырды.

– Ул шәһәрчек Самарская Луканың төньягында.

– Анысы нәрсә тагын? – дип сорады Сәет.

– Иделнең, Куйбышевтан сиксән километр югарырак, дугаланган урыны бар, анда Идел бик зур дуга булып ага.

Нәгыймгә кече улы сөйләгәннәр бик кызыклы булып тоелды.

– ГЭС үзе Куйбышевтан ерак булачакмы соң? – дип сорады ул.

– ГЭС әлеге дә баягы Самара Лукасының төньягында, Куйбышевтан сиксән километр өстәрәк урнаша. Безнең Жигулевск төзелеш белән янәшә генә диярлек. Ай-яй зур ГЭС булачак ул! Иделдә иң зур гидростанция булачак. Ленин исемен йөртәчәк. Беренче агрегатны илле бишенче елның, ягъни киләсе елның азагында җибәрәчәкләр.

– Ә җәмгысы ничә агрегат корылачак? – дип кызыксынды Сәет.

– Егерме. Мощность 2,3 миллион киловатт тәшкил итәчәк. Сусаклагычның мәйданы гаҗәп зур булачак. Иделнең киңлеге дә, тирәнлеге дә артачак.

Нәгыйм шаккатып баш чайкады. Әнкәсе исә, кече улы өчен зур горурлык хисе тоеп, соклануын белдерде:

– И-и-и, балакаем, боларны кайлардан белеп бетердең?

– Мин бит зур начальникне йөртәм, әнкәй, – диде Яббар, илһамланып.

Сәетнең кәефе кинәт сүренкеләнде. Эчке киеренкелеге чыраена чыкты.

– Нәчәлнигең төрмәләрдә утырганыңны белмиме? – диде ул, бөтенләй көтмәгәндә.

– Белә, – диде Яббар, ашый башлаган җиреннән туктап.

Сәет:

– Ә легионер булганыңны? – дип сорагач, барысы да тып-тын калдылар.

– Анысын да белә, – диде Яббар, абыйсына карарга кыймыйча.

Табынның шундук яме китте.

– Каян белгән? – дип сорады Нәгыйм. – Кем хәбәр иткән икән?

– Үзем сөйләдем барысын да, – диде Яббар.

– Ничек кабул итте? – дип кызыксынды атасы.

– Төшенкелеккә бирелмә, диде. Гаепсезлегең күзеңнән күренеп тора, диде. Урнаш, эшлә, әмма боларны башкаларга сөйләмәскә тырыш, диде. Әле шундук ике банка тушенка, бер банка сгущенка да бирде.

Сәет кашыгын шакылдатып өстәлгә куйды:

– Нәчәлнигең үзе яки берәр туганы легионер түгелдер бит?!
– Юк, – диде Яббар, абыйсына туры карап.
Сәетнең ачуы бәреп чыкты:
– ГЭС, агрегат, водохранилище, киловатт! Нәчәльнигең миһербанлы кеше! Тушенка, сгущенка! Син балда-майда йөзәчәксең! Ә миңа эшем буенча күтәрелергә районнан рөхсәт бирмиләр!
Әминә кырыенда утыручы олы улының иңенә кулы белән кагылып ялварды:
– Сәет, улым, түз, сабыр ит.
Нәсимә кубарга торган давылдан куркып эндәште:
– Ашагыз әле, ашыгыз суына.
Әмма инде ашның тәме югалды. Шулай да Нәсимәнең тавышы табын янындагы ярсуны бераз таратыбрак җибәрде.
– Авылда нинди яңалыклар бар? – дип кызыксынды Яббар, өстәл башында теләр-теләмәс кенә ашап утыручы атасына карап.
Нәгыйм урындыгын шыгырдатып җайлабрак утырды:
– Иң зур яңалык шул: Әнсарны райкомга эшкә алдылар. Авыл җитәкчесе булып аз гына эшләде югыйсә. Ай-яй тиз күтәрделәр үзен.
Әминә күрше малаеның дәрәҗәсе күтәрелүгә ихластан куанды.
– Маладис, – диде ул. – Сүз дә юк, маладис, читтән торып укыды, кулыннан эш килә, акылы бар.
– Аның урынына силсәвиткә кемне куйдылар соң? – диде Яббар.
– Килгән кешене сайладылар, – диде Нәгыйм. – Харис исемле. Агроном иде ул, практикага монда җибәргәннәр дә, шушында төпләнеп калды. Күп тә үтмәде, каяндыр бер керәшен кызын хатынлыкка алып кайтты. Сәер булса да, бик тырыш кеше, аны сайлап дөрес эшләгәннәрдер.
Сәет авыз кырыйларын алдындагы тастымал белән сөрткәч, Яббарга карап торды да кырыс тавыш белән әйтеп куйды:
– Синең аркада мине яхшы эшкә алмыйлар. Минем өчен иң зур яңалык шул.
Яббарның үзәге куырылып куйды:
– Нинди эшкә?
– МТСның баш механигы итеп тәкъдим итмәкчеләр иде, энесе сатлыкҗан дип, кандидатурамны кире кактылар.
– Бәлки, Әнсарга мөрәҗәгать итәргә кирәктер, – диде Нәгыйм, бөгелеп, сызлый башлагын аягын кулы белән угалый-угалый.
– Күпме мескенләнергә, түбәнсенергә була инде! – дип җикерде Сәет. – Шул Әнсар алдында гомер буе бил бөгәрмен микәнни?! Кемнеңдер сатлыкҗанлыгы аркасында мин гел кол сыман тезләнеп яшәрменме?!
Шунда Әминә көтелмәгән усаллык белән олы улына җикерде:
– Уңышсызлыкларыңны гел Яббарга гына сылтама!

Сәет «әкбәр» итеп тиз генә битен сыпырган булды да сикереп торды:

– Сылтамаскамы?! Мин уңышсызмы?! Эшем буенча бер генә дә кыек-мыек сүз әйткәннәре юк, эшемдә мине беркем гаепли алмый! Ә Яббар аркасында әле монда, әле тегендә абыныргга туры килә.

– Энем ялга кайтты дип куанып утырасы урынга тагын өйдә тузан тузгытырга утырасыңмы?! – диде Әминә, ачуланып.

Көтмәгәндә Нәсимә ирен якларга керешге:

– Соң, әнкәй, миңа да мәктәптә еш кына төрттереп куялар, имеш, гаиләбездә изменник бар. Мин укытучы кеше, патриотизм турында сөйли башласам, телем әйләнми. Баштарак үтәр яки күнегермен дигән идем...

Нәсимәнең күзләре яшьләнде. Барысы да тынып калдылар. Нәсимәгә үзенең туганнары тарафыннан да Яббар хакында сөйләшкәннәрен еш ишетергә туры килә – аны берсе дә яхшы сүз белән телгә алмый. Анасы Тәслимә Әминәләргә кодагый буларак әллә нигә бер генә кереп чыга, анысында да авылдашлар күзенә чалынмаска тырышып кына. Сеңлесе Фәйрүзә ире белән Казаннан ничә тапкыр кайтып бер тапкыр да Нәгыймнәргә кермәделәр. Кече сеңлесе Сәвиянең дә кияүгә чыкканнан соң монда аяк басканы юк. Тәслимә кызының тырышып-тырмашып укытучылыкка укып кайтканнан соң, Сәеткә чыгып, «предатель» туып үскән гаилә әгъзасы булуыннан беркайчан канәгать итмәде, гәрчә Сәеткә тел-теш тигезерлек булмаса да.

Боларның барысын да Нәгыймнәр йортында беләләр, Нәсимәнең хәлен аңлыйлар. Атасы Кашаф 1939 елны каты чирләп вафат булганнан соң йорт хуҗасы булып калырга тиешле абыйсы Фәрук сугышта һәлак булып калгач, киленнең башларында нинди генә уй-фикерләр тумас та, нинди генә авыр хисләр кайнамас икән!

– Түзәргә кирәк! – диде Әминә, тагы да кырысланыбрак. Соңгы вакытта ананың тавышында да элек ишетелмәгән катылык яңгырый башлады. – Син, Сәет, энең аркасында абынасың икән, егылсаң да, торып кит. Эшеңнән кусалар да, түз, гади эшче булып эшлә. – Аннары тавышын йомшартыбрак Нәсимәгә эндәште: – Ә син, килен, кияүгә чыкканда Яббарның фаҗигасен белә идең. Зинһар өчен, син дә түз!

Нәгыйм:

– Аллаһы әкбәр, – дип, табын яныннан китеп сәкегә барып ятты. – Түз... Синең гомергә шул бер сүз булды инде – түз, түз, түз.

– Әнкәй, китим мин, – диде Яббар тыныч кына.

– Юк, юк, улым, мунчалар кереп, ял итеп китәсең, – диде Әминә, катгый итеп. – Аннары... берничәне кунмыйча китмисең, улым...

– Син теләсә кайчан китә аласың, – дип мыгырдады Сәет. – Ә без монда калабыз, синең яманатың белән!

Яббар, битен сыпырып:

– Аллаһы әкбәр, рәхмәт, тәмле булды, – диде. Шуннан, торып: – Мин һава сулап керәм, әнкәй, – дип, ишегалдына чыгып китте.

Әминә әле Сәеткә, әле Нәсимәгә ачулы караш ташлады.

– Мин шуны әйтмәкче булам... – диде ана янаулы тавыш белән. – Сез, балалар, тагын Яббарга тел-теш тигезсәгез, миннән якты чырай күрмәссез! Риза-бәхил түгел!

Нәсимә елый-елый олы якка кереп караватка ауды. Сәет хатынын юатырга дип аның артыннан кереп китте.

– Әнкәй күзгә күренеп үзгәрә, кырыс күңелләнә, – диде Нәсимә, сулкылдап.

Сәет караватка кырына утырды:

– Әйе шул, сизәм.

– Мондый коры кеше түгел иде ул.

– Яббар аркасында күңеле катты аның, – диде Сәет. – Нык ярата ул кече малаен.

Нәсимә торып утырды, битен учлары белән сыпырды:

– Ничек инде баласын яратмасын.

– Мунча ягып җибәрәсе бар, – диде Сәет, хатынын елаудан туктатып, игътибарын башка нәрсәгә юнәлтер өчен.

Алар мунчага су ташыйсы бар дигән сылтау белән өйдән чыгып киттеләр.

Нәгыйм кече якның сәкесендә түшәмгә карап яткан килеш тәрәзәдән олы улы белән киленнең урамдагы коедан мунчага су ташыганнарын күзәтеп торучы карчыгына эндәште:

– Синең дә холкың үзгәрде, карчык.

– Шулаймы... – диде Әминә битараф кына.

– Артык кискен кыланма әле син.

– Барыгыз да Яббарны кыерсытасыз, – диде Әминә, картына карамыйча гына. – Син, ата кеше, үз балаңны әле бер тапкыр гына да якламадың.

– Дөньялыкта һәрбер кеше үзенә язганын алырга тиеш.

– И-и-и, нәрсә дип ята бит! – диде Әминә, нәфрәтләнеп. – Яббарның күңеле тутырук ут икәнне күрмисеңмени?! Тагын нәрсә алырга тиеш ул бала?! Шундый җәбер-золымнар кичкәннән соң да бимазалана бит ул! Нишләп шушы кадәре каты бәгырьле соң син!

Нәгыйм яткан урынында боргаланып алды:

– Бала, бала... Син Сәет белән Нәсимәгә бик орынма. Яббар ул читтә яшисе кеше, ә болары белән гомер азагына кадәр бергә яшисебез бар.

– Нәсимәсе дә Яббарга тел-теш тигезә башлады бит, – диде Әминә.

Нәгыйм тавышын әкренәйтте:

– Соң, анысы да гасабиланыр инде. Аларның соңгы вакытта кыбырсуларының сәбәбе балалары юклыктан. Күпме торып балалары юк бит.

– Булыр әле, Алла боерса, – диде Әминә, «бала» сүзеннән кинәт йомшарып.
Нәгыйм:
– Булса булыр иде инде, – дип, тагын стенага табан борылып ятты.
– Тик кенә ят, – диде Әминә бернинди ачусыз. – Йөрәгеңне тынычландыр да тик кенә ят.
– Ятам бит инде, – дип җавап бирде Нәгыйм, чак кына ишетелерлек итеп.
Нәгыйм шулай торымнан торымга ыңгыраша-ыңгыраша сәкедә әйләнгәләде, Әминә казан тирәсендәге вак-төяк эше белән мәшгуль булды.
Бераздан берни булмаган кыяфәт белән Яббар килеп керде, беркавым әле атасына, әле анасына елмаеп карап торды.
– Әти! Әнкәй! Мунчалар кереп тормам инде, – диде ул.
– Ничек инде мунчалар кереп тормыйсың? – дип пошаманга калды Әминә.
– Миңа кичекмәстән китәргә кирәк.
Әминә улына ялынырга тотынды:
– Юк, юк, улым, алай итмисең! Ничек инде мунчалар да кермичә, берничәне кунмыйча?!
– Тиздән иркенләп, озакка кайтырмын әле. Әти, сиңа бирәр төрле яңа дарулар кирәкмиме?
Нәгыйм әкрен генә торып утырды:
– Дарулар бар минем, улым.
– Әле булганнарын да ялындырып кына эчә, – диде Әминә.
– Дарулар кирәк булса, хат языгыз, фәлән-фәлән дару кирәк дип. Алып кайтырмын.
– Нинди хат инде! – диде Әминә. – Тиздән кайтам дисең бит. Син кайт, улым, гел кайтып йөр. Минем яныма кайтасың бит син. Син башкаларга игътибар итмә. Мин сине бик сагынам бит, улым. Иң кадерле кешем син минем, балакаем! Шуны онытма. Гел кайтып йөр!
Әминәнең күңеле тулганны күреп, Нәгыйм чыраен сытты:
– Елама инде. Улың шундый бөек төзелештә эшли. Горурланып, сөенеп, елмаеп кына утыр.
– Ул төзелүче ГЭС белән бигүк горурланырга иртәрәктер шул әле, – диде Яббар. – Нәчәлник әйтә: алты мең квадрат километрдан артык мәйданны су басачак, ди. Сер итеп әйтте. Бу тирәләрне дә отыры су басмагае дип куркам әле мин.
– Ул кинәт басмыйдыр бит, – диде Нәгыйм. – Баса башласа, әйтми калмаслар. Аннары, Куйбышев моннан ерак бит ул. Нүжәли суы монда хәтле менәр?!
– Менүе дә ихтимал. Егерме агрегат төзеләчәк бит. Хәер, әле алдан куркып утырырга кирәкмидер. Ләкин нәчәлник әйтүе буенча, су нык күтәреләчәк.
– Күрә торып, авылларга хәтле суны күтәртмәсләр әле, – диде

Әминә, әллә кайчан әллә кайдан су килеп басасын күз алдына да китерә алмыйча.

– Шулай, әнкәй, шулай. Анда бит бик зур инженерлар, белгечләр эшли, алар нишләгәннәрен аңлап эшлиләр.

– Улым, әллә берәрне генә булса да кунасыңмы? – дип, тагын бер тапкыр үтенеп карады Әминә.

– Юк, әнкәй, китим инде мин. – Ул тагын әле атасына, әле анасына карап куйды. – Шуны әйтмәкче идем... Миңа инде утыз яшь... Мин тиздән өйләнермен, ахрысы.

– Йөргән кызың бармы соң, улым? – диде Әминә, йөрәгенең дерт иткәнен тоеп.

– Бар.

– Татар кызымы?

– Татар. Куйбышев кызы. Татарча сөйләшүе чамалырак, әлбәттә.

Әминә бу хәбәргә бик сөенде.

– Булсын, булсын, – диде ул. – Татар кызы булгач, шул җиткән. Үзебезнең кеше булгач бик әйбәт. Кайчан алып кайтасың соң инде аны монда?

– Мин аны монда алып кайтып тормас идем... Сез рөхсәт итсәгез... Никахны барыбер кыз ягында укыталар. Сезне шунда алып барып...

Әминә улының сүзен бүлде:

– Ник башта аны монда алып кайтып күрсәтмисең соң?

– Мин, гомумән, аны монда алып кайтмас идем.

– Ничек инде?!

– Аңламыйсыңмыни ник алып кайтырга теләмәгәнен! – дип кысылды Нәгыйм.

Әминәнең әле генә яктырган йөзе тагын караңгыланып китте:

– Ул белмимени?

– Белә. Мин яшермәдем, аңа барысын да сөйләдем. Тик аның болай белүе бер нәрсә, ә якташларымның миңа карата мөгамәләсен сизүе, күрүе бөтенләй башка нәрсә!

24

1954 елның алтын көзе дөньяны алтын төсләргә манып маташкан көннәрнең берсендә Розаның атасы Куйбышев каласында ярым яшертен рәвештә дин хезмәтен алып баручы бер мулла картны тапты һәм шундук көнен билгеләделәр дә, күп тә үтми, никах укыттылар. Нәгыйм белән Әминәне шулкадәре ерак арага МТСтан машина сорап Сәет алып килде. Шулай итеп, Яббар һәм Роза ир белән хатын булдылар.

Розаның ата-анасы, туганнары Яббарның үз-үзенә бикләнү сәерлеген беренче көннәрдән үк абайладылар. Розаның күңелендә бер хыял бар иде – ир белән хатын булып яши башлагач, Яббарның легионнарда булганын, «изменник» дип мөһер сугылуын ата-

анасы һәм туган-тумачасы кешеләрчә аңлап кабул итәрләр, аның язмышының ул ягына күз йомарлар дип өметләнгән иде. Ул уйлаганча булып чыкмады шул.

Розаның ике туган абыйсы – кызу холыклы ир-егет, сугыш ветераны – Кызылъярга килеп Яббар турында белешеп кайтты. Шуннан соң Розаның ата-анасы, туганнары Кызылъярга беркайчан да аяк басмаска карар кылдылар һәм тормыш иптәшен дөрес сайламаганы өчен Розаны мөмкинлек чыккан саен чукырга тотындылар.

Шулай итеп, Роза белән Яббар Куйбышевка да, Кызылъярга да бергәләп кайтмас булдылар. Роза туып үскән каласына ял вакытларында ялгызы гына кайткалады. Яббар исә, әнкәсен бик сагынгач, берүзе генә туган авылыннан әйләнеп килү җаен эзләде.

Алар бит бер-берсен яратып өйләнештеләр. Яббар үзе кичергәннәрне, башына төшкәннәрне тәфсилләп сөйләде аңа. Әнкәсенә сөйләмәгән кайбер нәрсәләрне дә сөйләде ул хатынына. Роза өчен исә Яббар легионер да түгел, җинаятьче дә түгел, ә нечкә күңелле, фаҗигагә дучар булган бер кеше иде. Гаилә тормышы аның күңел җәрәхәтләрен савыктырыр, тулы канлы тормыш белән яшәп киләчәккә атларга яңа куәт өстәр дип уйлады. Алар, чынлап та, әйбәт кенә тормыш корып җибәрделәр кебек. Ләкин Розаның ата-анасы, туган-тумачасы Яббарга карата шикле һәм кырыс мөгамәләдә булгач, яшь гаиләдә тотрыклылык какшады шикелле. Роза да отыры капма-каршылыклы уйлар белән бимазалана башлады.

Ләкин алда икесен дә зур вакыйга көтә иде... Икеле-микеле уйлар кинәт юкка чыктылар, бернигә һәм беркемгә карамыйча, тормышны корырга, гаиләдә бәхетле иминлек урнаштырырга кирәк дигән эчке карар белән алар җитәкләшеп алга – киләчәккә атладылар.

...Ир белән хатын өчен бала туудан да әһәмиятлерәк вакыйга булырга мөмкинме икән?! Тупырдап торган, Яббарга коеп куйган кебек охшаган малайга алар Вәсим дип исем кушалар һәм бала туу шатлыгы белән дәртләнеп яши башлыйлар.

Илдә зур-зур төзелешләр кайнады, бишьеллык планнарны үтәү белән мәшгуль Коммунистлар партиясе өчен аерым авылларның, аерым кешеләрнең язмышы түгел, киләчәктә булачак коммунизм әһәмиятлерәк иде. Шуңа күрә сусаклагычның суы киң-киң мәйданнарны, болыннарны, авылларны, зиратларны күмәчәге якты киләчәк өчен түләнергә тиешле бәя дип саналды. Җир шарының алтыдан бер өлешен тәшкил иткән империядә табигать, туган җир төшенчәләре дә тышкы дошман янаган чакта гына күтәрелә иде. Ватан төшенчәсе исә компартиянең идеологиясенә хезмәт итүче төшенчә буларак кына яшәп килде.

Идел буендагы авылда туып үскән татар өчен Чукотка яки Магадан Ватан була аламы? Идел буйлары бурят яки чукча өчен Ватан була аламы?

Беркөнне Яббар үзенең начальнигыннан җан өшеткеч хәбәр ишетә. Яббар туып үскән төбәкләрне һичшиксез су басачак дигән имеш-мимешләр озакламый гамәлгә ашачак икән. Начальник махсус карталарны да күргән – су астында калачак территорияләр күптән билгеләнгән, Кызылъяр авылы урнашкан тирәләрне су йотачагы инде мәгълүм, ди.

Беренче агрегат худка җибәрелгән вакытта ук инде сусаклагыч якын тирәдәге авылларны, кырларны үз астында калдырды. Әле суның биеклеге тагы да ныграк күтәреләчәк, сусаклагычның мәйданы Идел буйлап өскә үрмәләячәк бит.

Яббар үзенә урын тапмады. Роза аны бу хакта уйламаска өндәде. «Гаиләбез турында, үзебез турында уйла, – диде ул аңа, – сиңа бит туган ягыңда якты чырай күрсәтүче дә юк. Нигә син әллә нинди хәлең җитмәс мәсьәлә буенча җаныңны ашыйсың?» Хатынының бу сүзләренә Яббарның ачуы килде. Ничек инде туып үскән җир өчен кайгырмаска? Ничек инде газиз әнкәсе яши торган җир турында уйламаска?! Ничек инде үзе туып үскән авыл язмышы өчен борчылмаска?! Су астында калу ул бит инде юкка чыгу, бетү дигән сүз.

Бик озак уйланганнан соң, ул Әнсар янына барып кайтырга булды. Әнсар үз районнарының райком секретаре ләбаса, туган якны, ичмаса, туган авылны, күрше авылларны, аларның зиратларын саклап калыр өчен көч куймый калмас. Бәлки, Әнсар әле туган якка яңа төрле афәт киләсен белмидер, әйтмәгәннәрдер, ишетмәгәндер.

25

Көн яктысыннан соң коридор караңгы булып тоелды. Күз ияләшкәч, стенада агымдагы 1956 елның планнары, аның кайбер уңышлары хакындагы плакатлар, гәҗитләр, графиклар, нindidер фоторәсемнәр абайланды. Яббар аларны якынрак килә-килә карап барганда, аның яныннан төз гәүдәле, оста ясалган прическалы бер хатын кулына кәгазьләр тотып, шык-шык басып үтеп китте. Биш-алты адым узгач, ханым туктап борылды:

– Яббар! Синме?

Яббар үз исемен ишетеп сискәнеп китте. Борылып караса, аңа таба, якты елмаеп, Фатыйма килә:

– Яббар! Танымыйсыңмыни?

Яббар, чынлап та, башта икеләнеп торды – улмы бу, юкмы.

Фатыйманы дөрестән дә танырлык түгел, ул бик үзгәргән, киеме, үзен тотышы, прическасы затлыланган.

– Фатыйма түгелме соң син?! – диде ул, шаккатып.

– Мин, мин, – диде Фатыйма, тагы да мөлаемрак елмаеп. – Исәнме! – Ул исәнләшергә дип җылы, йомшак кулын сузды. Яббар кыюсызланып, саклык белән генә аның ап-ак кулын кысып күреште.

– Исәнме! – диде Яббар, каушавын көчкә җиңеп. – Ә-ә-ә, әйе, әйе, син монда эшлисең бит. Мин сине танымадым. Киноларда гына күренә торган мадамга әйләнгәнсең. Нинди эштә соң син монда?

– Райкомның бухгалтериясендә эшлим. Ә син райкомда нишләп йөрисең?

– Әнсарны райком секретаре итеп сайлаганнарын ишеткән идем, менә килергә булдым әле.

Яббар Фатыймадан күзләрен алмады. Кайчандыр аны яраткан Фатыймамы соң бу? Шул яшьлектәге беренче мәхәббәтеме соң бу? Фатыйма аңлады аның уй-хисләрен. Ул үзе дә шундый ук тойгылар кичерә түгелме! Өлкәннәрдән кача-поса, авылдашлардан читенсенеп кенә инеш буйларында очрашып, аулакта үзләрен дөньядагы иң бәхетле кешеләр итеп тоялар иде бит алар. Фатыймага бәйләнгәне өчен Әнсар Яббарның иң явыз дошманына әверелгән иде. Аның бәйләнүеннән ничек котылырга белми йөдәгәннән соң, сугышуларга кадәр барып җитәләр иде бит. Әнсар авыл советы рәисе малае булса да, Яббар аңа бирешмәде. Чөнки Фатыйма Яббарны нык яратты. Мәхәббәт дәрт һәм дәрман бирә иде Яббарга. Ләкин язмышның йодрыгы Әнсарныкыннан катырак булып чыкты. Нык сукты, аямыйча, рәхимсез рәвештә китереп орды язмыш Яббарга. Аларга бергә булырга язмаган икән. Фатыйманы ачуланырга, гаепләргә аз гына булса да мөмкин түгел. Яббар йөрәгендә әле һаман да Фатыймага карата мәхәббәт утының сүнмәгәнен тойды.

Фатыйма кулындагы сәгатенә карап алды:

– Әнсар менә-менә кайтып җитәргә тиеш. Район буенча чыгып киткән иде. Нинди йомыш белән килдең?

– Бик җитди үтенеч белән, – диде Яббар. – Аннары үзе сиңа әйтер әле. Мине кабул итсә инде...

– Кабул итәр дип уйлыйм. – Фатыйма Яббарның күз карашыннан уңайсызланыбрак китте. – Болай тормышлар ничек соң?

– Бер көе.

– Улыгыз бар бугай? – дип кызыксынды Фатыйма.

– Әйе, улыбыз бар.

– Исеме ничек?

– Вәсим дип куштык.

– Вәсим... Матур исем.

– Сез дә кыз алып кайттыгыз дип ишеттем, – диде Яббар.

– Дөрес ишеткәнсең, – дип елмайды Фатыйма. – Кызыбыз туды, Сөмбел исемле. Безнең хәзер бер малай, бер кыз. – Ул беравык икеләнеп торганнан соң сорарга җөрьәт итте: – Карале, Яббар, нишләп гаиләңне авылга алып кайтмыйсың?

– Аңлыйсың бит инде ник алып кайтмаганымны, – диде Яббар, караңгыланып. – Аны ник сорап торасың?

Фатыйма, бу сорауны биргәненә читенсенеп:

– Гафу ит, – диде. Аннары шатлык белән әйтеп куйды: – Безнең тагын бер шатлыгыбыз бар бит – ниһаять, Әнсарның күкрәгендәге кыйпылчыкны алдылар.

– Әйбәт булган. Райком секретаре булгач, хирургларның яхшылары тотынгандыр инде.

– Әйе, дөресен әйтергә кирәк, кешенең должностена, абруена карыйлар шул.

– Әнсар кыйпылчыгыннан арынган... – дип уйга калды Яббар. – Ә менә минем күңелемдәге кыйпылчыгымны берничек тә беркайчан да бернинди хирург та алып ташлый алмаячак.

Фатыйма ягымлы итеп карады:

– Алай димә, Яббар. Тормышың яктылыкка таба юл алды бит инде. Өйләнгәнсең, улыгыз туган, эшлисең. Яшәү шартлары ничегрәк соң?

– Аерым фатир турында уйларга иртәрәктер әле. Баракта бер бүлмәбез бар, аңа да сөенеп туя алмыйбыз.

– Хатының нинди эштә?

– Безнең оешмада табельщица булып эшли.

– Алай икән, – диде Фатыйма, һәм алар шактый вакыт сөйләшергә сүз табалмый бер-берсенә карашып тордылар.

– Кем уйлаган язмышларның менә шушылай бормаланасын, – диде Яббар. – Иделнең Самарская Лукасыннан да катырак бормалана икән ул!

– Әйе шул, – диде Фатыйма сагышлы тавыш белән. – «Алдан күрү мөмкин түгел башның ни күрәчәген» дип җырлый идең бит син яшь чакта.

– Бергә чакларыбызны исеңә төшергәлисеңме соң?

Фатыйманың күңеле тулды:

– Гел хәтеремдә, Яббар. Син миңа ачу-үпкә тотмыйсыңмы?

– Юк. Ни өчен мин сиңа үпкәләргә тиеш?!

– Сугыштан сине көтәм дип калдым, ә үзем Әнсарга чыктым.

– Син мине сугыштан көтәргә вәгъдә бирдең, лагерьда утырып чыгуымны көтәргә вәгъдә бирмәдең бит.

Фатыйма күз яшьләрен көчкә тыеп торды.

– Син яшь чактагы шикелле үк якты күңелле, олы җанлы кеше булып калгансың, Яббар, – диде Фатыйма. – Йөзең, кыяфәтең бөтенләй башка, күзләрең дә сәер, ә кешелегеңне югалтмагансың, күңелең катмаган. Гәүдәңне бераз турайт, башыңны күтәребрәк йөр, Яббар. Инде аңлаган кеше аңлагандыр. Аңламаганнарына исбатлап җаныңны ашама. Күп түбәнсендең инде – җитәр! Минемчә, алар барысы да сине әле һаман тиешле җәзаңны алмагансың, әле җәфаланырга тиешсең дип саныйлар. Мин сатлыкҗан түгел дип әйткән саен, алар һаман сине сатлыкҗан дип инандырырга маташалар.

Фатыйма үзе дә олы җанлы кеше. Ләкин ул бит аны яратып йөрде, ә кияүгә Әнсарга чыкты. Юк, юк, аның башка чарасы юк иде. Дөрес, Яббарның күңелендә бераз үпкә бар, ләкин ул әйтә торган, белдерә торган үпкә түгел. Фатыйма аның сугыштан соң төрмәләрдә утырып чыгуын көтәргә тиешмени? Моңа туганнары, авылдашлары юл куймаслар иде барыбер. Фатыйманың атасы

Нургали сугыштан кайтмады, кайдадыр яу кырында ятып калды. Абыйсы Кыям сугыш вакытында трудармиядә хезмәт иткән, мәетләр күмеп йөри-йөри сәерләнеп, холкы нык үзгәреп кайтты. Шуңа да карамастан Яббарга карата җылы хисләр саклый Фатыйма – күзләреннән, тавышыннан күренеп тора. Инде алар икесе дә нык үзгәргәннәр, алар инде яшь чактагы Фатыйма һәм Яббар түгелләр. Ә шулай да җанга якын кеше булып калган икән Фатыйма. Яшь чакта бер төрле чибәр иде, хәзер исә бөтенләй башка төрле гүзәл ул – карап туйгысыз, тора-тора гашыйк булырлык хатын-кызга әйләнгән.

– Рәхмәт сиңа җылы сүзең өчен, – диде Яббар. – Рәхмәт сиңа барысы өчен дә. Рәхмәт сиңа. Минем моңарчы яшәгән гомеремнең иң якты, рәхәт чагы синең белән инеш буйларында йөргән көннәрем булган. Рәхмәт сиңа, Фатыйма, шул гүзәл хатирәләр өчен. Бәлки, мин хәзер шул синең белән бергә чактагы бәхетле мизгелләрем ярдәмендә генә яши аламдыр…

Коридор башында аяк тавышлары ишетелде. Кыяфәтеннән түрәләргә хас олысымаклык һәм вәкарьлек бөркелеп торган берәү, зур-зур адымнар белән атлап коридор башыннан өченче ишекне киереп ачты.

– Әнә Әнсар да кайтып җитте. – Фатыйманың тавышында каушау ишетелде. – Бар.

Фатыйма коридорның икенче башына юл алды, Яббар Әнсар кереп киткән ишеккә таба юнәлде.

26

Каты яраланып госпитальдә дәваланганнан соң, Әнсар үзен кире фронтка җибәрүләрен үтенде. Әмма аны фронтка җибәрү мөмкин түгел диделәр. Аңа Гомельдәге фильтрация лагеренең саклау гарнизонында взвод командиры вазифасын тәкъдим иттеләр. Әнсар ризалык бирде, чөнки күкрәгендә алынмый калган кыйпылчык торымнан торымга үзен белгертеп тора, фронтта дәваланырга мөмкинлек булмаячак, ә монда лагерьда ичмаса хәл алырлык һәм, ниһаять, мондагы эш тә гаять җаваплы, үзеңнең кирәклегеңне, читкә тибелмәгәнеңне тоячаксың.

Лагерьның киң, ләкин шыксыз, һәрвакыт әле тегеннән, әле моннан ишетелгән шомлы, куркыныч авазлары яңгырап торган ишегалдында Әнсар сыек кына томанлы көннең күкрәкне кысып бимазалавыннан котылыр өчен нишләргә белми әкрен генә арыбире йөренеп торды. Бүген ул иртәнге разводны да көч-хәл белән уздырды, көн агымында эшләнәсе эшләренең барысын да үзенең урынбасарына тапшырып, лагерь начальнигыннан бераз ял итәргә рөхсәт алды.

Хәзер шушылай гомер буе интегер микәнни ул? Ул кыйпылчыкны каезлап алсалар, йөрәккә зыян килер иде микәнни? Берәр әһәмиятле тамырлар киселер иде микәнни? Операцияләрдән соң

хирургтан төпченеп карады ул, әмма теге бер сүз дә әйтмәде – караңгы чырайлы, бер сүз дәшми торган хирург иде ул. Әллә телсез булды микән? Ярар, аякка бастырганы өчен рәхмәт инде. Монда җыйналган дезертирлар, сатлыкҗаннар, легионерлар, оккупациядә дошманга хезмәт иткән кешеләр белән аралашу, аларны көн саен күрү шулай ук Әнсарның ярасына уңай тәэсир итми. Кем генә юк бит монда. Менә бер тәбәнәк кенә буйлы, ябык, ләкин күренеп тора, кайчандыр таза, тыгыз гәүдәле булган урта яшьләрдәге берәүне ике конвоир тикшерүчеләр утыра торган бинага таба алып баралар. Чыраеннан ук «изменник» икәне күренеп тора. Кем икән ул? Моның күкрәгендә кыйпылчык юктыр. Үлем җәзасына хөкем итмәсәләр, ул, мөгаен, үз срогын утырып чыгар, исән калыр. Әнсарныкына караганда яхшырак түгелме соң бу сатлыкҗанның хәле? Ничек яхшырак булсын инде! Моның хәлендә калырга язмасын!

Әнә следовательдән берәүне алып чыгып киләләр. Шыр сөякле, битен сакал-мыек баскан, бераз аксый. Конвоирларның берсе аңа нәрсәдер әйтте, шуннан соң тоткын, авырлык белән булса да, кызурак атлый башлады. Әнсарга сак астындагы бу өрәк таныш кебек тоелды. Яннан үткәндә, ул, күкрәгенең кысуын да онытып, кычкырып эндәште:

– Яббар!

Тоткын гына түгел, конвоирлар да сискәнеп куйдылар.

– Яббар, синме бу? – диде Әнсар, якынрак килеп.

– Мин бу, – диде тоткын.

Конвоирлар – икесе дә яшь солдатлар – начальниклары каршында үрә катып бастылар. Тоткынны баракка үзем озатып куярмын дип, Әнсар конвоирларга казармага барырга боерды. Тегеләр честь биреп китеп бардылар.

Ике авылдаш, ике күрше, ике көндәш туган яктан еракта, караңгы, салкын, шыксыз лагерь уртасында, һәр икесе үз күзләренә ышанмыйча бер-берсенә карап тордылар.

– Нинди җинаять кылдың соң син? – дип сорады Әнсар.

– Әсир төшкәч, легионга кердем.

Әнсар Фатыймага фронттан әллә ничә тапкыр хат язып карады, әмма бер генә җавап та килмәде. Фатыйманың Яббарны яратуын сугышка кадәр үк белсә, аларның хат алышулары турында исә анасы язган хаттан мәгълүм иде аңа. Менә бит ничек ул дөнья – хәзер көндәше аның каршысында аяныч хәлдә, чарасыз халәттә, куркыныч кыяфәттә кукраеп басып тора. Әнсарның күңелендә шатлык елтырап алгандай булды, көндәшенең мескенлеген күреп сөенеч хисе тойды шикелле. Тик шулай да күршесен монда, мондый хәлдә очрату Әнсарны нык тетрәндерде.

Яббарның өзек-өзек сөйләгәнен тыңлаганнан соң, ул, үзе дә сизмәстән:

– Фатыйма беләме? – дип сорады.

Бу сораудан Яббарның башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте:

– Әйтә алмыйм.

– Ничәнче баракта син?

– Дүртенчедә. Тәмәкең бармы?

– Син тартмый идең бит.

– Хәзер тартам.

Әнсар бер кап папирос чыгарып Яббарга бирде:

– Кабы белән ал.

– Рәхмәт.

Әнсар Яббарны җылырак баракка – өченчегә күчерүләрен кайгырттты. Аның үтенечен шул көнне үк үтәделәр.

Ул үзе лагерь территориясендәге офицерлар өчен махсус корылган аерым-аерым бүлмәле бинада яши иде. Яббарны очратканнан соң, ул бүлмәсенә кайтып ятты. Күз алдыннан Яббар китмәде. Авылда берәрсе белә микән?

Ул тумбочкасыннан бер буханка ипи, ике пачка махорка алып гәҗиткә төрде дә өченче баракка китте. Бер яктан, Яббарның фаҗигасе аңлатып булмаслык канәгатьләнү тудырса, икенче яктан, ничек булса да авылдашына ярдәм итәсе килде аның. Яббарны чакыртып ипи белән махорканы биргәч, ул аңа допросларда үзен ничек тотарга, сорауларга ни дип җавап бирергә кирәк икәнне аңлатмакчы иде. Тикшерү бүлегенең начальник урынбасары майор Слепцовның бу тарафка килүен күргәч, Әнсар Яббарга тизрәк баракка кереп китәргә кушты һәм үзе майорга таба атлады.

– Кем белән сөйләштең син? – дип кызыксынды майор.

– Иптәш майор, ышанырлык түгел, авылдашымны, күршемне очраттым. Әле аның белән бер кызны бүлешә алмыйча сугышып йөргән идек. Һич башыма сыймый.

– Дезертирмы?

– Легионер.

– Нәрсә бирдең син аңа?

– Ипи белән махорка. Иптәш майор, бик кызгандым, ни дисәң дә бергә үстек бит, сугыша-сугыша булса да.

– Син күпне күргән, орденлы офицер, ә үзеңне куркыныч астына куясың. Мин сиңа моннан ары аның белән очрашмаска, сөйләшмәскә киңәш итәм. Сугыш бара, иптәш өлкән лейтенант... Ә ул – изменник...

Майор китеп барды. Әнсарга һава җитми башлады, ул шинеленең өске сәдәпләрен ычкындырды, көзге дымлы һава белән күкрәген тутырырга тырышып авыр һәм тирән иттереп сулады.

Шуннан соң Әнсар Яббарны читтән генә берничә тапкыр конвоирлар сагы астында допроска барганда, аннары себерке белән барак алдын себергәндә күргәне булды. Инде бүтән авылдашы белән якыннан аралашырга ул җөрьәт итмәде.

27

Фильтрация лагерендагы очрашу хәтердә аермачык булып уелып калды. Мөгаен, мәңгегәдер. Инде күпме вакыт узды, ә шулай да әле кичә генә булган кебек ул вакыйгалар...

Менә хәзер сугыш та юк, кан да коелмый, кешеләр төзелешләрдә эшлиләр, иген игәләр, нефть чыгаралар. Ник кирәк булган ул коточкыч сугыш? Кешеләрне, халыкларны канга батырыр өченме, әллә аерым кешеләрне сынар өченме?..

Нишләп тиз генә арада тыкрык аша күршеләр булган Әнсар һәм Яббарның язмышлары шулкадәр төрле-төрле килеп чыкты соң?

Әнсар – сугыш ветераны, каһарман, райком секретаре.

Ә Яббар? Аның да яраткан эше, гаиләсе бар, ата-анасы исән, ләкин җан тынычлыгы инде мәңгегә җуелган.

Яббар авылдашы кереп киткән ишекне ачты. Әнсар әле үзенең кабинетына кермәгән, кабул итү бүлмәсендә секретарь кыз машинкада баскан кәгазьләрне укып тора иде.

Яббар, килеп керү белән үк:

– Исәнмесез! – дип эндәште.

Әнсар әкрен генә борылып, мәгърурлык белән җавап бирде:

– Исәнмесез!

Ул Яббарны әллә танымыйча, әллә танымаган булып кыланып беравык карап торды.

Яббар якынрак килде:

– Әнсар Хәлиуллович! Исәнмесез!

– Исәнме, Яббар! Мин сине танымый торам. Фатыйма белән сөйләшеп торучы син идеңмени ул?

Яббар югалыбрак калды, ләкин дөресен әйтергә кирәк иде.

– Әйе, коридорда очраштык.

– Нишләп йөрисең?

– Мин сезнең янга дип килгәнием... Кабул итсәгез иде... Хәзер кабул италмасагыз, бәлки, башка көнне мөмкин булыр.

– Минем хәзер вакытым бар, мин сине кабул итәм, – диде Әнсар. Аннары, кулындагы кәгазьне өстәлгә куеп, секретарьга мөрәҗәгать итте: – Моны тагын бер нөсхә бас.

Әнсарның эш кабинетына кергәч, Яббар сүзне нидән башларга белми югалып утырды. Әнсар да үзенең түрдәге урынында түземлек белән авылдашын тыңларга әзер торды.

– Менә килдем әле, – диде Яббар, каушанкырап.

Әнсар беравык Яббарны җентекләп күзәтеп утырды.

– Күптә-ә-ә-ән күргән юк сине, – диде ул һәм графиннан стаканга салып су йотып куйды. – Кызылъярга да кайтмыйсың бугай хәзер?

– Кайткалыйм, – диде Яббар.

– Без атна саен кайтып йөрибез, сине бер дә күргән юк, шуңа әйтәм. Ничек соң хәл-әхвәлләрең?

– Бер көе.

– Алай икән, алай икән. Монда ни йомышлар белән килеп чыктың?

Яббар монда килүенең сәбәбен аңлатырга тотынды:

– Идел суының болай күтәреләчәген ГЭСны проектлаучылар үзләре дә алдан белмәгәннәрдер, мөгаен... Бәлки, белгәннәрдер...

Әнсар авылдашының ГЭС хакында сүз башлавыннан аптырабрак китте:

– Шуннан?

– Куйбышев сусаклагычы әле бик нык киңәячәк. Су тагын да күтәрелгәч әле хәтта Каманың түбән өлеше дә киңәеп күмеләчәк. Күпме җир, күпме болыннар су астында калачак. Авылларга су астында калу яный.

– Ярар, арттырма инде, – диде Әнсар, көлемсерәп.

– Инде шактый авылларны су басып китте. Кайберләре күчеп өлгерде. Җитешә алмыйча су астында калганнары да байтак.

– Шуннан?

– Су һаман күтәреләчәк.

– Водохранилище булгач, күтәрелер инде ул, – диде Әнсар, бер дә исе китмичә.

– Безнең авылга да куркыныч яный, – диде Яббар шөбһәле тавыш белән. – Кичекмәстән нәрсәдер эшләргә кирәк.

– Нәрсә эшләргә кирәк?

– Күченү ягын уйлау мәслихәт.

Әнсар тагын су эчеп куйды.

– Өстән кушмыйча без бит бернәрсә дә эшли алмыйбыз, – диде Әнсар. – Куйбышев водохранилищесы хакында обкомда сүз кузгаттылар. Кайбер авылларны калкулыккарак күчерү күздә тотыла. Су баса башласа, өстән кушарлар, күчерәсе авылларны күчерербез, бер дә кайгырма.

– Ә зиратны? – диде Яббар шомлы тавыш белән.

– Безнең авыл зиратын әйтәсеңме?

– Әйе. Зиратны күчерү турында хәзер үк уйларга кирәк, аны күчерү авылны күчерүдән дә авыррак булмагае. Каберләрне казып, ташып яңадан күмү йортларны сүтеп яңа җирдә төзүгә караганда катлаулырак булачак. Мисаллар күп.

Әнсар кул селтәп урындыгында киерелебрәк утырды:

– Син монда коткы чәчеп утырма әле. Бәлки, су безгә кадәр менеп җитмәс.

Яббар гасабилана башлады:

– Мин үзем күреп йөргән бик күп авыллар, зиратлар, кырлар, болыннар су астында калды. Күтәрелә су, күтәрелә! Әйтәм бит, хәтта Каманың да суы күтәреләчәк, Камага да тулачак су – югары агымына таба берничә йөз километрга кадәр. Шулай булгач, Иделнең ничек киңәячәген күз алдыңа китер.

Әнсарның да эче поша башлады, ләкин аңлашылмады – әл-

лә Яббарның көтмәгәндә вакытсыз килеп шундый проблема күтәргәненнәнме, әллә чыннан да сусаклагычның күтәреләчәгеннәнме.

– Су басуы ихтимал дип хәзер зиратны актара башлыйкмы?! – диде ул, күзләрен челәйтеп.

– Ә каберләр су астында калса?! Мин тикмәгә килмәдем. Мине ничек кұралмаганыңны белә торып, юк-бар мәсьәлә белән монда килер идеммени мин! Авылны, зиратны коткарырга кирәк, әлегә соң түгел!

– Авылларны, зиратларны коткаруны син кайгыртып йөрергә тиеш түгел, – диде Әнсар хакимнәргә хас эрелек белән. – Влач бар, махсус службалар бар. Партия беркемне беркайчан бәлаказада ташламас. Шуны да онытма: мин – партиянең райком секретаре, мин райисполком рәисе түгел.

– Барыбер сез хакимлек итәсез, барыбер сез җитәкчеләр, – диде Яббар. – Син бик абруйлы кеше, Әнсар. Зиратны күчерергә бүген үк тотынырга кирәк!

Әнсар, әңгәмәдән туюын күрсәтеп, өстәлендәге кәгазьләрне актара башлады.

– Син җүләрләндең мәллә! – диде ул, кирәкле кәгазен эзләгән булып кыланып.

– Бәлки, җүләрләнгәнмендер, – диде Яббар, кыза башлап. – Чөнки туып үскән җиреңне су баса башласа, чынлап та акылдан язарга мөмкин. Безнең туган җиребез, балачагыбыз узган, ерак бабаларыбыз иген үстергән тарафлар су астында калачак, аңлыйсыңмы?! Зират та су астында калса, безне бабаларыбызның рухлары кичермәс!

Әнсарның йөзенә ачу чыкты:

– Ерак бабаларыбызның рухлары турында син уйларга тиешме?!

Яббарның бите агарып китте:

– Нишләп мин уйламаска тиеш?!

Әнсарның гәүдәсе киеренкелектән калкыбрак киткәндәй булды:

– Хакың бар дип уйлыйсыңмы?

– Бар! – диде Яббар, тавышын күтәреп.

Әнсар авызын кыйшайтып көлемсерәде:

– Син онытылып киттең түгелме?

Яббар сикереп торды:

– Юк, онытылмадым! Нәрсәгә төрттергәнеңне аңлыйм. Онытылмадым! Һәм үз акылымда мин. Легионер киемен киеп фронтның бу ягына үрмәләп чыгуым да туган җиремне сагынганнан, туган ягымны күрәсе килүдән булды. Туган якның һәрбер сукмагын, һәрбер агачын, әрәмәсен, су буйларын бүтән беркайчан да күрмәм дип курыкканга дошман киемен кидем мин. Туган җиремә кайтып егылыр өчен беренче мөмкинлектә үк үзебезнекеләр ягына качкан кеше мин. Изменник дип ата, сатлыкҗан диген, легионер дип әйт, предатель диген, халык дошманы дип ата, ләкин ки-

чекмәстән авылны, зиратыбызны коткар! Син – райком секретаре. Син – зур кеше, сүземә колак сал! Мин бит үзем өчен генә сорамыйм. Зинһар, зиратны су астында калдырмагыз!

– Әле бернинди куркыныч янамаган килеш нишләп бу кадәре ачыргаланасың син?!

– Чөнки мин беләм, үзем күрдем, – диде Яббар, өзгәләнеп. – Инде Иделнең аскырак өлешендә күпме җирне су басканны үз күзләрем белән күрдем. Су һаман күтәрелә, әле тагын бер ел яки ел ярым чамасы суның артуы дәвам итәчәк.

Әнсар шактый вакыт дәшми утырды. Өстәлендәге телефон шылтыравына да игътибар итмәде. Яббарның урыныннан кузгалырга ниятләвен сизенеп, ул әкрен генә тавыш белән әйтеп куйды:

– Шушылай җан атып йөргәч, син үзеңне реабилитацияләрләр дип өметләнәсеңме әллә?

Яббар мондый сүзне ишетермен дип уйламаган иде, ул беравык тораташ булып катып, телсез калды.

– Аңламадым?.. – диде ул, әкрен генә торып.

– Алай усал карама миңа, – диде Әнсар, авызын кыйшайтып.

Яббар кире урынына утырды:

– Мине дошман ит, ләкин сүземә колак сал.

– Әле болай өзгәләнеп йөргәнеңә үкенерсең.

– Ник алай уйлыйсың?

– Чөнки сиңа ярлыкау беркайчан да булмаячак!

– Юк, Әнсар, үкенмәм, – диде Яббар, башын чайкап. – Мин бер генә нәрсәгә үкенәм.

– Нәрсәгә үкенәсең?

Яббар торып кискен хәрәкәтләр белән урындыкны читкә алып куйды:

– Теге фильтрация лагеренда синнән бер буханка ипи белән махорка алганыма үкенәм.

Әнсар, урыныннан торып, дошманнарча явыз караш белән авылдашына текәлде:

– Син үзеңнең пычрак биографияң белән ничек партия райкомына керергә җөрьәт иттең?!

Яббардан да нәфрәт бөркелде:

– Синең туган җиреңне шушы арада су басачак, синең туган ягың су астында калачак, ә син – партия, райком...

– Но-но! Кайда икәнеңне онытма! – дип җикерде Әнсар. – Үзеңнең кем икәнеңне һәрвакыт исеңдә тот!

Яббар түземлеген җуеп кычкырып җибәрде:

– Монда кергәнемә дә үкенермен, ахрысы!

Әнсарның чырае кинәт кып-кызыл булды, ярсудан аның хәтта куллары калтырана башлады.

– Күземнән югал, изменник Родины! – дип ысылдады ул.

Яббарның гәүдәсе кечерәеп калгандай булды.

– Мин изменник түгел! – диде ул буйсынулы тавыш белән.

– Алайса ник бөрештең? – диде Әнсар, тешләрен кысып. – Нинди оешмага килеп кергәнең акылыңа яңа гына барып җитте бугай. Инде хәзер үк үкенәсеңдер монда кергәнеңә, шулаймы?!

Яббар калтыранган кулы белән Әнсарның өстәлендәге графинны алды, кырыйга түгә-түгә стаканга су салды.

– Үкенәм, – диде ул, кулындагы сулы стаканга карап. – Үкенәм. Мин сатлыкҗан түгел! Мин беркайчан предатель булмадым! – Шуннан соң ул муенындагы кан тамырларын бүрттереп үкерде: – Мин беркемне, бернәрсәне сатмадым! Мин изменник түгел!

Яббар суны эчмәде, кулындагы стаканны өстәлгә куймакчы булды, әмма... Ник кирәк булды, нинди көч аны этәрде, нишләп үзен тыя алмады соң ул?! Стакандагы суны ул, көтмәгәндә, хәтта үзе дә сизмәстән, Әнсарның битенә сипте.

Әнсар гаҗәеп тынычлык белән чалбар кесәсеннән кульъяулыгын алып битен сөртте.

Стакан Яббарның кулыннан идәнгә төшеп чәлпәрәмә килде.

28

Судка туганнардан Сәет кенә барды.

Кайткач, ул суд утырышы турында башыннан ахырына кадәр бәйнә-бәйнә сөйләде.

– Нәрсә өчен дүрт елга хөкем иттеләр соң аны? – диде Әминә, еламсырап.

– Партия райкомына кергәне өчен! – диде Нәгыйм, карчыгына усал караш ташлап.

– Ник, ул бит анда начар ният белән кермәгән.

Нәгыйм башын салындырып чайкап куйды:

– Райкомга кереп аза кубарга ярыймы соң инде аңа!

– Судта да ул үзен дөрес тотмады, – диде Сәет. – Партияне сүкте, җитәкчеләрне сүкте, үзе эшләгән ГЭСтагы гаделсезлекләрне сүкте. «За измену Родине» утырып чыккан кеше судта шундый нәрсәләр сөйләгәч, ничек инде дүрт ел бирмәсеннәр! Әле ничек күбрәк бирмәделәр.

– Әнсарның битенә су сипкән өчен шулай күп биргәннәрдер дип уйлыйм мин, – диде Нәгыйм.

– Юк, Әнсар бөтенләй әйтмәде ул турыда. Киресенчә, ул Яббарны каты җәзага тартмауларын сорады. Яббарның Волжский ГЭСы, Куйбышев водохранилищесы безнең җирләргә зыян китерә дип әйтүен төп җинаяте дип таныдылар.

– Аның алай дип әйтүләрен шул Әнсар сөйләгәндер бит инде судта?

– Әнсар судта аны гаепләрлек итеп сүз әйтмәде. Әнсар сөйләмәсә дә, әллә син райкомда аларның сөйләшкәннәрен тыңлаучы

булмаган дисеңме?! Анда яшертен генә тыңлый торган нәмәрсәләре юк дисеңме әллә?!

Әминә елап җибәрде:

– Әй, балакаем, тагын харап иттеләр бит үзеңне.

– Үзе гаепле! – диде Нәгыйм. – Судимостең була торып рәзе райкомга барып керәләр!

Кинәт Әминәдән моңарчы аңа хас булмаган ачулы көр тавыш чыкты:

– Ул синең балаң! Гел битәрләргә, ачуланырга торасың! Илленче елдан бирле, лагерьдан кайтканнан бирле синең аңа бер генә дә җылы сүз әйткәнең булмады. Нишләсә дә, ялгышса да, абынса да, бәлага дучар булса да, ул – синең балаң. Алайга калса, аның язмышында синең дә гаебең бар!

– Нинди гаебем бар минем? – дип гаҗәпләнде Нәгыйм, карчыгының җикерүенә шаккатып. – Нәрсә, начар тәрбия бирдемме мин аңа, әшәкелеккә өйрәттемме?!

Әминә бер ноктага текәлеп уйга калды:

– Гаиләсе нишләр инде хәзер...

– Әнкәй, барыбер кайчан да булса белер идегез, анысын да әйтәм инде, – диде Сәет, әнкәсенә туры карамаска тырышып. – Яббарның хатыны судтан соң әйтте: разводка бирәм, диде. Төрмәгә утырганы өчен генә түгел, моңарчы яшәвебез гомумән бик авыр булды, алга таба да бергә барыбер рәтле тормыш күрмәячәкбез, диде.

– Үзенең сөйләве буенча, әйбәт кенә яшәп яталар шикелле иде бит, – диде Әминә, сыктанып.

– Сине кат-кат кайгырттырмас өчен генә әйбәт яшибез дип әйтә торган булгандыр инде ул, – диде Сәет.

Нәгыйм улының сүзенә баш какты:

– Әйбәт яшәсәләр, ичмаса, бер тапкыр гына булса да хатынын авылга алып кайткан булыр иде.

Әминәнең исә үз фикере бар иде:

– Авылга алып кайтмавының сәбәбе башкада, ул миңа бу хакта аңлатты. Авыл кешеләре хатынына авыр сүз әйтерләр дә тормышның рәте китәр дип уйлады ул.

– Бигрәк ышанучан кеше син, әнкәй, – диде Сәет, ачуланып. – Шулай тиз генә разводка бирәсе иткәч, чыннан да, яшәүләренең рәте булмагандыр.

– Аллага тапшырдык инде, – диде Әминә, тирән сулап.

Нәгыйм борын астына мыгырдап куйды:

– Гел кешеләрдән куркып, як-якка каранып, үзендә гаеп тоеп, газап кичереп яшәгән ир белән нинди хатын торсын!

– Разводка биргән икән, ярар! – диде Әминә, кинәт тагын тавышын күтәреп. – Минем улым исән булсын, Ходай ярдәменнән ташламасын берүк балакаемны!

Сәетнең, башын читкә борып:

– Хурлык өстенә хурлык өстәп кенә тора кече улың, – диюе ананы нык кайнарлатты.

– Син бүтән миңа андый сүз әйтмә! – диде Әминә нәфрәт белән. – Син ул күргәннәрне күрмәдең, гәрчә яшькә олырак булсаң да. Башкайларыңа ул күргәннәр берүк төшә күрмәсен! Бала чагыгызны онытгыңмыни? Ничек ярата иде ул сине – абый дип кенә тора иде. Нишләп шушы кадәр каты бәгырьлеләндең син, Сәет, улым?! Шушы хәтле атаңа охшасаң да охшарсың икән!

– Кешеләр арасында яшибез бит, әнкәй.

– Авылларны, зиратларны су басудан коткарырга кирәк дип килгән кешене төрмәгә утыртырга кирәк микәнни?! – дип елап җибәрде Әминә.

Нәгыйм һаман үзенекен тукыды:

– Аның игелекле уй-ниятләр белән йөрүенә кем ышансын! Райкомга кермәскә иде аңа!

Кайнар бәхәс шаукымы белән Хәлиулланың килеп керүен сизми дә калдылар.

– Керергә мөмкинме? – дигән булды ул, инде кереп ишекне япкач.

– Әйдә, әйдә, күрше, – дигән булды гел вакытсыз һәм кирәкмәгән чакта килеп керә торган күршесен өнәмәгән Нәгыйм.

Хәлиулла ясалма ягымлылык белән исәнләште дә ишек катындагы урындыкка утырды.

– Шулай диген, ә, – дип башлады ул сүзен. – Әнсар аны төрмәгә утыртуга каршы булды, шуны әйтергә кердем мин.

– Беләбез, күрше, беләбез, – диде Нәгыйм. – Рәхмәт. Язмыштан узмыш юк дип хак әйтәләр.

Башка сөйләшер сүз булмаганлыктан, тынлык урнашты. Хәлиулла тәрәзә янында бер хәрәкәтсез утыручы Әминәгә эндәште:

– Ни... Әминә, син безнең белән сөйләшмисең соңгы вакытта.

Әминә, күз яшьләрен яулык чите белән сөртеп, Хәлиуллага таба борылды:

– Нәрсә турында сөйләшергә тиеш мин? – диде ул, күршесенә беравык карап торганнан соң.

– Элек Зәкия белән гел аралаша идегез бит.

Әминә, тәрәзәдән тышка карап:

– Сезнең улыгыз райком секретаре, минеке – кәтерҗән! – диде. – Ни турында сөйләшим мин сезнең белән?!

– Әнкәй, син инде бөтен кеше белән дә алай дорфа сөйләшмә, – диде Сәет.

– Мине дә төрмәгә утыртырлармы әллә?! – диде Әминә, улына усал карап.

– Карчык! – дип җикерде аңа Нәгыйм.

– Тик кенә утыр! – дип каршы әйтте Әминә иренә. – Йөрәгең авырта икән, тыныңны да чыгармыйча утыр! Синдә генә йөрәк!

Хәлиулла урыныннан кузгалды:

– Ярый, чыгыйм әле мин.

– Күрше, утыр әле, утыр, – диде Нәгыйм, күршесе алай-болай

үпкәләмәгәе дип. – Тагын берәр йомышың яки әйтер сүзең бар идеме әллә?

– Бар иде шул, – диде Хәлиулла, кире урынына утырып.

Шул вакытны алҗып, әлсерәп Нәсимә кайтып керде.

– Уф, кайтып җиттем микәнни! – диде ул, ишек яңагына сөялеп. Шуннан соң гына: – Исәнме, Хәлиулла абый, – диде.

– Аллага шөкер, Нәсимә, исәнме. Каян кайттың болай?

– Ронодан.

– Ник барган идең?

– Әй, безне яңа уку елы алдыннан шулай җыялар бит инде. – Ул, Сәеткә карап, ничегрәк итеп әйтим икән дип, бермәл уйланып торды. – Район үзәгендәге мәктәпкә эшкә чакыралар.

Сәет хатынының бу яңалыгына ничек тәэсирләнергә дә белмәде:

– Син нәрсә дидең?

– Синең белән киңәшләшмичә нәрсә диим мин! Уйлашырбыз, дидем.

Хәлиулла күрше киленең бу хәбәрен хуп күрде:

– Ник, район үзәге район үзәге инде ул. Ризалык бирергә кирәктер, минемчә.

– Тагынниләр бар районда? – дип кызыксынды Нәгыйм.

– Ронода ишеттем: тиздән бу тирәне су басачак, ди. Безнең авылның да су астында калуы ихтимал икән. Иреңә кайтып әйт, тиздән монда юньле эш табып булмаячак, су баскач, бик күп авыл халкы район үзәгенә китәчәк, диделәр. Шуңа күрә район үзәгендәге мәктәпкә сөенә-сөенә күч, диделәр.

– Алар әле безнең энекәшебез барлыкны белмиләрдер, – дип мыгырдады Сәет.

Нәгыйм, күршесе янында Яббар турында сөйләшергә теләмичә, тизрәк сорап куйды:

– Су басачагы дөрес микән әллә?

– Мин дә шул хакта сөйләшергә кергәнием ләбаса, – диде Хәлиулла. – Мин дә ишеттем. Күрше авылның персидәтеле әйтте. Утсыз төтен булмый. Димәк, монда да су киләчәк. Имеш, безгә калкурак урында, Аулаш тавы итәгендә яңа йортлар төзеп бирәчәкләр. Кыскасы, яңа авыл салып, безне шунда күчерәчәкләр... Алай-болай су баса калса инде...

– И Ходаем, тагын ниләр күрергә язган икән, – дип ыңгырашты Әминә.

– Теге вакытта кайтканында Әнсар бу турыда бер сүз дә әйтмәгәние, менә шимбә көнне тагын кайта, төпченермен әле, – диде Хәлиулла.

Нәгыймнең ышанасы килмәде:

– Безнең авыл – борынгы Кызылъяр – үз урыныннан күчәр микәнни?

Хәлиулланың тавышында өмет яңгырады:

– Аулаш тавы итәгенә на всякий ыслучай гына йортлар сала-

чаклар, ди. Әле без әбизәтелне күчәчәкбез дигән хәбәр ишетелмәде.

– Ә алай-болай су басмаса, Аулаш тавына салынган авылны нишләтерләр? – дип уйга калды Сәет.

– Һи-и-и, анысы өчен бер дә борчылма, – дип кул селтәде Хәлиулла. – Кулланыш табарлар. Булган нәрсә тик ятмас.

Төрле фаразлар белән киләчәкне күзаллап, тормышның катлаулыгыннан зарланып, кеше гомерендәге авырлыклар турында гәпләшеп шактый вакыт сөйләшеп утырганнан соң, Хәлиулла чыгып китте.

29

1956 елның көзендә Яббарның хатыны Роза, бер яшьлек улын күтәреп, Кызылъяр авылына килде. Яббарның туганнары белән никахтан соң аның очрашканы булмады, Кызылъярга исә аның бу беренче мәртәбә килүе иде.

Авыл башында Нәгыймнәр йортын сорау белән үк аңа бер агай: «Теге, малае предатель Нәгыймнәрме?» – дигәч, Розаның, баласын кочаклаган килеш, ачык кырга йөгерәсе килде.

Авылның урамнары кисешкән үзәккә җиткәч, ун-унике яшьлек бер кыз аңа теләр-теләмәс кенә Нәгыймнәр йортын ничек табарга икәнне аңлатты.

Яббарның улын Нәгыймнәр йортында ничек кабул итеп, ничек яратканнарын күргәч, Роза хәтта монда килмәгәненә үкенеп тә куйды – шулкадәре җан җылысы, шулкадәре мәхәббәт белән кулдан-кулга йөрттеләр Вәсимне. Йөрәгенең ярсуын көчкә тыеп утырды Роза. Шулай да түзмәде, берничә тапкыр тып-тын гына елап алды. Сәет белән Нәсимә дә үз балаларыдай яратып карадылар Вәсимгә. Балалары булмау сәбәпле, алар өчен бигрәк тетрәндергеч вакыйга булды бу. Вәсим тач Яббар иде, баланың атасына охшаганлыгы барысын да таң калдырды.

Малайны сөеп, аны бәһасез хәзинә урынына кулдан-кулга йөрткәннән соң, Роза үзенең килүенең сәбәбен, ниһаять, әйтергә җөрьәт итте.

Ул барысыннан да гафу үтенде, Яббарның әйбәт кеше икәнлеген сөйләде. Аннары кыяр-кыймас кына: «Яббарны көтә алмам инде», – диде. Баланы алып Куйбышевка, ата-анасы янына кайтып китәчәген әйтте. Төрмәдән кайткач, Яббарга улын килеп күреп йөрергә рөхсәт булачак, диде. Соңрак, түзмәде, Яббарның Вәсимне ничек нык яратуын да сөйләп бирде.

Розаның бу хәбәреннән соң бик озак тып-тын гына утырдылар.

Берсе дә ашыкма, туктале, башта тынычлан, уйла, бәлки, көтәрсең димәде.

...Розаны баласы белән, МТСтан машина сорап алып, Сәет илтә китте.

Ул икенче көнне генә кайтты – кире кайтканда, юлда машина ватылган. Төне буе Нәгыймнәр йортында ут сүнмәде, Сәетне борчылып көтеп утырдылар.

Сәет кайту белән үк, Нәсимә:

– Вәсимне монда Кызылъярда калдырырга иде, үзебез үстерер идек, – диде.

Әминә сискәнеп китте:

– Мин үзем дә шуны уйлап утырдым. И Нәсимә, ник моны Роза монда чакта әйтмәдең?

Нәгыйм үзенең икеле-микеле фикерен әйтте:

– Оныгыбызны монда калдыру әйбәт булыр иде дә... Ләкин авылда аны изменник малае дип кагарлар иде.

– Әти дөрес әйтә, – диде Сәет. – Үсә төшкәч, Вәсим үзе монда килеп йөрер. Җаен табарбыз. Тора-бара Яббарга да халыкның мөгамәләсе үзгәрер, бәлки.

30

Яббарның кайгысы Әминәне кинәт аяктан екты. Сәет аны врачларга йөртеп карады, ләкин диагнозны әле тегеләй, әле болай куеп, төгәл һәм дөрес дәвалый алмадылар.

1956 елның кышына кергәндә, Әминә инде урын өстендә ята, хәтта намаз да укый алмаслык хәлдә иде.

Декабрь азагының ачы җилле, үтеп чыккысыз буранлы киндә ул үзенең янына өйдәгеләрне чакырды.

– Төрмәдән чыккач Яббар барыбер монда кайтачак, – диде ул, иреннәрен чак кына кыймылдатып. – Туган ягына кайтачак ул барыбер. Минем сезгә бер генә сүзем бар. Яббарны какмагыз. Әгәр сез алга таба да аны рәнҗетсәгез, минем җаным тынгылык тапмас. Әгәр сез минем улымны һаман да бимазаласагыз, туфрагым күтәргесез авыр булачак.

Аның бу сүзләреннән Нәсимә кычкырып елап җибәрде һәм авызын томалап тизрәк кече якка чыгып качты.

Сәет, башын салындырып:

– Ярар, әнкәй, борчылма, – диде. – Тынычлан. Теләгеңне үтәрбез.

Шул мәлдә Нәгыйм, гомер буена күпме авыр сүз әйтеп, күпме кырысланып карчыгын рәнҗеткәненә үкенде, хәтта шашар дәрәҗәгә җитте. Бу дөньядан китеп баручы изге җанны кочагына алып бернинди үлемгә бирмәскә иде! Юк, Нәгыймнең хәленнән килми бу. Гомер буена берәр тапкыр җылы сүз әйткәне булды микән карчыгына? Күкрәк гадәттәгедән катырак кысылды, ләкин бу юлы Нәгыйм барып дару эчәргә тотынмады. Газиз карчыгы урынына үзенең үләсе килде аның.

...Әминәне җирләп кайткан кичне Нәгыйм аңлады – аның җаны күкләргә ашкач, йорт та җансыз калды.

– Берүк зиратны су баса күрмәсен инде, – дип аваз салды ул бөтенләй бушап калган өйдә. – Чынлап та су күтәрелә калса, иң алдан зират күмеләчәк. Аллам сакласын!

– Аны авылыбызның зиратында җирләмәскә иде, – диде Нәсимә. – Су биеклеге артачак, дип, тирә-якта инде бөтенесе шаулаша.

– Ничек инде әнкәйне авылның зиратында җирләмичә башка җирдә җирләргә мөмкин! – диде Сәет, ачуланып.

– Ник, аны башка авыл зиратына күмеп була иде бит, – диде Нәсимә. – Ник тыңламадыгыз мине?!

Сәет үзе дә шулайрак уйлаган иде дә, ләкин әнкәсен кайсыдыр читтәге зиратка күмдерәсе килмәде шул.

– Бөтен нәсел-ыруыбыз шул зиратта күмелгән, – диде ул. – Ник күңелгә тагын шөбһә кертеп утырасың инде! – Ул, ярдәм өмет иткәндәй, атасына карап торды. – Әти, син ничек уйлыйсың?

Нәгыйм, аксый-аксый, өй буйлап йөрергә тотынды:

– Мин үзем ничек дияргә дә белмим. Бер караганда, шушы зиратыбызга күмүдән дә дөресе юктыр. Икенче караганда, су баса башласа, хәлләр хөрти. Зиратны күчерү турында уйлау зарур. Хәзер үк, бүген үк!

Сәетнең тавышында каушау сизелде:

– Иң элек белергә кирәк – су чынлап та нык күтәреләчәкме. Болай гына каберләрне актару яхшыга илтмәс.

31

1957 елның язында Кызылъяр авылын Аулаш тавы итәгенә күчерергә күрсәтмә килде. МТСның бөтен техникасы, берничә урман хуҗалыгы, районның барлык балта осталары ашыгыч рәвештә шушы эшкә оештырылды.

Аулаш тавында салына башлаган йортларга беркем дә куанмады, халык су астында калачак туган авыл өчен җан ачысы белән елады. Су астында авыл түгел, әйтерсең лә авылдашларның төп тарихы батып калачак иде. Гүя мәңге кайтарып булмаслык гомерләрнең иң кадерле өлеше югалачак, яшәешнең асылы табылган бер изге урын харап ителәчәк, үткәннәрнең һәм киләчәкнең мәгънәсе мәңгегә гаип булачак иде.

Хәленнән килгәннәр үз йортларын сүтеп яңа төзелүче авылга ташыдылар. Гап-гади авылда кадерле, изге нәрсәләр бихисап күп булган лабаса. Ләкин барысын да күчерерлек түгел иде яңа урынга. Мал-туарны, булган җиһазларны, ата-анадан, әби-бабадан калган истәлекле әйберләрне, вак-төякне яңа авылга ташып булыр да ул... Әмма өянкеләрне, имәннәрне, тупылларны ничек күчерәсең?! Тыкрыкларны, чишмә буйларын, таныш сукмакларны, туган авылның сүз белән генә аңлатып булмаслык чалым-сызыкларын, бакча артларын, читән буендагы кычытканнарын ничек яңа урынга күчермәк кирәк?!

Кызылъяр авылы бомбага тотылган кебек сурәттә иде. Үлем җәзасына дучар ителгән авыл белән Аулаш тавы арасында, тузан туздырып, йөк машиналары, арба таккан тракторлар, арба сөйрәүчеләр, җәяүлеләр тәүлек әйләнә йөреп торды. Җигүле атлар белән, «уфалла» арбаларын тартып, һаман нәрсәдер ташыдылар: араталыклар, такталар, рәшәткәләр, ватык-сынык кирпеч калдыклары, тимер-томыр, савыт-саба, чүпрәк-чапрак... Кайберәүләр үз әйберен генә түгел, нәрсә таба, шуны алып кайта башлады, торабара тыныч вакытта игътибарга ия булмаган чүп-чарга да чират җитте.

...Көзгә, кем ничек булдыра, шулай күченеп беткәннәр иде инде. Дәүләт алга таба да материаллар белән, акчалата, утын ташып, печән бүлеп ярдәм итәргә вәгъдә бирде. Дөрес, акча дигән нәрсәне элек тә күрмәгән халык аны алга таба да дәүләттән ала алмады. Утыны да, печәне дә өлешчә генә бирелде.

Сентябрьнең алтынга төренгән бер таңында Кызылъярның сүтелми калган йортларын, чалыш-чолыш каралты-кураларын, җимерелмичә төзек килеш калган морҗаларын, агачларын су камап алды. Шул ук вакытта авылдан читтәрәк урнашкан зиратны да су чолгады. Моны авылдашлар «яңа» авылдан тагы да өскәрәк – Аулаш тавының югары өлешенә менеп күзәттеләр.

Иң изге урын булып саналган зират, өч йөз хуҗалыклы авылның Югары очы, Түбән очы, Кәрим очы, Бакалы очы, тыкрыклары белән бергә – барысы коточкыч тиз арада мәңгегә күздән югалды.

Мәңгегә хушыгыз!

Авыл су астында калды. Түбән җирдә, уйсу урында иде шул Кызылъяр. Ерактан караганда хәтта чокырланыбрак та тора иде авыл урнашкан урын. Әйтерсең лә яшел бишектә тирбәлә иде ул. Ләкин кемнәр уйлаган аның тәкъдиренә мондый фаҗига язылганын? Ерак бабайлар авыл булып монда урнашкан чакта әллә нинди хәвеф-хәтәрләргә әзер булганнардыр, әмма кайчан да булса Идел үз ярларыннан чыгып авылларны йотар дип һич кенә дә башларына китермәгәннәрдер.

Авыл халкы, белгән догаларын укып, бәлки, авылдан читтәрәк урнашкан зиратны басмас дигән өмет белән суның көннән-көн киңрәк җәйрәгәнен күзәтте. Зиратны күчерү-күчермәү мәсьәләсе буенча каты бәхәсләрдән соң, каберләрне актармыйк дигән нәтиҗәгә килүләре дә, бәлки, су изге урынны читләтеп агар дигән теләк-өметтән булгандыр.

Халык тып-тын гына күзәтте.

Юк, өметләр акланмады.

Кызылъярның зираты да су астында калды. Агачларның ябалдашлары гына, су өстеннән калкып, Аулаш тавына барып сарылган яңа авылга нидер әйтмәкче, аңлатмакчы булып чайкала-чайкала нидер сөйләделәр.

Шулай итеп, кышка Кызылъяр авылы, мәңге сөйләп-елап туй-

мас газап белән, яңа урында салынган яңа йортларга кереп урнашып бетте.

Су өстен боз тоткач, авылның баганалары, таныш өянкеләр, тупыллар, иманнәр, ябалдашлары белән генә калкып, күктән мәрхәмәт сорагандай катып калдылар. Аларның күбесе киләсе язда бөтенләй су астында юкка чыгачаклар әле. Ә хәзер исә әле алар, яңа салынган авылга үпкә вә шелтә юллаган сыман, игътибарны гел үзләренә тартып тордылар.

Шулай итеп, Кызылъяр авылы, җан саклар өчен, Аулаш тавына таба үрмәләде. Авылның тарихы икегә бүленде – су басканчыга кадәр өлешкә һәм су басканнан соңга. Күрше-күлән элеккечә берберсенә якын урнашырга тырышса да, монда инде урамнар сузылуы, йортлар төзелеше бөтенләй башкача иде. Урамнарны элеккечә итеп төзеп булмады, урыны башка, җайсыз иде. Кешеләр исә үзләренең каралты-курасын мөмкин булганча элеккечә итебрәк кабатлап салырга тырыштылар. Хәтта Әнсар да ата-анасының йортын Сәетләр белән күрше иттереп салдырды. Монда араларында тыкрык булмаса да, шул тыкрыклык ара калдырып урнаштылар.

32

Яңа урынга тамыр җәяргә тырышып ятучы авыл халкын кызгангандай, кыш җылы килде.

Җиңел һавалы кышкы көннең берсе иде, Сәет белән Нәсимә аркылы пычкы белән кузлага куеп утын кискәндә, капкадан Әнсар килеп керде.

Исәнләшеп хәл-әхвәлләрне сорашкач, Әнсар затлы тунының төймәләрен ычкындырды, кыйммәтле бүреген калкытыбрак ян кесәдән алган кулъяулык белән маңгай тирен сыпырды.

– Урнашып беттегезме инде? – диде ул, әле һаман төзекләнеп бетмәгән каралты-курага күз йөгертеп.

– Юк әле, – дип җавап бирде Сәет. – Хуҗалыкны һич кенә дә рәткә кертеп бетерә алмыйбыз. Әти каты авырый, аны больнискә йөрттек.

– Ә-ә-ә, алай икән. Хәзер кайда соң ул?

– Ята.

– Кереп хәлен белимме?

– Йокыга киткәние, йокласын инде. Нәсимә, бар, бик тавышланмыйча гына самавырны куй.

– Район үзәгенә күчәсегез килмәде инде алайса? – диде Әнсар, Нәсимә кереп киткәч.

– Юк, калырга булдык, – диде Сәет. – Нигезне сакларга кирәк. Хәер, бу инде хәзер безнең авыл түгел. Исеме Кызылъяр булса да. – Ул каен тумранына утырды, бияләйләрен салып кырыйга куйды. Әнсар янәшә яткан тумранга утыргач, авыр сулап өстәде: – Туган авыл су астында калды, Әнсар Хәлиуллович. Туган нигез!

Бу үпкә-шелтәле сүзләрне Әнсар авылдашларыннан гел ишетеп тора, ул инде акланып-нитеп маташмый, чөнки аклану мөмкин түгел. Райкомда эшли торып та уяулыгын җуйды түгелме соң ул?.. Үзен гаепле санап, авылдашларыннан гафу үтенгән чаклары да булды инде аның. Гафу үтенүнең мәгънәсе бармы соң дип тә һәрдаим үз-үзеннән сорый ул. Ләкин барыбер танышбелешләренә, күрше-күләнгә тынычландыру сүзен әйтми кала алмый ул, чөнки дөнья бетмәде, тормыш дәвам итә, яшәргә кирәк, авыл халкында киләчәккә өмет сүрелмәсен өчен нәрсәдер эшләү мәслихәт.

– Алай димә, Сәет, барыбер бу авыл безнең туган нигезебез булып саналачак.

– Монда без туган нигезебезне тоеп яшәрбезме-юкмы, белмим. Зиратны күчерергә җитешә алмадык. Мәңге ярлыкамаслык гөнаһ бу, Әнсар. Хәзер әнә әти шуны уйлап урын өстендә ята. Шыр сөяккә калды, тамагына ашамый. Ничек без шундый коточкыч нәрсәгә юл куйдык?! Син бит, Әнсар, зур кеше, ничек моны абайламадың?!

– Без өстән кушканча гына эшли алабыз. Җитешмәдек бит. Мин шәхсән үзем суны болай кинәт күтәрелер дип уйламадым, хәбәр килер дә, өлгерербез дип өметләндем.

Сәетнең тавышында ачу гына түгел, нәфрәт яңгырады:

– Минем анамның кабере калды анда!

Әнсар болай да сөренке кәефле иде, хәзер инде бөтенләй йөзе караңгыланды:

– Синең әнкәңнеке генә түгел, бөтен авылның каберләре калды анда. Зиратны да кызганам, авыл да кызганыч. Их, Сәет, Сәет, без синең белән фронтовиклар, әллә ниләр кичеп кайттык, күрмәгән нәрсә калмады, киләчәгебез шушылай булыр дип кем уйлаган?! Мин райкомда эшли башлагач кына аңладым: безнең язмыш, туган җиребез язмышы үзебезнең кулда түгел икән. Син туган ягыңны яклап берәр сүз әйтеп кара! Сине җинаятьче диячәкләр, партия сәясәтен дөрес аңламаучы адашкан бер сарык диячәкләр.

– Аны мин райкомда эшләмәсәм дә күптән аңладым һәм хәзер дә аңлап йөрим. МТСтан командировкаларда еш булырга туры килә бит. Кая карама – зур-зур төзелешләр. Кеше яши дип тормыйлар, җирле халыкны санга сукмыйлар, ваталар, җимерәләр, бульдозерлар белән сөрдерәләр... Бер авыл янындагы икешәр метрлы кабер ташларын бульдозерлар белән сөрдереп күмгәннәр. Борынгы каберлек булгандыр, күрәсең. Заводлар, ГЭСлар, калалар төзелсен, ләкин гомер буе шул тарафларда яшәгән халыкның мәетләре өстендә түгел, аларның нигезен таптап түгел! Җирле халыкны санга сукмыйлар бит инде, килешәсеңдер!

Әнсар урыныннан кузгалды:

– Сүзләреңдә хаклык бар. – Ул шактый вакыт өстәп ни әйтергә белми торды. – Ләкин беркайчан да бу сүзләреңне башка беркемгә әйтмә, яме, – дип куйды ул, Сәеткә карамыйча гына.

– Ярар, – диде Сәет, утырган урыныннан торып.

Сөйләшер сүзләр күп тә ул, тотрыклы әңгәмә генә килеп чыкмый шул.

– Туган нигез, туган нигез... – дип борын астына гына мыгырдап уйга калды Әнсар. Шуннан соң кинәт сорап куйды: – Яббар хат язмыймы?

– Юк, язмый. – Энесенең исемен ишеткәч, Сәет җанланып китте. – Мин шуны уйлыйм хәзер... Аны кырык икенче елда алдылар. Ачлыкта үскән малай сугышка китте, менә хәзер бүгенгә кадәр әле ул адәм рәтле тормыш күрмәде. Ә бит тирәнрәк уйлап баксаң, аңарда гаеп ул кадәре үк зур түгел. Аңа барыбыз да артык каты бәрелдек, мин үзем дә артык каты төрттелдем.

– Легионерга нинди мөнәсәбәттә буласың инде... – Яббар турында сүз башлаганына Әнсар үкенеп куйды. – Төрмәдән монда кайтыр микән?

– Кайтачак, һичшиксез кайтачак! – диде Сәет, ялкынсынып. – Алай-болай кайтмаса, үзем табып алып кайтам. – Ул тавышын әкренәйтте. – Безнең Нәсимә белән балаларыбыз юк. Нәселне дәвам итүче, нигезне, ичмаса, күченгән авылыбызда булса да саклаучы дәвам барыбер кирәк. Яббарның улы бар.

– Аны хатыны ташлаган бугай бит?

– Ташласын. Хатын-кыз бетмәгән дөньяда. Яббарның улы бар. Кыяфәткә дә тач Яббар үзе. Ул аның дәвамы. Ул безнең дәвамыбыз!

Әнсар чәйгә чакырулары өчен рәхмәт әйтеп, авылны бер әйләним әле дип, өйгә кереп тормыйча саубуллашып чыгып китте.

...Нәгыйм 1958 елның мартында вафат булды. Үләр алдыннан Әминәсенең кабере су астында калганга чиксез кайгыруын, рәнҗүен белдерде ул.

Авылның яңа зиратын Аулаш тавының төньяк өлешендә билгеләгәннәр иде. Нәгыймне күмгәнче монда инде өч кабер бар иде, аныкы дүртенчесе булды. Җитмеш дүрт яшендә вафат булган Хисами карт, тумыштан чирле өч яшьлек кыз бала, сугышта каты яраланып кайтып савыга алмаган Рәфкать Кызылъярның яңа зиратында үз урыннарын алганнар иде инде.

Йортта Сәет белән Нәсимә икесе генә калдылар.

– Әти кырыс булса да, гадел кеше иде, – диде Сәет беркөнне. – Аның йөрәге гаделлеге аркасында таушалды. Бу илдә намуслы кешенең ничекләр йөрәккәе чыдасын?!

– Бер-бер артлы киттеләр дә бардылар, – диде Нәсимә боек тавыш белән.

Сәет тыела алмады, елап җибәрде:

– Әнкәй – бер зиратта, әти икенче зиратта җирләнде. Әнкәй су астында калды, әти – тауда.

– Тыңламадың бит мине. Су басуы ихтимал икәнен белә торып... Әнкәйне анда күммик дип, еландай телләремне чыгарып ялвардым мин сиңа.

Сәет учы белән дымлы битен сыпырды да кинәт хатынына кычкырды:

– Тик кенә утыр! Вакыт узгач бөтенесе акыллылана, хаклыга әйләнә!

– Кычкырма миңа! – диде Нәсимә тыныч, ләкин таләпчән тавыш белән. – Шуны әйтәсем килә: миңа карата катыланма, Сәет. Әнкәй әтинең кырыслыгына түзеп яшәде, ләкин мин алай түзмәячәкмен. Мин синең хатының икән, гаебем булган сурәттә генә кырыслан.

Соңгы вакытта шактый юашланган Сәет хатынына күндәм тавыш белән җавап бирде:

– Минем сиңа тик торганда каты бәрелгәнем юк та.

Нәсимә күптән әйтергә теләп йөргән фикерен дә кызып китеп әйтеп ташлады:

– Син энеңнең дә желеген суырдың. Бөтенесе аны дошман иткәндә, син аны аз гына булса да якларга тиеш идең.

– Үзеңнең «Мәктәптә ничек патриотизм тәрбиялим, укучыларның ата-аналарыннан оят, иремнең энесе легионер, ә мин балалар укыткан булам!» дип шыңшыганыңны оныттыңмыни?!

– Ул бер генә тапкыр булды, – диде Нәсимә. – Аптыраганнан гына.

Талаш шуннан ары китмәде. Үзара тату яшәп ятучы ир белән хатын арасында иминлек шундук кире үз урынына кайтты.

– Талашмыйк, – диде Сәет, авыр сулап. – Болай да бик авыр.

Нәсимә иренә тавыш күтәргәненә үкенеп куйды.

– Хәзер ашарга пешерәм, – диде ул, аралар бозылып китмәгәнгә куанып. – Нәрсә пешерим?

– Үзеңә кара, – диде Сәет битарафлык белән.

33

Яббар 1960 елның августында кайтты.

Туган авылы урынында су җәйрәп ятканын күргәч, үзәге өзелде. Коточкыч тетрәнү белән бергә ул ниндидер сәер шатлык хисе кичерде. Шатлык та түгел иде ул, иң кадерле нәрсәнең юкка чыгуы аны бу вәхши дөньяга, кансыз чынбарлыкка тоташтырып торган элемтә җепселләрен шытыр-шытыр өзде шикелле, шуңа күрә күңелдә барыбер аңлатып булмаслык җиңеллек барлыкка килгән шикелле булды. Әйтерсең лә үзәккә асып куелган күтәргесез авыр таш урынына җиңелрәген элеп куйдылар.

Анда, су астында, авыл зираты. Ә биратта аның әнкәсенең кабере.

Ул туп-туры су буена төшеп китмәкче иде, әмма башта Сәет белән Нәсимәне күреп сөйләшергә кирәк дип тапты.

Аулаш тавына күчерелеп утыртылган авылга кем булып килеп керергә тиеш соң ул? Чын Кызылъярда, туган авылында да аны кешегә санаучы аз булды лабаса. Ә авылның хәзергесендә?.. Кызылъяр исеме калса да, аның өчен бөтенләй чит-ят авыл бит

инде бу. Сәетләр яши торган йорт та аның туган йорты түгел, аның нигезе түгел. Дөрес, урамнарны, тыкрыкларны элекке чын авылдагы исемнәр белән атаганнар. Ләкин Яббарның туган авылы Кызылъяр түгел инде бу. Бер күршеләре элеккечә Хәлиуллалар икән. Элек икенче якларында күршеләре юк иде, урам очы булганлыктан, анда бушлык иде. Хәзер исә икенче күршеләре дә бар – килгән кешеләр, ирле-хатынлы, икесе дә МТСта эшлиләр, балалары өчәү икән.

Сәетләрнең йорты бикле иде. Сәет МТСтан кайтып җитмәгән, Нәсимә сеңлесе Сәвияләргә киткән. Моны аңа яңа күршесе – МТСта диспетчер булып эшләүче сары чәчле, тәбәнәк буйлы хатын әйтте.

Сул як күршеләрнең капка төбендә басып торучы карчыкны Яббар таныды – Зәкия карчык иде ул. Капкадан әкрен генә чыгып Зәкия белән янәшә басучы, һичшиксез, Хәлиулла карт иде. Ул башта алар белән барып күрешергә уйлаган иде, әмма кире уйлады, үзен танымасалар ярар иде дигән теләк белән күзләреннән югалырга ашыкты.

Яббар ике дә уйлап тормады, су буена төшеп китте. Очраган һәрбер кеше аңа туктый-туктый карап калды. Яббар бөтенләй танымаслык дәрәҗәдә үзгәргән, бәләкәй генә калган, бөкрәйгән, күзләрендә коточкыч кыргыйлык. Очраган авылдашларның кайберсе аны танымады, таныганнары исә тизрәк аның яныннан качарга тырышты. Ләкин Яббар алардан элеккечә курыкмый иде инде. Ул һәрбер очраган кешегә туп-туры карады, таныганнары белән авыз тутырып исәнләште. Җавап итеп исәнләшмәсәләр, һич кенә дә исе китмәде.

Озак йөрде ул су буенда.

Ирек бирсәң, дөньясын басачак бу су. Җәйрәп яткан су түренә карап, ул авыл батып калган урынны дөрес абайлады.

Әйе, шунда иде аның туган авылы.

Ул артка борылып карады. Туып үскән якны инде танырлык түгел иде. Яббар әллә нишләп китте, үзәгеннән ниндидер аваз чыкканын үзе дә сизмәде. Елауга да, улауга да охшаган тавыш тирә-якны сискәндерде. Еракларга кадәр яңгыраган бу авазны ишеткәч, җәйләүдәге сыер көтүен көтүчеләр бүре улыйдыр дип уйладылар.

Туып үскән изге җирнең бер өлеше – иң кадерлесе, иң изгесе – беткән, юкка чыккан!

Әнә теге тарафта авылның зираты су астында калган.

Анда әнкәсенең кабере!

Кичкырын аякларын көчкә сөйрәп, Яббар яңа авылга таба атлады.

Аның кайтуы хакында бөтен авыл гөр килә иде инде. Хәлиулла белән Зәкия, икәүләшеп Сәетләргә кереп, энең кайтты, диделәр.

Нәсимә аш пешерде, Сәет авыл кибетеннән бер шешә аракы алып кайтты.

Өстәлдәге шешә яртылаш бушагач, Яббар су буенда йөргәнен, анда нинди хисләр кичергәнен сөйләргә тотынды. Туган якның шулкадәре өлеше су астында калуына тора-тора шаккатты. Аның йончыган кыяфәте, күзләренең төссезлеге, картаюы, гыр-гыр килеп йөткерүе, авыр итеп көчкә сулавы төрмәләрдә утырганнан түгел, ә бәлки туган авылының, зиратның, анасы каберенең су астында калуыннан дип уйларлык иде.

– Их, энекәш! – дип ыңгырашты Сәет, Яббарның сөйләгәннәрен тын да алмыйча тыңлап утырганнан соң. – Кинәт су басты... Әле ничек үзебез исән калдык.

Яббар кинәт, кыжрап, абыйсына җикерде:

– Исән?! Син исәнмени?! Син тере кешеме соң?! – Аның күгәргән чыраеннан бөтенләй кан качты, ул бөтенләй ап-ак булды. – Авылыңның, бабаңнарның, анаңның каберләрен су астында калдыргач, син, гомумән, кешеме соң?!

– Җитешмәдек, – дип акланды Сәет. – Авылны да менә җанфәрманга тау итәгенә күчердек бит.

Нәсимә Яббарның кыяфәтеннән нык курыкты, соңгы вакытта юашланган иренең бу минутларда бөтенләй көчсез вә рухсыз булып калуын абайлады, шуңа күрә тизрәк сүз катарга кирәк дип тапты:

– Син, Яббар, Сәет белән мин кайгырмыйбыз дип уйласаң, ялгышасың.

Сәет стаканнарга аз-аз гына аракы салып куйды.

– Энекәш, миңа теләсә нәрсә әйт, ачулан, сук... Мин моңа лаеклыдыр, мөгаен. Ләкин берүк башкаларга, бигрәк тә Әнсарга тавыш күтәрә күрмә, яме.

Яббар авыз чите белән елмайды:

– Ник алай?

– Ник алай дип... Аңлыйсың бит инде.

– Юк, аңламыйм! – диде Яббар, абыйсына текәлеп карап. – Дөресрәге, мин аның гаебе зур икәнне аңлыйм, ә менә нишләп мин аңа тавыш күтәрмәскә тиеш – шуны аңламыйм!

– Нәрсәсен аңламыйсың? – дип янә сүзгә кушылды Нәсимә. – Тагын төрмәгә утыртып куймагайлары дип синең өчен борчыла.

Яббар Нәсимәгә усал итеп карады:

– Анам үлгәч, аның каберен су баскач, минем беркем алдында да акланасым килми. Башымны иеп тәүбә итәр өчен минем анам инде бу дөньяда юк.

– Синең улың бар, аның турында онытма, – диде Нәсимә, тавышын күтәреп.

Яббарның шундук кыяфәте кинәт үзгәрде.

– Әйе, минем улым бар, – диде ул, горурланып.

Нәсимә, Яббарның йөзе яктырып киткәнгә сөенеп, аның улы турында сөйләшүне дәвам итте:

– Улың белән очрашырга сиңа анасы рөхсәт итәрмен дигән иде...

– Рөхсәт итә, – диде Яббар, елмаеп. – Мин, иреккә чыгу белән үк, алар янына барып кайттым. Биш яшь инде Вәсимгә, биш яшь. Миңа бик охшаган.

Нәсимә дә моңа ихластан шатланды һәм:

– Вәсимеңне монда алып кайт, – диде.

Яббарны авыр уйларыннан, кайгысыннан хәтта улы турында сөйләшү дә арындырырлык түгел иде шул. Туган авылы, анасының кабере су астында калгач, ничек ул тыныч кына үзе турында, үзенең баласы хакында сөйләшеп утыра алсын.

– Мондамы?.. – диде ул, кинәт тагын усалланып. – Улымны монда алып кайтыргамы?.. – Ул стакандагы аракыны йотып куйды, ипи кисәген кабып Сәеткә текәлде. – Абый, синнән мин бер сорау көткәнием.

– Нинди сорау? – диде Сәет, инде әллә нинди сорауларга да әзер булып.

– Сугыштан соң, беренче тапкыр утырып кайткач, миннән «Нишләргә уйлыйсың, нишләргә җыенасың?» дип сораган идең. Бу юлысы да сорамассың микән дигәнием. Сорамадың. Хәзер мин сиңа шул сорауны бирим әле. Син, Сәет абый, нишләргә уйлыйсың?

– Ничек инде «нишләргә»? – диде Сәет, аптырап.

– Ничек яшәргә уйлыйсың? Су астындагы зират төшләреңә кереп йөдәтмиме соң әле?

Сәет сикереп торып әрле-бирле йөри башлады:

– Ичмаса, син күңелгә коткы кертмә! Күңелемдә ниләр кайнаганны белмисең бит син!

Яббар абыйсын нәфрәт белән күзәтеп утырды:

– Кеше башка кешенең күңелен ничек белсен, ничек күрсен, ничек аңласын! Теләсә нишлә! – Ул ике йодрыгын да төйнәде. – Шуны әйтәсем килә: син мине легионер дип кичермәдең, ә мин сине анам кабере өчен кичермим!

Нәсимә ике борадәрнең болай сөйләшүеннән котсыз калды:

– Туктале, Яббар, алай димә!

Кайнар әңгәмәгә бирелеп, алар капка тавышын ишетми калдылар.

Сәет, кинәт сагаеп:

– Өйалдына кемдер керде бугай, – дип кенә өлгерде, өй ишеге киерелеп ачылды һәм бусагада Әнсар пәйда булды.

– Исәннәрмесез! – диде ул көр тавыш белән.

Тавышына вәкарьлекне ясалмалы итеп кирәгеннән артыграк өстәде шикелле. Бу үзенең каушавын күрсәтмәс өчен иде, ахрысы.

Яббарның кайтканын ишетеп керде ул. Очрашу җиңел булмаячагын да белә, әмма күрешеп, исәнләшеп, күзгә-күз карашу мәслихәт. Барыбер кайчан да булса очрашырга туры киләчәк. Аның инде Яббарга карата мөнәсәбәте нык үзгәрде, ул аңа, аның

язмышына хәзер инде башкача карый. Ничәмә еллар буена баладән котыла алмыйча, гәүдәсен турайта алмыйча иза чигүче авылдашына, күршесенә аның хәзер чын-чынлап ярдәм итәргә исәбе бар.

– Исәнмесез! – дип җавап бирде Сәет.

– Исәнмесез, Әнсар Хәлиуллович! – диде Нәсимә. – Әйдәгез, түргә узыгыз.

Әнсар ишек катыннан кузгалырга ашыкмады.

– Исәнме, Яббар! – диде ул, тавышын кинәт бөтенләй үзгәртеп, хәтта йомшартыбрак.

Яббар тук чырайлы, пөхтә киемле сау-сәламәт күршесенә шактый вакыт карап торды, аннары кыланып, мыскыл иткән сыман:

– О-о-о, Әнсар Хәлиуллович! – дигән булды. – Начальник! Мин бит сине танымый торам! Ай-яй, корсак белән яңакны киң җәелдергәнсең син. – Һәм шаркылдап көлеп куйды.

Нәсимә өстәлне сөрткән булып Яббарның иңенә төртеп пышылдады:

– Яббар!

Әнсар, ниһаять, түргә узды, Яббарны яхшылап күзәтергә мөмкин булсын өчен, урындыкны алып аның каршысына утырды:

– Хәл-әхвәлләрегез ничек?

– Аллага шөкер, Әнсар Хәлиуллович, – диде Нәсимә чак кына сизелерлек ялагайлык белән.

Сәет тәкъдим иткән аракыдан Әнсар баш тартты.

Ул сөйләшергә сүз тапмый торган арада, Яббар, шатор-шотыр итеп яшел суган чәйни-чәйни, Әнсарга сүз катты:

– Әле бүген Фатыйманы күрдем... Фигурасы бозылган, артык тәмле ашаудандыр инде. – Ул күзләрен челәйтте. – Әллә ир игътибары җитмиме? Ха-ха-ха!

Сәет энесенең дорфа шаяруыннан һәм ямьсез итеп көлүеннән чыраен сытты.

– Болай булгач, тагын утыртып куялар сине, – диде ул үзалдына, ләкин барысы да ишетерлек итеп.

Әнсар ник кергәненә үкенде булса кирәк, ул утырган урынында як-якка чайкалып кымшанып алды.

– Тынычлан әле, Яббар, – диде ул, аңа туры карамаска тырышып. – Бераз салгач кайнарлану табигый, ләкин артыгын кыланма, яме.

– Артыгын?! – дип кычкырды Яббар кинәт. – Нәрсәнең артыгын кыланам мин?! – Ул сикереп торып табын яныннан кузгалды. – Мине ташламаган бердәнбер кеше әнкәй иде! Мине бу дөньяда бер генә кеше гомере буе яратты – әнкәй! Мин сезгә аның каберен мәңге гафу итмим! Син, Әнсар, партия күсесе! Сука! Ә син, Сәет, минем туганым түгел!

Яббар гомерендә беренче тапкыр абыйсына абый дип түгел, исеме белән генә эндәште.

Әнсар инде торып чыгып китмәкче иде, шулай да үзен көчкә йөгәнләп урынында утырып калды:

– Яббар, мин махсус сине күрергә дип кердем. Берәр ярдәм кирәк түгел микән, эшкә урнашу буенча, тегесе-монысы... Ә син...

Яббар шундук аның сүзен бүлде:

– Рәхмәт, начальник, миңа сучий кусок кирәкми!

Аралыкка кереп поскан җиреннән Нәсимә түзмәде, атылып чыкты.

– Яббар, җитте сиңа! – дип кычкырды тынгысыз гаиләдә яшәп нервылары нык какшаган хатын.

Яббар Нәсимәнең ачыргаланып кычкыруына аз гына да ригая бирмәде, Әнсарга тагы да якынрак килеп чак кына иеленкерәде һәм, авызыннан аракы белән суган исен аңкытып, эчендәгеен бушатуын дәвам итте:

– Син коткара ала идең зиратны. Синең бәгырең таштан. Сиңа туган җир, туган як кирәк түгел! Әнә нинди тук чырайлы син! Дөньяны су басса да, син үзең батмаячаксың. Чөнки б... батмый, бигрәк тә бу кадәре б..! Син ике аяклы бәдрәф! Передвижной нужник син, падла!

Төрмәдән кайткан кешедән мондый сүзләр ишетү райком секретаренда каушау дигән нәрсәне кинәт юкка чыгарды.

– Ә син кем? – диде ул, әкрен генә торып.

Яббар буыла-буыла йөткерергә тотынды. Әнсар чыгып киткәнче әйтеп бетерәсе сүзләре бихисап күп иде аның.

– Мин – кеше! – диде ул, ишеккә таба юнәлгән Әнсарга иярեп. – Вөҗданыма тап төшермәгән, әмма дә ләкин бәхетсезлеккә дучар булган корбан мин. Мин сугышта үзебезнекеләргә таба бер тапкыр да атмадым. Хәтта бер генә көнгә, бер генә минутка да сатлыкҗан булмадым. Мин әнкәйне сагынып, туган авылымны сагынып ашкындым үзебезнекеләр ягына. Мин туган илемә хыянәт итмәс өчен үзебезнекеләр ягына ашыктым. Әгәр дә шунда пленда чакта киләчәктә синең туган авылың, анаң күмелгән зират су астына батырылачак дигән булсалар, мин, мөгаен, атар идем, Совет Армиясенә каршы сугышыр идем.

Әнсар ишек катында аны ахырына кадәр тыңлап торды да:

– Син... чамалабрак! – дип кенә әйтә алды.

Шуннан да катырак әйтә алмады Әнсар, чөнки Яббарның җан газабыннан каралган йөзен, хәсрәт томаны эченнән дөньяда нинди дә булса яктылык табуга өметен җуйган тоныкк күзләрен якыннан күрде ул.

Яббар:

– Мин инде күп чамаладым, – дигәч, кинәт Әнсарның бәхетсез күршесен кочып җылы сүзләр әйтәсе килде. Ләкин әле бу мәлдә җылы сүзләр әйтү табигый булып тоелмас, мөгаен, шуңа күрә Әнсар бераз акланудан башларга кирәк дип уйлады.

– Яббар, каберләрне актару дөрес булыр идеме соң? – диде ул. – Мин зиратны ничек итеп актаруны аңламыйм.

– Ә мин ничек итеп зиратны суга күмүне аңламыйм. Мине

кешеләр нык кыйнадылар, җәберләделәр, хәтта аттылар да... Ачлык белән интектерделәр, мыскыл иттеләр, мәсхәрәләделәр, изделәр... Ләкин ни гаҗәп: мин аларның берсенә дә үпкә-нәфрәт сакламыйм. Рас шундый хәлгә төшкәнмен икән... Ә менә анам каберен, авыл зиратын су астында калдырганыгыз өчен мин сезне мәңге ярлыкамыйм. Син әйтерсең, изменникның ярлыкавы ник кирәк, диярсең. Моңа мин төкерәм! Бу вәхши дөньяда син мине кешегә санамасаң, теге дөньяда мин сине анам кабере өчен барыбер кичермәячәкмен!

Әнсар әңгәмәне тәмамларга кирәк икәнне, хәтта аны башлауның да кирәге булмаганны аңлады.

Ул:

– Ярый, сау булыгыз! – диде дә, артыннан берәрсе озата чыгар дипме, ишекне япмыйча гына чыгып китте.

34

Яббарның көн саен кояш баеганчыга кадәр су буенда авыл баткан тарафка карап утыруын авыл халкы һәрдаим күреп-белеп торды. Аңа игътибар итмәскә тырыштылар, чөнки һәрберсенең су басу вакыйгасына үзенең кайгылы мөнәсәбәте бар иде. Яббарны ачыктан-ачык дошман итмәсәләр дә, барыбер аның белән аралашмаска, аңардан читкәрәк тайпылырга тырыштылар. Участок инспекторы капитан Кәлимуллин гына туп-туры, махсус рәвештә аның янына килеп, күз-колак булып, отмечать итеп торды. Тизрәк эшкә урнашырга кушты, аракы белән мавыкмаска өндәде. Яббар исә участковый әйткәннәрне колагына да элмәде, аның бөтен игътибары, бөтен уй-хисләре су астында калган тарафта иде. Йортта эш күп булса да, Сәет Яббарга эш кушмады. Яббар да үзе белеп хуҗалыкта ярдәм итәргә атлыгып тормады, хәтта теләк тә белдермәде.

Әнсар кергәннең икенче көнендә Яббар, гадәттәгечә, су буена төшеп китте.

Әле урак өсте, МТС умартадай гөжләп тора, шулай да Сәет үзенә бер көн ял юллады – сентябрь җиткәнче, Нәсимә буш чакта каралты-кура тирәсендәге эшләрне карарга кирәк иде.

Яббар чыгып киткәч, алар инде әллә ничәнче кат ишегалдын җыештырырга тотындылар – бу эш күченгәннән бирле торымнан торымга инде кат-кат башкарылса да, чүп-чарның, йомычканың, агач чүбенең һич кенә дә бетәчәге күренмәде.

Көн уртасына таба участковый килде. Ул «Яббар район үзәгенә отделга барсын» дигәч, Сәет башта куркып китте. Әллә Әнсар шалтыратты микән дип уйлады ул. Участковый Яббарның надзорда икәнлеген, атнага бер тапкыр отделга барырга тиешлеген әйткәч, шундый тәртип барлыгын аңлаткач, Сәет бераз тынычланды.

Участковый чыгып киткәч, Сәет, онытылыр өчен, башындагы

авыр уйларны таркату нияте белән, себеркесен җил-җил селтәп, ишегалдын себерергә тотынды.

– Туган як җанлы малай булды ул бала чактан ук, – диде Сәет, хәл алырга туктагач себерке сабын җиргә кагып. Аннары өстәп куйды: – Әнсар белән бик дорфа сөйләште, шуңа эч поша әле.

– Аракы эчмәскә иде сезгә, – диде Нәсимә, йомычка өемен көрәк белән каерып носилкага салгач. – Инде кешеләр аның Әнсарга бәйләнгәнен ишеткәннәр.

Алар, шактый алҗып, ял итәргә сарай буендагы бүрәнәгә утырдылар. Шул вакытны капкадан Яббар кайтып керде. Аны мондый шат йөзле, күтәренке кәефле итеп кайтканнан бирле беренче тапкыр күрүләре иде. Сәет белән Нәсимә аптырап бер-берсенә карап куйдылар.

– Барыбер әле ямьле урыннарыбыз калган, – диде Яббар, канатланып. – Безнең туган якны су белән генә басып бетерү мөмкин түгел шул. Әле бит без чана шуган таулар калган, әле урманыбыз исән. Бүген һава бик әйбәт, сихәтле. Су буенда шундый рәхәт! Ниндидер көймә чайкалып тора – талга бау белән эләктереп куйганнар. Кемнеке икән ул?

Сәет, беравык уйланып торганнан соң:

– Ә-ә-ә, ул иске көймә, күптән тора ул анда, – диде. – Кайвакыт малай-шалай утырып йөри аңа.

Яббарның тавышында кинәт шом яңгырады:

– Баткан авылыбыздан кемдер көймә белән кайтканмы әллә дигән әкияти бер уй килде башыма.

– Кем кайтсын инде аннан?! – диде Нәсимә басынкы тавыш белән.

Яббардан сәер илһам ташып чыкты:

– Бүген мин анда ниндидер бер гүзәл кош күрдем, ни икәнен әйтә алмыйм, элек андый кош күргәнем юк иде. Шул кош ташка баскан да миңа текәлеп-текәлеп карый. Якынрак килдем. Миннән курыкмый, очып та китми. Инде бөтенләй якын ук килгәч кенә очып китте. Шунда гына ул кунаклаган ташка игътибар иттем. Нинди таш икән ул? Сынчы ясаган сыман, биле бар ул ташның.

– Саташа түгелме бу? – дип пышылдады Нәсимә.

– Юк, юк, саташмый, – диде Сәет, ишегалды уртасында сәхнәдәгедәй басып сөйләгән энесен күзәтеп.

Яббар башын күтәреп күккә карады:

– Һава әйбәт бүген.

– Участковый килде, – диде Сәет, энесен күктән җиргә төшерер өчен. – Сиңа район отделына барырга кушты.

Яббар бер дә исе китмәгән кыяфәт белән:

– Шулаймы? – дигән булды.

– Тузынуыңны бөтен авыл белә, – диде Сәет, шөбһәләнеп. – Әнсарга әллә ниләр әйтеп бетергәнеңне дә ишеткәннәр.

– Алай икән, – диде Яббар битараф тавыш белән.

– Авыл кешеләренең бөтенесе дә сине дошман итә дип уйла-

саң, ялгышасың, Яббар, – диде Нәсимә. – Сиңа хәзер үз-үзеңне кулда тотарга тырышырга кирәк. Авылны су басканнан соң, халык нык үзгәрде.

Яббар моңсу итеп елмайды:

– Кешеләргә ышанмыйм мин, Нәсимә. Ә шулай да миңа бүген искиткеч рәхәт!

– Участковыйны Әнсар чакыртмагандыр, – дип уйга калды Сәет. Аннары тереләнеп өстәп куйды: – Юк, юк, Әнсар түгел. Беткәнмени стукачлар. Алар гомергә булдылар, һәрбер авылның шикаять язучылары бар.

Күптән булмаган хәл, мөгаен, сугышка озаткан вакыттан бирле – Яббар килеп абыйсының иңенә кулын куйды:

– Абыем! Абыкаем! Төкер син аларга! Көн матур бүген. Табигать әле бөтенләй үк су астына китмәгән. Нинди гүзәл күренеш: су буе... көймә... нindидер таныш түгел бер гүзәл кош сайрый... сынга охшаган таш ялтырый... һава сихәтле...

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Яббар капкадан чыгып китте.

– Табигать турында сөйли башлагач тынычлануыдыр инде, – диде Нәсимә, сөенеп. – Аллага шөкер. Син, Сәет, аңа каты бәрелмә инде. Әйткәннәренә түз. Тиздән тынычланыр. Тагын төрмәгә утыртып куймасыннар инде үзен, Ярабби.

Сәет дәшмәде. Энесенең язмышы өчен борчылу күкрәк турысын газап тырнагы белән тырнап куйды. Алга таба ничек булыр? Нишләр бу Яббар, ничек яшәр?

Сәет кинәт әчке сискәнү тойды.

– Юк, Нәсимә! – дип сикереп торды ул утырган урыныннан. – Табигать турында канатланып сөйләве гади тынычлану түгел ул! – Сәетнең йөзеннән төс качты. – Көймә, таш... Аның нишләргә җыенганын аңладым мин!

...Сәет су буена йөгереп килеп җиткәндә, томан эченнән тоныкына булып бер тап күренде. Кемдер көймә белән томан куелыгына йөзеп кереп бара иде. Ишкәкләрнең суны ялкау гына чыпырдатуы ишетелде.

Сәет, томанлы дөньяны ярып, бар көченә кычкырды:

– Яббар!

Томан эченнән җавап көтеп тыңлап торгач, тагын кат-кат кычкырып карады:

– Яббар! Яббар! Яббар!

Җавап ишетелмәде. Сәетнең үз тавышы гына, әрәмәләр ягыннан кайтаваз булып кабатланып, су өстеннән каядыр таралып бетте. Сәет тагын томан эченә колак салып тыңлап торды. Көймәдәге кеше дә, көймә үзе дә томан эчендә тәмам югалды, ишкәкләрнең суны каерганы да инде ишетелми иде.

Әле бик озак карлыккан тавыш тирә-якны тетрәтеп яңгырап торды:

– Яббар! Яббар! Яббар!

35

Туып үскән авылы баткан тарафка Сәет сәгатьләр буе карап утыра. Көн саен диярлек килә ул монда. Бүген су астында калган яшьлек болыннарын, кырларын күз алдына китереп утырганда, ул ниндидер улауга охшаган тавыш ишетте. Күп уйланганнан колакка ишетеләме? Әллә саташумы бу?

Күп тә үтмәде, авыл ягыннан су буена таба берәүнең төшеп килгәне күренде. Сәет Әнсарны әллә каян ук таныды.

Кул биреп күрешкәч, Әнсар янәшә урнашып, беркавым дәшми утырганнан соң сорап куйды:

– Нинди улаган тавыш ул? Әллә миңа гына ишетеләме?

– Үзем дә аптырашта, кемдерме, нәрсәдерме улый, – диде Сәет, як-ягына каранып. – Сәер тавыш. – Аннары авыр сулап өстәп куйды: – Сәерлекләр күп инде ул монда.

Әнсар су өстенә кул ишарәләде:

– Безнең авыл әнә тегендә иде бит.

– Әйе. Аннан арырак зират иде. – Сәет тамагында төер тойды. – Үрмәләп булса да, тырнаклар кубарылып канга бата-бата булса да, зиратны күчерергә иде. Ичмаса, әнкәмнең каберен күчерергә тиеш идем мин.

– Кем уйлаган... Мин дә җанымның әрнүенә көчкә чыдап йөрим.

– Синең атаң-анаң исәннәр әле ичмаса. Аларның каберләре югалмаслык итеп алдан ук кайгырта аласың.

– Миңа да бик авыр, Сәет. Үземә үзем хуҗа түгел бит мин. Мин – партия кешесе, должностьтагы кеше. Менә обкомга эшкә чакыралар. Сиңа дөресен әйтәм: күңелем тартмый, үземне лаеклы дип санамыйм шикелле, ә менә баш тартырга йөрәк җитми, куркам.

– Куркасыңмы...

– Син миңа, бәлки, ышанмыйсыңдыр. Үземә үзем хуҗа түгел мин.

– Ышанам. Без үзебезгә дә, үзебезнең язмышка да, үзебезнең туган туфрагыбызга да хуҗа түгел! Без Туган ил дибез, ә үзебезнең Туган җиребезне саклый алмыйбыз. Каһарманнарыбызны да, сатлыкҗаннарыбызны да үзебез билгеләмибез, тегендәгеләргә карап хәл итәбез, алар бизмәнендә үлчәп бәялибез. Без Ватан өчен сугыштык, әмма без үз Ватаныбызның хуҗалары түгел. Безне дә, Ватаныбызны да кемнәрдер үз мәнфәгатьләре өчен файдаланалар. Без зур, бөек төшенчәләр белән сату-алу итәбез, ә бер-беребезнең кадерен белмибез. Туган ил, Туган җир дибез... Ә без аны саклый алабызмы? Күпме корбан биреп тә туган якны яклый алмыйбыз, хәлебездән килми.

– Нишлисең бит...

Алар шактый вакыт тып-тын суга карап утырдылар.

– Арабызда туган җирен иң нык яратучы Яббар булгандыр, – дип куйды Сәет.

– Мөгаен, шулайдыр.

– Ул сатлыкҗан түгел иде! – диде Сәет каттый тавыш белән.

– Нинди сатлыкҗан булсын ди ул! – дип җөпләде аның сүзен Әнсар.

Әллә каян – суның күренмәгән ярыннанмы, арттагы әрәмәләр эченнәнме – янә улаган тавыш ишетелде. Елауга охшаган бу тавышны аңларга тырышып икесе дә киеренкелектә утырдылар.

– Гомер уза-а-а, – дип сузды Әнсар, сәер тавыш ишетелми башлагач.

– Әйе, мең тугыз йөз җитмеш беренче елда, шушы халәттә синең белән икәү шушылай утырырбыз дип кем уйлаган?! Улым унсигез яшьтә, кызым уналтыда бит инде.

– Улың кайда укый?

– Авиация институтында. Кызым Сөмбел табиб булырга хыяллана.

Алар әңгәмәнең бик четерекле, бик җайсыз, ләкин шулвакытта кагылмыйча үтәргә ярамаган турына килеп җиткәнне икесе дә аңлыйлар.

– Яббарның улы Вәсимгә дә унҗиде тулды, – диде Сәет, беркавым дәшми торганнан соң.

Әнсар үзенең кызы Сөмбел белән Яббарның улы Вәсимнең соңгы вакытта очрашып бергә йөрүләре турында сүз катмакчы иде, шулай да тыелды, әйтмәде. Тып-тын гына суга карап һәрберсе үзенекен һәм икесенә дә кагылганын уйлады.

Кызының Яббар улы белән дуслашып йөри башлауларына, чынлап та, нык борчыла Әнсар. Ничек була инде бу? Кешедән ару түгел. Казанга, обкомга күчәр алдыннан гына бер дә яхшы яңалык түгел бу. Дөрес, болай начар егеткә охшамаган, шулай да…

Вәсим инде ундүрт яшеннән үк үзе Кызылъярга Сәет абыйларына кайтып йөри башлады. Яббарның улы икәнлеге мәгълүм булгач, авылда аңа башта кырын карадылар. Җитмәсә, төс-биткә коеп куйган Яббар иде инде менә. Әмма Вәсим бик авыл җанлы, кешеләрне яратучан, тиз аралашучы булганлыктан, аңа авылдашларның мөгамәләсе тиз арада яхшы якка үзгәрде, аны бәхетсез бала дип кызгандылар, атасы өчен җавап бирергә тиеш түгел, егетнең бер гаебе дә юк, диделәр. Сәет белән Нәсимәгә исә, балалары булмаганлыктан, Вәсим үз уллары кебек якын иде.

1971 елның Сабантуенда Вәсим Сөмбел исемле бер гүзәл кыз белән танышты. Аның Әнсар кызы икәнлеге егетне һич кенә дә пошаманга калдырмады, чөнки кызга ул үлеп гашыйк булды. Авыл халкы аларның кичләрен җитәкләшеп кичке уенга баруларын күргәч, әлбәттә, пыш-пыш килделәр, гайбәт чәйнәделәр. Унҗиде яшьлек егет белән уналты яшьлек кыз арасындагы якынлыкны күреп, кайбер ачы телләләре: «Ходай Әнсарга Яббарның рәнҗүен китерә», – диделәр. «Әнсар белән Яббар арасындагы дошманлык балаларында дәвам итмәгәе», – диючеләр дә булды.

Ә ике яшь йөрәк, беркемгә, бернәрсәгә карамыйча, бер көйгә типте, алар ныклап, саф күңелләргә генә хас сөю белән бер-берсен ярата башладылар, һәм әлегә Вәсимнең әтисен, аның фаҗигале язмышын бер тапкыр да телгә алмадылар.

Сөмбел белән атасы да, анасы да сак кына сөйләшеп карадылар. Әмма кыз Вәсим белән кача-кача барыбер очрашты. Аптырагач, әле җәй уртасы гына булса да, Сөмбелне авылдан алып киттеләр – район үзәгеннән Казанга күченергә җыенулары бик уңай сәбәп булып чыкты. Озакламый Вәсим дә, Сөмбелдән башка авылда ямь тапмыйча, анасы янына Куйбышевка кайтып китте.

Кыз белән егет хат алыша башладылар. Куйбышев белән Казан арасында хатлар тиз йөргәнлектән, алар хатларында үзләренең хисләрен аңлатып рәхәтләнделәр.

Тиздән Казанда очрашу хыялы икесен дә канатландырып торды – Вәсим университетка керергә җыена иде.

36

Су буенда серле һәм изге урын барлыкка килде. Батып калган авылны, зиратны, су астында югалган яшәү рәвешен, харап булган гореф-гадәтләрне, гаип булган тиңсез бер мохитне, изге догаларны, шул догаларга бәйле авыл халкының тарихын сагынып утыра торган мәйданчыкка әверелде бу урын.

Әрәмәлек янындагы бормалы сукмактан, баеп килүче кояшны куып тотарга, тоткарларга, шушы көннең кочагыннан аны беркая да җибәрмәскә ниятләгәндәй, зәңгәр күлмәкле үсмер кызның йөгергәне күренде. Су буендагы яшь егет аны абайлады, каршысына омтылды.

Кыз, каушанкырап, ике-өч адым җитәрәк туктады. Егет тә югалыбрак калды шикелле. Тыннар капкан бу мәлдә ике гашыйк арасындагы берничә адым бик якын да, шул ук вакытта мәңге үтә алмаслык та ара иде. Ике йөрәк, атылып чыгып, пар кошлардай күккә томырылып очып китәрләр шикелле тоелды.

– Вәсим, сәлам! – диде кыз, көчкә сулыш алып. Аның «Вәсим, сәлам!» дип әйтүен егет бик ярата, кыз моны белә, шуңа күрә үзе дә яратып аны гел шулай сәламли.

– Сәлам! – Егет кызны кочаклады, аннары күтәреп алды, кычкырып бөтерелә башлады. – Сәлам, сәлам, сәлам! Сәлам, Сөмбел!

– Булды, булды, төшер, башым әйләнә, – дип ялварды кыз, чәбәләнеп. Аяклары җиргә тию белән, берничә адым артка күчеп, осталык белән үрелгән коңгырт чәч толымын, егет күрсен өчен, җиңел хәрәкәт белән алга, түш ягына күчереп салды. – Кайтканымны каян белдең?

– Машинагызны күрдем, – диде егет, кыздан күзләрен алмыйча.

Аның күз карашыннан кыз оялыбрак китте, хәтта тавышы да чак кына ишетелерлек чыкты:

– Сүземдә тордым, чәчемне үстерәм.
– Берүк кистерә күрмә, – диде егет.
Алар, култыклашып, суга таба атладылар.
– Болай сөйләшик. Син мине үпкәләткән саен, бераз кистерәчәкмен.
– Хәйләкәр кызый, чәчеңне кистерәсең килсә, тотасың да үпкәлисең, хәтта үпкәләрлек булмаса да.
– Юк инде, шаярып кына әйтәм. Сиңа ничек ошый, шулай үстерермен чәчемне. Монда киләсемне каян белдең?
– Без бит гел шушында очрашабыз.
– Әйе шул, – диде кыз куанычлы тавыш белән. – Ә кайсы вакытта киләсемне ничек чамаладың?
– Мин инде көндез үк килеп утырдым монда.
– Шундый сагындым сине, Вәсим! – диде кыз, тукталып.
– Минем сине ничек сагынганымны белсәң иде, Сөмбел!
Алар су буенда утыручы агайны абайлап алдылар. Һава бөркү булуга карамастан, ул кыршылып, бәсәреп беткән иске плащтан иде. Хәрәкәтсез-кымшанусыз, тирә-якка бернинди ригаясез су өстенә карап, ул үз уй-кичерешләре белән мәңге шушында утырырга дучар ителгән кыяфәттә иде. Аны сискәндермәс өчен, тавыш-тын чыгармыйча, яшьләр сак адымнар белән, сулгарак каерылып, таллыклар куерган якка юнәлделәр.
– Син үзең метеор белән кайттыңмы? – диде кыз, егетнең беләгенә ныграк ябышып.
– Әйе.
Сөмбел кинәт җитдиләнде, тавышында хәтта курку да яңгырады:
– Әтием Казанда очрашып йөрүебезне белә. Синең дә авылга кайтканыңны сизсә, хәлләребез мөшкел.
Вәсим туктап кызга текәлде:
– Ник, ул бит әле мине бөтенләй белми. Синең белән инде өч ел таныш булсак та.
Кыз егетне тагын култыклап алды, бернигә исе китмәгән кыяфәт белән алга таба атларга этәрде.
– Синең әтиең белән аның арасында ниләр булып беткәнне беләсең бит инде, – диде ул әкрен генә, күпмедер ара узгач. – Әтиеңнең язмышын тирә-якта белмәүче бар микән?
Вәсим тереләнеп китте:
– Минемчә, монда сәбәп әтиемнең язмышына бәйләнмәгән. Минем әтием белән синең әниең арасында мәхәббәт булган... сугышка кадәр. Шуңа мине өнәмидер.
– Синең ни гаебең бар! – диде Сөмбел уйчан тавыш белән.
– Ярар алайса... – диде егет, кинәт кәефсезләнеп.
Сөмбел үзендә теләсә кемнең кәефен бер мизгелдә күтәрә алу сәләте барлыгын яхшы сиземли. Аның чибәрлеге, иситкеч ягымлы тавышы, йөзенең пакь сылулыгы, күзләренең зәңгәрлеге каршында сулган гөл дә яңадан чәчәк атар, мөгаен.

– Аптырама бер дә! – диде кыз, егетнең җилкәсенә йомшак йодрыгы белән сугып. – Төшенкелеккә бирелмә!

– Күңелгә шөбһә керде, – диде Вәсим, кызны иңеннән кочып.

Сөмбел туктап, никтер, як-ягына карап куйды.

– Нинди шөбһә?! – дип пышылдады ул. – Бернинди шик-шөбһәгә урын юк. Мин сине яратам, Вәсим! Син миңа шундый кадерле! Син миңа шулхәтле якын кеше!

Аның бу сүзләрен инде моңарчы ишеткәне булса да, егетнең йөрәге ярсып тибә башлады, эчтә гәүдә буйлап көчле дулкын уйнап үтте. Ул кызның битен ике яктан, кош тоткандай, саклык белән генә тотты, иреннәре белән аның иреннәренә тияр-тимәс кайнар итеп пышылдады:

– Чын әйтәсеңме?

– Чын булмаса, сине абына-сөртенә әрәмәләр арасыннан эзләп йөрер идемме?! – диде кыз, елмаеп.

Кинәт кичке эңгерне яңгыратып, әрәмә ягыннан килгән тавыш кат-кат яңгырады: «Сөмбел! Кызым! Сөмбел!»

– Әти мине эзләргә чыккан! – диде кыз, сискәнеп.

Тавыш якынайгач, алар таллык арасына кереп качтылар.

37

Бу вакытта плащлы кеше исә какшамас кыяфәттә уйга чумып утыра бирде.

Сөмбелнең әтисе, як-ягына карана-карана, шуның янына юнәлде. Читтәрәк туктап беркавым карап торгач:

– Сәет, синме бу? – дип эндәште.

Утыручы башта әкрен генә кайшалды, аннары борылып карады:

– Мин бу, мин. Исәнме, Әнсар!

– Исәнме! Утырасыңмы?

– Утырам, – диде Сәет, кул биреп күрешкәч. – Һава яхшы монда.

– Әйе, һавасы әйбәт, – диде Әнсар, янәшә утырып. – Мондагыдай һава башка беркайда да юктыр. Әллә шулай тоела гынамы.

– Озакка кайттыгызмы? – дип кызыксынды Сәет, еракка төбәлгән килеш.

– Берәр атна торырга исәп бар, – диде Әнсар. Шуннан соң авылдашының ниләр уйлаганын аңлап өстәп куйды: – Мин дә шушында уйланып утырыр өчен ашыгып кайтам авылга.

– Әйе, тарта шул, тарта, – диде Сәет, авыр сулап. – Көнаралаш шушында килми кала алмыйм.

– Ни хәлләрең бар? – дип кызыксынды Әнсар, шактый вакыт сүзсез утырганнан соң.

– Ничек дип әйтим... Ничә ел үтте, яңа урынга тамыр җәя алмый җәфа чигәбез. Менә шундый хәлләр.

Әнсар кашларын җыерып, авылдашын гадәттәгечә тизрәк тынычландырырга, өметләндерергә тырышкандай кызу-кызу әйтеп куйды:

– Алай димә, алай димә. Авыл гөрләп яши бит. Тамырлар җәелеп килә.

– Барыбер без туып үскән авыл түгел инде ул, – диде Сәет тонык кына тавыш белән.

Әнсар, сүзне авыл тирәсеннән югарыракка, дөресрәге, ерагракка кертәсе килеп:

– Гомер уза-а-а, – дигән булды. – Гадәттә, ни әйтергә белмәгәндә ул гел шулай ди.

– Әйе, уза, – дип, аның сүзен куәтләде Сәет. – 1974 елның да яртысын яшәдек. – Ул арткарак каерылып як-ягына карады. – Син кемгәдер эндәштең, ахрысы?

– Кызымны эзләдем. Иртәгә кунаклар киләсе, әнисе җитешә алмый, эш күп. – Әнсар четерекле нәрсә турында сүз башлыйсы булганга тамак кырып куйды. – Очравың әйбәт булды әле. Яшьләребез турында синең белән сөйләшәсем бар.

Сәет, әңгәмәнең ни хакында барасын чамалаганга күрә, битараф кыяфәт белән үзе сүз башлады:

– Беләм, Яббарның улы белән синең кызың бер-берсен яраталар. Вәсимгә әйткәләп карадым инде мин. Үз кызың белән үзең яхшылап сөйләшү файдалырактыр.

– Егет кешедән дә күп нәрсә тора, – диде Әнсар, борсалануын яшермичә. – Син аның әтисе урынына калган кеше...

– Тагын бер мәртәбә әйбәтләп сөйләшермен. Аларның хисләре тирәннән, ахрысы, өч ел йөриләр бит инде. – Сәет көлемсерәп куйды. – Син шундый зур кеше, обкомда эшли торып кызыңны гына тыя алырсың, шәт.

– Көлмә, – диде Әнсар коры гына. – Кыз белән егет арасы – четерекле нәрсә.

Сәет күзләрен челәйтеп әңгәмәдәшенә карады:

– Су буена да кәчтүм-чалбардан килгәнсең. Обкомда кия торган кәчтүмеңме әллә?

Әнсар авылдашының чәнчүле сөйләшүенә аз гына да үпкәләмәде.

– Чыннан да, әрәмәдә мондый киемнән йөрү авыл халкы өчен сәердер, сүз дә юк. Беренчедән, шушындый киемгә мин күнеккән инде, икенчедән, бу юлысы алмаш кием алып кайтырга онытканмын, югыйсә спорт чалбарларым да, җиңел күлмәкләрем дә күп.

Сәет билен язар өчен иеленкерәп куйды:

– Яшьләр өлкәннәрнең сүзенә колак салырга бигүк яратмыйлар инде анысы.

– Болай начар егеткә охшамаган ул үзе, – диде Әнсар, көтмәгәндә.

Аның бу сүзе Сәеттә горурлык уятты:

– Менә дигән егет! КГУның тарих факультетына бернинди блатсыз керсен әле!

– Афәрин! Афәрин! – дип хуплады Әнсар.

– Яббар малае булганга борчылма инде син, бик әдәпле, яхшы тәрбия алган егет ул, – диде Сәет үтә җитди кыяфәт белән.

– Юк, юк, аның кем малае булуында түгел хикмәт, – диде Әнсар, бераз гасабиланып. – Ул да, кызым да бик яшьләр бит әле. Сак булсыннар, йөзгә кызыллык китермәсен дип борчылуым.

– Алар яшендә үзебез дә кызлар белән чуала идек инде, – диде Сәет, елмаеп. Шундук елмаю урынына аның йөзендә сагыш төсе күренде. – Ул вакытта әле Фатыйма киләчәктә синең хатының булыр дип уйга да килми иде.

Әнсарга исә әңгәмәнең бу өлеше никтер җылы тәэсир ясады. Коры гына, җанга ятышсыз әңгәмә корырга исәп итүен дә онытып, ул:

– Дөресен әйткәндә, Фатыйма Вәсимне бик ошата, – дип әйтеп салды. – Сөмбелебез бик әйбәт егет белән йөри, сүз әйтмә, ди.

– Шулай булгач! – диде Сәет, үзе дә сизмәстән кинәт укталып.

Әнсар уфылдап урыныннан кузгалды:

– Ярар, кайтыйм әле мин. Аларны күрсәң әйт, Сөмбелне әнисе көтә – иртәгәгә кадәр тәмамлыйсы эшләр күп.

– Очрасалар, әйтермен, – диде Сәет, утырган урыныннан кымшанмыйча.

Әнсар, кулын каш өстенә куеп, кояшны үзенә алган мәгърип ягына карап торганнан соң, салмак кына адымнар белән әрәмәлек буендагы сукмактан авылга таба атлады.

«Менә, Әнсар, язмыш ул ничек уйнаклый. Һаман безне бер үк сукмаклардан йөртә. Инде тормышлар үз калыбына кереп, баштан кичкәннәр бары тик хатирәләрдә генә калгандыр, күңел җәрәхәтләре генә булып саклана дигәндә, араларда яңа бәйләнешләр булырга тора түгелме? Яббар яшәешегездә мәңге катнашачак, ул исән, аннан башка тарихыгыз да, киләчәгегез дә юк дигән билге түгелме соң бу! Яббар, Яббар! Син, энекәшем, бәлки, барысын да күрәсеңдер, безне күзәтәсеңдер. Әгәр дә без күз алдында икән, син инде, мөгаен, күрәсеңдер – җан тынычлыгына беребезнең дә әле ирешә алганы юк».

Вәсимнең килеп чыгуын Сәет сизми дә калды, егет, якты елмаеп, абыйсы янына килеп утырды.

– Сөмбелең кайда? – диде Сәет, көлемсерәп.

– Сез Әнсар абый белән сөйләшеп утырган арада озатып куйдым, – диде Вәсим. Аннары сүзне икенчегә борыр өчен генә: – Күптән утырасыңмы? – дигән булды.

Җавап урынына ул коры гына сорау ишетте:

– Сөмбел белән Казанда да очрашасызмы?

Егет тереләнебрәк китте:

– Әйе.

– Ул медицинскийның нинди факультетында укый?

– Лечебный факультетында. Терапевт булачак.

– О-һо-о-о, – дигән аваз белән Сәет соклануын белдерде.

– Ул әле икенче курсны гына тәмамлады, – диде Вәсим, елмаеп.

– Син үзең инде олыгайдың – өченчене тәмамладың, – дип үчекләде аны Сәет.

– Шулай, – дип көлемсерәде Вәсим.

Сәет егеткә шактый вакыт текәлеп карап торды.

– Син аның кем кызы икәнен беләсеңме соң? – дип сорады ул, егетнең әллә кичке җиләслектән, әллә абыйсыннан шүрләүдән беләкләрендә бала йоннары кабарганга игътибар итеп.

– Беләм, – дип җавап бирде Вәсим, абыйсының күзләренә карарга базмыйча, карашын су өстендәге ераклыкка юнәлтеп. – Минем атам белән Әнсар абый арасында нәрсә булганын гына төшенеп бетмим.

– Мин аларның арасында ниләр булганны сөйләргә телим. Сөмбел инде беләдер. Аңа атасы йә анасы сөйләми калмагандыр. Сиңа да сөйләр вакыт җиткәндер.

Вәсим, шуны гына көткәндәй, кинәт Сәеткә таба борылды:

– Сөйлә!

Сәет озак сөйләде, сөйләгәндә, җаны сулык-сулык елады. Барысын да сөйләде. Инде караңгы төште, төн җитте, ә ул сөйләде дә сөйләде. Яббарның фаҗигасен дә, һәммәсенекен дә, һәрберсенекен дә яккан учакны яңарта-яңарта бәян итте.

Аның сөйләгәннәре Вәсим өчен зур ачыш булмады. Аңа мәгълүм булмаган нәрсәләр күп түгел икән ләбаса.

– Сәет абый, мин бит боларны белә идем, – диде Вәсим тыныч кына, абыйсы, ниһаять, бәянын тәмамлагач. – Син сөйләгәннәрнең күбесен әниемнән ишеткән идем инде мин. Әтием бит аңардан берни дә яшермәгән.

– Син бит әтием белән Әнсар абый арасында ни булганын белмим дигән идең.

– Белмим түгел, төшенеп бетмим дигән идем мин.

– Ә Сөмбелең беләме соң?

– Белә.

– Беләдер шул, Әнсар сөйләми каламы соң инде.

– Әтием әнигә туган авылы турында, табигать турында, авыл кешеләре турында шундый оста, матур итеп сөйли торган булган. Шунысы кызык: ул һәрвакыт авылыбызда бик яхшы кешеләр, матур, эшчән халык яши дип сөйләгән, гәрчә авылдашлары аны дошман итсә дә. Улыңны Кызылъярга алып кайтачаксыңмы, дигәч, бераз үсә төшсен әле, үскәч алып кайтырмын, дигән булган ул әнигә.

Сәет дымланган күзләрен кул арты белән сыпырып алды:

– Син безнең нәселнең дәвамы, синең тамырлар монда, шуны онытма, Вәсим.

– Сәет абый, шулай да... әтием батып үлдеме?

– Төгәл әйтә алмыйм. Бәлки, көймәне агым иркенә куеп агып киткәндер. – Аның тавышында кинәт катгыйлык яңгырады: – Юк, юк, юк! Ул батмады, ул китеп барды. Бездән китте. Әнкәй янына китте. Ул үлмәде. Ул әнкәебез янына китте. Әнкәй исән чакта кешеләрнең мыскыллавына да, рәнҗетүләренә дә түзәргә риза иде. Әнкәй үлгәч, кимсенүнең генә түгел, яшәвенең мәгънәсен югалтты ул. Иң авыр чагында аны бердәнбер кеше ташламады һәм яратты – әнкәй. Ә без, калганнарыбыз, бары тик менә шушында килеп, авыл белән зират баткан тарафка карап, Яббар агып киткән тирәне күзләп, офтанып, үкенеп кенә утыра алабыз. Юк! Ул батмады! Синең атаң Яббар батмады, юкка чыкмады! Ул әнкәй янына китте. Бу салкынлыкка, бу вәхшилеккә түзалмыйча, аз гына булса да җылылык өмет итеп, әнкәй янына китте ул.

38

Әй язмыш! Бигрәк сәер һәм шул ук вакытта кызык бу дөнья. Сөмбелнең әнисе Фатыйма белән Вәсимнең әтисе Яббар яшь чакта бер-берсен яратканнар. Ә менә хәзер, еллар үткәч, Яббарның улы белән Фатыйманың кызы арасында кайнар мәхәббәт, алар бер-берсен минут саен сагынып яшиләр, киләчәкне фәкать кулга-кул тотышып барган сурәттә генә күзаллыйлар.

Вәсимнең әтисенә ниләр генә күрергә туры килмәгән, башкайларына ниләр генә төшмәгән һәм Әнсар абый белән аның арасында ниләр генә булып бетмәгән! Ә барыбер әтисе белән Әнсарны дошманнар итеп күз алдына китерәсе килми Вәсимнең. Әнсар абый бит Сөмбелнең әтисе! Ә Яббар – аның үзенең әтисе! Аның күңеленә бу ике кеше дошманнар булып һич кенә дә сыймыйлар, хәтердә дә дошман булып сакланырга тиеш түгел алар һәм элек тә дошманнар булганнардыр дип ышанасы килми.

Вәсим Әнсар белән очрашуны үзе эзли башлады, ничек булса да Сөмбелнең әтисен аулакта очратып сөйләшү теләге аны инде ныклап борчый... эләктереп алды. Һәм андый мөмкинлек үзен озак көттермәде.

Авылга кайткач Әнсар кичкә таба су буена төшми калмый – моны Вәсим яхшы белә һәм ул беркөнне, эңгер-меңгер вакытта, ышанычлы адымнар белән ярда ялык-йолык янган учак янына юнәлде.

– Исәнмесез, Әнсар абый! – дип эндәште Вәсим, читтәрәк туктап, учак янында утыручыга.

Әнсар, егетнең килгәнен күрмәгәнгә, сискәнеп китте.

– Исән, – диде ул, кырын яткан җиреннән чак кына калкынып.

– Мин – Вәсим, Яббарның улы, – диде егет, якын килеп.
– Мин сине беләм. Нишләп йөрисең?
– Сезне эзләп килдем.
– Мине эзлисе юк. Утыр учак янынарак. Калтыранасың.
– Каушаудан ул, – диде Вәсим, учак янына утырып.
– Каушаудан?! – дип көлемсерәде Әнсар. – Рас минем кызым артыннан йөрисең икән, син әйдә каушама инде. Безгә каушый торган кияү кирәкми. Хәер, бераз каушавың ярый анысы. – Ул шактый вакыт егеткә дикъкать белән карап торды. – Сөмбелне кыерсытма, яме, сак бул.

Вәсимнең учак җылысыннан кызарган бите тагы да ныграк яна башлады.

– Ничек инде кыерсытыйм мин аны! – диде ул, аптырап. – Яраткан кешеңне ничек кыерсытмак кирәк, Әнсар абый!

Әнсар, егеткә сынаулы караш белән карап:

– Син аны яратасыңмыни? – дип гаҗәпләнгән булып кыланды.

– Яратам, Әнсар абый! – диде егет ихластан.

Әнсар көлеп куйды:

– Үзе каушыйм ди, үзе, авыз тутырып, курыкмыйча, минем кызымны яратам дип утыра.

– Мин дөресен әйттем, – диде Вәсим, чыннан да нык каушавын көчкә йөгәнләп.

– Кайвакыт дөресен әйткән өчен дә эләктерәләр, – диде Әнсар серле тавыш белән.

Вәсим торып басты, беравык сүзен әйтә алмый торды, аннары кызып-кызып ярды да салды:

– Теләсә нишләтегез. Мин Сөмбелне яратам, аңардан башка яши алмыйм! Теләсә нишләтегез. Бәреп үтерсәгез дә риза!

Әнсар гәүдәсен арткарак каерып рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Вәсим аның көлүен ничек кабул итәргә белми аптырашта калды. Әнсар, кинәт җитдиләнеп:

– Бәреп үтерсәң дә... – дип уйга калды. – Юк инде, – диде ул, тирән сулыш алып. – Әшәкелекнең дә чиге булырга тиеш. Утыр әле, утыр. – Ул, гәүдәсен турайтып, егетне җиңеннән тартып янәшә утыртты. – Шушы хәтле атаңа охшасаң да охшарсың икән. Бөтен килеш-килбәтең атаңныкы. – Егетне аркасыннан кагып куйды. – Маладис!

Вәсим Әнсарның аталарча мөнәсәбәтеннән җаны-тәне буйлап аңлатып булмаслык дулкын йөгергәнен тойды, уңайсызланып башын читкә борды.

– Бу – Сәет абыйның да яраткан урыны, – диде Вәсим, сүзне җиңелрәк агымга кертәсе килеп. – Ул да монда озак-озак утырырга ярата.

Әнсар шактый вакыт куртка кесәләрен капшады, инде берничә тапкыр ян кесәдәге папирос кабына учы белән кагылды кагылуын, әмма куллары берне эшләсә, уйлары башкада иде аның, тәмәкесен

һаман эзләде дә эзләде. Ниһаять, папирос кабын кесәсеннән чыгарды да, учак кырыннан башы янган кисәүне алып, тәмәкесен кабызды.

– Безнең башка чарабыз юк инде, Вәсим, – диде ул, тирән итеп папиросын суыргач. – Шушылай утырасы гына калды. – Ул егеткә тагын текәлеп карады. – Син атаңа охшагансың. Ул әйбәт кеше иде. Яббар күргәннәрне күрергә язмасын... Сиңа гына түгел, беркемгә дә күрсәтмәсен...

– Нәрсәләр күрергә язгандыр инде, белгән юк, – диде Вәсим, олыларча уйга калып.

– Сезгә миһербанлырак замана килде. Кадерен генә белегез.

– Ярый ла ул заманның кадерен белеп, синең үзеңнең дә кадереңне белсәләр.

– Киләчәк сезнең, яшьләрнең кулына тапшырыла. Кеше кадерен белә торган җәмгыять төзегез. Коммунизм төзүне сез дәвам итәчәксез, хәзер инде калганы сездән тора. – Әнсар башын калкытып су өстенә карады. – Бөтен илне батыра гына күрмәгез.

– Кешенең кадерен ничек белсеннәр... Кеше хәтта үз фикерен дә әйтә алмый бит.

– Үз фикерен дип... Нинди фикер бит... Коммунистлар партиясенең фикеренә каршы булса, ул, әлбәттә, дөрес фикер түгел, аны әйтүнең кирәге юк.

– Зиратларны су астында калдыру фикере кемнеке? – диде Вәсим, ачыргаланып. – Тарихыңны бульдозерлар белән сөрдереп, күмеп, суга батырып калдыру аерым кеше ниятеме, әллә партиянекеме?

Әнсар эчке сискәнү тойды. Ул хәтта куркып китте дисәң дә ялгыш булмас. Ул кискен хәрәкәт белән тәмәкесен учакка ташлады.

– О-о-о, Вәсим энем, алай сөйләшмә, үтенеп сорыйм, алай сөйләшмә, – диде ул, пышылдап. – Кирәкмәгән нәрсәне төзергә беркем дә тотынмый. Зур төзелешләр, ГЭСлар идеясе аерым кешеләр башында туа, ләкин ул идеяләр Ленин партиясе, Коммунистлар партиясе таләбе буенча туа. Мәскәүдә, Политбюрода, ЦКда авылларның, зиратларның су астында калуын телиләр дип уйлыйсыңмы әллә син?!

– Анысы шулай. Ә аерым кешенең кадерен белү?!

– Соң, шул аерым кеше өчен төзелә бит инде барысы да.

– Кемнедер җәберләп, кемнедер кимсетеп, кемнедер батырып башкалар өчен нәрсәдер төзү дөрес микән?

Әнсар белә: егеткә акыл өйрәтеп, нотык укып утыруда мәгънә юк. Яшь әле ул, ләкин сүзе хак. Шуңа күрә куркып китте Әнсар. Туган якның фаҗигасен, атасының фаҗигасен үз йөрәге аша үткәрүче япь-яшь җан иясе дөрес сүзләр сөйли, бәгырьләргә кадалырлык фикерләр әйтә. Ничек сискәнмисең дә, ничек куркып китмисең?!

– Бик яшь әле син, – дип салкын гына елмайды Әнсар. –

Берүк анда, университетта, мондый темалар күтәрмә. Мин – тәҗрибәле кеше. Утны-суны кичтем. Синең өчен борчылып әйтәм: сак бул, артыгын сөйләшмә.

Вәсим, кабаланып, курткасының куен кесәсеннән блокнот чыгарды:

– Мин бер справочниктан укыдым, аны язып та алдым. – Ул учак яктысында кирәкле битне табып укырга тотынды: – «Куйбышевское водохранилище, в среднем течении реки Волга. Образовано плотиной Волжской ГЭС им. В.И.Ленина. Заполнено в 1955–57 годах. Площадь 5900 кв.км, объем 56 куб.км, длина 510 км, наибольшая ширина 27 км. Судоходство. Используется для орошения и водоснабжения. Рыболовство. На Куйбышевском водохранилище – порты Ульяновск, Тольятти и др.». Менә Әнсар абый, кыска гына мәгълүмат, коры гына саннар, ә күпме югалту, күпме фаҗига ята шушы су астында – бу хакта бернинди мәгълүмат юк.

– Их, энем, энем! – диде Әнсар, авыр сулап. Аның тавышы калтырый башлады. – Без барыбыз да бу турыда уйлыйбыз, кайгырабыз. Без теләгәнчә генә бармый шул тормышлар. Син тарих факультетында укыйсың, тарихчы булачаксың, күп нәрсәне эзләп, казып табачаксың, аңлаячаксың. Әлбәттә, барысын да әйтергә мөмкин булмас, ярамас... һәм кирәк тә түгел... Сез – яңа буын – безне вакыты җиткәч аңларсыз. Син әле яшь...

– Сез мине ачуланмагыз инде, – диде Вәсим боек тавыш белән. – Әгәр дә дорфарак сөйләшкәнмен икән, гафу итегез.

– Юк-юк, гафу үтенеп утырма, – диде Әнсар һәм егетне аркасыннан сөеп куйды. – Бик акыллы егет син... Син хаклы, ләкин... сак бул. Үзеңә хилафлык килмәсен.

Әнсар кайтып китте, Вәсим учак янында утырып калды. Ул үзе әңгәмәдән бик канәгать иде, Әнсар абыйга да ошады бугай бу сөйләшү дигән тойгы исә учак ялкыныннан да җылырак иде.

Шулай утка текәлеп әле генә узган сөбхәт тәэсирендә утырганда, шатлык өстенә шатлык өстәп, аның янына Сөмбел килде.

– Төшемме бу, өнемме?! – диде Вәсим, курткасын кызның иңенә салып.

Сөмбел түземсезлек белән егеткә текәлде:

– Нәрсәләр сөйләштегез?

Вәсим, кулын өскә күтәреп, бормалы хәрәкәтләр ясады:

– Сәясәт, халыкара обстановка... Әнә шундый җитди темаларга.

– Әйт инде.

– Әйттем бит инде.

– Ә безнең турыда?

Вәсим елмаеп кызны иңеннән кочты:

– Юк, сөйләшмәдек.

– Сөйләшкәнсез, сөйләшкәнсез, – дип бармак янады кыз.

– Белгәч, ник сорыйсың?

Сөмбел ярга таба атлады:

– Ә-ә-нә тегендә булган Кызылъяр авылы. Күптән түгел монда каяндыр укучылар экскурсиягә килгәннәр. Укытучылары сөйли икән, имеш, Кызылъярның бер кешесе читтән кайткан һәм... үзенең туган авылын тапмаган. Су астына киткән зиратта анасының кабере дә калган икән. Бу кеше беркөнне көймәгә утырып шул тарафка агып киткән дә кире кайтмаган. Шуннан соң аны беркайчан беркем күрмәгән. Ул юкка чыккан.

– Ул әнкәсе янына агып киткән, – дип, Вәсим кызны кочагына алды.

– Күрәсеңме, ул тарафлар ай калыккач ныграк яктырган сыман, – дип пышылдады кыз.

– Миңа да шулай тоела, – дип пышылдады егет.

– Мин әниемнән бер җыр отып алдым, җырлыйммы?

– Җырла, Сөмбел, син матур җырлыйсың.

Яулыгымның чите белән
Авызымны капладым,
Тын алырга да базмыйча
Әкрен генә атладым.

Авазың ишетмәмме дип
Туктадым. Өнсез торам...
Нинди яулык белән каплыйм, –
Җаным җыларга тора.

– Бигрәк моңлы җыр, – дип, егет кызны битеннән үпте.

Вәсим тоз тәмен тойды – кыз елый иде.

Бәхетле күз яшьләрендә үткәннәрнең кайгы тәме бар иде.

Шунда Вәсим аңлады: Сөмбел аның әтисенең, аларның нәселенең кайгысын да үзенекедәй кабул итә. Сөмбел аны ярата, ярата, ярата! Нәселенең барлык кайгы-хәсрәтләре белән, чынбарлыктагы яшәешнең азмы-күпме шатлыклары белән бергә кабул итеп ярата!

39

XXI гасырның бишенче елында Идел сусаклагычына илле ел тулды. Шул уңайдан кемдер экскурсия оештырган – олы яшьтәге укучылар төркеме томан арасыннан су буена килеп чыктылар.

Бу вакытта ярда унҗиде-унсигез яшьлек бер үсмер егет су өстеннән еракка карап басып тора иде.

Шактый олы яшьтәге җитәкче хатын, күрәсең, класс җитәкчеседер, күп сөйләүдән карлыккан тавышын һаман кызганмыйча нәрсәдер сөйләде дә сөйләде. Су кырында басып торган егеткә аның тавышы отыры ачык ишетелә башлады.

– Балалар! Экскурсиябез дәвам итә. Хәзер инде 2005 ел. Узган гасырның нәкъ уртасында, 1950 елны төзелә башлаган ГЭСның нәтиҗәсе буларак җәелгән бу диңгез. Чынлап та, моны кеше үз кулы белән тудырган диңгез дип атарга мөмкин. Ләкин шуны да онытмаска кирәк: ә-ә-әнә теге калкулыкта урнашкан авыллар алар үз урыныннан күчерелгән авыллар. Алар су астында калган авыллар дип тә әйтергә хакыбыз бар, чөнки тарихи урыннары, зиратлар, бик күп йортлар, каралты-куралар күчерелми кала. Әнә теге Аулаш тавы итәгендә урнашкан авылның исеме Кызылъяр. Шул авылның бер кешесе хакында төрле риваятьләр йөри. Яббар атлы кеше, сугыш ветераны, авылларны, зиратларны су басканчы тизрәк күчерергә кирәк дип югары инстанцияләрдә йөргәне өчен төрмәгә утыртыла. Үзегез беләсез, коммунистлар режимы... Бу кеше төрмәдә чакта аның анасы үлә. Яббар төрмәдән кайткач күрә – авыл халкын, йортлар салып, Аулаш тавына күчергәннәр, ә туып үскән авылы, анасы күмелгән зират су астында калган. Бу кеше көймәгә утырып туган авылы баткан тарафка йөзеп китә. Шуннан бирле аны беркемнең күргәне юк. Кемдер әйтә, рәнҗеп, көймәгә утырган килеш агым белән каядыр аска таба агып киткән, ди. Кемдер әйтә, батып үлгән, ди. Кемдер әйтә, үз теләге белән су төбенә киткән, ди, кемдер әйтә, су төбендә әнисенең каберен табарга маташканда баткан, ди.

Шунда бер укучы малайның тавышы ишетелде:

– Ул кеше сугышта сатлыкҗан булган, диләр. Имеш, легионер булган.

– Юк, дөрес түгел, – дип җавап бирде класс җитәкчесе. – Мин Кызылъяр кешеләреннән сораштырганым бар. Юк, сатлыкҗан булмаган, диләр. Авыллар, зиратлар турында күп шаулап йөрмәсен өчен, югарыдагы түрәләр аның хакында юри шундый хәбәр таратканнар, дип сөйли халык. Аны хәтта изге кеше дип санаучылар да бар.

– Аны эзләп тә карамадылар микәнни? – дип сорады бер кыз.

– Күрәсең, бу тарафтан китеп барган дигән версиягә күбрәк ышанганнардыр, – диде экскурсия җитәкчесе.

– Эзләргә теләүче булмагандыр инде, – диде берсе. – Мөгаен, батып үлгәндер ул.

Ярда басып торган егет экскурсантларга таба атлады:

– Дөресен мин беләм! – дип эндәште ул экскурсантларга.

– Ә сез кем буласыз? – дип мөрәҗәгать итте аңа класс җитәкчесе.

– Минем исемем Мөнәвир. Мин чыгышым буенча шул Кызылъяр авылыннан.

Класс җитәкчесе егетне җентекләп күзәтте:

– Кем малае буласың, мин ул авылның кайбер кешеләре белән таныш?

– Әтием Вәсим, әнием Сөмбел исемле.

– Хәтерләмим, – диде укытучы беравык, кашларын җыерып, Кызылъяр кешеләрен хәтерендә барлап торганнан соң. – Зур авыл бит ул. Дөресен беләм, дидең, ахрысы?

– Әйе, беләм, – диде Мөнәвир. – Ул Яббар атлы кеше батмаган. Агып та китмәгән. Ул бүгенге көнгә кадәр туып үскән авылын, әнкәсенең каберен, уйнап үскән болын-кырларын эзләп йөри. Кешеләр үз куллары белән ясаган диңгездә – вәхшилек, битарафлык диңгезендә – ерак бабалары күмелгән зиратны мәңге эзләп йөзеп йөриячәк ул.

– Ә сез каян беләсез? – дип гаҗәпләнде класс җитәкчесе.

– Беләм! Чөнки мин – Яббарның оныгы!

2004 – 2009

ПОВЕСТЬЛАР

КУРКУ

Ресторанның тынчу кочагыннан котылгач, күзге урамның һавасын сулап, гаҗәеп бер рәхәтлек тойдым. Өемә кадәр шактый гына ара булса да, җәяүләп кайтырга уйладым – сентябрьнең сулышы шулкадәр сихерле һәм назлы иде. Исерек авазларның шавыннан, аракы, тәмәке, тир исеннән исән-имин килеп чыкканнан соң, төн уртасыннан атлап барганда үзеңне табигатьнең тулы хокуклы бер әгъзасы дип хис итәсең, һәм бу халәт тынычландыра, тәнгә ял бирә, башка да уйларның яктыраклары керә башлый.

Шәһәр кечкенә булганлыктан, урамнарда инде кешеләр ыгы-зыгысы юк, машиналар да берән-сәрән генә үтеп китәләр, һәм аларның тавышы көзнең моңсу тынлыгына зыян китерми иде.

Ресторанда җырлый башлаганыма алты ел инде, аракысы да, музыкасы да, хатын-кызлар да – барысы да шактый ардырды. Сугышулар һәм кыйнашулар да булмады түгел. Ләкин барыбер бу эштән һич кенә дә китә алмыйм, дөресрәге, ычкына алмыйм.

Моның сәбәбе бер генә – җырга, сәхнәгә гашыйклыгым. Бу авыруга дәва табып була микән?.. Ни дисәң дә, провинциядәге шәһәрдә бердәнбер профессиональ сәхнә бары тик ресторанда гына.

Инде аракы эчүне дә ташладым, дөньямны онытып теләсә нинди хатыннар белән пычрак фатирларда кунып йөрүләремне дә туктаттым, дөньяга карашларым соңгы вакытта кискен үзгәрде, күңел чын иҗатны эзли, аңым белән түгел, ниндидер аң астындагы акыл белән чын сәнгатькә тартылам. Тик һаман да әле ресторан сәхнәсеннән төшеп китә алмыйм. Җырлыйм... Һәм бу шөгылемнән мәңге туктый алмам кебек. Инде югыйсә җан бизәрлек булмады түгел. Исерек чырайлар, әшәке сүзләр, кычкырыш, талаш, сугыш, аракы һәм дуңгыз мае исе, шомлы ыгы-зыгы – болар барысы да рестораннан кайтып йокларга яткач та башымда гөжләп бимазалый.

Бу юлысы, көзнең саргылт диңгезендә йөзеп, нервыларны тынычландырып, әкренрәк кайтырга булдым.

Арттан кемдер килә иде. Мин үземнең урамга борылдым, артымнан килүче дә борылды. Миндә бернинди шик-шөбһә юк иде, чөнки кичке урамда, шушындый матур төндә кем булмас та кем йөрмәс. Әнә каршыма кыз белән егет очрадылар, әнә юлның теге ягыннан тагын кемдер үтеп бара.

Шулай да, бара торгач, күңел тынгысызлана башлады, чөнки артымнан килүченең күз карашын җилкәм белән, нервыларым белән тоеп атлыйм.

Кайтып җитәргә тагын дүрт квартал бар иде. Кызурак атлый башладым. Ул да адымнарын тизләтте. Борылып карарга исәбем бар иде, ләкин андый вакытта артка карарга нәрсәдер комачаулый, куркыта, кемдер эчтә «Карама!» дип боерган кебек була. Артка күз ташларга җөрьәт итмичә, мин юлымны дәвам иттем.

Ул мине подъезд янында куып җитте.

– Исәнмесез! Сөйләшергә иде сезнең белән...

– Исәнмесез!

Өч сәгать буе җырлаган булсам да, каушаудан тавышым калтырабрак һәм нәзекләнеп чыкты. Әмма аның «сез» дип дәшүе һәм зыялы кыяфәте мине шунда ук тынычландырды.

– Сез ресторанда җырлыйсыз бит? – диде ул.

– Шулай.

– Сезнең исемегез Илдармы?

– Әйе.

Подъезд өстендәге лампа яктысында мин аны аермачык күрдем. Утыз-утыз биш яшьләрдәге ир-егет иде ул. Джинсы чалбардан, җиңел курткадан, аякларында кроссовка иде. Кара күзле, кара кашлы, борынгы грекларныкы кебек туры борынлы, юка иренле, куе бөдрә чәчле бу кешене артистка да, берәр кечкенә предприятиенең башлыгына да, спортчыга да, фарцовщикка да охшатырга мөмкин иде. Аның озын, уртача тазалыктагы гәүдәсеннән һәм килеш-килбәтеннән тауларны җимерердәй сәламәтлек бөркелеп тора иде.

Ә менә чем-кара күзләре куркыныч иде аның. Андый күзләргә озак карап булмый, андый күзләр белән очрашкач, тизрәк, ярдәм эзләгәндәй, читкә карарга тырышасың.

Күрәсең, артымнан атлаганда мин аның күз карашын тикмәгә тоймаганмын. Мондый күзләр сыртыңны гына түгел, таш диварны да тишеп керер сыман.

– Тыңлыйм сезне, – дидем мин.

– Әйдә, утырыйк әле, – диде ул, подъезд янындагы эскәмиягә ымлап.

Ул бик озак дәшми утырды. Ниһаять, түзмәдем:

– Ни йомышыгыз бар иде миндә? – дидем.

– Сез Айгөл янында еш буласызмы? – диде ул, ниндидер таләпчәнлек белән.

– Нинди Айгөл янында? – дидем мин һәм, сүзнең кем турында барганын аңларга тырышып, Айгөл исемле хатын-кызларны хәтеремдә барлый башладым.

– Техникумда укытучы булып эшләүче Айгөл.

«Ә-ә-ә, Айгөл! Айгөл Хәбировна... Менә кем турында сорый икән ул».

– Аның янына биш айлап барганым юк инде, – дидем мин, пошаманга калып.

Айгөлне белмим дип әйтүдә мәгънә юк иде, чөнки бу кеше белмичә килмәгән, ул, әлбәттә, минем белән Айгөл арасында булган мөнәсәбәтләрне беләдер. Тик менә кеме икән ул аның – иреме, егетеме, абыйсымы...

– Сез аны яратасызмы?

– Юк, – дидем мин.

– Ә ул сезне ярата...

Әйе, беләм, Айгөл мине ярата. Без аның белән бер елга якын очрашып йөрдек. Авырга узды, бала тапмакчы булды. Минем битарафлыгымны күреп бимазаланды. Аборт ясатты.

Мин аның белән ресторанда танышкан идем. Бик чибәр ул, мәхәббәт дигән нәрсә аңардан кайнап, бәреп тора. Тик аны бик күпләр назлаган, бик күпләр таптаган инде. Андыйлар ресторанда күп була. Үзенең кайнарлыгы, дәрте, матурлыгы белән ул мине әсир итте һәм аның кочагында бер ел дөньямны онытып яшәдем. Ләкин яраттым дип әйтә алмыйм. Мәхәббәт түгел иде бу, үземнең чын ирлегемне, булдыклылыгымны күрсәтү һәм тагын бер кат шуны табигать алдында исбатлау гына иде. Шулай да ярату хисләре бөтенләй үк булмады дип әйтмәс идем. Үзенә тарткан икән, димәк, нәрсәдер булган... Хайвани мөнәсәбәтләр генә түгелдер инде, чөнки аның белән кызык та, рәхәт тә иде. Әкренләп «айный» башладым һәм аңа карата тора-бара тәмам суындым. Ул артымнан йөрде, мин аңардан качу ягын карадым. Бераздан ул да тагылып йөрүдән туктады, менә биш ай инде күрешкәнебез юк.

– Сез йоклыйсыз мәллә? – дигән тавыш мине уйлар дингезеннән йолкып чыгарды.

– Айгөл белән минем арада инде бернинди дә элемтә-мазар юк, – дидем мин. – Гафу итегез, ә сез аның кеме буласыз?

– Беркеме дә түгел. Әле хәзерге вакытта беркеме дә түгел... Ошый ул миңа... Мин аны үземнеке итәргә телим.

Эчемә бераз җылы йөгерде. Шатлыгымны тыя алмыйча көлеп җибәрдем.

– Уф, котымны алдыгыз. Сез Айгөлнең иредер дип курыктым... – дидем мин. – Кайберәүләр бит, өйләнгәч, хатынының элек булган тарихларын актарып, сораштырып, төпченеп, көнләшеп йөриләр.

Әңгәмәдәшем миңа кушылып көлмәде, хәтта елмаймады да. Аның чыраенда һаман да төкселек саклана иде.

– Бигрәк тә сезгә бик күп мөрәҗәгать итәләрдер, – диде ул кырыс кына.

– Кемнәр?..

– Сез бозып йөргән, сез әвәләгән хатыннарның ирләре.

Мин ни әйтергә белми аптырап калдым. Аның тавышы калын, коры һәм роботныкына охшаган иде. Ул һәр сүзен ачык итеп, яңакка китереп суккандай, пичәтләп әйтә иде.

– Юк, алай бик интектермиләр, – дидем мин.

– Нишләп икән?.. Сез бит, ресторан музыкантлары, шәһәрнең бөтен кызларын, хатыннарын татып яшисез...

Мин үземне бераз җәберләнгән сыман хис иттем, һәм:

– Нигә алай дисез? – дидем. – Мәсәлән, мин үзе теләгән хатын-кыз белән генә йоклый алам. Минем беркемне дә көчләгәнем, алдаганым юк.

Шушындый төксе һәм бәхәсле темага таныш булмаган кеше белән төн уртасында бер-беребезгә «сез» дип дәшеп сөйләшеп утыру миңа бик сәер һәм авыр тоелды.

– Карагыз әле... гафу итегез... Сезнең исемегезне дә белмим, – дидем мин.

– Минем чын исемемне белү сезгә кирәк тә түгел. Миңа Арнольд дип дәшегез.

– Арнольд, сезне Айгөл кызыксындыра инде алайса... – дидем мин, тизрәк бу әңгәмәгә нокта куярга ашыгып.

– Хәзерге вакытта мине сез кызыксындырасыз! – диде ул һәм текәлеп карады.

Аның күз карашыннан миңа эссе булып китте. Үземне никтер кем алдындадыр гаепле хис иттем.

– Нишләп мин кызыксындырам соң сезне? – дидем, аңа карамаска тырышып.

– Сез чынлап та аны яратмыйсызмы?

– Юк.

– Ә мин аны яратам.

– Арнольд, рәхәтләнеп яратыгыз, мин бит сезгә комачауламыйм.

– Комачаулыйсыз.

– Ничек инде комачаулыйм?!

– Ул бит сезне оныта алмый...

– Мин гаепле түгел бит инде... Онытыр әле.

– Кем гаепле соң?..

Бу бәйләнү мине туйдыра башлады.

– Гафу итегез, Арнольд, – дидем мин, өйгә кереп китәргә кузгалгач, – миңа Айгөл кирәк түгел. Безнең арада нидер булган икән инде – булган да беткән... Арыдым мин, миңа ял итәргә кирәк.

Эскәмиядән торгач, Арнольд каршыма килеп басты.

– Сез Айгөл янына барып тагын бер тапкыр «Мин сине яратмыйм!» дип әйтергә тиешсез! – диде ул.

– Ул моны болай да бик яхшы белә.

– Сез тагын бер тапкыр барып әйтергә тиеш!

– Ярар, әйтермен, – дидем мин, аның күз карашы белән очрашмаска тырышып.

– Шуннан соң күз күрер...

Куркыныч кеше иде бу. Ресторанда әллә нинди шпаналар, сугыш чукмарлары белән аралашырга, исерек маньяклар арасында еш чуалырга туры килсә дә, мондый кешене беренче мәртәбә күрүем иде. Моңарда нindiдер коточкыч көч бар! Юка гына кабык булып эленеп торган әдәплелеге аша аның эченнән йөгәнсез нәфрәт ыргылып чыгарга һәм кирәк чакта китереп тибәргә әзер тора иде.

– Сау булыгыз! – дидем мин.

– Алга таба күз күрер, – диде ул, саубуллашуыма җавап итеп.

– Сез нәрсә әйтмәкче буласыз? – дидем мин, аптырап.

– Мин шуны әйтмәкче булам... Әгәр ул сезне оныта алмаса, сез юкка чыгарга тиеш...

Бу сүзләрнең мәгънәсен ничек аңларга да белмәдем. Мине күп тапкыр куркытканнары бар, янаганнары да. Ләкин бу кешенең сүзләре нишләптер бик нык тәэсир итте. Кәефем тәмам кырылды. Һәм бу төн убырыннан тизрәк качасым килде.

– Аңладыңмы? – диде ул боерулы тавыш белән.

– Аңладым, – дидем мин.

Лифт эшләми иде, бишенче катка җәяү менәргә туры килде.

Утны кабызганчы түргә үтеп тәрәзәдән тышка карадым. Ул әле һаман шунда басып тора иде.

Утны кабызгач та бер бүлмәле фатирым караңгылыктан арынмаган кебек тоелды. Тагын тышка күз салдым. Ул минем тәрәзәмә карап тора иде. Аның әкрен генә китеп баруын күргәч кенә бераз тынычландым.

Кайткач хикәя язарга утырырмын дигән идем, ләкин кәеф тә, дәрт тә, илһам да юкка чыккан иде.

* * *

Бу вакыйгадан соң атна-ун көн вакыт үтте.

Үзен Арнольд дип атаган сәер кешене онытмасам да, аның белән әңгәмәм хәтеремдә дә, күңелемдә дә бик үк зур урын алып тормый иде. Кыскасы, мин аның таләпле үтенеченә артык әһәмият белән карамадым һәм дә аның үзен тотышын, кырыслыгын җавапсыз мәхәббәт галәмәтенә бәйледер дип уйладым.

Була бит шундый хәлләр – син яратасың, ә ул сине – юк. Андый вакытта күңел халәте яңгырлы көзгә охшый. Шуңа күрә Арнольдның миңа мөрәҗәгать итүе, безнең мәгънәсез (минем уйлавымча) сөйләшү аның Айгөлне үзенеке итә алмаудан, мәхәббәттән ярсыган йөрәге кушуы буенча килеп чыккан нәрсә дип, үземдә тынгылык таптым.

Соңгы вакытта шактый күп яздым, күбесенчә шигырьләр. Рестораннан көннән-көн күңелем бизеп килә, ләкин шул кечкенә сәхнәне ташларга һаман үземдә көч табалмыйм.

Ул көнне иртәрәк кайттым, кичке уннар тирәсендә. Соңгы вакытта невроз белән интегә башладым. Шул сәбәпле кайвакыт, ансамблебезнең җитәкчесеннән рөхсәт алып, иртәрәк кайтып китә идем.

Кайтып чәй эчәргә генә өлгердем, ишек кыңгыравы зеңгелдәде. Барып ишекне ачсам, каршымда Арнольд басып тора. Капкара кәчтүм-чалбардан һәм ак күлмәк белән галстуктан.

– Нихәл! – диде ул.

– Исәнмесез!

Аны өемә кертәсем килмәгән иде. Ул моны аңлады бугай, һәм:

– Чакырылмаган кунак татардан да яманрак, – дип елмаерга тырышты. – Шулай да өй эченә узарга рөхсәт ит!

Һәм рөхсәтемне дә көтмичә өйгә керде. Аның «син» дип дәшүе, фамильярлыгы мине хәйран каушатты.

Мин:
– Рәхим итегез, – дими булдыра алмадым.
Теге вакыттагы кебек ул бик озак дәшми утырды.
– Бик бай яшәмисең икән, – диде ул, ниһаять. – Ресторанда эшләүче музыкант бай булырга тиеш ләбаса.
– Юк, музыкант кеше, гомумән иҗат кешесе безнең илдә, кайда гына эшләсә дә, бай булалмый, – дидем мин.
– Алай икән... Карале, Илдар, син нишләп минем гозеремне үтәмәдең?
Сүзнең ни турында барганын мин, әлбәттә, аңладым.
– Арнольд, бик әйбәтләп аңлаттым бит инде – миңа Айгөл кирәк түгел, теләсәң нишлә...
– Син мине шаярып йөри дип белдеңме әллә?!
– Әгәр дә инде син егет кеше икәнсең, аны яулап алу, үзеңнеке итү синең шәхси эшең, – дидем, тынычрак күренергә тырышып. – Сиңа бит беркем дә комачауламый, киртәләр куючы юк.
– Киртә бар шул... Киртә ул – син!
– Мин?!
– Әйе, Илдар, син! Чөнки Айгөл сине ярата.
– Мин нишләргә тиеш соң хәзер? – дидем тәтам аптырап.
– Мин бит сиңа теге вакытта әйткән идем – юкка чыгарга тиеш!
– Ничек инде?! – дидем мин, диванда киерелеп утыручы пырдымсыз кунакка текәлеп.
– Мин сине үтерәм!
Минем котым алынды. Чөнки бу өч сүзне ул тыныч һәм ышанырлык итеп сытып чыгарды. Куркыныч күз карашы аның үтерергә әзер булуын исбатлап тора иде.
– Ни өчен?.. – дидем мин, көлемсерәргә тырышып. Бәлки, шаярадыр дигән өмет белән аңа озак текәлеп карап тордым.
– Син бу дөньяда вакытта мин үземнең максатыма ирешә алмаячакмын. Шуңа күрә мин сине юк итәргә мәҗбүр.
– Һич аңламыйм, син шаярып сөйләшәсеңме, чынлапмы?..
– Шаярып маташа торган кешегә охшаганмыни?!
Чыннан да, шаярып эш итә торган бәндәгә охшамаган иде ул.
– Туктале, Арнольд, ничек инде бер хатын-кызны үзеңнеке итү максаты белән син кеше үтерүгә барасың?!
– Кеше үз максатына ирешер өчен әллә нинди җинаятьләргә бара ала... һәм ул һәрвакыт хаклы...
– Ләкин кешелеклелек дигән нәрсә бар бит, законнар бар, ниһаять...
– «Кешелеклелек» дип нотык уку – көчсезләр эше. Законнарны да куркак кешеләр уйлап чыгара. Дәүләтләр, гаскәрләр, төрмәләр көчле кешеләрдән куркып төзелгән нәрсәләр алар...
– Бу бит коточкыч теория, – дидем мин.
– Юкны сөйләмә. Мин сине тагын бер кат кисәтеп куям: Айгөл белән барып сөйләш!
– Нәрсә турында сөйләшим соң мин аның белән?

– Күпме аңлатырга инде?! «Син миңа кирәк түгел!» дип әйт. Синнән өметен өзсен.

– Ярар, әйтермен.

– Беләм, синең дусларың бар... Сугыш чукмарлары арасында да танышларың күп... Миннән котылыр өчен ярдәмгә аларны чакырасы булма! Миннән беркем дә коткара алмаячак сине... Милиция дә...

Мин ни әйтергә белмәдем. Бу хәтле дорфалыктан каушадым, курыктым.

– Арнольд, мин сине аңламыйм. Нигә миңа бәйләнәсең?

– Бәйләнмим, мин сиңа боерам! Мин сүземдә нык торучы кеше, син шуны аңларга тиеш.

– Әгәр Айгөл сине барыбер якын китермәсә?

– Ничә мәртәбә кабатларга инде?! Сине юк итәчәкмен!

– Әгәр мине юк иткәч тә синең белән булырга теләмәсә? – дидем мин, кинәт бу рәхимсез кешене күралмый башлап.

– Аны да юк итәчәкмен.

Мин хәлсезләнеп киттем. Шаярып сөйләшми иде ул.

– Төрмәгә утыртачаклар бит, – дидем мин һәм түземсезлек белән җавап көттем.

Ул авызын кыйшайтып елмайгандай итте.

– Җинаятемне исбатласалар, бәлки, утыртырлар да... Тотылмаска тырышырмын... шулай да эшләр үтерүгә кадәр үк барып җитмәс дип уйлыйм. Чөнки синең дә яшисең килә, аның да...

– Син аны көчләп яраттыра алмассың бит...

– Аның яратуы кирәк түгел миңа. Ул минеке булса, шул җиткән. Миңа ул секс өчен кирәк. Минем аның согын эчәсем килә, әвәлисем, изәсем килә... Белмим, нәрсәдер бу – мәхәббәтме, биологияме... белмим.

«Берәр маньяктыр бу, – дип уйлап куйдым, – йә психопаттыр...» Ләкин аңардан «Син псих түгелме?» дип сорарга батырчылык итмәдем.

– Беләм ниләр уйлаганыңны, – диде ул, мине сискәндереп. – Юк, мин чирле кеше түгел, мин нормаль кеше. Фәкать максатыма ирешү ысуллары гына үзенчәлекле.

– Агрессия беләнме?

– Агрессия түгел ул, маэстро. Кешенең куркаклыгыннан файдаланам мин. Кеше бит ул – куркак хайван. Аны куркытып кына үзеңә буйсындырып була.

– Ә ул кеше синнән курыкмаса?

Ул рәхәтләнеп көлде.

– Курку һәр кешедә яши. Курку – бөек хис, бөек көч. Курку булганга күрә генә тормыш дип аталган ыгы-зыгы бар бу дөньяда. – Ул утырган урыныннан торды. – Ярый, бер атна вакыт бирәм сиңа.

Ул чыгып китте, ләкин аның соңгы сүзләре фатирымның һәр почмагына, һәр ярыгына тулып, миңа ябырылырга әзер торадыр кебек иде.

Нишләргә икән?.. Боксчы дусларыма әйтергә микән? Алар мине гел саклап йөрерләр микән соң? Кайда яши икән ул? Адресын белсәм, барып үзен берәр ничек куркыта алмас идем микән?..

Кем бу?.. Нәрсә бу?.. Гади хулиганга да охшамаган. Кеше үтерүчегә дә охшамаган үзе... Сугышырга туры килсә, аңа үземнең генә көчем җитәр микән?.. Бик егәрле күренә шул...

Беренче очрашуда ук каушаганымны, курыкканымны сиздердем бит... Ничек диде әле ул... Кешенең куркаклыгыннан файдаланам, дидеме... Әйе, шулай диде. Куркуымнан файдаланып, рухымны какшатты да инде ул...

Мине шом басты. Үземне ярдәмсез, көчсез хис иттем.

Ничек тә үземне кулга алып, бу кансыз бәндәгә каршы тору чарасын уйларга кирәк иде. Мин дә ир кеше ләбаса, миндә дә горурлык бар...

* * *

Шулай да иң элек Айгөл янына барып кайтырга булдым. Ул көнне ресторанда музыка юк – минем ял көнем иде. Хәзер Айгөлне күрермен дә, берәр нәрсә ачыкланмый калмас дигән уй белән ул яши торган тулай торакка киттем.

Вахтер хатын белән бик озак ызгышкач, ниһаять, миңа тулай торакка керү насыйп булды.

Айгөл дүртенче катта аерым бүлмәдә яши иде. Техникум тулай торагы булганлыктан, егерме сигез яшьлек укытучы Айгөл Хәбировнага монда берүзенә тугыз квадрат метрлы бүлмә бирелгән иде.

Пычрак, сасы, студентлар шау-шуыннан тынчуланып беткән тулай торакта үземне ниндидер караңгы баз әсире кебек хис иттем.

Аңа күптән түгел бирделәр бу бүлмәне. Элек апасында яши иде. Туганыңда торсаң да, кешедә яшәве авыр ул. Үзеңә үзең хуҗа булыр өчен аерым куыш кирәк. Шуңа күрә Айгөл шушы таш читлеккә күчкәндер.

Минем әле монда бер тапкыр да килгәнем юк иде. Менә аның бүлмәсе. Ишекне шакыдым. Бүлмә эчендә карават шыгырдады, һәм, ишек ачылып, Айгөл пәйда булды.

Ул ышанмыйчарак карап торды, мин елмайгандай иттем.

– Исәнме, Айгөл!

Исәнләшүемә җавап итеп, аның нәфис бите буйлап күз яше тәгәрәп төште.

– Илдар, – дип пышылдады ул һәм күзләрен йомды.

Әллә нишләп киттем: каршымда табигатьнең таң калырлык гүзәл бер күренеше иде. Ул артка таба чигенде, мин бүлмә эченә үттем.

Кинәт ул кочагыма ташланды, үкси-үкси мине кочаклый, үбә башлады.

– Илдар... Исәнме... Килдеңмени... Мин сине гел көттем... Мин синең киләсеңне белдем, күңелем сизде...

Мин аны шундый кызгандым, үзем дә сизмәстән аның юеш керфекләреннән, хуш исле кара чәчләреннән, күпереп торган йомшак иреннәреннән үптем. Бу минутта ул миңа шулкадәр якын тоелды, хәтта аны ташлап рәнҗеткәнем өчен үземне гаепле һәм оятсыз, гөнаһлы итеп сизгәндәй булдым. Елаганда да искиткеч матур, гаҗәеп назлы бу кызның кочагымда изрәве, тыгыз күкрәкләренең тәнемә сылануы, аккош канатлары сыман тибрәлгән кулларының чәчләрем арасында адашып башымны сыпыруы – бу бәхетле һәм бүтән мәңге кабатланмас мизгел түгелмени?!

...Миңа кадәр аның егетләре, ирләре күп булган, имеш... Ләкин мондый минутта бар нәрсә онытыла.

Ишекне бикләдек. Ут сүнде. Караватның шыгырдавы да ямьсез түгел иде.

Сагынганбыз бер-беребезне. Бу минутларда без аерым-аерым ике кеше түгел идек, бербөтен организмга әверелдек. Әллә мәхәббәт иде микән соң бу, шайтан алгыры?!

...Бик озак сөйләшмичә яттык. Ул елады да елады. Инде торып, киенеп, чәй эчәргә утыргач та сөйләшмәдек. Ясаган чәйләребезне суытып, онытылып, бик озак бер-беребезгә карап утырдык.

Аның чибәрлегенә сокланып туярлык түгел иде. Аңарда дөрес булмаган, пропорциональ булмаган бер генә әгъза да, бер генә сызык та юк иде. Мондый гүзәл картинаны мәшһүр рәссам Бөек Табигать кенә ясый аладыр.

Хәтта нинди йомыш белән килүемне дә оныттым.

– Хәлләрең ничек? – дидем мин, ниһаять.

– Начар, – диде ул һәм газап белән елмайды. – Сине сагынам.

Мин аның бүлмәсенә күз йөгерттем. Шкаф, тумбочка, өстәл, ике урындык, караватъ... Шушы саран гына җиһазлы бүлмә, хатын-кыз яшәгәнгә күрә, җылы, якты һәм ямьле иде. Хатын-кыз яши торган бүлмәнең җаны була. Хатын-кыз яшәгән бүлмәдә, батареялар салкын булса да, җылы була. Бүлмәдә хатын-кыз яшәсә, коридорда әшәке итеп сүгенсәләр дә, аста вахтерлар эт шикелле өрсәләр дә, рәхәт була...

Айгөлнең күзләре һаман дымлы иде. Миндә капма-каршы хисләр бураны купты. Фахишә исемен йөрткән бу чибәр җан иясе үзенә чатырдатып тартып тора иде.

– Кияүгә чыгарга җыенмыйсыңмы соң? – дигән булдым.

Бу мәгънәсез сорауны без таныш хатын-кызларга еш бирәбез. Белмим никтер, тик бу миһербансыз сорау яңгырамый калмый. Үзеңнеке иткән кызга бу сорауны бирү тагын бер мәртәбә аның күңел җәрәхәтенә тоз сибү икәнлекне без әллә аңламыйбызмы, әллә аңламаган булып кыланабызмы?! «Юк, мин сине генә яратам!» дип әйтүен ишетәсе килә микән әллә?..

Бу сорауны сөйләшер сүз булмаганга бирдем, ахрысы.

– Юк, Илдар, кияүгә чыгу турында әле уйлаганым юк, – диде ул, авыр сулап.

Торып, тәрәзә янына басты, тышка карап тагын елый башлады.

– Тынычлан инде, Айгөл, – дидем мин.

Ул кинәт миңа таба борылды.

– Илдар, әйт әле... Шул элек булган нәрсәләр өчен ташладыңмы син мине?

Мин дәшмәдем. Ул тагын минем каршыма килеп утырды.

– Бөтенләй үк пычрак түгел бит инде мин! – дип кычкырды ул. – Синең белән танышканнан соң минем беркем белән дә булганым юк. Элек булган ирләремне мин инде күптән оныттым. Мин сине яратам! Кеше бит үзгәрә дә ала. Кешегә үзгәрергә, чистарынырга мөмкинлек бирергә кирәк. Мин инде мең кат үкендем, офтандым... Нишләп мин күптән үткән мәхәббәт маҗараларым өчен гомерем буе бәхетсез йөрергә тиеш соң?! Кешенең бит ялгышырга да хакы бар...

Аңардан ачыну, рәнҗү һәм ихласлык ниндидер яктылык булып сирпелеп тора иде.

Чыннан да, олы җанлы, якты күңелле кеше ул. Бәлки, табигать аны фәкать җенси мөнәсәбәтләр өчен генә яраткандыр... Ләкин кешеләр уйлап чыгарган төшенчәләр, кануннар бар шул: әхлак, гаилә. Бер ирнең генә хатыны булу... Үзләре бик күп хатыннар белән чуалсалар да, ирләр гаилә корыр өчен чиста, саф кыз эзлиләр. Мин дә шундыйлардан идем. Бу, әлбәттә, гаделсезлек, ләкин нишлисең бит, күрәсең, эгоизм башка хисләргә караганда көчлерәк һәм яшәүчәнрәктер инде...

– Син тагын да матурланыбрак киткәнсең, – дидем мин.

Бу комплиментның да урынсыз һәм буш икәнлеген икебез дә аңлап алдык; мин читкә карадым, ул мәсхәрәле елмаю белән:

– Әй, төчеләнеп утырма, зинһар, – диде.

Аның елаудан туктавыннан файдаланып, сорарга батырчылык иттем:

– Айгөл, син Арнольд исемле кешене беләсеңме?

Ул сискәнеп китте, бите кинәт агарды, күзләре, курку чәчеп, минем өстән каядыр ишек өстенә карадылар.

– Әйтмә ул исемне, – дип пышылдады ул, гүя кемнеңдер ишетүеннән куркып. – Ә син каян беләсең аны?

– Ул инде миңа ике тапкыр килде. Сиңа гыйшкы төшкән. Син мине онытмасаң һәм аныкы булмасаң, мине үтерергә вәгъдә бирде.

Айгөл миңа текәлеп карап катты.

– Син нәрсә дидең?

– Айгөл белән минем арада җитди нәрсә юк инде, дидем. Биш ай очрашканыбыз юк, дидем. Ә ул әйтә «Айгөл минеке булырга тиеш» ди. «Үземнеке итә алмасам, икегезне дә үтерәм» ди.

– Илдар! Куркыныч кеше ул... Мине күптәннән каравыллап йөри... Техникумга да килә. Монда да килеп йөдәтә. Аңа гел «Мин Илдарны яратам» дим, шуңа күрә ул синең янга барган инде.

– Кем соң ул?

– Белмим. Кайда эшләгәнен дә, кайда яшәгәнен дә, кем икәнлеген дә белмим. Урамда очрашып танышкан идек. Башта әдәпле

зыялыга охшаган иде... Коточкыч кеше ул... Мин аны гел куам. Килмәскә кушам... ә ул... Көчләп тә карады инде, булдыра алмады... Куркам мин аннан... Син дә куркасыңмы?

– Соң... шөбһәләнү бар инде... – дидем мин.

«Куркам» дип авыз тутырып әйтергә кыймадым. Ә курку миндә инде ныклап урнашкан иде. Арнольдның максатчанлыгы һәм гадәти булмаган сәерлеге куркыта иде.

Ләкин бу халәт чарасызлык дигән сүз түгел бит әле. Мин дә бит егет кеше, көчем җитмәсә, дусларым бар. Һәм инде, ниһаять, закон да бар бит әле.

– Ничек котылырга инде аңардан?..

Айгөлнең бу соравы уйларымнан арындырды. Аны тынычландырыр өчен:

– Мин аның белән әйбәтләп сөйләшермен, – дидем. – Алай ук куркыныч кеше түгелдер әле... Үтерәм дип куркыта гынадыр.

– Юк, Илдар, куркыныч кеше ул!

Аның бу сүзләреннән бөтен җанымны-тәнемне курку биләп алды. Чөнки бу сүзләрне ул котсыз калган кеше тавышы белән әйтте.

Килеп, алдыма утырды, муенымны кочаклап, сулышы белән тәнемне чемердәтте.

– Илдар, ташлама мине, – дип пышылдады ул.

Мин шунда аңладым: алга таба Айгөл белән бергә булмасам да, хәзерге вакытта аны ташлый алмаячакмын. Аны Арнольд дип аталган садистка калдырырга минем хакым юк иде. Хәзергә мин Айгөл белән булырга тиеш. Арнольдтан котылсак, алга таба күз күрер.

– Юк, мин сине ул куркыныч кешегә бирмим, – дидем мин, аны биленнән кысып.

Иреннәребез кушылдылар. Халат эчендә дерелдәп торган күкрәкләр, итәк ярыгыннан ялтырап чыккан шәрә ботлар, мамыктай йомшак куллар караңгы уйлар диңгезеннән күтәреп алдылар да, без яшәешнең сазлыгыннан чиксез биеклеккә якты болыт булып күтәрелдек.

Тәннәребез икедән бер булды, хәтта сулышларыбыз да уртак иде. Бәхет түгел идемени бу?! Минутлык булса да, бәхет иде бу. Кыска гомерле булса да, мәхәббәт иде!

Рәхәтлекнең чиксез-кырыйсыз галәмендә әллә йөздек, әллә очтык. Бу киңлектә безгә беркем дә, бернәрсә дә янамый иде. Кайгы да, курку да юк иде.

* * *

Айгөл минем фатирда яши башлады. Мин аны үземә алып кайтмый булдыра алмадым. Дөрес, Арнольд аны техникумга барып та очрата ала. Шулай да анда кеше арасында тияргә батырчылык итмәс. Урамда очратса да, әллә ни начарлык эшли алмас.

Айгөл эштән соң туп-туры миңа кайта иде. Мин ресторанга

киткәндә: «Сак бул!» – дип кала, ә мин аңа: «Курыкма... Ишекне беркемгә дә ачма...» – дип, тынычландырып, үзем шомлы уйларга батып чыгып китә идем.

Беркөнне ул атылып кайтып керде дә кочагыма ташланды. Мин хәтта аның йөрәк тибешен дә ишеттем. Ул бик озак калтыранып миңа сыенып торды. Мин аңладым: Арнольд очраган!

– Техникумнан чыккан идем... ишек төбендә басып тора... – диде ул, бераз тынычлангач. – «Яхшылык белән булмый, ахрысы» ди. Мине үзе белән әйдәп теңкәмә тиде.

Мин аны диванга утырттым, үзем каршына чүгәләдем.

– Йә, йә, тынычлан.

– Юл буе бәйләнеп барды... «Мин хәзер ашыгам, иртәгә техникумнан чыгуыңны көтәм» диде. «Мин сезне бүтән кисәтеп тормам инде» диде.

– Тагын ни диде?

Айгөл еларга тотынды.

– Кайда торасың, дип сорады.

– Әйттеңме?

– Әйттем.

– Ярар, әйбәт булган.

– Илдар. Син бүген ресторанга барма. Ул шунда килер, мөгаен... синең янга.

– Юк инде, качып йөреп булмый алай... Елама. Минем дә нервылар бар бит...

Мин киенә башладым.

– Ишекне беркемгә дә ачма. Монда килүе бар...

– Ишекне ватып керсә?

– Каян белим мин...

Минем мондый җавабым Айгөлне тагы да ныграк ярсытты, ул тагын елый башлады. Аның елавы исә минем болай да сыкраган күңелемнең сызлавын арттырды. Түзмәдем, кычкырып җибәрдем:

– Еламасана!

Ул диванга капланып үксеп калды.

...Ресторанда музыка сәгать җидедә башлана, минем әле ярты сәгатьтән артык вакытым бар иде. Арнольдтан котылу чараларын уйлап җәяү киттем.

Булды, җитте! Мин дә каты сөйләшә башлыйм. Бәлки, андый ук куркыныч кеше түгелдер, әдәп саклавымнан файдаланып кына кыланадыр.

Әгәр сугышсак... Көчем җитәр микән?.. Ул көчлерәктер, мөгаен... Ресторанда бәйләнсә, куркыныч түгел. Чөнки анда көн саен кәеф-сафа корып утыручы танышларым була. Алар әйбәт сугышалар, алар мине җәберләтмәячәкләр. Ә кайтканда берәр почмакта сагалап торса?.. Берничә таныш егет белән сөйләшеп куярга кирәк булыр – эштән соң мине озатып куйсыннар. Карале, нинди хәлдә калдым бит, ә!

Әгәр фатирыма барып, ишекне ватып керсә? Кинәт «Керсә ни булган?..» дигән уй чагылып үтте. Айгөл кычкырачак, ярдәмгә

кешеләрне чакырачак. Юк, ишекне ватып керергә җөрьәт итмәс. Бәлки, өйгә дә, ресторанга да килмәс. Бәлки, Айгөлне сагалап йөреп тә туйгандыр инде. Ләкин шунда аның «Кеше үз максатына ирешер өчен әллә нинди җинаятьләргә бара ала... Һәм хаклы» дигән сүзләре чыңлады. Аннары аның «Кешенең куркаклыгыннан файдаланам мин» дигәне дә аермачык булып исемә төште.

Димәк, куркуымнан файдаланмакчы була, кабих! Алайса, миңа курыкмаска кирәк. Курыкмаска! Ничек булса да аның үзен куркытырга кирәк!

Аннары уйларым мине Айгөл янына алып киттеләр. Чыгып киткәндә мин аңа кычкырдым. Кычкырмаска иде! Бик хисле, нечкә күңелле нәмәрсә бит ул. Ярар, кайткач гафу үтенермен дип, үземне тынычландырдым.

...Аппаратураны кабызып, без, дүрт музыкант, уен коралларыбызны көйли башладык. Гитарамның кылларын чирткәндә, кулларымның калтыравына игътибар иттем.

Залда кеше шактый күп, күбесе яшьләр иде. Түрдәге өстәлләрнең берсе артында шәһәребезнең хәйран «абруйлы» шпаналары утыра. Мин аларның икесе белән яхшы мөгамәләдә идем. Икесе дә татар егетләре, берсе – Рөстәм, икенчесе Марат исемле.

Ресторанның куе һавасын ярып, аккордлар яңгырады. Беренче җырымны көч-хәл белән ерып чыктым. Биергә чыкмадылар, чөнки залда утыручылар әле биерлек дәрәҗәдә «кызмаганнар» иде.

...Икенче җырым башлангач, залга УЛ килеп керде һәм туптуры сәхнәгә таба атлады. Җырның башыннан ахырына кадәр, сәхнә кырыендагы динамик колонкага сөялеп, ул миңа текәлеп карап торды. Кайвакыт җырны шулай дикъкать белән тыңлаучылар ресторанда булгалый, шуңа күрә минем иптәш музыкантларым АҢА игътибар бирмәделәр. Ә мин исә, аның җан өшеткеч күз карашыннан котылыр өчен, җырны ташлап урамга чыгып йөгерердәй булдым.

Җыр тәмамланды. Ул миңа кул ишарәсе белән зал артына, кухня ягына чыгарга кушты. Мин ансамблебезнең җитәкчесе Ренатка:

– Бер-ике җырны миннән башка гына җырлагыз, минем янга килделәр, – дип, гитарамны куйдым да сәхнәдән төштем.

– Әйдә минем белән, – диде Арнольд.

Ниндидер сихри көчкә буйсындым һәм аның артыннан атладым.

Кухня аша үтеп, ресторан хезмәткәрләре йөри торган ишектән агач әрҗәләр һәм сыра мичкәләре белән тулган ишегалдына чыктык.

Ул спорт киеменнән иде. Аның начар ният белән килгәне ап-ачык күренеп тора.

– Матур җырлыйсың син, – диде ул, ямьсез елмаеп.

Сизми дә калдым – ул бар көченә эчемә китереп сукты. Әйтерсең лә тимер белән суктылар – тыным капты, күз алларым караң-

гыланды, һәм шунда ук яман авырту мине урталай бөкләде. Эчемне ике кулым белән кысып бөгелеп торганда, аның салкын корыч тавышы яңгырады:

– Син яхшылап әйткәнне аңламыйсың бугай...

Нидер әйтергә теләдем, ләкин ыңгырашу гына сытылып чыкты. Кинәт яшен яшьнәгәндәй булды, утлар чәчрәде – ул астан битемә сукты. Башым ярылып киткәндәй булды, авызга тимер тәме керде, хәл бетте. Аның каты сугуыннан мин бөгелгән җиремнән бераз турайдым. Авызга эләккән икән – иреннәрем шунда ук күпереп чыкты, авыз кырыеннан кан агып төшкәнен тойдым.

– Бирәсеңме миңа Айгөлне, юкмы? – диде ул каяндыр томан эченнән.

Авыртудан һәм көчле стресстан күзләрем яшьләнгән иде, мин, аны күрергә тырышып, кулым белән битемне сыпырып алдым.

Ул тагын сугарга әзерләнде. Нәфрәт дигән нәрсә миндә җанвар сыман бәргәләнә башлады, мин тешләремне шыгырдатып куйдым. Рәнҗүемнең чиге юк.

Артымда әрҗәләр өеме иде. «Әрҗә белән сугарга кирәк...» дигән уй килде.

Бар көчемне җыеп:

– Бирмим мин сиңа Айгөлне, сука! – диеп кычкырдым.

Күрәсең, ул минем ярсуыма да әзер булгандыр, киерелеп көлеп җибәрде. Ярсуым ташып чыкты, һәм, әрҗә турында да онытып, йодрыгым белән аның иягенә тондырдым. Ул чайкалып китте, ләкин егылмады.

– Ах, падла! – дип, ияген тотты, мин шул арада өстәге әрҗәне тарттым. Әрҗә, кадакка эләккәнгә, өемнән алынмады. Мин каушадым. Һәм башыма, күкрәгемә, эчемә аның йодрыклары, аяклары «куна» башлады.

Көчле иде ул. Әрҗәләр өеме янында җиргә аудым. Ләкин аңымны җуймадым. Касыкка китереп типкәч кенә бераз аң томалангандай булды. Мин аның аяк тавышларын ишеттем – кире ресторанга кереп китте.

Озак ятмадым. Берәрсе күреп кереп әйткәнме, әллә үзләре сизенгәннәрме – музыкантлар чыктылар һәм мине күтәреп торгыздылар. Аякларымда хәйран нык басып торсам да, бөтен гәүдәм авырта, башым гөжләп сызлый иде.

Мин иптәшләремә ни булганын аңлаттым. Ансамблебезнең җитәкчесе Ренат:

– Сәхнә янында басып торган кеше кыйнадымы? – дип сорады.

– Әйе.

– Ул бит хәзер өстәл янында ашап-эчеп утыра!

– Ресторандамыни әле ул? – дидем мин, гаҗәпләнеп.

– Әйе, берни булмагандай утыра.

Шулчак залның түрендә утыручы Рөстәм белән Марат компаниясе исемә төште. Шуларга әйтергә кирәк, болай калдырырга

ярамый, үч алмыйча булмый... Безнең музыкантлар бик юаш егетләр, алардан сугышу да, яклашу да күтәрлек түгел иде.

– Ренат, – дидем мин, иреннәремне көчкә кыймылдатып, – анда, залда... Рөстәм белән Марат... үзләренең дуслары белән утыралар... Бар, кереп әйт, Илдарны кыйнадылар, диген... Тегене дә күрсәт аларга... монда алып чыгып дөмбәсләсеннәр үзен.

Ренат кереп китте, башка музыкантлар ишегалдында калдылар, мин битемне юарга дип, пешекчеләр бүлмәсенә юнәлдем.

Яңадан ишегалдына чыкканда, Рөстәм, Марат һәм үзләре кебек ике таза егет Арнольд белән сөйләшеп торалар иде инде. Музыкантлар читтән күзәтә иде. Мине күргәч, Рөстәм дәште:

– Илдар, кил монда. Шушы кеше кыйнадымы сине?

– Әйе, – дидем мин һәм Арнольдка карадым.

Ул тыныч иде.

– Син нишләп безнең музыкантларны җәберлисең? – диде Марат.

Арнольд тыныч кына һәм гадәттәгечә корыч тавыш белән:

– Бер шлюха өчен сугыштык дип әйттем бит инде мин сезгә, – диде.

Мин аны бу минутта үтерергә әзер идем, ләкин аңа сугарга үземдә көч тапмадым.

– Юк, ул бер кызны көчләмәкче була, ә ул кыз минеке, – дидем мин.

Әзмәвердәй дүрт «авторитет» каршында Арнольдның кыю гына, бернинди каушаусыз торуы яклаучыларымны сагайтты булса кирәк. Гадәттә, Рөстәм белән Марат күп сөйләшеп тормыйлар, бәргәләп ташлыйлар иде. Бик үк якын дусларым булмасалар да, алар мине еш кына исерек бәйләнчекләрдән, сәхнәгә менеп комачаулаучылардан яклыйлар иде.

– Нишләтергә соң инде сине? – диде Марат Арнольдка.

Арнольд:

– Теләсә кайсыгыз белән бергә-бер сугышам, – дип җавап бирде.

Боларга җитә калды. Оста сугышуы белән дан казанган Марат көтмәгәндә аның аяк астына китереп сукты. Арнольд чак кына егылмый калды. Ләкин ул, шунда ук үзен кулга алып, артка таба чигенде дә сикергәләп йөгереп йөри башлады. Дүрт сугыш чукмары аның тирәли йөгерешә. Арнольд аларны якын китермәде. Ул бик оста сугышты. Үзенә инде шактый гына суккаласалар да, Рөстәм белән Маратка да, аларның ике дустына да ялгыз сугышчыдан хәйран эләкте. Арнольд җитез генә аягы белән китереп тибә, арттан килергә тырышучы булса, кинәт борылып сугып та җибәрә иде.

Яклаучылар каушадылар. Хулиганнар арасындагы «авторитет»лар, гадәттә, нык каршы торучылардан шүрлиләр һәм конфликтны тизрәк бетерергә тырышалар. Чөнки «абруй»ның бетеп китүе ихтимал. Җитмәсә, карап торучылар җыелды: сугышны

тамаша кылырга залдан берничә кеше, поварлар һәм официантлар чыккан иде.

Бишесе дә канга баттылар, күлмәкләр ертылды, әмма егылучы әле юк иде.

Арнольдның сугышуына барысы да шаккаттылар. Ул арымады да бугай, ә мине яклаучылар исә, гыж-гыж килеп, көчкә сөйрәләләр. Арнольд дошманнарының дүртесенә дә катырак «манчый» башлады. Бу вакытта Рөстәм белән Марат мине яклап чыгуларына, мөгаен, үкенгәннәрдер дә...

Бермәлне ресторанннан дүрт милиционер килеп чыкты һәм сугыш туктатылды. «Авторитетлар»ның таныш сержантлары булганлыктан, протоколлар төзеп тормадылар һәм беркемне дә алып китмәделәр.

Арнольд ресторанга кермәде, аксый-аксый, ишегалдыннан урамга таба атлады. «Авторитетлар» аңа янап, сүгенеп калдылар.

Иң авыр, иң мескен халәттә мин калганмындыр. Рөстәм белән Марат миңа дәшмәделәр, яман итеп сүгенә-сүгенә, Арнольдны үтерергә вәгъдә биреп, юынырга кереп киттеләр.

Музыкантлар эшен дәвам итте, ә мин, ишегалдында берүзем калып, аракы әрҗәсе өстендә бик озак утырдым.

Җиңалмадылар! Ресторан халкының гына түгел, бөтен шәһәр яшьләренең котын алып торучы «авторитетлар» да җиңмәделәр! Бу минутларда мин Арнольдны түгел, аны «акылга утырта» алмаган Рөстәмнәрне дә түгел, үземне күралмый идем. Чарасызлык башыма дөп-дөп итеп тибә дә тибә иде.

Өемә китмәде микән ул?.. Хәзер аңардан мәрхәмәт көтеп булмый инде. Нишләргә?.. Барыбер кайтырга кирәк... Бу матавыкның ахыры кайчан да булса күренергә тиеш ләбаса...

Мин кайтып киттем.

* * *

Юк, мине сагалаучы күренмәде. «Фатирга килүче дә булмады», – диде Айгөл.

Минем кыяфәтне күргәч, Айгөлдә истерика булып алды. Аннары төпченеп теңкәмә тиде. Үзен гаепле санап, минем алда ул бик читенсенә иде.

Ресторан вакыйгасын сөйләп утырырга теләгем дә, хәлем дә юк иде. Кинәт мин Айгөл белән бәйләнешкәнемә үкенеп куйдым. Юк, аны кызганып өемә алып кайтканыма түгел, аның белән танышып ел ярым буена аралар һаман өзелмәгәнгә үкендем мин. Хәер, кем белгән берәр кайчан шушындый матавык килеп чыгасын?..

Әллә ташлаганым өчен аның каргышы төштеме миңа?.. Алай дисәң, нигә соң ул каргыш Айгөлнең үзенә дә төште?.. Ул бит миңа караганда да ныграк җәфалана.

Төн буе ул мине иркәләп ятты. Бераз елый да кочып үбеп куя, кат-кат гафу үтенә, аннары тагын мышык-мышык килә дә яратуы турында сөйли.

Бөтен тәнемнең сызлавы турында уйламыйча, ул мине кысып-кысып кочаклады. Хәер, аның шома җылы кулларының тәнемә орынуы, ботларының ышкылуы – авырттыру түгел, киресенчә, шифа биреп, тынычландырып җибәрде кебек.

Бүгенге куркыныч вакыйгадан соң мин аның кочагында мәңгегә калырга да риза идем. Шушы җылы, шәфкатьле кочактан беркая да чыкмаска иде. Сасы ресторанга барып, тормышның тискәре ягын өч сәгать буе тамаша кылмаска иде, чынбарлыкның пычрагына бүтән буялмаска иде...

Нишләп болай булды соң әле бу?.. Нишләп әле Айгөлдән җирәнми башладым?.. Әллә чын матурлыгын күреп тәмам аңладым микән?.. Әллә соң миңа аның шикелле ләззәт, рәхәтлек бүләк итүче юк һәм булмады микән?.. Нишләп соң әле кинәт кенә аның мәхәббәт маҗараларыннан көнләшүем юкка чыкты?.. Чибәрлеге белән исерттеме?.. Арнольдның комсызланып, ерткычланып йөрүе сәбәп түгел микән монда?.. Әллә шул куркыныч кешедән көнли башладыммы Айгөлне?.. Болай да гөжләп торган башымны уйлар өере тагы да катырак ду китерде. Айгөл пыш-пыш килеп нидер сөйли иде. Мин аның сөйләгәнен аңламадым. Башымдагы уйларымны рәткә кертеп, анализ ясамакчы булдым.

Айгөлне яклап Арнольдка каршы торуым игелекле эштер инде, әлбәттә. Ләкин аңлый алмый интектем: бу адымга мине нәрсә этәрде соң, нинди хисләр?.. Миһербанлы булырга омтылуданмы?.. Егетлек күрсәтәм дипме?.. Яратам микән әллә?.. Үз гомерем өчен куркып түгел микән?! Алай дисәң, мин бит аны өемә алып кайттым. Хәер, алып кайтмый чара да юк иде. Айгөл, барыбер мине яратам, ди, ә бу очракта Арнольд, икебезне дә үтерәм, диде... Бәлки, чыннан да үз гомерем өчен курку мине шушы адымга этәргәндер дә, Айгөлнең Арнольдны үзенә якын китермәсен белеп, аны үз өемдә тотып, күңелем ничек тә фаҗигане булдырмаска омтылгандыр. Арнольд белән ничек тә уртак тел табу ниятеннәндер... Аңлашылып бетми, шулай да... Ә курку инде үзәгемдә рәхәтләнеп яшәп ята иде.

Айгөл йокыга китте. Тәрәзәдән ай карады. Бу турыда инде шагыйрьләр күп яздылар: тыныч бүлмә, чибәр хатын, мәхәббәт, тәрәзәдән ай карый, бәхет... Ләкин ай яктысында Айгөлнең изрәп ятуын, аның йоклаганда да борчулы булып калган сулу йөзен, шул борчылуның ничектер үзенә килешеп торуын, аның сабыйларча җылы сулавын, бу могҗизалы матурлыкны шигырь белән генә аңлатып бетереп булмас иде.

Матур кызларга адым саен куркыныч яный. Матур кызны һәркемнең тотып карыйсы, кагыласы, кулланасы килә... Айгөлнең беркемгә зыяны тигәне юк, ә үзенә куркыныч яный... Чибәрлеге бар, укымышлы, яраткан эшендә эшли кебек, әмма үзен бәхетсез ди... Һәм ул чыннан да бәхетсез... Ни өчен икәнен төгәл әйтеп булмас иде, ләкин шулай да бәхетсез... Чибәр булганга микән?.. Миндә тагын әллә нинди уйлар, хисләр кайнады – кемнәндер көнләштем кебек, кемгәдер ачуым килгән сыман булды. Дөрес-

рәге, яңа төрле курку туды. Бу курку инде Арнольдның эзәрлекләвеннән генә түгел, гомумән, Айгөл белән үземнең язмышларыбыз өчен курку иде.

Шул курку мине Айгөлгә ныграк якынайтты. Яратам дип әйтә алмасам да, мин аны хәзер, нинди генә хәвеф-хәтәр килсә дә, ташлый алмас идем.

Ай яктысында аның йөзе аермачык күренде. Мин тагын, аңларга тырышып, фикерләремне җыйный башладым. Ул хәзер миңа ныграк ияләшер инде... Ә соңыннан аерыла алмасак?.. Шунда кинәт үземә ачуым килде. Нишләп соң мин һаман киләчәктә Айгөл белән бергә булудан куркам?.. Алайса, нигә, үземне куркыныч астына куеп, аны үземдә асрап ятам?.. Кызгану, егетлек күрсәтү генә түгелдер бит инде... Үз гомерем өчен курку гына да түгелдер! Монда башка хисләр дә бардыр бит!

Күрә торып чит кешегә бирәсем килми мәллә аны?

Тфү! Нинди уйлар соң бу?! Ник казынам шушы чүп-чарда?! Монда хәзер Арнольдтан котылу чарасын уйлап табарга кирәк.

Айгөл начар төш күрә иде бугай – кашлары җыерылды, битендәге борчылу курку төсенә керде, ул авыр итеп ыңгыраша башлады. Мин аны чәчләреннән сыйпадым, кулын алып иреннәремә тидердем. Күпергән иреннәрем авыртса да, аның кулын үбәсем килде. Ул уянды, чалкан яткан җиреннән ялт итеп башын борып, миңа карады һәм елмайды.

– Әллә нинди төшләр керә... – диде ул, татлы итеп киерелеп. – Син йокламыйсыңмыни?

– Юк.

Аның елмаюы караңгы уйларымны өтеп юкка чыгарды.

Күңелләр яктырып китте. Әйтерсең лә бу дөньяда ике Ай бар иде – берсе – күктә, икенчесе – минем шыксыз бүлмәмдә.

* * *

Иртән үземне бик озак көзгедән карап тордым. Иреннәрем кабартма төсле күпергән, күз төбемдә шәмәхә тап хасил булган. Мондый кыяфәт белән атна-ун көн җырлап булырлык түгел иде.

Айгөлне техникумга чаклы озата барырга булдым. Техникум янына килеп җиткәч, бер төркем укучылар:

– Исәнмесез, Айгөл Хәбировна! – дип исәнләшкәч, мин тизрәк китәргә ашыктым.

Айгөл Хәбировнаны шешкән авызлы, кара янган күз төпле кеше белән күреп укучыларның әллә ни уйлаулары ихтимал иде. Айгөл моны аңлады һәм матур итеп елмайды.

– Бүген дәресләр сәгать өчтә тәмамлана, – диде ул. – Бар инде, ояласың бугай...

– Сәгать өчтә сине каршы алырмын, – дидем мин.

– Ярар.

Ул техникумга кереп китте. Аны хәзер үзен генә урамда йөртергә ярамый иде. Үземә дә сак булу кирәк.

Минем бер яхшы танышым бар – Әгъдәс – спорт мастеры. Дус дип әйтә алмыйм, шулай да җырлавым өчен, матбугат битләрендә күренгән кечкенә әсәрләрем өчен мине бик хөрмәт итә иде. Мин аның кайда эшләгәнен дә, ни белән шөгыльләнгәнен дә әйтә алмыйм. Ләкин шуны беләә идем: шәһәребез спортчылары арасында, мафиозлар тирәсендә бик абруйлы кеше санала иде. Аның оста сугышуы турында бик күпләрдән ишеткәнем бар. Әгъдәс кайвакыт (мөгаен, берәр төшемле эш майтаргачтыр) ресторанга кереп шампан шәрабы кебек җиңел эчемлекләр эчеп утыра иде. Аның яраткан җырларын миңа җырларга туры килгәләде. Ресторанда төрле шпананың йөрүен күреп, аның миңа әйткәне дә бар иде: «Илдар, алай-болай кыерсытучы табылса, миңа әйт, адресымны беләсең...»

Әйе, аның адресын яхшы хәтерлим, чөнки фатирында берничә тапкыр кызлар белән күңел ачып утырганыбыз булды.

Айгөлне озатып куйгач, шул адрес белән киттем.

...Ишекне Әгъдәснең хатыны ачты. Әгъдәс йокыдан торып киенгән арада, икенче класста укучы кызы мәктәпкә чыгып йөгерде, хатыны эшкә китте.

Мин хәлемне аңлатып бирдем.

– Тә-ә-к, – диде ул, озак йоклаудан шешенгән чыраен сыпырып. – Кыяфәтең бигүк матур түгел синең, кәнишне... Синяк килешми икән сиңа...

Аның шаяруы миңа кызык тоелмаса да, елмайган булдым.

– Бәлки, син ул кешене беләсеңдер дә әле?! – дидем мин.

– Ниндирәк соң ул?

Мин Арнольдның төс-кыяфәтен тасвирлап бирдем. Шуннан соң:

– Минем аны элек күргәнем юк иде, – дип өстәдем.

– Андый отчаянный кешене мин белергә тиеш инде вообще-то, – диде Әгъдәс. – Исемен ничек дидең әле?

– Ул үзен Арнольд дип атады. Чын исеменең башкача булуы да ихтимал.

– Тәк... Нишлибез соң?.. Утыз яшьтә сугышып йөрү матур түгел, әлбәттә, шулай да синең өчен бераз йодрыкларны төйнәп алырга туры килер инде, – диде Әгъдәс һәм иңемнән кагып куйды. – Курыкма! Иманын укытам мин аның. Хатын-кыз өчен сугышып, матавыкланып йөрүең дөрес түгел инде, кәнишне... Нигә кирәк сиңа ул Айгөл?.. Кызлар беткәнмени?! Мин беләмме аны?

– Әйталмыйм. Бәлки, беләсеңдер дә... Техникумда укыта.

Ул кашларын җыерып уйланып утырды һәм бераздан:

– Ә-ә-ә, беләм, беләм, – диде. – Карале, Илдар шлюха түгелме соң ул?..

Миңа бик авыр булып китте.

– Шлюха түгел ул, – дидем мин, никтер үземне гаепле сизеп. Белмим, нишләптер Әгъдәс алдында читенсенеп куйдым. – Юк, әйбәт кыз ул...

– Әйе, чибәр ул, – диде Әгъдәс, – минем бер танышым аның белән чуалып алган иде.

Аның бу сүзләреннән миндә тагын әллә көнләшү, әллә үземнең шушы көнгә калуыма нәфрәтләнү кайный башлады. Бу минутта Әгъдәскә дә, Айгөлгә дә, Арнольдка да, әле яңа гына әйтелгән «чуалучы»га да шундый нык ачуым килде.

– Кем белән чуалгандыр – анысында минем эшем юк, – дидем мин, кырыс булудан үземне көчкә тыеп. – Начар кыз түгел ул...

– Ярар, ярар, борчылма, – диде ул, кәефемнең кырылуын шәйләп. – Эш синең Айгөлеңдә түгел... Синә кул күтәргән бит ул. Моның өчен мин аның иманын өшкерәчәкмен! Арнольд, имеш... Андый Арнольдларны күп күргән кеше мин... Тик менә ничек табарга икән соң аны?

– Кемне?

– Шул... Арнольд дигән кешене.

– Ул үзе килер инде.

– Кая килер?

– Ул хәзер мине дә, Айгөлне дә сагалап йөрер инде.

– Мин бит сезне гомер буе саклап йөри алмаячакмын.

Чыннан да, Арнольдның кайда һәм кайчан килеп бәйләнәсен шайтан белсенмени?..

– Өемә килер инде ул... – дидем мин.

– Син бу чыраең белән ресторанда җырлый алмыйсың инде.

– Юк, берәр атна ял итәрмен.

Уйлаша торгач, ул көнне Айгөлне Әгъдәс белән икәү каршыларга булдык. Әгъдәс: «Бер-ике көн синдә кунармын», – дигәч, шатландым. Ике атнадан артыкка сузылган гасаби киеренкелек мине шактый талчыктырган иде.

...Техникум янына килеп җиткәндә, йөрәгем жу итеп китте – эскәмиядә Арнольд утыра иде. Сәгатемә карадым – өч тулырга әле ун минут бар. Эчкә җылы йөгерде, димәк, әле Айгөл чыкмаган, һәм алар очрашмаганнар.

– Әнә ул, – дидем мин.

Әгъдәс мин күрсәткән якка карады.

– Юк, бу кешене белмим мин, – диде ул.

Арнольд безне күрми иде әле, ул башын аска иеп утыра һәм вакыты-вакыты белән, башын әкрен генә күтәреп, техникум ишегенә күз ташлый иде.

– Хәзер сөйләшәбез аның белән, – диде Әгъдәс һәм ашыгып аңа таба атлады, мин дә иярдем.

Ул безне күреп алды һәм торып басты. Аның өстендә джинсы кәчтүм, аягында кроссовка иде. «Киенә белә бу, нинди кием кисә дә килешеп тора үзенә», – дип уйлап куйдым.

Спорт кәчтүме кигән, боксчы икәнлеге гәүдәсенә, кыяфәтенә чыккан кешенең минем белән аңа таба якынлашуын күреп каушап калмасмы дигән идем. Юк. Ул һәрвакыттагыча тыныч һәм усал иде.

– Сәлам, – диде Әгъдәс, аның янына килеп җиткәч.

– Сәлам, – дип җавап бирде корыч тавыш. Һәм миңа карап мыскыллап елмайды.
– Нишләп утырасың монда? – диде Әгъдәс.
– Айгөлне көтәм.
– Илдарны син кыйнадыңмы?
– Мин.
– Беләсеңме, шуның өчен хәзер мин сине нишләтәм?!
– Нишләтмәкче буласың?..
Әгъдәс кыҗрый башлады:
– Мин синең иягеңне чыгарам. Гафу үтен Илдардан!
Арнольд шаркылдап көлеп җибәрде.
– Әгъдәс, син кызма әле, – диде ул, кинәт көлүдән туктап. – Беренчедән, синең бу эшкә тыгылуың бөтенләй кирәк түгел иде... Икенчедән, мин синнән курыкмыйм. Тыгылып маташма... Без бер б...не бүлешә алмыйбыз.
– Б... түгел ул! – дип кычкырдым мин.
Ярый әле техникум янында бездән башка беркем дә юк иде. Арнольд тагын мәсхәрәле елмаю белән миңа карап куйды.
– Өченчедән, әгәр телисең икән, мин синең белән бергә-бер сугышам! – диде ул Әгъдәскә.
– Мин бит сине бер сугуда үтерәм, падла! – диде Әгъдәс, авызын кыйшайтып.
Миндә әле, бәлки, сугышмаслар дигән өмет бар иде. Шуңа күрә, аларның кызганнан-кыза баруларын күреп, телгә килдем:
– Арнольд, син бит чын егет кеше... Айгөл белән мине бимазалавыңны туктат!
Минем бу мөрәҗәгатем бик юаш килеп чыкты.
– Юк, Илдар, – диде Арнольд, – мин синең белән сөйләштем бит инде.
– Син минем исемемне каян беләсең? – дип сорады Әгъдәс.
Арнольд киң итеп елмайды:
– Һи, Әгъдәс, шәһәребездә сине белмәгән кеше юктыр. Мин дә сине яхшы беләм.
– Белсәң бик әйбәт, – диде Әгъдәс коры гына. Ул бераз тынычланган иде. – Илдардан гафу үтен!
– Үтенмим!
– Алга таба да аларга бәйләнеп йөриячәксеңме?
– Әйе. Максатыма ирешкәнче, – диде Арнольд салкын гына.
Әгъдәс тагын кайнарлана башлады, як-ягына каранып куйды. «Хәзер сугып җибәрә...» – дип уйладым. Арнольд та моны сизенде бугай.
– Әгъдәс, – диде ул, – беләм, син каты сугышасың... Тик шуны аңла: мин сиңа бирешергә җыенмыйм. Исеңдә тот: синең хатының, икенче класста укучы кызың бар...
Әгъдәс түзмәде, кинәт аның битенә китереп сукты. Бик каты сукты – Арнольд, кычкырып, эскәмиягә «лып» итеп утырды. Ләкин шунда ук сикереп торды һәм һөҗүмгә ташланырга әзерләнде.
– Үтерәм, падла! – диде Әгъдәс, тешләрен кысып.

Бу вакытта мин дә Арнольдка якынлаштым. Аның борыныннан кан ага иде, ләкин исе китмәде, йодрыкларын төйнәп, сугышырга әзерләнеп йөренә башлады. Әгъдәс, тагын сугарга ниятләп, җайлы моментны эзләде.

– Мин синең кызыңны үтерәм! – дип кычкырды Арнольд. – Хатыныңны көчлим!

Бу сүзләрне ишеткәч, Әгъдәс бермәлгә туктап калды, шул мизгелдән файдаланып, Арнольд аның эченә типте. Әгъдәс сыгылып төште. Мин берничә тапкыр кизәндем, ләкин Арнольд, сикергәләп, артка чигенеп калды һәм тез астыма каты итеп типте. Мин авыртудан катып торганда, Әгъдәс аңа ташланды.

Шулвакытны техникумнан өерелешеп укучылар чыкты. Вахтер хатынның чәрелдәп кычкыруы ишетелде:

– Нишлисез?! Милиция! Сугышалар!

Халык җыелды. Сугышудан туктадылар, Арнольд шунда ук юкка чыкты. Җыелган тамашачылар да тиз арада таралып бетте.

– Кайда яши икән ул? – диде Әгъдәс, көчкә сулыш алып. – Хайван! Шәп сугыша... Адресын белмисеңме?

– Белмим.

Без эскәмиягә барып утырдык. Айгөл дә килеп чыкты. Безнең кыяфәтләребезне күреп, ул барысын да аңлады һәм, сүзсез генә башын аска иеп, каршыбызда басып торды.

– Кызымны үтерәм диде... падла, – дип ыңгырашты Әгъдәс.

Аның тавышында шөбһәләнү, курку бар иде. Ул Айгөлгә бик озак карап торды. Айгөл исә, үзен гаепле сизеп, бер миңа, бер аңа, бер читкә карады.

Әгъдәс торды да саубуллашмыйча китеп барды.

Курыкты ул да. Кызы, хатыны өчен пошаманга калды. Арнольд каршында ул да көчсезләнде. Айгөлгә карап торганда, аның ниләр уйлаганын аңладым. Ниндидер бер ят хатын-кыз өчен кызымны, хатынымны куркыныч астына кую кирәк микән, дип уйлады ул. Сугышканда Арнольдның җиңелмәве аны бермә-бер шомландырды, әлбәттә.

Мин як-ягыма карандым – Арнольд күренмәде.

– Киттек, Айгөл, – дидем мин, – кайтып уйлашыйк әле тагын.

Айгөл соңгы вакытта ябыкты, бите аксылланды, күзләре хәсрәт томаны белән пәрдәләнде. Ләкин бу борчулы, куркыныч халәт аның чибәрлеген томалый алмады. Аның гүзәллеген берничек тә, тыштан да, эчтән дә сүндереп булмас иде.

Сөйләшмичә генә өйгә атладык. Икебез дә әледән-әле артыбызга борылып карадык.

Тагын Әгъдәснең: «Минем бер танышым аның белән чуалган иде», – дигәне искә төште. Миндә көнләшү янә кабынды.

Ләкин Айгөлнең матур тавышын ишеткәч, эчтәге ярсу шул мизгелдә юкка чыкты.

– Илдар, әйдә карбыз алыйк әле, – диде ул.

Миңа кинәт рәхәт булып китте. Төзәлеп бетмәгән иреннәрем белән аның йомшак, җылы битеннән үптем.

Кибет каршында бер юан апа карбыз сатып утыра иде. Иң зурысын сайлап алдык та кайтып киттек.

* * *

Кичкә таба яңгыр ява башлады. Көзнең алтынсу аяз көннәреннән соң һәрвакыт табигатьтә бер котылгысызлык кабатлана – күктә бер генә якты сулыш алырлык та урын калмый һәм әллә ничәшәр көн тоташ яңгыр ява. Вак кына булып сибәләсә дә, октябрьнең яңгыры салкын һәм авыр булып төшә. Яңгырның тиз генә туктамасын белгәнгә күрә, яп-якты кояшлы көннәрдән соң дөньяның караңгыланып китүеннән күңелләргә дә томан сарыла.

Гадәттә, мондый төксе, салкын, юеш көннәрдә шигырьләр күп языла. Ул шигырьләрдә моң күбрәк була, ул шигырьләрдә дөньяны аңламау (һәм дә шул сәбәпле сәер фәлсәфәләргә чуму), кешенең табигать алдында көчсезлеге, үз-үзеңне белеп җиткермәү, кыскасы, бөек билгесезлек каршында каушау, курку күбрәк чагыла.

Офыклардан офыкларга кадәр җәйрәгән кара болытларны таратмакчы булып җил ачы итеп ыжгыра, ары сугыла, бире сугыла, ләкин аның өзгәләнеп елавы, электр чыбыкларында сәер көй чыгарып ыңгырашуы, агач ботакларына сыланып улавы – болар барысы да, киресенчә, көзнең шыксыз киченә шом һәм ниндидер мәкер өсти.

Җанда борчулар өерелгән вакытта, тормышта күңелсез хәлләр килеп чыкканда, мондый кичләр аеруча авыр һәм кичеп чыккысыз булып тоела. Бертуктаусыз коеп яуган яңгыр да, чарасызлыктан әрнегән сыман шыңшып бәргәләнгән җилләр дә күңелдәге авыр тойгыларны җебетә дә, тарата да алмыйлар, ә бәлки, җанныграк авырый, катырак борчыла һәм бер тарафта да яктылык күрми башлый.

Безнең дә менә шундый кичләребезнең берсе иде ул. Сөйләшмәдек. Айгөл, онытылырга тырышып, өйне җыештырган булды, ашарга пешерде, керләр юды. Тып-тын гына ашадык, аннан соң телевизор кабыздык. Тик аны караучы булмады. Айгөл диванга йөзтүбән капланды – йокламый, уйланып ята иде. Мин, китап алып, креслога утырдым, әмма укыганым истә калмады, һич кенә дә, онытылып, куркыныч уйларны куып тарата алмадым.

Айгөл торып утырды, бик озак миңа карап торды.

– Илдар, мин апамнарга кайтам... минем аркада син интегәсең бит...

– Шуннан? – дидем мин, көлемсерәп. – Апаңнарга кайттың ди?..

Ул авыр сулап куйды:

– Ә теге кеше килсә... әйтермен...

– Ни дип әйтерсең?

– Мин Илдарны яратмыйм... курыкканга күрә генә шулай дидем, дип әйтермен.

– Арнольдкамы?! – дидем мин, гаҗәпләнеп.

– Әйе.

– Шуннан?..

– Шуннан... теләсә нишләтсен, – диде ул, читкә карап. – Теләсә нишләтсен!

Бераз аңышмыйча утырдым.

– Син нәрсә... әллә аңа буйсынырга булдыңмы?! – дидем, аның ни әйтергә теләгәнен тәмам аңлап алгач.

– Соң, Илдар, башка чара юк бит инде, – диде ул битараф тавыш белән. – Сине дә күпме интектерергә туры килде... Җиңалмассың син аны...

Миндә тагын нәфрәт кабынды. Әле моңа кадәр аның Арнольдтан куркып качып йөрүе миңа аз булса да көч һәм кирелек өстәп тора иде. Аның шулай диюеннән коелып индем.

– Син чынлап әйтәсеңме? – дидем мин, бәлки әле, шаяртадыр дигән өмет белән.

– Әйе.

– Курыкмыйсыңмы?

– Куркам шул... Курыкканга күрә буйсынырга уйлыйм да инде...

Белмим, күңелемдә нинди хисләр күтәрелгәндер, көнләшүме, горурлыкмы:

– Юк! – дип кычкырдым. – Син аның белән булырга теләмисең!

Кинәт ул да кычкырып җибәрде:

– Теләмим! Куркам! Күралмыйм! Җирәнәм! Нишлим соң?.. Гел болай качып йөри алмыйм бит инде.

Мин аның янына барып утырдым, кочакладым. Әйтерсең лә шуны гына көткән, башын иңемә куйды да кычкырып елап җибәрде.

Озак елады ул. Күзгә яңгырны беркем, берни туктаталмаган кебек, бу очракта аны да елавыннан туктатып, юатып булырлык түгел иде.

Ул тагын диванга капланды. Мин бүлмә буйлап әрле-бирле йөренә башладым. Айгөл торып утыргач, аңа карап елмайдым. Ул да елмайды.

– Аптыраганнан әйтәм инде, – диде ул.

Мин инде үзем өчен катгый карар кабул иткән идем: Айгөлне Арнольдка бирмим!

– Бирелергә ашыкмыйк әле, – дидем, аның янына утырып, – мин исән бит әле... Дусларым ярдәм италмасалар да... ләкин мин үзем актык сулышыма кадәр тора алам бит... Инде һич тә юк икән... закон бар бит... милиция.

Бу сүзләрне күбрәк Айгөлне тынычландырыр өчен әйткәнмендер инде. Сүзләремдә ялган күп иде бугай... Актык сулышка кадәр яклый аламмы соң мин аны?.. Көчем, сабырлыгым җитәрме?.. Ничек инде, үземә ышанып бетмәгән килеш, андый вәгъдә бирдем мин?.. Милиция дип... Монысы егетләрчә түгел бит инде аның. Ир-егетләр арасында милициягә барып әләкләү пычрак

эш санала бит. Аннары шунысы да бар – милиция дә гел саклап йөрмәячәк.

Башыма нинди генә уйлар килсә дә, Айгөлне үземнең янымнан беркая да, беркемгә дә җибәрәсем килми иде.

– Миңа барыбер синең белән куркыныч түгел, – диде ул, уйларымнан аерып. – Мин синең янында үземне барыбер тыныч хис итәм. Синең белән рәхәт... Синең өчен күбрәк борчыла башладым... Минем аркада Арнольд сиңа яный бит.

– Анысы турында уйлама, – дидем мин. – Безгә нык торырга кирәк... Аның да түземлеге берәр кайчан бетәр.

Айгөл кинәт:

– Ташлама мине! – дигәч, үземдә зур көч тойдым.

– Ярар, – дидем мин, елмаеп.

Ул, урын җәеп, йокларга ятты, ә мин тагын, креслога чумып, уйлар диңгезендә чайкала башладым.

Миннән китеп барса, бәлки, яхшырак булыр дигән уй килде. Апасында торса, кичләрен Арнольд анда барып йөрмәс... Ә көндез сакланыбрак йөрер иде... Алай дисәң... әгәр үзе Айгөлне көчләп яраттыра алмаса, миңа барыбер куркыныч янаячак... Айгөлнең үзенә дә... Әгәр дә... Айгөл аныкы булырга ризалашса... бу очракта беркемгә дә куркыныч янамый түгелме соң?..

Эчемә җылы йөгерде. Инде әллә ничә ирне татыган бер хатын-кызның аңа буйсынуыннан гына ни булган... ләкин шунда ук бу уйлардан эсселе-суыклы булып киттем. Мин Айгөлнең аның белән йоклавын күз алдыма китердем. Аның Айгөлне кочаклавын, үбүен, чишендерүен аермачык күрдем. Бу уйлардан җирәндем, оялдым һәм аларны башымнан тизрәк куарга тырыштым.

Кинәт ишек кыңгыравы зеңгелдәде. Сискәнеп киттем. Айгөл дә уянып башын калкытты, куркып миңа карады.

Мин АНЫ көткән идем. Шуңа күрә бигүк котсыз калмадым. Шулай да йөрәгем муен тирәсендә дөпелди башлады. Кыңгырау тагын зеңгелдәде, аннары ишекне шакыдылар.

Тиз генә кухняга чыгып, ит кисә торган зур пычакны алдым. Айгөл торгач: – Ят, ят, ник тордың? – дидем мин.

Ул нишләргә белмичә диванда утырып калды.

Ишекне ачтым. Ялгышмаганмын – каршымда Арнольд басып тора иде. Өс киеме яңгырда чыланган.

Минем пычак тотып торуымны күргәч, ул берничә адым артка чигенде. Аның артка таба атлавы миңа куәт өстәде.

– Туктыйсыңмы, юкмы безне эзәрлекләүдән?! – дидем.

Ярсуымны күреп, ул бер дә аптырамады шикелле, шулай да бер урында катып калды. Кулымда пычак булса да, үземдә нык-лы ышану тоймадым. Әгәр дә ул миңа ташлана калса, белмим, пычак белән кадый алыр идем микән, юкмы...

– Бар кит! Якын килмә! – дидем мин, калтырана башлап.

Минем бу халәтем невротикларга гына хас өянәкне хәтерләтә иде бугай.

– Инде боксчы дусларың да коткара алмаганны, бу пычак белән

генә миннән котыла алмаячаксың, – диде ул тыныч кына. – Айгөл синдәме?

– Миндә. Аның сине күрәсе дә килми. Бар кит! Оныт аны!

– Бир миңа Айгөлне!

– Бирмим! Ул синең белән булырга теләми.

– Чыксын әле... Аның белән сөйләшергә телим, – диде ул һәм миңа таба атлады.

Мин кычкырып җибәрдем:

– Якын килмә! – Һәм площадкага чыгып, артымнан ишекне япкач: – Якын килмә, кадыйм! – дип өстәп куйдым.

Ул туктады да көлемсерәп миңа карап торды.

– Корал миндә дә бар, – диде ул, елмаюдан туктап. – Шаярма пычак белән! Син нишләп ул кызыйга ябыштың соң? Нишләп миңа бирәсең килми аны? Шулай бик шәпмени ул проститутка?

– Проститутка түгел ул!

– Син аны миңа биреп тор... Мин аны «авыз итеп» карыйм... Ошамаса, кире сиңа бирермен. Кем белгән, бәлки, секс партнеры буларак миңа ошамас та әле ул.

– Ул уенчык түгел! – дидем мин, ярсуымнан тыела алмыйча. – Кешедән кешегә бирергә ул уенчык түгел!

Арнольд, башын чайкап:

– Дурак син! – диде һәм лач итеп идәнгә төкерде.

Кычкырып сөйләшүебез күршеләрне уятты, каршы фатирның ишеге ачылды һәм, пычак тотып торуымны күргәч, ишек шунда ук ябылды.

– Мин синнән курыкмыйм, – дидем. – Түземлегемне сынама... үтерәм мин сине.

Ул пырхылдап көлеп җибәрде.

– Куркасың син миннән... Хәтта пычак белән кадарга да куркасың. Дурак син! Бер кыз өчен харап булачаксың бит... Миңа каршы торганнарның фаҗигагә юлыкмый калганнары юк әле.

Лифтны чакырып тормады, ул җәяү генә аска төшеп китте.

Эчке киеренкелек бөтен гәүдәмне шартлап өзелерлек дәрәҗәгә җиткергән бер нерв җепселенә әверелдерде. Нишләгәнемне аңламыйча өйгә кердем, ишекне бикләдем, пычакны никтер телевизор өстенә куйдым. Китап киштәсе янына бардым, калтыранган кулларым белән ниндидер китап алдым, шунда ук кире урынына куйдым.

Айгөл дә, шәлперәеп, мине күзәтеп утыра иде. Кыяфәтем аны нык куркытты, ахры, миңа тыныч кына эндәште:

– Илдар.

Мин бер сүз дә дәшмәдем, тынычлана алмыйча кухняга чыктым, аннан соң никтер ванна бүлмәсенә кердем һәм үземне көзгедән карап тордым. Битем ап-ак, күзләрем элпә белән капланган иде. Невроз бу дип уйладым. Нишләптер кулларымны сабынлап юасы иттем.

Бүлмәгә кергәч Айгөлгә:

– Курыкма, йокла, – дидем.

Үзем, креслога иңеп, күзләремне йомдым. Ике сәгать чамасы утырганмындыр, хәйран тынычланган кебек булдым һәм Айгөл янына барып яттым.

* * *

Мин уянганда, сәгать унбер иде инде. Янымда Айгөл күренмәгәч, кухнядадыр дип уйладым, чөнки якшәмбе – техникумда ял көне.

– Айгөл!

Җавап ишетелмәде.

– Айгөл!

Тынлык.

Сикереп торып кухняга чыктым – беркем дә юк иде. Ваннада да, туалетта да юк. Өстәлдә записка-фәлән күренмәгәч, аптырадым. Кайда икән ул?

Озак борчылырга туры килмәде, кайтып керде. Бер кулында пакет, икенчесендә сумка иде.

– Кайда йөрдең?

– Кибеткә бардым, сөт, ипи, ярма алып кайттым.

– Котымны алдың. Моннан соң миннән башка беркая да чыкма. Сагалап торуы бар...

– Урам тулы кеше... Көндез нишләтә ала инде ул мине?.. – диде ул, бер дә аптырамыйча.

Чыннан да... Мин Айгөлгә караганда да ныграк куркам түгелме соң?.. Ләкин шунда ук аның куркыныч сүзләре искә төште, үзен аямыйча сугышуы, горур һәм тәкәббер кыяфәте күз алдыма килде, ямьсез корыч тавышы колагымда яңгырады. Юк, ул көндез дә куркыныч иде.

– Шулай да сак булырга кирәк, – дидем мин.

Яңгыр һаман сибәли иде, шуңа күрә көне буе өйдә утырдык. Телевизордан хәйран кызык тапшырулар күрсәттеләр, шул сәбәпле кәефләребез бераз күтәрелде. Тик кичкә таба тагын икебезнең дә сөмсеребез коелды.

Көтмәгәндә Айгөл:

– Бүген дә килер микән? – дип куйды.

– Килүе ихтимал.

– Илдар, син аңа пычак белән кадый күрмә... Үтерерсең... Төрмәгә утыртып куярлар үзеңне...

Мин дәшмәдем.

Авыр тынлык тагын фатирны яулап алды һәм без, ишек кыңгыравы зеңгелдәвен көтеп, киеренкелек кичереп утырдык.

Ләкин килүче булмады.

Йокларга ятар алдыннан бераз җиңеллек тойсам да, киләсе көн өчен борчылу башланды. Иртәгә Айгөл техникумга бара. Мин әле ресторанга бармаячакмын – битем төзәлеп бетмәгән. Айгөлне техникумга озатып куярга, аннары каршы алырга кирәк.

Йоклап китә алмый бик озак яттык.

– Илдар, син ул ресторанда җырлавыңны ташла, – диде Айгөл, шактый вакыт сөйләшмичә яткач.

– Нигә алай дисең?

– Юньле эш түгел бит инде.

– Шулай шул, – дидем мин, авыр сулап. – Җырлыйсы килә бит…

– Башка эштә эшләп тә җырлап була бит. Шигырьләр, хикәяләр язасың… Минемчә, сиңа абруйлырак эш кирәк… Син бит күбрәк язуга омтыласың.

Җавап бирмәдем. Авырткан урыныма басты Айгөл. Дөрес әйтә ул.

Профессиональ сәхнә дип… Гомер буе ресторанда җырлап булмас инде. Казанга китәргә иде. Әдәби әсәрләремне матбугатта чыгарырга да җай күбрәк анда. Аннары… Казанда яшәү зур сәхнәгә менәргә мөмкинлек тудырыр иде… Шулай, провинция – провинция инде ул.

– Дөрес әйтәсең, – дидем. – Тагын бер ярты елдан уйларга кирәк булыр… Чын иҗат белән шөгыльләнер вакыт җитте бугай. Әле бүген ул турыда уйларлыкмыни… Күрәсең бит, нинди хәлдә әле без синең белән…

– Нинди хәлдә?

«Арнольдтан котылу турында уйларга кирәк» дип әйтмәкче идем, тыелып калдым.

– Йокла, – дидем мин һәм үзем торып утырдым.

Тышта яңгыр. Өйдә дә җылылык юк. Тормышта да, иҗатта да. Иртәгесе көндә дә – шомлылык, билгесезлек.

Дөньяның яме югалды. Егерме сигез яшьтә бит инде мин. Ни эшләдем дә нинди гамәлле нәрсә кылдым соң?!

Матбугат битләрендә берән-сәрән чыгып килгән шигырьләрем, хикәяләрем өчен генә яшәмимдер бит… Нәрсә яздым да искитәрлек нинди яңа фикер әйттем?! Дөрес, әле матбугатта дөнья күрмәгән әсәрләрем дә байтак, ләкин алар гына иҗатымны әһәмияткә ия итә алырлармы?..

Барысы бергә өелде: иҗатымнан канәгатьсезләнү, күзнең эчпошыргыч яңгыры, Айгөл белән араларның һаман өзелмәве, ресторанннан китеп зур сәхнәгә адым ясарга батырчылык итмәү, Арнольдтан курку, үземне һәм бичара Айгөлне якларга көчем җитмәү һ.б.

Шом, курку әсир итте. Авыр, караңгы уйлар йөгән алып ташларга көч җитми иде. Кеше көчле, имеш… Ялган! Һәр кеше дә көчле була алмый. Табигать көчле иткән икән – син көчле. Бөтен кешегә дә герой булырга язмаган. Батырлыгы юк икән, ул кешедән ничек каһарманлык таләп итәсең?! Кешеләр һәммәсе дә батыр йөрәкле, курку белмәс булып туса, инде күптән бер-берсен үтереп бетерерләр иде.

Кемдер амбразураны күкрәге белән томалый, ә кемдер, атакага күтәрелү белән, йөрәге ярылудан үлә. Аларның берсен дә гаепләргә ярамый.

Һәрбер кеше дөньяга үзенә тиешле бер миссия белән килә: кемдер бөек эшләр кылырга, кемдер батырлыклар майтарырга, кемдер сәнгать өчен, кемдер вак-төяк эшләр белән гомер итәргә.

Дөнья бит бу... Бу дөньяга, мәсәлән, мин тумасам, Арнольд куркыныч кеше булмас иде. Мин аңа караганда көчсезгә күрә генә ул горур һәм батыр.

Ә Арнольд кебекләр тумаса, дөнья бөтенләй күңелсезләнер иде, чөнки үзәк өзгеч вакыйгалар бетәр иде, детективлар, кинолар, китаплар иҗат ителмәс иде... Арнольд кебек куркыныч кеше тумаса, барлык кешеләр батыр һәм курку белмәс булырлар иде, шул сәбәпле үтерүләр, көчләүләр, талаулар бермә-бер артыр иде.

Ләкин бу фәлсәфи уйлануларым миңа тынгылык бирмәде. Һәркемне, һәрнәрсәне якларга мөмкин, әмма минем әле Арнольд белән тагын очрашасым бар иде. Ситуация килеп чыккач, философия дигән нәрсәнең эзе дә калмый, юкка чыга. Чөнки синең фәлсәфәң башка кешенеке белән һич кенә дә тәңгәл килми. Карашлар бертөсле булуы мөмкин, аң дәрәҗәсе бер үк булуы ихтимал, ләкин һәркемнең дөньяда кайнаган тормышка мөнәсәбәтләре үзенчәлекле. Беркайчан да «Мин хаклы!» дип әйтергә ярамый, чөнки бу дөньяны һәркем үзенчә кабул итә, үзенчә кичерә һәм җавап бирә.

Арнольд кебек таш бәгырьле кешеләр булмаса, дәүләт дигән механизмның, төрмәләрнең, тәртип саклаучы органнарның кирәге калмас иде.

Кешеләр җинаятьсез яши алмыйлар. Җинаятьчеләрне хөкем итсәләр дә, кансызлыкка, ерткычлыкка көрәш игълан итсәләр дә, кешеләр, үзләре дә аңламыйча, аң астындагы ниндидер сәер һәм серле тойгы белән вәхшилекне хуплыйлар, ләззәтләнеп кабул итәләр.

Куркыныч киноларны адәми затлар йотлыгып карый. Гәҗитләрдән оператив хроникаларны яратып укыйлар, чөнки анда җинаятьләр турында сүз бара.

Әсәрләрдә көчләү, талау, үтерү булса, ул китаплар зур уңыш казана һәм кыйммәт бәяләргә сатыла. Сугыш турындагы фильмнарны, әсәрләрне яраталар, чөнки аларда – кан, үтерү, җимерү, яндыру – коточкыч вакыйгалар кайный.

Курку теләге яши кешедә!

Кешеләрнең бер-берсен җәберләве миллионнарның күңелләренә хуш килә. Чөнки кинода үлүче кеше син түгел. Үтерүчесе дә син түгел. Коточкыч күренешне тамаша кылып утыручы үзен корбан итеп күз алдына китерми. Күренешне тиешле дәрәҗәдә кичерми, аңлап бетерми.

Детектив әсәрне яратып укучы кеше үзен суеп үтерүләрен теләми, ләкин башка берәүнең муенын пычак белән ышкуларын рәхәтләнеп укый.

Куркырга тели!

Кинода берәр садист хатын-кызны көчләсә, телевизор караучы экранга якын ук килә. Ләкин беркемнең дә үз хатынын яки кызын көчләтәсе килмәс иде.

Кеше ерткычлыкны күреп, укып, ишетеп ләззәт, канәгатьләнү таба һәм шул ук вакытта үзендә һәрвакыт җан тынычлыгы эзли, үзен беркайчан да җәберләтәсе килми.

Курка!

Кемнеңдер җанын кыйсыннар, аңа гына тимәсеннәр!.. Куркыныч вакыйгаларга җаны сусый, экраннардан, китаплардан кан һәм мәет эзли, ә үзенә куркыныч янаса, ярдәм сорый, игелек, миһербан көтә.

Курка!

Һәм шул ук вакытта куркырга омтыла.

Менә минем белән дә романнарда очрый торган вакыйга килеп чыкты. Персонажы да китаптагыча – исеме Арнольд, көчле, куркыныч, эзәрлекли, сугыша.Тик мин генә китаптагыча каршы торырга үземдә җитәрлек көч тапмадым. Романда яисә китапта минем урында берәү бер-ике сугуда Арнольдны һушсыз калдырыр иде һәм, Айгөлне коткарып, рәхәт гомер кичерер иде.

Юк, тормышта алай түгел шул... Чынбарлыкта китаптагы кебек бөтен нәрсәне тезеп, төскә буяп, матур итеп кенә тәгәлләп булмый!

Тормышның чынын язсаң, аны укучы да булмас иде. Хәер, аның чынын язып бетерергә сүз дә, көч тә җитмәс иде.

Чынбарлык барыбер куркынычрак. Чынбарлык, әдәби әсәрдәге сыман, курку хисләрен бер мәлгә генә уятып калмый, чынбарлык кешенең гомере буе котын алып тора.

Арнольдның теге вакытта әйткән сүзләре искә төште: «Курку һәр кешедә яши... Курку – яшәешнең этәргече... Курку – бөек көч, бөек хис! Курку булганга гына бу дөньяда тормыш дип аталган ыгы-зыгы бар...»

Алай ук микәнни?! Курку һәр кешедә бар – анысы дөрестер, ләкин гел курку тоеп яшәве дә авыр бит...

Курку, курку... Аңарда курку хисләре юк түгелдер ләбаса?.. Нәрсәдән курка икән ул?.. Ни белән өркетеп була икән аны?.. Гаиләсе, әти-әнисе бар микән?.. Кем икән ул?.. Нәрсә икән?..

* * *

Айгөлне техникумга кадәр озаттым һәм, дәресләр тәмамлангач, каршы алдым. Кесәмдә пәке йөртә башладым.

УЛ күренмәде. Яңгыр туктаган иде инде, җәяүләп атладык. Очрамаса да, ул якында гына, безнең тирәдә йөридер шикелле иде.

Өйгә җиткәндә, күңел сизенде: УЛ подъезда көтеп торадыр. Күңел кат-кат кабатлады: «Подъезда сагалап тора. Шунда ул!»

Шигемне Айгөлгә белгертмәдем. Аякларым үзләре шәһәр милициясе урнашкан бинага таба атладылар. Милиция бүлеге мин яши торган урамда, минем йорттан өч квартал ераклыкта гына урнашкан иде.

– Кая барабыз без, Илдар? – диде Айгөл.

– Милициягә.

Ул бүтән дәшмәде.

Әйе, Әгъдәс тә, ресторан «авторитетлар»ы да миңа инде ярдәм итмәячәкләр. Хәлләреннән килми. Ә үзем пычаксыз каршы тора алмаячакмын. Пычакны кулланып исә төрмәгә кереп утыруым да ихтимал.

Уголовный розыскта бер танышым эшли иде, шуның белән киңәшеп карарга булдым.

...Хәбибуллин, утыз биш-кырык яшьләрдәге капитан, үзебезне хәйран җылы каршы алды. Бүлмәсенә килеп керү белән, Айгөлне майлы күзләре белән җентекләп күзәтте. Айгөл аңа бик ошады бугай – бер-беребезнең хәл-әхвәлләрен сорашкан арада, ул аңардан күзләрен алмады һәм ниндидер өмет катыш сынаулы елмаюы белән Айгөлне оялтып бетерде.

Мин барысын да сөйләдем. Ярдәм итүен сорадым.

Хәбибуллин күп уйлап тормады, тезеп китте:

– Тә-ә-әк... Монда болай итәргә кирәк... Айгөл аның белән булырга ризалашсын. Айгөлнең бүлмәсенә кайтсыннар... Чишенеп караватка яткач, Айгөл кычкыра башлый... көчлиләр, дип... Алдан берничә сержантны тулай торак янына куярбыз. Айгөл кычкырып ярдәмгә чакыра. Все! Арнольдыгыз 117 нче статья белән зонага сетка үрергә китә. Чишенгәнче дә була... Айгөл үзенең күлмәген үзе ерта да, көчлиләр, дип кычкыра. Җенси мөнәсәбәтләргә керсәләр, көчләү өчен утырачак, ә инде болай гына кычкырса, «за попытку» китәчәк.

Айгөл дә, мин үзем дә таң калдык. Хәбибуллинның һич кенә тартынмыйча, оялмыйча шундый тәкъдим ясавы безнең өчен көтелмәгән нәрсә иде.

– Ә башкачарак булмыймы соң? – дидем мин.

– Мин дә риза түгел, – диде Айгөл.

Хәбибуллин эре тешләрен күрсәтеп елмайды:

– Башкачарак нишлисең инде? – диде ул. – Аны башкача төрмәгә утыртып булмый.

– Ник?.. Төрмәгә утыртмыйча гына булмыймыни? – дидем мин. – Сөйләшеп, куркытып. Мәсәлән...

– Андыйлар милициядән бик курыкмыйлар шул. Адресын белмисеңме?

– Белмим.

– Адресын белмәгәч, аны ничек итеп отделга чакыртабыз соң? Тотып алып килер өчен сәбәп кирәк бит. Моның өчен бездән сезгә сакчылар кирәк булачак.

Хәбибуллинның Айгөлдән күзләрен алмыйча утыруы җанымны ашады. Чыгып йөгерәсем килде хәтта. Ләкин милиция соңгы таянычыбыз иде.

– Бер-ике сержантны ярдәмгә бирә алмассызмы соң? – дидем. – Мин аларга акча түләр идем.

Хәбибуллин көлеп куйды.

– Ярар, сөйләшеп карармын. Ләкин бу очракта аларга приказ

биру мөмкин түгел. Үтенеч формасында гына мөрәҗәгать итеп була. Алар да куркалар бит... Сержантларның да андый кешеләр белән конфликтка керәселәре килми. Шәһәр кечкенә. Теләсә кайсы вакытта сагалап торып үтерүләре бар.

– Берәр чара таба алмассыз микәнни? – дидем мин.

– Мин бер чараны тәкъдим иттем инде. Аннары... аны бит җинаять өчен генә тотып кулга алырга мөмкин. Ярар, аптырашмагыз әле, уйлашырбыз. Сез, Айгөл, иртәгә көндезге дүрттә миңа керегез, ямме?

Айгөл миңа карап куйды. Икебез дә аңладык: Хәбибуллинның Айгөлгә күзе төште. Безнең качып йөрүебез дә, Арнольдның безне эзәрлекләве дә аны кызыксындырмый иде.

Шулай да Айгөл:

– Ярар, – дип килеште.

– Мин килимме соң? – дидем мин.

– Юк, кирәкми, – диде Хәбибуллин. – Мин Айгөлгә киңәшләр бирермен, үзен ничек тотарга кирәклеген аңлатырмын.

Шулвакытны тәрәзәгә күз салдым. Һәм сикереп тордым – урам буйлап, салмак кына атлап, Арнольд бара иде. Күңелем дөрес сизгән – ул минем йорт ягыннан килә иде, димәк, чынлап та подъездда көтеп торган.

Мин кычкырып җибәрдем:

– Әнә ул! Әнә Арнольд бара!

Хәбибуллин да сикереп торды:

– Тәк, тәк... Айгөлдә фатирыңның ачкычы бармы?

– Бар.

– Айгөл, тиз генә чык та, урамның икенче ягыннан атла, – диде Хәбибуллин, тәрәзәдән тышка карап. – Ул сине күрсен. Бәйләнә башласа, Илдарның өенә йөгер. Ул синең артыңнан барсын. Сиңа ияреп фатирга керсен. Шунда кычкыра башла, күлмәгеңне, юбкаңны ертырга тырыш. Бар, тиз бул! Мин хәзер берничә кеше алам да синең артыңнан барам. Син, Илдар, монда калып тор! Күренми тор, алайса, оештырылган эш икәнен сизенер.

Айгөл тораташ булып катып калды.

– Бар, Айгөл, – дидем мин. – Бар, бәлки, бу бердәнбер соңгы чарадыр.

Айгөл чыгып йөгерде. Хәбибуллин телефоннан шалтыратырга тотынды. Ул кемнәргәдер ниндидер командалар бирде.

– Аны куркытырга гына кирәк, – дидем мин. – 117 нче статьяларны аңа ябыштырып маташмаска иде...

– Син хаклы, – диде Хәбибуллин, чыгып китәргә җыенып, – куркытабыз гына аны. – Дөресен әйткәндә, хатын-кыз өчен мондый гауга куптару бөтенләй кирәк түгел, кәнишне.

Ул чыгып китте. Мин тәрәзәдән урамны күзәтә башладым.

Милиция бинасыннан бер йөз адым чамасы читтәрәк Арнольд белән Айгөл сөйләшеп торалар иде. Менә Айгөл, тиз-тиз атлап, минем өйгә таба китеп барды. Арнольд аның артыннан иярде. Айгөл йөгерә башлады, Арнольд та адымнарын кызулатты.

Мин үземне кая куярга белмәдем. Хәбибуллин җитешер микән? Соңга калмас микән?.. Инде кузгалыр вакыт җиткәндер бит... Түзмәдем. Ишегалдына чыктым. Хәбибуллин да, сержантлар да күренми. Инде фатирга кергәннәрдер... Инде Арнольд Айгөлгә бәйләнә башлагандыр.

Гамьсез кыяфәт белән Хәбибуллин һәм ике сержант вытрезвитель ягындагы ишектән килеп чыктылар. Тынгысызланып, арлыбирле йөреп торуымны күреп, Хәбибуллин елмайды:

– Борчылма. Адресың ничек әле синең?

– 33 нче йорт, 17 нче фатир. Инде барырга вакыттыр бит.

– Юк әле, иртәрәк, – диде ул, – ун-унбиш минут вакыт үтсен.

Ул тагын нәрсәдер мыгырдады, ләкин мин аны тыңлап торырлык хәлдә түгел идем. Бар көчемә өйгә йөгердем. Айгөлне берүзен аның белән биш-ун минутка түгел, бер минутка да калдырырга ярамый иде.

Хәбибуллин артымнан кычкырып калды:

– Тукта!

Мин туктамадым.

...Ишек бикле түгел иде. Фатирга атылып кердем. Айгөл креслода, Арнольд диванда утыра иде.

Көчкә сулыш алып, ишек яңагына сөялдем.

– Тынычлан, Илдар, – диде Арнольд, көлемсерәп.

– Бар, чыгып кит, – дидем мин, сулышымны тигезли алмыйча җәфаланып. – Бар, кит, күземә күренмә!

Арнольд урыныннан кымшанмады.

Шулвакытны милиционерлар килеп керделәр.

Арнольд аптырамады да, гаҗәпләнмәде дә.

– Миңа монысы кирәк түгел иде, – диде ул, миңа карап.

– Арнольд, син аңла. Минем башка чарам юк, – дидем мин, үзем дә сизмәстән aклана башлап.

Хәбибуллин алга үтте:

– Ярар, ярар, акланма! Өеңә ят кеше кергән, сөяркәң белән утыра, ә син акланып торасың.

Арнольд торып басты.

– Кем буласың инде син? – дип мөрәҗәгать итте аңа Хәбибуллин.

– Ә син үзең кем буласың? – диде аңа Арнольд.

– Мин угрозыск капитаны Хәбибуллин булам.

– Кая... удостоверениеңне күрсәт.

Хәбибуллин мондый дорфалыкны көткән, ахрысы, ачуы килмәде, үзен сабыр һәм итагатьле тотты. Таныклыгын күрсәткәч, ул:

– Сорауларны мин сиңа отделга баргач бирермен инде, – диде. – Әйдә, киттек.

Сержантлар Арнольдны алып чыгып киттеләр, Хәбибуллин фатирда калды.

– Кагылмадымы? – дип сорады ул Айгөлдән.

– Юк. Сез кычкырырга кушкан идегез... Булдыра алмадым мин... Кагылмагач, ничек кычкырыйм инде...

– Ярар, ярар, бик әйбәт, – дидем мин, аны тынычландырырга тырышып.

Минем тизрәк аның Арнольд белән ни турында сөйләшкәннәрен беләсем килде.

– Бер унбиш минуттан отделга килегез, – диде Хәбибуллин. – Мин Арнольд белән сөйләшә торырмын. Ә син, Айгөл, тиз генә гариза яз!

– Нинди гариза? – дип сорадым Айгөл өчен.

– Милиция начальнигы исеменә. Менә шулай... Арнольд исемле кеше бәйләнеп йөдәтә, дип... Куркыта, дип яз. Илдарны кыйнаганын да яз...

Мин аның сүзен бүлдем:

– Алары ук кирәк түгелдер инде.

– Кирәк, кирәк. Барысы да кирәк. Унбиш минуттан икегезне дә көтәм.

Ул чыгып киткәч, Айгөлгә карап, аның сөйләвен көттем. Ә ул исә көчәнеп кенә елмаеп куйды. Аның болай тыныч булуы миңа ниндер бик сәер тоелды.

– Ник кычкырмадың?.. Нишләп ярдәмгә чакырмадың?.. – дидем мин һәм шунда ук тупас, мәгънәсез сорау биргәнемне аңладым.

– Илдар, мин бар көчемне җыеп кычкырмакчы булып карадым... Тик ул миңа кул күтәрмәде, көчләргә тотынмады. Килеп чыкмады миннән, булдыра алмадым... Моның өчен бик оста актриса булырга кирәктер.

Дөресен генә әйткәндә, аның кычкырмавына һәм Арнольдка 117 нче статья ягылмавына мин шат идем. Хәбибуллин оештырырга маташкан «спектакль» баштан ук күңелемә хуш килмәгән иде.

Әмма Айгөлнең ярдәм сорап кычкырмавына, алдан оештырылган гаделсез ысул белән кешене төрмәгә утыртырга теләмәвенә сөенсәм дә, шул ук вакытта мин тагын караңгы уйлар чокырына егылып төштем.

Нишләп әле ул Арнольд белән тыныч кына сөйләшеп утыра иде?.. Кычкырмавының чын сәбәбен әйтте микән миңа Айгөл?.. Әллә инде башка сәбәп бар микән?..

Көнләшү иде бу. Курку, башка төрле курку нервларымның җепселләре буйлап аска да, өскә дә үрмәләде. Айгөлне миннән алып китәрләр дигән курку иде микән, әллә аларның бер-берсеннән курыкмыйча сөйләшеп утыруларыннан куркумы?..

Ничек кенә булмасын, бу юлысы куркуның исеме көнләшү иде. Хәбибуллинның да, сержантларның да күбрәк Айгөл белән кызыксынулары (Арнольд белән түгел!), Айгөлнең бүген Арнольдтан курыкмавы – барысы бергә җыелып, миндә яңа төрле депрессия башланды. Айгөлгә ябышып, аны беркемгә дә бирмәскә, яшереп куярга, хәтта Хәбибуллин янына да бүтән бармаска дигән теләкләр туды.

Әллә үтерергә микән Айгөлне?! Шушы куркыныч уй мине айнытып җибәрде. Хәшәрәт уйлардан арыну юк икән.

Айгөл миңа карап елмаеп утыра иде.
– Менә, гаризаны яздым, – диде ул.
– Айгөл, карале, нәрсә диде ул сиңа?
– Кем?
– Арнольд.
Ул авыр сулап куйды.
– Һаман бер үк нәрсәне кабатлый инде ул – женси мөнәсәбәтләргә керергә кыстый. Куркыта, яный.
– Ә син?
– Ә мин нәрсә?.. Гадәттәгечә, ризалашмыйм.
– Син… нишләп болай тыныч соң? Елмаеп утырасың… – дидем мин, аларның бүтән сүзләре дә булгандыр дигән уй белән.
– Әй, Илдар, арыдым мин. Туйдым! Милиция ярдәм итәр дип уйлыйсыңмы әллә син?! Аның белән сөйләшәчәкләр дә шуның белән вәссәлам. Ә Арнольд барыбер теңкәбезгә тиячәк. Милиционерлар үзләре миңа бәйләнеп йөрмәгәйләре әле. Ул синең Хәбибуллиның да юньле кешегә охшамаган.
– Туктале… Бәлки, милициянең тәэсире булыр… Тагынниләр сөйләштегез?
– Шул инде… Минем белән йокламасаң, Илдарың үләчәк, ди. Аннары үзең дә, ди…
– Әйдә, унбиш минут үтте бугай инде. Бәлки, Хәбибуллин янында аның белән күзгә-күз карашып, кешеләрчә сөйләшә алырбыз.
Айгөл сәер итеп елмайды.

* * *

Кабинетында Хәбибуллин үзе генә иде. Айгөлгә ул коридорда утырып торырга кушты.
Айгөлнең гаризасын өстәлгә куйдым.
– Мин аның белән сөйләштем, – диде Хәбибуллин бик зур эш майтарган кыяфәт белән. – Ул әдәпле, зыялы кеше, хулиган түгел, җинаятьче түгел… Мин аның белән әйбәтләп сөйләштем…
– Шуннан? – дидем мин, аптырап. – Безгә бәйләнүдән туктаячакмы соң ул?
– Юк, туктамаячак, – диде ул коры гына.
Угрозыск инспекторы моны шулкадәрле тыныч һәм берни булмагандай әйтте ки, хәтта сикереп торып, аның бугазына ябышасым килде.
Шулай да сабырлыкны җуярга ярамый иде.
– Ничек инде? – дидем.
Хәбибуллин урындыгында киерелеп елмайды:
– Илдар, тыңла әле мине. Син – җырчы, шагыйрь кеше. Солидныйрак булырга кирәк сиңа. Бер потаскуха өчен сугышып, җәнҗал куптарып йөрмә!
Түзмәдем, сикереп тордым.
– Син ничек шулай битараф була аласың?! Мине якын итми-

сең икән инде... ичмасам, законны хөрмәт ит! Син бит шул законны яклар өчен куелган кеше.

– Утыр әле, Илдар, кызма. Зинһар, матур сүзләр сөйләмә. Син бит иске китаптагыча сөйлисең. Тормыш бит бу... Әле хәзергә ул Арнольдны бернишләтә дә алмыйм. Чөнки җинаять кылмаган әле ул.

– Аның җинаять эшләгәнен сабыр гына көтеп йөрергәмени инде хәзер?! – дип кычкырдым мин.

– Кычкырма, Илдар, – диде Хәбибуллин ясалма ягымлылык белән. – Тиктомалга кешене ябып бикләп куя алмыйсың, ни кыйный алмыйсың. Мин аңа әйттем, «Илдар белән Айгөлгә бәйләнеп йөрүеңнән тукта!» дидем. Ул әйтә, «Юк, Айгөлне минеке иткәч кенә туктаячакмын!» ди. Монда, туган, мәхәббәт! Монда милиция нипричем.

– Ничек инде?! Нинди мәхәббәт турында сөйлисең син?! Айгөл аңардан курка... куралмый!

– Анда синең ни эшең бар? Беткәнмени хатын-кызлар дөньяда?! Хатын-кыз бүлешеп йөри торган заманмыни?!

– Мин синнән мондый сүзләр ишетермен дип уйламаган идем. Ул бит мине үтерергә йөри!

Хәбибуллин авызын кыйшайтты:

– Үтерергә йөри дип тә кешене төрмәгә ябып булмый.

– Төрмәгә генә димени... Башкача куркыт!

– Юк, Илдар дус, бөтен кеше дә милициядән курыкмый бит. Дөресен әйткәндә, Арнольд кебек укымышлы, эрудицияле, хәйләкәр кешеләрдән милиция үзе бераз шүрли.

– Син дә шүрлисеңмени?

– Ничек аңлатыйм инде мин сиңа... Аны ничек куркытырга тиеш соң мин?.. Ул законнарны бик яхшы белә. Өстәвенә ул – кыю, чая кеше. Андый кешене кайвакыт, җинаять кылган урынында тоткан суәттә дә, гаеплелеген исбатлый алмый йөдисең. Аның белән низаглашып йөрүдән тукта син! Ул барыбер үз сүзендә торачак. Айгөл белән араңны өз.

– Юк!

– Беләсеңме нәрсә... – диде ул, хәйләкәр елмаеп. – Айгөлне без үзебез ун-унбиш көн саклап йөрербез. Минем дача иркен... Йоклау шунда булыр...

Бу кешегә ник мөрәҗәгать иткәнемә үкенә башладым.

– Дачага?! Айгөлне шунда алып бармакчымыни син?!

Ни сәбәптер көлеп җибәрдем.

Өстәлдән гаризаны алдым да ертып ташладым. Хәбибуллин мине тынычландырмакчы булды:

– Кызма әле, утыр. Мин бит сиңа дусларча киңәш бирәм. Арнольд белән матавыклануыңны ташларга кирәк.

– Өйрәтмә, капитан! – дип кычкырдым тыела алмыйча.

Һәм ишеккә таба юнәлдем.

– Айгөл керсен әле, – диде ул.

– Юк, монда бүтән кермәячәк ул! – дидем мин һәм ишекне шапылдатып ябып чыгып киттем.

Айгөл безнең сөйләшкәнне ишеткән, ахры – аның кыяфәте «барысы да аңлашыла» дип тора иде.

...Милиция начальнигына кереп чыктым. Урта яшьләрдәге подполковник: «Пүчтәк нәрсәләр белән аптыратып йөрмәгез әле...» – дип чыгарып җибәрде.

Мин аңладым: кешене яклар өчен башта җинаятьче җинаятен кылырга тиеш. Шунсыз безгә беркем дә ышанмаячак, беркем ярдәм итмәячәк.

Арнольд белән Хәбибуллин нәрсә турында сөйләштеләр икән?.. Әңгәмәләре ничегрәк булды икән аларның?.. Әллә Хәбибуллинны да куркытты микән?.. Адресын! Арнольдның адресын белешмәде микән ул?

Мин кире Хәбибуллин бүлмәсенә йөгердем.

– Уз әйдә, кер, – диде ул, берни булмагандай.

– Син Арнольдның өй адресын белешмәдеңме? – дидем мин.

– Юк, белешмәдем.

Саубуллашып та тормыйча чыгып киттем. Дөресен әйткәндерме-юкмы – шайтан белсен. Адресын белсәм дә инде... нишләтә алам мин аны?

Гаиләсе бар микән аның?.. Баласы бар микән? Бәлки, балаңны үтерәм дип куркытыр идем... Бәлки, үзен үтерергәдер... подъездында көтеп торырга да...

Ни гаҗәп: бу коточкыч уйлардан сискәнмәдем дә, чирканмадым да.

...Без милиция бинасы каршындагы эскәмиягә утырдык. Айгөлнең йөзе яктырып, тынычланып киткән иде. Гаҗәпләнеп аңа карап тордым. Аңарда куркуның әсәре дә калмаган иде. Озакка сузылган киеренкелектән соң тынычлану – апатия билгесе. Инде милиция дә ярдәм итә алмагач, беркаян иганә күренмәгәч, куркыныч алдында «ни булса шул...» дигән мәгънәдәге тынычлык иде бу.

Тимер рәшәткәле «воронок» килеп туктады. Дүрт сержант бер исерекне машинадан чыгара алмый җәфа чиктеләр. Ниһаять, аны сөйрәп төшерделәр. Һәм айныткычка сөйрәп алып киттеләр.

Арнольд аек кеше шул, дип уйлап куйдым мин. Арнольд бик аек кеше. Салкын, аек акыллы. Надан һәм айныр-айнымас милиция Арнольд кебек аекларны җыналмый шул...

– Илдар.

Мин сискәнеп киттем.

– Илдар, мин курыкмый башладым.

– Нәрсәдән? Кемнән?

– Арнольдтан да, беркемнән дә, бернәрсәдән дә курыкмый башладым. Үзең уйлап кара... куркыныч яный... сине кемдер, нәрсәдер эзәрлекли... Син аңардан котыла алмыйсың... Аны җиңәргә чара табалмыйсың... Шулай булгач, куркып кына аны

жиңеп, котылып булмый бит... Курку куркынычны җиңә алмый бит.

Айгөл елмаерга тырышты, ләкин булдыра алмады, ияге, иреннәре дерелди башлады, һәм ул үкереп еларга тотынды.

– Үтерәм мин аны! – дидем мин.

Айгөл яшьле күзләрен күтәреп миңа карады:

– Кемне?..

– Арнольдны. Йә ул, йә мин: икебезнең берсе үләргә тиештер инде...

– Юк, юк, ни сөйлисең син?! Илдар, әйдә бу шәһәрдән китәбез.

– Кая китәбез?! Кайда көтеп торалар синең белән мине?!

Айгөл елавын дәвам итте.

Кесәдә пычак йөртергә кирәктер. Иртәгә ресторанга җырларга чыгам. Ни булса шул... Кадыйм! Үтерәм! Бу кадәре мескен, беткән җан булырга ярамый. Чыннан да, куркып кына котылу юк. Җиңәргә кирәк! Куркуны да, аны да!

Бик озак урамда йөрдек. Билгесезлек җәфаласа да, икебез дә катгый карарга килгән шикелле идек. Тик икебез ике карарга килгән идек бугай.

Мин пычак белән актык сулышыма кадәр каршы торырга үземә сүз бирдем. Ә Айгөл... Нигә кинәт тынычланды әле ул?.. Мине шушы сорау борчый башлады.

– Айгөл, син бик тынычландың, ахрысы?

Бу сорау шулкадәр сәер яңгырады: ул да, мин дә читенсенеп куйдык.

– Янымда син булганга куркыныч түгел миңа, – дип җавап бирде ул.

Ул миңа елышыбрак атлый башлады. Шулай да аның тынычлануы миңа сәер тоелды. Кинәт битарафланып китүе мине тагын куркыта башлады. «Ике дөнья – бер морҗа», – дип уйлый башламасын берүк. Күңелемдә мин аның Арнольдтан һаман да куркуын теләдем. Буйсына гына күрмәсен.

Ә буйсынса нәрсә... Бу очракта миңа инде куркыныч янамаячак... Айгөлгә дә... Бу уйлар башыма еш килә һәм мин аларны шунда ук куып җибәрергә ашыга идем.

Бирәсе килми Айгөлне аңа. Югалтудан куркам. Югыйсә мин аңа беркайчан да өйләнмәячәкмен. Аның ирләре күп булган... Тфү! Тагын шул вак уйлар!..

Әгәр Айгөл Арнольдка: «Мин Илдарны яратмыйм», – дисә, матавык шуның белән бетәр иде... Котылыр идек. Ниндидер көч бу уйны да башымда озак тотмый иде.

– Син минем аркада болай җәфаланырга тиеш түгел, – диде Айгөл, өйгә житкәндәрәк.

Юк инде. Хәзер кем кемне! Хәзер инде ул миннән барыбер үч алачак.

– Миннән башка кем җәфаланырга тиеш соң? – дип шаярган булдым.

Подъезд янына җиткәч туктадык. Икебездә дә бер шик иде – сагалап тормый микән?..

Кесәмнән пәкене чыгардым һәм подъездга кердем. Беркем дә юк иде. Айгөлгә дәштем. Лифтка утырып менеп киттек.

Өйгә кергәч, Айгөл муенымнан кочып алды һәм кайнар сулышы белән битемне өтеп пышылдады:

– Яратасың бит син мине, Илдар...

Дәшмәдем. Минем аңа беркайчан да яратам дип әйткәнем булмады. Мәхәббәт маҗараларында күп кайнаган бу чибәргә «Яратам!» дип әйтергә горурлык сыман ниндидер бер хис комачаулый иде. Әллә яратмаганга, әллә, киресенчә, нык яратканга...

Мин дә аны кочакладым.

– Яратасыңмы мине, Илдар?

– Әле яңа гына үзең әйттең бит инде.

– Юк, син әйт.

Мин аның битеннән үптем дә бүлмәгә уздым.

Кара-каршы утырганда, ул әле һаман җавап көтә иде:

– Әйт инде.

– Яратуның ни икәнен белми торып, ничек инде авыз тутырып «Яратам!» дип әйтеп була... – дидем мин.

Ләкин Айгөлгә бу мәсьәләдә фәлсәфә кирәк түгел иде. Ул кинәт җитдиләнде, кара күз алмалары зурайды, нәни томшыкны хәтерләткән матур борыны бераз киңәйде, соңгы вакытта ябыгып, аксылланып калган битенә кызыл төс йөгерде.

– Аның нәрсәсен белмисең инде?.. – диде ул, күпереп торган алсу иреннәрен турсайтып. – Менә мин сине яратам... Син миңа шундый якын, кадерле кеше... Син миңа кирәк... Яратуның ни икәнлеген мин дә белмим. Тик шулай да мин сине яратам!

Аның шушы мәгънәсез килеп чыккан җөмләләре кәефебезне күтәреп җибәрде. Үзенең кызык китереп чыгара алуына сөенеп, ул матур итеп көлеп куйды. Шуннан соң килеп алдыма утырды. Башымны кочагына каты итеп кысты.

– Авырттымы? – диде ул, битемә башын иеп.

Мин аның күзләрендә усаллык шәйләп алдым. Аның да нервлары нык какшаган иде.

Ул кинәт сикереп торды, киредән диванга барып утырды.

– Илдар, гафу ит мине!

– Ни өчен гафу үтенәсең?

– Минем өчен матавыкланып йөрисең.

– Нишлисең бит инде...

Ул тагы да җитдиләнебрәк китте һәм, ниндидер зур ачыш ясаган сыман, күзләрен уйнаклатып:

– Димәк, яратасың син мине! – диде. – Яратмасаң, минем өчен бу кадәре интегеп йөрмәс идең...

– Һе, интегеп дип... Син бит үзең Арнольдка «Илдарны яратам» дисең. Шуңа күрә миңа барыбер матавыкланмыйча булмый...

Аның шул мизгелдә үк сөмсере коелды.

Нигә алай дидем соң инде мин... Нинди гадәт соң бу – һәрвакыт «яратмыйм» дигәнне аңлатырга тырышып сөйләшәм. Шунда «Айгөл, яратам!» дисәм ни булган? Нинди кирелек комачаулый соң хатын-кызның күңелен күреп тәмле сүз әйтергә?! Югыйсә бит инде хәзер Айгөл иң якын кешемә әверелде.

Нигә мин аның беренче егете түгел икән?.. Әнә бит ул нинди чибәр! Сабый бала кебек бит ул! Үзе укытучы, үзе сабый кебек... Дөньяны балаларча аңлый һәм кабул итә. Сабый кебек гөнаһсыз дип әйтеп булмаса да, сабый бала кебек чиста дип әйтергә мөмкин. Матур, чиста кеше ул!

Минем аны юатасым килде.

– Айгөл, матурым! Яратам дип әйтсәм ни дә, әйтмәсәм ни... Сүз генә бит ул... Без бит инде болай да бергә, ир белән хатын шикелле... Язылышып, паспортларга пичәт сугуның кирәге юк.

– Язылышу турында әйтмим дә мин... – диде ул, уйга калып. – Хәзергә без бергә дә... ә аннары?..

Ә аннары ничек һәм нәрсә буласын әйтә алмыйм, дөресрәге, белми идем.

– Аннары күз күрер әле, – дидем мин. – Теге бәндәдән котылырга кирәк башта.

Ул кухняга таба китте. Бүлмәгә озак вакыт керми торгач, янына үзем чыктым. Куллары белән башын кысып, ул тәрәзәдән тышка карап утыра иде.

– Беләсеңме нәрсә, – диде ул, башын минем якка бормыйча гына. – Хәзер нишләптер бу интегүебезнең чиксез дәвам итүен телим.

– Аңламадым?..

Мин чынлап та аның ни әйтергә теләгәнен аңламадым.

– Гел шулай куркыныч янап торсын иде... Без гел икәү бергә калыр идек...

Мин көлеп җибәрдем.

– Сабый бала син, – дидем, аның дулкынлы кара чәчләрен сыпырып. – Гомер буе куркып яшәү рәхәт булыр идемени?..

– Кеше барыбер гел куркып яши... Кемдер аз гына курка, кемдер ныграк... Мин үземне синең каршыңда бик тә гаепле итеп сизәм. – Аның тавышы калтырый башлады, димәк, тиздән елау башланачак. – Мин... Мин Арнольд белән булырга ризалашыр идем вакытлыча гына... Аннан соң мине үзеңә китермәячәксең – шуннан куркам. Болай да инде элеккеге хәлләрем өчен мине битәрлисең. Мин бу көннәрдә бик күп уйладым. Арнольд сиңа тимәсен өчен, әллә аның белән йоклыйм микән?..

– Ни сөйлисең син?!

Аны туктатырлык түгел иде инде. Ул сикереп торды да кычкыра башлады:

– Илдар! Ул сине үтерергә йөри! Әйдә аның белән сөйләшик. Вакытлыча гына мин аныкы булып торыйм. Аннан соң мине үзеңә якын җибәрерсеңме?

– Юк! – дип кычкырдым мин.

– Нишлик соң? Мин синең өчен күбрәк курка башладым.

– Әйе, үтерсә, ул башта мине үтерәчәк. Ә син аңа тере килеш кирәк.

Айгөлнең елавы бәгырьләрне сыкратты. Әллә Арнольд белән йокласынмы? Юк! Йокламасын! Нәрсә бу?! Мине бүген-иртәгә үтерүләре ихтимал, ә мин Айгөлне бирергә ризалашмыйм. Юкса Айгөлне аңа бирсәм котылам бит! Шуннан соң, кем әйтмешли, Арнольдны да, Айгөлне дә «знать не знаю»... Җаным тыныч булачак. Айгөлгә «Соңыннан барыбер бергә булачакбыз» дип әйтәм дә...

Туктале, бу бит Айгөлне бөтенләйгә, мәңгелеккә югалту дигән сүз.

Диванда йөзтүбән капланып сулкылдап ятканда да гаҗәеп матур терелек, яктылык сирпелә иде аңардан. Минеке ул! Бирмим мин аны беркемгә дә! Батырлык түгел бу. Мин үземне яхшы беләм. Бу – матур нәрсәне аерасы килмәү. Бу – кешедәге бөек эгоизмның бер чагылышы. Бу – гүзәл кызны үзеңнең хосусый милкеңә әверелдерү.

Ләкин нишләп соң шул матур әйберне югалтасы килмәү үз гомеремне югалту куркынычыннан да көчлерәк?! Нәрсә бу?! Күңелеңә хуш килгән матур нәрсәне югалту куркынычы үлем куркынычыннан да куәтлерәк микәнни?! Күрәсең, шулайдыр.

Байлык өчен, кием-салым, акча, мал хакына кешеләр бер-берсен үтермиләрмени?! Затлы паласлар, зиннәтле җиһазлар өчен кеше бүген дә үлемгә таба атлый лабаса!

Нәрсә соң бу?! Кеше гомере шулай арзан микәнни?.. Нишләп үземә үлем янаганда да Айгөлдән баш тартмыйм икән?!

Әллә... мәхәббәт шушы микән? Юк, юк! Бу фәкать матур әйбердән колак какмаска тырышудан. Айгөл – шул ук «байлык». Аның җанын исәпкә алмасаң, ул – валюта кебек нәрсә. Ул – шактый зур байлык. Ә байлыктан баш тартырга кеше беркайчан да ашыкмый. Байлыкны яклап кеше кан коярга да әзер, хәтта үзенекен дә.

Ялгышмыйм микән мин?.. Башымда әллә нинди буталчык уйлар кайнаса да, Айгөлнең күз карашын күргәч, аның тавышын ишеткәч, күңелләр ачылып, яктырып китә, фәлсәфәнең вәхши логикасы һәм акылдан яздырырлык версияләр юкка чыга иде. Менә хәзер дә олы, якты җанлы, хыялый уйлар белән яшәүче Айгөл һәм дөньяның миллионлаган табышмакларын чишәм дип кайгыга баткан мин генә – икәүдән-икәү язмыш каршында аптырап калдык.

Кайсысы чынбарлык соң моның – очсыз-кырыйсыз фәлсәфәме, әллә бер-беребезгә карап сөенеп тә, көенеп тә утыруыбызмы?..

Мин аның юеш битеннән үптем. Бите тозлы иде.

– Тәмле син, – дидем мин, – тозлы.

– Баллы мин, – диде ул, елмаеп. – Син ул әче...

Һәм, үзенең шаяруыннан канәгать булып, тагы да яктырак елмайды.

* * *

Ике атна вакыт үтте. Арнольд күренмәде.

Мин ресторанда җырлавымны дәвам иттем. Көн саен Айгөлне техникумга озатып, дәресләрдән соң каршы алу көндәлек эшемә әйләнде.

Әллә эзәрлекләүдән туктады микән?.. Котылдык микән әллә?..

Арнольд та арыгандыр. Ул да бөтенләй үк акылсыз кеше түгелдер. Шулай да үземдә як-ягыма карану гадәтен сиздем. Сәхнәдә җырлаганда да зал ишегеннән күзләремне алмый башладым. Өйгә кайтканда гел автобус белән кайтырга тырыштым. Подъездга җиткәч, эчтә берәр ят тавыш ишетелми микән дип колак салып шактый вакыт торырга туры килә иде.

Сирәк кенә булса да Айгөл белән урамга саф һава суларга чыга башладык. Эзәрлекләүчебез күренмәгәч, бераз тынычландык шикелле. Әмма куркуны бөтенләй куып таратырлык көч юк иде. Милициянең дә ярдәм итәргә омтылып тормавын күргәч, без инде иң куркыныч фаҗигаләргә дә әзерләнгән кебек булган идек.

Әйе, УЛ инде ике атна күренми. Тик ул тудырган КУРКУ гына безне ташларга җыенмый иде.

Гаҗәп, УЛ үзе күренми, ә аңардан һаман куркабыз.

Курку өчен пространство да, вакыт та юк микәнни?!

Ә бәлки, УЛ инде бу дөньяда юктыр?..

Әгәр дә УЛ үлеп китсә, ә без бу хакта белмәсәк, аңардан курку барыбер дәвам итәр микән? Кызык, кеше үзе юкка чыкса да, куркытуы исән кала!..

Соңгы көннәрдә УЛ күренми башлагач, Айгөл дә тереләнебрәк китте.

Ләкин икебездә дә башка төрле курку уянды. «Нишләп әле УЛ кинәт юкка чыкты?..» дип шомлана башладык. Бу сорауны бер-беребезгә бирмәсәк тә, хәзер инде икебез дә куркытучыбызның күзгә күренмәс булуыннан курка башладык. Бу куркуның табигате шул ук булса да, формасы һәм тәэсире үзгә иде. Нинди уйлар белән йөри ул, тагын нинди адым ясар – билгесез.

Октябрь азагының кар күрсәткән көне иде. Кар шактый күп яуды. Ап-ак кар. Каралып, пычранып беткән җирне табигать пакь төс белән капламакчы була. Ләкин беренче карның гомере кыска, ул шунда ук эри, һәм пычракны арттыруга үзе дә өлеш кертә.

Хәер, кыш урталарында биек, калын көртләр өелсә дә, табигать үзенең ак төсе белән дөньяны барыбер агартып бетерә алмый. Кышның да гомере санаулы. Аның хезмәте дә санга сугылмый. Ак кар өстенә завод торбаларыннан чыгып корым утыра, шул аклык өстенә тәмәке төпчекләре, чүп-чар төшә... Ак кар өстенә кан тама... Ап-ак карны кеше таптый. Ә инде мартның «рәхимсез» кояшы карның тапталганын да, тапталмаганын да тиз арада ашап бетерә.

Мартта бураннар уйнап ала – кышның бирешәсе килми.

Октябрь ахырында җәй, актык көчен җыеп, үз хокуклары өчен

сугыша – яңгырын коя, көтмәгәндә көне җылытып куя, кайбер үсемлекләрне хәтта чәчәк аттырып та карый.

Җан ияләре арасында да мәңге низаг! Мәңге көрәш, сугыш! Арадашчылар, хакимнәр юк һәм кирәк түгел монда. Үз юлында һәммәсе дә хаклы һәм гөнаһсыз. Гармония, аһәңдәшлек дип атыйлар моны.

Кешеләр арасында да шул коточкыч законнар, шундый ук вәхши гармония хөкем сөрә түгелме соң?..

Әхлак нормалары бар! Ләкин кешеләр һәммәсе шул кануннарга буйсынып яшәсә, конформизм дигән нәрсә килеп чыгачак бит! Бу очракта ирек, рух азатлыгы дигән төшенчәләр буш сүз булып чыгачак.

Әхлак дип аталган законнарга, кагыйдәләргә һәрбер кеше буйсынсын өчен каты куллы диктатор кирәк. Әмма һәрбер диктаторның үзенең көчләү механизмы була. Һәм инде монда да ирек, азатлык инкарь ителә. Парадокс!

Һәр кешенең рухын җиңеп булмый шул. Юк, бәлки, буладыр да... Кемнедер мәхәббәт үзенең колы итсә, кемнедер нәфрәт буйсындыра. Кемнедер ата-анасы җиңә, кемнедер төрмә... Кемнедер яман авыру авызлыклый ала, кемнедер хәтта үлем куркынычы да үзгәртми. Кемнедер кайгы сындыра, кемдер үзе кайгы ясап йөри.

Биш миллиард кешене буйсындырыр өчен биш миллиард ысул кирәк. Әгәр алай түгел икән, кешенең ирeклеге, азатлыгы турында гәп куертуда мәгънә юк.

Хәтта дин дә кешене авызлыклый алмады. Чөнки дин дә бөтен кешелекне бер канунннарга буйсындыру максаты белән уйлап чыгарылган иде. Конформизмның бу төре кешене матурламады да, чистартмады да, биек рухи баскычка да менгермәде. Дин фәкать халыкларны укмаштыруда, аларны төркемләүдә, тәртипкә өндәүдә, тыштан карап торган ямьле булып күренгән гореф-гадәтләрне тудыруда гына уңай роль уйнады.

Моңа кадәр яшәп килгән диннәрнең зыяны исә кан коюда һәм башка дин вәкилләрен җәберләүдә генә түгел. Диннең кайбер формалары бердәнбер Алла, пәйгамбәрләр, фәрештәләр кебек илаһи затларны кешеләргә тәкъдим итте. Нәтиҗәдә бик күп адәми затлар Алла булырга омтылды. Пәйгамбәрлеккә дәгъва кылучылар санын тарихта санап бетерерлек түгел.

Һәм, шулай итеп, җирдә «аллалар», «пәйгамбәрләр» бихисап күбәйде. Тоталитаризм дип аталган күренешне шул дини конформизм нәтиҗәсе дип карарга кирәк түгел микән?..

Айгөл Аллага ышанмый. Ләкин аның Алласы бар – ул аның үзендә. Айгөл тормышның, дөньяның һәрбер матур чагылышына табына. Аңа мәхәббәт кирәк. Мәхәббәт – аның Алласы. Дин тотучыга караганда Айгөл гөнаһлырак дип уйламыйм!

Үзем дә мин хорафатка ышанучан, «Алла юк» дип әйтми торган кеше. Тик мин аны үземчә күзаллыйм, аңа үземчә табынам.

Һәммәбезне бер үк нәрсәгә табындыру мөмкин түгел. Ышану, инану үзәктән, эчке дөньядан чыгарга тиештер. Һәммәбезне бер үк нәрсәгә буйсындыру әсирлеккә дучар итү белән бер булыр иде. Шулай булгач, мин Арнольдны нәрсәдә, нинди җинаятьтә гаепләргә тиеш соң?! Кем хаклы соң – улмы, минме?! Башка кешегә: «Алай дөрес түгел, болай кирәк...» – дип әйтергә хакым бармы соң минем?.. Әгәр Арнольдны бәдәни теләкләр җинаятькә этәрә икән, аны бу халәтендә хөкем итәргә ярыймы?.. Кем хөкем итәргә тиеш?..

Әгәр аны шәһвәт әллә нинди кискен чараларга алып бара икән, табигатьне хөкем итәргә кемнең хакы бар?! Шуңа күрә монда фәкать көрәш, сугыш турында гына сүз алып барырга мөмкиндер. Үз теләген канәгатьләндерергә аның хакы бар... Һәм дә минем моңа юл куймаска хакым бар.

Менә ул дөнья! Менә ул тормыш! Менә ул табигать! Менә ул аһәңдәшлек, баланс!

Менә ул чынбарлык!

* * *

Беркөнне рестораннан чыккач, өйгә кайтасы килмәде. Ниндидер көч кайтуыма каршылык күрсәткән кебек булды. Күңел тартмаса да, кайтырга кирәк, чөнки өйдә Айгөл көтә иде.

Автобус тукталышы нәкъ минем йортым каршында. Шуңа күрә акрын гына атласам да, карлы яңгыр мине чылатып өлгерерлек түгел иде. Як-ягыма каранып, салмак кына адымнар белән йортка таба юнәлдем.

Кемнеңдер тиз генә подъезд эченә кереп киткәнен шәйләгән кебек булдым. Йөрәк жу итте. Кесәмдәге пычакны капшадым. Һәм тукталдым. УЛ микән?.. Әллә күземә күренде генәме?.. Йомшак адымнар белән подъезд төбенә килеп җиттем. Бер ир белән хатын тиз-тиз атлап кереп киттеләр, мин дә аларга ияр-дем.

Алар җәяү менеп киттеләр, мин лифтка утырдым.

Бишенче катта лифт ишеге ачылгач, каршымда УЛ пәйда булды.

Барысы да бер мизгел эчендә булып алды.

Алла саклады мы, һәр җан иясенә хас үз-үзеңне саклап калу инстинктымы, һөҗүмгә әзерлегем коткардымы – белмим. Аның бер кулы кесәсендә иде. Аңарда корал бар!

Ул лифтка таба атлады, миңа чыгарга мөмкинлек юк иде. Бар көчемә аның эченә типтем, ул артка таба китте, бөгелде. Тиз генә лифтның «1»ле кнопкасына бастым. Лифт төшеп китте. Урамга атылып чыктым һәм милиция бинасына таба йөгердем. Күп тә үтмәде, аның артымнан йөгергәне ишетелде. Милициягә җиткәндә борылып карадым – ул юк иде.

Дежур торучы милиционерларга хәлне аңлатып бирдем. Ике сержант мине фатирыма кадәр озатып куйдылар. Арнольд күренмәде.

Шик калмады – хәзер инде ул мине чын-чынлап үтерергә йөри. Лифт эчендә бергә-бер калсак, беткән идем. Гаҗәп, мин кесәмдә пычак барлыгын бөтенләй истән чыгарганмын. Әле ничек тибә алдым икән?..

...Айгөлнең битендә төс юк иде. Арнольд бик озак ишекне шакыган икән. Аның белән очрашып бәрелешүемне Айгөлгә әйтмәм дигән идем, түзмәдем, сөйләдем. Болай да инде шом, курку, әйтелмәгән сүзләр – бөтенесе бергә эчтә җыелып, авыр йөк булып өелгән иде.

Айгөл еламады, хәтта бу юлы юатырга да тырышмады. Ул дәшмәде. Бары тик бер тапкыр гына:

– Мин гаепле, – диде.

Бу юлы мин дә җавап бирмәдем. Ул гаепле түгел, әмма сәбәп аңарда.

Үтерергә кирәк Арнольдны!.. Башкача котылу юк... Мин аны үтермәсәм, ул мине үтерәчәк... Юк итәргә кирәк аны... Ничек? Ничек, ничек?!

Юк, миннән булмый. Андый сәләтем юк... Моның өчен башка төрле кеше кирәк... Айгөл белән сөйләшергә... Аны фатирымда саклап ятуны дәвам итәргә ярамый... Араны өзәргә... Ул да миннән баш тартырга тиеш... Үзе дә риза бит инде... Җиңелдек микәнни... Үзәгемдә җаннарны өзәрлек сыкрау тойдым. Җан сызлавын үлем генә басар төсле тоелды. Нинди дә булса үлем... Кемнеке дә ярый...

Бу мәлдә Айгөлне үтерәсем килде. Үземдә дә яшәү теләге калмаган иде инде.

Җинаятьчеләрне хөкем иткәндә, психиатрлар, психологлар катнашырга тиештер. Һәр җинаятьне өйрәнергә, аңларга тырышырга кирәктер. Прокуратураларда җинаятьченең халәтен аңлый торган, кешенең күңелен аз булса да укый белүче махсус белгечләрнең утыруы зарурдыр.

– Үтер мине! – диде Айгөл.

Мин сискәнеп киттем. Әйтерсең ул минем уйларымны укып утырган.

Күңелләрем тагын актарылып китте, аның тавышы караңгы уйлардан айнытып җибәрде.

– Юк, үтермим, – дидем мин, елмаерга тырышып. – Мин Арнольдны үтерәм.

– Төрмәгә утыртачаклар.

– Сине үтергән өчен дә утыртачаклар бит барыбер, – дип шаярган булдым.

– Куркыныч бу дөнья, – диде ул, бер ноктага текәлеп.

– Без курыкканга гына куркыныч тоела бу дөнья.

Туктале! Тупик микәнни бу?! Дөнья бик тар түгел ләбаса. Булмый! Айгөлне югалту мөмкин түгел! Миңа кирәк ул! Үләсе дә килми... Китәргә! Кая?!

Эзсез югалып булмас бит... Бәлки, вакытлыча юкка чыгып, күренми торыргадыр...

– Айгөл, әйдә бу шәһәрдән китеп торабыз.

– Әйдә, – диде ул битараф кына тавыш белән. – Мин иртәгә эштә сөйләшеп карыйм. Бәлки, бөтенләй расчет алырмын.

Тагын өмет туды. Китеп торырга кирәк!

– Кая китәбез соң? – дидем мин.

– Минем Казанда туганнарым яши. Әлегә шуларда тора алабыз. Тик шунысы бар – алар төпченәчәкләр инде... Аннары, әниләргә ни дип хәбәр итәргә?.. Алар ни уйларлар?..

– Син анысы өчен борчылма әле, – дидем мин. – Котылу турында уйларга кирәк.

Ай буе куркып, киеренкелек кичереп яшәү икебезне дә тиз кабынучан итте, уйларыбызның да, сөйләшүебезнең дә рәте-чираты юк иде. Без үзебезне чын кешеләрдәй хис итми идек. Озак вакыт курку астында йөргәч, кеше бераз хайванга әйләнә. Дөрес, кеше ул болай да хайван, ә курку исә аны кешечә фикерләүдән, әйләнә-тирәдәге вакыйгаларны дөрес, төгәл аңлаудан, чынбарлыкка тәңгәл реакциядән мәхрүм итә.

Без дә нәкъ шундый халәттә идек. Икебез дә мескенгә әйләнеп калдык. Ә мескен кеше чын кеше түгел инде ул.

Мин үземне Айгөл алдында булдыксыз, көчсез бер сәләмә ярым кеше итеп тойдым. Бу минутта аңардан гафу үтенәсем килде. Ләкин гафу үтенәсе урынга мондый сүзләр әйтелде:

– Айгөл, мин аны җиңалмам инде. Ләкин мин сине аңа бирмим! Үтерсен. Курыкма, үтерсә дә, ул мине генә үтерәчәк. Качып йөрүдән туктарга кирәк. Ни булса да булсын...

– Чит шәһәргә китмибезмени?

– Күз күрер. Таң атсын әле.

* * *

Икенче көнне Айгөлнең кәефе нишләптер бик яхшы иде. «Йоклар алдыннан әйткән сүзләремнең тәэсиредер...» – дип уйладым. Аның яктырып китүе минем дә күңелне җылытып, рухымны күтәреп җибәрде.

Ул минем муеныма сарылды.

– Илдар, бердәнберем минем...

– Син бик шат бүген, – дидем мин, сәбәбен әйтмәс микән дигән өмет белән.

– Янымда син бар бит, – дип җавап бирде ул.

Мин аны кысып кочакладым, иреннәреннән үптем. Хатынкызга күп кирәкмени – ул тәмам җебеде һәм эре күз яше бите буйлап тәгәрәп тып итеп идәнгә тамды.

– Иртүк елама әле, – дидем мин.

Ул кинәт караңгыланып китте.

– Куркам!

Бу сүзне әйткәндә, аның үзәгеннән җан ачысы сытылып чыкты. Аның бу сүзендә аяныч та, үпкә дә, офтану да, кичеп чыккысыз хәсрәт тә бар иде.

Чәй эчкәч, мин аны техникумга кадәр озатып куйдым. Сәгать өчтә килеп алырга вәгъдә бирдем.

– Ярар, – диде ул һәм, вокзалда аерылышырга торган сыман, күзләрен тутырып карап калыйм дигәндәй, миңа текәлеп торды.

Айгөл белән күп сөйләшми идек без. Бер-беребезне болай да аңлый идек, ахрысы. Өйдә дә, көннәр буе бер-беребезгә сүз катмый, һәркем үзенә ниндидер эш табып утырган чаклар бар иде. Шуңа күрә ачуланышканыбыз да юк иде бугай, хәтерләмим.

Техникумга кереп китәр алдыннан ул нидер әйтергә теләде, тик әйтмәде. Минем дә дәшәсем килде, ләкин сүз тапмадым. Иреннәрем белән маңгаена кагылгач, ул очып китәргә әзерләнгән кошны хәтерләтте.

– Соңга калма! Төгәл өчкә кил! – диде ул һәм техникумга йөгереп кереп китте.

...Ул көнне урамда бертуган апам очрады. Бер шәһәрдә яшәп, килеп хәлемне дә белмисең, дип, шелтәли-шелтәли, мине үзләренә алып китте. Җизни эштә, балалары мәктәптән кайтмаганнар иде әле. Авылга да кайтып килергә кирәк, бөтенләй югалдың, дип, әрли-әрли, тәмле ризыклар белән сыйлады һәм ябыкканлыгымны, картаеп киткәнлегемне дә әйтеп үтәргә онытмады.

Ресторанда җырлавымны ташларга кирәклеге турында шактый озын лекция тыңлаганнан соң, мин, гафу үтенеп, рәхмәтләр һәм җизни белән балаларга күп сәламнәр калдырып, чыгып йөгердем. Чөнки сәгать өч тулып килә иде инде.

Техникум янына килеп җиткәндә, сәгать дүртенче унбиш минут иде. Соңгарак калдым. Айгөл күренмәде. Кереп, вахтер хатыннан сорадым.

– Айгөл Хәбировна чыкмадымы?

Вахтер хатын шырпы белән теш арасын каезлап утыра иде. Мин сорау биргәннән соң да әле ул, авызын кыйшайтып, тешен актарды.

– Айгөл Хәбировна чыктымы, юкмы?

Тау хәтле гәүдәнең кай төшеннәндер:

– Чыкты, – дигән тавыш ишетелде. – Ун-унбиш минут элек.

Үзе генә кайтып киткәндер... Мине көтеп торгандыр да... Шулай да шикләндем.

– Кайсы якка киткәнен күрмәдегезме?

– Әллә тагы... Дәресләр беткәч, монда тәрәзә янында басып торды ул. Аннары бер егет кереп алып чыгып китте аны. Кая киткәннәрен шайтан белсенмени аларның.

Эшләр харап! Нишләргә?.. «Ник аның белән чыгарып җибәрдең Айгөлне?» дип, вахтерны җилтерәтәсем килде. Туктале! Бәлки, Арнольд белән китмәгәндер? Башка кеше белән китүе дә ихтимал бит... Кем булса да...

– Гафу итегез... Ниндирәк егет иде ул?

– Озын буйлы, кара чәчле чибәр егет... Бик пөхтә.

Шик калмады – Арнольд! Кая киттеләр икән?

Миңа һава җитми башлады. Атылып урамга чыктым.

Айгөл үзе теләп киткәндер... Аның «Башка чара юк...» дигәне искә төште һәм соңгы вакытта тынычланып, сәерләнеп калуы күз алдыма килде.

Урамда йөриләрдер әле... Айгөл аның белән әллә кая бармас... Урамда сөйләшеп йөриләрдер...

Шәһәр буйлап аларны эзләп чаптым. Бу вакытта кемнән, нәрсәдән курка идем – белмим.

Күпме вакыт урамнарны айкап йөргәнмендер – хәтерләмим. Өемә кайттым, фатир буш иде. Ятып хәл алдым. Башымда нинди уйлар кайнаганын аңлау мөмкин түгел иде.

Курку, курку, курку.

Айгөлнең бүлмәсендә түгел микән алар?.. Ник баштук шунда бармадым икән... Ул яшәгән тулай торакка киттем. Бу минутларда мин Арнольдтан курыкмас идем. Каршыма килеп чыкса да, курыкмас идем. Аларның берсен булса да табу нияте мине җанварга әверелдерде.

Тулай торак вахтасында кемдер чәрелдәп кычкырды, ләкин мине дөньяның барлык вахтерлары җыелган суръттә дә туктатырлык түгел иде. Баскычлардан ничек менгәнемне хәтерләмим. Айгөл бүлмәсенең ишеге бераз ачык иде. Бүлмәгә атылып кердем. Урындыкта, тумбочкага терсәкләре белән таянып, Айгөл утыра иде. Үзе генә.

Сорау бирергә кыймыйча, бүлмә уртасында катып калдым.

Ул башын күтәрде. Йөзендә битарафлык, дөньядан ваз кичү язылган иде.

– Илдар, син котылдың, – диде ул карлыккан тавыш белән.

– Аңламадым?..

– Мин аның теләген үтәдем... Беренче теләген.

– Ничек инде?!

– Мин Арнольд белән булдым.

Кычкыруымны сизми калдым:

– Нишләдең син?! Ник аның белән киттең? Ник мине техникумда көтеп тормадың?

Җавап урынына аның иреннәре кыйшайды, ләкин елмая алмады.

– Айгөл! Син чынлап әйтәсеңме?! – Минем һаман ышанасым килми иде. – Тагын киләчәкме ул?

– Белмим.

Ул калтырый башлады. Мин, нишләргә белмичә, баскан урынымнан кузгала алмадым. Томанлы күзләре белән миңа карап торгач, ул башын иде.

– Әйдә, миңа кайтабыз, – дидем мин.

– Юк, Илдар, мин монда калам.

– Син гафу ит мине, мин гаепле... Техникумга соңга калып килдем...

– Илдар... Синең бернинди гаебең юк... Үзем шундый карарга килдем. Син үзең гафу ит мине.

Йөгереп барып аны кочакладым. Кочагымда һәрвакыт эреп

китә торган Айгөл бу юлы тораташ булып каткан иде. Кочып та, назлап та аның бәгырен җылытырлык түгел иде.

– Зинһар, кагылма миңа, – диде ул газап белән.

Мин тагын бүлмә уртасында катып калдым. Тагын дәштем:

– Әйдә, ки курткаңны. Миңа киттек.

– Юк.

– Алайса, мин монда синең белән калыйммы?

– Юк, калма. Бар, кайт! Гафу ит!

– Айгөл, нишләп син миннән гафу үтенәсең?

– Белмим.

– Көчләдеме?

– Әллә тагы... Син җирәнәсеңме миннән?

– Юк, – дидем мин, сөйләшүнең җайлана башлавына сөенеп.

– Ә мин үземнән үзем җирәнәм. Үзем яши торган дөньядан җирәнәм.

– Айгөл! Бик бетерешмә әле.

Ул кинәт өзгәләнеп кычкырды:

– Илдар! Зинһар, чыгып кит! Калдыр үземне генә! Берүзем каласым килә!

* * *

Кыйналган кеше сыман, аякларымны көчкә сөйрәп, шәһәр буйлап атладым. Башымда уйлар боламыгы, күңелемдә нәфрәт кайный иде.

Җиңелдем! Теләгенә иреште Арнольд...

Ә курку һаман исән иде. Кемнән, нәрсәдән?! Бу сорауга җавап юк иде.

Бәлки, Айгөл дөрес адым ясагандыр... Ләкин көчсезлегем, ярдәмсезлегем үземне рәхимсез рәнҗетте.

Нигә кирәк минем язган шигырьләрем, хикәяләрем?! Шигырьләрдәге матур сүзләр, саллы булып тоелган фикерләр нинди көчкә, нинди әһәмияткә ия соң?.. Чынбарлыкта аякларымда нык торалмагач, шигырьләрем белән кемне җиңә алам соң мин? Шигъри юллар белән матурлыкка мәдхия язып кына шул матурлыкны тапталудан, пычранудан коткарып булмый бит!

Инде сәгать кичке сигез иде. Ресторанга соңга калдым. Мин килгәндә, музыка яңгырый иде инде.

Җырларлык хәлдә түгел идем мин. Музыкантлардан гафу үтендем дә буш өстәл артына барып утырдым. Залда кеше аз. Шуңа карамастан һава тынчу һәм сасы иде. Бер стакан лимонад эчтем дә урамга чыгып киттем.

Рестораннан йөз адым киткәнмендер – миңа эндәштеләр:

– Илдар!

Борылып карадым. Миңа таба Арнольд килә иде. Күн плащ һәм киң эшләпә аны киноларда күренә торган гангстерга охшата иде.

«Хәзер пычагымны чыгарам да кадыйм...» – дип уйладым.

һәм шунда ук бу ниятемнең файдасызлыгын, кирәк түгеллеген аңладым.

– Нихәл, Илдар! – диде ул, килеп җиткәч.

Дәшмәдем.

– Әйдә, кереп бераз аракы кабыйк, – диде ул, елмаеп. – Синең белән дуслашыр вакыт җитте бугай.

– Эчмим мин.

– Ха-ха-ха, бөтенләй ташладыңмыни?

Мин бу кешене күралмый идем, шулай да аның белән нишләптер сөйләшәсем килде, аны аңларга теләгем туды.

– Айгөлне мин...

Мин кырт кистем:

– Беләм.

– Бүгеннән ул минеке. Дөресен генә әйткәндә, ул миңа бигүк ошап бетмәде. Салкынрак. Хәер, аны аңлап була... Әле миңа иярләшәсе бар аның.

Миндә үтерү теләге тагын кабынды.

– Хайван син, – дидем мин тыныч кына.

– Алай бик каты орынма инде, Илдар. Үзең шагыйрь кеше...

– Каян беләсең син минем шагыйрь икәнемне?

– Һе, гәҗит-журналларны мин дә укыштырам бит. Хәйран кызык әйберләрең бар синең. Зерә ресторанда череп ятасың.

– Ярый. Ни йомышың бар миндә?

– Алай йомыш юк. Җырлыйсыңдыр дип, махсус синең яныңа килүем иде.

– Миннән көлеп, рәхәт чигеп утырыргамы?

– Юк ла. Син мине пүчтәк кешегә санама инде. Минем әле, киресенчә, синнән гафу үтенәсем килә.

– Гафу итмим мин сине! Әле үч алачакмын!

Арнольд көлеп җибәрде.

– Ошыйсың син миңа, маэстро. Әйдә, бер утырып сөйләшик әле.

Мин бу тәкъдимне кабул иттем. Ресторанның өстәге катында кунакханә урнашкан, аның керә торган ишеге аерым һәм кергәч тә зур фойесы бар. Без, шунда кереп, диванга утырдык.

Сүзне мин үзем башладым:

– Ни турында сөйләшмәкче буласың минем белән? Үз теләгеңә ирештең бугай инде...

– Әйе, максатыма ирештем. Ләкин бу – чүп. Бу җиңү түгел!

– Син үзең акыллы кешегә охшагансың, яшең дә шактый бар инде, вакланып, юк нәрсә белән шөгыльләнеп йөрисең түгелме?..

– Айгөлне синнән талап алуымны әйтәсеңме?

– Әйе.

– Нишләп ваклану булсын... Үзең дә бик нык каршы тордың бит, димәк, көрәш юк нәрсә өчен бармаган. Илдар, мин синнән шуны сорамакчы булам... Айгөл теге вакытта ук әйткән иде... Үзең дә әйткән идең... Айгөлне яратмыйм, дип... Син аны теге вакытта ташлаган да идең бит... Шулай булгач, нишләп син бер

айдан артык минем белән сугыштың? Нәрсә бу, олы җанлы булырга тырышуданмы? Менә шуны аңлата алмассыңмы?

Мин үземне тыныч хис итә башладым. Бер ай буе куркытып йөргән бәндәнең кешеләрчә сөйләшеп утыруы нәфрәтемне бераз таратты, дөньяны каплап торган ниндидер зур кара болыт арасыннан яктылык күренгән сыман тоелды.

– Моны сиңа аңлата алмыйм, – дидем мин. – Куркыныч кеше син... Мин Айгөлне кызгандым... Синең кулыңа аны бирәсем килмәде.

– Куркыныч кеше?! Алай дип әйтү бигүк дөрес булмас. Куркыта белүче кеше мин. Һәм бу сыйфатым белән, бу сәләтем белән горурланам.

– Бөтен кеше дә куркак түгелдер бит... Сине җиңәрдәй кеше юктыр дип уйлыйсың мәллә?..

– Бардыр. Нишләп булмасын, дөнья бит бу.

– Карале, Арнольд, син кем? Кем булып, кайда эшлисең?

– Эшем чиста минем. Сиңа аны белү кирәк түгел.

– Гаиләң бармы?

– Бар. Хатыным, ике кызым.

– Кызларыңның язмышлары өчен курыкмыйсыңмы?

– Куркам. Ничек инде курыкмыйсың ди?

– Ә менә синең кебек берәү киләчәктә кызларыңны эзәрлекләп йөрсә?.. Син минем үч алуымнан курыкмыйсыңмы?

– Кемнән үч алмакчы буласың?

– Синнән.

Арнольд бик озак миңа текәлеп карап торды.

– Юк. Үч алырсың дип уйламыйм. Айгөл тагын сиңа елышыр һәм миңа тагын мәшәкатьләнергә туры килер дип кенә куркам мин.

– Шулкадәр комсыз кешемени соң син? Үзеңә ошаган һәрнәрсәне йолкып алырга дигәнмени?..

– Шундый кеше инде мин, маэстро. Үземә ошаган әйберне татымый калудан куркам.

Ул сәгатенә карап алды.

– Ярый, кузгалыйм мин, – диде ул һәм китәргә ашыкты.

Аның кая барырга җыенганын беләсем килде. Урамга чыккач, түзмәдем, сорадым:

– Кая барасың хәзер?

– Айгөл янына.

Дәшмәдем. Күңел ярсый башлады.

– Тыныч бул, маэстро, – диде ул, көлемсерәп.

– Арнольд, барма аның янына, – дидем мин, үземне кулга алырга тырышып. – Ул авыр хәлдә. Аның синең белән очрашасы килми.

Арнольдның йөзе кинәт усалланды, күзләрендә яман елтырау чагылды.

– Син, маэстро, кит минем юлдан! – диде ул, тешләрен кысып. – Сөйләшеп утыргач та, әллә син мине үзгәрде дип уйлыйсыңмы?!

Мин аңардан һаман курка идем. Сугышып җиңә алмас идем

мин аны. Ялынып та бернишләп булырдай түгел иде. Аны куркытып карарга теләдем:

– Мин синең балаларыңны йә хатыныңны үтерәм!

– Юк, үтермисең, – диде ул тыныч кына. – Син андый кеше түгел. Син куркасың!

– Башка кешегә әйтеп үтертәм! – дидем мин, бәлки әле, куркыр дигән өмет белән.

– Шуны исеңдә тот... әгәр дә кызларыма берәр нәрсә булса, мин сине шул ук көнне табып ботарлыйм!

Юк, куркыта алмадым. Ул бары тик үзенең теләген канәгатьләндерми калудан курка иде.

Автобус аны Айгөл яши торган урамга алып китте, ә мин, дөньяның сәерлегеннән куркып, төнге урам буйлап атладым.

* * *

Икенче көнне, техникумга барып, Айгөлне эзләдем. Авырый, диделәр. Тулай торагына бардым, анда да юк иде. Апасының адресын белми идем. Тагын техникумга бардым, больницада түгел микән дип кызыксындым, нинди авыру икәнен сорадым, ләкин беркем дә әйтә алмады. Кич белән тагын тулай торакка барып кайттым – юк иде.

Шулай сагалап йөри торгач, өч көн үтеп китте. Больницаларга барып эзләп карадым, аның фамилиясе бер журналда да табылмады.

Ә беркөнне, техникумга баргач, директор: «Айгөл Хәбировна, расчет алып, Казанга китте», – диде.

Мин җиңел сулап куйдым. Бер-беребезне онытырга да әйбәт булыр, Арнольд та Казанга барып эзләп йөрмәс.

...Шимбә көн иде. Базарга чыгып керәсе иттем. Көн салкын булуга карамастан, базар кайный иде. Сату-алу, алдау, талаш, ыгы-зыгы. Сатучыларның да, алучыларның да күзләрендә курку бар иде. «Әллә Арнольд хаклы микән?..» – дигән уй башка китереп сукты. Монда да курку хөкем сөрә иде. Кесәләрендәге акча, кулларындагы мал өчен куркумы?.. Алдарлар дип куркумы?.. Таларлар дип куркумы?.. Нәрсәдәндер, кемнәндер курка иде халык... Туктале! Кешеләр бер-берсеннән куркалар түгелме соң?! Мин тизрәк китәргә ашыктым. Нидәндер курыктым... Югыйсә кесәмдә акча да юк иде.

Базардан чыгучылар кайсы кая йөгерешәләр иде. Җитешмәүдән, соңга калудан курка кешеләр, шуңа күрә чабышалар.

Юл аркылы гарип абзый чыгып бара. Бөкресе ямьсез «кычкырып» чыгып тора, аяклары чалыш, көчкә атлый – карарга куркыныч. Зур тизлек белән йөк машинасы килә иде, аның якынлашканын күргәч, абзый ашыга башлады. Болай да көч-хәл белән генә атлаучы гарипнең йөгерергә тырышуы тетрәндергеч иде.

Машинага тапталудан курка дип уйладым мин. Ул да үлемнән

курка микәнни?! Бик авырлык белән генә йөрсә дә, бу дөньядан китәргә курка микәнни?!

Машина тизлеген киметте, чөнки шофер да кеше таптатып төрмәгә утырудан курка иде.

Гарип абзый юлның теге ягына исән-имин чыгып җиткәч, хәл алырга туктады. Гәҗитләр сатыла торган киоскка сөялеп маңгаендагы тирен сөртте, башын иеп сулышы тигезләнгәнне көтте. Кызганыч, аңа бу минутта беркем дә, берничек тә ярдәм итә алмый иде.

Нинди каргыш төшкән бу кешегә?! Нинди гөнаһ кылганы булды икән?! Ни өчен аңа гомерлек җәза бирелгән соң?.. Нишләп бу кеше болай да караңгы уйлар белән йөргән чагымда күземә чалынды?..

Яныннан үткәндә мин аның йөзенә карадым һәм... сискәнеп киттем – ул елмая иде. Тешсез аңкауларын күрсәтеп, беркемгә, бернәрсәгә түгел, каядыр бушлыкка карап елмая иде. Машинага тапталмый калуына сөенә идеме ул, әллә туктап ял итү аңа минутлык рәхәт биргәнме, белмим.

Җирдә көчкә басып торучы ямьсез кыяфәтле гарипнең елмаеп торуы бу минутта миңа бик сәер тоелды. Яныннан тыз-быз үтеп баручы, дөнья куып күзләре акаеп беткән кешеләрдән көлүе микән әллә аның?.. Әллә бу гарип башкаларга мәгълүм булмаган берәр серне белә микән?..

Мин инде шактый вакыт карап тора идем, аның моңа исе китмәде. Үзалдына мыгырдап, ул елмая иде. Миннән көлә микән әллә ул?.. Аңа эндәшәсем килде, ләкин батырчылык итмәдем. «Яшисең киләме?» дип сорамакчы идем бугай мин.

Аның сакал-мыек баскан, газап камчысының эзләре булып сызылган җыерчыклы, кайгы пәрдәсе белән томаланган ике күзле шыксыз чырае минем якка борылгач, эсселе-суыклы булдым һәм тиз генә китеп бардым.

Куркыныч бу дөнья!

Ерак китә алмадым, аякларым кире гарипкә таба атладылар.

– Куркасыңмы? – дип сорадым мин аңардан.

Җавап урынына ул бик әшәке итеп сүгенде һәм таягы белән кизәнде.

Мин аны тынычландырырга тырыштым, алай гына да түгел, аның газабының бер өлешен үземә аласым килде.

– Гафу ит! – дидем мин аңа. – Гафу ит мине, кешеләрне! Кичер бу дөньяны!

Ул кинәт кычкыра башлады:

– Кит моннан! Талыйлар! Коткарыгыз!

Мин бар көчемә йөгердем. Инде шактый ерак ара узгач, туктадым һәм үземә-үзем сорау бирдем: «Нәрсәдән курыктым мин хәзер? Кемнән? Нигә кирәк булды бу мәгънәсез курку?»

Кинәт хәлсезләнеп киттем. Күз алларым караңгыланды, аякларым калтырый башлады. Эчтән бугазымның буылганын тойдым. Аңым томаланды, аяк астым чайкала иде.

Томан арасыннан Арнольд белән Айгөл пәйда булдылар. Алар култыклашканнар һәм миңа текәлеп карап торалар иде. Аларның артыннан теге гарип килеп чыкты һәм рәхәтләнеп киерелә-киерелә көләргә тотынды.

Мин караңгылыкның төпсез упкынына төшеп киттем.

* * *

Аңыма килгәндә, дару исе сеңгән тынчу палатада ята идем.

Хәтеремдә казынып, бик озак яттым. Палатада бер мин генә түгел идем, ләкин беркем белән дә кызыксынмадым, хәтта башымны борырга да ирендем.

Үзем кичергән куркыныч вакыйгаларны искә төшерү никтер авыр тәэсир итмәде. Моңа кадәр тынгы бирмәгән кешеләргә, борчыган нәрсәләргә карата күңелемдә битарафлык тойдым. Әйтерсең лә минем аларга бөтенләй катнашым юк иде.

Миндә бары тик бер хис сулкылдый иде – курку! Сәламәтлегем, гомерем өчен курку!

Яшисе килә иде. Курку дип аталган көч мине бу куркыныч дөньяда калырга өндәде.

Үлемнән дә түгелдер, бәлки... яшәмәүдән курка идем бугай...

Бу куркыныч дөньяны бүтән күрмәм дип курка идем бугай мин...

1992

БАЯН ТУРЫНДА БӘЯН

(Сатирик повесть)

– Казан каласына мең ел тула икән! – диде Салих тантаналы тавыш белән.

– Кайчан? – дип ясалма кызыксыну белдерде хатыны Җәмилә, камыр изә-изә.

– Шушы арада. – Салих көзге каршына килеп басты. – Башкалабызга чынлап та мең яшь микәнни?! – Бу сорауны кемгә юнәлтте ул: көзгедәге үзенең сурәтенәме, әллә бернигә ригаясез камыр басучы Җәмиләсенәме – аңлашылмады. – Мең яшь тула микәнни Казанга да?!

– Инде сиңа илле тулганны, Казанга гына мең бардыр, – диде хатын, камырын төеп.

Аның җавабы никадәр хак булса шулкадәре бәхәссез яңгырады ки, Салих беркавым ни әйтергә белми торды. Барып диванга чалкан яткач кына:

– Казанга барам! – дип игълан итте ул. – Баян апкайтам. Меңьеллык тарихлы башкалабыз була торып, нишләп әле мин моңга, музыкага сусап яшәргә тиеш?!

– Казанга киеп барырга синең рәтле күлмәгең дә юк бит, бөтенесенең якасы кырылган, – диде камыр басучы.

– Спонсор эзләп йөрүче кешенең өс-башы сәләмә булырга тиеш аның, – диде Салих, никтер бу юлысы үзенең фәкыйрьлегеннән күңеленең кайсыдыр бер почмагында канәгатьлек хисен барлап, вөҗүдендә чынбарлыктан ниндидер өстенлек абайлап.

Ни гаҗәп: мескенлеккә ияләшеп, күнегеп беткәч, кеше үзенең бу халәтен тирә-яктагы мохиттән, үзен камап алган, үзәгенә үтеп кергән чынбарлыктан әһәмиятлерәк дип таный башлый, үзенең мескенлеген яшәештән өстенрәк дип аңлатырга омтыла.

Түшәм өстендә түбә, түбәдән өстәрәк зәп-зәңгәр күк икәнне Салих ишетеп кенә түгел, күреп тә белә. Күк тарафларының чиксез-кырыйсыз икәнлеге дә мәгълүм аңа. Җәмиләгә кирәк түгел бит ул күкнең киңлекләре! Ә өмет өчен зәңгәр күкләр, чиксез галәмнәр кирәк. Адәм баласын өмет өйдә яткырмый. Өмет аны җилкендерә, хәрәкәт иттерә, канатландыра, һаваларда очырта. Өмет адәм баласын йолкып алып яшәешнең уртасына илтеп кертә. Һәм кеше, үзе дә аңламастан, яңа авырлыклар, сынаулар, газаплар аша үтәргә мәҗбүр була.

Күңелендә кыймылдаган өмет кошының җылысын тоеп, Салих өйдән чыгып китте.

* * *

Клуб мөдирен күргәч, авыл җитәкчесе Мулланурның яшисе килми башлады. Дөньядан шушы завклуб аркасында туйган иде ул.

– Нәрсә кирәк инде тагын? – дип ыңгырашты Мулланур, Салихның аксыл чыраена карамаска тырышып.

– Баян, – дип шыңшыды мәдәниятнең тынгысыз хезмәткәре.

– Мин сиңа ничә мәртәбә әйттем: баянга түгел, авыз гармунына да акча юк! Нәрсә син, баян да баян дисең һаман! Тегесен урлатмаска идең. Рәхмәт әйт үзеңнән түләттермәгәнем өчен.

– Рәхмәт.

Бу рәхмәтне Мулланур аңа даими рәвештә әйттереп тора иде. Салихның урланган уен коралы өчен түләргә акчасы юк икәнен үзе дә, авыл җитәкчесе дә, авыл халкы да, хәтта баянны чәлдергән карак та белә иде. Клуб мөдиренең рәхмәтне һәрдаим әйтүе, беренчедән, авыл җитәкчесе әйтергә кушканнан булса, икенчедән, бераз ялагайланып яңа баянга акча юнәтеп булмасмы дигән уйнияттән иде.

Мулланурның ике каш арасы ахыр чиккә кадәр җыерылды, борын тишекләре чамадан тыш киңәйде, кып-кызыл битендәге итләч борынның ике як-ягында аксыллык урын алды. Гадәттә, зур, тирән фикер әйтер алдыннан шундый кыяфәткә керә иде ул.

– Нигә син шул гомердән бирле баян дип саташасың?! Баян бит ул нимес инструменты! Җитәр нимес көенә биергә!

– Үзебезнең инструмент булмагач...

Мулланур кайнарлана башлады:

– Булмаса ни! Ярыйсы гына яшәп ятабыз бит әле. Клубта кино күрсәтми башлагач та алай зур үзгәреш сизмәдем, китапханәгә яңа китаплар кайтмаганнан да беркем үлмәде. Менә, ачуым килмәгәе, клубың җимерелеп төшсен, әйеме, аңа карап дөнья ишелмәячәк, валлаһи газим.

Салих та көтмәгәндә җикереп ташлады:

– Алай фикерли башласаң... Әйе, мәсәлән, синең алгы дүрт тешеңне сугып төшергәннән авылга бернинди зыян килмәячәк, шулай бит инде!

Мулланурның борын кырыендагы аклык кинәт кенә киңрәк җәелде:

– Аңламадым?

– Мин фәкать синеңчә фикерли генә башладым, – диде завклуб, җикергәненә шундук үкенеп.

Авыл җитәкчесе, авыз читләрен асылындырып:

– Кем әле син шулхәтле минемчә фикерләр өчен?! – дип ысылдады.

– Ни...

– Син, әйдә, клубтагы булган нәрсәне барлап, җыйнап, саклап калу турында кайгырт, – диде Мулланур, авылдашының кикриге шиңгәнне чамалап.

– Баянсыз клуб буламыни! – дип карышырга маташты Салих.

– Акча юк, – диде Мулланур һәм, өстәленең тартмасын ачып, актарынырга тотынды. Эзләр әйберсе дә юк иде аның, фәкать эшлекле кыяфәткә кереп, завклуб белән әңгәмәне тизрәк туктатырга исәп итте ул.

– Алайса, машина биреп тор, – дип, аның теңкәсенә тиде Салих.

Мулланур, тартманың астын өскә китереп:

– Кая барасың? – дип үчекләде.

– Казанга барам, спонсорлар табам, – дип ярып салды Салих, тавышында үҗәтлек яңгыратып.

– Беренчедән, Казанга барып җитәрдәй техника бездә юк. Икенчедән, синең кебек хәерчеләр башкалада чат саен басып та, утырып та, хәтта ятып та торалар. – Мулланур тартманы каты иттереп япты. – Карале, Салих, синең белән сөйләшкәннән соң саруымның кайнавын сода да басмый. Ник йөдәтәсең соң син мине?!

– Мин Казанга барырга тиеш! – диде Салих, киреләнеп.

Мулланур күзләрен акайтты:

– Син беләсеңме, Казанга барып җитәргә күпме бензин кирәк?! Бензинның бер литры күпме торганы мәгълүмме сиңа? Бар әле, чыгып кит! Баш миемне көзән җыера башлады.

Салих, авыл җитәкчесенең баш миендәге процесска куанып, бәйләнүен дәвам итте:

– Син татар мәдәниятенә битараф кеше. Син моңсыз, культурасыз бәндә.

– Ташла! – дип кычкырды Мулланур, башы турында онытып. Ләкин бу кычкыруга аның актык хәле сарыф ителде бугай, ул кинәт шәлперәйде, тавышы басынкыланды. – Татар мәдәнияте баянга килеп терәлгәнмени? Безгә су кергән, хатынның бөере авыртып тора, үземнең инде икенче көн урт тешем сызлый, ә син юк нәрсә белән теңкәгә тиясең.

Салих:

– Барыбер Казанга барам! – дип, авыл җитәкчесен тәмам бетерде.

– Хәерле юл, – дип ыңгырашты Мулланур.

* * *

Авыл җитәкчесенең «хәерле юл»ы бернинди фәтвага ия түгел, киресенчә, бар, күздән югал, бүтән күренмә, алдыңнан артың яхшырак һәм башка күптөрле чәнчүле теләкләргә охшаш яңгырады. Мулланурның битарафлыгыннан да бигрәк Җәмиләнең иртәгәсе көндә башланачак сәфәргә мөнәсәбәте авыр тәэсир ясады.

– Автобуска акча бирмим, – диде мәдәният хезмәткәре белән бимазаланып яшәүче хатын.

Шундый җавапны ишетәсен белсә дә, нинди әһәмиятле сәяхәткә чыгачагын аңламаучы надан хатынына Салих әле яңа тап булган нәрсәгә караган сыман текәлде:

– Ничек инде бирмисең?!

– Булмагач, каян алып бирим мин аны?! – диде Җәмилә, алъяпкыч почмагын бөгәрли-бөгәрли. Гадәттә, алдашкан вакытта ул шундый хәрәкәтләр ясый иде.

Салих, хатынының бераз каушавыннан файдаланып:

– Ә бәрәңге саткан акча кайда? – дип кызыксынды.

Җәмилә тавышын бераз күтәрергә кирәк дип тапты:

– Оныттыңмыни жимпер алганны?! Күпмелек саттың соң син бәрәңгене?! – Һәм еламсырап өстәп куйды: – Кешедән оят, ничә ел инде бер пәлтә киеп йөрим.

«Пәлтә» сүзен ишеткәч, Салихның күңелендә хатынына карата бераз кызгану белән бергә аны аңларга тырышу кебек хисләр дә сулкылдап куйды.

– Шыңшыма, хатын, – диде ул, ягымлырак булырга тырышып. – Ярый әле, шул начар гына пәлтәне киеп куярга менә дигән буйсының, чибәрлегең бар.

Салих моннан егерме сигез ел элек алган диванга барып ятты. Җәмилә шундук елаудан туктады. Борынын лаштырдатып тарткач:

– Шул телең генә коткара инде сине, – диде ул мәңге тынгысыз иренә.

– Кешене нәрсә булса да торымнан-торымга коткарып торырга тиеш, хатын, – диде Салих, түшәм тактасының ботак урынында калган җөенә текәлеп. – Сорамыйм мин синнән акча. Кая яшереп куйганыңны да, ничә сум икәнен дә беләм, әмма вә ләкин таләп итмим. – Ул торып утырды. Кинәт чыраен сытты һәм тирәннән каертып ыңгырашып куйды. – Хәлем кинәт начарланып китте әле.

Шуннан соң ул тагын чалкан ятты.

– Тагын диприссиядер, – диде хатын битараф кына.

– Шулайдыр, – диде Салих, ыңгырашу сытылып чыга торган каты күкрәген кытыршы кулы белән угалап. – Тик менә бу юлысы тирәнрәк төште бугай бу депрессия.

Җәмилә иренең күзләрен әйләндерә-әйләндерә шыңшуыннан шүрләбрәк калды.

– Чын әйтәсеңме син? – диде ул, сагаеп.

– Нишләп шаярып ятыйм мин! – дип ыңгырашты Салих.

Җәмилә якынрак килде:

– Филшерны чакырыйкмы?

Салихның чыраена газап томаны саркыды:

– Кирәкми. Аның «зеленка»дан башка бүтән даруы юк. Ничек чирләсәң дә, миләш кайнатып эчәргә куша бит ул. Син Мулланурны чакыр. Салих үлә, диген. Үләр алдыннан әйтәсе сүзләре бар, диген.

Җәмилә авызын чалшайтып елап җибәрде.

– Елама, хатын, – диде Салих, чак кына ишетелерлек итеп. – Син бит мине жәлләп еламыйсың. Син теге яшереп куйган акчаңны минем үлемтеккә тотарга туры киләчәк дип борчылып елыйсың.

– Ни сөйлисең инде син, җүләр! – дип кычкырды Җәмилә. – Ничек килә шундый уйлар башкайларыңа. Фильшерга әйтик, каладан «скорый» чакыртсын.

Салих тагын авыр иттереп ыңгырашып куйды:

– Кирәкми «скорый» чакыртырга! Барыбер кеше үлгәч кенә килеп җитә ул. Мулланурны чакыр.

– Авыл җитәкчесен чакыру яхшы түгел.

– Ә аңа әйтәсе сүзләремне әйтмичә бу дөньядан китеп баруым яхшы булырмы?

Җәмилә котсыз калды. Нишләргә белми аптырады – суган исле кулларын барып юаргамы, әллә шул килеш кенә өс киемен алыштырыргамы, ире янына утырыргамы, әллә фельдшер артыннан йөгерергәме, Мулланурны чакырыргамы, әллә үзенә шушында ятып үләргәме?

– И Ходаем! – диде ул җан ачысы белән һәм өйдән атылып чыгып китте.

Салих, күзге каршына барып, кыяфәте йончыганрак булып күренсен өчен, чәчләрен тузгытты, күлмәк төймәләрен чиште, шуннан соң куркыныч позада янә диванга ятты.

...Күп тә үтмәде, Җәмилә белән Мулланур атылып килеп керделәр.

Мулланур диванда ятучыга беркавым карап торганнан соң, завклубка түгел, ә бәлки кешегә эндәшкән кебек мөрәҗәгать итәргә булды:

– Нишләдең, Салих?

– Миңа инде күп калмагандыр, – дип шыңшыды дивандагы гәүдә. – Мин инде озак булмам. Алай-болай кинәт ычкына калсам, сиңа исән чакта әйтәселәремне җиткерәсем килә.

– Әй, кыланма инде, – диде Мулланур, көлемсерәп. – Депрессияме, гадәттәгечә?

– Монысы актык депрессия инде, – диде Салих, чак кына ишетелерлек итеп.

– Сиңа бирәр нәрсә кирәктер инде тагын, – диде Мулланур, өй эченә күз йөгертеп.

Салих башын калкытты:

– Ник алай дисең?

– Син бит кирәк нәрсәне гел шулай кыланып сорыйсың, – дип елмайды Мулланур. – Ни кирәк икәнен дә беләм инде мин.

Салих күзләрен йомды:

– Көлмә. Синең завклуб булып эшләгәнең юк, шуңа көлке сиңа.

Авылдашының оста иттереп, чын артистларча кылануыннан Мулланур кәефләнеп китте, диван кырына утырды.

– Көлмим. Кай җирең авырта?

– Җан сызлый, – дип җавап бирде Салих, башын стенага таба борып.

Мулланур, оча алмый калган кош баласы сыман морҗа янында басып торучы Җәмиләгә карап:

– Алайса, сиңа авыл җитәкчесе түгел, берәр мулла кирәктер, – дип көлемсерәде.

Салих кинәт торып утырды:

– Юк, син дә кирәк! Син кайгыртырга тиеш авыл мәдәнияте!

Салих ишек катына юнәлде.

– Хәлең бер дә мөшкел түгел, – диде ул коры гына. – Син минем белән алай сөйләшмә, яме. Депрессия дип тормам. Үләргә ятучы кеше мондый амбициозный булмый ул.

Җәмилә ирен якларга кирәк дип тапты:

– Мулланур абый, син аңа ачуланма инде. Ул кайвакыт ни әйткәнен аңламый да кала. Яз-көз аның неврозы ныгый.

Салих, торып, депрессияләргә ышанмый торган авыл җитәкчесенә таба атлады:

– Син татар мәдәниятенә битараф кеше! Син моңсыз, культурасыз бәндә!

– Симулянт, – диде аңа Мулланур.

– Барыбер Казанга барам, – диде Салих, инде беркемгә, бернәрсәгә карамыйча, ниятеннән баш тартмаячагына инандырырлык тавыш белән.

Җәмиләнең калтыравыклы авазы ишетелде:

– Куркам, төнлә саташып чыгып китмәгәе.

– Барыбер Казанга барам! – дип өстәде завклуб, хатынына таба борылып.

Барыбер барачак бу, дип уйлап куйды Мулланур. Әллә барып кайтсынмы?

– Карале, Салих, мин сиңа ат бирә алам.

Салих сискәнеп китте.

– Бир! – диде ул, кулларын сузып, гүя атны менә хәзер, шушында ук аңа китереп бирәләр. – Командировочный да бир!

– Менә анысы юк инде, туган, – диде Мулланур, авызын кыйшайтып. – Анда барырга мин кушмыйм бит сиңа.

– Ярар, зинһар, атны гына бирә күр, – дип ялварды Салих.

– Ат караучы Вахит абый янына бар, мин рөхсәт бирде, диген. Ат белән барып кайт. Ичмаса, хет бер-ике атна күрми торырмын үзеңне. Түлке синең анда спонсор табасыңа һич кенә дә ышанмыйм. Казанда җырчылар, артистлар бихисап күп. Алар үзләре төрле районнарга чыгып акча соранып йөриләр. Казанда акча кем бирсен сиңа?!

Мулланур чыгып киткәч, Җәмилә котсыз калып иренә карап катты:

– Казанга атка атланып барып керерсең микәнни?

– Барып җитәргә кирәк әле башта, – диде Салих, кинәт тере-

леп. – Атны шәһәр читендәге берәр шәхси хуҗалыкта калдырып торып та була бит. Киттем мин ат утарына.

Җәмилә иренең чыгып киткәнен сизми дә калды.

...Салих ат утарына якынлашканда, атбагар Вахит абый абзар төбәсендә бик сәер төш күреп йоклап ята иде. Имеш, утардагы атларны санаганда, бер атка күбрәк чыга икән. Моның өчен җыелышып Вахитны сүгәләр, имеш: «Нишләп конюшняда артык ат хасил булган?» Вахит ничек итеп акланырга белми, бер атка артыграк булуга сөенергә кирәк икәнне аңлатырга тырыша, ләкин һич кенә дә теле әйләнми, өстәвенә беркем дә моны тыңларга теләми. Хатыны тешләрен шыгырдатып аның бугазына ябыша: «Нишләп конюшняда артык ат, кабахәт?!» Күп тә үтми, барысы да җилтерәтергә, суккаларга тотыналар.

Вахит саташулы йокысыннан уянып җитәр-җитмәс торып утырды. Җилтерәтүче кешенең авылдашы Салих икәнне шактый вакыт аңышмый торды.

– Вахит абый, Мулланур синнән ат алырга кушты.

* * *

Көн кичкә авышты.

Илнең кая барганын чамалау кыен булса да, трассада гыжвыж килеп төрле тарафларга чабучы машиналарда утыручылар һәрберсе кая, ник, нинди максат белән йөрүләрен беләләр. Үзләренең мәшәкатьләре белән абаланып ары-бире чабуны дөньялыктагы алгарышның алшарты дип инанган «яңа урыслар»ның һәм аларга ияреп казганучы «яңа татарлар»ның олы юлда хуҗа икәнлекләренә ил-көн инде ияләште, күнекте.

Тик менә атка атланып, агач чүбе тутырылган капчык сыман әвеш-тәвеш килеп чайкала-чайкала баручыны күрү бик күпләре өчен гайре табигый күренеш тоелгандыр, мөгаен. Кемгәдер кола атны күрү могҗиза булса, икенчеләре өчен атка атланган йолкыш кешенең кагайтылгандай какча бәдәнен бераз иеленкерәтеп юл шау-шуыннан каушанкырап баруы сәер һәм кызык иде. Ыгы-зыгы астында чит-ят кеше буларак югалыбрак калса да, бу җайдакның кыйбланамәсе дә, кулавызы да бар иде. Аны ниндидер илаһи көч бетонлы юллар, тимер-томырлы машиналар, таш бәгырьле кешеләр арасыннан офык сызыгына таба алып китте. Алда кояш баеп килгән тараф икәнне ат сизенде, ахрысы, ул яннан гына узып китүче машиналарга бернинди ригая бирмәде, ә менә алга таба карап, көрсенгәндәй, пошкырып-пошкырып алды. Кансуланып торган шәфәкъ учагында тагын бер көн янып бетеп килә, тау артыннан аның инде утлы күмерләре генә балкый иде.

Атны торымнан-торымга аяклары белән кымтып, Салих билгесезлек вәгъдә итүче киләчәккә юл тотты. Киләчәк ул – билгесезлек. Кире юл юк, фәкать шунда гына бару мөмкин. Чөнки

билгесезлектә барысы да – бәхет тә, кайгы да. Шунда синең тәкъдиреңә язылганы!

Җылы көннәргә әле ераграк икәнне онытмасыннар өчен апрель азагының җиле салкынча, юеш теле белән тәнне ялап-ялап алды. Нократ елгасы аша салынган күпердән арырак калкулыкта кунакханә барлыгын Салих ишетеп белә иде. Кунакханәнең арткурасы бардыр, бәлки, атны урнаштырырга да берәр абзар сыман нәрсә юк түгелдер дигән өмет белән ул күперне чыкты.

«Милиция» дигән язу әллә каян ук күренде, бу сүз вак хәреф белән язсаң да һәркемнең күзенә ерактан ук чалынадыр һәм дөрес таныладыр.

Милиция посты кирпеч бинадан, шлагбаумнардан, төрле билгеләр ясалган баганалардан, такталардан, прожекторлардан, җыйнак кына будкадан гыйбарәт иде.

Утыз яшь тирәсендәге милиция сержанты, муенына автомат асып, юл кырында эленке-салынкы, әмма үтә җитди кыяфәт белән йөргәндә, җайдак пост янына килеп җитте. Аның туктарга исәбе юк иде, ләкин башта сыбызгы тавышы ишетелде, аннары «Стой!» дигән имәнгеч сүз яңгырады.

Салих: «Тр-р-р-р, малкай!» – дип, атын туктатты.

Сержант, күзләрен акайтып, аяусыз тавыш белән кычкырды:

– Пачиму по трасси на лошади едешь?

Салих, аттан төшеп:

– Я же по краю трассы еду, – дип җавап бирде.

– Ну и што! – дип чәчрәде милиционер. – Чичас здис эскурт прайдет.

– Нинди эскерт?

– Эскерт түгел, Мәскәү делегациясенең колоннасы Чаллыдан Казанга барачак, – дип татарчага күчте сержант.

– Ник, алар миңа комачауламый бит, – диде Салих, аны-моны уйламыйча.

Сержант, үзеннән дә җүләррәк кешене күрүенә шаккатып:

– Вәт дурак! – дип куйды. – Правительственный дилигация узачак, аңладыңмы?! Ну-ка, дакументы!

Адәм баласының җаны бар. Җан гына аны әле кеше итми, җан ул сарыкта да бар. Кеше булыр өчен әле паспорт та кирәк.

Салих, борсаланып, куен кесәсеннән документын чыгарды:

– Менә паспортым.

Сержант күзен кылпакландырып паспортны карады да:

– Атка дакумент бармы? – дип кызыксынды.

– Юк.

– Кем аты бу?

– Минеке.

– Синеке икәнне раслый торган документ бармы?

– Юк.

– Бияме, алашамы?

– Айгыр.

– Кайда учетта тора?

– Конюшняда. Вахит абыйда.

– Вахит кем?

– Атбагар.

– Атбагар нәрсә дигән сүз?

– Ат караучы.

Сержант үзенең будкасына таба атлады.

– Атыңны ограждениегә бәйләп куй да монда кил.

Салих, атны будка янындагы тимер рәшәткәгә бәйләп, сержант янына килде.

– Соңгы вакытта йорт хайваннары, кош-корт урлау очраклары бик ешайды, – диде милиционер, Салихның паспортын дикъкать белән кат-кат актарып. – Шуңа күрә мин тикшерергә обязан.

– Сез бит монда машиналарны гына тикшереп торырга обизьян, – дип базынды Салих.

– Ат ул, между прочим, транспорт та, – диде сержант. – Атка без неравнодушны. Президентыбызның атларны ничек яратканын ишетеп беләсеңдер?

– Ишетеп кенә түгел, күреп тә беләм. Бөтен конторaларда ат рәсеме төшерелгән плакатларябыштыралар. Шул президент ат ятратканга бит инде ул.

Сержант акаеп Салихка карады:

– Но-но, сүзне алайга кертмә! Син миңа бу ат синеке икәнне исбатла.

Салих үзенең каршында мондый киртәнең калкуын көтмәгән иде, ул әллә нинди авырлыкларга, сынауларга әзер, әмма дә ләкин бетчәләнгән чырайлы нindидер бер маңка малайның кат-кат сорау биреп йөдәтүенә түзәргә исәбе юк иде.

– Ничек исбатлыйм? – диде ул, тавышын көрәйтеп. – Карале, синең башка эшең юкмыни?.. Авыл аты бу. Күмәк хуҗалык җитәкчесе Мулланур биреп торды. Казанга барып кайтырга. Спонсор эзләп чыгып киттем мин. Авыл клубына баян кирәк. Җибәр инде син мине. Ат бик арыды, инде көне буе киләм бит. Атны урнаштырыр урын булса, Мамадыш тукталышындагы кунакханәдә кунармын дигәнием.

– Әйдә будкага! – дип боерды сержант.

– Ник? – диде Салих, никтер будкага керергә куркып.

– Компьютердан тикшерәм – сине дә, атны да. Анда безнең бөтен данныйлар бар. Алай-болай синең фамилияң яисә ат турында берәр мәгълүмат юк микән.

– Ничек мин кампиятырда булыйм, минем бит авылдан чыкканым юк. Атның исә конюшнядан чыкканы юк.

Әйе, чынлап та, компьютер базасында Салих та, ат та, хәтта Вахит абый үзе дә юк иде.

Сержант Салихка паспортын бирде:

– Правительственный делегация килеп җиткәнче кунакханәгә менеп өлгерәсеңме соң син?

– Ныграк куалармын, – диде Салих, паспортын куен кесәсенә тыгып.

Сержант, кашларын җыерып, борын тишекләрен киңәйтеп:

– Дамба астыннан бар! – дип боерды. – Не дай Бог тагын юлдан барсаң. Учти, алда анда безнең постлар бар әле. Аңладыңмы?

– Аңладым.

Салих аты калган тарафка ашыкты. Милиционер, кокардалы башын чайкап:

– Әллә кемнәр бар дөньяда, – дип калды.

Сержант салмак кына адымнар белән үз куышына таба юнәлгәч, тирә-якны җан өзгеч тавыш ярып җибәрде.

Будка артыннан Салих пәйда булды һәм сержантка таба абына-сөртенә ыргылды:

– Ат юк! – дип акырды ул. – Ат әллә кая киткән! Атны урлаганнар!

– Нәрсә булды?

Салих сержантны түшеннән эләктереп алды:

– Ат юк! Синең аркада!.. Атым кайда?! – Милиционерны ычкындырып, ул әрле-бирле чаба башлады. – Ат кайда? Атым юк!

Аңа ияреп, сержант та бөтерелергә тотынды:

– Ник соң син аны бәйләп куймадың?

– Бәйләдем мин аны, – дип еламсырады Салих.

– Әллә кая китмәс. Шушы тирәдәдер. Эзлә.

– Юк бит. Кая китәр ул, ә?!

Салих, елый-елый, будка тирәсен әллә ничә кат әйләнеп чыкты, ары-бире йөгеренде, калкулык астына берничә мәртәбә мүкәли-мүкәли төшеп менде. Сержант та аңардан калмады, ияреп йөрде. Ләкин ат күренмәде.

Алар хәл алырга туктадылар.

– Кире авылыңа чапмагандыр бит? – диде сержант, еш-еш сулап. – Алай дисәң, ул арада күздән югалмас иде.

Салих, кыҗрап, тагын милиционерны җилтерәтте:

– Ник бәйләндең, ник тоткарладың соң син мине?! Хәзер нишлим инде?

– Атның үзе кире килә торган гадәте бар, бәлки, кире килер.

– Ат ул ашаган җиренә кире кайта. Милиция постына кире ник килсен ул! – Салих тагын тирә-якны күзәтте. – Юк инде, юк, качкан!

– Кая китәр икән шул арада?! Озак та тормадык югыйсә будкада.

Салих борын куышы белән бугаз тоташкан тирәдән җанны өзәрлек ямьсез тавыш чыгарып еларга тотынды:

– Авыл җитәкчесе үтерә мине!

Сержант өстәрәк урнашкан кафе тарафына чекерәеп карап торды.

– Елама, – диде ул. – Әнә күрәсеңме, БМВ тора теге кафе янында.

– Нәрсә соң ул биемвы?

– Шундый машина. Ул Мирза дигән кешенеке. Әнә үзе дә чыгып килә.

Салихның беркемне күрәсе, ишетәсе килмәде.

– Чыкса ни... – дип шыңшыды ул.

– Мирза абый! – дип кычкырды сержант. – Кил әле монда!

Кафедан ашап-эчеп чыгып килүче җан иясен җәмгыятьнең бернинди катламына кертү мөмкин түгел. Илдәге үзгәрешләрдән, кыйбласызлыктан файдаланып, хәйләкәр, елгыр, яраклашучан һәм оятсыз кешеләр тантана итә башлады. Бу әрсезләр, бүгенге белән көн күреп, ил-көн ялаешенә төкереп, үзләренең кыңгыр эшләре белән масаеп, кешелек дөньясы инде мең-мең еллар элек кабул иткән изге төшенчәләрне таптап, хуҗаларча аяк атладылар.

Кафедан чыккан шактый гына исерек бәндә озак көттермәде, җырлый-җырлый килеп җитте:

Ал чәчәк аткач бала-а-ан,
Гөлгә күмелә ала-а-ан,
Ал чәчәк аткач бала-а-ан,
Гөлгә күмелә ала-а-а-а-ан...

– Гадәттәгечә, салган, – дип елмайды сержант.

Мирза чыраеннан чиксез яктылык сирпеп килеп күреште:

– Сәлам бирдек, Минәзәл дус! Алла хакы өчен автомат көпшәңне минем якка борма. Ату йөрәк болай да яралы, кем әйтмешли. Нихәлләр бар соң?

– Минем служба бара. Миңа нәрсә. БМВыңны читкәрәк алып куйсаң, минем монда полный тәртип була. Алайса, тиздән зур делегация узачак.

Мирза кафе янында торган машинасына борылып карады:

– Хәзер, алып куям, брат. Син кушсаң, таудан Вяткага этеп төшерергә дә могу машинамны. – Шуннан соң ул киерелеп көлеп куйды.

– Кирәкми. Әнә кафе артынарак кына куй.

– Бик зур кеше киләмени? Путин үзе түгелдер бит?

– Юк, ул түгел.

Мирзаның кыяфәтенә вәкарьлек чыкты.

– Минем Путинны күрәсем бар, – диде ул, башын өскәрәк калкытып. – Без бит әшнәләр аның белән. Узган ел Сабантуена килгәч танышкан идек. Мин Казанда Сабантуй өчен ответственный идем. Путинга мин әйттем бит, башыңны катыкка тыксаң, Татарстан сине мәңге онытмас, дидем. Бу безнең иң зур милли уен, мәйтәм, давай, катыктан акча эзләгән булып кылан. Кеше күрмәгәндә генә авызына акча каптырдым да, теге, катыкка башын тыгып, имеш, акча тапты.

– Аның авызында акча бар идемени инде? – диде Минәзәл, шаккатып.

– Булмаска. Әйтәм бит, кеше күрмәгәндә капты авызына.

Минәзәл паузадан файдаланып сорау кыстырды:

– Мирза абый, син берәр ат күрмәдеңме бу тирәдә?
– Юк, күрмәдем. Нинди ат?
– Ат югалттык.
Мирза башта кикереп куйды, аннары:
– Башың исән булсын, башыңны югалтма, – диде.
Шулчакны күзгә күренеп шәлперәйгән завклуб телгә килде:
– Минем атым юкка чыкты, күрмәдегезме?
– Күрмәдем дидем бит инде, – дип җикерде Мирза. – Нинди ат соң ул?
– Минем атым, – диде Салих.
– Юк белән башны катырмагыз әле, – диде Мирза һәм җитди кыяфәт белән кулын йөрәк турысына куйды. – Татар йөрәге скрипкә түгел, уйнамагыз, пажалысты.
Шуннан соң ул киерелеп җыруын сузды:

Ачуланма, туган,
Закускага суган, –
Кесәнең такыр чагы-ы-ы.
Алып кил миңа тагы-ы-ын
Күрше карчыкның казы-ы-ын,
Алып кил миңа тагы-ы-ы-ын
Күрше карчыкның казы-ы-ы-ын...

– Туктале! – дип бүлде Минәзәл аның җырын. – Син бу тирәдә бик абруйлы кеше...
Мирза җырлаудан туктап кукраеп басты:
– А как же! Мин бит Мирза! Знаменитый мал врачы. Тикмәгә докторскины защищать иттеммени мин! Миңа бит профессор дигән исем дә бирделәр күптән түгел. Шуны юып йөреш әле.
– Бер үтенеч бар, – диде Минәзәл.
– Синең гозерме, әллә бу карачкынныкымы?
– Мин карачкы түгел, – дип канәгатьсезлек белдерде атсыз завклуб.
– Ә син докажи, – диде мал врачы чәнчүле тавыш белән. – Ха-ха-ха.
Мирзаның «ха-ха-ха»сы Минәзәлгә дә ошамады, ул Салихны юатырга булды:
– Ярар, үпкәләмә инде, аның сөйләшүе шундый.
Мирза сержантны иңеннән какты:
– Маладис, аңлыйсың, дуңгыз. Тизрәк әйт инде, Минәзәл, үтенечеңне. Яратмыйм озакка сузганнарын. – Ул тагын кулын йөрәк турысына куйды. – Татар йөрәге скрипкә түгел, уйнама, әйт тизрәк.
– Мирза туган, менә бу кешенең будкада документларын тикшергәндә аты каядыр юкка чыккан.
– Шуннан?
– Ат авылныкы, – дип өстәде Салих.
– Мин, ветеринарный врач буларак, ул ат турында бернәрсә әйтә алмыйм, чөнки минем әлеге дә баягы атны күргәнем юк, –

диде Мирза. – Ә менә доктор наук буларак чамалый алам: ат йә качкан, йә урлаганнар. – Ул башын күтәреп күккә карады. – Һәм дә профессор буларак әйтәм: хайван күккә очып китә алмый, чөнки Аллаһы Тәгалә миңа, мал врачына әйтми-нитми, җир йөзеннән йорт хайваннарын, бигрәк тә авылныкын юкка чыгармый.

Салих күңел төпкеленнән ыңгырашып куйды:

– Хәзер ничек авылга кайтыйм?!

Мирза, маңгаен буй-буй җыерчыкландырып:

– Җәяүләп инде, – диде. – Атың югалгач ничек кайтасың инде! Только җәяү!

– Син аңа ат үлде дип справка эшли алмыйсыңмы соң? – диде милиционер, чак кына ишетелерлек итеп.

Мирза тантаналы тавыш белән әйтеп салды:

– Минәзәл туган! Син кушсаң, ул ат ике тапкыр үлеп, ике тапкыр терелеп, өченче тапкыр җан тәслим кылды дигән документ та эшләп бирә алам. Син бит мине әллә ничә тапкыр выручать иткән кеше. Яхшылыкны онытмыйм мин.

Шуннан соң ул янә үзенең яраткан җырын дәвам итте:

Ачуланма, туган,
Закускага суган, –
Кесәнең такыр чагы-ы-ы-ы.
Ки-и-ил, ки-и-ил, ки-и-ил, кил, иркәм, кил инде-е-е,
Ки-и-ил, ки-и-ил, ки-и-ил, кил, иркәм, кил инде-е-е,
Кил, иркәм, кил инде, елмаеп көл инде,
Сагындым, бәгърем, сине-е-е-е.

– Эшләп бир, зинһар, күрмисеңмени бу бичараның кыяфәтен?! – диде Минәзәл, Салихка ишарәләп.

Мирза Салихка текәлеп карады:

– Да-а-а, кыяфәтең бигүк чибәр түгел. Синең кыяфәтең обманутый вкладчикныкы сыман. Ярар. Атың үлде дип справка бирәм мин сиңа. Алайса, йә үзең шушында үлеп китәрсең дә, бәддогасы безгә булыр. Ха-ха-ха. Кем соң син?

– Салих атлы мин, – диде мәдәният колы.

– Салих атлы атсыз Салих син хәзер, – дип мыскыл итте аны Мирза. – Кайда эшлисең?

– Авылда.

– Алдыйсың. Авылда хәзер эш юк.

– Валлаһи, авылда эшлим.

– Кем булып?

Салих, чыраен сытып:

– Завклу-у-у-уб, – дип ыңгырашты.

– Андый эш бармыни әле ул?! – диде Мирза, ихластан аптырап.

Шуннан соң ул кесәсеннән справка бланкасын чыгарды. Минәзәл шундук бераз иеленкерәп басты. Мирза кәгазьне сержантның җилкәсенә куеп язарга кереште.

– Гафу ит, Минәзәл, туган, без шактый күп эчтек, – диде Мирза, яза-яза.

Сержант, көлемсерәп:
– Ярый, ярый, – диде. – Сиңа, киресенчә, эчмәсәң килешми.
Мирза Салихка эндәште:
– Фамилияң ничек?
– Ә?
– Нәҗмиев, – дип җавап бирде сержант Салих өчен.
– Әйе, Нәҗмиев, – дип кабатлады Салих.
– Исемең?
Салих үзенең исемен эзләп хәтерендә казынганда, аның өчен тагын сержант әйтте:
– Салих.
– Әйе, Салих, – дип хуплады завклуб.
– Отчествоң? – диде Мирза таләпчән тавыш белән.
Сержант бу юлысы Салихның ык-мык килгәнен дә көтмәде:
– Габделбәревич, – диде.
Салих үзенең отчествосы белән дә килеште:
– Әйе, Габделбәревич.
Мирза бланканы язып тутыргач:
– Кайсы авылдан син? – дип кызыксынды
– Катлаулыдан, – диде Салих.
– Катлаулыданмыни?! – дип гаҗәпләнде Мирза. – Муллануруга сәлам әйтерсең.
– Сез аны беләсезмени? – диде Салих, сөенеп.
– Татарстанда мин белмәгән кеше бар микән ул! – диде Мирза.
– Ә сезнең үзегезнең исемегез ничек? – дип сорарга җөрьәт итте атсыз завклуб.
Мал врачы алтын тешләрен ялтыратып авызын ерды:
– Мирза. Меня зовут Мирза, работать мне нельзя. Ха-ха-ха.
Мирзаның икенче кесәсеннән пичәт чыгаруын күргәч, Салихта өмет уянды.
– Алайса, бу справкага ышанырга тиешләр?
Минәзәл пичәт суктырырга дип тагын бөгелеп җилкәсен куйды.
– Минем справкаларыма ышанмаган кешене очратканым юк әле, – дип, Мирза пичәте белән шапылдатып кәгазьгә басты. – Мә, кайгырма. Ат югалды дип бу кадәре бетеренмиләр инде. Баш исән булсын. Ха-ха-ха.
Салих, рәхмәт әйтергә дә онытып, ат үлгәнне раслый торган пичәтле справканы укып-нитеп тормыйча, калтырана-калтырана бөкләп, куенына тыкты.
Рәхмәтне аның өчен, гәүдәсен турайткач, милиционер әйтте:
– Рәхмәт, Мирза әфәнде.
Мирза тагын сержантны иңеннән кагып куйды:
– Үзеңнең хәлләрең ничек соң, агайне?
Сержантның төсе начар якка үзгәрде.
– Әйбәт тә, тик менә правительственный колонна узачак хәзер, – диде ул, борма-борма сузылган трассага карап. – Мәскәү делегациясе белән. Син машинаңны юлдан ал инде, Мирза абый.

– Алырмын, алырмын, борчылма, – диде Мирза, башын кагып. – Кем килгән соң?

– Әллә тагы...

– Безгә юньле кеше килмәс. Йә Шахрай, йә Чубайстыр инде. Ха-ха-ха. Ярый, киттем мин. Хушыгыз! Киләсе очрашуларга кадәр!

Мирза, җырлый-җырлый, машинасына таба атлады.

Ачуланма туган,
Закускага суган, –
Кесәнең такыр чагы-ы-ы-ы.

Минәзәл мал врачы киткән якка карап көлемсерәде:

– Суган гына түгел синең закускага. Гел ит кенә ашыйсың син.

– Бу справка чынмы соң? – дип борчылды Салих, документларын капшап.

– Чын булмый инде. Пичәте-ние бар.

Салих тирән сулап куйды:

– Кире авылга юл тотам инде хәзер.

– Бар. Түлке трассадан барма. Кырыйдан гына атла, – дип озатып калды аны сержант.

* * *

Салих кайтып кергәндә, Җәмилә телевизорда барган тапшыруны тыңлый-тыңлый тәрәзә төбендәге гөлләргә су сибеп йөри иде.

– Кадерле дуслар! – диде телевизордан чепи күзле, почык борынлы әллә егет, әллә кыз. – Безнең тапшыру аша сез үзегезнең туганнарыгызны, якыннарыгызны котлап, аларга җыр бүләк итә аласыз. Чаллы каласыннан килгән хатны укыйм. «Исәнмесез! Чаллыдан сезгә күптин күп сәлам! Сезгә инде унбиш ел буе беркайда да эшләмәүче Хәниф Ибраев яза. Минем гаиләм шактый зур: аяклары кәкре булса да, шактый чибәр хатыным, «икеле»гә укыса да, үз ягына яхшы уйлый торган ундүрт яшьлек улым, мине бигүк яратмаса да, үзем аны бик ярата торган унике яшьлек кызым, бер файдасы булмаса да, яшниктагы комга гына йөри торган песиебез, болай күп ашамаса да, инде үзәкләремә үтеп җанымны нык ашаган тещам, инде йөрми торган булса да, тәрәзәдән карап аның ишегалдында торуын күреп сөенер өчен «Москвич»ым бар. Җыр сорарга дип язуымны аңлагансыздыр инде. Гаиләм өчен түгел. Аларга җыр кирәкми, аларга акча кирәк. Җырны мин башка кешеләр өчен сорыйм. Штатлар кыскартылу сәбәпле, мине унбиш ел элек заводтан чыгардылар. Бу минем өчен зур кайгы булды. Шунысы гына куандыра: заводтан куылучылар бер мин генә түгел, без бик күп. Менә шул сокращениегә эләккән коллегаларыма багышлап җыр тапшырсагыз иде. Без эшсезләргә алтмышынчы елларда популяр булган «Таң ату белән эшкә йөгерәм»

дигән җырны тапшырсагыз, рәхмәтле булыр идек. Бу җырны шулай ук Чаллы шәһәренең Автозавод районы хокук саклау органнары, прокуратурасы, суд хезмәткәрләре хөрмәтенә дә юлласагыз яхшы булыр иде. Чөнки безне кыскартып эштән чыгаручы завод директорын, дәүләт милкен урлаганы өчен, күптән түгел дүрт елга ирегеннән мәхрүм иттеләр. «С конфискацией» диделәр. Менә бит, кайгы килсә, аның артыннан шатлыгы да килә». Хәниф Ибраев сораган җыр фонотекабызда юк икән, аны без башка вакытта бирербез. Ә хәзер Хәниф Ибраевка һәм аның коллегаларына, аларны җәберләүчене төрмәгә утыртучыларга һәм төрмәдәге теге завод директоры хөрмәтенә җыр тапшырабыз.

Өй эченә телевизордан мәгънәсез бер келтер-келтер җыр акканда, ишектән, Салихка иярен, чиксез тирән мәгънәле шом дулкыны бәреп керде.

Иренең өйгә кереп, курткасын да салмыйча, бер сүз дәшми диванга ауганын күргәч, Җәмилә шактый вакыт баскан урыныннан кузгала алмый торды.

Ниһаять, ул телевизорны барып сүндерде дә, ишетелер-ишетелмәс кенә:

– Барып кайттың да мәллә? – дип сорады.

– Күрмисеңмени?! – диде Салих, түшәмгә карап.

– Акча таптыңмы? – дип якынлашты хатын, ире белән бергә йортка бәла кайтканны сизенеп.

Салихның тонык кына тавышы ишетелде:

– Без шактый вакыт гомер кичердек бергә. Бәхил бул, яме.

Җәмилә йөгереп барып тәрәзәдән тәрәзәгә күчеп йөргәннән соң:

– Нәрсә булды? – дип кычкырды. – Нишләп җәяү кайттың?

– Ат әллә качкан, әллә урлаганнар, – диде Салих, хатынына карамаска тырышып.

Җәмилә, котсыз калып юлның яртысында ук бәлагә тарыган иренең бәянын тыңлагач:

– И Ходаем, хәзер инде ат бәясен түләтәчәкләр, – дип илаулап елап җибәрде. – Төрмәгә дә утыртып куярлар әле үзеңне.

– Миңа хәзер барыбер, – диде Салих, күңеленең катканлыгын анык күрсәтергә тырышып. – Миңа, кем әйтмешли, ике дөнҗа – бер морҗа.

– Аңа барыбер! Дөнҗа! Морҗа! Ә мин? Ә кызың? Без нишләргә тиеш? Мулланурны ничек юмалыйбыз хәзер?

– Бар, чакыр аны. Анда бер мал врачын очраттым мин. Профессор. Исерек булса да, сүзне тыңлады. Ат үлде дип справка бирде. Чакыр Мулланурны. Справканы күрсәтәм.

Җәмилә көч-хәл белән утырган урыныннан кузгалды да фуфайкасының эчке, чистарак ягын әйләндереп киеп:

– Бар икән күрәселәр! – дип чыгып китте.

Салих әрле-бирле йөренергә тотынды: «Ник болай интегәм соң мин?! Нинди гөнаһларым өчен соң бу иза чигүләр?!»

Чөйдән тастымал алып муенына чорнады, үзен-үзе буып кара-

ды. Күзләре акайды. Йөткерергә тотынды. Тастымалны читкә ыргытты. «Үләксә бит мин! – диде ул, кулы белән муенын угалап. – Тулы кеше түгел бит мин! Мин бит хәтта асылына да алмыйм. Бу мескенлекнең чиге бар микән, юкмы?!» Бәлки, болай гына үлеп булыр дип ул барып диванга ятты, кулларын күкрәгенә куеп, суламаска тырышты.

Бераздан бусагада Мулланур пәйда булды, аның артыннан үле-мәлле кыяфәттә Җәмилә күренде.

– С приездом! – диде авыл җитәкчесе мыскыллы тавыш белән.

– Благодарю, – дип җавап бирде завклуб, түшәмгә караган килеш кенә.

– Йә, күрсәт, кайда баян, спонсорский акча, атланып чыгып киткән атың?

Җәмилә Мулланурга ялварды:

– Бик каты бәрелмә инде, хәле авыр бит.

– Кем гаепле соң аның хәле авыр булуда?! – дип җикерде авыл җитәкчесе. – Тагын нинди убытоклар китерерсең икән син авылга, ә?! Кемнәр уйлап чыгарган шушы клубларны, кемнәр уйлап тапкан аның завклубларын, кемнәр уйлап чыгарган ул баянны – бөтенесен җыеп, һәрберсенең муенына баян тагып, язгы ташуларда Камага тондырыр идем. Яр кырыенарак чыкканнарын үзем лично багор белән эчкәрәк этеп торыр идем. Кая куйдың атны, мөртәт?!

– Ат үлде, – дип хәбәр итте Салих ат урынына үзем үлсәм яхшырак булыр иде дигәнне аңлаткан тавыш белән.

– Шулай нык кудыңмыни?

– Юк, баруын әкрен генә бардым. Каты чабарга куркам бит мин.

– Ат болай гына үлми ул.

Салих, кабаланып, кесәләрен капшарга тотынды:

– Менә... анда танылган мал врачы... профессор званиесе дә бар икән аның... Мирза исемле. Кафедан ашап-эчеп чыгып килә иде. Справка бирде. – Ул курткасының куен кесәсеннән, калтырана-калтырана, справканы алып Мулланурга сузды. – Менә справка. Атны шунда, Мамадыштан ерак түгел, үләт базында калдырдык. Ул профессор сине белә.

Мулланур справканы йолкып алды.

– Минем үләт базларында йөри торган таныш профессорларым юк. – Справканы укыганда, авыл җитәкчесенең кыяфәте бөтенләй аңлатып булмас төскә керде. – Син үлгән дип язып биргәннәр бит справканы.

– Ни дип?..

Мулланур, үзе дә ышанырга теләмичә, справканы кат-кат укыды:

– Менә укыйм: синең фамилияң, синең исемең...

– Ничек инде? – дип, Салих справканы алмакчы булды, әмма Мулланур бирмәде.

Җәмилә справканы Мулланурдан тартып алып укып чыкты. Хатынның чырае агарды, куллары калтырый башлады.

– Чынлап та шулай килеп чыга. Ат турында сүз юк. Свидетельство о смерти. Синең исем-фамилияң.

Салих әле хәлнең бөтенләй үк мөшкел түгел икәненә барыбер чак кына булса да ышанырга омтылды, гәрчә «ике дөнья – бер морҗа» дип әйтсә дә.

– Минем исем-фамилиям булмый, атның фамилиясе юк бит! – дип аңлатырга тырышты ул.

– Нинди справка алып кайттың син, жулик? – диде Мулланур, кыҗрап.

Җәмилә шундук ире ыстаныннан аваз бирде:

– Нишләп жулик булсын ул!

Мулланур Җәмиләнең кулыннан справканы алды да бармагы белән төртеп укыды:

– Менә кара: Нәҗмиев Салих Габделбәревич. Бу синең иреңме?

– Минеке, – диде тугры татар хатыны.

– Үлде диелгән. Чичлосы бар, подписе, пичәте. Ат турында сүз юк.

Салих кәгазьне үзе дә кат-кат укыды. Шуннан соң ул тагын диванга чалкан ауды.

– Ул профессор исерек иде, ялгыш язган инде, күрәсең.

– Ник соң син аны язгач ук карамадың? – дип кычкырды Мулланур, Салихны ботарлап ташлардай булып.

– Мин анда тәмам хәлсезләндем, укып торырлык чутым юк иде. Ну, син бит ышанасыңдыр – ат үлде, мин түгел!

– Син үлсәң яхшырак булыр иде, – дип тешләрен шыгырдатты авыл җитәкчесе.

Җәмилә шундук каршы килде:

– Алай димә, Мулланур абый. Андый сүз әйтмиләр инде.

Мулланур Салих өстенә төкерекләрен чәчеп кычкырды:

– Син атның үлгәнен исбатла! Ник үлгән соң әле ул? Әллә сатып җибәрдеңме?

– Юк!

– Ат сатарга түгел, бәрәңге сатарга да ояла бит ул, – диде Җәмилә, ирен кызганып. – Әйбер сата торган кеше түгел ул. Бәрәңгене дә үзем сатам бит мин.

– Ничек инде сау-сәламәт ат үлеп китәргә тиеш?! – дип аптырады Мулланур, кулларын як-якка җәеп.

– Милиционер бик шөкәтсез кеше иде, ат шуңардан нык курыкты да, йөрәге ярылды бугай. Андый ямьсез кеше күргән хайванмыни ул.

– Синең үзеңне бәреп үтереп, күкрәгеңә шушы справканы куеп калдырасы бар!

Җәмилә ачыргаланып авыл җитәкчесе каршына басты:

– Туктале, Мулланур абый. Салих тегенди-мондый кеше түгел, син аны әллә нинди җинаятьләрдә гаепләргә ашыкма. Теге мал врачын барып тапсын. Ул профессор бераз салмыш булган, ди, шул сәбәпле справканы дөрес язмаган.

Мулланур авызын кыйшайтты:

– Әйе, профессорларның аек көннәре юк инде аларның. Хәзер ничек барсын да, ничек тапсын ул аны? – Ул, нәфрәтләнеп, Салихка таба иелде. – Тагын ат биримме?

– Юк, юк, кирәк түгел! – дип кулларын селтәде Салих. – Кирәк түгел!

– Мин әле бу арада сөенеп йөргән идем – ат караучы Вахит абый төш күргән: имеш, утарда бер ат артык икән. Имештер, бөтенебез җыелып аны ачуланабыз икән – нишләп лишний ат хасил булды конюшняда, дип. Ә ул, имеш, акланырга тырыша, тик ничек акланырга белми. Аптырагач, кычкыра: артык ат булганга сөенергә генә кирәк бит, аңгыралар, ди. Мин инде аның төшен яхшыга юрап йөри идем. Тфү! Бар икән әле күрәселәр!

– Салихның хәлен дә аңла инде, Мулланур абый, – дип өзгәләнде бичара хатын.

– Менә нәрсә. Бар, ат үлгәнгә чын справка ясатып, атның диагнозын яздырып, минем өстәлемә алып кайтып куй, – дип боерды Мулланур.

Җәмиләгә җан керде.

– Ярар, ярар. Тыңла, Салих, – диде ул, күзләрендә өмет очкыннары уйнатып. – Ник бер сүз дә әйтмисең? Намусың чиста булгач, ник куркырга!

Салих башын стена ягына борды:

– Ярар.

Мулланур, тешләрен шыгырдатып:

– Баян! Казан! Спонсор! – дип мөгрәде. – Тфү! Культураны алга җибәрүче, сволочь! Бәреп үтереп, кабереӊ өстенә таш урынына нимес баяны куясы бар синең, деятель культуры, хайван!

Моннан да тәэсирлерәк әйтү мөмкин түгел икәнне чамалап, авыл җитәкчесе завклубның кайгылы йортыннан чыгып китәргә ашыкты.

Өйдә кабер тынлыгы урнашты. Әйтерсең лә справканы дөрес язып биргәннәр.

– Бар, ятма! – диде Җәмилә.

– Кая барыйм?

– Теге мал врачын тап.

– Җәяү ничек барып җитим мин анда!

Җәмиләнең ияге дерелди башлады.

– Мин сиңа акча бирәм, – диде ул, тамак төбендәге төенен йота алмыйча. – Теге бәрәңге саткан акчаны. Автобуслык кына бирәм түлке. – Аның хәсрәтле бите буйлап күз яше тәгәрәде.

Салих торып утырды.

– Автобуска акча бирәсеңмени?

– Бирәм инде, бирәм.

Салих торып әрле-бирле йөрергә тотынды.

– Рәхмәт, хатын! – диде ул, хатынының миһербанлылыгыннан үзенең дә күңеле тулып. – Изге кеше син.

– Ярар, ярар, – диде Җәмилә, иренең төчелеген бераз өнәмичә. – Хәлем начарланып китте әле үземнең дә.

Ул, ыңгыраша-ыңгыраша, иреннән бушаган диванга барып ятты.
Салих хатыны янына атылып килде:

– Кай төшең авырта, хатын?

– Диприссия, – дип пышылдады Җәмилә. Аның битен инде күз яшьләре чылатып бетергән иде. Кирәгеннән артык дымнан йөзе хәтта бүртебрәк киткән иде.

– Тагын ниләр күрергә язган икән?! – дип куйды Салих, чарасызлыктан тәмам иңсәеп.

– Чыннан да, чукындың бит шул баян дип!

– Карчыгым, бәгырем! Кичер! – диде Салих җан ачысы белән.

* * *

Вакыт бәхетле кеше өчен дә, хәсрәтлесе өчен дә барыбер үтә икән ул. Шактый вакыт узды. Шунысы гына сәер – клубтан баян югалгач та авыл җир йөзеннән югалмады, ат юкка чыккач та Җир шары урталай ярылмады, хәтта Салих Казан тарафларына олагып гаип булгач та дөнья ахырзаманга аяк басмады.

Җәмилә таушала төшкән хатны кат-кат укыды, гәрчә инде ул аны яттан белсә дә. Һәрбер җөмләдә аңлаешлы фикердән тыш тагын ниндидер яшертен мәгънә табарга тырышты. Яхшы хәбәр алып килмәгән бу кәгазьдән арыну да, котылу да мөмкин түгел иде.

Аптырагач, телевизорны кабызды. Берәр милиция сводкасында, криминаль хәбәрләр арасында Салихны телгә алмасလармы? Могҗизалы рәвештә сурәте чагылмасмы, исеме ишетелмәсме?

Телевизордан исә хатлар буенча концерт җиффәрәләр иде. Алып баручы төртелә-төртелә хат укыды:

– Безгә Тизәкле авылыннан Сәүбән абый яза. Тизәкледән. Районын әйтмәгән. «Менә хәзер бездә җыр багышланмаган шәһәр калмады, – дип яза ул. – Инде авылларның да бөтенесенә диярлек җыр багышлап яздылар. Нишләп хәзер авылның урамнарына, чатларына яки тыкрыкларына багышлап җыр язмаска?! Мәсәлән, мин яши торган урам «Габбас тыкрыгы» дип атала. Мондагы табигатьнең матурлыгын күрсәгез иде сез! Эстрадага килгәндә, инде бакча артында җыр багышланмаган чәчәкләр, үләннәр калмагандыр, мөгаен. Ә менә безнең тыкрыкта әллә нинди сез күрмәгән үләннәр үсә. Композиторларны, шагыйрьләрне безгә чакырып тыкрыкны күрсәтеп булмас микән?» – дип тәмамлый Тизәкле авылыннан Габбас абый үзенең хатын. Бик шәп идея. Димәк, эстрадабызда әле иҗатка офыклар тагы да киңәя.

Хатны укыганнан соң, кыска итәкле, сап-сары чәчле тыңкыш, сакау бер кыз, боргаланып-сыргаланып, имиләрен дыр-дыр китереп, сөю турында җырларга тотынды. Җәмилә телевизорны сүндереп инде әллә ничәнче кат хатны укырга кереште.

Мулланурның кергәнен ул сизми калды, әмма аны күргәч аз гына да сискәнмәде. Газиз ире әйтмешли, куркудан узган иде

инде ул. Аңа инде, халык авызы һәм шул ук газиз иренең теле белән әйткәндә, ике дөнҗа – бер морҗа иде.

– Киткәненә ничә көн булды? – дип сорады Мулланур, Җәмиләгә карамаска тырышып.

– Унике көн, – диде Җәмилә, шулай ук авыл җитәкчесенең күз карашын очратырга базмыйча.

– Почтада сиңа хат килгәнне әйттеләр. Шуңа кердем.

– Килде, – дип ыңгырашты нужа өчен туган татар хатыны.

– Берәр бәла-казага юлыкканмы әллә тагын?

Җәмилә бәгырен ертып әйтеп салды:

– Теге мал врачы үзе дә үлгән бит.

– Справка язып биргән профессормы?

– Әйе. Мә, укы.

Мулланур Җәмиләнең кулыннан хатны алып үзенә әһәмиятле урыннарын кычкырып, калган юлларны фәкать күз йөртеп, мөгрәп кенә укып чыкты:

– «Исәнме, Җәмилә! М-м-м-м... Эзләдем-эзләдем... М-м-м-м... Ул мал врачы шушы арада үзе үлгән. Кинәт үлеп киткән. Берәр чире булгандыр инде. Хәзер нишләргә дә белмим. Казанда Идел буе районының базарында шабашка эшләп, бераз ипи-чәйлек акча эшләдем. Хәзер мал врачы үлгәнлеккә дә справка кирәк бит инде. Алайса, Мулланур ышанмаячак. Классташларыбыз Локман белән Гөлнурларда кундым ике кич. Базарда очраштык. Күп итеп сәлам әйттеләр сиңа. Локман теге врачның үлгәнлегенә справка алырга ярдәм итәр дип ышанам. Мин хәзер авылга кайтырга да куркам инде. Мулланурны ул врач беләм дигән иде. Исеме Мирза аның. Син, Җәмилә, Мулланурдан сора әле, аның кайда туганын белми микән? Гөлнурлар адресы буенча миңа язып җибәр. Мин әлегә аларда. Сау булып тор, җанкисәгем. Мин бик сагындым сине. Кайчан кайтырмын – белмим. Сау бул! Синең Салихың».

– Менә шундый хәлләр, – дип авыр сулап куйды Җәмилә.

– Локманы кем тагын? – диде Мулланур, хатны өстәлгә куеп.

Бөтенләй көтмәгәндә Җәмиләнең сагышлы йөзендә елмаю сыман яктылык урын алды.

– Безнең классташлар, – диде ул, кинәт хатирәләренә бирелеп. – Без бергә укыдык. Гөлнур, мин, Салих, Локман. Локман Гөлнурга өйләнде, Салих – миңа.

– Локманга чыгасың калган.

– Ник?

– Тормышың тынычрак булыр иде, бәлки.

– Теге мал врачының исеме Мирза, ди. Сине белә икән ул. Сез танышлармы әллә?

– Белмим мин бернинди Мирзаны, – дип кырт кисте Мулланур.

– Ул мал врачының исән чагында кайда яшәгәнен белергә кирәк бит.

Мулланур, ишек катына җиткәч, борылмыйча гына:

– Хәзер үлгән кешенекен түгел, исән кешенең кайда яшәгәнен дә билгеләве авыр! – диде.

Мулланур чыгып киткәч, Җәмилә: «И Салих, Салих!» – дип кычкырып елап җибәрде. Аның илаулавына йортка сарыла-сарыла искән җил улавы кушылды. Әле Җәмилә тынычлангач та җилнең электр чыбыкларында бәгырьне телгәли торган көй чыгарып уйнаганы ишетелеп торды.

* * *

Казан каласы һаман шул элекке урынында – Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында кайный иде.

Салихның монда килүе киләчәктә тарих битләрендә урын алырмы-юкмы, әйтүе кыен, хәлбуки бу калада башына төшкән михнәтләр тәэсирендә атсыз баянчы фәкыйребез, мөгаен, хәтта инде вафат булгач та гүр кочагында бер атна-ун көн чамасы калтыранып-калтыранып алырдыр.

Локманнар фатирында кичке аш вакыты җитте. Локман, аның хатыны Гөлнур һәм Салих бәрәңге шулпасы ашап утырганда, кызлары Чулпан көзге каршында мыш-мыш килеп бизәнде. Ул Салихның Алабугада укучы кызы Миләүшә белән бер яшьтә, әмма бөтенләй башка төрле холыклы, икенче төрле кыяфәтле иде.

Телевизордан хатлар буенча төзелгән концерт сыман нәрсә бара иде. Алып баручының тавышыннан да, кыяфәтеннән дә нинди җенесле икәнен чамалау мөмкин түгел иде. Ул чираттагы хатны укыды:

– Зәй шәһәреннән безгә бала караучы Хәнифә түтәй яза. «Карт җырчылар күп чыга, яшьрәкләрне җырлатыгыз, – дип яза ул безгә. – Мөмкинлектән файдаланып, Казанда яшәп Вьетнам базарында төрек курткалары сатучы кызым Гөлфидәгә, шул ук Казанда яшәп Прибалтика аша Польшадан герман машиналары алып кайтучы киявебез Габделбәргә сәламемне җиткерегез. Уллары Айрат инде зур булып үсте. Калдырып киткәннәренә дүрт ел бит инде. Шушы җыр аша баланың тиздән мәктәпкә укырга барырга тиеш икәнлеген берәр ничек хәбәр итү мөмкин булмас микән? Бәлки, онытканнардыр».

– Казан ошыймы соң? – дип кызыксынды Локман, телевизордан сүзләре аңлашылмый торган чирмеш аһәңле җырны керфекләрен буяган, битен чамадан тыш пудралаган кыска буйлы сары чәчле бер егет борын аша шыңшый башлагач.

– Минем бит Казанның ниндилегендә хәбәрем юк, – дип җавап бирде Салих. – Баш каткан минем. Казан бик тынгысыз, шаушулы кала. Ничек яшисездер монда.

Локман авыр сулап куйды:

– Кеше теләсә кайсы мохиткә ияләшә. Кеше үзенең халәтенә дә күнегә, тора-бара тәмам күнә.

– Кызым, чәй куй әле, – диде Гөлнур.

Чулпан, керфеген буйый-буйый:

– Поставь уж сама! – дип сыкрады.

Гөлнур чәй куярга кузгалгач, Салих Локманга:

– Бөтен ышаныч синдә, – диде.

– Мин тырышып карармын. Ләкин аңламыйм: ул врач үлгән икән, аның үлүе турында справка нигә кирәк?! Бит ул справканы язганнан ат табылмаячак.

– Ичмаса, Мулланурның нәфрәте бераз кимер иде.

– Минемчә, турыдан-туры спонсорлар эзләргә кирәк – атка да, баянга да акча җитәрлек булсын. Әлбәттә, теге врачның яшәгән җирен, кайда үлгәнлеген эзләрбез. Әгәренки кеше үлгән икән инде, аның бу дөньяда юклыгын гына ничек тә исбатлый алырбыз, шәт.

– И-и, Җәмилә ут йотып ятадыр инде анда, – дип сүзгә кушылды Гөлнур, кухня тарафыннан килеп.

Салихның авыз тәме югалды.

– Әле кызым белми, – диде ул, тамак төбендә төен тоеп.

Чулпан тыңкыш тавышы белән тыгылды:

– Часто кайтамы Миләүшә?

– Каникул саен.

– Ой, я тоже в деревню хочу, – дип ыңгырашып алды кыз, иреннәрен турсайтып.

Гөлнур авылдашына кашларын җыерып карады.

– Ник соң сез кызыгызны да культура буенча укырга керттегез, аңламыйм?

– Үзе теләп керде.

Локман, хатынына ачулы караш ташлап:

– Нинди сорау инде бу, – дип җикерде. – «Ник керттегез?!» Анда синең ни эшең бар?! Нәрсә, мәдәният хезмәткәре булса начармыни?!

Гөлнур, күзләрен әйләндереп, өстәл яныннан читкәрәк китте:

– Болай гына әйтүем. Менә бит, Салих та культпросветучилище тәмамлаган кеше... Ничек бимазалана.

– Монда культпросветучилищеның бернинди катнашы юк! – диде Локман, кашыгын тәлинкәгә шакылдатып. – Син укытучы башың белән әллә ничек фикерли башладың соңгы вакытта. Менә мин журналист булып йөргән булам, гәҗиттә эшлим, имеш! Нәрсә, бимазаланмыйбыз мәллә?

Гөлнур, усал елмаеп, иренә бармак төртте:

– Менә-менә, гәҗиттә эшләвеңнең дә фәтвасы юклыкны, ниһаять, картаеп килгән көнеңдә аңладың.

– Бүгенге көндә кыйммәтләр үзгәрде, җәмгыятькә кирәкле чын профессияләрнең абруе югалды дип әйтергә телим мин, – диде Локман, ир белән хатынның бәхәсеннән бераз куырылып калган авылдашына карап.

Көтмәгәндә Чулпан әңгәмәгә тыгылды:

– Ну ладно, пап, че ты опять кричишь?

– Татарча сөйләш! – дип җикерде Локман.

– Зинһар, кызма, – диде Гөлнур, фатир температурасының күтәрелә башлавын чамалап.

Локман битен салфетка белән сыпырды.

– Әнә, педагог булсаң, кызыңны сөйләшергә өйрәт!
– Синең дә кызың бит ул, – дип каршы әйтте хатын.
– Финансово-экономическийга керттең, теләге булмаган килеш, менә күрербез, кайда эшләр дә кем булыр! Бимазаланмасмы?!
Салихның күңелендәге давылга Казан фатирындагы буран өстәлде.
– Мин китим, – диде ул.
Локман классташына да тавышын күтәрде:
– Утыр, кая китәсең?! Син без әйткәләшкәнгә карама. Без гел шулай әрләшәбез.
– Шулкадәре кырыс булмыйлар инде, – диде Гөлнур, иренә үпкәләп.
Локман тынычланды.
– Яши-яши шундыйландым мин.
– Потому что беркайчан беркая ял итәргә барганыбыз юк, – диде Чулпан, түгәрәк чыраена алсу пудра кундырып. – Поэтому нервныйлар барыгыз да.
Локман башта ни әйтергә белми торды. Кызына шактый вакыт карап утыргач:
– Арыдыңмыни, ял итәргә! – дип мыскыллы елмайды. – Нинди сүз таптылар. «Отдыхать», «ял итәргә». Эшләп арыганнармыни! Нәрсә эшләделәр дә, ни кырдылар әле ял итәрлек? Шул булганын җимереп арысалар гына инде. Кая карама, кемне генә очратма, фәлән җиргә фәлән көнгә ялга бардык дигәннәрен ишетәсең. Дәүләт таркалып барганда, тегендә-монда ял итәргә йөриләр. Арыганнар!
– Авылга кайтып килик, ичмаса, – диде Гөлнур, иренең авыл турында сөйләшкәндә күңеле йомшарганны белеп.
– Авылга кайту ярый, – дип татлы елмайды Локман. – Һавасы чиста. Менә шул ялга йөрүче сорыкортларданерактарак булып тору да үзе ял бит.
– Авыл да бик тәртипсез шул хәзер, – диде Салих сагышлы тавыш белән. – Яшьләр бик әшәке. Һавасы да тирә-яктагы заводлар аркасында тынчуланды. Авылда да кеше бозылды, төнлә чыгарга куркыныч.
– Күтәрегез культураны, сез бит культура работниклары, – диде Гөлнур чәнчүле тавыш белән.
Локман хатынын урынына утыртты:
– Сез укытучылар тәрбияләгән шакалларның культурасын ничек күтәрсеннәр алар.
Шунда тагын Чулпан чәчрәп чыкты:
– Ой, ну нәрсә сез спорите? Сез бер-берегезне ачуланып утырасыз, ә жизнь по-своему идет. Как будто сез зарланганнан берәр нәрсә яхшы якка үзгәрә. Вас послушаешь, прямо не знаешь, то ли плакать, то ли смеяться.
Локман чыраен сытты:
– Кызым, безелдәмә әле. Тавышың анаңныкына охшаган, тешкә сылана торган тавыш.

– Үзеңнеке матур инде, – диде Гөлнур, балаларча үпкәләп. – Чәй кайнады, ахрысы, бар әле, кызым, алып кил.

– Ну, мам, сходи уж сама, – дип шыңшыды кыз.

– Хезмәт хакың гәҗиттә болай начар түгелме? – дип кызыксынды Салих.

– Мин үзем канәгать. Начар димәс идем. Ләкин мин үзем эшләгән эшемнән канәгать түгел. Әйтәсе фикеремне кычкырып әйтә алмагач, нәрсәгә кирәк ул минем профессиям. Мин журналист дип саный алмыйм үземне. Гомумән, бездә журналистика юк. Журналистика булсын өчен хөрлек кирәк, күңел хөрлеге. Әле мин матбугатта көчле, таң калырлык фикерле бер генә мәкалә дә укыганым юк. Менә бүген бөтен гәҗит-журналларны ябып куй – аңа карап бернәрсә үзгәрмәячәк, тормыш, Чулпан әйтмешли, үз көенә барачак та барачак. Әй, кызым, кайвакыт акыллы фикерләр әйтеп куясың. Маладис, ул ягың белән анаңа охшамагансың.

Чулпан әтисенә килеп елышты, бераз назланып алганнан соң, кызу-кызу атлап, эшем кешесе сыман бүлмә буйлап нидер эзләргә тотынды.

Салих рәхмәт әйтеп табын янынннан кузгалды, тәрәзәдән беркавым тышка карап торганнан соң инде әллә ничәнче тапкыр:

– Ничек яшисез бу Казанда?! – дип куйды. – Бигрәк тынгысыз бит монда.

– Яшәү беркайда да рәхәт түгел, – диде Локман, тирән сулап.

– Анысы шулай, – дип классташының сүзен җөпләде Салих.

Локман сөйләшүдән тәм таба башлады.

– Беләсеңме, нәрсәсе авыр тормышның безнең өчен? – диде ул, Салих янына барып янәшә баскач. – Безгә яшәү шартларын тагалар. Менә синең белән миңа мичкә тәгәрәткән бәрәңге белән ипи дә җитәр иде, бер чалбар, бер күлмәк җитәр иде, шулаймы? Ләкин халыкның күбесе синең өс киемеңә, кыяфәтеңә, кесәң калынлыгына игътибар итә. Барысына төкереп ыштансыз яшәргә дә булыр иде, ләкин гаилә бар, балалар бар, телисеңме-юкмы, кешеләрнең фикереннән, аларның мөгамәләсеннән беркая да китеп булмый.

– Шулай, – дип килеште Салих.

– Кая гына килеп кермә, хәерче икәнлегеңне сизәләр дә сине кешегә санамыйлар. Һәм син менә шул килеш берәр эш майтарып кара. Сине ихтирам итмәсәләр, бернинди эш кыра алмыйсың. Кеше фикереннән азат булу мөмкин түгел, Салих. Үзең үлгән суратта дә үзеңнән соң синең хакта фикер кала әле! Гомумән, кеше дөньяга туу белән үк башкалар уйлап чыгарган кануннар дөньясына, аңа кадәр туган кешеләр уйлап чыгарган яшәү шартларына күнегергә, шул мохиттә яшәргә мәҗбүр. Шуңа күрә җаваплылык һәрбер кешедә булырга тиеш. Теге яки бу кешене битәрләгәнче иң элек шуны онытмаска кирәк – ул кеше башка кешеләр дөньясында яшәргә мәҗбүр.

Чулпан әңгәмәдә катнашмый кала алмады.

– Юк, индивидуальность өчен көрәшергә кирәк, – дигән фикерне әйтеп салды.

Локман авызын кыйшайтып көлемсерәде:

– Менә, яшьләрдән еш ишетәм шул сүзне. Нинди индивидуальность? Сезнең бит бер үк сүзләр, бер үк кызыксынулар. Нәрсәң индивидульно соң синең, мәсәлән? Борынны яннан тишеп, алка тагып башкалардан аерылып буламы? Кашны йолкып була, ертык чалбар киеп була, ләкин бу индивидуальность түгел, кызым. Сез барыгыз да бер көтүдә йөрисез, ә үзегез индивидуальность, ирек дигән буласыз. Бер буын да әле өлкәннәргә көрәш игълан итеп әллә кая ерак киталмады. Чөнки һәр буын үзе картая бара һәм тора-бара хәтта тиздән бу дөньядан китәсен чамалый башлый. Күк астында йөргән бер бөҗәк икәнен яшь кеше аңламый бит ул. Җәмгыятьтән беркая китә алмыйсың. Ниндидер сыйфатларың, яшәү рәвешең үзгә булуы ихтимал, әмма ләкин барыбер бер үк кануннар буенча яши кешеләр – бер үк ризык ашыйлар, бер үк һава сулыйлар, бер үк ихтыяҗларны канәгатьләндерәләр. Бүгенге бардакта теләсә кем үзен индивидуальность дип игълан итсен, ләкин аңа карап бу балаганнан котыла алмый ул.

– Элегрәк барыбер яшьләрдә әхлак кануннары азмы-күпме яши иде әле, – диде Салих.

Чәйнек күтәреп килгән уңайдан Гөлнурның да әйтер сүзе бар иде һәм ул аны әйтте:

– Менә бу перестройкадан башланды бөтен әшәкелек.

– Юк, – дип каршы килде ире. – Нишләп, алайса, коммунистлар вакытында алай нык тәрбияләгәч, берничә ел эчендә вәхшилек белән фәхешлеккә кереп баттык? Ай-яй әйбәт тәрбияләнгән икән алайса халык социализм чорында. Сәбәбе дә, нәтиҗәсе дә үзебездә. Көнбатыш та гаепле түгел. Үзебездән эзлик бөтенесен дә. Җинаятьче дә үзебездә, аны хөкем итүче дә. Төзүчесе дә янәшә, җимерүчесе дә. Бөтенесе үзебездә яши!

– Культура түбән дәрәҗәдә инде бездә, сүз дә юк, – диде клуб мөдире, җәмгыятьнең культурасызлыгында үзенең дә гаебен сизеп.

Локман Салихка карап көлеп җибәрде:

– Мин сине шушы беркатлылыгың өчен хөрмәт итәм, Салих туган. Нәрсә соң ул культура? Ул бит яшәү укладының бер чагылышы. Башта нигез кирәк, йортың төзек, тамагың тук булырга тиеш, аннары гына кеше җырлый-бии башлый. Борынгы кешеләр иң элек корал әзерләгәннәр, ауга барганнар, мамонтны тунап, ит пешереп, учак янында тамак туйдырганнар. Шуннан соң гына сәнгать башланган – таш куышның стеналарына рәсемнәр ясый башлаганнар. Бит беренче рәсемнәрдә мамонтларга һөҗүм итүләрен ясаганнар. Бернинди Мәдәният министрлыклары, культура бүлекләре юк әле ул вакытта. Йокларга җылы урыны, ашарга ризыгы булгач кына мәдәният барлыкка килә ала. Яшәү рәвешебез нинди – культурабыз шундый! Үзебез нинди – культурабыз шундый!

– Вот видишь, значит, бүгенге заманда кеше күбрәк акча эшләргә омтылырга тиеш – тамагы туйсын өчен, и вообще, чтобы хорошо жить, – дип чәрелдәде Чулпан, һаман күзгә каршында бөтерелеп. – Значит, культура турында потом надо думать.

– Акчаны аны эшләп табарга кирәк, – диде атасы. – Бүгенге ысуллар белән түгел. Ничек табасыз акчаны – менә культурагыз да шулай. Милли мәдәниятебез дә бар безнең! Менә Салих – аның вәкиле! Милли культураны сакларга кирәк. Аны саклар өчен татарның яшәү укладын сакларга кирәк. Аны бүген сәясәтсез саклау мөмкин түгел. Барыбер сәясәткә килеп терәлә, зараза! Әйдә, чәеңне эч, Салих. Минем хатын белән кызым болай надан кешеләр түгел инде дә, тик шулай да хатын-кыз сүзе хатын-кыз сүзе инде ул, игътибар итмик.

Салих тирән сулап куйды:

– Иртәгә көнне эш белешүгә багышлыйм, Алла боерса.

Локман уйга калды:

– Нинди эш табарсың икән инде син? Казанда эш күп, ләкин синең һөнәрең буенча урыннар буш түгелдер шул.

– Барыбер эзләргә кирәк, – диде Салих. – Син теге врачның кайда үлгәнен белеш инде, яме. Ул бик танылган кеше булган. Путин белән дә таныштлар икән алар. Былтыргы Сабантуйда катыктан акча эзләргә тәкъдим иткән ул аңа.

– Алайса, акыллы кеше булмаган ул, – диде Локман. – Ул катык белән бөтен татарны мыскыл иттеләр. Кемдер башын катыкка тыгып үзен мыскыл иткән икән – бу аның шәхси эше. Ә менә «Катык чөмереп акча эзләү – татарның милли уены» дип үзәк телевидениедән әйтүләре мине бик кимсетте. Татарның милли уены булалмый ул. Ходай кешегә башны акыллы фикерләр, бөек эшләр өчен биргән. Аны катыкка тыгарга ярамый!

* * *

Салих беркөнне иртәнге якта, кич белән кайтырмын дип, Локманнардан чыгып китте. Ләкин шул көнне кич белән дә, икенче көнне дә, алга таба да авылдашларында ул бүтән күренмәде.

Салих юкка чыкты. Локман милициягә, моргка, хастаханәләргә шалтыратып белешеп карады, Казанның район базарларында кыймылдаучы бомжлар арасыннан эзләде, әмма авылдашының эзенә һич кенә дә төшә алмады.

Шактый вакыт узды. Шул арада дөньялыкта күпме баян урлангандыр да, күпме кеше харап булгандыр, күпме ат югалгандыр да, күпме мал врачы җан тәслим кылгандыр. Нинди клуб мөдире генә түгел, әллә кемнәр, әллә нәрсәләр дә гаип була. Ахыр чикләре кайларда икәне дә мәгълүм булмаган җиһанда бер кеше югалганнан гына зыян юктыр шикелле. Вәләкин безнең Салихыбызда сирәк кешегә хас җан газабы бар. Һәркемгә дә бирелмәгәч,

димәк, газап та үзенә күрә «байлык». Дөнья буйлап баян эзләп йөрүче каһарманыбызны һич кенә дә югалтасым килми, чөнки аның газабы ул аныкы гына түгел, бәлки барыбызга да кагылырга тиештер.

...Дөнья мәж килеп XXI гасырның беренче елын яшәп яткан-да, Казанның нәкъ үзәгендә Салих гармунда уйнап утыра иде. Йончыган кыяфәтле сәнгать колы, кара күзлек киеп, таушалып беткән гармунны каера-каера тартып, бер көйдән икенчесенә күчә-күчә, Казан үзәген моңга батырырга маташты. Күктә бөтен инсаният дөньясын бертигез хокукта күрүче кояш балкыды, ә Салихның табаны ашалып беткән ике ботинкасы арасындагы калай савытта әлеге дә баягы кояш нурыннан төс алып вак тиеннәр ялтырап ята иде.

Җир йөзенең Казан дип аталган төбәге буйлап бара торгач, гәҗиттә эшләп иске гәҗит сыман саргайган чыраена акыллылык чыгарырга тырышып, Локман, бер сәбәпсез, бер ниятсез, бер максатсыз, Куйбышев мәйданына килеп чыкты. Казан үзәгендәге чүпчарга, пычракка, исерек яшүсмерләргә, һәр почмакка, һәр диварга иңгән мәңгелек төкселеккә Локман күптән ияләшкән иде инде. Тротуарлардагы какырыкларга ул элегрәк җирәнеп, нәфрәтләнеп караса, хәзер исә ул аларны бөтенләй күрми иде. Сыраханәләр, рюмочнаялар янындагы сидек исе дә аны тетрәндерми башлады. Гомер буе гәҗиттә мәкаләләр язып та җиңеп булмады бу пычракны, бу әшәкелекне. Ул үзенең чынбарлык алдында каушавын тойды, тирә-якны җиңәрлек куәткә ия түгеллеген аңлады. Кинәт кенә тирәнрәк уйлап багып үзен дә тротуарда сытылып ятучы сары тәмәке төпчегенә тиңләгәч, аның кыяфәтендәге ясалма тәккәберлектән җилләр исте, муенында галстук булса да, аңарда бернинди кукраю калмады.

Нинди генә мәкалә язсам да, нинди генә хәбәр бирсәм дә, гәҗитне нинди генә язмалар белән бизәсәм дә, ошбу пычраклыкны җиңү мөмкин түгел ләбаса дип уйлады ул. Күңелләргә чисталыкны ничек кертмәк кирәк, бит тирә-ягыбызда, күңелләребездә тәртип юклыктан туа шушындый бозыклык. Ачынып язган бер хикәясен тәкъдим итеп, Казандагы барлык редакцияләрне йөреп чыкты ул. Әмма бер гәҗит тә, бер журнал да аны бастырырга теләмәде. Дөресен әйткәндә, моңа аның ачуы килмәде, үпкәләмәде, хәтере калмады. Үзе гәҗит хезмәткәре буларак ул аңлый – мондый язмаларны бездә бирергә ярамый. Ялган, коррупция, кодалык, гаиләлек, караклык, ришвәтчелек, имансызлык чәчәк аткан ил-көндә ничек мондый язманы бастырмак кирәк?!

Гомумән, чарасызлыктан, хәлсезлектән, ярдәмсезлектән күңеле боек аның. Булмый икән бездән! Булдыра алмыйбыз!

Булмый бездән!

Булдыра алмыйбыз!

* * *

Локманның «Саташулы йокы» исемле беркайчан беркайда басылмаган хикәясе.

Яшәгән, ди, Әвеш Тәвешевич атлы бер чиновник.

Үзеннән түбәнрәкләр ул яшәгәнгә яшиләр дип, ә үзе исә өстәгеләр яшәгәнгә яшим дип инанган, ди.

Беркөнне Әвеш Тәвешевич бик озын, куркыныч төш күргән. Имеш, иң өстә утыручы түрә атлар ярата икән. Моны белгәч, чиновник атларга шулхәтле гашыйк булган ки, хәтта хатыны бераз көнләшә дә башлаган, имеш. Ул кабинетында, дачасында, өендә ат сурәтле рәсемнәр элеп кенә калмаган, үзе дә ат асрый башлаган.

Тик менә Әвеш Тәвешевичның коллегасы, күптәнге конкуренты, аяк чалучысы Мүхлиев ике ат асрый икән. Имештер, моның өчен аның абруе чак кына югарырак күтәрелгән сыманрак тоела икән.

Шушы урында төш тәмамланып, уяныплар гына китәсе дә бит! Юк шул. Күрәчәк диген...

Йокы дәвам иткән, төш тә өзелмәгән. Заман үзгәребрәк киткән, имеш. Дөньялыкның терәкләре бераз чалышлык җибәргән дә, бөтенләй уйламаганда-көтмәгәндә, иң өстәге түрә булып ишәк яратучы кеше килгән, ди. Урта Азия тарафларында туган кеше булгандыр, күрәсең. Төш күреп ятучы Әвеш Тәвешевич тиз арада ишәккә гашыйк булган, имеш. Ат сурәтләрен ишәкнекенә алыштырып, атны суеп казылык ясатканнан соң, Үзбәкстаннан, күп акча түләтеп, ишәк кайтарткан, ди. Ләкин бичара ишәк, күрәсең, чиновниклардан аермалы буларак, ватан җанлы булгандыр, күп тә үтми, Ташкентны сагынып үлгән, имеш.

Ә менә Мүхлиев Төркиядән кайтарткан икән ишәкне. Аның ишәге төрекләр сыман чырыш нәрсә булып чыккан, ул Татарстанның климатына иләшкән, имеш.

Шушындый төш керсен әле!

Йокы дәвам иткән. Саташуның да азагы күренмәгән.

Иң югарыдагы урынга хоккей яратучы түрә менеп утыргач, Әвеш Тәвешевич боргаланып ала, өстендәге юрганын тибеп җибәрә. Имеш, Мүхлиев конькида да шәп йөри, ди, кәшәкәсен дә ресторанда кулланыла торган кашык сыман оста тота, ди. Әвеш Тәвешевич тә конькида йөрергә, кәшәкә тотарга өйрәнергә керешә. Инде боз өстендә яңа туган бозау сыман таеп, мүкәләп йөрми башлагач кына, инде кәшәкә белән кизәнеп шайбага сугарга өйрәнгәч кенә, илдә үзгәрешләр булып, патшалыкка суда йөзәргә яратучы, йөзү буенча спорт мастеры килә, имеш. Аңа ияреп барлык чиновниклар суда йөзәргә тотына, безнең Әвешебез генә, тумыштан судан курку сәбәпле, йөзәргә өйрәнә алмый. Мүхлиев исә суда батмый торган нәрсә булып чыкты – тормышта да чуртан сыман йөзеп яши, суны да үз стихиясе итә.

Төшнең иң куркыныч урыны шушыдыр дип уйласагыз, ялгы-

шасыз. Хаким булып яңа кеше килә дигән хәбәр ишетелгәч, йөзә белмәүче Әвеш Тәвешевичнең эченә җылы йөгерә. Ләкин саташуның куәте кинәт көчәя, чөнки влачка парашюттан сикерергә яратучы кеше килә. Балконга чыкканда да башы әйләнә торган чиновнигыбыз хәтта төшендә дә бу дөньяга ник туганына үкенә башлый. Башкалар сикерә дип, ул да парашют киеп сикерә, аның парашюты ачылмый, ул кычкыра, бәргәләнә. Мүхлиевнең парашюты ачылып, чиксез киңлек кочагында елмаеп тын гына газиз җиргә таба төшеп баруын күргәч, саташуның нинди газаплы икәне аңлашыладыр.

Төш дәвам иткән. Кинәт йокы нindидер якты, балкышлы, алкышлы бәйрәмгә таба юл ала. Төшнең бу өлешендә иң югарыдагы түрә булып бәйрәмнәр, тамашалар яратучы кеше килә. Инде төш татлыланырга тиеш бит югыйсә. Юк шул! Имеш, чиновнигыбызны бер тамашага да, бер бәйрәмгә дә, бер церемониягә дә чакырмыйлар икән. Бу хурлыкны, бу позорны күтәргәнче, суда батып үләселәр калган яки парашют ачылмыйча җиргә төшеп чәчрәп үләсе калган. Ә бит Мүхлиев бөтен банкетларда катнаша, әллә нинди комитетларда, коллегияләрдә утыра, әле монда, әле тегендә аның имансыз чырае чагылып тора.

Саташулы йокы дәвам иткән. Ни гаҗәп: иң зур түрә булып халыкны яратучы кеше килә. Әвеш Тәвешевич исә, карьера артыннан йөреп, өстәгеләргә тәлинкә тотып, түбәнсенеп, куркып, кайгырып, ялагайланып, инсаният дөньясыннан аерылган иде инде, ул кешеләрне яратмый, чөнки хәтта үз халкының телен белми, ул аңа чит-ят, халыкны аңлый алмый. Халыкны ул үзе өчен үзенчә генә ярата ала. Мүхлиев тә яратмый кешеләрне, ләкин ул яраткан булып кылана белә, халыкны яратуны шулхәтле оста уйный.

Саташулы йокы дәвам иткән. Үзгәрешләр тагын килгән.

Атларны да, ишәкләрне дә, спортның барлык төрләрен дә, кешеләрне, гомумән, дөньяны яраткан булып кыланучы өр-яңа хаким килгән, имеш.

Саташуның шушы җирендә чиновнигыбыз уяна. Ләкин торырга аның инде хәле булмый. «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртып, аны сырхауханәгә алып китәләр.

Тынычландырып йоклата торган уколлар кадаганнан соң, әлеге дә баягы төш тагын керә.

Имеш, хаким булып кармак белән балык тотарга яратучы кеше килә. Әвеш Тәвешевичнең куанычы хәттин аша, чөнки ул үзе дә малай чактан ук кармакка балык тотарга ярата.

Имеш, хаким күлгә кармак салган, ә аның кыр-кырында тезелешеп чиновниклар, ваграк түрәләр, куштаннар үзләренең кармак таякларын кысып тотып утырганнар. Әвеш Тәвешевичкә дә урын бар икән, имеш. Хакимнән бер-ике кеше аша гына ул үзенә урын җайлап кармагын сала. Аның кырыенда дошманы Мүхлиев утыра, ул чак кына хакимгә якынрак. Калкавычына караганда күбрәк хаким ягына карый. Монда да аңа бәхет елмая – хакимгә дә

якынрак, бер-бер артлы эре-эре балык та эләгеп тора, имеш. Ә безнең Әвешебезнең калкавычы һич кенә дә тибрәлми. Бары тик Мүхлиев чираттагы бәртәсен судан тартып чыгарганда гына, дулкыннар тәэсирендә Әвешнең калкавычы бәкедәге каз бугы сыман чайкалыбрак куя.

Әвеш Тәвешевич салкын тиргә батып уяна. Шундук әле генә күргән төшен башыннан ахырына кадәр хәтер аша уздыра. Коточкыч төш! Иксез-чиксез саташу! Аңа балык эләкми! Мүхлиевкә генә эләгә. Дошманга балык эләгә, аңа – юк! Бу төшне бер генә төрле юрарга мөмкин – эштән алырлар, ахрысы. Һәм никләр уянганына үкенеп куйды ул. Хәер, төштә ни, өндә ни – барыбер шул ук йокы, шул ук төш, шул ук саташу!

Ул кесә телефоныннан эшенә шалтыратты. Аның вазифаларын Мүхлиев башкарганын әйттеләр. Сез борчылмагыз, дәваланыгыз, дигән булдылар.

Ярар, аякка баскач эшемдә, бәлки, калдырырлар дип өметләнде ул. Әлекке эштә калдырмасалар да, шул ук даирәләрдә урын беткәнмени?! Чирләде дип урамга чыгарып ташламаслар әле. Шушы кадәр куркып, карьера ясап, тәлинкә тотып ялагайланганнан соң да читкә тибәрләр микәнни?!

Барысы да иң югарыдагы кешедән торачак. Яңа хакимдә бөтен өмет. Дәваланганнан соң, хәл кергәч, ничек тә аңа ярап булыр әле, осталык та, тәҗрибә дә юк түгел бит инде. Спортның аерым төрләрен яратучы, суда йөзүче, парашюттан сикерүче җитәкчеләр тәмам җелеккә үттеләр. Андыйлар алдында үзеңне күрсәтү авыр шул. Ярарга тырышам дип, булдыра алмаган көе спортсменга әйләнү мөмкин түгел! Монысы гомумән дөньяны ярата, ди, димәк, һәрбер кешегә үз урыны табылыр, интегергә туры килмәс.

Ул тагын эшенә шалтыратты.

– Алло, бу мин әле... – диде ул, йөрәгенең ярсып тибүеннән урталайга ярылырдай булып.

– Яңа хаким инде бүгеннән алып вазифаларына тотынды, – диделәр аңа.

– Ниндирәк кеше икән соң? – дип сорарга йөрәксенде ул.

– Әле билгеле түгел. Болай бик куәтле кешегә охшаган, эш буенча да, тормышта да.

Әвеш Тәвешевич тагын бер соравын ничегрәк әйтергә икән дип икеләнеп торганда, гүя аның ни уйлаганын белгәннәр – телефон трубкасында яңа мәгълүмат яңгырады:

– Спортсмен.

– Спортның нинди төре буенча? – диде чиновник, башы әйләнеп киткәнен тоеп.

– Ун километрлы кросска йөгерергә ярата.

Әвеш Тәвешевичнең кулыннан телефоны төшеп китте, ул караватына чалкан ауды.

Шул кичне ул бу дөньядан китеп барды.

* * *

Гомерләр заяга узып бара микәнни дигән уй баш миеннән вөҗүд буйлап чемердәп төшеп йөрәк турысында калак сөяге астына кадалды. Шулвакытны каяндыр таныш көй, күңелгә якын моң яңгырады. Әмма бу юлысы Локман моңа куанмады, чөнки мондый мохиттә, монда, бүген, шушы мәлдә җанга якын көй урынсыз, хәтта мыскыл итеп яңгыраган сыман кабул ителде.

Көй ишетелгән тарафка ихтыярсыз борылгач, ул баскан урынында катып калды.

– Сыздырасыңмы? – диде Локман, кара күзлекле «телсез» музыкант янына килеп.

Салих, уйнаудан туктап, башын күтәрде. Классташын таныгач, ул шундук телгә килде:

– Булдыра алганча.

– Кая югалдың?

– Югалмадым, менә бит монда утырам.

– Кайчаннан бирле күренмисең! – дип җикерде Локман, үләмәт авылдашына кыжрап. – Без Гөлнур белән әлләниләр уйлап бетердек инде. Әйдә, тор, кеше көлдермә. Киттек, безгә кайтабыз.

– Юк, беркая да кайтмыйм, – дип киреләнде Салих.

Локман тагын як-ягына каранып алды:

– Кеше көлкесенә калдырма үзеңне дә, мине дә!

– Мин болай да адәм көлкесенә калдым инде, – диде Салих, каядыр башкаланың түренә карап. – Мин бит тагын бер фаҗигагә юлыктым.

– Нәрсә булды тагын? – дип котсыз калды Локман.

Салихның ияге дерелди башлады:

– Берәүгә коттедж төзешергә наниматься иткәнием, «әйбәт түләрмен» дигәние.

– Шуннан? – диде Локман, шомраеп.

– Хуҗасы бик бай инде. Авызы тутырук алтын, бармак саен алтын. Гел ун меңлек коньяк кына эчә. Аның ашый торган ризыкларының исемен дә, ни икәнен дә белмим мин. – Салихның ияге генә түгел, чыраеның әллә кай төшләре мыймылдап куйды. – Гаражы өстендәге материалларын аралаганда, ялгыш, машинасы өстенә тимер уголоклар ишеп төшердем.

– Машинасы нинди? – дип кызыксынды Локман.

– «Мирсидис». Шулхәтле бай булгач, машина түбәсе янчелүгә бик борчылмас дип уйлаган идем, – дип дәвам итте урам музыканты.

– Борчылдымы? – диде Локман чәнчүле тавыш белән.

– Шунда, гаражында ук сугып аударды. Күпме ятканмындыр – чамаламыйм. Аңыма килгәч, аның чыраен күрдем дә, «Үтерәм!» дигәнен генә ишеттем. Алай җиңел генә үлеп китеп булмый шул. Биш мең доллар сорый. – Ул кинәт хәлсезләнде, кыяфәтеннән дөньяга һәм шул дөньяда урын табалмаучы үзенә карата битарафлык аңкыды. – Мин инде асылынмакчы идем, рух җитми,

Локман. Инде әллә ничә тапкыр асылынып карадым, булдыра алмыйм.

– Асылыну җиңел булса, үзен бераз ихтирам иткән һәрбер кеше асылыныр иде.

– Мин, Казанга килгәч, үземнең кирәк түгеллегемне генә түгел, кеше түгеллегемне аңладым, – диде Салих, үзе өчен зур ачыш ясап. – Минем өчен Казанга мең ел булса ни дә, ун мең ел тулса ни! Бу дөньядан тиз генә ычкындыра торган берәр дару табалмыйсыңмы?

– Ярар, телеңә салынма! – диде Локман, йодрыгын төйнәп. Бу мизгелдә ул авылдашын үзе бәреп үтерергә әзер иде. – Андый дару синең баяныңнан да кыйммәтрәк монда. – Ул кыршылып беткән гармунга карап торды. – Бу гармунны каян алдың соң син?

– Икенче Горкида берәүгә кирпеч ташышкан идем. Кайгы-хәсрәтләремне сөйләгәч, иске гармунын бирде. Бака телләренең яртысы уйнамый. Шуңа бик сыздырып булмый. Шуңа аз түлиләрдер инде.

Локман Казан шабашнигының алдындагы тиеннәргә карап авызын кыйшайтты:

– Бәлки. Күп җыелдымы соң?

– Ничек җыелсын инде, – дип сукранды Салих, акчаны җыеп чалбар кесәсенә тыкканда. – Бер ун-унбиш сум чамасы гына.

Локман, кашларын уртага җыерып, чутлый башлады:

– Биш мең долларны утызга тапкырласаң... безнең акча белән йөз илле мең чыга. Гармун уйнап көненә унбиш сум җыйсаң... Тәк... ун мең көн уйнарга кирәк... Ничә ел була инде ул?.. Тәк... ун меңне өч йөз алтмыш бишкә бүләбез... Син дә уйла, тик утырма...

– Баш эшләми минем, – диде Салих җиңел генә.

– Тәк... биш... м-м-м... Якынча егерме җиде-утыз ел чамасы ышкыйсың була гармунны. Сиңа хәзер кырык. Теге ун меңлек коньяк эчә торган кеше белән җитмеш яшеңдә расчет ясыйсың. Аннан соң үлеп китсәң дә була.

– Көлмә инде, – дип шыңшыды аяусыз язмышның моңлы колы.

– Мин җитди сөйләшәм, нишләп көлим! – диде Локман, ачуланып. – Бу арада кайда куНдың соң син?

– Кайда туры килә, – диде Салих, башын читкә борып.

– Ник безгә кайтмыйсың?

– Яхшы түгел.

– Менә болай утыру, теләсә кайда кунып йөрү яхшымы? – дип оялтырга тырышты аны Локман. – Әйдә, киттек безгә!

Салих үҗәтләнеп янә гармунын тартырга әзерләнде.

– Юк, мин үз профессиям белән акча эшләп утырам. Барысы өчен дә рәхмәт сиңа.

Локман Салихны җиңеннән тартып торгызмакчы булды.

– Хәзер үз профессияң белән акча эшлим дисәң ачтан үләсең. Тор!

Салих, кискен хәрәкәт белән җиңен ычкындырып:
– Үлү яхшырактыр, бәлки, – дип шыңшыды.
Локман, кыҗрап, ядау музыкантның изүенә ябышты:
– Телеңә салынып утырма, якташ! Кордаш! Классташ!
Салихның авылдашы җилтерәтүенә бирешергә исәбе юк иде. Алар тарткалашырга тотындылар.
– Беркая да бармыйм! – диде Салих, тешләрен шыгырдатып. Шуңа өстәп койты гына сүгенеп тә куйды. Тарткалашу әүмәкләшүгә күчте. Әүмәкләшү инде сугышуга охшый башлады.
– Каерышма, зараза! – диде Локман, ысылдап. – Мине монда күп кеше таный. – Ул, авылдашының якасына ябышкан килеш, як-ягына карап куйды. – Оятка калдырасың, кабих!
Салих бер кулы белән сөекле гармунын кочып, икенчесе белән классташының бугазга ябышуына каршы торды:
– Гармунны ватасың. – Шуннан соң үпкәле тавыш белән өстәп куйды: – Син, журналист башың белән гәҗиттә эшләгән килеш, теге мал врачының туган авылын табарга да ярдәм италмадың. Җибәр! Күлмәкне ертасың, хайван!
Шулвакытны кайсыдыр тарафтан сыбызгы тавышы ишетелде.
– Што здис праисхудит?! – дип акырды каяндыр калкып чыккан милиция лейтенанты. Шундук татарча да өстәп куйды: – Нишләп тәртип бозасыз?!
Локман ялагайланып елмайды:
– Бозмыйбыз, иптәш лейтенант, бозмыйбыз.
– Ник сугышасыз? – дип сорады милиционер, әйтерсең лә сугышуларының сәбәбен белү аның өчен гаять әһәмиятле иде.
– Сугышмыйбыз, – диде Локман. – Бу минем якташым.
Лейтенант борын тишекләрен киңәйтте, тирә-якка күз ташлады:
– Казанның үзәк урамында потасовка оештырасыз.
Салих күзлеген салды да милиционерга текәлеп катты:
– Йөзең таныш. Кайда күргәнем бар соң?.. – Салих кинәт, кычкырып, лейтенантның беләгенә ябышты. – Таныдым! Искә төште! Син бит Мамадыш постында торганыең. Вятканы чыккач – күпер башында. Минәзәл бит син!
Милиционер җирәнеп кенә Салихның шыр сөякле бармакларыннан беләген азат итте.
– Но-но! Без рук! Ал кулыңны! – диде ул, үзенең Минәзәл икәненә каршы килмичә.
– Мине хәтерләмисеңме? – диде Салих, лейтенант тирәли бөтерелеп. – Анда минем атым югалды. Хөкүмәт делегациясе узмакчы иде. Мал врачы, справка... Мине дә, атны да компьютердан тикшердең. Атбагар Вахит абыйны да карадың компьютерыңнан.
– Ә-ә-ә, булды андый хәл, – диде Минәзәл. – Төсмерлим мин сине. Атың югалды шул, әйе, әйе. Табылмадымы?
– Табылмады, – диде Салих газаплы тавыш белән. – Аттан соң нинди михнәтләр күргәнемне белсәң иде. Син нишләп монда соң?
Минәзәлнең кыяфәтенә канәгатьлек төсе йөгерде.

– Мин хәзер Казанда, – диде ул, гүя Казанны урыслар түгел, ә ул алган. – Күрәм, син дә Казанда хәзер.
Салихның үпкәләве чыраена чыкты:
– Әйе, менә мин дә башкалада. Син теге вакытта бәйләнмәгән булсаң, аттан колак какмый идем мин. Ишеткәнсеңдер инде, теге мал врачы үлгән бит.
– Мирзамы?! – диде сержант, күзләрен акайтып.
– Әйе. Мамадыш районында үткән-сүткән кешеләрдән сораштырган идем. Аны яхшы белүче кеше әйтте.
– И-и-и, кызганыч, кызганыч, – диде милиционер, кайгырган булып. – Бик кызык кеше иде. Каты эчте шул. Талантлы кешеләр шул эчеп харап булалар инде алар.
Салихның үз хәсрәте хәсрәт иде.
– Ул миңа теге вакытта справканы дөрес бирмәгән. Аның язуы буенча ат түгел, мин үзем үлгән булып чыгам икән.
Минәзәл Россиядә мәңге калкып, мәңге җавапсыз кала торган сорауны бирде:
– Хәзер нишләргә соң?
– Хәзер инде аның үлгәненә дә таныклык кирәк, – диде Салих. – Кайсы авылдан иде ул?
– Мин аның кайсы авылныкы икәнен белмим бит. Син центральный загска бар, анда үлгән кешеләр турында мәгълүматлар булырга тиеш.
– Инде әллә кайлардан тикшерттем, – дип сүзгә кушылды Локман. – Беркайда бернинди мәгълүмат юк.
– Бәлки, ул без вести пропалдыр, – дип фараз кылды Минәзәл. – Хәзер кеше күп югала бит. – Ул, үрелеп, урамның теге ягына карады. – Син монда буласыңмы әле?
– Кая барыйм инде мин, – диде Салих.
– Мин үз постыма барыйм әле, аннары сөйләшербез, – диде Минәзәл. Ул мизгел эчендә юлның теге ягына чыгып югалды.
– Сине ничек күреп була? – дип кычкырды Салих тыз-быз үткән машиналар арасыннан урамның аръягына.
Минәзәлнең:
– Мин гел шушында дежурить итәм, – дип кычкырганы кайсыдыр тарафтан яңгырап куйды.
Локман әле һаман лейтенант киткән якка карап торучы Салихка эндәште:
– Әйдә кайтабыз!
– Мин кич белән үзем барырмын сезгә. Бу милицонер белән тагын сөйләшим әле. Аның аркасында башланды бәла-казаларым, бәлки, ярдәм итәр.
Кич белән үзебездә көтәбез, син кайтмыйча ашарга утырмыйбыз, дип кат-кат кисәткәннән соң, Локман китеп барды.
Салихның телгәләнгән күңеленә өмет җылысы йөгерде. Ул җәһәт кенә кара күзлеген киде, гармунын кыегайтып, суза-суза, уйнап җибәрде.
Беравык моң саркытып утыргач, аның каршында купшы ки-

енгән, муенына бармак юанлыгы алтын чылбыр аскан, урта бармагына самавыр конфоркасы хәтле алтын йөзек кигән бер яшь егет пәйда булды. Егет, башын кыңгыр салып, беркавым тыңлап торды да тыңкыш тавыш белән:

– Сәлам, абзый! – диде.

Салих, ишетмәмешкә салышып, гармунын каера-каера тирә-якка нәгъмә таратуын дәвам итте.

– Матур сайрыйсың, – дип авызын ерып елмайды егет.

Салих исә күз кырые белән аңа күз сала-сала гармун тартты.

– Инструментың гына зәгыйфь синең.

Салихның чырае караңгыланды.

– Башкасы булмагач нишлим, – диде ул, үзен гаепле итеп сизгәндәй, һәм гармунын ачу белән катырак киереп уйный башлады.

Егет як-ягына каранып алды да, иелебрәк:

– Минем бик шәп баяным бар, кирәк түгелме? – диде.

Салих шундук уйнаудан туктады, сикереп торды, аның хәтта тыны капты.

– Кирәк булмый! – дип иңрәде ул. – Шул баян кирәк булганга монда утырам да инде мин. – Ул егеткә сынаулы караш белән карап торды. – Бик кыйммәттер бит?

– Сиңа ярты бәясенә бирәм, – диде егет ачык кыяфәт белән. – Чөнки миңа кичекмәстән акча кирәк.

Салих, иләсләнеп:

– Күпмегә бирәсең? – дип кызыксынды.

Егет күзләрен челәйтте:

– Сөйләшербез.

– Әйе шул, аны башта карарга кирәк, – диде Салих, өненә кайтып.

Егет күз кысып баш какты:

– Карарсың. Ошарга тиеш ул сиңа. Шәп инструмент.

– Синең үзеңнекеме соң ул?

– Әйе. Мин консерваториядә укыйм, дүртенче курста. Студент кешенең инде аның, үзең беләсең, акча кирәк тә акча кирәк.

– Әйе, әйе... Яшь кешегә акча кирәк, – диде Салих, моңсу елмаеп. – Хәер, карт кешегә дә кирәк инде ул. Мин үзем менә акчасыз кеше. Хәерчелекнең нинди яман нәрсә икәнен бик яхшы беләм. Әгәр бәясе мине канәгатьләндерерлек булса, бәлки, классташымнан әҗәткә алып торырмын. Кайчан карыйбыз соң баянны?

– Син иртәгә монда буласыңмы? – дип сорады егет, бармагы белән тротуарга төртеп күрсәтеп.

– Монда.

– Иртәгә обедтан соң шушында алып килермен.

– Ярый, сөйләштек, – диде Салих, егетнең никтер юешләнебрәк торган кулын кысып. – Исемең ничек?

– Рим.

– Рим... Кызык исем, – диде Салих, көлемсерәп. – Мин Салих абыең булам. Бик кыйммәт сорамассың инде. Мин ерактан килгән кеше.

– Сиңа бөтенләй арзанга бирермен, – диде Рим, авызын җәеп.

Рим киткәч, Салих, гармунын ящик өстенә куеп, ашыга-ашыга калай савытка җыелган акчаны санарга тотынды. Янына кемдер килеп баскач, ул сискәнеп китте. Бу Миңзәәл иде.

– Теге шакал нишләп йөри синең янда? – дип кызыксынды ул, егет киткән якка ымлап.

Салих акчасын кесәсенә тыгып куйды.

– Шакал түгел ул. Баян тәкъдим итте. Арзан бәягә бирермен, диде.

– Син Казан шпанасына ышанма. Алдавы ихтимал. Акчаңны да алырлар, баян да бирмәсләр. Сак бул.

– Алайса, иртәгә, ул баян алып килгәч, минем янга сугылырсың әле, бергәләп карарбыз баянны, яме?!

– Ярар.

– Мин бик авыр хәлдә. Бурычка баттым. Ат өчен дә түлисе бар. Берәр ничек спонсор табарга ярдәм италмыйсыңмы?

– Нинди спонсор! Мин ни артист, ни язучы түгел, – диде лейтенант, көлемсерәп. – Берәрсеннән конфисковать иттерү ягын карасак кына инде.

– Алай кирәкми. Мин бер мафиозникка йорт төзешкәндә, гаражы өстеннән «Мирсидис»ына уголоклар төшердем.

– Яньчелдеме?

– Бик каты.

– Нәрсә ди?

– Башта кыйнады. Хәзер биш мең доллар түләргә тиеш мин аңа.

Миңзәәлнең кыяфәте кинәт җитдиләнде.

– Түләмичә булмый. Түләмәсәң үтерәләр. Казан бу. Бурычы бар кеше йә бурычын түли, түләмәсә...

– Аңлыйм.

– Син шулай да ул «Мерседес» хуҗасының исем-фамилиясен, кайда яшәвен әйт әле.

– Салмачы артында аның коттеджы. Каенлыктан болайрак. Фамилиясен белмим, Гоша дип йөриләр аны. Машинасының номеры өч «бер»ле.

Миңзәәл блокнотына нәрсәдер яза-яза мыгырдады:

– Өч «бер»ле... Блатной номер. Капкансың син, туган. Сине ничек табып була? Координатларыңны калдыр әле миңа. Шулай да алай-болай... Машина ремонты өчен түләргә тиеш буласың инде, сүз дә юк. Кызыксыныйм әле, бик куркыныч кеше микән. Бәлки, әйбәтләп сөйләшеп килешү мөмкиндер?

– Аның белән кешеләрчә сөйләшү мөмкин түгелдер. Мин әлегә Локманнарда яшим. Әле яңа гына минем яннан китте ул. Авылдашым, классташым.

Миңзәәл Локманнарның адресын язып алды. Аннары Салихны юатып берничә җылы сүз әйтте. Заманы әллә нинди бит аның, бернишләтә алмыйсың, бирешмә, дигән булды. Шуннан соң, тагын очрашырга вәгъдә биреп, постына китте.

Салих, гармунында уйнап, кычкырып җырлап җибәрде:

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул шул,
Караңгы төн, томанлы көн –
Без аерылган көн бит ул...

* * *

Гөлнур телевизорны кабызды. Анда хатлар буенча җырлар яңгырата торган тапшыру бара иде.

– Чираттагы хатны укыйм, – диде тапшыруны алып баручы. – «Минем бертуган апамның иртәгә туган көне. Аңа ныклы сәламәтлек, бәхет телим. Шулай ук җизнинең абыйсының уртанчы улының хатынының классташы Зәйтүнәнең дә иртәгә туган көне. Аны да чын күңелдән котлыйм. Сәламәтлек, бәхет, эшендә һәм тормышында зур уңышлар телим. Бу җырны шулай ук гаиләбезнең якын дусты, иремнең армиядәге хезмәттәше Шәүкәтнең оныгы тууы белән котлап ишеттерәсе килә. Чын күңелдән котлыйм! Аның хатыны Нәҗибәгә улыбыз Радикны финансово-экономическийга кертергә ярдәм иткәне өчен олы рәхмәтемне белдерәм. Шулай ук машинабыз белән авариягә эләккәч, ике мең доллар урынына бер мең генә доллар түләткәне өчен Мицубиси Паджеро шоферы Мостафин Закирга тирән рәхмәтебезне белдерәбез. Вәзи Мәзиев башкаруында берәр җыр бирмәссез микән?»

Локман белән Гөлнурның әчкелтем тавышлы җырчының моңын тыңлыйсылары килмәде, телевизорны сүндереп, чәй эчәргә утырдылар.

– Нинди җебек кеше булгандыр инде, – диде Гөлнур, Салихка караганда күбрәк аның хатыны Җәмиләне кызганып.

Локман чынаягын чыкылдатып тәлинкәгә куйды.

– Алай димә! – диде ул, кайнар чәй чәчрәгән беләген кашып. – Бу заман җебеккә, катыга карамый. Әллә кемнәр югалып калды, әллә кемнәр сәнәктән көрәк булды. Салих ул сәнгатькә, моңга гашыйк кеше. Хәтерләмисеңмени яшь чакларыбызны, кичке уеннарны! Иң кирәк, иң абруйлы егет шул иде бит. Мәҗлесләрдә дә ул гел түрдә булды.

– Соң, заман Салихка яраклашмас бит инде, нәрсәдер эшләргә кирәк, – диде хатын зарлы тавыш белән. – Ул бит ир кеше. – Чулпанга карап өстәп тә куйды: – Тиздән кызын кияүгә бирәсе.

– Сөйләшкәндә җиңел ул. Син әйткәннәр белән килешәм, ләкин бер яктан гына карарга ярамый.

Чулпан мыш-мыш килеп кием үтүкләгән җиреннән сүзгә тыгылмый кала алмады:

– Ул просто адаптироваться итә алмый бу дөньяга.

Локман кызына таба борылды:

– Ул чиста кеше, намуслы кеше, шуңа тормышын кайнатып

җибәрә алмый. Бүген кеше сайларга тиеш – намуслы булыргамы, әллә тулы канлы, мул тормышта яшәргәме?

Чулпан эшеннән туктап тавышын күтәрде:

– Ой, пап, әле ярый син менә шулай уйлыйсың. Тагын күпмедер вакыт узар, алай уйлаучылар калмаячак. Все равно по общим законам жить придется.

Локман, чәен юри каты итеп шопырдатып эчеп куйгач:

– Ерткычлар законы буенча яшәрсез, – диде.

– Менә минем булачак ирем булдыксыз, хәлсез, акчасыз булса, сезгә рәхәт булырмы? – диде Чулпан, үтүкләнгән кофтасының кайсыдыр төшен җентекләп карап.

Гөлнур катгый итеп баш чайкады:

– Ю-у-у-к, хәлсез, булдыксыз, акчасыз кешегә чыкмыйсың! Сәнгать кешесе дә кирәк түгел, атаң шикелле журналист та кирәкми.

Локман, хатынына бөтенләй колак салмыйча, кызына мөрәҗәгать итте:

– Синең бу йөри торган егетең миңа бер дә ошамый.

– Нормальный парень, – диде Чулпан канәгатьсез тавыш белән.

Гөлнур кызын якларга кирәк тапты:

– Бик әйбәт, заманча егеткә охшаган. Килеп керү белән затлы одеколон исе аңкый үзеннән. Күрдеңме, Чулпанга нинди туфли бүләк итте. Минем гомергә андыйны кигәнем юк.

– Студент кына килеш каян ул хәтле акча ала икән?! – дип кайнарланды Локман. – Маңка малай! Беркөнне ике меңлек виски күтәреп кергән.

– Сөенергә кирәк, – диде Чулпан, кофтасын урындык аркасына ыргытып. – Димәк, ата-анасы байлар.

– Белмим, белмим, – диде көн саен гаиләсе белән бәхәсләшеп, көрәшеп яшәүче ир.

– Ярар, Аллага тапшырдык инде, – диде Гөлнур, авыр сулап. – Чатта гармун уйнап утырышлы булмасын берүк.

– Хайваннар арасында хайванча яшәгәнче, бәлки, чатта гармун белән утыру арурактыр, – диде Локман, хатыныннан туя башлап.

Чулпан авызын кыйшайтты:

– О-о, начинается.

– Тик кенә тор! – дип кычкырды ата кеше. – Минем шакмаклы күлмәкне үтүкләдеңме?

– Үтүкләдем, үтүкләдем, – диде кыз, иреннәрен турсайтып.

Гөлнур фатирга тынычлык иңдерү нияте белән:

– Ярар, тиктомалга тавыш чыгарма әле, Локман, – диде. Аннары саклык белән генә кызыннан сорап куйды: – Егетең безгә киләме бүген?

– Килә.

Гөлнур ялагайланып иренә эндәште.

– Атасы, кырыс сөйләшмә инде ул егет белән, зинһар. Бик җитди ниятләр белән йөри шикелле.

– Кем әле аның белән кырыс сөйләшкән?! – дип мыгырдады Локман.

Шулвакытны ишек кыңгыравы зеңгелдәде. Чулпан йөгереп барып ишекне ачты. Ләкин бусагада аның егете түгел, ә култык астына гармунын кыстырып, Салих пәйда булды.

Гөлнурның: «Урамда акча эшләп буламы соң?» – дигән соравына җавап итеп, клуб мөдире кич буе урамда сәнгать белән шөгыльләнүнең авырлыгын, иҗат өчен Казан чатларында шартлар юклыгыннан зарланды. Рэкетирлар, вак шпаналар килеп йөдәтүен телгә алгач, кат-кат Минәзәлне жылы сүз белән искә алды, һәрвакыт яклавын, беркемнән дә кыерсыттырмавын, хәтта башка смена милиционерларын да җил-яңгыр тидермәскә кисәтеп куйганын сөйләп рәхмәтләр укыды.

– Җәмиләдән дә хат юк, – диде Гөлнур, авылдашы сөйләгәннәрдән соң уйга калып. – Аны бик кызганам. Сагынасыңмы соң?

Салих чак кына елап җибәрмәде.

– Ничек сагынмыйсың инде! Сагынам!

– Мин әлегә теге врачның эзенә төшә алмадым, – диде Локман, авылдашына ярдәм итә алмаганына хафаланып. – Минемчә, үлгән кеше хакында мәгълүмат эзләп, аның исән түгеллегенә справкалар юнәтеп йөрүнең фәтвасы юк. Иганә эстәп мин берничә бизнесменга мөрәҗәгать иткәләдем инде. Сиңа бит хәзер шактый акча кирәк. – Ул түшәмгә карап санарга тотынды. – Биш мең доллар теге «Мерседес» өчен... аннары ат өчен. Баян да кыйммәт бит әле.

– Андый акчаны ничек, каян тапмак кирәк?! – диде Гөлнур, күзләрен акайтып.

– Эзләп маташмыйк, Локман, – диде Салих тәкъдиргә язылганга берсүзсез буйсыну белдереп. – Андый акчаны кем бирсен синең белән миңа?

Локман аклангандай тезеп китте:

– Мин инде филармониягә дә бардым, Мәдәният министрлыгында да булдым, театрларга да кереп чыктым. Юк, һич кенә дә арзан бәягә уен коралы табу мөмкин түгел.

Барысын да сискәндереп, ишек кыңгыравы зеңгелдәде. Чулпан йөгереп барып ишекне ачты. Бусагада аның сөйгән егете пәйда булды. Ул затлы киемнән, кулында чәчәк бәйләме, икенче кулында бер шешә коньяк, култык астына бер кап кәнфит кыстырылган иде.

– Исәнмесез! – диде купшы киемле егет, авызын ерып. Әмма Салихны күреп шундук аптырашта калды.

– Привет, Рим! – диде Чулпан, сикергәләп, һәм җәһәт кенә егетнең кулындагы күчтәнәчләрне алып өстәлгә урнаштырды. – Әни, чәчәкләрне вазага куй.

Гөлнур чәчәкләрне иснәп бермәл күзләрен йомып торды, шуннан соң, рәхмәтләр укый-укый, бәйләмне вазага утыртты.

Чулпан киенергә дип күрше бүлмәгә кереп шылгач, Рим, нишләргә белми, бер урында таптанып алды. Салих аңа карап утырган урынында шаңкаеп калды, икеле-микеле уй белән күзләрен челәйтте:

– Син теге Рим бит?

– Юк! – дип кырт кисте егет һәм ярдәм эзләгәндәй як-ягына каранып куйды.

Салих, капылт кына урыныннан кузгалып, егет тирәли әйләнеп чыкты:

– Баян алып килергә вәгъдә итүче син түгел идеңмени?

– Юк, ялгышасыз, – диде Рим, түземсезлек белән Чулпанның чыкканын көтеп.

– Син бит вәгъдә иттең!

– Ә-ә-ә, искә төште, – дигән булды егет, шактый оста уйнап. – Син идеңмени ул? Әйе, әйе. Аннары сөйләшербез, яме, абзый.

Салихның сөенечтән хәтта кан басымы да күтәрелде, аның аксыл чырае Гөлнурның кызыл халаты төсенә керде.

– Ярар, ярар, иртәгә мин шунда булачакмын, – диде ул, егеттән күзләрен алмыйча.

Чулпан күрше бүлмәдән атылып чыкты да:

– Хәзер, китәбез, Рим, чак кына көт инде, хәзер, хәзер, – дип, абаланып, тумба тартмаларыннан нидер эзләде.

Локман, Казанда шактый вакыт яшәгәнгә күрә, кеше сүзенә шундук ышанырга торучылардан түгел иде.

– Баяның бармыни? – диде ул, егетне җентекләп күзәтеп. Күрәсең, андый затлы уен коралы белән елтыр күзле булачак кияүне бергә күзаллавы кыен иде.

Егет, беренчедән, сөйләшүнең бу темага кереп киткәненнән, икенчедән, кешене кешедән аера белүче Локманның күз карашыннан нык шүрләде:

– Әйе, бар, – диде ул, өзеп-өзеп.

– Зинһар, сат Салих абыеңа арзанрак бәягә, – диде Локман таләпчән үтенүле тавыш белән. – Бүләк итсәң дә була. Чулпан, кызым, сөйләш әле шуның белән.

– Рим, в самом деле у тебя баян есть, что ли? – дип, күз алмаларын киңәйтте Чулпан.

– Есть, – диде Рим басынкы тавыш белән.

Чулпан ялварырга тотынды:

– Рим, продай его ему за дешево, пожалуйста. У этого дяди дела совсем плохи.

– Ярар, ярар, – диде Рим, баян мәсьәләсеннән тәмам туеп.

Баянны Локманнарга алып килеп күрсәтергә вәгъдә биргәч, егет белән кыз чыгып киттеләр. Локманның чыраеннан кырыслык эреп юкка чыкты.

– Егет, әлбәттә, бераз каушады, – диде ул, аталарча елмаеп. – Безнең алда сату-алу турында сөйләшергә читенсенде, бәясен әйтергә авырсынды, егетне аңлап була.

– Күпмегә сатар икән? – диде Салих, кан басымының тагы да югарырак күтәрелүен тоеп.

– Баянын карыйк әле башта, – диде Локман коры гына. – Бәлки, бүләк итәр.

– Бүләк итмәс инде ул, – диде Гөлнур, күңеле белән булачак кияү ягынарак авышып.

Локман көлемсерәп куйды:
– Менә күрербез инде – кызыңның йөргән егете яхшымы, начармы.
– Бушлай бирүен бирмәс, ләкин бәясен бик күтәрмәсә иде, – дип борсаланды Салих.
Локман бүлмә буйлап йөри-йөри зарланырга тотынды:
– Анысы шулай. Карале, Салих туган, нинди мескенлек, ә! Ни генә ала башласак та, арзан кирәк! Акчабыз җитәр микән, кыйммәт сорамаслар микән, дип яшә әле син гомер буе! Без шушы көнгә калырдай кешеләр микәнни соң?! Нефтьле Татарстанмы без, әллә бетле Татарияме?
Гөлнур үзенең гел кабатлап әйтә торган фикерен әйтте:
– Ил мөлкәтен дөрес бүлмәделәр, кемдер баеды, кемдер хәерчеләнде.
Локман кызып китте:
– Ташла, Гөлнур, алай примитив карама! Мәсьәлә катлаулырак монда. Үзебездән тора барысы да. Үзебезне күпмегә бәялибез, шулкадәре түлиләр. Үзебезне үзебез талыйбыз. Үзебезне үзебез бетерәбез. Үзебезнең арабыздан эзләргә кирәк кабахәтен дә, яхшысын да. Бөтенесе үзебездә – нәтиҗәсе дә, сәбәбе дә!
Салихның уенда исә фәкать баян гына иде.
– Монда алып килүе әйбәт булыр, бергәләп карарбыз, – диде ул, күңелендә өметнең ныклап урнашуын тоеп. – Аннары, таныш кешедән әйбер алу җиңелрәк инде ул. – Ярый сез бар әле, – диде Салих күңел мөлдерәмәлегеннән калтыранган тавыш белән. – Нишләр идем?!
Локман, килеп, авылдашын иңеннән какты:
– Их, кордаш, кордаш!
Иренең тынычланып елмаюын күргәч, Гөлнур илһамланып китте:
– Салих, әйдә, яшь чактагы берәр көйне уйна әле.
– Әйе, туган, күңелне тетрәндереп ал, зинһар! – диде Локман, җәһәт кенә түр почмактан гармунны алып килеп.
Салих ялындырып тормады, гармунны алды да сыздырып уйнап җибәрде. Аның җырлавына Локман белән Гөлнур да кушылды.

Яшьлегемне эзләп чыктым
Җәйнең болыннарына,
Әйтте җил: «Синең яшьлегең
Февраль бураннарында».

Гел бураннарда эзләдем
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Дөрес чамаламаганмын
Гомеремнең чикләрен,
Авыз итә алмый калдым
Июньнең җиләкләрен.

Гел бураннарда эзләдем
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Ник болай тиз үтә көннәр –
Һаман да аңламадым,
Бакчамда җиргә коела
Сентябрь алмалары.

Гел бураннарда эзләдем
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Алмагачым әйтте миңа:
«Югаласы югалган,
Озак йөргәнсең февральдә,
Шуңа чәчең агарган».

Гел бураннарда эзләдем
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Йөгердем кыш уртасына –
Яшьлекне табыйм инде.
Адаштым, хәлем җитмәде,
Ярый әле яз килде.

Гел бураннарда эзләдем
Язның тал-тирәкләрен,
Сентябрьнең алмаларын,
Июньнең җиләкләрен.

Җирдә бәйрәм. Ничәнче кат
Чәчәк ата сиреньнәр.
Иң кирәк сүзне әйтерләр
Инде башка иреннәр.

Язда булдым, җәйне гиздем
Яратып һәм табынып.
...Йөрим алма бакчасында,
Бураннарны сагынып.

* * *

Салих урам чатында әле бер кырыйга, әле икенче якка авыша-авыша гармунын каерганда, кемдер битараф кына үтеп китте, кайсысыдыр көйне танырга теләгәндәй каш җыерды, кайберәүләр көйне туктап тыңлап торды. Гармунчының алдына акча ташлаучылар күп түгел иде.

Кулына дипломат тоткан тыгыз гәүдәле бер абзый зур кызыксыну белән гармунчыга таба атлады. Читтәрәк туктап, нинди көй икәнне генә түгел, музыканың, көй-нәгъмәнең философлар да, галимнәр дә, музыка белгечләре дә төшенеп җитмәгән асылын,

мәгънәсен аңларга теләгән кыяфәттә, башын чак кына кыңгыр салып, шактый вакыт тыңлап торды. Якын килеп баскан кешегә башын күтәреп карагач, Салих уйнавыннан туктады.

Сәер кеше авызын кыйшайтып елмайгач, Салихны ток суккандай булды. Электр плитәсен рәтләгәндә аны ток сукканы бар иде, шул җан өшеткеч халәтне ул менә тагын кичерде. Гармунын читкә куйганнан соң, калтыранган кулы белән кара күзлеген салып пинжәк кесәсенә тыкты. Эндәшергә теләде, әмма теш алдырыр алдыннан кадала торган наркоз тәэсирендәгедәй оеган, әйләнми торган тел тәмсез авызда һич кенә дә кыймылдамады.

Ниһаять, ул:

– Мирза әфәнде! – дип ыңгырашты. – Өнемме бу, төшемме?!

Мирза, өрәкләргә хас кыяфәткә кереп:

– Ә син үзең ничек уйлыйсың соң? – дип мөгрәде.

Салих, әллә каян хасил булган «өрәк»не югалтудан куркып, аның җиңенә ябышты:

– Кешеме син, өрәкме?

– Мыскыл итмәвегезне үтенәм! – диде «өрәк» тыныч кына. – Кысма беләкне ул хәтле, кәчтүмне бөгәрлисең.

– Сине бит үлде дигәннәрие, – диде Салих, күзләрен акайтып. Бу мәлдә ул инде үзем үлеп «тегендә» Мирза белән очраштым микән әллә дип тә уйлап куйды.

Мирза, як-ягына каранып:

– Алай дигән кеше үзе инде хәзерге вакытта гүр ияселәр, – диде. – Мирза ул бөтен кеше үлеп беткәч тә бер атна-ун көн йөриячәк әле. Чөнки шулкадәр күп эшләрем эшләнмәгән әле бу дөньяда. – Ул Салихка текәлеп карап торды, танымавы ясалма түгел, чынлап та, бичара завклубны дөньяви мәшәкатьләр чатырына кереп адашкан мал врачы оныткан иде. – Син соң кем буласың? Мин бит сине белмим...

Салих Мирза тирәсендә бөтерелергә тотынды:

– Мин – Салих! Минем атым үлгәнгә справка биргән идегез.

– Мин гомеремдә ничәмә мең справка биргән кеше, – диде Мирза эшлекле кыяфәт белән. – Барыгызны да хәтерли алмыйм, бигайбә.

Салих кабаланып аңлатырга керешге:

– Күптән түгел булды ул. Вятка күпере янында. Минем атым югалды. Шунда постта торучы сержант белән бергәләп ат үлгәнгә справка язып бирегез дип сездән үтенеп сорадык. Сез язып бирдегез. Андый справка кирәк түгелие.

Мирза, тротуардагы чүп-чар өстеннән күз карашын йөгертеп, хәтерендә казынды.

– Атың терелгән мәллә? – диде ул, Салихка текәлеп.

Салихның газабы бөтен вөҗүден биләп алды.

– Юк шул, атым югалды бит минем, – дип әйтте ул үзенең мәңгелек хәсрәтен. – Ә сез справка биргәниегез... мине җәлләп.

– Нәрсә, җәллисе калмаган мәллә? – диде дөньялыкка яңадан туган профессор.

Салих читенсенеп кенә, ялагайларча елмайды:

– Алай түгел. Сез, гафу итегез, ул вакытта бераз салмыш идегез.

– Мин хәзер дә салмыш, – диде Мирза канәгатьлек белән.

Салих ялагайлануны дәвам иттерергә кирәк дип тапты.

– Бик әйбәт, – диде ул, мал врачының мәңге айнымаганына куанган булып кыланып. – Димәк, сез сәламәт кеше.

Күпне күреп, күпне аңласа да, Мирза төче сүздән йомшарыбрак китте:

– Сиңа нәрсә кирәк, башыңны төзәтергәме? Махмыр түгелдер бит?

– Юк. Сез миңа теге вакытта ат үлде дип язасы урынга ялгыш мин үлде дип язып биргәнсез.

Мирза шаккаткан булып күзләрен акайтты:

– Алай булырга мөмкин түгел!

– Шулай язгансыз шул, – диде Салих, елмаюында ялагайлыкны саклап.

– Ну, син исәндер бит? – дип кызыксынды мал табибы.

– Күрүегезчә, исән-сау... әлегә, – диде Салих, Казан урамына чыраеннан якты нур сибеп.

– Соң, алайса, ерт та ат ул справканы. Ялгышулар була инде ул. Ерт та ат. Исән килеш үлдем дигән справка белән йөрү, минемчә, тыйнаксызлык билгесе. Сыра эчәсеңме?

Салих, Мирзаны югалтудан куркып аңа текәлеп карап торган килеш:

– Эчәм! – диде. Шуннан соң тиз генә читтәрәк яткан бер ящикны алып килеп үзе утыра торганы янына куйды.

Мирза акрын, ләкин ышанычлы хәрәкәтләр белән алдына куеп ачылган дипломаттан бер шешә сыра чыгарды да, Салихка сузып:

– Мә, тешең белән ач, – диде.

Мал врачын югалтудан Салих шулкадәр курыккан иде ки, хәтта тешләренең начарлыгын, теш белән шешә бөкесе ачу түгел, хәтта катырак ризык та ашый алмаганын әйтергә базмады. Шулай да:

– Тешләр начар минем, – дип, авыз серен ачып салды.

Мирза, бер дә уйлап тормыйча, шешәне үзенең алгы тешләре белән «бык» иттереп ачты.

– Мә, эч. Ул справка белән берәр кәнәтил килеп чыктымы әллә?

Салих сыраны теләр-теләмәс кенә йотып куйды.

– Авыл җитәкчесе Мулланур ат таптыра миннән, – дип еламсырады ул. Шуннан соң сыраны тамагына күбрәк агызды.

Мирза, дипломаттан тагын бер шешә чыгаргач, иреннәрен юкартып Салихка карады:

– Син аңа әйт, татар йөрәге скрипкә түгел, пажалысты, уйнама, диген.

– Мин сезнең аны белүегез турында әйткәнием, тик менә ул сезне белмим, диде.

Мирза шешәне шул ук ысул белән ачкач:

– Мин белгән җиткән, – дип куйды. Шуннан соң бер шешә сыраны бер-ике йотуда эчеп тә бетерде. – Мин нишләргә тиеш хәзер?

Салих ихлас күңелдән:

– Мин шулхәтле шат сезнең исән булуыгызга! – диде. – Сезне күрүемә бик шат. Мин бит Мамадыш районында сезнең хакта сораштырдым. – Аның йөзе кинәт караңгыланды. – Гафу итегез, сезне «үлде», диделәр.

Мирзаның моңа бер дә исе китмәде. Үз гомерендә ул шулкадәр күп кәнәтилләргә эләгеп, шулхәтле матавыклардан ничек кирәк алай чыгып, утны-суны кичеп, ни гаҗәп, әле һаман да исәнимин җир йөзендә йөри иде. Инде әллә ничә кат үлеп терелгән мал врачы бөтен кешелек дөньясын ярлыкаган сыман кызгылт чыраен сагышка манып авыз чите белән генә елмайды.

– Безнең якта шундый тиреләрчә юньсез шаяру бар: берәр кеше турында сорасалар, «үлде» дип җавап бирәләр, – диде ул, тирәннән кикереп куйгач. – Безнең районда кеше артык күп, бәлки, шуңадыр.

Шул арада берничә бомж бушаган шешәләр өчен гауга куптарып алдылар. Ниһаять, алар юкка чыккач, Салих әңгәмәне дәвам итте:

– Мин инде сезнең үлүегез турында таныклык ясату артыннан йөри идем. Мулланурга кайтарып бирергә.

– Мин үземнең үлүем турында да сиңа справка язып бирә алам, тик анысы бушка булмаячак, кыйммәткә төшәчәк, – диде Мирза кырыс кына.

Салих ялварырга тотынды:

– Юк, юк, рас инде сез исән икән, атым үлгәнлеккә генә таныклык ясап бирегезче!

Мирза бик эшлекле кыяфәт белән кесәләрен капшагач, дипломатын тагын бер тапкыр ачып япты:

– Минем үзем белән бланкалар бар, тик пичәт кесәмдә түгел. Бер хатында калдырганмын. Иртәгә очрашыйк. Ясап бирермен.

Салих, шатлыгыннан нишләргә белми, бер урында таптанды:

– Сез Казанда нишләп йөрисез соң?

– Иң зур эшләр Казанда кайный, туган! – диде Мирза ифрат та тантаналы тавыш белән. – Мин бит Татарстанга гаять кирәкле кеше. Менә күптән түгел генә сайлаулар булып узды. Депутатлар корпусына кандидатлар туплау тыныч кына, тәртипле рәвештә барсын өчен мәш килдем. Менә Казанның меңьеллыгын билгеләүдә дә мине катнаштырырга маташалар. Төрле артистларга ярдәм итүче дә мин. Концертларын оештырам, тегеләй итәм, болай итәм. Умия Мәмиева дигән җырчы кызга сигез күлмәк тектерергә акча күчерттем. Вәзи Мәзиев дигән яшь җырчыга аппаратура алып бирдем.

– Вәзи Мәзиевкә дә сез ярдәм итәсезмени?! – дип таң калды Салих.

– Әлбәттә! Эт шикелле күзгә карап ялварып торалар бит, ничек инде иганә күрсәтмисең! Башка төрле оештыру эшләремнең дә чуты-кырые юк.

– Сез мал врачы була торып шулай киң диапазонда эшлисез икән! – диде Салих, сокланып.

Шунда Мирза, аны-моны уйламыйча, ә бәлки, киресенчә, уйлаптыр, әйтеп ташлады:

– Кешеләре хайван булгач, минем кебек мал врачлары кирәк монда, туган.

– Бәлки, сез миңа да спонсорлык ярдәме күрсәтә алырсыз? – диде Салих кыюсыз гына.

– Синең нинди талантың бар соң?

Салих гаҗәеп җитдилек белән:

– Авылга баян кирәк! – дип ярып салды.

– Кирәк нәрсә күп ул. Кирәкнең аның чиге юк. Үзең нишли аласың соң син – җырлыйсыңмы, биисеңме?

Салих, каядыр Мирзаның баш түбәсеннән югарырак карап:

– Минем үзем язган бер җырым бар, – диде. – Хатын миннән китәргә йөргәндә, ялагайланып аңа багышлап язган идем. – Сыра Салихның баш миенә үтеп кергән иде инде. Ул гармунын алып ящикка утырды. – Хәзер мин аны җырлап күрсәтәм, – диде ул, кемгәдер һәм нәрсәгәдер кыҗраган, янаган сыман итеп.

– Хатының китә башлагач ялагайланып яздыңмы? – диде Мирза, гыр-гыр көлеп.

– Әйе.

– Алайса, көчле җырдыр ул. – Мирза, игътибарын туплап, худсовет рәисләренә хас беләмән вә таләпчән кыяфәт белән тыңларга әзерләнде. – Йә, җырла!

Салих шундук гармунын каерып уйнап җибәрде, тонык кына тавышы, бәгыреннән сытылып чыгып, Казан урамының якын тирәсенә күз күрмәс, ләкин кичеп чыккысыз томан булып сарылды.

Көзгә кереп барабызмы,
Нигә болай караңгы?
Әллә томан арабызда,
Әллә авыр карадың...

Китте миннән, синдә йөри
Күңелемнең яртысы,
Сине югалткан көнне үк
Мин үләрмен, ахрысы.

Сәгать саен күз алдымда,
Белмим, нигә юксынам,
Сине кочып елар өчен
Хәсрәтем дә юк сыман.

Китте миннән, синдә йөри
Күңелемнең яртысы,
Сине югалткан көнне үк
Мин үләрмен, ахрысы.

Мизгел саен яңа дулкын,
Мизгел саен сагынам,
Ни булгандыр зиһенемә –
Бары сиңа табынам.

Китте минпән, синдә йөри
Күңелемнең яртысы,
Сине югалткан көнне үк
Мин үләрмен, ахрысы.

Көзгә кереп барабызмы,
Нигә болай караңгы?
Әллә томан арабызда,
Әллә авыр карадың...

Китте миннән, синдә йөри
Күңелемнең яртысы,
Сине югалткан көнне үк
Мин үләрмен, ахрысы.

Җыр тәмамлангач, Салих шактый вакыт сулышын тигезли алмый җәфа чикте.

Мирза исә таң калды.

– Гениәлне! Син бит талант! – дип кычкырды ул, тагын буш шешә тәтемәс микән дип алар янында йөрүче бомжны сискәндереп.

– И-и, кая инде, – диде Салих, җырлаганда алсуланган йөзенең чөгендер төсенә керүен тоеп.

Мирза кинәт кызып китте, аның ярсып ары-бире йөрүен күргәч, буш шешәне аулаучы бомж читкәрәк шылды.

– Менә, татар мәңге шулай ул! – диде Мирза, борын тишекләрен киңәйтеп. – Тыйнак, мескен булырга тырыша һәрвакыт! «Кая инде» димә! Кыюрак булырга кирәк. Әйдә, концертларыңны оештырабыз. Бер конферансье, бер биюче кыз кирәк. Болай гына акча беркем дә бирми. Концертлар шаукымында тегеннән-моннан акча күчерттереп булыр. Эшлибезме?

Салихның каушаудан тавышы кысылып чыкты:

– Мин бит авыл клубында гына җырлыйм. Аннары елга бер тапкыр район үзәгендә.

– Син бит ишетәсең, күрәсең, беләсең – район үзәгендә җырлау түгел, хәтта район үзәгенә барганы булмаган кеше дә килеп Казанда концертлар куя хәзер. Булышам мин сиңа! Репертуар әзерли тор! Күп итеп акча эшлибез.

– Куркам, каушыйм. – Салих кинәт тавышын күтәрде. – Ә акча кирәк! Минем бит ат өчен түлисе бар! Баянга акча кирәк! Әле бит син белмисең: шабашка эшләгәндә, берәүнең иномаркасын уголоклар төшереп яньчедем – аңа биш мең доллар түлисе бар.

– О-о-о, син көннән-көн тирәнрәк батып барасың! – диде Мирза, кинәт илһамын каядыр югалтып.

– Шулай шул, – дип иңсәеп төште Салих.

Мирза кинәт шундук тагын куллары белән кискен хәрәкәтләр ясап сөйләргә тотынды:

– Мин әйткәнне тыңла. Татар йөрәге скрипкә түгел, уйнама! Әйткәнгә колак сал. Бөтен нәрсәң булачак. Мин дә хәерче идем. Хәзер Казанда гына ике фатирым бар. Казан безнеке ул. Итне татар да, урыс та, яһүд тә бик ярата. – Ул йодрыкларын төйнәп як-ягына каранды. – Мин яшь тана ите белән... Кыскасы... – Мирза Салихка таба иелде. – Ышанасыңмы миңа?

– Ышанмый. Теләсә кайда теләсә кайчан теләсә нинди справка язып бирә торган кешегә ничек ышанмыйсың.

– Иртәгә көндезге сәгать икедә сине кайда табып була?

– Мин көн саен монда гармун уйныйм. Шушында очрашыйк.

– Синмени инде ул соңгы вакытта монда гармунда җиффәрәсең?

– Әйе. Синең дустың теге Минәзәл дә моннан ерак түгел дежурить итә. Әнә тегендә.

– Беләм. Мин булыштым бит аңа монда күчеп урнашырга. Бүген аның сменасы бугай. Аны барып күрим әле мин. Ярый, иртәгә сәгать икедә очрашабыз.

– Ярар. Син бүтән югалма инде! – диде Салих, профессорны җибәрәсе килмичә.

Мирза туктап борылды да:

– Мин югала торган кеше түгел! – диде.

Югалмый торган кеше китеп барды, Салих, җан укталуыннан очып китәр дәрәҗәгә җитеп, ул киткән тарафка таба карап калды.

* * *

Кич белән тончыга-тончыга Питрәч тавыгыннан пешкән шулпаны ашаганда, Салих теге мал врачының шушы дөньяда икәнлеген, аның белән ничек очрашуын, ни хакында сөйләшкәннәрен бәян итте. Бу могҗизалы очрашудан соң алда киң-киң мөмкинлекләр ачылуы ихтимал икәнне кат-кат сөйләгәндә, киләчәкнең офыклары яктырасына аның үзенең ихластан ышанганы күренде.

Локман исә канатланырга ашыкмады.

– Концертларын белмим, малай, концерт белән күп кеше мавыга хәзер, – диде ул, тавык ботының шәрәләнгән сөяген кимерергә әзерләнеп. – Элегрәк эшлисе килмәгән кеше милициягә эшкә урнаша иде, хәзер ялкау кеше, арзан бәяле синтезатор кнопкаларын басарга өйрәнеп, сәхнәгә чыгу ягын карый. Син башта справка белән эшеңне тәмамла. Син ул Мирзаның координатларын алып калмадыңмы соң, мәсәлән, телефон номерын?

– Юк, – диде Салих, тораташ булып катып.

Локман тавык сөяген тәлинкәгә томырды:

– Нинди кеше син, ә! Ничек инде син аның телефон номерын да сорамый калдың?! Тагын югалса?!

– Иртәгә сәгать икедә очрашабыз, – диде Салих шөбһәле тавыш белән, чак кына ишетелерлек итеп.

– Берәр сәбәп белән йә сәбәпсез алай-болай килми калса?

– Куркытма инде.
– Монда нинди эш белән йөри соң ул?
– Ул бөтен өлкәдә дә киң колач белән йөзә, ахрысы. Ул бик блатной кешегә охшаган.
– Бозауларны списать итеп, ит белән акча эшләүчедер инде.
– Ярдәм итәргә торучы кеше турында алай димә, – диде Салих, үпкәләп.
Бер сәгать чамасы вакыт узгач, баян күтәреп Чулпанның егете килеп керде. Ул баянны саклык белән генә урындыкка куйгач, барысы да инструмент янына җыелдылар. Локман Салихка баянны зур дикъкать белән җентекләп карарга кушты.
– Шәп инструменттыр бу, – дигән булды Гөлнур, баянның түгел, егетнең бәһасен бераз арттырыр өчен.
– Классный баян, – дип өстәде Чулпан. – Ваще!
Урындыкка утырып баянны алдына куйгач, Салих бермәл һушсыз калып торды. Күзен йомып тирән итеп сулады, шуннан соң инструментны әйләндергәләп карарга тотынды. Мәҗүси хәрәкәтләр белән озак капшады уен коралын. Баянга мөнәсәбәте, мәхәббәте аның һәр кыймылдавында чагылды. Карап торуга гаплади күренеш кебек – кеше уен коралын карый, ләкин тирәнрәк игътибар итсәң, абайламый мөмкин түгел – бу каушау катыш тантаналы бер серле церемония, гүя дөньялыкның иң бөек бер сере ошбу вакыйгага килеп тоташкан.
– О-о-о, бу бит әле өр-яңа диярлек, шәп баян! – дигән нәтиҗәгә килде Салих, үзе дә сөенеп, өйдәгеләрне дә куандырып.
Локман авыз чите белән генә кызына эндәште:
– Егетең белән сөйләш инде, бәясен чамалап сорасын.
– Сколько просишь? – дип мөрәҗәгать итте Чулпан сөйгән ярына.
Рим иңнәрен сикертеп шыңшыды:
– Ну, синең хакка инде... ике меңгә бирәм.
Локман читкәрәк китеп пышылдады:
– Мондый ислемай сибенгән егет бер меңгә бирсә дә ярый инде.
Гөлнур егетне якларга тотынды:
– Алай түгел, Локман. Ул бит аңа да кадерле, үзе дә акчага сатып алган бит ул аны.
Көтмәгәндә Чулпанда Салихны кызгану өстенлек алды.
– Отдай за полторы, ты же все равно играть не умеешь, – диде ул каушабрак калган егетенә.
– Бәлки, өйрәнер әле, – дип яклады анасы егетне.
– Өйрәнәсе кеше инструментны сатарга йөрми ул, – дигән мантыйкны чыгарып салды ата кеше.
Салих:
– Анда, консерваториягездә арзанракка табып булмыймы соң? – дип кызыксынгач, Рим сискәнеп китте.
– Ул каян белсен, – диде Чулпан, егетнең каушавыннан куркып.
– Консерваториядә укый бит, шуңа соравым, – диде Салих.

– Безгә юридическийда укыйм диде, – дип гаҗәпләнде Локман, тавышында егетне өнәмәвен белгертеп.

– Консерваториядән юридическийга күчте ул, – дип ялганлады Чулпан.

Салихны кемнең кайда укуы кызыксындырмады, ул баянны капшау белән мәшгуль иде – әле уйнап карады, әле иснәп алды, әле сыпыргалады.

Кинәт аның чырай төсе үзгәрде. Ул баянын алдында торткан килеш иңсәйде, икенче мәлдә җан талпынуыннан укталгандай хәрәкәт ясады, күзләре елтырап куйды, кул калтыравыннан котылыр өчен баянны кочаклап ук алды. Моны барысы да сизделәр, ләкин аның бу халәте шатлыктандыр дип уйладылар.

– Шәп баян бу! – дип кат-кат кабатлады Салих үзалдына гына. Саклык белән генә, шомраеп, баянны тагын әйләндергәләп алгач, ул әкрен генә башын күтәрде. – Бу баян ничектер бик таныш, якын тоела әле миңа. Син моны каян алдың?

– Базарда сатып алдым, – диде Рим, котсыз калып.

Салих инде Казан базарларын яхшы белә иде. Шуңа күрә:

– Кайсы базарда? – дип сорады.

– Вьетнамскийда.

Салих баянны янә җентекләп тикшерергә тотынды, кат-кат иснәп карады, бу юлысы хәтта колагын куеп тыңлап торды. Беркавым берниндн хәрәкәтсез, чак кына да кымшанмыйча утырганнан соң, аның куллары гына түгел, бөтен гәүдәсе дерелди башлады. Ул өйдәгеләрнең һәрберсенә җөнүннәрчә акаеп карап чыкты. Аның дөньяларны тетрәндерерлек әһәмиятле игълан ясарга әзерләнгәнен барысы да чамаладылар, гүя хәзер Катлаулы авылының клуб мөдире Татарстанның башкаласы Казанда, килеп җиткән ахырзаманның төгәл көнен, сәгатен әйтергә тиеш – һәрберсе баскан урынында шаңкайдылар.

– Җәмәгать, бу бит минем баян! – дип шәрран ярды ул ниндидер чит-ят тавыш белән. Шуннан соң сикереп торып баянны урындыкка куйды да, төкерекләрен чәчеп, аптыраштан шыкраеп каткан тамашачыларның һәрберсенә якын килә-килә аңлатырга тотынды. – Бу минем баяным! Безнең клубтан урланган баян бит бу! Аның өстендәге инвентарь номерын кырып сөрткәннәр! Мин, дөнья хәлен белеп булмый, алай-болай кирәк була калса дип, инвентарь санын тагын яшерен урында, үзем генә белә торган төшендә вак кына итеп язган идем. Менә, карагыз. – Ул баян каешының аскы яктан эләктерә торган урында вак кына итеп язылган саннарны озын кәкре бармагы белән төртеп күрсәтте. Барысы да иелеп инвентарь номерны карадылар. – Бу минем инструмент! Документлары клубта! Исбатлый алам!

Рим акрын гына ишеккә таба юнәлде.

– Стоять! – дип кычкырды аңа Локман.

Егет бер урында катып калды.

– Мин аны сатып алдым, – диде ул, давыл кубасын сизенеп һәм хөкемнең каты булачагын чамалап.

Локман белән Салих, хатын-кызның чыр-чыр кычкыруларына игътибар бирмичә, Римнең, ярга тартып чыгарылган җәен балыгы сыман бәргәләнүен инкарь итеп, кулларын артка каердылар, Чулпанның иске колготкие белән бәйләделәр дә урындыкка дыкылдатып утыртып куйдылар.

– Җибәрегез! – дип ыңгырашты егет, боргаланып.

Локман аның борын төбенә чәйгүн хәтле йодрыгын китерде:

– Менә хәзер танавыңа берне җибәрәм! Тик кенә утыр!

– Мам, че они делают? – дип чинады Чулпан, печ итәсе килгән сыман бер урында таптанып. – Җибәрегез аны! Рим, тебе больно?

– Нишлисез сез, садистлар! – дип кычкырды Гөлнур. – Кияүгә мондый тупас мөгамәлә күрсәтергә ярамый!

Ләкин өйдә Локман хуҗа иде.

– Нинди кияү булсын ул?! – дип акырды ул хатынына. – Барыгыз да читкәрәк китегез! – Шуннан соң Римгә таба иеленкерәп сорады: – Каян алдың бу баянны?

– Базарда сатып алдым, – диде Рим, башын читкә борып.

Допроска Салих кушылды:

– Кайчан?

– Күптән инде.

– Сатучының төс-битен хәтерлисеңме? – дип сорады Локман.

– Әллә тагы...

– Милиция чакыртырга кирәк, – дигән карарга килде Локман.

Ана белән кыз, каршы төшеп, икәүләшеп еларга тотындылар. Аналы-кызлы бәхетсез тормыштан, булдыксыз ирләрдән зарлана-зарлана илаулаганда, ишек кыңгыравы зеңгелдәде.

Локман ишекне барып ачкач, бусагада милиционер пәйда булды. Чакыртмаган килеш тәртип саклау органыннан вәкил килү барысын да аптыраншта калдырды. Иң нык гәҗәпләнүче Салих булды, чөнки Минәзәлне ул килеп керү белән үк танып алды.

– Минәзәл!

– Исәнмесез! – диде Минәзәл һәм шундук фатирда ниндидер кәнәтил барганын сизенде. – Минем килеп керүем вакытсыз булды бугай.

Локман кискен хәрәкәтләр белән Минәзәлне беләгеннән тотып түргә алып килде:

– Киресенчә, нәкъ вакытында килеп кердегез. Безгә хәзер нәкъ менә милиционер кирәк тә.

Салих, табигать баласы буларак, шул арада егетне кызгана да башлады:

– Әллә җибәрикме? Баянны алып калыйк та җибәрик.

– Мин аны сатып алдым, – дип еламсырады Рим, милиционерга карап.

Чулпан өстәп куйды:

– Базарда сатып алдым, ди бит!

– Карагыз әле, бер гаепсез кешене ничек интектерәләр! – диде Гөлнур, милиционерның бу матавыкка нинди мөнәсәбәттә икәнен аңлый алмыйча.

Минәзәл фуражкасын салып битен җилләтте.

– Аңлатыгыз әле, нәрсә бара монда? – диде ул, фуражкасын тир дымыннан бераз бүртебрәк киткән башына яңадан киеп куйгач.

Салих, гасабиланып һәм шул ук вакытта баяны табылудан сәер илһамлану кичереп, тизрәк аңлатырга ашыкты:

– Бу егет баян алып килде. Миңа сатарга. Ә бу баян – безнең клубтан урланган инструмент. – Кабаланып, калтырана-калтырана баянны боргалап күрсәтте. – Менә монда, яшерен урында үзем язган инвентарь номеры. Менә монысы кызымның сагызы ябышып бераз буявы купкан иде. Менә монысы – өстә, күректә томатный соус табы бар. Бер туйда шабашкада уйнаганда тамызган идем. Минем баян бу. Минеке! Исбатлый алам.

Локман усал һәм таләпчән тавыш белән Римгә җикерде:

– Казанда берәр туганың бармы?

– Әтием монда булырга тиеш, – дип борынынннан этеп чыгарды тоткын.

– Кайда ул?

Минәзәл милицияне катнаштырмый гына, үзара килешергә тәкъдим итеп, чыгып китәргә дип ишеккә таба юнәлгәч, Локман аның юлына аркылы төште:

– Юк, юк, китмисез! – Шуннан соң милиционерның моңсуланыбрак киткән чыраена бермәл карап торды. – Ә сез ник килгәниегез соң монда?

– Бу теге, Мамадыш күперендәге милиционер, – дип аңлатты Салих. – Хәзер Казанда хезмәт итә ул. Лейтенант ул хәзер. Минем янга килгәндер.

– Әйе, сиңа әйтәсе сүзем бар иде, – диде Минәзәл. – Ярар инде, чатка гармун уйнарга чыгарсың әле, шунда әйтермен.

Ләкин Локманнан ычкыну милиционерның хәленнән килмәде.

– Әлегә монда каласыз! – дип таләп итте Локман. – Мин – журналист, күп тиражлы гәҗиттә эшлим. Сүземне тыңлагыз, китмәгез! – Ул бөрешеп, кечерәеп калган бәйдәге бичарага таба борылды. – Атаңны кайдан табып була?

– Телефоннан шалтыратып, – диде егет тыңкыш тавыш белән. – Мобильнигым эчке кесәмдә.

Аның пинжәк кесәсеннән телефонын алгач, Локман инештән еракта, су күрмичә үскән каз бәбкәсенә охшап калган кызына бирды:

– Чулпан, җый атасының номерын!

Телефоннан элемтә оештырган арада, Минәзәл тагын чыгып китү ягын карады.

– Мин китим инде, – диде ул, чак кына ишетелерлек итеп. – Бу минем эшем түгел.

– Юк! Нәкъ милиция эше бу! – диде Локман, Минәзәлне кире борып.

Номерны җыйгач, Чулпан җәһәт кенә мобильникны егетнең колагына терәде:

– Сөйләш.

– Әти, бу мин, Рим! – дип мөгрәде әсир егет. – Әти, мине заложник итеп алдылар... Син монда килергә тиеш... Монда килгәч күрерсең... Мин баян алган идем бит базардан... Шуны миннән урлагансың дип талап алмакчы булалар... Кирәкми... Монда милиционер бар инде... Син үзең монда кил... Дөреслек урамы, утыз бишенче йорт, алтмыш дүртенче фатир... Минем куллар бәйләнгән... Телефонны да башка кеше тотып тора, мин сөйләшәм генә... Күп... Кил, сиңа тимиләр алар... Юк, юк, кирәк түгел... Монда башкарак ситуация... Ярар...

– Киләме? – дип кызыксынды Локман, Рим сөйләшүдән туктагач.

– Килә. – Ул соңгы чараны кулланып карыйсы итте – елап җибәрде. – Мин баянны сатып алдым!

– Егетне мыскыл итеп кеше көлкесенә калабыз бит! – дип өзгәләнде Гөлнур.

Әнисенең егет яклы икәнен аңлагач:

– Әти, җибәрегез Римне! – дип аяк терәп таләп итте Чулпан.

Локман тыныч, ләкин яман усал итеп ысылдады:

– Тик кенә тор! Алайса, хәзер сине дә бәйләп ташлыйм!

– Менә милиционердан сорагыз әле, гаебе исбатланмаган килеш кешене бәйләргә ярыймы? – диде Гөлнур, ачыргаланып.

Локман хатынына бульдог сыман өреп куйды:

– Клубтан баян урларга ярыймы, дип сора башта!

– А ты докажи, что это Рим украл! – дип чикылдады кызы.

– Исбатлый алмасам, гафу үтенермен, – диде Локман, кинәт тынычланып.

Күпмедер вакыт шулай әрләшеп, тарткалашып, Минәзәлне фатирдан чыгармыйча, Римне төрле сораулар белән йөдәтеп үтте. Ишек кыңгыравы зеңгелдәүгә, гәрчә сискәнеп китсәләр дә, барчасы сөенде шикелле.

Салих Казанга килгәч көтелмәгән вакыйгаларга күнегеп, хәтта могҗизаларга да исе китми башлаган иде. Әмма вә ләкин өйгә барлык хайваннарның врачы, бөек ветеринар, даһи санитар Мирза килеп кергәч, беркавымга урнашкан тынлыкта ул үзен төштә дип хис итте. Хәтта үләт базларында да, каргалар каркылдау сәбәпле, мондый тынлык булмый.

Мирза чак кына иеленкерәп исәнләште дә урындыкта каңгыраеп утыручы егеткә текәлде.

– Сез кем? – дип кызыксынды Локман.

Салих сөенеп аваз салды:

– Бу Мирза әфәнде! Исәнмесез, Мирза әфәнде! – дип, «профессор» белән кул биреп күреште.

– Теге үлгән профессормы? – диде Локман, чыраен сытып.

– Сез мине эзләп килдегезме? – диде Салих, шоп-шома елгада салларда агып барган әкияти халәткә кереп.

Мирза тоткын егет тирәли бер әйләнеп чыккач, коры гына:

– Мин улымны эзләп килдем, – диде.

– Нинди улыңны?!

– Аның малае бит бу! – диде Минәзәл, маңгаендагы тирен кул арты белән сыпырып.

Локман мыскыллы итеп елмайды:

– Шулаймыни?! Бик шатмын!

Гөлнур авызын җәеп елап җибәрде:

– Оят, хурлык!

– Ничек?! Бу синең улыңмыни? – диде Салих, елганың айкала-чайкала башлап, күңел салының янтаюын чамалап.

Рим чарасызлыктан кысылган тавыш белән:

– Әти, мин гаепле түгел! – дип ыңгырашты.

Мирза тешләрен шыгырдатып улына таба атлады.

– Нәрсә булды тагын синең белән, мөртәт?! – дип кизәнде ул. Рим күзләрен чытырдатып йомды, әмма әтисе сукмады. – Тагын нәрсәләр кылдың, хайван?!

Салих низаг тууга каршы иде. Баян табылгач, ул әллә нинди каракларны да гафу итәргә, кичерергә әзер иде. Ул хәтта Мирза малаеның клуб баянын урлаганы өчен үзендә дә бераз гаеп тойгандай булды.

– Синең улың Рим миңа баян тәкъдим итте... – диде ул шатлыклы тавыш белән. – Мин сатып алмакчы идем... Сез гафу итегез, Мирза әфәнде, ләкин бу баян минеке. Исбатлый алам. Минем клубтан югалган инструмент бу.

Җирнең түгәрәклеген без барыбыз да ишетеп, укып кына беләбез. Беребезнең дә аны күкләргә менеп күзәткәнебез, аның күкәйгә охшаганлыгын үз күзебез белән күргәнебез юк. Тик шулай да торымнан-торымга Җирнең шар формасында икәнлеген, кайларга гына чыгып китсәң дә барыбер кире әйләнеп кайтырга насыйп икәнне искәртеп, көтелмәгән һәм үз күзеңә ышанмаслык очрашулар даими рәвештә булып тора.

Гөлнур Мирзаны танып алды да әкрен генә аңа таба якынайды.

– Болар бит безнең авылга кайтып йөрүчеләр, – диде ул, кашларын борын өстендәге урталыкның бер ноктасына таба җыерып. – Болар бит Мулланурның туганнары. Кайда күргәнем бар бу егетне, дим... Сез бит Мирза абый!

– Әйе.

– Мулланур абыйның двоюродный браты.

– Дөрес, – диде Мирза, читкә карап.

Локман шундук нәтиҗә ясап куйды:

– Димәк, малае, авылга кайткач, клубтан баянны урлаган. – Ул кинәт Римгә таба борылды. – Соңгы тапкыр авылга кайчан кайттың?

Җавап ишетелми калды, чөнки Мирза сапер көрәге кадәр киң уч төбе белән газиз улының яңагына чабып җибәрде:

– Дуңгыз!

Яңак чапылдавыннан соң Чулпанның:

– Ужас! – дигәне ишетелеп куйды.

– Җәмәгать! – диде Мирза. – Әйдәгез, тавыш-тынсыз гына килешик.

– Синең чыраеңа карагач, һич кенә дә килешәсе килми, – дип ярдырды Локман.

Мирза серле итеп башын чайкады.

– Сердце татарина не скрипка, не надо играть. Миңа бик каты бәрелергә тырышма инде син, нәчәлник.

– Сиңа бәреләсе юк. Үзең бер бәрелерсең әле, – диде Локман, бүлмә буйлап йөри-йөри. – Тә-ә-ә-әк, баян табылды. Шул баян аркасында Салих атсыз калган... Будь добр, ат бәясен түлә!

Могҗизалар дөньясында инде шаккатарлык нәрсә дә калмады шикелле. Ә шулай да Мирзаның әйткәне могҗизага тиң иде:

– Атың миндә синең. Мурзиха авылының мал врачында ул. Шунда урнаштырдым. Хәзер шалтыратам мин аңа. – Мирза барсеткадан телефонын алып номер җыйганда, фатирда һәммәсе тораташ булып катып калды. – Алло! Сәгыйть! Ат синдәме? Теге, башындагы ак таплы яшь айгыр. Әнә, Вятка буеннан илтеп бирделәр бит сиңа... Ну... Качты?! Ничек? Утарны сикереп чыккан? Чын әйтәсеңме? Ярар, мин сиңа кич белән шалтыратырмын әле.

– Мурзихада... – дип мыгырдады Салих.

Мирза телефонын пинҗәк кесәсенә тыгып куйды, шуннан соң траурлы тавыш белән игълан итте:

– Җәмәгать! Ат качкан. Бер дә борчылмагыз. Түләрмен. Менә хәзер үк бераз наличными бирәм.

Ул биргән бер уч акчаны Салих шундук чалбар кесәсенә урнаштырды.

– Кеме генә юк бу дөньяның! – диде Локман, Мирзага җирәнеп карап.

– Кайткач, авылда безнең турыда сөйләмә, – диде Мирза Салихка. – Мулланур минем двоюродный туганым бит. Анда кайтырга ару булмаячак.

Локманның әле болай гына күнәсе килмәде:

– Ат өчен түләмәсәң, гәҗиттә язып чыгам. Катлаулы авылы җитәкчесенең туганы һәм аның малае фәлән-фәлән җинаятьтә чуалганнар, дип.

Мирза чыраена ясалма газап йөгертте:

– Татар йөрәге скрипкә түгел, уйнамагыз инде, зинһар. Түлим дигәч түлим инде, сез нәрсә. Минәзәл, минем әйткән сүземдә торучы кеше икәнне әйт әле шуңа.

– Түли, түли! – дип җөпләде милиционер, үзенең дә гәҗиткә эләгеп куюыннан шүрләп.

Салих, инде күп михнәтләр күрсә дә, авылча беркатлылыгыннан аз гына да арынмаган иде.

– Мин аңламыйм, ничек сез, профессор башыгыз белән... – дип, үзенең аптыравын белдерергә маташты ул.

Локман инде хәзер классташына да җирәнеп карады:

– Нинди профессор булсын ул! Күзеңне ачып кара!

Фатир хуҗасының бу сүзләреннән соң Минәзәл түзмәде, пырхылдап көлеп җибәрде.

– Мин аңламыйм, ник урладыгыз соң сез минем атны? – дип, Салих янә үзенең сабыйлыгын күрсәтте.

Мирза ничек булган, шулай әйтеп бирде:

– Ну, юл кырында ат йөри. Егетләргә куштым: «барыгыз, машина бәреп киткәнче, бу атны Мурзихага илтеп куегыз», дидем. Мин бит белмәдем синең Мулланур абыйның авылыннан икәнеңне.

Салихның тавышында ачулану һәм хөкем итү нотасы яңгырады:

– Ник, ә Мулланур абыеңның авылыннан булмаганны урларга ярыймы?!

– Нәрсә син аның белән сөйләшеп торасың, Салих?! – диде Локман нәфрәт белән. – Сез бит төрле планета кешеләре.

Салих, читенсенебрәк:

– Гаеп сездә бит, килешәсезме? – дип, Мирзага мөрәҗәгать итте.

Мирзаның яшәешкә үз карашы булганлыктан:

– Гаепсез кеше юк бу дөньяда, – дигән фәлсәфи ачыш ясады.

Минәзәл, фатирда ызгыш-талаш вә сугыш чыкмаганга чиксез куанып:

– Әйдәгез, килешегез инде, – дияргә ашыкты. – Баян табылды. Бераз акча тамызды. Ат бәясен түләргә вәгъдә итте. Үзем контрольдә тотармын. – Ул яп-якты итеп елмайды. – Минем бит сиңа, Салих абый, куанычлы хәбәрем бар. Шул хәбәр хакына җибәр син боларны. Түлисе бәяне түләрләр, түләрләр. Куанычлы хәбәрне әйтим инде тизрәк.

Салих, куанычлы хәбәрләргә бигүк күнекмәгән зат буларак, баян табылудан да зуррак шатлыкның килүен бөтенләй көтмәгән иде. Шул сәбәпле өсте-өстенә куанычлы хәбәрләрнең өелүе йөрәгенең урталайга аермагае дип пошаманга калды. Шыр сөякле, кәкре-бөкре бармаклы кулын күкрәкнең йөрәк турысына куйды да Мирзадан отып калган сүзләрне әйтте:

– Татар йөрәге скрипкә түгел...

– Башта бу малайны азат итегез инде, – диде Минәзәл.

– Чишегез, – дип ризалык бирде Локман.

Мирза улының кулларын кысып бәйләгән колготкины чишә алмый иза чикте.

– Ай-яй тыгыз бәйләгәннәр сине бу юлысы, – диде ул, ниһаять, төенне сүткәч. – Шакал! – Шуннан соң яшь каракның башына чәп итеп сукты. – Әйдә, эттән туган нәрсә! Бәреп кенә үтерәсе бар сине!

Ата белән ул чыгып киткәч, Гөлнур форточкаларны ачты. Һаваны җиңеләйтер өчен Минәзәл яхшы хәбәрне җиткерергә ашыкты:

– Салих абзый, теге мафиозник Гошаны Васильево поселогында атып үтергәннәр. Бик каты разборкалары булган. Шулай итеп, хәзер инде биш мең доллар түлисең юк.

Локман авылдашының иңенә шапылдатып сукты:

– Менә бит, Алла бар ул!

– Кеше үлгәнгә сөенмә инде, – диде Салих, ачуланып.

– Нинди кеше соң син! – диде Локман көлә-көлә. – Үзеңне үтерер иде бит ул.

Салихның кәефе кинәт күтәрелде:

– Чыннан да, Алла кушмаган эш юк. Баян табылды. Биш мең бурычым юк. Сөенергә кирәк, сөенергә. Мирза ат өчен түләр микән?

– Моны мин үз өстемә алам, – диде Минәзәл үтә җитди кыяфәт белән. – Мин ул кеше өчен бик күп яхшылык эшләдем һәм дә... аның турында мин бик күп беләм.

– Карале, профессор түгелдер ул? – диде Салих, уйга калып.

Аның бу соравына беркем дә җавап бирмәде. Локман гына, гасабиланып:

– Син кайчан дөньяга күзләреңне ачыбрак карый башларсың икән?! – дип куйды.

– Шулай да, Аллага шөкер, эшләр уңай якка борылып бара түгелме?! – диде Салих, йөзеннән шатлык нуры сибеп.

Минәзәл милиционер булуына карамастан, Салих алдында гафу үтенергә булды:

– Гафу ит инде мине.

– Син нәрсә, синең гаебең юк бит, – дип юатты аны завклуб.

Көтмәгәндә Гөлнур ирләрнең күңелләренә тулган шатлыкны юкка чыгарды.

– Сөенергә бик ашыкмагыз әле, – диде ул, шкафтан хат алып. – Менә Җәмиләңнән хат килде. Сиңа түгел, минем исемгә. Сиңа язып тормаган инде. Киткән ул синнән. Син кайткач, үзе разводка бирәчәк.

Минәзәл, кичекмәстән чыгып таю ягын карап:

– Минем кирәгем калмагандыр инде монда, – диде. – Киттем мин. Син кайгырма, хатын-кызның кире кайта торган гадәте бар аның. Минем үземнең хатын инде биш тапкыр китеп, дүрт тапкыр кире кайтты. Сау булыгыз!

Шул сүзләрдән соң милиционер чыгып китте.

– Күңелем сизгәние аны, – дип ыңгырашты Салих, әле күптән түгел баян карагы утырган урындыкка коелып иңгәч. – Мин бүген начар төш күргәнием. Имеш, мин йорт каршында басып торам. Ә Җәмилә, мин югалткан атка атланып, Казан тарафларына китеп бара. Мин нидер кычкырмакчы булам, әмма телем әйләнми. Артыннан йөгерергә телим, ләкин аяклар тыңламый. Куркып уянып киттем.

Салихның агарып катуыннан нык курыктылар. Локман, тынычландырырга ниятләп:

– Начар төш түгел бу, – диде. – Син югалткан атка атланып чыгып киткәч, ул бик ерак китә алмаячак, шулаймы? Син дә ул ат белән Вятка күпереннән арырак киталмадың.

Гөлнур:

– И кызганам шул Җәмиләне, – дигәч, Локман хатынына ашардай булып карап куйды.

– Гел Җәмиләне генә кызганасың син!

– Бер класста укыдык, дуслар идек, – дип сагышлы елмайды Гөлнур. – Салих бит, ни дисәң дә, ир кеше. Хатын-кызга авыррак.

– Болай да тормышның рәте юк иде, хәзер инде тәмам җимерелде, – диде Салих кичеп чыккысыз газап белән.

– Татулашырсыз әле, – диде Локман, якташының җанына өмет сулышы өрергә теләп. – Ат шикелле эзсез югалмас хатының. Хатын-кыз ат түгел ул. Менә акча сорап уннан артык фирмага мөрәҗәгать иттем: Катлаулы авылының мәдәниятенә ярдәм итәргә кирәк дип. Кайберсенә синең проблемаңны, синең вакыйгаңны, синең халәтеңне сөйләдем. Ярдәм итәрбез, диделәр. Шуларның берничәсе генә булышса да, шәп булачак бит.

– Акча ник кирәк миңа хәзер?! – диде Салих, күз яшен җиңе белән сөртеп.

– Акчаң булса, бер кайгың да кайгы түгел, хәтта хатынның китүе дә. Борчылма, барысы да рәткә керер дип ышаныйк.

– Ышанып кына... – дип, Гөлнур үзенең килешмәвен белдермәкче иде, тик җитешә алмады, ире кычкырды:

– Тик кенә тор! Ышанычны да югалтсаң, яшәүнең мәгънәсе каламы соң?! – Локман кинәт ясалма ягымлылыкка күчте, тавышында үчекләү яңгырады. – Ну ничек, хатын, Чулпанның хәлле егете ошыймы соң хәзер сиңа? – Шуннан соң кычкырып эндәште: – Чулпан, кил әле монда!

Күрше бүлмәдән елап шешенеп беткән Чулпан чыкты:

– Нәрсә?

– Акчалы, булдыклы егетең шушымы синең, кызым?

Чулпан, башын иеп торганнан соң:

– Ну ладно, пап, че ты издеваешься! – диде.

Локман кызын кочаклап алды:

– Елама, кызым, тынычлан.

Әтисенең назыннан Чулпан тагын мәлҗерәде, яңа көч белән еларга тотынды, кочактан шуып чыгып, янә күрше бүлмәгә кереп китте.

Ата кеше рәхәтләнеп көләргә тотынды:

– Хәерче кирәк түгел, ха-ха-ха! Булдыксыз кирәк түгел, акчасыз кирәк түгел! Ә мондый кирәкме? – Аннары, җирәнеп, иреннәрен чалышайтты. – Рим! Исеме исем түгел!

– Ярар инде, үз кызыңнан үзең көлмә! – диде Гөлнур җан ачысы белән.

– Мин кызымнан гына түгел, күбрәк синнән көләм!

– Кемнең кем икәнен алдан каян беләсең! – дип акланды хатын.

– Кешенең чыраена язылган кем икәнлеге – укый белергә генә

кирәк! Кешене кешедән аера белер вакыт җитте сиңа да, хатын! Иллегә таба китеп барасың бит инде, кәкре-бөкре аякларың белән титак-титак атлап.

Иренең бу сүзләре Гөлнурны чыгырыннан чыгарды. Ул:

– Оятсыз! – дип, күрше бүлмәгә, кызы янына кереп китте.

– Кайгырма, Салих! Гел кара полоса гына булмый тормышта. Синең бит бер кешегә дә начарлык эшләгәнең юк. Мәктәптә укыганда да класста иң тыйнагы, иң тәртиплесе син идең бит. Әле беркөнне Гөлнур да шулай дип утырды. Шуңа күрә синең тормыш барыбер бер җайланып китәчәк. Син бит якты тормышка лаеклы. Ә бит тирәнрәк уйлап баксаң, иң мөһиме шул – лаеклы булу! Бәхеткә лаеклы булу – үзе бәхет, хәтта бәхетнең үзен күрмәгән сурәттә дә.

* * *

Баян белән зур сумка күтәреп, Салих туган авылына кайтып җитте. Этләр авылга кергән кешене әллә танымыйча, әллә завклубның авылга исән-сау кайтып керүен өнәмичә, әллә аның озакка югалып торганына ачуланып ярсып-ярсып өрергә тотындылар. Эңгер-меңгер вакыт булганга күрә йортлар ут алган, Салихлар йортының гына тәрәзәләре сукыр иде.

Капка шыгырдап ачылды, каралты-кураның таныш исе йөзгә сыланды. Өй бикле, ачкыч гадәттә яшерелә торган урында иде.

Ул бик озак вакыт ишек катында кымшанмыйча басып торды. Авыр тынлык. Нишләп болай соң бу? Нигә язмыш инде яшәү җайга килә дигәндә генә бар нәрсәнең мәгънәсен югалта соң? Гомумән, бар микән соң яшәүләрнең мәгънәсе?!

Баянны, сумканы идәнгә куеп, өй эченә узды. Киткән Җәмилә. Чынлап та киткән. Анасындадыр инде. Тагын барып ялынырга, ялварырга, гафу үтенергә, тәүбә итәргә кирәкме? Бу юлысы инде кире кайтмас ул.

Салих өй түрендәге урындыкка барып утырды. Газапларның бетәсе юк икән. Яңа сынау көтеп яткан монда. Озак утырды ул тәрәзәдән караңгы өй эченә саркыган ай яктысында.

Өйалдында кемдер барлыгын ишеткәч, ул сискәнеп китте. Кем икән? Ишек ачылды. Сулы чиләкләрнең идәнгә куелганы ишетелде. Кече якта ут кабынды.

Урта ишек ачык иде, Салих хатынын аермачык күрде. Җәмилә! Колонкага суга барган! Салих әкрен генә торып басты.

– Ишекне бикләргә оныткаммын икән, – диде Җәмилә үзалдына. – Әй бу хәтер, хәтер, – дип, суны мич янына илтеп куйды, баян белән сумканы күреп сискәнеп китте.

Хәер, аларны абайламаган сурәттә дә аның күңеле инде зур вакыйгага буласын сизенгән иде. Ул, аяк очларына гына басып, олы якка таба юнәлде. Түрдәге шәүләне күргәч, ни гаҗәп, сискәнмәде, өркемәде, үрелеп, ишек кырындагы өзгечкә басты. Йөз иллеле лампочка бөтен дөньяны яктыртып җибәрде.

Күзләре чагылудан чеꞏләеп торган хатынына Салих ишетелер-ишетелмәс кенә эндәште:
– Җәмилә!
Ул ирен таныды. Тик менә Җәмиләнең беркайчан да якын кешесе белән озак вакыт аерылышып торганы юк, шул сәбәпле бу мизгелләрдә үзен ничек тотарга, ни әйтергә кирәклекне белми иде.
– Мин, – диде Җәмилә, сулыгып беткән йөзен кечкенә, ләкин авыр эштән катыланып беткән кулы белән сыпырып куйгач. – Ә син Салихмы?
Салих хатынына таба атлады:
– Әйе, танымыйсыңмыни?
Алар бик озак бер-берсеннән күзләрен алмыйча, ни әйтергә белми аптырап тордылар.
– Кая югалдың син? – диде Җәмилә хәлсез тавыш белән.
Салих хатынының ябыгып, агарыбрак калуыннан куркып китте.
– Казанда идем, – диде ул, нишләргә белми як-ягына каранып. Ул да мондый вакытта үзен ничек тотарга кирәклеген белми икән ләбаса.
– Чынлап та Казанга мең яшьме? – дип сорады Җәмилә, алдындагы бер ноктага карап.
«Казан» сүзен ишеткәч, Салихның күңел океанында зур-зур дулкыннар күтәрелә башлады.
– Бардыр, – диде ул, күзләрен акайтып. – Бик шау-шулы, ыгы-зыгылы шәһәр ул. – Салих Казанның зурлыгын, бөеклеген ничек тасвирларга белми торды, аптырагач, бармагын өскә күтәреп әйтеп куйды: – Анда бер өчпочмак егерме дүрт сум тора. Шул олы яшьтәге шәһәр булганга шулай кыйммәт бит анда өчпочмаклар, пәрәмәчләр!
– Ошадымы соң Казан? – дип сорады Җәмилә, чак кына ишетелерлек итеп.
– Юк! – дип кырт кисте Салих. – Анда син булмагач, бер яме юк аның.
– Ошагандыр. Ошамаса, болай озак кайтмый тормас идең, – дип ыңгырашты Җәмилә.
Салихка җан керде:
– Син ничек соң монда?
– Элеккечә, бернинди үзгәрешем юк, – диде хатын, иренең килеш-килбәтен башыннан аягына кадәр күзәтеп. – Син менә үзгәргәнсең.
– Кайсы төшем үзгәргән? – диде Салих.
– Әллә тагы... Городскойланып киткәнсең бераз.
– Юкны сөйләмә инде.
Йоклап яткан вулкан да бервакытны бәреп чыга. Ә сагынучы хатынның күңеле аның вулкан гынамы соң сиңа!
Җәмиләнең:
– Салих!– дигән авазы бәгыреннең иң тирән төпкеленнән аты-

лып чыкты. Ә бит авыл хатынының бәгырь тирәнлеге әлегә кадәр беркемнең үлчи алганы юк. Тау башы урамындагы коедан да тирәнрәк бит ул татар хатынының бәгырь тирәнлекләре!

– Җәмилә!

Алар, кинәт бер-берсенә ыргылып, кочаклаштылар, гүя икедән бергә әверелделәр.

– Кая югалдың син? – дип елады Җәмилә, иренең кочагында изрәп. – Инде үзем сине эзләп чыгып китмәкче идем. Гөлнурларга гел хат язу да яхшы түгел, кешедән читен.

Салих хатынын катырак кысты:

– Син мине ташлап киттеңмени?

– Кая китим мин... инде бу яшьтә?! Юри яздым син тизрәк кайтмассыңмы дип. Инде әллә ниләр уйлап бетердем, анда берәр марҗага йортка кергәнсеңдер дип тә шикләндем.

Салих көлеп җибәрде:

– Кемгә кирәк мин... инде бу яшьтә.

– Алай димә. Баянда уйнаганыңны ишетсәләр, теләсә кем кертер, – диде Җәмилә, лышык-лышык борынын тартып.

– Мин сине шундый сагындым! – диде Салих.

– Мин дә сине сагындым! – Җәмилә иренең җилкәсен капшады. – Бигрәк нык ябыккансың.

– Әле ничек исән калдым.

Җәмилә, быдыр-быдыр сөйләшеп, ирен диванга утыртты, тиз генә таз белән җылы су алып килеп, аның аякларын юды, чипчиста сөлге белән сөртеп, өр-яңа оекбаш кигертеп куйды.

– Тиздән Миләүшәбез кайта, – диде Җәмилә, плитәгә җылытырга куелган ботканы болгатып.

– Син аңа хатта язмагансыңдыр минем маҗараларны?

– Юк, юк, язмадым.

– Кил әле, карчык, монда, аннары ашарбыз.

Җәмилә ире янына диванга килеп утырды. Уңайсыз тынлыктан арынырга сүз тапмагач, ул, алъяпкычының итәген йомарлап:

– Киләсе атнада Сабантуй, – диде.

– Ай-яй, вакыт тиз уза, – диде Салих, тирән сулап.

– Мулланур абый да сине бик юксынды. Инде мин аның белән әйбәтләп сөйләштем: ат өчен аз-азлап түләрбез, срогын да билгеләмәскә тиеш, хәлегездән килгәнчә түләрсез, диде. Алай бик каты ачуланмый инде ул сине хәзер.

Салих кул селтәде:

– Түләп бетерербез әле ничек тә.

– Әйдә ашыйбыз.

– Нинди ашау, Җәмилә! – диде Салих, үзенең бәхетле икәнен аңлап. – Шулкадәр сагындым сине. Бергә чакта гына аңламыйсың шул бер-береңә кирәклекне.

– Казан ничек анда?

«Казан» сүзен ишеткәч, Салихның чырае үзгәрде, башта бераз бөкрәйде, аннары кинәт гәүдәсен турайтты:

– Анда бөтенләй башка дөнья, Җәмилә! Казанга мең ел түгел, йөз мең ел булса да риза мин.

Җәмилә, күзләрен чекерәйтеп, иренең өс-башын күзәтте.

– Яңа кәчтүм алган... – диде ул, әйткән сүзенә үзе генә аңлый торган мәгънә салып. – Син анда Казан хатыннары белән чуалмый калмагансыңдыр.

Салихның ачуы чыкты:

– Таптың сөйләшер сүз! Син нәрсә инде!

– Ярар, ярар.

Салих җәһәт кенә сумканы алып килде, аннан төрле бүләкләр чыгарырга тотынды:

– Сиңа да бүләкләр алып кайттым, кызыбызга да.

Җәмилә хатын-кызның гел телендә яши торган сорауны бирде:

– Акча каян алдың?

– Ат өчен Мирза бирде. Калганын соңрак түләрмен, диде. Уйлап-уйлап тордым да, әй, төкеримсәнә дип, ул биргән акчага сезгә бүләкләр алдым.

Шуннан соң ул ике кофта, ике чуар яулык, күлмәк, бер флакон хушбуй алып, хатынына тоттырды, аннары аның күктән төшкән бәхет тәэсирендә әйләнгән башына чәшке бүрек кигертеп куйды. Тагын әллә нәрсәләр, әллә ниләр чыкты сумкадан.

Җәмилә: «Сөбханалла!» – дип, ким дигәндә ике йөз мәртәбә әйтеп, көзге каршында бөтерелде. Әле кофтаны түшенә куеп карады, әле яулыкны әйләндергәләде, әле хушбуйны ачып иснәде. Иң ошаганы күлмәк булды.

– Мондый бүрекне куркынычтыр бит киеп йөрергә, – диде хатын шомлы тавыш белән. – Аны караклар салдырып алмасмы соң?

– Караңгы төшкәч кимәссең, көндез генә киярсең, – диде Салих. – Төнлә үзем киярмен.

Җәмилә:

– Ярар, – диде дә, йөгереп килеп, рәхмәт йөзеннән ирен кочаклады. – Ярый син бар әле дөньяда! Минем гомергә мондый матур кием кигәнем юк бит. Болай ук расходланасың калмаган.

Салих, тар гына күкрәген горурлык белән киереп, тантаналы рәвештә әйтте:

– Ничек инде мин Казан хәтле Казанга барып бүләксез кайтыйм ди.

– Рәхмәт яусын!

– Миләүшә Сабантуйга кайтамы?

– Сабантуйдан соң гына кайтыр, мөгаен. «Имтихан вакытына туры килә» дип язган.

– Хатын, Локманнар кайтуы ихтимал. Бездә кунак булырлар инде, яме.

– Бездә булмый, кемдә тукталсыннар инде алар, – диде киң күңелле хатын, Казаннан кунаклар кайтасына ихластан сөенеп.

Салих Казанга киткәннән бирле майланмаган ишек питләсе

имәнгеч тавыш чыгарды, ишек каерылып ачылды, һәм бәйрәм шаукымы хөкем иткән өйгә Мулланур аяк басты. Фуражкасын салгач, ул бик озак, җитди итеп карап торды.

– Исәнме! – диде ул, ниһаять.

– Исән, – диде Салих. – Үзең исән-саумы?

Кул биреп күрешкәндә, Мулланур:

– Кайттыңмы? – диде. Кешегә җылы сүз әйтү гадәтенә ия булмаган Мулланурның шушы сүзе дә йөрәккә сары май булып ятты.

– Кайттым, – диде Салих серле тавыш белән, әйтерсең лә ул чиксез космосларны айкап, галәм киңлекләреннән әйләнеп кайткан иде. – Җәмилә, син, бар, чыгып тор әле.

Җәмилә:

– Ботка җылынды, – дип, ишегалдына чыгып китте.

– Мин сиңа хәзер барысын да сөйлим, – диде Салих. – Кинодагы сыман мажаралар килеп чыкты бит.

Мулланур, өстәлдә, диванда, урындыкларда яткан бүләкләрне карый-карый:

– Сөйләп тормасаң да була, – диде. – Барысын да беләм.

Салих сагайды:

– Нәрсәне беләсең?

– Бөтенесен дә беләм, – диде Мулланур бөтенләй аңа хас булмаган басынкы тавыш белән. – Миңа Мирза шалтыратты. Син Мирза турында, аның улы Рим хакында авылда беркемгә дә сөйләмә инде, хәтта хатыныңа да. Мирза минем двоюродный туганым бит. Ул гомере буе зимагурлыкта йөрде. Үзе бик башлы ул, зараза, әмма һич кенә дә пүтле тормыш алып бармады. Әллә нинди шуллер булды, бернишләтә алмыйсың. Алар монда кайткалап йөриләр. Хәтерләмисең генәдер. Малаеның да кайтканы бар.

– Баянны шул урлаган инде.

– Бәлки, шулдыр... Белмим... – дип ык-мык килде авыл җитәкчесе. – Тик син оныт инде бу турыда. Мирза да бик үтенә, «Салих берүк хурламасын инде» ди.

Салих гәүдәсен турайтты:

– Ат өчен түләтмисеңме соң?

– Юк инде. Син гаепле түгел бит. Списать итәрбез. Безнең үзебезнең дә мал врачыбыз бар лабаса. Безнеке профессор түгел, әлбәттә, ә шулай да бер атны списать итәрлек кенә башы бар. – Аның йөзе караңгыланып китте. – Мин начар төш күрдем бит әле.

– Нинди төш?

– Минем төштә, имеш, Конюх Вахит абый төш күреп ята икән, – диде Мулланур, авыр сулап. – Аның төшендә, имеш, конюшнядан ат югалган.

– Шул мин югалткан атны күргәндер төшендә, – дип тынычландырырга тырышты Салих төшенкелеккә бирелеп баручы авыл җитәкчесен. – Гел-гел ат югалып тормас әле.

– Ярар инде, – диде Мулланур эшлекле кыяфәт белән. – Ял ит. Тиздән Сабантуй. Сиңа эш күп булачак. Борчылма, тынычлан, ял ит.

Мулланур чыгып киткәч, Салих телевизорны кабызды, тавышын каты иттереп ачты. Алып баручы – кызмы, егетме – тамашачыларга чираттагы хатны укырга тотынды:

– Безнең тапшыруга бихисап күп хатлар килә. Укып бетерерлек түгел. Менә шуларның берсе. «Минем хәтерем начар, – дип яза Халидә апа Әгерҗедән. – Хәтерем шул келтер-келтер җырлар аркасында бетте дип саныйм. Җырга гашыйк кеше буларак, яңа чыккан җырчыларны, аларның җырларын истә калдырырга тырышып зиһенем чуалды, дәвалаучы табибым әйтмешли, психикам чалышайды. Һич савыгып булмый, чөнки дәвалаучы врачым да үзешчән композитор һәм җырчы булып чыкты. «Күрәчәкне күрмичә, гүргә кереп булмый» ди халык. Үзебезнең авылда да хәзер җырчылар күп. Җырчы түгел кешеләр авылыбызда хәзер дүртәү генә калдык: мин, Гарифә әби, Гакыйф малае Рәсим, Самат абый. Мин хәтерем булмаганга җырлый алмыйм, Гарифә әбигә туксан дүрт яшь, ул хәзер җырлау түгел, елый да алмый инде. Гакыйф малае Рәсим – тумыштан телсез, шул сәбәпле беркайчан да җырчы булмаячак. Самат абый сәвит заманында палитический җыр җырлап биш ел төрмәдә утырган булган, аны хәзер үтерсәң дә җырлатып булмый. Безнең өчен – җырламаучылар өчен – берәр җыр тапшырсагыз иде».

Кызларга охшаган бер егет, аяк очларына баса-баса, җыр сузды. Җыры тозсыз-моңсыз-мәгънәсез булып чыкты, вәләкин бу минутларда өйгә нинди аваз тулса да, җанга ятышлы иде, бу мизгелләрдә яктылыкка сусаган күңел дөньяның һәр авазын, һәр сызыгын кабул итәрлек күтәренкелектә иде.

* * *

Иртәгә Сабантуй дигән көнне Казаннан авылга Локманнар гаиләсе кайтып төште. Бөтен дөньясы аһ-ваһлар, кочаклашулар, күз яшьләре, көлешүләр, кыскасы, шатлыклы ыгы-зыгы астында калды.

Җәмиләнең күзе Гөлнур белән Чулпан тоткан күчтәнәчләргә төшсә, Салихның карашы исә Локман кочаклаган баянга кадалды.

Хатын-кыз күчтәнәчләр белән табын тирәсендә бөтерелгәндә, Локман тантаналы тавыш белән йортны яңгыратты:

– Салих туган, мин мөрәҗәгать иткән ун фирманың дүртесе сиңа ярдәм кулын сузды. Менә сиңа дүрт конверт, дүртесендә дә акча. Теләсә ничек тот. Бер сәүдә йорты сиңа яңа баян бүләк итә. Ал!

Локман акчаны Салихның кулына тоттырды, баянны түргә илтеп куйды. Бу кадәре акчаны берьюлы кулында гомерендә дә тотып карамаган Салихның күзләре тонды.

– Болай булса, ат өчен үзебез дә берьюлы түли алачакбыз, Аллаһы боерса, – диде ул, читенсенеп кенә. – Ул фирмалардан акча алу дөресме соң, уңайсыз бит?

– Уйлама юк-барны, анысы синең эш түгел. Юкка картая торган гадәтеңне кайчаннар ташларсың икән, кордаш?! Һимаячелек дип атала ул. Мин гәҗит битендә мөрәҗәгать бирдем, алар ярдәм иттеләр. Тәртип!

– Баяным бар бит инде... – диде Салих, комсыз булып күренүдән куркып.

Локман авылдашының иңенә төртте:

– Нинди кеше соң син! Рәхмәт әйт тә ал! Менә иртәгә Сабантуйда яңа баянда сыздырасың инде!

Йорт каршына җиңел машина килеп туктагач, Салихның йөрәге жу итеп куйды. Ике баян һәм бу кадәре акча өчен җавапка тартмагайлары! Машинадан берәү чыкты да, чемоданга охшаган нәрсә күтәреп, Салихларның капкасына таба юнәлде. Таныш кешегә охшаган...

Әйе, чыннан да таныш кеше булып чыкты – затлы футлярлы баян кочаклап, Минәзәл килеп керде. Ул тирләп беткән һәм ешеш сулый иде. Аның монда килеп җитүе бер могҗиза булса, икенче могҗиза – аның кочагындагы баян иде.

– Нәҗмиевләр йортымы бу? – диде ул, көчкә сулыш алып.

Салих аңа таба атлады:

– Әйдә, әйдә, кер, Минәзәл, безнең йорт бу.

– Менә баян алып килдем, – диде Минәзәл гомерендәге иң мөһим бурычын үтәгән кыяфәт белән.

– Нинди баян соң бу? – диде Салих, баяннар күбәюдән шүрләп.

– Сиңа, Сабантуйга бүләк итәргә дип, махсус алып килдем. Конфискованный.

Минәзәл идәндә янәшә торган ике баянны абайлап, үзе алып килгән баянны да шулар янына китереп куйды.

Милиционер, табынга чакырулары өчен рәхмәт әйтеп, үзенең туган ягына – Зәенскигә Сабантуйга кайтып барышлый керүен аңлатып, машина көтеп тора, шоферның да әле үз авылына кайтасы бар дип, барчасына исәнлек-саулык теләп, капыл гына чыгып та китте.

Салих, аның артыннан ияреп, «кирәк түгел бу баян» дип тә карады, «Минем бит хәзер өч баяным була» дип зарланып та алды. Әмма Минәзәл тыңларга теләмәде, машинага утырды, елмаеп кул болгады, шуннан соң машина, тузан туздырып, урам чатында юкка чыкты.

Җәмилә кунакларга тавык шулпасы бүлгәндә, ишек тагын каерылып ачылды.

Бусагада бу кеше пәйда булыр дип кемнәр уйлаган! Аның бер култык астында каты кәгазьле зур төргәк, икенчесендә баян иде.

Мирзаны күргәч, Салих үзе өчен хәл итә алмый торды – сөе-

нергәме яки көенергәме? Көтелмәгән кунакның тикмәгә йөрмәгәне кыяфәтеннән үк аңкып торганга, өйдә тынлык урнашты.

Локман үзе дә сизмәстән афоризм әйтеп куйды:

– Чакырылмаган кунак чакырылганыннан да яманрак!

Мирзаның бу юлысы яхшы ният белән килгәнен әүвәле Локман чамалады һәм сөенечтән яңгыратып көлеп җибәрде. Аңа кушылып Чулпан кул чәбәкләргә тотынды. Гөлнур белән Җәмилә генә әллә аңламыйча, әллә бернәрсә дә аңларга теләмичә карап утырдылар.

Мирза, чакыруны көтеп тормыйча, түргә узды, төргәкне өстәлгә куйды, янәшә торган өч баянны күреп, үзенекен дә шулар янына урнаштырды.

Хәзер инде Салихның гади генә йорты дүрт баянлы йортка әйләнде.

– Җәмилә, таныш бул, бу – теге профессор, доктор наук, мал врачы, – диде Салих.

– Исәнмесез! – диде Җәмилә, бу профессор монда да әллә нинди кәнәтилләр оештырып китмәгәе дип куркып.

– Менә миннән сиңа баян, – дип, инструментка ымлады мал врачы. – Шуннан соң куен кесәсеннән бер пачка акча чыгарды. – Монысы – ат өчен.

– Кирәк түгел бернәрсәң дә! – диде Салих, котсыз калып.

Әмма дә ләкин Локман каты итеп боерды:

– Кирәк! Баян да кирәк, акча да кирәк! Ал!

Локман үзе Мирзаның кулыннан акчаны йолкып диярлек алып, Салихка тоттырды, барып, баяннарны тигезләп тезеп куйды.

– Ә монысы нинди төргәк? – дип сорады Салих.

– Тозлы балык. Тәтештәге дусларым биреп җибәргәннәр.

– Кирәк түгелие... – диде Салих, тәмам югалып.

– Кирәк! – диде Локман.

Мирза, кулын йөрәк турысына куеп, акланырга тотынды:

– Салих туган, мин синең Мулланур җитәкче булып эшли торган авылдан икәнеңне белгән булсам... ни... белмәдем бит.

– Ярар, ярар, – дип бүлде аның сүзен Локман. – Татар йөрәге скрипкә түгел, Мирза, уйнама! Сабантуйларың мөбарәк булсын!

– Син теге... ни... артыгын кыланма инде... – диде Мирза Локманга ачусыз-нисез генә. – Дөнья бу. Барыбыз да җирдә йөрибез. Бәлки әле, тагын очрашырга туры килер.

Аны әдәп өчен генә табынга чакырдылар, ләкин Мирза баш тартты, рәхмәт әйтеп, Сабантуй вакытында эшләре муеннан икәнен аңлатып чыгып китте.

Салих, әле кулындагы акчага, әле баяннарга карап:

– Болай ярамас бит, – диде.

Бу юлысы Гөлнур сүз катты:

– Биргән нәрсәдән баш тарта торган заман түгел!

Җәмилә иренең артык тыйнаклыгыннан, чамадан тыш намус-

лылыгыннан инде яши-яши туйган иде. Кунак барда тавыш-тын чыгармый торганлыгын онытып, ул да:

– Гөлнур белән Локман белми әйтмәсләр, алар кушканча эшлә инде син, – дип куйды.

– Синең баяннарың хәзер урлап бетерерлек түгел, – дип шаярды Локман.

Салих күктән төшкән бүләкләргә карады:

– Әйтмә дә генә! Кайсысында уйнарга белгән юк!

Бәйрәм өстенә бәйрәм килгәнгә чиксез куанып, аннары дөнья хәлләрен сөйләшеп, хатирәләргә бирелеп, Җәмиләнең аш-суга осталыгын мактый-мактый ашап-эчеп утырганда, Мулланур атылып килеп керде:

– Саулармысыз! Кунаклар бар икән. Исән-сау гына кайтып җиттегезме?

Аның ниндидер шатлыклы хәбәре барлыгы сизелеп тора иде.

– Бик әйбәт кайттык, – диде Локман. – Туганыңны күрдеңме соң?

– Күрдем, – диде Мулланур, чыраен сытып.

Табынга кыстауларына бөтенләй игътибар итмичә, Мулланур берничә адым алга атлады, чынбарлыктан аерылыбрак киткәндәй, өйнең үзе генә күрә торган кайсыдыр бер төшенә карап:

– Җәмәгать! – диде. Аның иреннәре дерелди, ияге калтырана башлады. – Җәмәгать! Ат кайтты!

Табындагылар барысы да сикереп тордылар.

– Нинди ат?

– Ат үзе кайтты! Бичаракаем, туган җир туган җир шул. Кайткан! Салих, ишетәсеңме, ат кайткан! Син югалткан ат, кайтып, ат абзары тирәсендә йөри. Утар ишеген ачкач, үзе кереп китте.

Салих өйдәгеләрнең һәммәсен кочаклап чыкты.

– Әй, бичара малкай, ничек юлны тапкан диген син! – диде ул, күз яшен учы белән сыпырып.

– Ничек адашмаган! – диде үз гомерендә район үзәгеннән дә арырак бармаган Җәмилә.

Гаҗәпләнүнең, соклануның, шатлыкның чиге булмады:

– Ат кайткан! Ат кайткан!

– Алланың рәхмәте төшкере!

– Җаныкаем, ат кайткан!

– И-и малкай! Һәй, акыллы ат икән үзе!

– Ат кайткан!

– Мин утырып тормыйм инде, – дип, табынга сөйрәүләренә аяк терәде Мулланур. – Эш күп. – Аннан, Салихны беләгеннән тотып, ишек катына алып китте. – Син миңа рәнҗисеңдер инде?

– Рәнҗемим, – диде Салих ихлас күңелдән. – Син ат биреп тормаган булсаң, мондый бәйрәм тәтер идемени?!

Мулланур, күзләрен акайтып, тагын бер кат:

– Ат кайтты! Үзе кайткан! – диде дә, барчасына саулык-сәла-

мәтлек теләп, бәйрәмнәр мөбарәк булыр дигән ышаныч белән чыгып китте.

Атның үзе кайтуына шаккатып туймадылар. Атның акыллы хайван икәнен, Салихның бәхетле кеше булуын кат-кат кабатладылар. Җәмилә үзенең кинәт туган фикерен кыстырып куйды:

– Нәрсәсенә гаҗәпләнәсез?! Казан хәтле Казаннан минем Салихым кайтканны, ат кына кайтыр инде ул!

Шаярырга исәп итмәсә дә, аның әйткәне бик кызык килеп чыкты, табындагылар рәхәтләнеп көлделәр.

Салих дүрт баян арасыннан үзенекен алып килде. Бармаклар баян телләренә тияр-тимәс йөгерделәр. Күзләр йомылды. Тәннәр чемердәп китте. Татлы сагыш вөҗүдкә сарылды. Өйдә акыл чикләренә сыймый торган, җанга ятар сихри аһәң туды.

Бу көйдә сагыш белән моң да, дәрт белән дәрман да бар иде.

Бу уйнап-җырлап туйгысыз нәгъмәдә үпкә-нәфрәт тә, шул ук вакытта әйтеп бетергесез чиксез рәхмәт тә яңгырады.

2001– 2007

ХИКӘЯЛӘР

НАРКОКУРЬЕР

Мидхәт өйалды баскычына утырып, үкчәләре ашалып беткән ботинкасын киеп маташканда, сарайдан, таз күтәреп, хатыны Мәрзия килеп чыкты.

Хатын, тазны җиргә куеп, иренә таба ямьсез караш ташлады:

– Тагын балыкка җыендыңмы?!

– Күрмисеңмени, – диде Мидхәт, хатыны күргәләгәнче чыгып шылмаганына үкенеп.

Мәрзия ишегалды аркылы сузылган баудан ычкынып җил белән очып китәргә талпынган керләрне капшарга тотынды.

– Башка ирләр шабашкага йөриләр, акча эшләү ягын карыйлар.

– Мин шабашник түгел, – диде Мидхәт, үзенең шабашник түгеллеге белән ихластан горурланып.

– Болай яшәргә дә ярамый инде, – диде Мәрзия, иренә таба атлап. – Әнә кара, әллә кайлардан килеп коттеджлар салып яталар.

Мидхәт бакча артында калыккан чит-ят коттеджлар тарафына карады:

– Мин дә салыр идем. Вәләкин урлый алмыйм. Авылда эш булмаганга да, авыл хуҗалыгы таркалганга да мин гаепле түгел.

– Барыбер нәрсәдер эшләргә кирәк, – диде Мәрзия, тавышын күтәрә төшеп. – Кешедән оят. Ботинкаңа кара әле. Балыкка да, бәйрәмгә дә, мал арасына да, шәһәргә барганда да шул бер ботинканы киясең.

Мидхәт гомер юлыннан атлап алҗыган аягындагы кыршылып-таушалып беткән ботинкаларга беравык карап торды. Аяк киеме, чыннан да, ахыр чиккәчә иске иде. Инде сул аягыныкы бераз «авызын» да ачкан. Ул, бер сүз дәшми, капчыгын иңенә асты һәм, хатыны тагын берәр җан әрнеткеч сүз катканчы, коймага сөялгән кармак таягын алып, капкадан капылт кына чыгып китте.

Мәрзия, булдыксыз ирен сүгә-сүгә, нәрсәгә тотынырга белми ишегалды буйлап беркавым әрле-бирле йөргәннән соң, быдыр-быдыр килеп, тормыштан зарланып, керләрне җыя башлады.

Елга буена таба сузылган борма-борма юлдан атлаганда, Мидхәт үзенең чынлап та мескен хәлдә икәнлеген уйлады. Илле дүрт яшендә генә булса да, эшсез калды, акча юк, бәяләр көн саен артып тора. Тырышып-тырмашып ике бала үстерделәр – кыз белән малай, икесе дә калада, заводта эшлиләр, аларны башлы-күзле итәсе

бар. Алар атна саен кайта, биреп җибәрергә бәрәңге белән суганнан башка нәрсә юк.

Мидхәт, ярда урнашып, кармагын салды.

Чиртми. Калкавыч хәтта янтаймый да. «Безгә балык эләкми...» дигән татар халык җыры исенә төште аның.

Бервакытны якында гына алагаем зур затлы машина килеп туктады. Джип эченнән, башта чыр-чыр килеп, әле кычкыра-кычкыра, әле җан биздергеч тавыш белән көлә-көлә сап-сары чәчле кыз атылып чыкты, аннары рульдә килгән егет аны куарга тотынды.

Алар, балыкчыга бөтенләй игътибар итмичә, янәшә генә диярлек чишенделәр. Егет белән кызның су кергәнен Мидхәт сүгенә-сүгенә күзәтеп утырды. «Майларына чыдый алмыйлар. Япь-яшь килеш коттеджлар төзиләр, иномаркаларда йөриләр. Каян килгән боларга ул кадәр акча? Ничек шулхәтле урлый алалар болар?!»

Мидхәт аларның ярдагы киемнәренә игътибар итте. Аның күзенә джипта килгән егетнең затлы ботинкасы чалынды. Мәрзиянең битәрләгәне искә төште. Үпкә-нәфрәт хисе үзәктән чыгып, бөтен гәүдә буйлап салкын дулкын булып йөгерде. Мидхәт шактый вакыт кыйммәтле аяк киеменә күз кырые белән кызыгып карап утырды, хәтта калкавычка да игътибар итми башлады. Үзенең «авызы» ачылган, үкчәсе ашалган, катып кәкрәйгән ботинкасына карап куйды.

Гомерендә кеше әйберсенә кул сузмаган Мидхәтнең кинәт башына бер кара уй килде – теге затлы ботинканы урларга!

Егет белән кыз судан чыгып, яр буйлап әллә кая ук еракка йөгерделәр. Кызның чи-чи килгәне дә чак кына ишетелә. Машина да каплап тора. Алар күренгәләгәнче, чәлдерергә мөмкин.

Мидхәт тиз генә кармагын җыйды, рюкзагын алды, аларны куак арасына яшерде. Шуннан, үзенә һич тә хас булмаган ниндидер елгырлык белән, пар ботинканы эләктерде. Куак арасына кереп ботинканы рюкзагына тыккач, артына борылып карый-карый, өенә таба элдерде.

Кыз белән егет, аны-моны абайламыйча, көлешеп-шаярышып су коенып калдылар.

Германиядә тегелгән аяк киеме булып чыкты ул. Ай-яй, шәп ботинка тегә икән Совет Армиясе тарафыннан тар-мар ителгән халык!

Мәрзия дә иренең беркайчан хөрмәт күрмәгән аягындагы кыйммәтле ботинканы шаккатып күзәтте. Аның:

– Каян алдың? – дип сораячагына Мидхәт ничегрәк алдашырга икәнлекне кайтканда уйлап куйган иде инде.

– Дүрт кило ярым бәртәс тоткан идем, – дип шыттырды ул. – Ниндидер бер «яңа урыс» килде дә: «Сат әле балыгыңны, свежий балык ашыйсым килә», – диде. Ботинкасына игътибар иттем дә, ошагач: «Ботинкаңа алышам», – дидем.

– Затлы ботинка бу! – диде үзе дә гомерендә бер яхшы аяк киеме күрмәгән Мәрзия.

* * *

Мидхәт йокыдан торуга, хатыны көн саен эшләнә торган гадәти эшләрдән тыш инде авыл кибетенә дә барып кайтырга өлгергән иде.

Чәй эчәргә утырганда, ул көтелмәгән яңалыкны хәбәр итте:

– Авылга милиция килгән.

– Ник икән? – диде Мидхәт, шомраеп.

– Ниндидер бер махсус эт белән йөриләр, ди.

Мидхәт куырылып китте:

– Нәрсә булды икән?

– Наркотик эзли торган эт ди ул. Теге коттедж төзелә торган тирәдә наркотик кулланалар дигән имеш-мимешләр ишетелгәләп тора бит. Шуларның наркотикларын эзлиләрдер.

«Ботинка хуҗасы милиция чакырткан микәнни» дип котсыз калган Мидхәтнең шундук эченә җылы йөгерде. Ул, ихластан ачуланып, башын чайкап куйды.

– Авыл җиренә үк үтеп керсен әле шул наркотик, ә! Ай-яй, кая бара бу дөньялар. Нинди заман бу! – Мидхәт урыныннан кузгалды. – Мин урамнан әйләнеим әле. Наркоманнарны тотмадылар микән анда?

Аягындагы германский ботинкага күз салып, Мидхәт вәкарьлек белән урам буйлап атлады. Затлы аяк киеме кигәч, халәт бөтенләй икенче икән ул. Бу ботинканы урлаганга Мидхәтнең вөҗданы чак кына да кыймылдамады. Гомер буе рәхәт күрмәү өстенә соңгы елларда күпме түбәнсенү, кимсенү кичергәнгә күрә, үзенең урлашуга баруы белән, ни гаҗәп, күңеленең бер почмагында килешү тойды.

Шулай күтәренке халәттә барганда, көтмәгәндә елга ягыннан менә торган тыкрыкта башта алагаем зур эт күренде, аннары чандыр гына бер милиционер хасил булды. Мидхәт хәтта куркырга да өлгерми калды – эт, килеп, аның ботинкасын иснәп-иснәп алды да тамагы ертылырдай итеп өрергә тотынды.

Милиционер этнең бәен берничә кат кулына урагач, буш кулы белән куен кесәсеннән таныклыгын алып күрсәтте:

– Капитан Гайсин. Ботинкагызны салыгыз!

– Ник? – диде Мидхәт, басып торган урынында җиргә иңәрдәй булып.

– Эт нәрсәдер сизенде. Салыгыз аяк киемегезне!

Шул арада авыл халкы җыелды. Авыл халкы ул тиз җыела. Бигрәк тә авылдашлары берәр бәлага тарыса. Авылда гына түгел, һәркайда халык төркеме кеше шатлыгын уртаклашырга атлыгып тормый. Кешеләр фаҗигаләрне яраталар, аларга кемнеңдер мескенләнүе яки көлкегә калуы ошый, бу очракта аларны чакырырга кирәкми, алар үзләре җыелалар.

Мидхәт ботинкасын салган арада, капитан Гайсин этне тыкрык коймасына бәйләп куйды. Капитан Мидхәтнең аяк киемен әйләндергәләп карады. Шуннан соң, кесәсеннән пәке чыгарып,

ботинканың эчке табанын кубарды, ике бармак очы белән кысып, сак кына кечкенә полиэтилен пакет алды.

Гайсин, ботинканы җиргә ташлап, пакетны өскә күтәрде һәм халыкка мөрәҗәгать итте:

– Ак порошок! Берничә пүнәтәй кирәк...

...Мидхәтнең наркотик белән тотылуы хакында бөтен авыл шау-гөр килде. Икенче көнне моны күрше авыллар ишетте, ә инде атна азагында бу хәбәрне бөтен район белә иде. Тып-тын гына гомер итеп, ике бала үстереп, аларны башлы-күзле итү хыялы белән яшәүче гап-гади авыл кешесенең наркомафиягә катнашы барлыгы барысын да шаккатырды. Мидхәтнең наркокурьер икәнлегенә ышанасы килмәүчеләр дә шактый иде, вәләкин аның ботинка табаны астында ак порошоклы кечкенә пакет шаһитлар барында табылгач, ничек инде ышанмыйсың!

* * *

Милиция кабинетында капитан Гайсин ашыга-ашыга нәрсәдер язганда, Мидхәт аның каршысында тын алырга да куркып утырды.

Ул, өстәлдәге кәгазь өеме янында торган бер пар аяк киеменә карамаска тырышып, инде әллә ничәнче кат:

– Минем ботинкам түгел ул! – дип өзгәләнде.

Гайсин да үзенең бер үк мәнсез соравын әллә ничәнче мәртәбә кабатлады:

– Синең ботинкаң булмагач, нишләп синең аягыңда иде соң ул? – Капитан, язудан туктап, Мидхәткә яман усал караш ташлады. – Каян алдың, кем китерде бу наркотикны? Үзең кулланасыңмы, әллә берәрсенә сатарга җыендыңмы?

Бу кадәре берсеннән-берсе вәхши сораулардан Мидхәт бөтенләй шәлберәеп төште. Ни дип тә җавап бирергә белмәгәч, еламсырап сорап куйды:

– Мине хәзер төрмәгә утырталармы?

– Юк, ял йортына җибәрәләр, – дип үчекләде аны капитан. – КарловыВарыга. Дөресен сөйләп бирсәң, срогың кимрәк булачак.

Мидхәт талпынып карыйсы итте:

– Юк, наркотигы гына түгел, хәтта ботинкасы да минеке түгел! – диде ул, дөньядагы барлык ботинкалардан һәм башка төрле аяк киемнәреннән ваз кичәргә әзер булып.

– Синең пуҗум аша наркотрафик үтәдер дип һич уйламаган идем, – диде Гайсин, күзләрен челәйтеп.

Мидхәт ачыргаланып кычкыра башлады:

– Минем пуҗум аша бакча сукалаганда, ат үтә дә, чүп утаганда, матик белән хатыным үтә. Нинди наркотрафик үтсен минем колорадский жуклы бәрәңге бакчасыннан?!

Милициядә эшләп каешланып беткән Гайсин, аның ачыргалануына бөтенләй ригая бирмичә, сорау алуын дәвам итте:

– Наркотикны сиңа каян китерәләр? Җавап бир! Алайса, мин сине төрмәдә черетәчәкмен!

«Ботинка урлаганымны әйтеп бирсәм, бәлки, шуның өчен генә җавапка тартырлар, әллә нинди каһәр суккан наркотиклар сылтап маташмаслар», – дип уйлап куйды Мидхәт.

– Урлаган өчен күбрәк срок бирәләрме, әллә табан астында наркотик саклагангамы? – дип сорады ул тагын нәрсәдер язарга тотынган капитаннан.

– Нәрсә урлыйсың бит.

– Мәсәлән, аяк киемен урлаган өчен күп бирәләрме? – диде Мидхәт, тереләнеп.

– Кемнекен урлыйсың бит.

Капитан язудан туктап шактый вакыт текәлеп карап утыргач, Мидхәт дөресен ярып салырга булды:

– Мин ул ботинканы урладым!

Гайсин авызын чалышайтып көлемсерәп куйды:

– Бөгештермә. Следствиене ялгыш юлдан җибәрергә телисеңме?

– Менә шушы утырган җиремдә чәчрәп катыйм, мин ул ботинканы урладым! – диде Мидхәт, сикереп торып. – Минем гомергә мондый затлы, кыйммәтле ботинка алганым юк! – дип кычкырды ул, өстәлдәге ботинкага ишарәләп.

– Каян урладың соң син аны?

– Су буенда...

– Кемнекен?

– Су коенучы бер «крутой»ныкын.

– Аның «текә» икәнен каян беләсең?

– Ул безнең бакча артында коттедж сала. Аның иномаркасы да хәтәр.

– Нинди марка?

– Маркасын белмим. Аның машинасының алды сатучы Хәбирәнең чырае сыман ыржаеп тора. Номеры да өч тугызлы.

* * *

Гайсин кәгазьләрен актарып утырганда, кабинетка атлет гәүдәле, сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле, гомумән алганда милләтсез чырайлы бер егет керде. Карап торуга аңа егерме биш яшьләр чамасы иде. Өстенә чит телдәге язулар белән чуарланган футболка, джинсы чалбар һәм аягына кроссовка кигән бу затның кыяфәтендә курку түгел, хәтта бернинди шик-шөбһә чагылышы да юк иде.

– Мөмкинме? – дип рөхсәт сораган булды ул, сагызын чәйничәйни.

– Керегез. Утырыгыз. Фамилия?

– Саттаров, – диде егет, милиционер өстәле каршындагы урындыкка утырып.

– Исемегез?

– Марс!

– Атагызның исеме?
– Эдуардович.
– Менә нәрсә, Марс... – диде Гайсин, ниһаять, кәгазьләреннән аерылып егеткә карагач. – Синең ботинкаңны урлаганнар. – Ул өстәл тармасыннан Мидхәт урлаган ботинкаларны чыгарып өстәлгә куйды. – Бу аяк киемен мин сиңа тапшырырга тиешмен.
Марс ботинкага карап алды да ваемсыз гына:
– Минем ботинкамны урлаганнары юк, – диде.
Капитанның яңакларында төерләр йөри башлады:
– Менә бит, таптык урланган ботинкагызны.
Марс:
– Бу бит минем ботинка түгел, – дип, сагызын катырак чәйнәргә тотынды.
– Кемнеке соң ул?
– Каян белим мин!
– Без бит урлаучыны да тоттык, – дип елмайды Гайсин һәм ишек артында ишетелерлек итеп кычкырды. – Мидхәт абый, кер!
Мидхәт, военкомат коридорындагы шәрәтән призывник сыман, ишек катында коелып, иңәрдәй булып басып торды. Йончыган кыяфәтле, йөзеннән хайвани курку аңкыган бу абзыйга Марс битараф чырай белән сүлпән караш ташлады. Мидхәт исә, егетнең күз карашы белән очрашмаска тырышып, башын читкә борды. Түрдәгерәк буш урындыкка утыргач та, ул тәрәзә ягына – ишегалдындагы агач ботагында пыр-пыр килгән чыпчыкларга карады. Кечкенә кошчыклар дөньядагы иң бәхетле җан ияләре булып тоелды аңа бу мизгелләрдә.
Ул Гайсинның тавышыннан сискәнеп китте:
– Димәк, сез су буенда менә бу гражданинның ботинкасын урладыгыз, шулаймы?
– Әйе, – дип баш какты Мидхәт, әле Марска, әле ботинкага карап. – Иртән хатын ачуны китерде, кешедән оят, аяк киемең катып, ашалып беткән, диде.
– Шушы кешенеке урладыгызмы? – дип соравын кабатлады Гайсин, егеткә ымлап.
– Әйе. Алар анда бер кыз белән су коендылар.
Гайсинның кәефе күтәрелеп китте – чөнки эш җайлы гына ачылырга тора, карьера өчен уңай эш булырга тиеш бу. Ул егеткә исеме белән, ягымлы итеп эндәште:
– Марс, синең ботинкамы бу?
– Юк, – диде Марс, бер дә исе китмичә. – Алдый ул. Аның үзенең ботинкасы бу.
– Мондый ботинка алырлык акчам булса, мин башта теш куйдыртыр идем, – диде Мидхәт, тавышын күтәреп.
– Экспертиза бу ботинка кемнеке икәнне барыбер күрсәтәчәк, – диде Гайсин, кайбер папкаларны өстәл тармасына тыгып.
Марс көлемсерәп куйды:
– Ярар, ботинка минеке ди. Бу тинтәк аны урлаган ди.
– Но-но, без оскорблений! – дип җикерде капитан.

– Ярар, ул урлаган ди минем ботинкамны... Ботинкасы минеке булган сурәттә дә, аның табаны астында табылган наркотик минеке түгел бит. Инде ботинканы урлагач, аның табаны астына наркотик яшергән ул.

Мидхәт, күзләрен акайтып, егеткә таба иелде:

– Каян килсен миңа наркотик! Мин тәмәкене дә ташладым! Моннан сигез ел элек.

Гайсин күзләрен кылпакландырды:

– Ә бәлки, сез икегез дә бер бандадандыр?

Марс шаркылдап көлеп җибәрде:

– Моның беләнме?

Гайсин исә бик җитди кыяфәткә керде:

– Әйе. Син ботинкаңны яр буенда калдырасың, ә Мидхәт абый ботинканы алып китә. Шулай итеп, наркотикны бер-берегезгә тапшырасыз. Алай булырга мөмкинме?

Марс тагын да катырак көләргә тотынды. Көлгәндә, аның сагызы авызыннан атылып чыгып идәнгә төште.

Мидхәт җан өзгеч тавыш белән кычкырырга тотынды:

– Ни сөйлисез сез?! Ботинка урлаганым өчен җавапка тартыгыз, әмма әллә нинди наркотиклар такмагыз миңа! – Аның шундук хәле бетте. Чак кына ишетелерлек итеп өстәп куйды: – Хатын үтерә мине!

Марс аңа җирәнеп карады:

– Аңарчы мин үтерәм әле сине!

– Но-но, без угроз, пажалысты! – дигән булды Гайсин.

* * *

Милиция бүлегенең подвалында урнашкан камераларның берсендә, түр почмактагы шконкада, берәү авыр мышнап бөгәрләнеп яткан иде. Тузан эчеп, катып, почмаклары каешланып беткән иске одеялны бөркәнеп, стенага таба борылган килеш тоткын йокыга талган иде. Газаплы сулавыннан аңлашыла – татлы йокы түгел бу.

Ул монда берүзе ята, дүрт урынлы камераның өч шконкасы исә буш иде. Бервакытны тимер ишек ямьсез тавыш белән гөрселдәде, аннары кеше сыярлык кына итеп ачылды. Камерага Марс килеп керде. Ишек дөңгелдәп ябылды, шакол-шокыл йозак бикләнгәне ишетелде.

Марс, беркавым ишек катында басып торган килеш, камера эченә күз йөгертте. Буш шконкага утырып, йоклап ятучыга карап торганнан соң, юри каты иттереп йөткереп куйды. Аның йөткерүеннән йоклап ятучы кеше уянды да әкрен генә торып утырды, аннары, күзләрен чекерәйтеп, Марска карады.

Алар, шактый вакыт бер сүз дәшми, бер-берсенә карап утырдылар.

Марс камерадашына мыскыллы тавыш белән сүз катты:

– Ну, нәрсә, наркокурьер? Нишлибез?

Мидхәтнең бу егет белән бер камерага эләгүенә бик нык борчылганы сизелде.

– Монда нишлисең инде, – диде ул. – Гафу ит мине.

– Нәрсә өчен? – диде Марс, көлемсерәп.

– Ботинкаңны урлаганым өчен. Болай килеп чыгасын кем белгән?

– Ботинкасы кадалып китсен! Ә менә наркотик белән мине подставить иткәнең өчен нишләтергә сине, ә?

– Мин бит анда синең наркотигың бар икәнне белмәдем.

– Нинди наркотик? Минем анда бернинди наркотигым юк иде.

– Синең наркотик түгелмени ул?

Марс камера буйлап әрле-бирле йөрергә тотынды:

– Нинди наркотик?! Мин спортсмен. Минем хәтта тәмәке дә тартканым булмады.

– Каян килгән соң ул, алайса?

– Син карап торуга чмошный гына мужик, ә үзең шулхәтле оста кыланасың! – диде егет, йодрыкларын төйнәп.

– Менә шушында җир йотсын! – дип өзгәләнеп кычкырды Мидхәт. – Бернинди наркотикка катнашым юк. Аллам сакласын!

Марс Мидхәткә беравык текәлеп карап торды:

– Кем тыккан соң аны анда?

– Синеке дә түгелмени ул наркотик? – дип аптырашта калды Мидхәт.

– Юк! – диде Марс, кыҗрап.

Мидхәт уйга калды:

– Әллә ул пакетны берәрсе урамда төшереп калдырып, хатыным аны табып алып, чит кешенең ботинкасы аягымны авырттырмасын дип табаны астына тыкты микән дип тә уйлап карыйм... Алай дисәң, соңгы вакытта хатын миңа яхшылык эшләргә атлыгып тормый. Ул әле, киресенчә, аягы авыртсын дип, ерак бармасын дип, юри берәр нәрсә тыгарга мөмкин.

Марс Мидхәтнең бу сүзләреннән соң, беркавым уйга калып, шконкада утырды.

Кинәт ул, сикереп торып, камера ишеген йодрыгы белән дөбердәтергә тотынды:

– Һәй, ачыгыз! Ачыгыз тизрәк! Ачыгыз, дим!

* * *

Мидхәт изолятордан азат ителеп милиция бүлегеннән якты дөньяга чыкканда, аны хатыны Мәрзия каршы алды. Мидхәтне танырлык түгел иде – сакал-мыек баскан, ябыгып шыр сөяккә калган, тәбәнәкләнгән, бераз бөкрәйгән. Ниһаять, хатыны аны танып алды, йөгереп килеп ирен кочаклады. Мидхәтнең кочаклашырга хәле юк иде, шулай да хатынының мондый мөгамәләсе аңа шундук кодрәт бирде.

Аларның икесенең дә күзләре дымлы иде. Бик сагынганнар иде бер-берсен. Алар бер-берсенә бик якын кешеләр икән ләбаса!

Акча юклыгы да, өс киеменең искелеге дә, ботинканың төбе ашалып бетүе дә бу минутларда мөһим түгел иде. Бар матди нәрсәнең дә әһәмияте югалган, бары тик ике кешенең – тормыш авырлыкларын көн саен, адым саен бергә җиңеп яшәгән ир белән хатынның – бер-берсен сагыну хисе генә калган иде.

– Ничек булып чыкты соң? – дип сорады Мәрзия, елап туйгач.

– Теге бергә су коенган кыз Марска кияүгә чыгарга хыялланып йөргән, ә Марс башкага өйләнәсе булган. Теге кызый, моңа ачу итеп, ботинкасына наркотик тыккан. Аннары милициягә хәбәр итәргә җыенган, бу егетне утыртсыннар өчен. Менә шулай.

– Ай-яй, хәзерге кызлар кабахәт тә соң!

– Мине карале син – гомеремдә кеше әйберенә кул сузмаган идем...

– Әйтмә дә! Ник кирәк булды сиңа ул ботинка!

– Үзең бит, гел бер иске ботинка белән йөрисең, дип теңкәмә тидең.

– Хатын теңкәгә тия дип, урлашуга бармыйлар инде.

– Анысы да дөрес.

* * *

Кайту белән үк, кичкә калсалар да, мунча яктылар. Иске суыткычның катыру өлешендә күптәннән саклап тотылган итне салып борчаклы аш пешерделәр. Мәрзия өстәлгә үз кулы белән бер шешә аракыны китереп куйгач, Мидхәтнең бәгыре тәмам җебеп китте, битендәге җыерчык буйлап күз яше агып төште.

Йоклаганда Мидхәт төш күрде: имеш, капитан Гайсин килгән дә боларның өен тенти. Кесәләрен актара, аяк киемнәрен иснәп карый. Әле фуфайка кесәсеннән, әле галуш эченнән, әле мич башындагы киез итектән, әле суалчан тутыра торган банкадан пакет-пакет ак порошок таба, имеш. Хәтта Мәрзиядән аракы яшерә торган чолан посрыгында да наркотик табыла, имеш. Бу кадәре наркотик өчен «пожизненный срок» булырга мөмкин дип саташып, әллә ничә тапкыр сикереп торды Мидхәт. Ул төнне хатыны бөтенләй йокламады диярлек, карават кырында ирен тынычландырып утырды.

...Яңа көн туды. Тормыш элеккечә, төгәлрәк әйткәндә, үзенчә дәвам итте. Мәрзия мыш-мыш килеп идән юганда, Мидхәт шыпырт кына балыкка барырга җыенды.

– Тагын балыкка җыендыңмы? – диде Мәрзия, кызыл чыраен калкытып.

– Әйе, – диде Мидхәт, капчыгына ипи кисәге тыгып.

Хатын юеш чүпрәкне, лычт иттереп, идәнгә ташлады:

– Син бармак буе балык тотып кайтасың... Айлар буена сузыла торган фаҗигаләргә тарыгасың...

– Гел алай булып тормас әле, – диде Мидхәт.

Шулвакытны боларның йорты каршына джип килеп туктады. Капкадан кергәннәрен сизгәч, Мидхәт каршы чыгарга булды. Ишегалдында, кулына зур төргәкләр, пакетлар тотып, Марс басып тора иде. Мидхәт артыннан Мәрзия дә күренде.

– Капчык асып кая җыендың, Мидхәт абый? – диде Марс шат тавыш белән.

– Балыкка.

– Теге урынгамы? – дип көлде Марс.

– Бу юлысы анда ук бармам, – диде Мидхәт.

Марс, җитди кыяфәткә кереп, Мидхәткә таба атлады:

– Рәхмәт сиңа! Менә бу бүләкләр, күчтәнәчләр сезгә.

Бүләкләрне Мәрзиягә тоттыргач, ул бер коробканы Мидхәткә тапшырды.

– Ни өчен рәхмәт әйтәсең син миңа? – диде Мидхәт, пошаманга калып.

– Ботинкамны урлаганың өчен. Син ботинкамны урламаган булсаң, нәрсәләр булып бетәр иде – билгесез. Рәхмәт, ботинкамны урлаганың өчен. Бу кәнәтилнең болай тәмамлануы бик әйбәт.

Мидхәт кулындагы коробканы әйләндергәләп карады:

– Нәрсә соң бу?

– Мидхәт абый, бу сиңа нәкъ шундый ук өр-яңа ботинка. Миннән сиңа бүләк.

Мидхәт котсыз калды:

– Юк, юк, кирәкми!

– Курыма, ал, – диде Марс, елмаеп.

Шуннан соң егет пинжәгенең куен кесәсеннән бер пачка акча чыгарды. Ләкин ул аны Мидхәткә тапшырырга өлгермәде, Мәрзия, тиз генә кулындагы әйберләрне өйалды баскычына куеп, акчаны эләктереп алды да халат кесәсенә яшерде.

Марс кат-кат рәхмәт әйтә-әйтә саубуллашып чыгып китте.

Ул чыгып киткәч, Мидхәт коробканы ачты һәм аның йөрәге жу итеп куйды. Анда күз явын алырдай бер пар ботинка иде. Нәкъ ул урлаган ботинка төсле, ләкин өр-яңа.

– Ташла! – дип кычкырды Мәрзия. – Кия күрмә!

Мидхәт ботинканы баскыч алдына куйды. Мәрзия җәһәт кенә чоланнан сугым пычагы алып чыкты. Хатынының пычак очы белән ботинка табанын каезлаганны Мидхәт тыныч кына күзәтте.

Ходайның рәхмәте төшкере, табан астыннан берниндә наркотик-мазар чыкмады.

* * *

Су буенда ул көнне аеруча рәхәт иде.

Әкрен генә аккан су көенә күңел тирбәлеп куйды. Мидхәт, капчыгын ачып, Марс бүләк иткән аяк киемен алды. Башта, бар көченә кизәнеп, бер ботинканы елганың уртасына ыргытты, аннары икенчесен томырды. Ботинканың икесе дә су төбенә төшеп киткәч, Мидхәт иркен сулап куйды.

Кармагын суга салып, ул, гадәттәгечә, чиртә башлаганны сабыр гына көтте.

Гадәттәгечә, чиртмәде. Мөгаен, чиртмәс тә инде.

Тик ниндәндер рәхәт бүген. Аңлатып булмаслык күңел хөрлеген тойды ул.

Калкавыч кыймылдап куйды. Юк, балык түгел бу, җил кагылды калкавычка. Җил гәүдәгә сарылды, аның иркәләвеннән тән чемердәп китте.

Мидхәт үзенең аягындагы иске ботинкага күз салды һәм, балык эләкмәүгә карамастан, якты кояшлы әбелхәят кочагында җан тынычлыгын тоеп, ниндидер сәер шатлык белән җырлап җибәрде.

2007

ТЫН ОКЕАНДА КӨРӘШ

Тын океанда балык тотып йөргән кораб баткач, су өстендә экипаждан бары тик Хәммәт кенә калды. Аның гөнаһлары бик күп булмагандыр инде, чөнки кораб баткан урында бер юан һәм озын бүрәнә чайкала иде. Хәммәт шул агачны кочаклады да, болай да төксе океанга тагы да шом өстәп, шыранлап кычкыра-кычкыра, әҗәл дулкыннарында тирбәлә башлады. Бу минутларда аның җиһанга, яшәешкә булган кайнар мәхәббәте бер агач кәүсәсендә тупланган иде. Шуңа күрә ул бүрәнәгә бөтен җаны-тәне белән тозлы диңгез суы кебек сеңде.

Тирә-якта чиксез океан кайный...

Менә күп тә үтмәс, Хәммәт су төбенә китәр... Акулалар азыгы булуың да бик ихтимал... Ачлык та бар бит әле... Кыскасы, Хәммәткә яшәргә күп калмады. Бу уйлардан аның тәне оеп, күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте.

Шулай күпмедер вакыт үлем белән яшәү арасында йөзеп йөргәннән соң, Хәммәт еракта, су өстендә, бер кара тап күреп алды.

– Әһә-һә-ә-ә-й!..

Кара тап ягыннан «А-а-а-а-й!» дигән тонык кына җавап тавышы ишетелде. Хәммәтнең сөенечтән тәненә бераз җылы йөгерде, аның шактый гына тозлы су йоткан эчендә ниндидер өмет уты кабынды булса кирәк.

Кара әйбер якынлашкач, Хәммәт шикелле үк бәхетсезлеккә дучар булган адәмнең, шулай ук ниндидер агач кисәген кочып, тыпырчынганы аңлашылды. Агачы гына аның Хәммәт сарылган бүрәнәгә караганда нәзегрәк тә, кыскарак та иде.

Хәммәткә якынайганда, океан колы авызыннан су фонтаны сиптереп алды да:

– Ты кто?.. Wer ist du?.. – дип төрле телдә сорау бирде. Шушы ике сорау белән аның чит телләр диңгезендә йөзүе тәмамланды.

Хәммәткә сорауның русчасы якынрак тоелды. Шуңа күрә:

– Я – Хаммат!.. А ты?.. – диде ул, бүрәнәсенә җайлабрак ябышып.

– Хаммат?! Татар мәллә син?..

– Татар, татар! – дип кычкырды Хәммәт, океан өстенә шатлык нуры таратып. – Син дә татармыни?!

– Әйе. Гата исемле мин. Корабыбыз батты. Мин генә менә исән калдым. Ә син нишләп монда берүзең йөзеп йөрисең?

– Безнең траулерны да океан йотты бит, – дип ыңгырашты Хәммәт, Гатага кулын сузып. – Син кайсы яктан?

– Мамадыш районыннан.

– Ә мин Казанның үзеннән.

Танышу тәмамланганда, алар янәшә чайкалалар иде инде.

Океан уртасында ике татар, ике якташ очрашу Хәммәтне дә, Гатаны да өметләндереп, канатландырып җибәрде һәм алар күпмедер вакыт үлем белән яшәү арасында бер генә сызык – берәр генә бүрәнә икәнен онытып тордылар. Ләкин шатлыкның күз күрмәс канатлары бичараларны кайнап торган океаннан йолып ала алмады – якташлар бүрәнәләренә бик нык ябышканнар иде шул.

Иң элек Гата айнып китте.

– Хәммәт, су төпләрендә тончыгып үләргә язган микәнни, ә?..

– Әй Ходаем! – дип ыңгырашты Хәммәт. – Тирә-якта корабмазар, утрау ише нәрсә дә күренми бит, ичмаса...

Хәммәт нечкәрәк күңелле булып чыкты – беренче булып ул елап җибәрде, аннары аңа Гата кушылды. Аларның күз яшьләреннән океанның тозлы суы шактый гына артты да шикелле...

– Гата, уйлашыйк әле, берәр чара табып булмасмы? Без бит болай озак йөзеп йөри алмабыз – тамак ачар, хәл бетәр... Шторм кузгалуы да бар...

– Нинди чара табасың инде монда, – диде Гата, авызыннан ярты литр чамасы су сиптергәч. – Туктале, Хәммәт... Әйдә, ике бүрәнәне бергә бәйлибез. Алай ышанычлырак булыр, кечкенә сал шикелле нәрсә ясыйк. Минем менә чалбар каешым бар.

Хәммәт Гата ябышкан агачка күз салды. «Бик нәзек шул. Нишләп әле мин үз гомеремне куркыныч астына куйыйм...» дип уйлады ул һәм болай диде:

– Юк инде, туган! Һәркемнең үзенә тәгаенләнгән гомере булган шикелле, Ходай һәрберебезгә берәр бүрәнә бирде. Синең йомычкаңны мин кораб хәтле агачыма бәйли алмыйм, бигайбә. Болай җаным тынычрак. Синең агачың начар булганга мин гаепле түгел.

Шуннан соң ул бүрәнәсенең буеннан-буена мәхәббәт аша күз йөртеп чыкты.

Күк йөзе караңгылана башлагач, якташлар агачларын кысыбрак кочакладылар. Дулкыннар зурайганнан-зурая барды, күкнең караңгылыгы куера төште.

Гата ялварулы тавыш белән тагын бер мәртәбә мөрәҗәгать итте:

– Хәммәт туганым! Давыл башлана, бәйлик дим агачларны, бергә ничек тә куркынычсызрак булыр.

Тау хәтле дулкын икесен дә коендырып алгач, Хәммәтнең куркуы эгоизмны җиңде, һәм ул кәүсәләрне берләштерергә ризалык бирде.

Хәзер инде аларның язмышлары чын мәгънәсендә бер чалбар каешы белән бәйләнгән иде.

Давыл тынгач, бер-берсенең исәнлеген сораштылар. Икесе дә исән иде әле.

Агачларның Хәммәт ябышкан башы нишләптер батыбрак тора башлады. Шуңа күрә Хәммәт ике агачтан торган «сал»ның уртасына табарак күчте. Бу, әлбәттә, Гатага ошамады.

– Карале, Хәммәт дус, – диде ул, үзен көчкә кулга алып, – син миңа таба шуышма инде, батырасың бит мине дә...

– Нәрсә-ә-ә-ә?! – диде Хәммәт, Гатаның өстенә акула сыман ташланырга әзерләнеп. – Минем бүрәнәм булмаса, күптән балыклар азыгы идең бит инде син!

Ике агачлы «сал»да территория өчен сугыш башланды. Гатаның оятсызлыгыннан, рәхмәтсезлегеннән ярсып, Хәммәт:

– Чишәм каешны! – дип кычкырды. – Бир минем бүрәнәмне!

Хәммәт агачларны бергә бәйләп торган бәйне чишмәкче булды, ләкин булдыра алмады – каеш юешләнеп тыгызланган иде. Аптырагач, каешны ул чәйнәргә кереште. Гата якташының бу ниятенә комачаулар өчен аңа таба шуышкан иде дә, әмма авырлыктан «сал» янтайды һәм ул кире үз урынына – элекке позициясенә чигенергә мәҗбүр булды.

Бик озак маташа торгач, Хәммәт тешләре белән каешны өзүгә ирешә.

Агачлар бер-берсеннән теләр-теләмәс кенә аерылып киттеләр, һәм якташлар яңадан берәр бүрәнә иясе булдылар.

Хәммәт Гатаны үчекләп шаркылдап көлде дә, куллары белән тиз-тиз ишкәкләп, аңардан ерагая башлады.

Кинәт Гата да ямьсез тавыш белән кычкырып көләргә тотынды. Шунда Хәммәт су төбенә төшеп киткәндәй булды – ялгыш Гатаның агачын кочаклаган лабаса!.. Тарткалаша торгач, бутаганнар агачларны... Ул Гатаның «йомычка»сына ябышкан, ә Гата, хайван, аның утрау кадәр бүрәнәсенә атланып, шатлыгыннан «Җомга көе»н җырлый.

> ...Онытасым юк үлгәндә дә,
> Гүрләргә кергәндә дә...

Хәммәт, шашынып, башын агачка шап-шоп бәрде.

– Бир бүрәнәмне, кабахәт! – дип үкерде ул. – Карак! Кеше талаучы! Мин сине судка бирәм... Мәскәүгә язам!..

Аның авызына су тулгач, сүзне Гата алды:

– Яз, яз, – диде ул, куллары белән ишкәкләп. – Син лутчы ООНга яз, сугыш нейтраль суларда бара бит.

Гатаның ерагаеп барганын күргәч, Хәммәт, чарасызлыктан урталай ярылырдай булып, тешләрен агачка батырды.

Бу вакытта инде Гата «Җомга көе»н тәмамлап, дөньяның киңлеге турында ниндидер бер башкорт җырын җырлый иде.

Шулай да, офыкта акулалар шәйләнгәч, бүрәнәләр тагын берберсенә бәйләнделәр. Акулалар күздән югалгач, «сал» экипажында янә талаш купты.

Тәүлек буена океан кочагында «иркәләнгәч», Алла һәм стихия колларының тамаклары ачты. Агачларның кабыгын ашаганда, гаделлек буенча, һәркем үзенең бүрәнәсен кимерергә тиеш иде. Ләкин нәзек агачның кабыгы бик ачы, тәмсез булып чыкты. Ә кайсы агач кемнеке икәнлеге әлегә законлаштырылмаган иде.

Бу юлысы «сал»ның бавы булып хезмәт иткән чалбарны Гата чәйнәп өзде. Хәзер инде икесе дә игътибарлырак булдылар, шуңа күрә икесе дә юан бүрәнәгә куллары, аяклары һәм тешләре белән ябыштылар. Нәзек агач, үпкәләгән сыман, бата-калка хуҗасыз чайкалып торды.

– Гата, минем дүрт балам ятим кала, күч син теге агачка! Бу бүрәнәне мин беренче таптым бит! – Хәммәтнең тавышында ялвару, үтенү һәм таләп итү ноталары яңгырады.

– Минем дә гаиләм бар, – диде Гата коры гына. – Мин сиңа караганда яшьрәк тә, әле бөтен гомерем алда бит. Яшисем килә минем!

Чынлап та, Гата яшьрәк тә, тазарак та иде. Ул, шуннан файдаланып, Хәммәтнең чәченнән эләктереп алды да аны берничә мәртәбә суга батырып калкытты. Каршы торуның мәгънәсезлеген аңлагач, Хәммәт «Алланың ачы каһәре төшсен!» диде дә ятим агачка таба йөзеп китте.

Ике бүрәнә арасында талаш дәвам итте.

Кычкырудан тавышы карлыккач, Хәммәтнең сүгенүле каргышларына Гата җавап бирә алмый башлады.

Нәкъ шулвакытта еракта зур кораб күренде. Гатаның талашканда өзелгән тавыш җепселләреннән:

– Хәммәт... кычкыр... тизрәк... – дигән сүзләр көчкә шыелдап чыкты. – Котылабыз... Кычкыр... Минем тавыш юк бит...

Газиз бүрәнәсеннән колак кагу Хәммәтне бик рәнҗеткән иде. Шуңа күрә ул авызын бик ямьсез итеп кыйшайтты да:

– Тот менә! – диде. – Кычкырмыйм! Чукынып кат!

Гатаның өзгәләнгән үзәгеннән:

– Кычкыр, Алла хакы өчен! – дигән аваз ишетелер-ишетелмәс кенә булып сытылып чыкты.

– Бүрәнәмне бирсәң, кычкырам, – диде Хәммәт.

Океаннарда сирәк очрый торган бүрәнәне дошманына бирү уе Гатаның акылына сыярлык түгел иде. Ул ямьсез итеп елмайды да:

– Мин синең нинди кеше икәнеңне аңладым инде, – диде. – Кычкырам дип ялганлап, бүрәнәмне эләктермәкче буласыңмы?..

Алар ызгышкан арада, кораб юкка чыкты.

Тын океанда көрәш дәвам итте...

1989–1990

МӘГЪНӘСЕЗ НИЗАГ

«Б» хәрефе «А»дан көнләшә башлады. «Нишләп әле алфавитта ул беренче булып торырга тиеш?.. – дип уйлады ул. – Нишләп мин түгел? Минем аннан кайсы җирем ким?»

«Б» хәрефе ачуын озак тыеп тора алмады, беркөнне «А» хәрефенә үзенең тынгысыз күңелендә кыбырсыган ризасызлыкны ачып салды:

– Карале, «А», ни сәбәпле син миннән өстен торырга тиеш? Күрше, син мине гафу ит инде, монда гаделсезлек килеп чыга түгелме соң? Нинди сыйфатларың өчен алфавит синең белән башлана?

«А» хәрефе бу мөрәҗәгатьтән башта аптырап калды.

– Ә нишләп минем белән башланмаска тиеш? – диде ул аннан, тиз генә үзен кулга алып. – Шулай кирәк дип тапканнар. Тарихи нәрсә бит бу...

«Б»ның моңа ачуы нык кабарды.

– Син, «А», тарих-фәлән диеп башымны катырма. Заманалар икенче хәзер, алфавитта да үзгәрешләр булырга тиеш. Минем синнән кай төшем ким?

«А» хәрефе дә кайнарлана башлады.

– Заманалар икенче дип... Әллә син үзеңне миннән затлырак саныйсыңмы?! Беренче буласың киләме әллә?

– Килә шул, – диде «Б» хәрефе, яшермичә.

– Ә нишләп син беренче булырга тиеш?

– Чөнки синең барлык хәрефләр өстендә торырга хакың юк. Синең белән бик күп начар сүзләр башлана. Мәсәлән, «авантюра». Бу сүздә син хәтта өч тапкыр кабатланасың. «Ахмак» сүзен алыйк. Монда да син ике урында. Син кергән әшәке сүзләрне көне буе санарга була: алкаш, армия, аңгыра, аракы, автономия... Әйтәм бит, бөтен пычрак сүздә син бар. Ә менә минем белән нинди матур сүзләр төзелгән: бал, балет, балык...

«А» хәрефе гасабилана башлады:

– Син, «Б», бик чәпчемә әле, – диде ул, тынычрак булырга тырышып. – Син әйткән «бал», «балет», «балык» сүзләрендә, үзең күреп торасың, мин дә бар. Мин булмасам, бу сүзләр дә булмас иде. Аннары, син үзең дә бит шактый гына күп әдәпсез сүзләрдә зур урын алып торасың.

– Мәсәлән, нинди сүзләрдә? – дип сорады «Б».

– Һе, күп алар... Бәдрәф, б...т, б...к...

Бу сүзләрдән «Б» хәрефе кечерәеп калды. Аның каушавын күреп, «А» дәвам итте:

– Борис Ельцин исемендә дә син бар. Әле син «Берия» дигән сүздә дә иң беренче булып торасың.

Барысын да тыңлап торган «В» хәрефе дә бәхәскә кушылып китте.

– Чыннан да, «Б», син, үзеңнең кем икәнлегеңне белә торып, өскә үрмәләргә тырышасың, – диде ул. – Мин беренчелекне дәгъва-

ласам, әле бер хәл иде, чөнки андый пычрак сүзләрдә катнашканым юк. Минем белән бары тик кирәкле һәм файдалы сүзләр генә башлана: валерьянка, валидол, валюта...

Моңа кадәр сабырлыгын җыеп торган «Г» хәрефе «В»ның сүзен кырт кисеп бүлде:

– Ә «волюнтаризм»ны кая куясың?! Ә «вандал», «Ворошилов» сүзләрен оныттыңмыни? «Совет» дигән сүздә дә үзеңә урын тапкансың. Тыныңны да чыгарма! Монда мин генә гөнаһсыз! Мин алфавитның башында торырга тиеш! Чөнки затлы хәреф булгач, «Галактика», «Галәм», «гармун» кебек сүзләр берегез белән дә түгел, минем белән башланганнар.

Шулвакытны «Е» хәрефе чәчрәп чыкты:

– Оятсыз! Җирбит! Син дә хәрефләр рәтендә торган буласың, хәшәрәт! ГКЧП дигән коточкыч сүздә син бит иң беренче булып килеп чыктың. Сине алфавиттан бөтенләй юк итәсе бар. Заманында менә мине синең кебек тираннар харап итте. Мин – репрессияләнгән хәреф. Заманында мин ике хәреф идем – өстемдә тагын ике ноктам бар иде. Ул «ЙО» дип атала иде. Мине нокталарымнан мәхрүм иттеләр. Мин, җәберләнгән хәреф буларак, алфавитта беренче булып торырга тиеш!

«А» белән «Б» арасында чыккан бәхәс бөтен алфавитны урыныннан куптарды. Һәм әле моңарчы булмаган гауга чыкты. Башка хәрефләр «Е»ны да, «ЙО»ны да мәсхәрәләп ташладылар. Урыс телендә «Е» һәм «ЙО» белән бик күп әшәке сүзләр башланганын да мисал итеп китерергә онытмадылар.

Һәрбер хәреф үзен башкаларга караганда өстенрәк, кирәгрәк дип саный иде, һәрберсенең беренче буласы килде.

– Алфавитны үзгәртергә кирәк! – дип кычкырдылар барысы да.

Әллә нинди тәкъдимнәр туды.

ГКЧП сүзендәге дүрт хәрефне юк итәргә өндәүчеләр дә булды. Сүгенү сүзләрендә катнашучы хәрефләрне дә алфавиттан сызып ташларга кирәк диелде.

Начар сүзләрне өйрәнү өчен тикшерү комиссиясе төзелде. Әшәке сүзләр шулкадәр күп иде. Нәтиҗәдә алфавитның һәр хәрефе теге яки бу әшәке сүздә урын алып тора иде. Ямьсез сүздә катнашмый калган хәреф алфавитта юк икән.

Сүзләр боламыгында барлык хәрефләр буталып беткән булганга, аларның берсен алып, аның урынына икенчесен куярлык түгел иде.

Гөнаһсыз, чиста хәреф табылмады.

Төрле экспериментлар, урын алыштырып, манипуляцияләр ясап карагач, бернәрсә ачыкланды: хәрефләрнең алфавиттагы тәртибен алыштыру сүзләрнең язылышын да, мәгънәсен дә үзгәртә алмый икән.

Ә сүзләрдә хәрефләрнең урыннарын алыштырырга беркем дә батырчылык итмәде. Чөнки бит моның өчен коточкыч революция кирәк!

1991

ГОНОРАР

«Эт чаба дип, бет чаба». Гаптеринең дә җиңел генә байыйсы килде. Беркөнне ул һинд чәе пачкасындагы рәсемгә игътибар итте. Хәтерләсәгез, әлеге дә баягы рәсемдә сакаллы агай филгә атланып бара.

– Карале, бу мужик тач миңа охшаган бит! – диде Гаптери үз-үзенә.

Һәм ике дә уйлап тормады, шул ук көнне берничә гәҗиткә хат язды. Имеш, ничәмә еллар буе, бернинди түләүсез-нисез аның сурәтен чәй кабында кулланалар. Ә гонорары кая?! Аңа бит ишелеп һәм умырылып акча килергә тиештер!..

Мәгълүм ки, гәҗитләр андый сенсацияләрне эләктерергә генә торалар. Берничә көн үтүгә, чәй пачкасындагы кешенең Баткаклы авылында мал врачы булып эшләүче Гаптери икәнлеге хакында дүрт гәҗит берьюлы язып чыкты. Имештер, Гаптери атка атланган булган икән. Чәй кабын ясаучылар юри, атка борын өстәп, фил ясап куйганнар.

Кичекмәстән комиссия төзелер, һәм чыраен чәй пачкасы белән чагыштырып карагач, каерылып гонорар килер дип, Гаптери көтә башлады.

Гәҗитләр, берсен-берсе уздырып, су куша-куша, «Чәй пачкасындагы ветеринар Гаптери» хакында гәп куерттылар.

Ә гонорары һаман килмәде.

Кинәт бөтен авыл халкы «Гаптери баеп китмәгәе» дип пошаманга калды. Әле гонорар күренмәсә дә, Гаптерине инде күралмый башладылар.

«Алачак гонорарының яртысын колхозга бирсен!» – диде авыл халкы бертавыштан. Һәм күп тә үтмәде, Баткаклы халкының күмәк хаты гәҗитләрдә дөнья күрде.

«...Рас Гаптери атланган фил фил түгел, ә ат икән, димәк, ул ат колхозныкы. Шул сәбәпле алай-болай Һиндстаннан һәм башка илләрдән Гаптеригә валюта килә башласа, аның яртысы колхозга тапшырылырга тиеш. Дөресен әйткәндә, Гаптери ул рәсемдә үзе атланган хайванга караганда ямьсезрәк. Соңгы вакытта ул эшендә дә начар эшли. Дүрт сыер ящур белән үлде. Какуй ул ветеренар! Оятсыз!»

Хат болай дип тәмамланган иде: «...Юньле булса, аны хатыны ташлап китмәс иде...»

Гонорар һаман килмәде.

Ә менә рэкетирлар «озак көттермәделәр», беркөнне алар Гаптеринең капка төбенә бер «Мерседес» һәм ике «девятка» белән килеп туктадылар. Авыл халкы аларны Гаптеригә гонорар алып килгән комиссиядер дип уйлады. Һәм мәш килеп гонорарның яртысын колхозга бирүне таләп иттеләр. Ләкин «Мерседес»тан чыккан әзмәвердәй бәндә авылдашларга ашәке итеп сүгенгәч һәм кыска гына әңгәмәдән соң Гаптеринең күз төбендә шәмәхә «гонорар» хасил булгач, халык сагаеп калды. Бу какуй-то не такуй комиссия иде.

Гаптерине тентеп, зур акча тапмагач, рэкетирлар аның бер сарыгын «Мерседес» багажнигына салып алып киттеләр. Сарык мескен үзенең «Мерседес»ларга гына утырыплар китүләрен аңлагандырмы-юкмы – мәгълүм түгел.

Ә гонорар һаман килмәде.

Беркөнне Гаптеринең йорты каршына, чыелдап, «Волга» машинасы килеп туктады. «Монысы безнең машина, валлаһигазим, акча алып килгәннәрдер!» – диде халык. Әмма вәләкин машина эченнән, мыш-мыш килеп, биш ел элек Гаптерине ташлап киткән Саҗидә килеп чыкты. Чәй кабындагы кешенең элекке ире икәнлеген ишеткәч, вөҗданы аңа алимент сорап килергә кушкан.

Гаптери чәчрәп чыкты:

– Нинди алимент?! Безнең балаларыбыз булмады бит!

– Аның каравы синнән киткәч булды! – дип чатнатып җавап бирде Саҗидә.

Гонорарның әле килмәгәнлегенә инангач, чәй пачкасындагы фил хәтле гәүдәсен әвеш-тәвеш китереп, Саҗидә: «Килгәләп йөрермен», – дип чыгып китте.

Гонорар гына килмәде. Ләкин килер сыман иде.

Авыл халкы Гаптерине сагалый башлады. Кая бара, кем белән аралаша, почта аңа нәрсә китерә – барысын да белешеп, күзәтеп, хәбәрдар булып тордылар. Хәтта Гаптери калага барганда да аның артыннан күзәтчеләр җибәрә торган булдылар.

Ә гонорар күренмәде.

Аның каравы рэкетирлар тагын өч тапкыр килеп киттеләр һәм дә Гаптеринең чираттагы бер сарыгы, ике казы, сигез тавыгы «Мерседес»та «важно» гына китеп бардылар.

Ә менә беркөнне капка төбенә микроавтобус туктады. Аның эченнән пөхтә, юан һәм галстуклы кешеләр төште. Авыл халкы аларны чолгап алды һәм, гөж килеп, валютаның яртысын сорады.

Кызганычка каршы, болары налог инспекциясе булып чыкты. Допрос ясап Гаптеринең җелеген корыттылар. «Син Һиндстаннан дополнительный доход аласың дип ишеттек, давай налог түлә!» – диделәр.

Бу алдашуга ник тотынганына Гаптери үкенә башлады. Тик шулай да кинәт баю теләге барыбер әле өстен һәм көчлерәк иде.

Инде рэкетирлар бөтен мал-туарын, кош-кортын алып киттеләр, Саҗидәнең сөяркәләре бик каты кыйнадылар үзен, налог инспекциясе «Налог түләмәсәң, төрмәгә утыртабыз!» дип янады.

«Килмәде әле ул акча!» – дип өзгәләнде Гаптери. Ләкин аңа никтер ышанырга теләмәделәр.

Тора-бара тирә-якка Баткаклыда миллиардер яши икән дигән хәбәр таралды. Һәм шул арада күрше районнардан мәчетләр төзергә акча сорап унике мулла, сигез абыстай һәм бик куркыныч кыяфәтле унбиш кеше килде.

Алардан соң Казаннан, безгә спонсор булалмассыз микән дип, яшь җырчылар, артистлар килә башлады.

Күрәчәкне күрмичә, гүргә кереп булмый, ди. Гомергә балалары булмаган Гаптеринең инде җитлеккән дүрт малае һәм ике кызы табылды. Аларның һәммәсе үзен Гаптеринең газиз баласы дип төрлечә исбатлады.

Гонорар гына килмәде.

Авыл халкы барыбер Гаптерине куралмады, чөнки кайчан да булса аның баеп китү ихтималы җаннарына тынгылык бирми бимазалады.

Кыйнаулар, допрослар, акча даулаулар эзсез-тәэсирсез үтмәде. Гаптери көннән-көн шәлперәя барды, ябыкты, хәлсезләнде. Һәм түзмәде, инде рэкетирлар соңгы үрдәкне алып киткәч, өйдә җиһаз калмагач һәм Сажидәнең сөяркәләре бөтен кабыргаларын сындырып бетергәч, гәҗитләргә хат язды: «Мин алдадым, чәй пачкасындагы кеше мин түгел!»

Шуннан соң яңа табылган балалары аны өерелешеп кыйнадылар.

Тагын бер каты ударны прокуратура ясады – алдашканы өчен зур штраф чәпәде. Аның инде штрафка түгел, хәтта тәмәкегә дә акчасы юк иде. Күршесе Чатан Зәгыйдулла чәй кабындагы кешенең Гаптери икәнлегенә инде мәңгегә инанган иде һәм: «Баегач, гонорарыңнан биш процент бирерсең», – дип, штраф түләргә әҗәткә акча биреп торырга булды.

Дөресен әйткәндә, гонорарны Чатан Зәгыйдулла гына түгел, бөтен авыл халкы көтте. «Хитрить итә, – диде халык, – гонорарның яртысын бирмәс өчен бөгештерә...»

Ә Гаптери бичара урын өстенә ятты – җан һәм тән җәрәхәтләре мәңге төзәлмәс кебек тоелды. Шулчакны гонорарсыз гына, хәерче булып яшәсәң, җан тынычрак булуына инанды ул.

Аның үлүен бөтен авыл теләде. Чатан Зәгыйдулла гына Гаптеринең биш процентын бирмичә бу дөньядан китүенә каршы булды. Һәм күршесен булдыра алган кадәр карады, дәвалады.

Ә гонорар барыбер килмәде.

Алланың рәхмәте һәм Чатан Зәгыйдулланың ярдәме белән, Гаптери савыкты, аякка басты. Һәм кичекмәстән Баткаклыдан китәргә карар кылды.

Атна-ун көн вакыт узгач, ул, калган малын «газик»ка төяп, авылдан чыгып китте.

Рэкетирлар, налог инспекциясе, Сажидә, караклар, хәерчеләр, спонсор эзләп йөрүчеләр, авылдашлар, әллә каян килеп чыккан балалары һәм, әлбәттә, биш процент иясе Чатан Зәгыйдулла – барысы да Гаптеринең кая юл тотканын һәм кайда яшәячәген инде күптән белешеп куйганнар иде...

1994

КОНТРА

1930 елны Җир шарында әһәмиятле ике вакыйга булды. Германиядә рейхстагка сайлаулар барган көннәрдә, Чатырлы авылында юләр Сәлимҗан колхоздан чыкты. Бу ике политик акциядә һичшиксез нindидер бәйләнеш барлыгын сизенгән ГПУ Чатырлы авылына контрреволюционерларны, шпионнарны ачыклауда каешланып беткән чекист Галәмшинны җибәрде.

Иң элек колхоз председателе Шәйхине чакыртып бик озак сөйләштеләр. Галәмшин Чатырлыга баргач, үзен яңарган авыл, колхозлар һәм якты киләчәк турында роман язучы дип танытырга тиеш була, ә Шәйхигә аны юләр Сәлимҗанга фатирга кертергә әмер бирелә.

Шулай итеп, шпионнар тотуда эт каешына әйләнгән Галәмшин, Сәлимҗанда яшәп, аның Германия разведкасының Чатырлы авылында совет властена каршы көрәшеп ятучы агенты түгелме икәнен ачыклау эшенә керешә. Хуҗа белән ул бик тиз уртак тел таба. Кунак үзенең ягымлылыгы, акыллылыгы белән Сәлимҗанның да күңеленә хуш килә.

Әртилдән чыкканда, Сәлимҗанга колхоз абзарыннан бердәнбер кәҗәсен кире бирмәделәр. Шул ачудан ул берничә көн сүгенеп, арлы-бирле, керә-чыга йөрде. «Әһә, фашист партиясенең сайлауларда социал-демократларга караганда азрак тавыш җыюына эче поша моның, шуңа күрә үзен кая куярга белми, – дип уйлады бик күп «вредительләрнең» башына җиткән контрразведчик. – Аңлыйм, бик аңлыйм хәлеңне, контра!..»

Ул, Сәлимҗанның бер хәреф тә танымавыннан файдаланып, романны яза башлыйм дигән булып, гаепләү материалларын төзергә кереште.

Кәҗәсен кызганып, колхоз председателе Шәйхине каргау Галәмшинның кәгазьләрендә совет властен каһәрләү булып сурәтләнде. Урамда аерым хуҗалык иясе Зәйдулла белән тәмәке тартып, җыен юк-барны сөйләшеп утыруы Сәлимҗанны «үз ишләрен бер оешмага туплап, колхозларга каршы агитацияләүдә» гаепләргә бик җайлы булып чыкты.

Ә беркөнне сәкедә юа ашап утырганда: «Әй, чукынсынсана кәҗәсе, ачтан үлмәм әле», – дип ачы өзгәләнеп әйтүе «...колхоз мал-туарының тизрәк үлеп, кырылып бетүен тели...» дип, уяу чекист тарафыннан адәмнәрнең язмышларын хәл итә торган «роман»га теркәлде.

Тәбәнәк буйлы, чатан аяклы, җәенке борынлы һәм кысык күзле, чыраеннан миңгерәүлек катыш беркатлылык кычкырып торган, әмма бөтенләй үк аңгыра булмаган, ләкин шулай да барыбер акылга туеп җитмәгән 30 яшьтәге НКВД колы Галәмшин Сәлимҗанның юри генә юләр булып кылануына шикләнми иде. Бик күп шпионнарны тоткан гыпыушникның баш миендә: «Бигрәк тәҗрибәле разведчик булып чыкты бу, кара, ничек оста итеп юләргә сабыша, күр әле син аның осталыгын... Сволочь!.. Кон-

тра!..» – дигән уйлар көннән-көн тирәнрәк уела килде. «Ничего, тиздән эләгерсең кармакка», – дип, йорт хуҗасын төрле баш бутагыч сораулар белән «капшап» интектерә башлады. Ә тегесе исә, аны-моны уйламыйча, сөйләшергә кеше булу сөенеченнән дөньясын, хәтта кәҗәсен дә онытып, теленә ни килсә, шуны сөйләп тик утырды.

Ләкин беркөнне Аллаһы Тәгалә ГПУ агенты Галәмшинның мескен Сәлимҗанга каршы башлаган кампаниясен туктатырга исәп итте, ахрысы.

Сәлимҗан тозга һәм керосинга дип калага киткәч, Галәмшин ашыга-ашыга өйне, каралты-кураны тентергә кереште. Сәлимҗанның бәхетсезлегенә каршы, утны-суны кичкән ГПУ агенты кар базына төшәргә маташканда, аягы баскычтан таеп китеп, башы белән баз төбенә кадала һәм шунда аның муены шартлап сына.

Дөньяда халыкара хәлләр кискенләшә барганда, илдә рәхимсез сыйнфый көрәш кайнаганда, «халык дошманы» Сәлимҗан бер куркусыз рәхәтләнеп калада йөргән чагында, җаны-тәне белән шул Сәлимҗан аше бандитларга каршы көрәш алып барган контрразведчик Галәмшин дөм караңгы сасы кар базында батырларча һәлак булды. Мәңгелек дан аңа!..

Ходай моны белмәде микәнни: Галәмшинның тормышына нокта кую – бичара Сәлимҗанны Кояш тирәли әйләнгән Җир шарына утырып йөрүче адәмнәр исемлегеннән сызып ату белән бер иде ләбаса... Чөнки сыйнфый көрәш бара! Коточкыч көрәш!

Сәлимҗан өч көн үткәч кайтты. Авылда бер кеше дә юк, халык колхоз болынында печән чаба. Аның күңелен авылга кергәндә үк ниндидер шом баскан иде, хәвеф-хәтәр киләсен сизенгән иде инде ул. Күршесе кылый Нурулланың эте дә өреп-нитеп тормады бу юлы, бер чинап алды да капка астыннан ишегалларына шуып кереп китте.

...Ул, күзләрен акайтып, арыш саламына охшаган чәчләрен үрә торгызып, болынга чапты. Тиргә баткан ертык күлмәгенең итәген бөгәрли-бөгәрли «язучы»ның базга егылып үлгәнен тотлыга-тотлыга көчкә аңлатты.

Авылдашлары аңа ат җигеп бирделәр дә: «Бар, агайне, мәетне калага үзең илтеп тапшыр инде, – диделәр. – Милициягә илт син аны».

«Немец шпионы» мәрхүм «язучы»ның башланган «роман»ын да милициягә тапшырырмын дип, бик әйбәтләп чүпрәккә төреп куенына тыкты да, мәет өстендә йөргән чебеннәрне кугалап, атны калага чаптырды.

Аны озатып калган Шәйхи: «Халык дошманы» булса да, начар кеше түгел иде бу Сәлимҗан», – дип уйлап, авыр сулап куйды. Сәлимҗан белән кыямәт көненә кадәр бүтән күрешмәячәгенә шиге юк иде председательнең. Шул көнне, контра малын колхоз абзарында тоту ярамас дип, Сәлимҗанның кәҗәсен Шәйхи урамга куып чыгарды.

Бер атнадан Чатырлыга хәбәр килде: юләр Сәлимҗанны төрмәгә утыртканнар. Ятим үскән, аңгы-миңгелеге белән дан казанган, бер гөнаһсыз булып саналган җан иясе «контрреволюцион элемент», «халык дошманы», «коммунизм төзүгә комачаулаучы», «Германия шпионы» һәм, ниһаять, «ГПУ вәкилен үтерүче» булып чыкты.

Тик, өч ай чамасы вакыт узгач, Сәлимҗан, тешсез авызын ерып, бик зур эш майтарган кеше шикелле, чатан аяклары белән җилҗил атлап, көтмәгәндә Чатырлыга кайтып керде.

...Тикшерү вакытында (врачларга рәхмәт яусын инде) Сәлимҗанның диваналыгы шыр ярып кычкырып торганга күрә, эшне туктатырга булдылар. Тумыштан ук бер җан иясен дә сөймәгән следователь, бер килгәч буш кайтмасын инде дигән шикелле, сугып Сәлимҗанның алгы тешләрен койды да: «Бар, чүпрәкбаш, күземә күренмә бүтән!» – дип, аны кабинетыннан куып чыгарды.

Сәлимҗан, урамга чыккач, тротуарда җыелып торган яңгыр суы белән авызын чайкады да, котылуына чиксез куанып, следовательгә эченнән генә рәхмәтләр укый-укый, туган авылына юл тотты.

Капкасы төбендә дөньядан ваз кичеп яткан газиз кәҗәсен күргәч, ул үзен дөньяда иң бәхетле кешедәй хис итте.

Авылдашлары гына читләште Сәлимҗаннан. Аерым хуҗалык Зәйдулла да аның белән тәмәке көйрәтеп, дөнья хәлләрен сөйләшеп утырудан баш тартты. Бердәнбер иптәше, сердәше булып кәҗәсе генә калды. Өч ай төрмәдә ятып ниләр күргәнен, следовательнең ничек итеп сорау алганнарын – барысын да бәйнә-бәйнә сөйли иде үзенең бердәнбер якын җан иясенә. Тик кәҗә генә, коточкыч заманда яшәвен аңлап булса кирәк, хуҗасы сөйләгәндә сакалын селкетә-селкетә башын читкә бора иде. Ишетмәмешкә салына, янәсе. Имеш, сәясәткә тыгылмый.

Кыш көне кәҗә вафат булды. Бик карт та түгел иде югыйсә. Колхоз утарында бер-бер чир эләктерде микән, әллә инде хуҗасы «халык дошманы» булудан гарьләнеп, протест белдерде микән – аның шулай кинәт үлеп китүенең сәбәбе турында тарих архивларында бер мәгълүмат та сакланмаган.

Гомерендә беренче тапкыр шулай ачынып елады Сәлимҗан. Базында ГПУ агентының мәетен тапкач та бу кадәр кызгану хисе уянмаган иде аның күңелендә.

Шул ук көнне каладагы ГПУ бүлегенә колхоз председателе Шәйхи тарафыннан мондый кәгазь җибәрелде: «Юләр дип төрмәдән азат ителгән Гыйләҗев Сәлимҗан Мотыйк улы совет властена каршы көрәшен дәвам итә. Биш ай колхоз абзарында яшәгәне өчен, совет властена ачу итеп, 24 декабрь көнне кәҗәсен үтерде».

Сәлимҗан кәҗәсен бакча артында күмеп йөргән вакытта, бу донос теге теш коярга ярата торган следовательнең кулына барып эләкте. Тик, күрәсең, Ходайның кәефе күтәренке вакыт булгандыр инде – шул көнне үк следователь исемен йөртүче ерткыч кулга алынды һәм үзе дә, «халык дошманы» дип, планетаның Лена елгасы Боз океанына тоташкан районына олактырылды. Ә Сәлим-

җан өстеннән килгән кәгазь иксез-чиксез донослар, жалобалар, протоколлар арасында югалды. Бүгенге көнгә кадәр ул «документның» күзгә чалынганы юк әле.

Сәлимҗан исә үзе тормыш ыгы-зыгысында һич тә югалмады, сәяси вакыйгаларның үзәгенә эләгеп, күзәтү астында калды.

Туры килеп торуын кара әле син аның... 1938 елны Троцкий эмиграциядә мәш килеп IV Интернационалны оештырып маташкан көннәрдә, Сәлимҗан өч көн рәттән Мукшы күленнән беләк буе сазаннар тотып алып кайтты. Кәеф яхшы, авыз ерык, сөенәсөенә кайта да балыкларын тозлап киптерергә элеп куя ул.

Председатель Шәйхинең төн йокылары качты. «Нәрсәгә сөенә икән бу тинтәк, нәрсәгә әзерләнә икән?..» – дигән уй аның җанын ашады.

Кипкән балыкларын кала базарына сатарга барганда, урманны чыккач, Сәлимҗанны кулга алдылар.

Таныш булмә... Следователь генә икенче. Монысы яшьрәк, тик тегесеннән дә явызрак күренә. Сорау алу алай бик озакка сузылмады.

– Бу балыкларыңны кая алып бара идең син?..

Көтмәгәндә балыксыз калу табигатьтән йомшак булган Сәлимҗанны бик тә рәнҗеткән иде. Кинәт ул утырган урындыгыннан сикереп торды да, җәенке борынының тишекләрен тагы да киңәйтебрәк, ярсудан акайган күзләрен следовательнең итләч чыраена кадап, мәрхүм кәҗәсенекенә охшаган тавыш белән кычкырырга тотынды:

– Кая, кемгә алып барсам да барыбер түгелмени?! Анда синең ни эшең бар?! Минем балык бит ул! Ничәмә көн Мукшыда салкын су ерып тоттым бит мин аларны!..

Следовательгә барысы да аңлашылды, аның башка сораулары булмады. Сәлимҗан авыз кырыендагы селәгәйләрен күлмәк җиңе белән сөрткәләгән арада, өстәлдә тиз генә «Кипкән балыкларын посылка белән Троцкийга җибәрмәкче булган...» дигән документ туды.

...Сәлимҗан, алты елга хөкем ителеп, лагерьга җибәрелде. Следователь Шурин, чираттагы ялын алып, бераз какшаган сәламәтлеген ныгытырга Сочига китте.

Судта Сәлимҗан аптырагач үзенең миңгерәү икәнен искә төшереп: «Карале... ни... Өтерменгә утыртмагыз инде мине... Мин бит җүләр...» – дип тә караган иде. «Инде акыллыланырга вакыт!» – дип җавап бирделәр аңа.

...Бер ел тайгада урман кискәннән соң, язмыш Сәлимҗанга тагын елмаеп куйды. Эчке эшләр комиссариатында җитәкчеләр алышыну уңаеннан амнистия игълан ителде.

Лагерьда кемнәрне генә күрмәде дә кемнәр белән генә очрашмады Сәлимҗан. Политтоткыннар, кеше үтерүчеләр, караклар, тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр белән... Статьясы политикага

бәйле булса да, акылы иләс-миләс булганга күрә, ул политтоткыннар белән аралаша алмады, ә уголовниклар исә аны үзләре янына якын да китермәделәр. Шуңа күрә ул Субай авылының үзе шикелле үк акылга туеп җитмәгән керәшене белән бер кечкенә, ике кешелек аерым «группа» тәшкил итеп яшәде.

Микайла (иптәшенең исеме шулай иде) амнистиягә эләкмәде. Чөнки ул дәүләт өчен, халык өчен, гомумән, социализм өчен иң куркыныч элементларның берсе иде.

Ул ата дуңгызына (белмим, кайлардан тапкандыр, кемнәрдән ишеткәндер андый сүзне) Лаза дип исем куша. Беркөнне моның урамда, шыранлап: «Лаза! Лаза!» – дип дуңгызын чакырганын ишетәләр. Диваналыгы белән бөтен тирә-якта танылган Көрпә Микайла икенче көнне авылдан юк була һәм, Лазарь Кагановичны мыскыл итүдә гаепләнеп, ун елга ирегеннән мәхрүм ителә.

Ике дус аерылышканда Микайланың срогы беткәч очрашырга вәгъдәләшәләр. Ләкин аларга инде кабат күрешергә насыйп булмый.

Беркөнне йоклар алдыннан бушлатында мыж килеп йөргән бетләрне сытып утырганда, Микайла үз гомерендә соңгы политик җинаятен кыла.

– Рәхмәт әйтсеннәр әле шундый пычрак кешенең исемен бер гөнаһсыз дуңгызыма биргәнем өчен, – ди.

Бу сүзләрдән соң Субай авылының ат караучысы Көрпә Микайла Җир йөзеннән юк була.

...Ә бу вакытта инде Сәлимҗан, Мукшы күленнән балык тотып, авызының эчендәрәк исән калган берничә теше белән юа күшәп, ягарга урманнан чыбык ташып, бәхетсез язмышыннан берсүзсез канәгать булып, беркемгә дә ачу тотмыйча яшәп ята иде.

Тик, лагерьдан кайткач, авылдашлары аның белән сөйләшмәү генә түгел, хәтта аңардан кача торган булдылар. Кәтерҗән Сәлимҗан исеме белән ата-аналар балаларын куркыта башладылар.

Еллар үткән саен, кушаматлар берәм-берәм онытыла барды. Тик менә Контра дигәне генә бик ябышкак һәм озын гомерле булып чыкты. Сәлимҗан ул сүзнең мәгънәсен бөтенләй тирәннән үк аңлап бетермәсә дә, аның начар кешегә, дошманга әйтелә торган сүз икәнен белә иде. Шуңа күрә барысы да аңа контра дигәч, үзенең контра икәненә тәмам ышана башлады. «Күрәсең, мин шундый начар кешедер инде» дигән уй белән килешеп яшәде ул. Бөтен авыл дошман дигәч, дошмандыр инде...

Ә үзе исә ул бу дөньяда бер генә кешене дә дошман итмәде. Үз хәле, үз язмышы белән килешеп, кояшлы һәр таңны куанып каршы алып, бу вәхши дөньяга булган чиксез мәхәббәтенә хыянәт итмичә яши бирде.

...Сталин үлгәч, аңа сарык көтүен көтәргә рөхсәт иттеләр. Бу сөенечтән аның яшәешкә мәхәббәте икеләтә артты. Шулай да авылдашлары аңардан читтәрәк булырга тырыштылар.

Көтүче сумкасын җилкәсенә асып, чыбыркысы белән бергә Контра кушаматын сөйрәп, Сәлимҗан гомер сукмагыннан картлыгына таба атлавын дәвам иттерде.

...Сиксәненче елларда гына аның белән сөйләшә башладылар. Яшьрәкләр: «Сәлимҗан бабай, син «халык дошманы» идеңмени, төрмәләрдә утырдыңмыни?.. Контра дигән кушамат та шул еллардан калдымыни?..» – дип сорагач, Сәлимҗан: «Әй, булды инде андый гөнаһлар... Җәш чак бит, палитиканы аңлап бетермәгәнмендер инде», – диде. «НКВД работниклары бер гаепсезгә кешеләрне төрмәләргә яба торган булганнар, дөресме ул?» – дигәч, сиксән яшьтән узган Контра – Сәлимҗан кызып китә иде:

– Җу-у-ук! Бик чисный, бик әйбәт кешеләрие алар... Утызынчы җылда миндә бер гыпыушник кунак булып торгание... Мәрхүм, базга җыгылып үлде. Иллә дә ыспай, җагымлые, урыны җәннәттә булсын. Аннары берсе мине өтермәнгә утыртасы урынга тешләремне генә койды да кайтарып җибәрде, рәхмәт җаугыры... Ә бер тапкыр алты җыл биргәннәрие, бик тиз чыгардылар лагирдан. Җу-у-ук, бик яхшы, кешелекле ие гыпыушниклар...

Соңгы вакытта авылдашларының якты чырай күрсәтүеннән, үзенә игътибар итүләреннән Сәлимҗанга гүя канатлар үсеп чыкты. Исерек кеше шикелле авыл урамнарыннан көненә әллә ничә тапкыр үтеп, очраган бер кеше белән кычкырып исәнләшүдән җан рәхәте таба башлады ул.

Ә беркөнне көтү көткән болыннарына чыгып керергә булды. Беркавым дөньяның матурлыгына, аның киңлегенә, яшәүнең рәхәтлегенә сокланып йөргәч, кинәт аңарда кешеләргә рәхмәт әйтү теләге туды һәм күңеленнән ташып чыгарга торган мәхәббәтен авылдашларына ничек тә булса белгертәсе килеп, авылына таба йөгерде.

Каян килгәндер гомер буе юньле ашау да күрмәгән сиксән биш яшьлек картка йөгерерлек хәл!..

Тик, әллә артык шатланудан, әллә йөгерүдән, авылга җиткәндә аның сулышы буылды, аяклары тотмый башлады. Шулчак ул әҗәле килгәнен аермачык тойды.

Басу капкасы төбендәге чирәмгә егылгач, Сәлимҗан торырга маташып карады, ләкин булдыра алмады. Аның томанлы күзләре күктә ашыга-ашыга аккан болытларга ялварып карады. Әмма, аны гомере буена кешеләр санга сукмаган кебек, болытлар да бер адәмнең дөнья белән бәхилләшеп ятуына исләре китмичә, офыкка таба бер-бер артлы актылар да актылар.

«Халык дошманы» икәнлегенә ышанып гомер кичергән Сәлимҗан актык сулышларын алганда үзен бик тә гаепле, кешеләргә бурычлы итеп тойды. Алардан гафу үтенеп, кичерүләрен сорыйсы килде.

Бер якын кешесе дә булмаганлыктан, бу минутларда берәүнең дә исеме аның исенә төшмәде. Бары тик янында яшел үлән чемченеп йөргән сары бәбкәләргә ишетелерлек кенә булып, күгәргән

иреннәреннән «ә-ә-ә-әй» дигән офтанулы чакыру-ялвару сытылып чыкты. Аңа җавап итеп, ата каз бик яман ысылдап куйды. Әйтерсең лә шул ата каз да белә Сәлимҗанның илле биш ел контра булып йөргәнен.

Контра – Сәлимҗан дөньядан китте. Менә инде дүрт ел хәбәрехәтере юк...

1989

КЫЗЫК ЗАМАНДА ЯШИБЕЗ!

Баш түбәсендә ике бет очрашты.

– Нихәл, агайне!

– Аллага шөкер! Үзең сау-сәламәтме? Кәефләр ничек?

– Әйбәт.

Бетләр чәч бөртеге төбенә җайлап урнаштылар да дөнья хәлләрен сөйләшергә тотындылар.

– Да-а-а, – дип сузды Беренче бет, башын кашып, – бик дөрес әйтәләр кызык һәм вакыйгаларга бай заманда яшибез дип. Чынлап та, искиткеч әйбәт замана килде бит безгә, туган, ә...

– Әйтмә дә генә инде, – дип җөпләде аның сүзен Икенче бет. – Сугыштан соң рәхәт күргән юк иде, бу үзгәртеп корулары бик шәп нәрсә булып чыкты бит. Бик кызык чорда яшибез, бик кызык!

Беренче бет, башның иясе ишетмәсен дигән сыман, тавышын бераз әкренәйтте:

– Безгә, шампунь-мазар юклыктан файдаланып, үрчеп калырга кирәк. Бәлки, тарих шулай соңгы шанс бирәдер. Бәлки, мондый уңай шартлар киләчәктә насыйп булмас та...

Икенче бет тә пышылдауга күчте:

– Шулаен шулай да, әмма ләкин үрчергә бик авыр шул – кешенең чәче сирәгәйде хәзер. Ярый ла (ул үзләре яши торган башка аяк табаны белән тибеп күрсәтте) моның чәче хәйран куе әле – яшәргә дә, үрчергә дә була. Бөтенләй пеләш кешеләр күп бит. Үзең беләсең, андый кешеләрдәге бетләр ыштан төпләренә кача-поса интегеп гомер сөрәләр. – Бет авыр сулап куйды. – Ыштан төбендәге тормыш тормышмыни инде ул!

– Анысы да дөрес, – дип көрсенеп куйды Беренче бет, тавышын күтәреп. – Тик менә синең шикелле болай пессимизмга бирелсәк, безнең, әлбәттә, киләчәгебез булмаячак.

– Пессимизм дип... Аптыраганнан әйтәм инде. Нәрсә тәкъдим итәсең соң?

Беренче бет, дулкынлануын көчкә йөгәнләп, Икенче бетнең иңенә таянды да тезеп китте:

– Беренчедән, озын, куе, пычрак чәчле кешеләргә күчеп бетәргә кирәк. Икенчедән, бетле башлар арасында элемтәне кеше күп җыелган урыннарда тотарга – митингларда, автобусларда, чиратларда, парламентларда, чөнки мондый урыннарда кешеләр бер-

берсенә бик якын торалар. Һәм, ниһаять, өченчесе, иң нык тешли торган егетләребезне депутатларның башларына күчерергә кирәк. Катырак ашасыннар! Мәсәлән, берәр депутат шапшаклыкка каршы чыгыш ясаса яки сабын-шампунь турында сүз катса, аның башын бөтенесе берьюлы тешләсеннәр! Умырсыннар!

Дулкынлану Икенче беткә дә күчте.

– Тәкъдимнәрең кызыклы гына болай, – дип килеште ул. – Ләкин, дустым, син онытма, депутат бит ул моның шикелле (ул тагын үзләре яшәгән башка типте) хәерче түгел. Депутатның аның, җанкисәгем, сабын-шампуне да, башка әйберсе дә мул. Депутат ул еш юына, белмим, анда нинди генә бет исән-имин яши алыр икән...

– Соң, мин бит инде шуңа күрә дә иң кыю, иң җитез егетләребезне җибәрергә дим, – диде Беренче бет, гасабиланып.

Беркавым тып-тын утырганнан соң, Беренче бет тагын сүз башлады:

– Әйдә бүген без, менә шушы тинтәк башта яшәүчеләр, бергә җыелыйк әле. Нәселебез белән бергәләп киңәшик.

Бу тәкъдим Икенче бетнең күңеленә хуш килде.

– Дөрес әйтәсең, җыелып сөйләшү кирәк. Аннары бүтән башларга да хәбәр итәрбез.

Әңгәмә тагын бер мәлгә тынып торды.

Бераздан Беренче бет ниндидер офтанулы тавыш белән:

– Их, кешеләрнең барысы да безнең хуҗабыз кебек алкаш булса иде, – дип куйды. – Рәхәт тә соң мондый башта яшәүләре. Мунчага бармаганына бер ел була бугай инде.

– Ходай озын гомер бирсен инде үзенә, Ярабби, – дип өстәп куйды Икенче бет.

Беренче бет кыяфәтенә җитдилек кертте:

– Ярар, туган, киттек, җыйыйк кардәшләрне.

– Кайда җыелабыз?

– Шушында.

Бетләр, чәч бөртекләрен аралый-аралый, башка бетләрне әйдәргә чаптылар.

Әмма дә ләкин дөнья хәлләрен алдан белеп булмый шул.

Бетләр җыелып маташкан вакытта, башның иясе шул бетле башын төзәтергә дип, сыраханәгә сөйрәлеп бара иде.

Ул башын төзәткән арада, бетләр барысы да митингка җыелдылар.

Аракы күп эчүдән һәм бетләрнең нык тешләвеннән нервлары шактый какшаган алкаш бик дуамал кеше иде. Бу юлысы да ул сыраханәдә кем беләндер нидер бүлешә алмый сугыша башлады.

...Аның башына арттан шешә белән суктылар. Шешә нәкъ бетләрнең корылтае барган урынга бәрелеп чәлпәрәмә килде.

Баш иясе «ашыгыч ярдәм» машинасында утын агачы сыман дырылдап барганда, Икенче бет исән иде әле. Ул, башын калкытып, күз карашы белән Беренче бетне эзләде.

– Бик кызык заманда яшибез, – дип пышылдады ул, сытылган кан кардәшенә карап, һәм... җан бирде.

1991

АХЫРЗАМАН

Дөнья бетәргә өч көн калгач, күктән мөрәҗәгать яңгырады:

– Хәерле көн, җан ияләре!

Менә инде замана ахыры да җитте. Сезне асрауны дәвам итүнең мәгънәсе калмады – моны инде сез үзегез дә аңлыйсыздыр. Әйтергә кирәк, сезнең тарафтан җиһанның бу түгәрәк вә әйләнмәле сәхнәсендә куелган тарих тамашасы бик күңелле булды. Күп гасырларга сузылган Җир трагикомедиясе бөтен Галәмне таң калдырды. Рәхмәт сезгә!

Хөрмәтле адәм токымнары! Сезне ахырзаман белән ихлас күңелемнән тәбрик итәм!

Дөнья белән хушлашырга өч көн вакыт бирелә. Юынып, ашап куегыз, чөнки теге дөньяда беренче көннәрне сезнең тамагыгызны туйдыру, мунча ягу регламент буенча каралмаган.

Теге дөньяда үзегезне тыныч һәм әдәпле тоту сорала. Барыбер барыгыз да оҗмахка сыеп бетә алмаячаксыз. Җәннәткә иң беренче чиратта юләрләр, алардан соң дин тотучылар, сугыш ветераннары һәм алдынгы дояркалар кабул ителәчәк.

Кыямәт көнендә халык бихисап күп булыр – кешелек тарихында яшәгән барлык адәми затлар гарасат мәйданына җыйналачак. Шуңа күрә анда кычкырып сөйләшү, тәмәке тарту, хатын-кыз белән шаяру катгый рәвештә тыела.

Кадерле җан ияләре! Рөхсәт итегез, сезләрне тагын бер мәртәбә замана ахыры белән тәбрик итәргә!

Хушыгыз!

Ахирәттә очрашуларга кадәр!

* * *

Бу игъланнан соң җирдә хаос башланмады, чөнки эшләр дөнья бетүгә таба барганны һәр аек кеше аңлый иде инде.

Шулай да һушсыз калучылар булмады түгел. Бигрәк тә язучылар аптырашка батты. Тарихка кереп калам дип гомерен романнар иҗат итүгә багышлаган кешегә моннан да авыр хәбәр юктыр...

Кайгыга чумучылар белән беррәттән, дөнья бетәсенә куанучылар да булды. Болар атарга хөкем ителгән җинаятьчеләр, наркоманнар, импотентлар, алиментщиклар һәм Фирзәр Мортазинның күп акча эшләвенә җен ачулары чыгып йөргән көнче композиторлар һәм җырчылар иде.

Әлбәттә, һәркемнең оҗмахка эләгәсе килә. Кешеләр ашыга-ашыга изге вә саваплы эшләр кыла башладылар. Җинаятьләр бетте. Эчү, сугышу, сүгенү калмады. Адәм затлары арасында ихтирамлы, шәфкатьле мөнәсәбәтләр урнашты.

Әби-бабайларны хәер-сәдака биреп акчага күмделәр, озын-озын чиратлар кибетләргә түгел, мәчетләргә, чиркәүләргә тезелде.

Кунакханәләрдә баеп йөрүче фахишә хатыннар, акчаларын төрле фондларга күчереп, авылларга сыер саварга омтылдылар.

Шагыйрьләр, язучылар шул арада тиз генә Аллага мәдхияләр язарга тотынды.

Табигать иркен сулап куйды. Заводларның торбаларыннан агулы төтеннәр чыкмый башлагач, хәтта дөнья бетәсенә сөенүчеләрнең дә бераз яшиселәре килеп китте.

Җирдә әкиятләрдә генә сөйләнә торган, моңарчы кешелеккә хас булмаган Бөек Мәхәббәт хөкем сөрә башлады. Әйтерсең лә Галәмнең бу нәни утравында бик күп гасырлар буе Явызлык һәм аның тугры юлдашы Ялган бөтенләй яшәмәгәннәр.

Бу өч көндә кешеләр шулкадәр үзгәрде ки, әгәр дә планетаны читтән күзәтсәң, анда кайчандыр тираннар булганына, кан һәм күз яше коелганына, һәр илдә, һәр шәһәрдә, һәр авылда Кайгы яшәп ятканына һич тә ышанырлык түгел иде.

* * *

Дөнья бетәсе көнне, шомлы тынлыкны ярып, күктән таныш тавыш яңгырады:

– Хөрмәтле җан ияләре! Гафу итегез, тамашаның иң кызык өлешенә килеп җиткәнбез ләбаса... Мин сездән мондый үзгәрешне һич кенә дә көтмәгән идем. Сез бөтенләй үк әшәке нәрсәләр түгел икән бит. Дөресен генә әйткәндә, мин моңа бик шат. Җирдә әле иман калган икән. Киләчәктә ниләр кыланасыгыз мине гаять кызыксындыра. Шуңа күрә тормышыгызны дәвам итәргә исәп бар. Хәзергә яши бирегез. Дөнья бетәр алдыннан мин сезгә әле тагын хәбәр бирермен. Хушыгыз! Дөнья бетүләргә кадәр!

Җир шары, биш миллиард халыкны һәм башка чүп-чарны күтәреп, Кояш тирәли сәяхәтен дәвам иттерде.

1990

ЕЛЬЦИН ТРАМВАЙГА УТЫРДЫ...

1990 елның август көнне Галәмдә тетрәндергеч сенсация булды. Татарстан язучылары белән очрашканнан соң, бөтен Галактикага даны таралган Рәсәй патшасы Борис Ельцин 2 нче маршрут белән йөрүче трамвайга чыгып утырды.

Бу күренештән кайберәүләр һуштан язып егылды, телсез һәм өнсез калучылар шулай ук шактый күп булды.

Әйтерсең лә дыңгычлап тутырылган халыкны йөртергә күнеккән мескен трамвай, шундый затлы шәхес кереп утыргач, йә шартларга, йә очып китәргә тиеш иде.

Ельцинның трамвайга утыруы митингтагы халыкның аңын томалап, Татарстанга статус, бәйсезлек һәм кер сабыны кирәклеген оныттырды. Бу минутта олысы да, кечесе дә, урысы да, татары

да, исереге дә, аегы да, тәмәкелесе дә, тәмәкесезе дә Ельцинны кочаклап лач-лоч үбәргә әзер иде.

Трамвай келтер-келтер кузгалып китте, аның артыннан әле ике-өч ел элек кенә бер аягы белән коммунизмга кергән, әмма ләкин бүгенге көндә урамда тәмәке төпчеге җыючы кешеләр Ельцинны гына түгел, трамвайны кочаклардай булып артыннан йөгерделәр.

Йөрәк авырулылар, астмалылар һәм олы корсаклылар арттарак калды, ә иң алда Татарстанга союздаш статусы бирүгә каршы кешеләр чапты, чөнки аларның Ельцинга әйтәсе сүзләре бик күп иде.

«...Иллә дә прастуй кеше икән бу Ельцин...»

Рәсәй башлыгының гап-гади трамвайга кереп утыруы Казанны дер селкетте. Мондый каты селкенүне шәһри Казанның 1552 елда гына татыганы бар. Ул вакытта Иван Грозный башкалабызны дары мичкәләре белән дыңгырдаткан иде. Ә Ельцин исә, ике кулын кесәсенә тыккан килеш, трамвайга кереп утырды һәм... шулай итеп «Казанны алды».

Еллар үтәр... Тора-бара, бәлки, 2 нче маршрутлы трамвайлар да булмас, зур кешенең кечкенә трамвайга утыруын тамаша кылган кешеләр дә, тәки рәтле тормыш күрми, бу дөньядан китеп барырлар. Ләкин Ельцинның трамвайга утыруы мәңге онытылмас...

XX гасыр кешелек тарихына ике бөек вакыйга бүләк итте: 1919 елда даһи Ленин өмәдә бүрәнә күтәрде, 1990 елда Ельцин трамвайга утырды. Әле мондый гасырны Бөтендөнья тарихы белми иде.

Сүз ахырында шуны әйтәсем килә: әгәр дә Ельцин, шук малайлар кебек, трамвайның артына асылынып та барган булса, валлаһи, эффект мең тапкыр көчлерәк булыр иде.

1990

КОЛОРАДО КОҢГЫЗЫ

Җәй көне Идел-Вятка регионын вертолеттан күзәтсәң, бакчаларда урталай бөгелгән кешеләрне күрергә мөмкин. Үзгәртеп коруның чыгып килүче кояшына артларын туңкайткан бу кешеләр җиләк-җимеш җыючылар түгел, алар – колорадо кортларын чүпләүчеләр.

Торгынлык елларында пролетариатның 3–4 сутый бакчасын оккупацияләгән ул буржуаз кортлар, илдә барган үзгәрешләргә карамастан, оятсыз рәвештә үрчи бирәләр һәм миллионлаган совет гражданнарын үзгәртеп кору процессында актив катнашудан мәхрүм итәләр.

Колорадо кортын саескан да, карга да, хәтта тавык та ашамый. Нишләп ашасыннар... Димәк, ул кортларның капиталистик илдән

килгәннәрен безнең тавыкларыбыз да аңлый. Шуңа күрә җирәнәләр. Ничек инде «Кызыл Байрак» колхозында туып үскән, кып-кызыл кикрикле тавык әби-бабасы Америкада яшәгән таракан белән үзенең бердәнбер бүтәкәсен пычратсын ди... Юу-у-ук, ашамый ул аны!

Монда ниндидер башка чара табарга кирәк.

Колхозларның бәрәңге басуларына агу сибеп караганнар иде, нәтиҗәдә агрономнар арасында агуланып үлүчеләр күп булды. Ә теге каһәр суккан бөҗәкләргә берни дә юк... Хәзер инде менә авылларда агрономнар җитми.

Әллә, минәйтәм, берничә ел бөтен илебез белән бәрәңге утыртмый торыйк микән?.. Алай дисәң, ачлык башлануы ихтимал. Әле, Аллага шөкер, безне шул бәрәңге коткарып тора да.

Әллә соң бу эшкә төрле корткычларны, паразитларны юк итүдә тәҗрибәсе зур булган Эчке эшләр министрлыгын тартырга микән?..

Һич тә булмаса, җавап акциясе итеп, Көнбатышка үзебезнең йорт тараканнарын җибәрик. Бу эш безнең КГБның хәленнән килергә тиеш. Тик шунысы бар: безнең шапшаклыкка ияләшкән тараканнарыбыз анда адаптация чорын үтә алмаслар. Алар анда ачтан үлеп бетәчәкләр.

Верховный Совет сессияләрен башыннан ахырына кадәр тыңлап утырам. Кызганычка каршы, бер депутат та, колорадо коңгызы проблемасын күтәреп, чыгыш ясамый.

Ну, Америка! Без сиңа моны мәңге гафу итмәячәкбез!

Америка белән СССРның президентлары инде күпме тапкыр очраштылар, ләкин колорадо коңгызы хакында сөйләшкәннәре юк.

270 ел узгач, Русияне корт басасын белгән булса, Петр I Көнбатыштан бәрәңге алып кайтмаган булыр иде, валлаһи.

Минемчә, алга таба да эшләр болай барса, бөтен бәрәңгене корты-ние белән Америкага илтеп ташларга кирәк. Дөге ашарбыз. Кытай белән дуслаштык инде хәзер. Без аларга сабын, шикәр, кер порошогы, суыткычлар, телевизорлар һәм башка вак-төяк бирик, ә алар безгә капчык-капчык дөге җибәрсеннәр. Бәрәңге сагындырыр сагындыруын, ләкин аптырамагыз бер дә – юк әйбер тора-бара онытыла ул. Әнә чәйсез тора алмабыз шикелле иде... Аллага шөкер, оныттык Җирдә чәй барлыгын. Кисель файдалырак та әле – тешне саргайтмый.

Мин эшли торган институтта биологлар колорадо коңгызы турында дистәләгән диссертация якладылар. Аларның фәнни хезмәтләре мондый темалардан гыйбарәт: «Колорадо коңгызының Евразиядә килеп чыгуы...», «Колорадо коңгызының башка бөҗәкләр белән мөнәсәбәтләре», «Колорадо коңгызының хезмәт җитештерүчәнлегенә йогынтысы» һ.б.

Безнең бүлек җитәкчесенең хезмәте иң кызыклысы булырга охшый. Аның диссертациясе «Колорадо коңгызының үзгәртеп

коруга каршы гамәле» дип атала. Әмма вәләкин бер генә галимнең дә шул бөҗәкләрне бетерү өстендә эшләгәне юк. Безобразие!..

Менә, әйтик, бензин проблемасын хәл итә алмый җәфа чигәбез. Кая китә бензин, солярка, керосин? Мин сезгә җавап бирәм: бәрәңге бакчаларына сибүгә китә! Чөнки уксусның гына көче җитми. Шуңа күрә дә хәзер бәрәңгене ашап кикергәч, трактор исе килеп китә.

Дөрес булса, колорадо коңгызы чәчкә сиптерә торган лактан бик курка, ди... Ну, иптәшләр, гафу итегез, чәч лагын бәрәңге бакчасына сиптереп әрәм итеп булмый инде. Сез беләсезме, аны күпме ир-ат эчә?! Аны сиптереп бетергәч, эчүчеләргә ни кала ди? Дихлофоска күчәчәкләр бит.

Нишләргә дә белгән юк инде.

Туктагыз әле, җәмәгать! Ничек элегрәк башыма килмәгән бу уй, ә?! Безнең галимнәребез бихисап күп ләбаса! Мөгаен, илебездәге һәрбер колорадо коңгызына бер галим туры киләдер.

Лабораториядә күз чекерәйтеп микроскоп белән уйнап утырганчы, җәй көне алар җыйнаулашып басу-кырларга чыксыннар. Һәрбер галим берәр генә коңгызны сытса да, бу проблема бер көн эчендә хәл ителәчәк. Барлык профессорлар, доцентлар, докторлар, кандидатлар баканың кан әйләнешен өйрәнеп вакыт әрәм иткәнче бәрәңге бакчаларына чыксалар, валлаһи, бер колорадо коңгызы да калмаячак.

Язам әле Мәскәүгә бу идеямне!..

1989

ҺӘЙКӘЛ

Безнең калада бер һәйкәл бар. Аның кем истәлегенә салынганын беркем дә белми.

Таштан ясалган бу ир кеше, бер кулына китап тотып, икенчесе белән офыкка таба күрсәтеп, бик күп еллар буе шәһәр өстеннән каядыр чиксез ераклыкка карап тора.

Киләчәккә күрсәтәме ул, әллә, киресенчә, сагыну-сагыш белән тарихка текәлгәнме — анысын шулай ук әйтүе кыен. Чөнки, география укытучылары әйтүенчә, дөнья түгәрәк һәм шул сәбәпле кайсы якта киләчәк, кай тарафта үткән заман — билгеләү мөмкин түгел.

Аның сакал-мыегы бар, ә башында — чыпчыклар утырып ял итәр өчен эшләпәсе. Урам себерүче Кашшаф абый аның битендә кошлар калдырган «сәламнәрне» кеше-кара күрмәгәндә себеркесе белән сыпырып төшерә.

Шәһәребезнең шапшаклыктан арынмаячагын каян белгән диген — скульптор һәйкәлне күн итек киертеп ясаган.

Бәлки, исән чагында ул күренекле кеше булгандыр, һәйкәлне бит аны теләсә нинди шырды-бырдыга куймыйлар. Ясаганнар ясавын, ләкин кем икәнен әйтүче юк. Берсе: «Бу – язучы!» – ди, кемдер исә аны шәһәребезне проектлаган архитекторга охшата, ә кемдер, иңнәрен сикертеп, берәр революционердыр, ди.

Бәлки, исән чагында ул бик әйбәт кеше булгандыр, бәлки, берәр адәм актыгы булып, дөньяны бутап йөргәндер. Ничек булса да, кем булса да, халык һәйкәлгә ияләшкән инде. Аңардан башка шәһәрне күз алдына китерүе дә кыен.

Ә менә беркөнне, көтмәгәндә, аның нинди кеше булганлыгы ачыкланды.

Кашшаф абый иртән урам себерергә чыкты һәм чак кына авып китмәде: һәйкәл басып түгел, утырып тора иде. Китабын янына куйган, ике кулы белән башын тоткан. Кашшаф абый, йокыдан уянып җитмәдем микән әллә дип, үзенең ботын чеметеп карады. Юк, өнендә иде… Ул себеркесен тотып атты да кычкыра-кычкыра өенә таба йөгерде.

Бездә халык тиз җыела. Ике-өч минут үтүгә, һәйкәлне шәһәр кешеләренең чуар бозрасы урап алган иде инде.

Аннары, бездә һәр очракта, нәрсә генә булмасын, милиция чакыртырга яраталар. Күп тә үтмәде, бер майор беркетмәме, актмы төзи иде инде.

Сорау алу башланды:

– Ник утырдың?

Һәйкәл башын калкытты:

– Дөрес бармыйбыз. Дөрес якка күрсәтмәгәнмен бит… Ничәмә еллар буе… – Ул тагын куллары белән таш башын кысты.

– Кем соң син?

– Әйтмим, оялам.

Халык гөжли башлады:

– Әйт, курыкма!

– Аның ни оялы бар…

– Ялгышмаган кеше юк ла ул.

Һәйкәл «дөрес бармыйбыз» дигәннән соң, милиционер, халык гөжләгән арада, тиз генә обкомга, аннары КГБга телефоннан шалтыратып килде. Чөнки бу вакыйгадан «сәясәт исе» аңкый иде.

Һәйкәл үзенекен такылдады:

– Дөрес күрсәтмәгәнмен… Дөреслек юк анда…

– Ә кайда бар соң ул? – диде халык көтүе бертавыштан. – Дөрес күрсәтмәсәң ни… Без бит барыбер син күрсәтеп торган якка бармадык…

– Дөреслек бер якта да юктыр инде ул! – дип кычкырды чәрелдек тавышлы хатын.

КГБның эшләре болай да тыгыз булу сәбәпле, күгәреп беткән һәйкәлнең торышын үзгәртүе чекистларны кызыксындырмады.

Үз хәлем үземә җиткән, сакалым билемә җиткән дигәндәй, обком да бу эш белән вакланмады, аны үз агымына тапшырды.

Һәйкәл халыкка үзенең исемен әйтмәсә дә, ни өчен куелганын ярып салды:

– Мин – сезгә якты тормыш күрсәтүче. Дөресрәге, күрсәтеп торырга тиеш идем.

Тамашачыларның кәефе кырылды:

– Әй, әллә юньле кешеме дип торабыз...

– Революционер икән...

– Әнә күрсәттеләр инде, – дип өстәде теге чәрелдәвек тавышлы хатын.

Халыкның һәйкәл белән кызыксынуы кинәт сүрелде, чөнки алар тамаша көткәннәр иде. Ә монда тагын политика! Җитмәсә, иң эчне пошыра торган темага – якты тормыш, якты киләчәк турында.

Халык таралды. Обком һәйкәлне урынында калдырырга дигән карар чыгарды.

Кашшаф абый һәйкәлне юатты:

– Революцияләрдән, революционерлардан халыкның косасы килә инде хәзер, агайне... Шуңа күрә безнең кешеләргә исең китмәсен. Кайгырма!

– Нишлим соң мин хәзер, кайсы якка күрсәтеп торыйм? – диде һәйкәл, еламсырап.

– Күккә күрсәтеп тор. Шунда гына инде ул дөреслек. – Кашшаф абый, чыраен сытып, зәңгәр төтенгә чумган шәһәргә күз салды. – Аның якты тормышы да шул күктә генәдер инде.

Һәйкәлгә Кашшаф абыйның тәкъдиме ошады.

– Карале, нишләп мондый уй минем башыма элегрәк килмәде икән? – диде һәйкәл һәм бармагы белән күккә төртеп күрсәтеп катып калды.

Ләкин халык моңа да гаҗәпләнмәде.

1989

ВИРУС

Бөере авыртып сырхауханәгә баргач, Гайнетдин бабайдан төрле анализлар алдылар да, теге атнада килерсең дип, авылына кайтарып җибәрделәр.

Тик икенче көнне үк Гайнетдиннең йорты каршына «ашыгыч ярдәм» машинасы килеп туктады. Ак халат кигән ике кеше җирәнеп кенә бабайның кул-аякларыннан тотып, машинага селкеп салдылар да калага юл тоттылар.

«Сиксән яшьлек Гайни картта СПИД тапканнар!» дигән хәбәр авылга бик тиз таралды.

Кешеләр бабайның яман авыру эләктерүенә түгел, ә аның сиксәнгә җитеп тә җенси мөнәсәбәтләргә керә алуына гаҗәпләнделәр. Бу вакыйгадан авылдашлары гына түгел, бөтен сырхауханә гөж килде, тирә-як аһ-ваһ итте.

Кичкә таба Америкадан, Франциядән һәм тагын биш-алты илдән профессорлар килеп төште.

Аерым палатага ябып бикләп куйгач, Гайни карт бик курыкты. Шәфкать туташы СПИДның нәрсә икәнен аңлаткач, бабай сөенде, чөнки ул СПИДның ни дәрәҗәдә коточкычлыгын бөтенләй үк аңлап бетермәде. Җитмәсә, ул мактанчыграк та кеше иде һәм бу вакыйга авылдашлары каршында, бигрәк тә үзе кебек карткоры алдында шапырынырга әйбәт булды.

Табиблар сорау алганда, Гайнетдин бабай болай дип ялганлады:

– Көз көне авылыбызга заводтан эшчеләр килгәние... бәрәңге алырга... Шулар арасыннан бер марҗа белән чуалган идем...

Ә инде ахири дуслары Шәрәфетдин белән Хәсәнша килгәч:

– Кала базарында карлыган саткан чакта бер унсигез яшьлек кыз белән танышканыем... Төнне шуның белән апасының фатирында уздырдык, – диде.

Әйтергә кирәк, бабайлар Гайни картны кызгансалар да, күбрәк аңардан көнләштеләр:

– Ну, маладис, – диде Хәсәнша сырхауханәнең өченче катындагы тәрәзәдән карап торган Гайнетдингә. – Бүгенге гәҗитләр барысы да синең хакта язганнар бит.

Бу вакытта инде оператив рәвештә төзелгән медицина комиссияләре пыр туздырып шәһәр халкын тикшерәләр иде.

Гайнетдиннең абруе тагын да күтәрелгән булыр иде дә бит, ләкин эшне чит илдән килгән профессорлар бозып ташлады. Беркөнне палатага көтүләре белән врачлар кереп, Гайни карттан гафу үтенделәр.

– Гафу ит, бабай, теге микроскопта күренгән вирус СПИДныкы түгел икән, – диде Америка табибы. – Ялгышканнар сезнекеләр.

Франция галиме өстәп куйды:

– Ул вирус зарарлы түгел, андый гына микроблар белән һәр совет кешесенең эче тулган.

Гайни картның кәефе кырылды.

Сырхауханәнең баш врачы Наданов, картны тынычландырырга ниятләп:

– Бабай, зинһар, борчылма, – диде. – Врачларыбызның хата җибәргәнен, вирусның СПИДныкы түгел икәнен гәҗитләрдә язарбыз.

Гайнетдин бабай өзгәләнеп табибларга ялынды:

– Балакайларым, Алла хакы өчен, мәсхәрәләмәгез, СПИД булгач, СПИД килеш калсын инде. Алайса, Шәрәфетдин белән Хәсәнша алдында ялганым тотылачак бит.

Ак халатлы кешеләр башта берни аңламый тордылар һәм, эшнең нәрсәдә икәнлегенә төшенгәч, рәхәтләнеп көлделәр.

– Ярар, язмабыз, – диде Наданов.

Авылга кайткан көнне горур кыяфәтле Гайнетдин кичкә таба койма буенда яткан бүрәнәгә чыгып утырды.

Аңа якын килергә курыктылар, шуңа күрә сораулар һәм җаваплар бер егерме адым аша бирелде.

– Гайни бабай, нишләп бик тиз чыгардылар?

– Андый вирус карт кешедә озак яши алмый, тиздән үләчәк ул, – диде Гайнетдин.

Өлкәнрәк яшьтәгеләрнең Гайнетдингә бер зур үтенечләре дә бар иде:

– Син, Гайнетдин, пажалысты, үзебезнең авыл хатыннарына тимә инде, йоктыра күрмә чиреңне.

Гайни карт бик серле итеп елмайды да:

– Юк, юк, бирусым үлгәч кенә чамалармын, – диде. – Бирусым үлмичә, хатын-кызга тотынмыйм, Аллаһы боерса.

Авыл кешеләре Гайнетдиндәге СПИД вирусының тизрәк үлүен теләп йөргәндә, беркөнне бабайның салкын тигән бөерләренә тагын өянәк булды, һәм ул үзе үлеп китте.

Гайнетдинне җирләп кайтканда, Шәрәфетдин Хәсәншага:

– Хатын-кыз белән бәйләнешүнең бер дә яхшыга илткәне юк шул, – диде.

– Хатын-кыздан инде бөтен бәла, – дип җөпләде аны Хәсәнша. – Шул заводтан бәрәңге алырга килгән марҗа белән буталмаган булса, тагын бераз яшәгән дә булыр иде. – Хәсәнша авыр сулап куйды. – Врачларын да әйтер идем...

1990

КЫШКЫ ИНТЕРВЬЮ

Ауропадан Казанга килгән Дэвид атлы журналист Казан каласын кар басканны кунакханә тәрәзәсеннән ни чарадан бичара кыяфәтендә, боегып күзәтеп торды.

Казан турында беренчеләрдән булып журнал битләрендә дәвамлы мәкаләләр, интервьюлар әзерләргә хыялланган иде ул. Юллардагы бөкеләр, урамдагы көртләр аны кунакханә әсире итеп тотты, шул сәбәпле ул телефон аша гына хакимият тарафлары белән элемтәгә керә алды. Ирекле журналист булганга күрә, аңа һәрбер инстанциядә саклык һәм ваемсызлык белән карадылар. Җитәкчеләрнең чакыруы буенча түгел, үзе килгән бит ул. Президент аппаратыннан Министрлар Кабинетына, аннан Мәдәният министрлыгына, аннары шәһәр хакимиятенә этеп-төртеп йөрткәннән соң, аның белән очрашырга күптән түгел эшли

башлаган Имиев фамилияле бер уртакул чиновникны тәкъдим иттеләр.

«Чит ил журналистына интервью биргәндә, авызыңны чамалабрак ачарга кирәк икәнне син үзең дә аңлыйсыңдыр, – диделәр аңа. – Әңгәмә вакытында сүзне гел толерантлык ягына каер, чөнки бүгенге Татарстанның иң зур казанышы – толерантлык».

Чит ил журналисты кар ерып, туңып йөрмәсен өчен, аны кабинетка чакырмыйча, интервьюны ул тукталган кунакханәдә бирергә булдылар.

Служебный машинасын кеше йөри торган тротуардагы кар өеменә терәп куеп калдырганнан соң, кунакханә ишеген ачканда, бигрәкләр дә демократик һәм толерант илдә яшибез – журналистның каршына үзебез барабыз дигән горурлык хисләре кичерде Имиев.

Исәнләшү-күрешү, гадәти төче сүзләр, әле Казанны, әле Казанга килгән журналистның туган илен купшы сүзләр белән телгә алганнан соң, сай гына чынаякларга салынган салкынча чәйне йота-йота, әңгәмәгә керештеләр.

Инглизчә, французча, немецча, урысча да белә торган 35–40 яшьләрдәге Дэвид, тиздән Универсиада узачак төбәкнең төп телен өйрәнүне дә үзенең бурычы дип санаган һәм ул татарча Татар конгрессы җитәкчесенә караганда да яхшырак сөйләшергә өйрәнгән икән.

Татарстанның әле кырыкка җитмәгән чиновнигы Имиев бер телдә дә рәтләп сөйләшә белмәүче кавемнән иде. Әңгәмә Дэвид тарафыннан татар телендә башлангач, үзен татар дип санаучы сары кашлы, мукшы чырайлы татар чиновнигы каушабрак калды. Интервью башлангач, ул шулай да тиз генә үзен кулга алды, чөнки җаваплылык көчле иде.

– Казан кар астында кала бит инде... – дип башлады сүзне Дэвид. – Сезнең җитәкчеләр моны аномаль күренеш дип аңлаталар. Имеш, быелгы кадәр кар яуганны хәтта тарихчылар да хәтерләми. Мәсәлән, Канадада мондагыдан да күбрәк кар ява, әмма анда шәһәрләр сездәге кебек карга күмелми.

– Без – толерантная республика... – дип башлады җавабын ни урысча, ни татарча Казан чиновнигы. – Бездә чиркәүләр, мәчетләр, синагогалар эшли. Поэтому, бездә халык менә шушындый природный стихияләр башлангач, бөтен эшләрен ташлап кайсы мәчеткә, кайсы чиркәүгә, кайсы синагогага спешат. Ходайдан милость сорарга һәм погоданы яхшыртырга умолять итәргә. Как раз этим и объясняется юлларның чистартылмавы, дворларга кереп булмавы, машина пробкаларының километрларга сузылулары. В такие часы народ у нас привык разговаривать с Всевышним, потому что только от него все зависит, а не от руководителей республики и, тем более, от руководства города. – Үзенең шулхәтле оста алдавына үзе дә шаккатып, ул кызулык белән өстәп куйды:

– Мәчетләрне, чиркәүләрне күпләп төзегәннән соң, народ стал очень религиозным и богобоязненным. Дингә нык кереп батты халык. Без моңа хәтта бераз борчылабыз да. Алай ук нельзя в религию погружаться.

Дэвид көлемсерәп куйды.

– Машина йөртүчеләр дә, җәяүлеләр дә шәһәр хакимиятен гаеплиләр, – диде ул, сынаулы караш белән Имиевкә текәлеп.

– Бездәге толерантлылык – это не пустые слова. Безне имеют право критиковать люди разных национальностей, разных вероисповеданий. Безне критиковать итә алалар машиналылар һәм җәяү йөрүчеләр, здоровые и больные, белемлеләр һәм необразованные... Значит, без чыннан да толерантлылык принципларыннан исходим в своей деятельности.

– Мин җәй көне килмәкче идем, әмма җәй бик эссе булды, шуңа кичектергән идем килүемне. Әйтегез әле, Универсиада уздырыласы җәйдә шундый эсселек булса, бу зур спорт чарасын параличламасмы?

Кышкы кар-бураннардан үндүрт килога ябыккан Имиев җәй темасына күчкәнгә сөенеп куйды.

– Без бик толерантлы халык, – диде ул, әңгәмә башындагы киеренкелекнең бераз кимүен тоеп. – Үзебез башлаган бөек эшне без һәрвакыт үзебез генә парализовать итәбез. Шулай да без алдан ук нишләргә икәнне беләбез. Без считаем, что Универсиада вакытында Казанның гади халкы җәйге бакчаларына китсә яхшы булыр иде. Казанның основной урамнары ябылачак. Универсиада ул кунаклар һәм элита өчен үткәрелә. Ә алар кондиционерлы биналарда, иркен транспортларда, короче говоря, будут все время находиться в благоприятных условиях.

Дэвид беравык аптырап торганнан соң, чираттагы соравын бирде:

– Казан урамнарында бәдрәфләр юк. Сез бу турыда нәрсә әйтә аласыз?

– Мин белдем, что сез бу сорауны бирерсез. Как я уже говорил, бездә толерантлык көчле. Соңгы вакытта Казанда бик күп биналарны, даже исторический биналарны да сүтәргә, җимерергә туры килде. Наверное, обратили внимание, что йөз-йөз илле адым саен җимерек биналарны күрергә мөмкин. По естественным нуждам безнең гражданнар шул хәрабәләргә, җимерек йортлар арасына йөри. Без – толерант халык. Анда печ итәргә, т...га ходят люди разных национальностей. Менә бүген Казанда без туалетлар төзеп куйсак, развалиналарда хаҗәтен башкарган меңләгән-меңләгән кешеләрнең мнениесе ничек булыр? Бәдрәф булгач, ул платный булырга тиеш. Ә печ иткән өчен акча түләргә күнекмәгән халыкка нинди удар булачак бу – даже пердставить себе трудно! Без толерантлык өчен бу вопроста да көрәшергә тиешбез.

Дэвид көлеп җибәрде.

– Бәдрәф – толерантлылыкны күрсәтә торган урын бит инде! – диде ул, көлүдән туктап. – Анда бит барлык милләт, барлык дин вәкилләре керә. Толерантлыгыгызны тирәннәнрәк күрсәтер өчен бәдрәфләрне тизрәк ясарга кирәктер, бәлки.

Толерантлык сүзен чит ил кешесе дә телгә алгач, Имиев үтә җитди кыяфәткә керде.

– Туалетлар обязательно төзеләчәк! – диде ул, тавышын күтәреп. – Без, толерантлы республика буларак, Казан уртасында дөньядагы иң зур бәдрәфне төземәкче булабыз – на четыре тысячи мест. Милли бәдрәф. Кызлар-егетләр в национальных костюмах, чәкчәкләр тотып, оркестр көе астында җырлап-биеп торачаклар. Туалетта озак утырган өчен махсус призлар булачак. Бездә толерантлык уровены шулкадәр югары, что даже ирләр бәдрәфе белән хатын-кызлар бәдрәфе арасында стеналар куймаска уйлыйбыз – бөтен нәрсә тигез булсын, ачык булсын, күренсен, беркем беркемнән өстен булмасын һәм аерылмасын, иң мөһиме... оялмасын! Все должно быть прозрачно, видно, понятно! Только так можно достичь наивысшей толерантности!

– Бәлки, Казанны зур бер бәдрәфкә генә әйләндерергәдер, – диде Дэвид, күзләрен челәйтеп. – Бай республика үзенең башкаласын Идел буе регионының бәдрәфенә әверелдерергә хакы да, мөмкинлеге дә бар бит.

– Сезнең мондый сарказмыгызны мин аңлыйм, – диде Имиев коры гына. – Но не обижаюсь. Потому что мин толерантлы республикада яшим. – Казанны зур бер бәдрәфкә әверелдерү фикерен миңа күрәзәче дә әйткән иде инде, – дип өстәде ул, кинәт уйга калып.

– Нинди күрәзәче?

– Мине күптән түгел Әгерҗе районындагы күрәзәчегә послали – кайчан кар явудан туктаячак дип сорарга.

– Ничек җавап бирде?

– Кар ул без бу дөньядан киткәч тә явачак әле, – дип җавап бирде.

– Нишләп күрәзәчегә барырга булдыгыз?

– От безысходности, – диде чиновник, кинәт шәлберәеп.

– Тагын нәрсәләр диде күрәзәче?

– Она много чего наговорила. Но из того, что она наговорила, я не все своему шефу доложил.

– Нишләп алай?

– Аның әйткәннәрен сөйләсәң, ул күрәзәчене төрмәгә утыртырлык. Ә бездә толерантность... Ире чуваш булганга посадили дип әйтүләре бар. Без барысын да алдан ныгытып уйлыйбыз. Толерантность – это у нас не пустые слова.

– Гафу итегез, сез милләтегез буенча кем?

– Татар, – диде Имиев, бу сорауга гаҗәпләнеп.

– Сез татарча начар сөйләшәсез...

– Бездә татарча сөйләшә белүче чиновникларны бармак белән генә санарлык. Я русскую школу закончил... и потом, ни... – Имиев ничек акланырга белми ык-мык килгәннән соң, бик шәп җавап тапты: – У нас здесь исторически так сложилось! Кстати, безгә Универсиада алдыннан велели учить английский язык, а не татарский. Без – толерант халык. Универсиадага кунаклар килгәч, без по-английски базарить должны, – дип ялгыш «феня»га күчә башлады Имиев.

– Бигрәк сәер, чиновникларга Универсиадага кадәр туган телне – татар телен өйрәнергә бурыч йөкләргә кирәктер бит?..

– Но мы толерантный народ! – диде Имиев сәер илһамлык белән. – Мы ради толерантности и о своем родном языке готовы забыть! Забота о других, уважение других — это проявление нашей духовности!

– Күрәзәче Татарстанның киләчәге турында нәрсә диде?

– Толерантлык шушылай продолжаться итсә, у татар будущего не будет, диде. Ә татар халкы бетсә, Татарстана тоже не станет, диде. Конечно же, я это не стал шефу говорить. Зачем его расстраивать, когда он денно-нощно трудится во имя толерантности?!

– Бәлки, күрәзәче үз милләтеңнең интересларын инкяр итүне күздә тотып әйткәндер. Бәлки, иң элек татарлар турында уйларга кирәктер?

– Ә толерантлык служит в первую очередь татарам.Толерантность позволяет безнең республикада яңадан-яңа спорт биналары төзергә. Скоро Татарстан в целом мире прославится количеством спортивных сооружений.

– Кечкенә республика өчен күбрәк түгелме? Алар бит Татарстан республикасы җилкәсендә, халык акчасына тотылачак.

– Зато через несколько десятков лет на каждого татарина будет один стадион. Это же будет великое достижение, такого еще в мире не было. Наша толерантная республика еще много раз ошарашит этот обветшалый мир!

– Нишләп соң сез һаман кемнедер шаккатырыр өчен яшисез? Үзегез өчен яши башлар вакыт түгелме? Нишләп һаман читтән килгән бәя кызыксындыра сезне, нишләп чит ил кешеләренең бәяләмәсенә бәйле сез? Үз халкыгыз өчен кайчан яши башлаячаксыз?

Имиевнең тавышы калтырый башлады, ияге дерелдәп куйды.

– Без – толерант халык! – диде ул, әңгәмә башындагыннан да ныграк тетрәнеп. – Мы не можем, не имеем права жить для своего народа! Безнең халык ул безнеке инде! Никуда он не денется! Надо, чтобы другие были довольны! Мы очень долго шли к этой толерантности!

Имиевнең күңеле мөлдерәмә тулды. Күз яшен сөртер өчен тиз генә пинжәк кесәсеннән кульяулыгын алды. Журналист әңгәмәне дәвам итүнең кирәк түгеллеген аңлады.

...Әңгәмә тәмамланып сәгать ярым чамасы вакыт үткәч, Дэвид, машина яллап, Әгерҗе районына чыгып китте.

2011

НУРУЛЛАНЫҢ ЭМИГРАНТ СӨНГАТУЛЛАГА ЯЗГАН ХАТЫ

Исәнме, авылдаш!

Котлыйм сине 90 яшең тулу белән. Сиңа сәламәтлек, озын гомер телим!

Үземнең хәлләргә килгәндә, бер көе генә гомер кичереп ятам. Саулыгым гына бөтенләй юк. Кайлардан булсын инде ул, мин дә туксан беренче яшемдә бит. Аннары, мин күргәннәрне эт тә күрмәгәндер.

Сиңа шатлыклы хәбәр җиткерергә ашыгам: безнең Рәсәйдә тагын революция башланды бит әле. Тик менә соңгы вакытта зиһенем томаланды, хәтерем начар, акылым да алышынгалап тора — шул сәбәпле нинди революция икәнлеген әлегә аңлап бетермим. Минем аңлавымча, аның тегесе дөрес булмаган бугай.

Сезне, ак эмигрантларны, хәзер бездә бик ихтирам итәләр, телевизордан да еш күрсәтәләр, гәҗитләрдә мактап һәм зурлап язалар. Эмигрантларга кире кайтырга да рөхсәт итәлә, ди, хәзер, хак булса.

Сөнгатулла, алай-болай кайтырга ниятең юкмы?

Ике уйлап торма, туп-туры үземә кайт. Менә 2000 елда фатир бирәбез диделәр — рәхәтләнеп икәүләп яшәп ятарбыз. Син, элекке ак офицер буларак, монда зур ихтирамга лаек булачаксың. Син реабилитациягә һичшиксез эләгәчәксең. Мин генә ул Кызыл Армия сафларында кан коеп та, гомерем буе эт типкесендә йөрдем.

Бу революция теге коточкыч еллардагы шикелле зәһәр һәм канкойгыч булмаячак, диләр. Кайтырга исәбең булса, үзең белән корал алып кайтып йөри күрмә, картаеп беткән башың белән. Алай бик кирәк булса инде, минем әле егерменче елда ук яшереп куйган ике маузерым, дүрт ящик патроным бар.

Анда, сезнең Әмрикәдә, Вакытлы хөкүмәтнең башлыгы Керенский да яшәп ята дип ишеттем. Исәнме әле ул? Исән булса, ул да кайтсын!

Сөнгатулла туган, кайт!

Бу революциядә Сиваш сазлыкларының син – бер ягында, мин икенче ягында күшегеп атышып ятышлы булмаячак. Бу юлысы аклар яклы да, кызыллар яклы да булмабыз, Алла боерса. Гел революцияләр кайнап торган илдә анархист булудан да яхшысы юктыр дип уйлый минем әле бөтенләй үк миңгерәүләнеп бетмәгән башым. Әнә бит ничек буталып бетте барысы да: дус дошман булган, ә дошман әйбәт кеше булып чыкты.

Теге утызынчы елларда колхозлар төзү дә дөрес нәрсә булмаган бит. Хәзер халык пыр тузып кулаклар истәлегенә һәйкәл куюны таләп итә. Тик ул һәйкәлне мин һич тә күз алдыма китерә алмыйм. Көрәк сакаллы, ат хәтле бер мужик ясап куярлар инде, обрез тоттырып.

Ярар, анысында безнең эшебез юк, безгә хәзер актык көннәребезне тыныч кына үткәрү турында уйларга кирәк.

Кайт, Сөнгатулла туган, чыгып килә безнең кояш!

Бер дә курыкма, теге син 1919 елны Царицында атып үтергән комиссар Самойлов үзе халык дошманы булган – беркөнне гәҗиттә укыдым. Сиңа әле, кайтсаң, бәлки, берәр медаль дә бирерләр шул хайван өчен.

Китәсең калмаган чит илләргә, Сөнгатулла!

Минем шикелле бер егерме ел утырыр идең утыруын төрмәләрдә, аның каравы вафат булгач, туган туфрагыңда күмеләсеңә ышанып яшәр идең калган гомереңне.

Мөмкинлегең булса, кодрәтеңнән килсә, кайт, дустым!

Менә әле бездә тагын мәчетләр төзергә җыеналар. Чөнки халык бернәрсәгә дә, беркемгә дә ышанмый башлады, шуңа күрә халыкны яңадан Аллага ышандырырга маташалар. Дөрес булса, мәчеткә йөрмәгән кешегә иткә, шикәргә, кер порошогына, сабынга талоннар бирмәячәкләр, ди.

Халыкның активлыгы көннән-көн арта: көн саен һөҗүм. Син куркып калма тагын, магазиннарны штурмлыйлар алар. Яхшы товар кайтса, универмагларны Кышкы Сарайдан ким «алмыйлар».

Кайтырга уйласаң, үзең белән сабын, теш пастасы, шикәр, чәй ише вак-төякне күбрәк алып кайт. Аяк уа торган әдикалуннар да бардыр Әмрикәдә, анысын да онытма (бездә аларны эчеп бетерделәр инде). Башка әйберне ничек тә табарбыз әле монда да. Революция вакытында урлап та, талап та була ул, үзең беләсең – син революцияләрне күргән кеше.

Ярый, Сөнгатулла, мин шуның белән тәмамлыйм. Тагын бер кат котлыйм сине 90 яшең тулу белән! Сау булып тор! Көтәм сине революцион Россиядә!

Сәлам белән кызыл партизан Мурзин Нурулла.

1989

ТӨНГЕ МАҖАРАЛАР

Казанда төнлә йөрергә куркыныч икәнен сез беләсездер инде. Бу калада төнлә йөрүчеләрне, бигрәк тә ялгыз йөрүчеләрне, нишләптер яратмыйлар – аларны йә кыйныйлар, йә талыйлар, йә чишендерәләр…

Беркөнне миңа эштән бик соң кайтырга туры килде. Сәгать төнге беренчеләр булгандыр – автобус киләсенә инде өметем тәмам беткәч, таксига акча юклыгын, үземнең хәерчелегемне каргый-каргый, җәяүләп төнге кала буйлап өемә таба юл тоттым.

Автобус тукталышыннан бер егерме адым үттем микән, каршымда, ай яктысын каплап, алагаем гәүдәле бер бәндә пәйда булды. Валлаһи, мондый өрәкне төн генә тудыра аладыр һәм дә мондый очрашулар безнең Казанда гына мөмкиндер. Ул миңа трактор пускачы чыгара торган шатырдавык тавыш белән ир-ат арасында бик популяр булган классик сорауны бирде:

– Тартырга юкмы? – Аның бу ике сүзендә төнге күкләргә генә хас булган серле һәм шомлы көч бар иде.

Йөрәгем, куркаклыгымнан гарьләнеп, күкрәгемнән тышка бәреп чыкмакчы булды. Бу минутта минем бөтен гәүдәм шул бер тынгысыз йөрәктән генә торадыр кебек иде.

Тәмәке тартмавымны аңлаткан арада, тагын шундый ук гәүдәле адәм затына охшаган бернәрсә «үсеп чыкты». Мин каушаудан бөтенләй югалып калдым. Аптырагач, кире борылып китмәкче идем дә, тик бу ниятем уңышсыз тәмамланды. Мине ике яктан эләктереп алдылар һәм күлмәгемне салырга киңәш бирделәр.

Тумыштан юаш кеше буларак, эчтән генә: «Кыйнамасалар ярар иде», – дип, өченчекөн «толкучка»дан кырык сумга алган күлмәгемне талаучыларга тапшырдым. Алар күлмәгем белән бергә төн кочагында эреп юк булдылар, ә мин, салкыннан һәм котым алынудан яфрак кебек дер-дер калтырап, билдән шәрә килеш моңаеп басып калдым.

Рәнҗүемнең чиге юк иде… Ярый әле җәй… Ә кыш көне булса… Менә шул җәй булуы гына мине бераз тынычландырды да инде.

Дзержинский урамына җиткәч, мин кызурак атладым, чөнки бу урам караңгырак һәм хулиганнары белән дан тота.

Кинәт арттан:

– Әй, тукта! – дигән боерык ишетелде. Бу әмернең миңа адресланганын нindидер эчке сизенү белән аңладым. Шулай да юлымны дәвам иттем, чөнки күңелемнең бер тирән почмагында «Бәлки, әле миңа түгелдер…» дигән өмет сулкылдый иде.

Юк! Миңа эндәшкәннәр икән.

Өчәү куып җиттеләр. Берсе (башлыклары булды, ахрысы):

– Син нәрсә, саңгыраумы әллә, козел?! – дигәч, мин бу дөньяга

кәҗә тәкәсе булып тумаганыма үкенеп куйдым. Өчесенең дә күзләреннән нәфрәт чәчелеп тора иде.

Мин, үземне никтер бик гаепле итеп тоеп, башымны аска идем.

– Тартмыйм мин... юк тәмәкем... – диде салкын иреннәрем.

– Ә безгә тәмәке кирәк түгел, – дип җикерде икенче юлбасар. – Чалбарың ничәнче размер?

Мин 48 нче размер киям, ләкин куркудан бу авыр сорауга:

– 52 нче, – дип җавап бирдем.

– Сал! Зуррак зуррагын. Ну аны тарайтып була, – диде өченче карак, мине тынычландырырга теләгән кебек.

Күп тә үтмәде, әле яз көне генә спекулянтлардан алган 200 сумлык «варенка» чалбарымны да төн йотты.

Йа Ходаем!.. Беренче чекист, «тимер Феликс» исемен йөрткән урамда ыштансыз кал инде, ә...

Мин, ярдәм сораган шикелле, як-ягыма, аннары йолдызлы күккә карадым. Ләкин кешеләр зур өметләр баглаган очсыз-кырыйсыз күктә битарафлык хөкем сөрә иде. Җитмәсә, шунда бер төркем яшьләр, миннән көлә-көлә, шау-гөр килеп үтеп киттеләр. Берсе хәтта:

– Кызынасыңмыни, абзый? – дип, ярама тоз сибәргә дә өлгерде.

Дзержинский урамының икенче башына җиткәндә, иске йортлар ишегалдыннан каршыма мәче сыман тагын бер төн убыры атылып чыкты һәм:

– Сал кроссовкаларыңны! – дип боерды.

Талаучы шулкадәр ашыга иде, әйтерсең ул, бөтен эшен ташлап, чит планетадан минем кроссовкаларымны алырга гына дип җиргә килгән дә аның тизрәк кире очып кайтасы бар.

Аңа карап мин дә кабаландым. Нәтиҗәдә аяк киемем белән бергә оекбашларымны да салып биргәнмен.

Шулай итеп, мин бер трусиктан гына калдым. Ләкин миңа хәзер барыбер иде инде...

Трусигымны җилфердәтеп, үзем яши торган урамга кергәндә, артымнан тагын кемнәрдер килгәне ишетелде. Мин, әлбәттә, борылып карарга курыктым.

Шулчак исемә келт итеп килеп төште: «Минем трусигым да фирменный лабаса...» Күршем Сириядән алып кайткан иде. Ләкин мин дөньядан ваз кичкән идем инде, шуңа күрә дә анадан тума шәрә калу ихтималы мине алай бик борчымады.

Эзәрлекләүченең якынлашканын сизгәч, туктадым да трусигымны салдым. Бу күренештән күктәге ай да, оялып, болыт артына кереп качты.

Түземлекнең дә чиге бар бит – кинәт борылдым да артымнан килүчегә:

– Мә, сволочь! Ки рәхәтләнеп! – дип, трусигымны аның йөзенә ыргыттым.

Ыргыттым да... баскан урынымда катып калдым. Каршымда резин тәпәчен кысып торган милиция сержанты басып тора. Фуражка кокардасына, тәртип саклаучының битен каплап, сирийский трусигым эленгән иде.

...Милицияне мәсхәрәләгәнем өчен унбиш тәүлек утырып, шәһәр буйлап шәрәтән йөргәнем өчен илле сум штраф түләп чыккач, мин алама киемнән генә йөрергә һәм төнлә урамга чыкмаска ант иттем.

1990

БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ

Беренче мәхәббәт... Кеше гомерендә иң татлы, иң гүзәл хатирәләр.

Тәүге сагышлар, янулар, ялгышулар, мәнге кабатланмас якты төш булып, үзәкләрне өзәрлек үкенеч булып, хәтердә яшиләр.

Күрәсең, дөнья бик киң түгелдер инде ул, чөнки яшьлектә бер-берсен сөйгәннәрне язмыш очраштыргалап тора.

Гадәттә, андый очрашулар вокзалларда була, шуңа күрә Сәлимә белән Гарифның юллары Мәскәү шәһәренең Казан вокзалында кисешүе әллә ни гаҗәп хәл түгел.

– Сәлимә!

Ике авыр сумка күтәргән хатын сискәнеп куйды. Әлбәттә, Сәлимәнең кулларыннан сумкалары төшеп китте, гаҗәпләнгәндә кешенең күзләре акаерга тиеш булганлыктан, күз алмалары киңәйде, тез буыннары калтырады – чөнки аның каршында Гариф пәйда булды.

– Бәрәч, Гариф, синме бу?! Каян килеп чыктың?!

Гариф куанычыннан юләрләрчә шаркылдап көлеп җибәрде. Аның «ха-ха-ха-хей» булып чыккан шатлык авазы вокзал бинасын ярып үтте дә каядыр пространствода югалды. Ул тавышка вокзалдагы кешеләр борылып карады, дежур милиционер кулындагы тәпәчен кысыбрак тотты, кайсыдыр почмакта бала елап җибәрде, утыргычта чебен җыеп йоклап яткан бер исерек, уянып, бик әшәке итеп сүгенеп куйды. Ләкин аларның берсе дә Гариф белән Сәлимәнең күңелләрендә ниләр кайнаганын белмәде.

– Әй, Сәлимә, карале, ә... Мин сине әллә каян ук танып алдым. Әле яңа гына командировкага килеп төштем, «Татарстан» поезды белән. Ә син үзең нишләп йөрисең монда?

– Колбасага килгән идем. Кайтып барышым менә, ярты сәгатьтән поездым китә...

Күз карашлары белән бер-берсен беркавым иркәләп торганнан соң, Гариф, үзе шикелле үк таң калган хатынның кулын тотып:

– Сәлимә!.. – дип пышылдады.

Сәлимә, дулкынлануын көчкә басып, телгә килде:

– Карале, син, ни... очрашуыбызны әйтәм... Егерме ел үтте бит инде... Әй, гомер, гомер диген, ә!

Алар, бер-берсеннән күзләрен алмыйча, буш утыргычка барып утырдылар.

Ул көнне Җир шарының биш миллиард халкы арасында Гариф белән Сәлимә иң бәхетле кешеләр иде.

– Бер дә үзгәрмәгәнсең, Сәлимә, шулай ук яшь, чибәр. – Гарифның каушаудан тавышы калтырабрак чыкты.

Сәлимә уңайсызланган кыяфәт белән:

– Әй, кая инде... – дигән булды. – Картаеп барам бит... Тазардым да менә... Әле ничек таныдың... Ә син менә, валлаһи, һаман шул көе, чәчләрең генә бераз агарган.

– Әйе, чәчләр агара... Йә, сөйләп җибәр, ничек яшисең, саусәламәтме, тормышың ничегрәк?

– Тормыш ярыйсы болай... Казанда яшибез, ирем заводта механик булып эшли, үзем мех фабрикасында. Ике бала үстерәбез: кызым быел тугызынчы классны тәмамлый, улым – җиденчене. Синең үзеңнең дә гаиләң бардыр?

– Бар. Хатыным, ике кызым. Игезәкләр, Түбән Кама шәһәрендә заводта эшлиләр. Үзебез Чаллыда яшибез, эшләү – КамАЗда.

– Әйбәт торасызмы соң? – Сәлимәнең күз яшьләре менә-менә атылып чыгарга тора иде.

Бу сорау Гарифны да нигәдер күңелсезләндереп җибәрде.

– Начар түгел, ярыйсы шикелле болай, – дип мыгырдады ул. – Тик менә сине генә һич оныта алмыйм. Чыннан да, беренче мәхәббәт озын гомерле була икән ул.

– Әй, Гариф, мин дә сине бик сагынам бит. Кире кайтырга иде шул көннәргә. Ирем дә яхшы кеше – эчми-тартмый дигәндәй, балаларым акыллы, тик барыбер нәрсәдер җитми... Төшләремдә сине еш күрәм.

Сәлимәнең бу сүзләреннән соң Гарифның да күңеле тула башлады.

– Их, Сәлимә!.. – дигән офтану гүя сирәк тешле авызыннан түгел, бәлки күңеленең иң тирән җиреннән сытылып чыкты.

Аның офтануының тирәнлеген аңлаган Сәлимә дәвам итте:

– Мин, бөтен нәрсәне ташлап, шул бәхетле көннәребезгә очар идем. Чыннан да, нинди бәхетле вакыт иде бит ул... Таңнар атканчы төнге урамнарда йөри идек, салам эскертләрендә кунган чаклар да булды. Безнең шулай нык яратышуыбызга бөтен авыл шакката иде бит.

Бу минутта Гариф белән Сәлимәгә күз иярмәс канатлар үсеп чыкты. Ул канатларда кояшлы яшьлек иленә Гарифны, Сәлимәне һәм сумкалардагы егерме дүрт кило колбасаны – барысын бергә күтәреп алып кайтырлык көч бар иде.

– Шулай иде шул... – диде Гариф, авыр сулап. – Бер-беребездән башка бер көн дә тора алмый идек. Исеңдәме, – Гариф татлы елмаеп куйды, – яп-якты җәй иде, кич белән әрәмәгә төнбоеклар җыярга бардык. Табигать шундый матур, ә без шундый бәхетле идек.

Сәлимә җанланып китте:

– Истә булмыймы соң, Гариф, нишләп андый минутлар онытылсын ди. Әрәмәгә барыр алдыннан иске тегермән янында очрашырга вәгъдәләшкән идек. Ярты сәгатькә соңга калып килгәнем өчен сугып, күз төбемне яндырган идең... Ну кызу канлы да идең соң үзең...

Гариф читенсенеп куйгандай булды.

– Яшь чак – җүләр чак, диләр бит, булгандыр инде, – дип әйтүне кирәк тапты ул. – Гашыйк кешенең аңы томанлырак бит инде аның.

– Гариф, карале, кичке уеннарда безнең шикелле матур пар булмагандыр, әйеме... Хәтерлисең микән, бер тапкыр кичке уеннан кайтканда коеп яңгыр ява башлады да, без синең белән лыч су булдык. Аннары, туңуыбызны да онытып, Салих абыйларның мунча бурасы эчендә төне буе кочаклашып-үбешеп чыктык. Кочаклашканда, минем җилкәмдәге чуан сытылды, хәтерлисеңме?

– Ә-ә-ә... Сабантуй көннеме? Хәтерлим, хәтерлим! Ул көнне әле «Нишләп Шәрәф Мөршидәсенә күз кысасың» дип, минем йөземә төкергән идең. Битемнән ике көн суган исе килеп йөрде.

Сәлимә, гаҗәпләнеп:

– Шулай ук булдымыни әле ул? – диде. – Талашканны хәтерлим, ә менә төкергәнем исемдә түгел. Көнләшкән булганмындыр инде.

– Их, Сәлимә!.. – Бу юлысы Гарифның бәгыреннән офтану белән бергә язмышка үпкәләү сыман нәрсә дә чагылып киткәндәй тоелды. – Ник сиңа өйләнмәгәнемә үкенеп туя алмыйм. Бездән дә бәхетле кешеләр булмас иде. Югыйсә бар иде бит өйләнешергә хыялланып йөргән чакларыбыз.

– Бер тапкыр Зәй буеннан, юл буе булачак гаиләбезне, киләчәк тормышыбызны күз алдына китерергә тырышып, бер-беребезнең сүзен бүлә-бүлә, сөйләшеп кайткан идек.

Гариф сөйләгәндә, Сәлимә, шул минутларны тагын бер кат кичерер өчен, яшьләнгән күзләрен йомып тыңлады.

– Әйе шул, – диде Сәлимә, күзләрен ачмыйча гына. – Әле талашып та киттек бугай авылга җиткәндәрәк. Нидән чыкты әле ул талаш?

Гариф, исенә төшерергә тырышып, кашларын җыерды:

– Әллә тагы... оныттым инде.

Икесе дә уйга калдылар.

Паузаны Сәлимә өзде:

– Син анда миңа: «Характерың гына килделе-киттеле синең», – дидең бугай.

Гарифның чырае яктырып китте:

– Әйе, әйе, шулай дигәнием. Ә син миңа: «Үзеңне бел, псих!» дидең.

Икесе дә рәхәтләнеп көләргә тотындылар.

– Ә-ә-ә, Гариф, Гариф! Бөтенләй искә төште хәзер. – Сәлимәнең, хатын-кыз булуына карамастан, хәтере начар түгел иде. – Син мине бик нык үпкәләттең анда. «Синең күк корчаңгылы кызлар күп бу дөньяда, өйләнмим мин сиңа, пумала!» – дидең.

– Точно! – дип, сабыйларча шатланып кычкырып җибәрде Гариф. – Шуның өчен бит син мине абыйларыңа әләкләп кыйнаттың. Байтак яттым мин бүлнистә – җиде айлап булгандыр. Уң кулымны, өч кабыргамны сындырдылар, башымны ике җирдән ярдылар, колагым ертылган иде. Синең белән мин больницадан кайткан көннең кичендә үк иске тегермән янында очраштык.

– Әйе, Гариф, мин сине шундый нык сагынган идем. Син бүлнистә берничә сүз урысча өйрәнеп, бераз эреләнебрәк тә кайткан идең.

– Сәлимә, бер-беребезне гафу итә белә идек без, әйеме?!

– Мәхәббәтебез көчле булганга ул, Гариф! – Сәлимәнең сүзләрендә дә, үзен тотышында да мәңге сүнмәс мәхәббәт чагыла иде. – Безнең бит, Гарифкаем, ныгытып талашу да бер тапкыр гына булды. Байтак кына очрашмый тордык бугай анысында. Өебезгә ут төртмәгән булсаң, ул хәтле талашмаган да булыр идек әле. Ярый әле янгын зурга китмәде, вакытында сүндереп өлгерделәр.

– Менә анысында, Сәлимә, син үзең гаепле идең. Иптәш кызларыңа: «Аның авызы сасы, үбешкәндә косасылар килә», – дип хурлап йөрдең бит мине. Югыйсә сезнең өйгә ут төртү уемда да юк иде. Янгыннан соң бер ай узгач, без синең белән тагын бергә идек инде, әйеме?! Хәтереңдәме, Самат абыең мине клубта пычак тотып куып йөргән иде. «Сәлимәне ташламасаң, эчәгеләреңне муеныңа элеп куям» дип…

– Әллә тагы… – диде Сәлимә, иңнәрен сикертеп.

Биш минут чамасы тып-тын, бер-берсеннән мәхәббәт һәм сагыш тулы күзләрен алмый утыргач, Сәлимә авыр сулап куйды.

– Әй Гариф, Гариф!.. Тиздән поездым да китә инде… Гомерем буе синең белән менә шулай сөйләшеп утырыр идем.

Әйе, аларның искә төшерер нәрсәләре, сөйләшәсе сүзләре чиксез күп иде.

– Минем дә синең белән аерылышасым килми, – диде Гариф, Сәлимәнең калтыранган кулын кысып. – Әллә… Әй, юк… соңдыр инде…

Гарифның ни әйтергә теләгәнен Сәлимә аңлады, әлбәттә. Ул

Гарифның иңенә башын салды да, иренен турсайтып, үпкәләгән тавыш белән:

– Армиягә китмәгән булсаң, мин башка кешегә кияүгә чыкмас идем дә бит, – диде. – Тәки шул армиядән калырга бирәр чара табылмады... Әй бу язмыш!..

– Соң, нишләргә иде инде миңа тагын?! – Гариф нервылана иде. – Инде армиягә алмасыннар өчен солярка да эчеп карадым бит. Ике көн битем зәңгәрләнеп йөрде дә, бетте шуның белән, сау-сәламәт көе калдым. Әй, сөйләшмик әле мондый күңелсез темага, бозмыйк бәхетле очрашу минутларын.

Алар сөйләшмичә генә утыра бирделәр. Икесенең дә уйларында аларның бергә булган яшьлек еллары иде.

Дикторның тавышы аларны гына түгел, бөтен вокзалны сискәндереп җибәрде.

– Сәлимәм!..

– Гарифым!..

– Мин сине һаман да шулай ук өзелеп яратам!

– Мин дә!

...Вагонның ачык тәрәзәсеннән Сәлимәнең елаудан шешенгән йөзе күренде:

– Гариф! Август аенда минем отпуск. Авылга кайтам. Син дә кайтырга тырыш. Иремнең отпускасы декабрьдә генә. Үзем генә кайтам...

Гариф шатлыгыннан хәтта сикереп куйды.

– Сәлимә! Алай булгач, мин дә августта ял алырга тырышырмын. Иске тегермән янында очрашырбыз. Соңга калып килмә түлке – характерымны беләсең...

– Ярар, ярар, куркытма! Күп куркыттың инде яшь чакта да.

– Күп сөйләшмә, Сәлимә! Болай да ярсыган вакыт... Вагоныңа керермен дә дөмбеп ташлармын!

– Дөмбеп кара, хайван, төрмәдә утырасың килсә!

– Кем хайван?.. Кеше булдыңмыни? Унсигез яшеңә тикле корчаңгыдан арынмаганыңны оныттыңмыни, чүмеч авыз?! Син ул хайван! Ирең, балаларың бар килеш, «Гарифым», «Беренче мәхәббәт...» дип, селәгәеңне агызып, шыңшып утырасың!

– Ә үзең соң, үзең? Корчаңгы, дигән була. Синең үзеңнән бит әле хәзер дә бакча сукалап кайткан ат исе килеп тора.

– Ну, Сәлимә, син чынлап та үзгәрмәгәнсең икән.

– Син дә шул ук Гариф булып калгансың.

– Сәлимә, туктале, ызгышмыйк.

– Соң, Гариф, үзең бит беренче башладың.

– Сәлимә, яратасыңмы мине?

– Яратам, Гариф! Август аенда әбизәтелне кайт, яме!

Поезд кузгалды. Сәлимә нәрсәдер әйтергә теләде, булдыра

алмады – аның күз яшьләре дөньяны томалады, тамак төбенә төен тыгылды.

Гариф, мәхәббәт уты чәчеп торган күзләрен Сәлимәдән аера алмыйча, вагон белән янәшә атлады.

– Сәлимә, җаным, август аенда... иске тегермән янында...

Поезд тизлеген арттырды.

1989

ТЕЛЕВИДЕНИЕ ШАУКЫМЫ

«Телевидениедән киного төшерергә киләләр икән...» дигән хәбәр авылны гөр китерде. Нинди тапшыру икәне, кемнәрне төшерәчәкләре билгеле булмаса да, һәркем үзен телевизордан күрергә хыялланды.

Колхоз рәисенең әмере буенча капка төпләрен кат-кат себерделәр, кибетне ачтылар. Җимерек клубны, экранга эләгә күрмәсен дип, сүтеп утынга турадылар. Дүрт-биш урында якты киләчәккә дәшә торган лозунглар элеп куйгач, мәңге айнымас Галимҗанга урамда болганып йөрмәскә кушылды.

Аның аек чагын авылның аксакаллары да хәтерләми. Галимҗан телевизорлы һәм башка бик күп кызык нәрсәле бу дөньяга исерек булып туган, күрәсең.

Соңгы вакытта ул янгын сүндерүче булып эшләде. Галимҗан пожарник булып эшләгәндә, авылда бары тик бер тапкыр гына янгын чыкты. Анысы да Галимҗанның тәмәке төпчегеннән иде, һәм янгын сүндерә торган кораллар склады бер төн эчендә янып бетте.

Ярый, ул хәл инде булган – беткән... Мин бит сезгә башка вакыйга хакында сөйләргә җыенам.

* * *

Авыл халкы телевидениегә төшәр өчен иң яхшы киемнәр әзерләп куйды, мунча керде, медальләр һәм значоклар сандыктан алынып түшләргә кадалды.

Телевизордан күренергә халык әзер иде. Төшерүчеләр киләсе көнне күрше авыллардан да байтак кеше җыелды. Халык төркеменнән урысча сөйләшкән тавышлар да ишетелде, чөнки урман артында гына урыс авыллары бар.

Ләкин халыкка телевизордан күренү насыйп булмады.

Авылга «Кеше һәм закон» тапшыруыннан килделәр һәм эчкечеләр белән кызыксындылар.

– Һәр авылдан берәр алкоголикны гына төшерәбез, – диде

җитәкчеләре. – Үзегез беләсез, авыллар шактый күп, әмма безнең телестудиядә пленка чамалы гына – дефицит.

Авылдашлары Галимҗанны, кадрга эләгә күрмәсен дип, ферма каравылчысы йоклый торган будкага бикләп куйганнар иде. Менә сиңа мә! Хәзер шуны телевизорга төшерәчәкләр!

Колхоз рәисе, бик борчылып, операторга мөрәҗәгать итте:

– Карагыз әле, аны юындырып, киемен алыштырырга кирәктер бит?

– Юк, юк, алкаш шулай шапшак булырга тиеш ул, – диде оператор.

Телевидение автобусы ферма янындагы каравыл өенә таба юнәлде, аның артыннан, гөж килеп, халык тагылды.

* * *

Будка ишеген ачып җибәргәч, ферма исен юк итеп, җәйге һавага Галимҗан исе чыкты. Ул, сәкегә йөзтүбән капланып, гырлап йоклый иде. Август аеның ач чебеннәре тешләве аның катып беткән ялангач аякларына һич тә тәэсир ясамый иде.

– Тор! – диде колхоз рәисе, Галимҗанны селкетеп. – Телевизорга төшерәләр.

Галимҗан башын калкытты да, эшнең нәрсәдә икәнен аңлагач:

– Төшмим! Башка вакытта килегез! – дип борылып ятты.

Председатель Галимҗанны ныграк җилтерәтте:

– Карале хайванны! Тор, шакшы! Алкашларны төшерергә килгәннәр бит алар.

– Төшмим! – дип кабатлады Галимҗан, башын күтәрмичә генә. – Беренчедән, мин алкаш түгел. Икенчедән, минем карарга телевизорым юк. Үзең төш. Син дә бит миннән ким эчмисең.

Колхоз рәисе, кул селтәп, будкадан чыкты.

Шулай яткан килеш кенә берничә кадр ясагач, Галимҗанны юмалый-юмалый стенага сөяп утыртып куйдылар. Чөнки телевизор караучылар алкоголикның чыраен да күрергә тиеш.

– Төсле телевизордан шәп күренәчәк бу, – диде оператор, эшен тәмамлагач.

– Булдымы? – дип мыгырдады Галимҗан.

– Булды, ят, – диделәр аңа.

Галимҗан:

– Өч минутлык эш өчен кешене борчып йөрисез, – дип, үпкә белдерде дә яңадан сәкегә сузылып ятты.

Галимҗаннан авылдашлары көнләште, ә бала-чага исә сәкедә нәсел үгезе сыман мышнап ятучы «экран йолдызы»на сокланып карады.

* * *

Ярты ел узгач, телевидениегә хат килде.

«Хөрмәтле редакция!

Сезгә «Париж Коммунасы» исемендәге колхоз җитәкчеләре яза.

Сез беләсездер инде: безнең районда телевизор Казан программасын күрсәтми. Шул сәбәпле менә инде алты ай буена «Кеше һәм закон» тапшыруы буласы көннәрне бөтен авыл, Галимҗанны карарга дип, эш ташлап, күрше районга йөри.

Шуңа күрә сезгә үтенечебез бар: тизрәк күрсәтегез инде Галимҗанны. Әллә соң сез аны ялгыш «Хайваннар дөньясында» дигән тапшыруда күрсәттегезме?

Хөрмәтле редакция!

Сезнең теге вакытта авылыбызга килүегез бик начар тәэсир ясады. Телевизорга төшермәсләрме дип, бөтен авыл эчүгә сабышты.

Тракторчы Габдулла тракторы белән күрше авылга самогонга киткән җиреннән инде ике ай күренми.

Монтер Әгъләм, баганадан егылып төшеп, бер аягын һәм дүрт кабыргасын сындырды.

Мал врачы Хәлим исерек баштан сыерларга ярамаган укол кадаган. Хәзер сыерлар үгез сорамый.

Тире җыючы Шәйдулла узган атнада махмырдан үлде. Үләр алдыннан: «Ичмаса, мине күмгәндә телевизорга төшерсеннәр», – дип васыять әйтеп калдырган.

Тарих укытучысы Сәлимдә «белая горячка» башланды. Тарихи вакыйгалар белән саташып, урам буйлап балта күтәреп йөри. «Мин 1812 елны Бородино кырында Раевский батареясында сугыштым», – дип, авылдашларының теңкәсенә тия.

Теге сез киногa төшереп киткән Галимҗан гына эчми хәзер. Үзен телевизордан күрер өчен тәмам айныды. Сезнең тапшыруларны Актаныш районына барып карый – анда аның туганнары бар.

Хөрмәтле редакция!

Сез бер кешене эчүдән туктаттыгыз. Ләкин авыл көннән-көн исерә бара бит... Зинһар өчен, ярдәм итегез!

«Париж Коммунасы» исемендәге колхоз җитәкчеләре».

* * *

Бу хат телевидениедә зур кызыксыну уятты. Төшерү группасы авылга тагын килде.

Авыл уртасында басып торырга да урын юк иде. Авылның тарихында бу кадәре халык җыелуы 1920 елны гына булганы бар. Аклар гаскәре чигенгәндә, авылда атна-ун көн торган полкта

бер негр да булган, имеш. «Шул негрны карарга хәтта сарманнар да килгәние», – дип сөйли Шәрәфетдин бабай.

Телевидение редакторы, халык белән исәнләшкәч:

– Галимҗан кайда? – дип кызыксынды.

Халык аптырашта калды.

– Ә нигә кирәк ул Галимҗан? – дип сорады берничә тавыш.

– Тапшыруга төшерәбез, – дип җавап бирде редактор.

Галимҗан, авылдашларын аралый-аралый, редакторга таба ашыкты.

Халык ачу белән гөжли башлады:

– Тагын Галимҗанны төшерәләр...

– Нишләп гел аны гына?..

– Кая гаделлек?! Ә башкалар?..

– Монда хәзер аңардан да ныграк эчүчеләр бар...

– Мин дә эчәм!..

– Галимҗан эчми бит инде хәзер... Аның нәрсәсен төшерәсең инде?!

Гөжләү бераз тынгач, сүзне тагын редактор алды:

– Җәмәгать! Галимҗан телевидение йогынтысы астында эчүен ташлаган. Бу бит безнең өчен бик яхшы материал. Аны әбизәтелне тапшыруда күрсәтергә кирәк. Башкаларга үрнәк булсын.

Халык тагын умарта күчедәй кайный башлады.

Монтер Әгъләм, аксый-аксый, алга чыкты:

– Син давай бөгештермә, – диде ул редакторга. – Хватит прастуй халыкны алдарга. Мин сезнең аркада эчкечегә әйләндем, баганадан егылып төштем. Син мине төшерергә тиеш!

Кинәт кемдер:

– Сәлим килә! – дип кычкырды.

Халык төрле якка чәчелде.

Утын яра торган колун балтасын болгап, тарихи вакыйгалар белән саташып йөрүче «белая горячка» иясе Сәлим җил-җил атлап редактор каршысына килеп басты.

– Мин 1905 елгы рус-япон сугышында Цусимадан исән калып чыккан кеше, – дип башлады ул сүзен. – Төшер мине кинога!

Редактор, тарих укытучысының акайган күзләреннән һәм балтадан куркып, аның диңгез сугышында катнашканына каршы килмәде.

– Бик әйбәт булган, – диде ул юаш кына.

– Әйбәт булса, төшер әйдә! – дип кычкырды Сәлим. – Мин егерме алты Баку комиссарларының егерме җиденчесе.

Бу вакытта редактор Сәлимнең егерме җиденче генә түгел, егерме сигезенче комиссар булуына да риза иде.

Кинәт Сәлим, җан өзгеч тавыш белән акырып, балтасын күтәрде. Редактор автобус эченә кереп качканын үзе дә сизми калды.

– Ач! – дип кычкырды тарих укытучысы, автобусның ябык

ишегенә балта түтәсе белән орып. – Мин Ватан сугышында Киевны берүзем алган кеше. Бирермен мин сезгә «белая горячка»!

Аның соңгы сүзләре коймалар артына поскан, агач башларына менеп кунаклаган авылдашларына адресланган иде.

Сәлимнең өстенә унбишләп кеше сикерде һәм аның кул-аякларын бәйләделәр дә күтәреп өенә алып кайтып киттеләр. Үзен күтәреп баручыларны ул: «Бериягә язам!» – дип куркытты. Бераз вакыт үткәч, югары очтан тонык кына булып Сәлимнең «Сәнәкчеләр баш күтәрә!» дигән сүзләре ишетелде.

Телевидение автобусы, Галимҗанны алып, Казан студиясенә юл тотты. Автобуска утырганда, Галимҗан авылдашларының:

– Авылга кайтма, үтерәбез! – дигәннәрен ишетте.

* * *

Галимҗан төшкән тапшырулар барыбер эфирга чыкмады – моның сәбәбен беркем дә белми. Мөгаен, Галимҗан, авылдашларыннан куркып, үзен күрсәтмәүләрен сорагандыр.

Ул беркавым Актаныштагы туганнарында яшәде.

Укытучы Сәлимнең коега төшеп үлгәнен ишеткәч, Галимҗан туган авылына кайтырга батырчылык итте.

Әлбәттә, авыл халкы аның кайтуын өнәп бетермәде.

Авылдашларының кичермәвен Галимҗан йөрәгенә бик якын алды һәм тагын эчә башлады.

1990

ЫШАНЫРГА КИРӘК

Кашпировскийның телесеансларын кабул иткәч, борын очындагы миңем бетте. Әллә ул сеансларны миңа күп карарга ярамый, әллә инде Кашпировский телевизордан борыныма озаграк карап торган – икенче кат телевизор каршында утырганнан соң, борыным кечерәя башлады һәм юкка чыгу куркынычы астында калды.

Борыным бетүдән мине Чумак коткарды. Аның биодулкыннары астында торган су белән ышкыгач, борыным үз хәленә кайтты, әле бераз зурайды да бугай.

Димәк, ул тапшыруларны миңа карарга ярамый.

Гипнозның кемгәдер файдасы бар, ә кемгәдер ул, киресенчә, зыян китерә... Ничава, Алла боерса, тиздән экстрасенсларга барыбыз да иярләшербез, ышана башларбыз һәм, ниһаять, һәрберебез файда гына күрер.

Ышанырга гына кирәк!

Әйткәнемчә, әле хәзергә телесеанслар һәркемгә дә ярдәм итми.

Минем белән эшләүче Гришаның тәнендәге татуировкалары беткән. Аның җилкәсендә шундый матур чиркәү бар иде. Кашпировскийның күзләре чиркәүнең тәресен ашап бетергән. Гришаның эче поша: «Төрмәдә утырганда егерме җиде пачка чәй түләп ясаткан идем», – ди.

Минем күршем Гыйльметдин абый «иптәш Чумак сыекчаларның сыйфатларын үзгәртә ала» дигән сүзне ишеткәч, мичкәсеннән өч литрлы банка белән брага алып, телевизор каршысына китереп куйган.

– Сеанстан соң браганың градусы биш тапкыр артты, – ди Гыйльметдин абый, – шул өч литрны эчкәнием, берни хәтерләмим – шартлап ауганмын...

Әнә Лотфый белән Хәернисаның сигез ел бергә торып балалары юк иде... Кашпировскийны карагач, Хәернисa авырга узды. Лотфый үзен кая куярга белми эчүгә сабышты. Көнләшә: «Бала Кашпировскийдан», – ди. Аерылышалар бугай инде.

Күрше подъездда манный боткасы гына ашап яшәүче 98 яшьлек Фәйзрахман бабайның кычытып тешләре чыга башлаган. Ә аның тешләре Беренче бөтендөнья сугышында ук окопларда ятканда коелып беткән булган. Фәйзрахман бабай хәзер Кашпировскийга озын гомер теләп, рәхмәтләр укып утыра.

Күрәсез, чынлап та, кемгәдер файдасы бар, кемгәдер, киресенчә, зыян гына. Аптырамагыз бер дә, телесеанслар һәммәбезгә дә уңай тәэсир итә башлар. Ышанырга гына кирәк!

Тиздән скептиклар да ышана башлар. Чөнки безнең бүгенге көндә башка ышаныр нәрсәбез юк. Аллага ышанмыйбыз, партиядән шикләнәбез, киләчәгебездән куркабыз, бүгенге тормышыбыздан көлгән булабыз.

Быел көз коры килде – рәхмәт яусын Чумакка, аның эше бу... Быелгы кышны да җылырак итсә, аңа рәхмәтебез чиксез булыр иде.

Минемчә, Чумакны күбрәк тышкы политика эшләрендә кулланырга кирәк. Капиталистик илләрдә җәйләрне коры итсен, кышларын җитмешәр градус ясасын. Шулай итеп, Җир шарында социализмның тәмам җиңеп чыгуын тизләтер иде ул. Мәсәлән, койдырсын Америкага өч ел беррәттән яңгыр – бүртеп, череп бетсеннәр, барыбер капитализм череп бара торган система бит.

Ходаем, үзең сакла берүк, Чумак белән Кашпировский чит илгә тая күрмәсеннәр... Андый сихерчеләр бүгенге көндә безгә бик тә кирәк. Менә күрерсез, бер егерме елдан алар илебездә авыру, сәрхуш кешеләрне калдырмаслар. Ә безгә чиратларда торырга, трамвайларда, автобусларда төрткәләшергә, бер-беребез белән талашырга һәм сугышырга сәламәтлек, ай-һай, ничек кирәк.

Шулай ук нитратлы ризыклар ашыйк, шулай ук бер-беребезнең нервыларын бетерик, урманнарны кисик, елгаларны пыч-

ратыйк, атом станцияләрен күбрәк төзик... Чөнки безгә хәзер бернинди чир дә, хәтта радиация дә куркыныч түгел – безне Кашпировскийлар, Чумаклар терелтер, шулар безне аякка бастырыр.

Менә бит, ә!.. Сәламәт булыйм дисәң, җайлы гына, авызыңны ачып, күзләреңне чекерәйтеп, телевизорга карап утырасың...

Гипноз тәэсир итмәгән кешеләр! Зинһар өчен, борчылмагыз! Сезгә дә ярдәме тия башлар. Ышанырга гына кирәк!..

Ә йөзләгән милләттән торган халыкның ышана башлаячагына минем иманым камил. Халык ышанучан безнең... Әйбәт халык... Бигрәк тә төрле «Алла»лар өчен, «пәйгамбәр»ләр өчен, гипнотизерлар өчен, сихерчеләр өчен безнең халык бик уңай клиентура.

Ышанырга гына кирәк...

1990

ЧЫН ЯРАТУ

– Яратасыңмы мине? – диде Миләүшә ялварулы тавыш белән.

– Яратам! – дип пышылдады Зәбир.

– Минем өчен коега сикерер идеңме? – дип сорады Миләүшә, таләпчән итеп.

Зәбир, уйлап-нитеп тормый:

– Әлбәттә, сикерер идем, кадерлем! – диде.

Миләүшә кинәт җанланып китте:

– Сикер әйдә хәзер үк!

Зәбир аптырашта калды. Ул ык-мык килеп торган арада, Миләүшәсе үпкәләргә дә өлгерде:

– Яратмыйсың син мине... Яратсаң, сикерер идең... Әнә Фәрит минем өчен коега сикергән иде.

«Тагын Фәрит...» дип уйлады Зәбир, көнләшүдән, чарасызлыктан һәм шул таныш булмаган Фәриткә карата ачудан үзен кая куярга белмичә.

Зәбир кинәт Миләүшәнең беләгеннән тотты да:

– Әйдә киттек! – диде. – Сикерәм!

Миләүшә шатлыктан кулларын чәбәкләде. Аның бу кыланышы Зәбирне тагы да ныграк дуамалландырды, һәм алар, ашыгаашыга, авыл башындагы коега таба юл тоттылар.

Зәбир коега сикерде. Мәхәббәте бик көчле иде шул. Кое эченнән су чапылдаган тавыш бер минут чамасы яңгырап торды. Бераздан Миләүшә, коега карап:

– Зәбирчик! – дип эндәште. – Син исәнме?

Кое төбеннән чыккан «Исе-се-сә-ә-ән!» дигән калтыравыклы җавап Зәбир тавышына охшамаган иде.

– Ничек чыгасың инде хәзер? – дип сорады Миләүшә, Зәбирне бераз кызганып.

Зәбир сөйгәненең бу соравына игътибар итмәде.

– Үзең курыкмадыңмы соң, матурым? – дип борчылды ул Миләүшәсе өчен.

– Бар бераз... – диде Миләүшә. – Ничек чыгасың, дим?

– Яратуыма ышанасыңмы соң хәзер, җанкисәгем? – дип сорады кое.

– Ышанам, әлбәттә, – диде Миләүшә.

– Миләүшә! Чиләкне төшер... Чылбыры беткәнче төшер! Мин чылбыр буйлап менәрмен.

Миләүшә чылбырга бәйләнгән чиләкне коега төшереп җибәргәч, астан «А-а-а-а!» дигән җан өзгеч аваз, күтәрелеп, авыл этләрен уятты.

Аннан:

– Башка төшердең бит! – дигән шелтә менде.

Миләүшәнең моңа ачуы килде:

– Ә мин күрәм, што ли?! И ваще, нәрсә син миңа кычкырасың?!

– Гафу ит, Миләүшә, – диде Зәбир һәм чылбырга тотынып менә башлады. Кое эченнән аның авыр итеп мышнаганы ишетелде. Кинәт тагын чалт иткән тавыш яңгырады.

– Чылбыр өзелде, – диде кое.

– Монысында мин гаепле түгел инде, – диде Миләүшә, чылбыр өзелүдә үзенең катнашы булмаганга куанып. – Кешеләрне чакырыйммы?

Кое эченнән борчулы тавыш чыкты:

– Юк, юк, матурым, кирәк түгел. Кешеләрдән оят... Бәлки, үзебез берәр чара табарбыз.

– Нәрсә-ә-ә?! Син кешедән ояласың?! Минем өчен коега сикергәнеңне кешеләргә белдерергә куркасыңмы?! Шулмы синең яратуың? Фәрит әнә кешеләр алдында сикергән иде!

«Фәрит» дигәнне ишеткәч, кешеләрне ярдәмгә чакыруга кое төбендәге мәхәббәт колы каршы килмәде.

...Икенче көнне төнге урамда, марля белән уралган башын бер кулы белән тотып, йөткерә-йөткерә, Зәбир Миләүшәгә назлыдан-назлы сүзләр әйтеп тора иде. Зәбир үзен каһарман дип исәпләде һәм шуңа күрә Миләүшәне инде үзенеке дип санады. Ул да теге Фәриттән ким-хур түгел ләбаса! Фәрит әле кое чылбырлары өзелеп бимазаланып ятмагандыр.

– Хәзер белдеңме инде ничек яратуымны? – диде Зәбир тантаналы тавыш белән.

– Ышанам, Зәбир, – диде Миләүшә, авыр сулап. – Тик Фәрит ныграк яраткандыр инде, күрәсең...

Зәбирнең бәгыре урталай ярылды.

– Нинди Фәрит соң ул? Кем ул? Кайда ул?

Миләүшә дә кызып китте:

– Че психуешь?! Ул минем Минзәләдә практикада вакытта йөргән егетем.

– Соң, мин дә сикердем бит инде коега. Тагын ничек исбатлыйм соң яратуымны?

– Һе... Фәрит бит ул башы белән аска чумды. Ә син аякларың белән аска сикердең.

Зәбир тагын бер кат салкын коега сикергәндәй булды.

– Баш белән чумды?! – диде ул, шаккатып.

– Әйе, башы белән. Менә бу ярату, ичмаса!

– Исәнме соң ул?

– Исән. Акылы гына бераз алышынгалап тора.

– Карале, аның акылы коега чумганчы ук булмагандыр инде. Акыллы кеше коега баш белән чуммас.

Миләүшәнең күзләре акайды:

– Нәрсә дидең?! Шәп икән яратуың. Ул синнән акыллырак иде, беләсең килсә.

Зәбир кинәт мәхәббәт турында онытты. Бу минутларда аның кое салкыныннан һәм Миләүшәнең салкынлыгыннан бәсләнгән күңелендә теге Фәрит исемле дошманга карата нәфрәт кенә сулкылдый иде.

Зәбир, аякларын көчкә сөйрәп, авыл башындагы коега таба китеп барды. Аның артыннан, вак-вак атлап, сөйгән яры иярде.

Зәбир чумды!

* * *

Хастаханәдә җиде ай яткач, ул аякка басты. Коега чумып исән калуына һәм Миләүшәнең бирегә килгәләп йөрүенә чиксез куанып, Зәбир үзен бик бәхетле хис итте. «Менә хәзер ышанадыр инде яратуыма» дип уйлады ул.

Беркөнне Миләүшәсе килгәч, Зәбир бу хакта сорарга тагын батырчылык итте:

– Хәзер ышанасыңмы инде?

– Ышанам! – диде Миләүшә. – Ләкин...

Зәбирнең чыраена сары төс йөгерде:

– Нәрсә «ләкин»?

– Әй, юк, болай гына... – дип мыгырдады Миләүшә, «ләкин»не ник әйткәненә үкенебрәк.

– Әйтеп бетер, әйтеп бетер! – диде Зәбир, тынгысызланып.

Миләүшә әйтеп бетерергә булды.

– Фәрит бит мин әйткәнне көтеп тормады... үзе сикерде. Ә син мин кушкач кына сикердең.

Моны ишеткәч, Зәбир телсез калды. Ул авыр адымнар белән палатасына керде дә караватка ауды. Бу минутларда ул коедан исән чыкканына үкенә иде.

Күп тә үтмәде, тышта, палата тәрәзәсе каршында Миләүшәнең чәрелдәвек тавышы яңгырады:

– Зәбир!

Зәбир, барыргамы тәрәзә янына, юкмы дип, бик озак икеләнеп ятты. Миләүшә тагын биш-алты тапкыр кычкыргач, ул түзмәде, форточкадан башын тыкты. Аста, елаудан шешенеп беткән йөзен угалап, Миләүшәсе тора иде.

– Нәрсә, минем белән сөйләшәсең дә килмимени? – диде Миләүшә.

Зәбир дәшмәде.

– «Яратам!» дигән булып мине алдап йөрттең, – дип шыңшыды Миләүшә. – Әле син коега сикергәнеңә дә үкенәсеңдер. – Ул тагын кычкырып елап җибәрде.

– Бар кайт! – диде Зәбир тыныч кына һәм форточканы шапылдатып япты да караватына сузылып ятты.

Теге Фәритнең ник коега сикергәнен Зәбир инде аңлаган иде.

1991

КАРГЫШ

Җайлыгали гомер буе ат шикелле эшләде. Тик нишләптер аның ни акчасы, ни малы булмады. Тамагы туеп җитмәсә дә, үзенең хезмәте белән якты киләчәк төзүгә һичшиксез өлеш кертүенә ул ышанып һәм шуңа куанып яшәде.

Үләр алдыннан аның ике әйбере бар иде: түшендә бер соры медаль, ашказанында – язва. Авыруы үзе белән гүргә кереп китте, медале өстә, бу дөньяда калды.

Аның карчыгы, шул медальне алып, түбәгә шифер сорарга райкомнарга барып йөрде. Ләкин, кызганычка каршы, андый медальләр илдә язваларга караганда да күбрәк, ә шифер чамалы гына булып чыкты.

Озакламый карчык шиферга да туеп җитмәгән дөньядан үзе дә китеп барды.

Картларның балалары булмаганлыктан, йорт эчендәге өстәлурындыкларны күрше-күлән ташып бетерде. Иске булу сәбәпле, йортны колхоз утынга турады.

Күрше керәшен авылыннан килеп тамак хакына утын ярып, су ташып йөрүче җүләр Пилипкә теге медаль эләкте һәм ул аны түшенә кадап куйды.

Тормыш дәвам итте. Шунысы гаҗәп: тормыш бу авылда гына

түгел, бөтен илдә дәвам итте. Әйтерсең лә фаҗига бөтенләй юк, әйтерсең лә бар дөньясын актарып ташлардай бернәрсә дә булмады.

Ләкин тормышлар дәвам итсә дә, илнең кая таба барганын иң гыйлемле галим дә әйтә алмас иде. Микроскоптан шактый вак әйберләрне күрсә дә, иске китаптан кемнең бабасы кем булганлыгын мәгълүм кылса да, мамонтларның ни сәбәптән үлеп беткәннәрен әйтергә маташса да, биш-алты телдә сөйләшсә дә, сүтелгән йорт урынында ята-ята елаган җилнең телен кеше беркайчан аңлый алмаячак.

Дөньяның иң бөек фикер ияләре җыелып зур симпозиумнар үткәргән сурәттә дә Җайлыгалинең гомер йөген сөйрәп иза чиккәннән соң ишәк сыман эшләгән өчен бүләк ителгән медален дә алмыйча бу дөньядан вакытсыз китеп баруының сәбәбе аңлашылмас.

* * *

Беркөнне шомлы хәбәр таралды. Төнлә авылда мәрхүм Җайлыгалинең җаны пәйда булган. Ап-ак шәүлә булып күренгән, имеш.

Бу хәбәрне Җайлыгалинең күршесе – эчкече Гыйлаҗи әйтте. Ләкин, эчкеченең күзенә ни күренмәс дип, авыл халкының бу хәбәргә игътибары бигүк зур булмады.

– Менә шушы басып торган җиремдә чәчрәп катыйм… Җайлыгали… ап-ак киемнән… – дип, тегеннән-моннан йолкып сөйләде Гыйлаҗи ипи кибетенә чиратка тезелгән авылдашларына. – Хатыннан яшереп куйган самогоным бар иде… мунча өйалдында… Төнлә шуны алырга дип барганыем… мунча артыннан килеп чыкты. «Нишләп минем медалемне җүләр Пилипкә бирдегез?» – ди. Куркуымнан телсез калдым. Ул шулай диде дә юкка чыкты. Рәнҗидер мәрхүм миңа – аның медален, барыбер кирәге юк инде дип, үз кулларым белән Пилипкә бирдем бит. Рәнҗидер… Шулай төннәрен килеп гел бимазалар инде…

– Самогонны күбрәк эчсәң, Җайлыгали генә түгел, бабаң да кайтып керер әле.

– «Белая горячка» синдә, брат, эчмә бүтән!

– Ычкынасың син!..

Ипи чираты, гөж килеп, эчтәлеге белән шушы өч җөмләгә охшаган нотык сүзләре белән Гыйлаҗины башыннан аягына кадәр коендырды.

Бөтен авыл халкы «белая горячка» дигәч, Гыйлаҗи үзе дә мәрхүм күршесенең рухы белән очрашуны эчкечелек зәхмәтедер дип килеште. Ләкин кешеләр үзләрен һәм бичара Гыйлаҗины тынычландырырга тырышсалар да, авылның һәр тыкрыгына, һәр каралты-кураның караңгы почмакларына шом иңгән иде. Нин-

дидер авыр хәсрәт йөге бар иде авылның, ниндидер гөнаһы, гаебе бар иде. Аң белән тотып алырлык нәрсә түгел иде бу. Авылны борчыган нәрсә кеше аңыннан йә өстәрәк, йә, киресенчә, астарак ята иде.

Шулвакытны кибет яныннан үтеп баручы партком секретаре Якуб туктады да, кет-кет көлеп, Гыйлаҗидан сорады:

– Ничек, ничек диде? Медальне ник Пилипкә бирдегез, диеме?

Партком секретаре көлгәч, халык төркеме дә, ярарга тырышып, кыхы-кыхы көлгән булды.

Кызу канлылыгы белән авылда гына түгел, бөтен районда дан казанган тимерче Хөснулла янында торучыларга селәгәен сибеп кычкырырга тотынды:

– Соң ул медальләрне җүләр кеше генә тагарга тиештер дә инде. Җүләр булгач, әнә коммунизм төзибез дип ишәк кебек эшләдек – шуның ише медальләргә алданып. Тиктомалга үзләренең күкрәкләрен үзләре медальләр белән тутыручылар да булды... Алары да акыллы түгел. Әнә иясе гүргә кереп киткәч, әлеге дә баягы медальнең кирәге шул мескен Пилипнең түшенә кадарлык кына булып чыкты. Кемгә кирәк ул медаль хәзер?! Бил бөгеп эшләүче кешенең кадерен исән чакта белергә кирәк! Медаль белән алдап түгел, башкачарак белергә кирәк хезмәт кешесенең кадерен. Кирәк булса, андый медальләрне мин көн саен алачыгымда меңәрне ясый алам.

Хөснулланың чыгышыннан өркеп, ипи чираты гына түгел, кибет янында чыр-чу килеп уйнап йөргән балалар да тынып калдылар.

– Күп сөйләмә, алып китәләр бит хәзер үзеңне... – диде кемдер басынкы тавыш белән.

– Апкитмиләр! Димакратия хәзер! – дип, тагын да ныграк кычкырды Хөснулла. – Пириструйкы хәзер! Апкитсәләр дә, апкитмәсәләр дә, мин әйткән сүз дөрес: ул медальнең кирәге исән чакта да, үлгәч тә бер чама.

– Дөрес, дөрес, Хөснулла абый, – диде партком секретаре һәм баягыдан да ямьсезрәк итеп көлеп куйды.

Хөснулла әйткән сүзләрдән котсыз калган халык партком секретаре көлгәч җанланып китте һәм бераз тынычланды.

* * *

Ул төнне авылга йокы кермәде. Кешеләрнең күңелләрендә тынгылык юк иде. Төн уртасында этләр ярсып өрделәр, абзарларда йорт хайваннары кыбырсыды. Кемдер зарлана-зарлана боргаланып ятты, кемдер бер сәбәпсез торып ут кабызды, кемдер, куркудан кечерәеп, тараеп калган урамга күз салды, кемдер тыптын гына, Ходайдан мәрхәмәт сорап, белгән догаларын укыды.

Урамнарда беркем йөрмәде, кешеләр шылт иткән тавышка да сискәнеп нидер көтеп яттылар.

Кинәт төнне ертып, җаннарны өзәрлек итеп кычкырган тавыш ишетелде. Бу үкерү кеше тавышына да бераз охшаган, шулай да күбрәк саташкан җанвар авазын хәтерләтә иде. Бу тавыш йә күктән, йә җир астыннан чыгарга тиеш иде, чөнки җир йөзендә андый коточкыч тавыш белән акыручы җанвар да, адәми зат та була алмас.

Бу аваздан авыл өстеннән очып барган ниндидер төн кошы шапылдап җиргә килеп төште. Этләр, котлары алынып, өрүдән туктадылар. Бишек балалары шар ярып еладылар, олыраклар юрган астына качтылар.

Авыл куркудан бөреште һәм һаман шул мескен җиргә иңде. Чөнки аның бүтән сыеныр урыны юк. Бу вакытта дөм караңгы билгесезлекнең салкын кочагында калтыранып утырган авыл үзен төпсез бушлыкка төшереп җибәрми тотып торган газиз җиренең эчләренә төшеп утырыр иде.

Бик нык курыккан, котсыз калган вакытта, нишләптер һәркем, һәрнәрсә җиргә иңеп юкка чыгарга әзер була. Андый вакытта нигәдер чиксез-кырыйсыз күкләргә очып китәсе килми. Шатлыклы, бәхетле минутларда һаваларда очкан күңел, шом баскач, авырлыктан аска тарта.

Гөнаһлары күп булып, үзендә гаеп сизсә, кеше күкләргә талпынмый. Киресенчә: «Оятымнан җир тишегенә кереп китәрдәй булдым», – ди. Әйе, күккә түгел, җир тишегенә...

Күктә җавап бирәсе бар, анда сине хөкем итәрдәй Бөек Көч бар. Шуңа күрә авыр минутларда, кайгы килгәндә, курыкканда адәм баласының җиргә сеңәсе килә.

Кычкыру тагын кабатланды. Әллә кабат кычкырдылар, әллә теге аваз күкләрне ярып чыгып киткәннән соң, Галәмгә сыя алмый, кайтып янә яңгырадымы?!

«Ахырзаман билгесе бу!» – диделәр диниләр дә, алласызлар да.

Кычкыручының Җайлыгали икәнлегендә шикләнүче юк иде, эчкече Гыйлаҗиның сөйләгәннәре дөреслегенә авыл бу төнне ышанды. Бу рәнҗүле аваз мәрхүм Җайлыгалинең тавышына бик охшаган иде.

* * *

Инде бүтән таң атмастыр кебек иде. Ләкин нинди генә хәвеф-хәтәр килмәсен, гайре табигый хәл булмасын, барыбер мескен адәм баласын өметләндереп таң ата да куя.

Авылның котын алган теге төннән соң да, берни булмагандай, тау артыннан кояш килеп чыкты, кошлар сайрады, сыерлар мөгрәде, көтүче ачы итеп сүгенде, кешеләр эшкә китте, балалар мәктәпкә йөгерде.

Кыскасы, тормыш тагын дәвам итте.

Җайлыгали турында сөйләшергә курыктылар. Гадәттә, авылда берәр яңалык, бигрәк тә тетрәндергеч вакыйга булса, аның турында һәр урамда, тыкрыкта, чатта «су куша-куша» чәйниләр. Әмма Җайлыгалинең рухы белән бәйле вакыйга халыкның акылына сыярлык түгел иде.

Урамда кич утырулар бетте, яшьләр бакча артларында йөрми башлады, төнлә тышка печ итәргә чыгулар да тукталды.

...Беркөнне җүләр Пилип, үзе генә аңлый торган ниндидер сәер җыр шыңшып, авылга килеп керде.

Төшке аш вакытында өенә баш төзәтергә дип кайткан Гыйлаҗи аны күреп өеннән атылып чыкты һәм Пилипкә таба ыргылды. Аның медальне талап алырга ниятләгәнен Пилип ничек аңлап алгандыр – бер Алла гына белә. Ул сабыйларча елап җибәрде, тиз генә түшендәге медальне йолкып бушлат кесәсенә салып куйды. Гыйлаҗи, аты-юлы белән сүгенеп, аңа ташланды:

– Бир мидәлне! Анаңны, денеңне...

Ул бер мәлгә һушсыз калган тилене якаларыннан әләктереп җилтерәтә башлады һәм, җаен китереп, чалып җиргә екмакчы булды. Ләкин күп еллар буе аракы эчү сәбәпле, Гыйлаҗи инде бик сыек гәүдәле иде. Пилипне алып сугардай җегәре юк иде аның. Мыш-мыш килеп йолкыша һәм сөзешә торгач, алар икесе дә җиргә шапылдап аудылар. Гыйлаҗи аста калды.

Гыйлаҗиның каршылык күрсәтми башлавына гаҗәпләнеп, Пилип аның өстеннән әкрен генә торды. Бернинди хәрәкәтсез ятучы Гыйлаҗины иелеп селкетеп карады. Теге ыңгырашып куйды. Аның мәңге айнымас башы егылганда юлда яткан ташка туры килер дип кем белгән дә, кем уйлаган... Аның муены астыннан кан агып чыккач, Пилип, күзләрен акайтып, як-ягына карады, ямьсез тавыш белән нидер әйтмәкче булып мөгрәп куйды. Шуннан соң ул елый-елый инешкә төшә торган тыкрыктан йөгерде.

Тиз арада күрше-күлән җыелды. Гыйлаҗи авырлык белән күзләрен ачты. Аны күтәреп өенә алып керделәр. Ясин чыкканнарын да, хатын-кызларның сулык-сулык елаганнарын да тыңлап-нитеп тормыйча, Гыйлаҗи җан бирде.

Берничә ир, ярсып, тыкрык буйлап Пилип артыннан йөгерде.

Авылда кыйный беләләр.

Күрәсең, акылга зәгыйфь кешене тикмәгә генә «Алла бәндәсе» димиләрдер. Гаделсезлектән, авыр хезмәттән тимергә әйләнгән йодрыклар астында «Алла бәндәсе» булмасаң, исән калу мөмкин түгел.

Инешкә манчый-манчый кыйнаганнан соң, Пилипне шул инешкә кадәр сузылып төшкән Галимә әбинең бакча коймасына сөяп утыртып куйдылар.

Озак утырды ул аңына килә алмыйча. Караңгы төшә башла-

гач кына күзләрен ачты һәм иң беренче хәрәкәт итеп бушлат кесәсендәге медальне капшап карады. Медальнең үзендә булуы аңа хәл кертте, сихерле көч сыман аякларына бастырды, гәүдәсенең авыртуын һәм авырлыгын киметте.

Пилип каты кыйналуын да онытты, ыңгыраша-ыңгыраша булса да, хәйран җәһәт кенә аягүрә басты һәм аксаклап үз авылына таба атлады.

* * *

Гыйлаҗи үлгән төнне авыл өстендә ямьсез итеп көлгән тавыш ишетелде. Бу, һичшиксез, Җайлыгалинең тавышы иде.

Авыл тын алырга да куркып ятты. Партком секретаре Якуб бөтенләй үлле-мәлле хәлдә булды, чөнки Җайлыгалинең рухы аның йорты тирәсендә йөрде.

Бакча капкасы шыгырдады, эт өзгәләнеп улады. Тәрәзә артында шәүлә күренде. Һәм кинәт-кинәт көлгән тавыш ишетелеп куйды.

Якубның хатыны Фәния кайнар сулышы белән юрган астын өтеп пышылдады:

– Якуб, әллә мылтыктан атып карыйсыңмы?

Якуб дәшмәде, юрган астыннан әледән-әле салкын тиргә чыланган башын чыгарып, тәрәзә ягына күз салгалады.

Юк, курыкты ул мылтык белән чыгарга. Тик кенә ятарга кирәк... Заманалар башка... Партиясе дә бетәргә тора... Бүген партком секретаре ул, иртәгә – юк... Ни булса, ул... Тик кенә ятарга кирәк... Нинди мылтык ди ул тагы...

Нишләп аның йорты тирәсендә йөри соң ул?.. Бу сорауга җавабы бар аның. Җайлыгали алдында нинди гаебе барлыгын Якуб бик яхшы белә.

Җайлыгали колхозның иң авыр эшләрендә эшләгән кеше иде. Эчкерсез, сабыр һәм надан булуы аркасында авылдашлары арасында да абруй казанмады. Һәм инде колхозның да аңа беркайчан ярдәме тимәде. Ә мәрхүмнең ярдәмгә мохтаҗ вакытлары күп булды.

Якуб юләр түгел, Җайлыгалинең җаны бу тирәдә ник йөргәнен аңлый. Гыйлаҗига Җайлыгалинең каргышы төшкәнлегенә Якубның шиге юк иде. Гомере буе җан тирен түгеп эшләгәне өчен бирелгән медальне үзеңнән соң дуракка бирсеннәр әле!.. Кемнең җаны әрнемәс моңа?!

Якубның гаебе исә аның алдында тагы да зуррак. Чөнки медальне партком секретаре буларак ул Җайлыгалигә бүләк иттерде – хезмәте өчен. Ә үзе күптән түгел бөтен халык алдында: «Дөрес, дөрес, Хөснулла абый...» – дип, медальне җүләр кеше тагарга тиешлеген хуплады.

Шуңа күрә Җайлыгалинең рухы аның йорты тирәсендә йөри.

* * *

Төн йокысыз үтте. Якуб, таң ату белән җүләр Пилипне эзләп, күрше керәшен авылына китте. Тилелеге белән тирә-якта дан казанган Пилип капка төбендә иртәнге кояш нурларында мәлҗерәп утыра иде. Якуб, аның йокымсыравыннан файдаланып, шыпырт кына якынаеп медальне җүләрнең түшеннән йолкып алды.

Пилип аңына килгәндә, Якубның мотоциклы авылдан чыгып бара иде инде. Тиле ачы тавыш белән елап, абына-сөртенә аның артыннан йөгерде.

...Якуб, каяндыр колак кырые белән ишеткән догаларның сүзләрен әйтергә маташып, чак кына ишетелерлек итеп гафу үтенә-үтенә, Җайлыгалинең кабер калкулыгы янында утырды. Шуннан соң кабер өстендәге балчыкны бераз актарып чокыр ясады һәм медальне күмеп куйды.

Китәргә кузгалгач, ул инде әллә ничәнче тапкыр:

– Гафу ит, Җайлыгали! – диде. – Кадереңне белүче булмады. Мин дә партком секретаре буларак шушы медальдән артыгын бирә алмадым. Ә теге көнне медальне җүләр кеше тагарга тиеш дигән сүзләрне хуплап көлгәнем өчен, зинһар, рәнҗемә!

Кинәт зират түрендә, карт каеннар арасында кемнеңдер гәүдәсе чагылып үтте дә биек, куе булып үскән үлән арасына ятты. Якуб курыкмады. Чөнки ул аны таныды.

– Пилип, нишләп йөрисең?

Пилип дәшмәде. Якуб аңлады: бу тиле аның медальне яшергәнен күзәтеп торган.

– Пилип, кил әле монда!

Пилип әкрен генә үлән арасыннан калыкты, аягүрә басты һәм Якубка таба кыяр-кыймас атлады.

– Пилип, син күреп тордыңмы?

– А-а-а... м-м-м-м-м-м...

– Медальне күмгәнне күрдеңме?

– Күлдем.

– Медаль шушында, Җайлыгали янында ятсын, яме. Медальне сиңа биргән өчен аның рухы рәнҗеп йөри. Шуңа күрә Гыйлаҗига аның каргышы төште. Медальне сиңа Гыйлаҗи биргән бит...

– Миңа мидал киләк, – дип мыгырдады Пилип һәм кабер өстенә кулын сузды.

– Тимә, Пилип, каргышы төшәр.

Җүләр аны тыңламады, кабер өстен капшап медальне эзли башлады. Якуб түзмәде, аның өстенә сикерде.

Якубның партком секретаре икәнлеген һәм андый кешедә власть барлыгын хәтта җүләр Пилип тә аңлый иде. Шул сәбәпледер инде, күпмедер вакыт әүмәкләшкәч, ул партком секретарена би-

реште. Якуб аны, кулын каерып, зират коймасы артында торган мотоциклына таба алып китте. Тилене көч-хәл белән мотоцикл коляскасына салгач, Якуб, кыжрап, бер тапкыр аның чыраена да «менеп төште». Пилип, авызын җәеп, саргаеп беткән тешләрен якты дөньяга чыгарды да елап җибәрде.

Мотоцикл авылга таба очты. Зират калкулыкта урнашкан, шуңа күрә тизлек зур иде.

Көтмәгәндә Пилип үзен медаль хәтле медальдән мәхрүм иткән дошманына ташланды. Мотоцикл беркавым боргаланып барды да юл кырыендагы чокырга мәтәлеп төште.

...Пилип мотоциклдан бер ун адым чамасы читтәрәк ята иде. Аңына килгәч, ул илаулап елап җибәрде, аннары, шыңшый-шыңшый, дүртаяклап мотоцикл янына килде.

Мотоцикл яны белән ята. Аның астыннан ул, шактый вакыт маташа торгач, көч-хәл белән Якубны сөйрәп чыгарды. Партком секретареның авыз-борыныннан һәм башының кайсыдыр җиреннән кан саркый иде. Пилип аны чалкан яткырып куйды да, зәңгәр күккә карап катып калган төссез бозлы күзләрдән котсыз калып, авыл ягына йөгерде.

Әмма ерак китмәде, кире борылып зиратка юл тотты.

* * *

Якубны күмгәннән соң, авыл яңа фаҗигаләргә әзер иде. Гыйлаҗи белән Якубка Җайлыгалинең җан каргышы төшкәнлеген халык сизде, аңлады.

«...Хөснуллададыр чират...» – диде халык.

Хөснулла белгән догаларын укыды, карчыкларга хәер бирде һәм: «Медальне җүләр кеше генә тагарга тиеш дип, киресенчә, Җайлыгали кебек баш күтәрмичә тир түгеп эшләүче беркатлы кешеләрне кызганып әйттем», – дип сөйләнде.

Хөснулла гына түгел иде нык куркучы. Авылның һәрбер кешесе диярлек теге яки бу вакытта, теге яки бу вакыйгада мәрхүм Җайлыгали алдында гаебен сизә иде.

Кемдер аның эскерттән бер чеметем салам алып кайтканын колхоз рәисенә әләкләгән.

Кемдер аның бәрәңге җиренә бер метр кереп рәнҗеткән.

Кемдер комбикорма өләшкәндә аның өлешенә кул сузган.

Кемдер утын алып кайтканда аңа череген төягән.

Кемдер исерек баштан, ызгышып, аңа суккан булган.

Кемдер...

Кемдер...

Кыскасы, юаш кешене һәрвакыт кагалар инде аны. Җайлыгали шундыйлардан иде.

Ә менә хәзер, үлгәч, барысының да котын алды. Бөтен авыл

мәрхүм Җайлыгалидән гафу үтенә башлады, белгән догаларын укырга тотынды.

Пилипкә бәйләнүне туктаттылар. Аның түшендәге медальгә карарга да курка башладылар. Берәрсенә килеп утын ярышырга яисә башка эштә ярдәм итәргә теләсә: «Юк, юк, Пилип, җанкай, кирәк түгел, үзебез эшлибез», – дип, аны болай гына ашатып-эчертеп җибәрә торган булдылар.

Ә Җайлыгалинең җаны авыл өстендә еш күренде.

* * *

Көзгә таба мал-туар арасында яман чир башланды, сарыклар, сыерлар, кош-кортлар кырылды. Игеннәр уңмады, бәрәңге бөтенләй диярлек җитлекмәде.

Аяк-куллары сызлап, баш миен көзән җыерып түшәктә ятучы Хөснулла түшәмгә текәлеп мыгырдады:

– Төште Җайлыгалинең каргышы, төште... Бөтен авылга төште каргышы... Теге вакытта ипи чиратында Якубка ияреп бөтен халык көлгәние... Төште каргыш...

Хөснулла саташып интекте. Авылда ашказаны, бөер, бавыр авырулары белән изаланучылар күбәйде. Унлап кеше йөрәк өянәге белән сырхауханәгә озатылды.

Авылның абруйлы дип исәпләнгән агайлары җыелып киңәштеләр һәм, медален алып, Пилипне җүләрләр йортына җибәрү мәслихәттер, ә медальне Җайлыгалинең каберенә күмеп кую саваплы булыр дигән фикергә килделәр.

Һәм шулай эшләделәр дә.

Атна-ун көн вакыт үтте. Авыл ут йотып яшәсә дә, бу вакыт эчендә өрәк-мазар күренмәде. Тик көтмәгәндә тагын яман хәбәр ишетелде.

Җүләрләр йортында Пилипне бик каты кыйнаган булганнар, чыдамаган – дөнья куйган. Бик кызгандылар Пилипне, бөтен авыл үзен гаепле дип санады – харап иттеләр бер гөнаһсыз Алла бәндәсен!

Аны күмәргә үз авылына алып кайттылар һәм керәшен зиратында җирләделәр.

Шул ук төнне аның елавына охшаган елау ишетелде. Таң беленер алдыннан Пилипне җүләрләр йортына җибәрергә иң беренче булып тәкъдим ясаган Шәйхулланың каралтысы дөрләп яна башлады.

«Юк, каргыштан котылып булмас, ахрысы», – диде халык. Соңгы вакытта авылда кеше болай да азайган иде. Инде бу хәлдән соң авылны ташлап китүчеләр саны артты.

Янгын тагын берничә тапкыр чыкты.

Авылны өркетеп йөрүче рухның кемнеке икәнен әйтерлек түгел иде – Җайлыгалиме ул, әллә Пилипме?..

Хәлен белергә керүчеләргә Хөснулла үзенекен сукалады:

– Пилипне җүләрләр йортына җибәреп тагын зур гөнаһ алдык... Ә дөресен генә әйткәндә, шул Җайлыгалинең каргышы дәвам итәдер инде. Акланып, чистарынып, гөнаһларны юып бетерергә язмагандыр инде кешегә... Авыл бетәчәк... Бетеп килә авыл... Моның сәбәбе бер генә – калай медальгә алдап, билен турайтмый эшләтеп, кешене ишәккә санамасалар, авыл бетмәс иде. Ничек коткарырга авылны? Ничек үзебезне коткарырга – белмим. Гафу итәрлек микән безнең кылганнарыбызны? Кичерерлек микән безне?

* * *

Озакламый авылда беркем калмады. Күченеп беттеләр. Күп тә үтмәде, бирегә шәһәр халкы килеп дачалар төзи башлады. Авыл урынында мәш килеп әллә нинди шикле кешеләр казынырга тотынды. Болар өрәкләрдән дә, шайтанның үзеннән дә курка торган кешеләр түгел иде. Төннәрен кемдер елады, ниндидер шәүләләр күренде. Ләкин төнге рухларның авазын, җан әрнүен аңлардай түгел, хәтта тыңлардай кеше дә калмаган иде инде.

Монда хәзер күптән гөнаһларга батып, әллә нинди каргышлар төшкән кешеләр йөри иде. Кайвакыт үзара сугышалар, атышалар. Йортлары яна, урлашалар, талыйлар, көчлиләр.

Әллә урыны шундыймы, әллә шундый урыннан килгәннәрме – кем белгән?!

1992

БҮРЕК УРЛАУ

Кеше бүрек тегеп кия башлаганнан бирле, дөньяда бер гореф-гадәт яши – бүрек урлау. Бу шөгыль кайчан туган – әйтеп булмый, чөнки кеше кайчан бүрек кия башлаганны хәтта безнең авылның тарих укытучысы Сәлмән абый да белми.

Тарих инде тәмам исбатлады: бүрек урлаучыларга каршы көрәшүнең мәгънәсе юк. Бүрек бар икән – аның хуҗасы булган шикелле, аны урлаучы да булырга тиеш. Бу – закон.

Хәзерге вакытта тәртип саклаучы органнарның андый вак-төяккә бик эчләре пошмый. Чөнки алар бу мәсьәләгә глобаль рәвештә карыйлар.

Алар үзләренчә болай анализ ясый: ярый, берәүнең бүреген урладылар ди. Берәү бүрексез калды, ә икенче бүрексез адәм баласы бүрекле булды. Димәк, бүрек саны барыбер кимеми бит. Илдә күпме бүрек бар, шулкадәр кала. Алар бары тик бер хуҗадан икенчесенә күчеп кенә йөри. Шулай урланып йөри торгач,

бүрекнең иң беренче иясенә, ягъни чын хуҗасына кире әйләнеп кайтуы да ихтимал.

Бүрек урлауның иң популяр төре – аны талап алу.

Бу күренешне, кыргыйлык белән янәшә торса да, матур һәм йомшак итеп атыйлар: «бүрек салдыру».

Кайберәүләр биш йөз тәңкәлек бүрек киеп, биш тиен дә тормаган башларын куркыныч астына куялар.

Һәркемгә мәгълүм: ияк астына суккач, бүрек атылып җиргә тәгәри. Бу ысулны бүрек талаучылар, ягъни бүрек салдыручылар бик еш куллана. Каушамаска кирәк. Ияккә «манчысалар», бүрек белән бергә очарга тырышырга кирәк.

Талаучының эчкә яки касыкка сугуы ихтимал. Бу очракта инде, телисеңме-юкмы, шыгырдап бөгеләсең һәм бандит синең бүрегеңне бернинди мәшәкатьсез салдырып ала. Монда инде шул бөгелгән позициядән талаучыга баш белән бәрергә кирәк.

Соңгы вакытта бүрекләрне бәдрәфтә чүгәләп утыручыларның башларыннан салдырып алып китәләр. Шуңа күрә хаҗәтханәләрдә бүрекне кулга тотып утыру мәслихәттер.

Бүрек өчен көрәш барганда, мәңге кабатланмас бер мизгел булып ала: талаучы да, таланучы да икесе берьюлы бүреккә ябышалар. Бу мизгелдә бүрек әле беркемнеке дә түгел. Дөресрәге, бүрек инде үзенең иясенеке түгел, ләкин әле талаучыга да тәмам күчеп җитмәгән.

Бу мизгелдә гаилә корып, балалар тәрбияләп, изге һәм савaплы эшләр кылырга дип якты дөньяга килгән ике адәм өчен җиһанның гүзәллеге, яшәешнең мәгънәсе йоны кырыла, эче тирдән исләнә башлаган бер бүреккә туплана.

Көньякның күгендә балкучы йолдызлар гаҗәп күңелле тамашаны күрүдән мәхрүмнәр.

Бүрек өчен көрәшнең финалы болайрак тәмамлана. Талаучы талаучы инде ул – бүрекне ничек булса да эләктерә һәм караңгылыкка омтыла. Бүректән колак каккан кеше инстинкт буенча аның артыннан чаба һәм, бандит күздән югалгач кына үзенең стенокардия белән авырганын исенә төшереп, нитроглицерин каба.

Ул бүрекне инде бүтән кию генә түгел, күрү дә насыйп булмый. Аны милиция таба алмый. Чөнки милиция кебек зур нәрсә өчен бүрек – бик вак әйбер.

Ярый әле бүрекне баш белән бергә салдырмыйлар. Бүрекне башы-ние белән йолкыган очракта да талаучы ул башны берәр чүплеккә атып, бүрекне генә үзендә калдырыр иде – үзендә бер баш бар бит инде. Җиткән. Нәрсәгә аңа ике баш... Ике башка бит ике бүрек кирәк. Бер бүрек кенә урлыйсы урынга икешәрне урларга туры киләчәк.

Бүрек салдыру – бик тетрәндергеч акт. Бүрек иясе өчен дә, шул бүрекне талаучы өчен дә. Бу көрәштә һәркем гөнаһсыз һәм

хаклы. Бүрек хуҗасы бүрек аныкы булганга хаклы, ә талаучы яхшы бүрекгә булмаганга үзен хаклы дип саный.

Ул бүрек нинди башны каплап йөргән һәм таланып алынгач нинди башны каплаячак – бүрек салдыру процессында бернинди дә роль уйнамый. Ә бүреккә исә барыбер. Чөнки аның җаны юк. Әгәр бүрекнең җаны булса, урлангач та хуҗасына кире очып кайтыр иде. Әгәр бүрекнең җаны булса, талаучыны тешләр иде, тырнар иде... Юк шул. Талаучының да, таланучының да җаннары бар, ә менә шул җан ияләрен сугыштырган бүрекнең җаны юк.

Төнге урамда, тәүлекнең шигырьләр язып кына утыра торган вакытында, меңләгән йолдызлар күзәтүе астында, мәңгелек гармония вәгъдә итүче Галәм уртасында ике җан иясе бер бүрек өчен бер-берсенең бугазына ябышалар. Монда инде гармония дигән нәрсә бераз югалып тора. Шунысы кызык: вакыйга XX гасыр тәмамланганда бара.

Бүрек урларга беркайда да махсус өйрәтмиләр һәм ул тумыштан килгән сәләт тә түгел. Бүрек урларга Тормыш дигән бөек институт өйрәтә.

Кешенең баш киемен талап алу – аны мыскыл итү, мәсхәрәләү, җәберләү, оятсыз рәвештә кимсетү, рәнҗетү һәм талаучының үзе төшеп баткан пычрак түбәнлеккә тагын берәүне сөйрәп төшерергә тырышуы.

Бу – илебездәге кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең бер мисалы. Монда бүрекнең гаебе юк. Монда бүрек – бер сәбәп кенә.

«Каракның бүреге яна» диләр... Дөрес түгел. Кайбер мәкальләрне, әйтемнәрне үзгәртәсе, алыштырасы бар. Хәзерге каракның бернәрсәсе дә янмый. Кеше талаучылар, караклар бүген рәхәтләнеп яшиләр. Каракларны тота алмыйбыз, талаучылардан куркабыз.

«Каракның бүреге яна» дип түгел, бәлки «Каракның бүреге яңа» дип әйтсәк, дөресрәк булыр...

1990

САТАШУЛЫ ЙОКЫ

Яшәгән, ди, Әвеш Тәвешевич атлы чиновник.

Үзеннән түбәнрәкләр ул яшәгәнгә яшиләр дип, ә үзе исә өстәгеләр яшәгәнгә яшим дип инанган ул.

Беркөнне Әвеш Тәвешевич бик озын, куркыныч төш күргән. Имеш, иң өстә утыручы түрә атлар ярата икән. Моны белгәч, чиновник атларга шулхәтле гашыйк булган ки, хәтта хатыны бераз көнләшә дә башлаган, имеш. Ул кабинетында, дачасында, өендә ат сурәтле рәсемнәр элеп кенә калмаган, үзе дә ат асрый башлаган.

Тик менә Әвеш Тәвешевичның коллегасы, күптәнге конкуренты, аяк чалучысы Мүхлиев ике ат асрый икән. Имештер, моның өчен аның абруе чак кына югарырак күтәрелгән сыманрак тоела икән.

Шушы урында төш тәмамланып, уяныплар гына китәсе дә бит! Юк шул. Күрәчәк диген...

Йокы дәвам иткән, төш тә өзелмәгән. Заман үзгәребрәк киткән, имеш. Дөньялыкның тәрәкләре бераз чалышлык җибәргән дә, бөтенләй уйламаганда-көтмәгәндә иң өстәге түрә булып ишәк яратучы кеше килгән, ди. Урта Азия тарафларында туган кеше булгандыр, күрәсең. Төш күреп ятучы Әвеш Тәвешевич тиз арада ишәккә гашыйк булган, имеш. Ат сурәтләрен ишәкнекенә алыштырып, атны суеп казылык ясатканнан соң, Үзбәкстаннан, күп акча түләтеп, ишәк кайтарткан, ди. Ләкин бичара ишәк, күрәсең, чиновниклардан аермалы буларак, ватан җанлы булгандыр, күп тә үтми, Ташкентны сагынып үлгән, имеш.

Ә менә Мүхлиев Төркиядән кайтарткан икән ишәкне. Аның ишәге төрекләр сыман чырыш нәрсә булып чыккан, ул Татарстанның климатына иялəшкән, имеш.

Шушындый төш керсен әле!

Йокы дәвам иткән. Саташуның да азагы күренмәгән.

Иң югарыдагы урынга хоккей яратучы түрә менеп утыргач, Әвеш Тәвешевич боргаланып ала, өстендәге юрганын тибеп җибәрә. Имеш, Мүхлиев конькида да шәп йөри, ди, кәшәкәсен дә ресторанда кулланыла торган кашык сыман оста тота, ди. Әвеш Тәвешевич тә конькида йөрергә, кәшәкә тотарга өйрәнергә керешә. Инде боз өстендә яңа туган бозау сыман таеп, мүкәләп йөрми башлагач кына, инде кәшәкә белән кизәнеп шайбага сугарга өйрәнгәч кенә, илдә үзгәрешләр булып, патшалыкка суда йөзәргә яратучы, йөзү буенча спорт мастеры килә, имеш. Аңа ияреп барлык чиновниклар суда йөзәргә тотына, безнең Әвешебез генә, тумыштан судан курку сәбәпле, йөзәргә өйрәнә алмый. Мүхлиев исә суда батмый торган нәрсә булып чыкты – тормышта да чуртан сыман йөзеп яши, суны да үз стихиясе итә.

Төшнең иң куркыныч урыны шушыдыр дип уйласагыз, ялгышасыз. Хаким булып яңа кеше килә дигән хәбәр ишетелгәч, йөзә белмәүче Әвеш Тәвешевичнең эченә җылы йөгерә. Ләкин саташуның куәте кинәт көчәя, чөнки властька парашюттан сикерергә яратучы кеше килә. Балконга чыкканда да башы әйләнә торган чиновнигыбыз хәтта төшендә дә бу дөньяга ник туганына үкенә башлый. Башкалар сикерә дип ул да парашют киеп сикерә, аның парашюты ачылмый, ул кычкыра, бәргәләнә. Мүхлиевнең парашюты ачылып, чиксез киңлек кочагында елмаеп, тын гына газиз җиргә таба төшеп баруын күргәч, саташуның нинди газаплы икәне аңлашыладыр.

Төш дәвам иткән. Кинәт йокы ниндидер якты, балкышлы, алкышлы бәйрәмгә таба юл ала. Төшнең бу өлешендә иң югарыдагы түрә булып бәйрәмнәр, тамашалар яратучы кеше килә. Инде төш татлыланырга тиеш бит югыйсә. Юк шул! Имеш, чиновнигыбызны бер тамашага да, бер бәйрәмгә дә, бер церемониягә дә чакырмыйлар икән. Бу хурлыкны, бу позорны күтәргәнче, суда батып үләселәр калган яки парашют ачылмыйча җиргә төшеп чәчрәп үләсе калган. Ә бит Мүхлиев бөтен банкетларда катнаша, әллә нинди комитетларда, коллегияләрдә утыра, әле монда, әле тегендә аның имансыз чырае чагылып тора.

Саташулы йокы дәвам иткән. Ни гаҗәп: иң зур түрә булып халыкны яратучы кеше килә. Әвеш Тәвешевич исә, карьера артыннан йөреп, өстәгеләргә тәлинкә тотып, түбәнсенеп, куркып, кайгырып, ялагайланып инсаният дөньясыннан аерылган иде инде, ул кешеләрне яратмый, чөнки хәтта үз халкының телен белми, ул аңа чит-ят, халыкны аңлый алмый. Халыкны ул үзе өчен үзенчә генә ярата ала. Мүхлиев тә яратмый кешеләрне, ләкин ул яраткан булып кылана белә, халыкны яратучы ролен шулхәтле оста уйный.

Саташулы йокы дәвам иткән. Үзгәрешләр тагын да күренгән.

Атларны да, ишәкләрне дә, спортның барлык төрләрен дә, кешеләрне, гомумән дөньяны яраткан булып кыланучы өр-яңа хаким килгән, имеш.

Саташуның шушы җирендә чиновнигыбыз уяна. Ләкин торырга инде хәле булмый. «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртып аны сырхауханәгә алып китәләр.

Тынычландырып йоклата торган уколлар кадаганнан соң, әлеге дә баягы төш тагын кергән.

Имеш, хаким булып кармак белән балык тотарга яратучы кеше килә. Әвеш Тәвешевичнең куанычы хәттин аша, чөнки ул үзе дә малай чактан ук балык тотарга ярата иде.

Имеш, хаким күлгә кармак салган, ә аның кыр-кырында чиновниклар, веграк түрәләр, куштаннар, тезелешеп, үзләренең кармак таякларын кысып тотып утырганнар. Әвеш Тәвешевичкә дә урын бар икән, имеш. Хакимнән бер-ике кеше аша гына ул үзенә урын җайлап кармагын сала. Аның кырыенда дошманы Мүхлиев утыра, ул чак кына хакимгә якынрак. Калкавычына караганда күбрәк хаким ягына карый. Монда да аңа бәхет елмая – хакимгә дә якынрак, бер-бер артлы эре-эре балык та эләгеп тора, имеш. Ә безнең Әвешебезнең калкавычы һич кенә дә тибрәлми. Бары тик Мүхлиев чираттагы бәртәсен судан тартып чыгарганда гына дулкыннар тәэсирендә Әвешнең калкавычы бәкедәге каз тизәге сыман чайкалыбрак куя.

Әвеш Тәвешевич салкын тиргә батып уяна. Шундук әле генә күргән төшен башыннан ахырына кадәр хәтер аша уздыра. Ко-

точкыч төш! Иксез-чиксез саташу! Аңа балык эләкми! Мухлиевкә генә эләгә. Дошманга балык эләгә, аңа – юк! Бу төшне бер генә төрле юрарга мөмкин – эштән алырлар, ахрысы. Һәм никләр уянганына үкенеп куйды ул. Хәер, төштә ни, өндә ни – барыбер шул ук йокы, шул ук төш, шул ук саташу!

Ул кесә телефоныннан эшенә шалтыратты. Аның вазифаларын Мухлиев башкара икәнен әйттеләр. Сез борчылмагыз, дәваланыгыз, дигән булдылар.

Ярар, аякка баскач эшемдә, бәлки, калдырырлар дип өметләнде ул. Элекке эштә калдырмасалар да, шул ук даирәләрдә урын беткәнмени? Чирләде дип урамга чыгарып ташламаслар әле. Шушы кадәр куркып, карьера ясап өстәгеләргә тәлинкә тотканнан соң да читкә тибәрләр микәнни?!

Барысын да югарыдагылар хәл итә. Яңа хакимдә бөтен өмет. Дәваланганнан соң, хәл кергәч, ничек тә аңа ярап булыр әле, осталык, тәҗрибә юк түгел бит инде. Спортның аерым төрләрен яратучы, суда йөзүче, парашюттан сикерүче җитәкчеләр тәмам җелеккә үттеләр. Андыйлар алдында үзеңне күрсәтү авыр шул. Ярарга тырышам дип, булдыра алмаган көе, спортсменга әйләнү мөмкин түгел! Монысы гомумән дөньяны ярата, ди, димәк, һәрбер кешегә үз урыны табылыр, интегергә туры килмәс.

Ул тагын эшенә шалтыратты.

– Алло, бу мин әле... – диде ул, йөрәгенең ярсып тибүеннән урталайга ярылырдай булып.

– Яңа хаким инде бүгеннән алып вазифаларына тотынды, – диделәр аңа.

– Ниндирәк кеше икән соң? – дип сорарга йөрәксенде ул.

– Әле билгеле түгел. Болай бик куәтле кешегә охшаган, эш буенча да, тормышта да.

Әвеш Тәвешевич тагын бер соравын ничегрәк әйтергә икән дип икеләнеп торганда, гүя аның ни уйлаганын белгәннәр – телефон трубкасында яңа мәгълүмат яңгырады:

– Спортсмен.

– Спортның нинди төре буенча? – диде чиновник, башы әйләнеп киткәнен тоеп.

– Ун километрлы кросска йөгерергә ярата.

Әвеш Тәвешевичнең кулыннан телефоны төшеп китте, ул караватына чалкан ауды.

Шул кичне ул җан бирде.

2006

«АЛГА КИТКӘН» АЛКАШ МОНОЛОГЫ

Хәзер бөтенесе эчә. Эчмәгәне «травка» тарта, наркотик кадый, бензин исни. Мин – аракыга тугры булып калган гражданин, ягъни чын патриот.

Ярар, сүз минем турыда гына түгел, гомумән, яшәү ямен аракы ярдәмендә табучылар хакында.

Эчкечелеккә каршы көрәшүнең мәгънәсе юк икәнне инде кәҗә дә аңлыйдыр. Ә дөньядагы яшәеш ул эчсәң дә, эчмәсәң каядыр бара да бара.

Кайвакыт ишетергә туры килә: имеш, дөнья алга бара.

Бара, әнәң... Чүт сүгенмәдем. Дөньяның аның кайда алды да, кайда аның арты?! Дөньяның кай тарафларга барганын минем күршем Сәгыйть тә белми – ике югары белеме була торып.

Фән-техника казанышларын күрәбез, беләбез: затлы машиналар, купшы коттеджлар, джакузилар, жалюзилар...

Жалюзи дигәннән, мине узган атнада УЗИдан карадылар. Бавырны, бөерләрне, бүтәкәмне тикшерттем. «Эчүдән тукта», – диделәр. «Ник?» – мәйтәм. «Бавырың зурайган», – диләр. «Кечерәймәгән бит, зурайган, – дидем, – кимүгә таба китмәгән бит».

Мин алардан сорадым: «УЗИегыз душу показываетмы?» Юк, бөтен нәрсәне күрсәтә, кешенең күңелен, җанын, бәгырен күрсәтә алмый икән.

Нинди алга бару! Минем күңелемнең халәтен күрсәтеп бирә торган аппарат та юк дөньяда. Мин аларга шигъри юллар белән әйттем: исерекләр бик күп алар, тик юк менә безнең кебекләр.

Әй, җан турында сөйләп торган булам. Прогрессның бөтен җимешләре аек кешеләргә генә хезмәт итә, шулар өчен уйлап чыгарыла – минем шуңа ачуым килә.

Нәрсә, салган кеше кеше түгелмени? Бу нинди дискриминация? Автомобиль руленә аек кеше генә утырырга тиеш. Исерек кешегә теге ярамый, бу ярамый, тегендә керергә ярамый, монда юл ябык. Гел тыю да тыю гына. Ярый ла исерек чагында читен түгел. Ә айный башлагач, махмыр чыга башлагач? Төнге икедә кайтып ятып иртәнге дүртләр тирәсендә уянып киткәч, махмырның ни дәрәҗәдә тирәнлеген аңлатыр өчен аерым бер сәләт кирәк. Шулчагында унитазның кирәклеген ничекләр аңлатыйм? Дистанционный управлениеле унитаз уйлап чыгара алмыйлар микәнни? Инде бит космосларга очтык, унитазга охшаган бер әйбер бик озак айда йөрде, ә караватяныына шуып килә торган унитазны ясый алмыйлар. Күршем Сәгыйтькә әйткән идем шулай дип. Сиңа тиздән гел караватастында гына торучы кечкенә унитаз булачак, ди. «Утка» дип атала, ди.

Шаяруы хайванның! Минем нәкъ менә күршем Сәгыйтькә претензиям зур. Ул галим булып санала. Технарь. Техника бу-

енча галим булгач, нишләп эчкечеләр өчен аерым лифт разрабатывать итми? Перегар исе белән бер җиренә өргәч әкрен генә менә торган.

Эчкечеләр өчен вахтада махсус врач утырырга тиеш. Кан басымын үлчәп, тынычландыра торган уколлар кадый торган бер табиб утырырга тиеш һәр подъездда.

Эчкечеләр өчен аерым автобуслар йөрергә тиеш. Анда күңеле болганган кешеләр өчен махсус пакетлар булырга тиеш. Аягында тора алмаганнарга ятар өчен урын каралырга тиеш.

Телевизордан, радиодан һава торышын эчкечеләргә дә әйтергә кирәк. Мәсәлән, күз күреме кырык-илле метр дигәч, бер ярты эчкән кешегә ун-егерме метр дияргә кирәк. Һава дымлылыгы бер төрле булса, махмырдан тирләгән кеше өчен икенче төрле ул. Температура фәлән градус булса, ике кешегә бер ярты эчкәч, күпмедер градуска арта.

Сыйфатсыз эчемлекләр хакында да әйтәсем килә. Мин әгәр дә биш меңлек коньяк эчсәм, башка кыяфәттә булыр идем.

Нишләп пластик шешәләрдә рассол сатылмый? Иртәнге рассол ул бит иртәнге аш кебек.

Күршем Сәгыйть юкны бушка аударып энциклопедияләр актарып ятканчы портативный самогонный аппарат уйлап чыгарсын иде. С-с-с-с... самогонный аппарат та уйлап чыгара алмаган башы белән киная аша төрттереп, чеметеп сөйләшкән була.

Колорадо коңгызыннан котылырга һаман агу уйлап чыгара алмыйлар. Күпме ир-ат сыйфатсыз аракы эчеп үлде! Кешене үтерә торган сыекча ясыйлар, ә колорадо коңгызын бетерә торганга башлары җитми. С-с-с... самогонны чистарта торган фильтр да ясамыйлар бит бездә.

Эчкечеләр өчен махсус гәҗит чыгарырга кирәк.

Эчкечеләр өчен махсус телевизион тапшыру эшләргә кирәк.

Эчкечеләр өчен FM диапазонында махсус канал булдырырга кирәк. Хәмер яратучыларның күңеленә хуш килгән җырлар яңгырасын.

Эчкечеләр оешмасын төзергә кирәк. Парламентка үзебезнең депутатларны сайларбыз. Эчкечеләр мәнфәгате өчен көрәшүче сәясәтчеләр кирәк. Дөрес, анда алкаш депутатлар җитәрлек, ләкин алар әлегә безнең мәнфәгатьләрне кайгыртмыйлар.

Эчкечеләрне аерым милләт дип игълан итик. Үзебезгә дәүләт сорыйк, денеңне... Чүт сүгенмәдем.

Кайчан безне кешегә саный башларлар? Кем әйтмешли, йөрәк бит болай да яралы...

Их, бер ике йөз сум акча булса кесәмдә, бернәрсә кирәк булмас иде – дәүләте дә, кемнеңдер ихтирамы да. Баш төзәтергә дә акча табылмасын әле. Шушы булдымы ил, шушы булдымы капитализм!

«Үзенең эчкечеләрен ихтирам итмәгән дәүләтнең киләчәге юк», – дигән бер акыл иясе. Беләм мин ул фикер иясен. Күрше подъездда яши. Минем кебек эшеннән куылган кеше. Шуңа керәм әле хәзер. Ул миннән дә акыллырак, берәр нәрсә уйлап чыгарырбыз.

2006

ҖИРӘНҮ

Тавык лапастан чыкты да томшыгы белән канат асларын капшады.

«Әй шапшак та инде бу тавык, – дип уйлады кояшта кызынып торган дуңгыз, – гомер буе юынма әле... Ничек әтәч ташлап китми икән шушы пычрак тавык кавемен...»

Дуңгызның, мондый уйлардан гасабиланып, тәне кычыта башлады.

«Бигрәк пычрак нәрсә бу дуңгыз, – дип уйлады тавык, дуңгызның койма баганасына ышкынып кашынганын күргәч. – Бу да йөргән була бит хайван санында. Әле, җитмәсә, ата дуңгыз тирәсендә чуалган була, шакшы...»

Тавык дуңгыз ягына тагын бер нәфрәтле караш ташлады да тирес өемендә тырнап чокыр ясады һәм җайлап кына шунда кереп урнашты.

Дуңгыз тирес өеме ягына җирәнеп карады һәм, тавык кебек шакшы нәрсәләр белән бер дөньяда яшәвенә офтанып, яңгыр суыннан хасил булган сазга кереп ятты.

1991

«ДОСУГ»ТАН КЫЗ ЧАКЫРТТЫМ

Минем беркайчан да теге «досуг» дигән оешмадан кызлар чакыртканым юк иде. Акча да чамалы. Каушата да. Аннары без бит инде башкачарак тәрбия алган буын. Минем өчен каядыр шалтыратып кызлар чакыру яңа нәрсә бит инде. Хатын белән аралар бозылып, аерылышу чигенә җиткәч һәм дә хатыным анасына киткәч, күпмедер вакыт бик каты кайгырып ятканнан соң, беркөнне тәвәккәлләдем бит мин дә.

Хатыным Гөлүсә белән аерылышасым килми, аралар рәтләнер, беркөнне ул кире кайтыр, инде бергә күпме вакыт гомер иткәнбез икән, гаиләбезне таркатмабыз дип өметләнеп йөрим. Ә шулай да хатынга ачуым-үпкәм бар. Без бит бала-чага түгел бер-беребездән китә-кайта йөрергә.

Йортыбызның стенасына эре һәм куе итеп язылган «досуг» номерына күз кыры белән генә карап китә торган идем элегрәк тә. Беркөнне почта ящигымнан бер кәгазь кисәге алдым. Шундый чибәр шәрә кыз сурәте бар һәм телефон номеры. Монысы да «досуг»ныкы булып чыкты.

Өйгә кергәч, кыюлык өчен йөз илле грамм аракы эчтем. Башка киткәнен көтеп ун-унбиш минут чамасы зал белән йокы бүлмәсе арасында әрле-бирле йөрдем.

Телефон трубкасын колагыма куйгач, каушаудан йөрәгемнең ярсып тибүен ишеттем. Калтыранган кулымны көчкә буйсындырып, аксылланыбрак киткән бармагым белән «досуг» номерын җыйдым.

– Алло! – диде назлы тавыш.

Бу тавыш сине алдап сдача бирми торган сатучыларныкыннан да ягымлырак иде.

– Это досуг? – дидем мин.

– Да, я вас слушаю. Мы к вашим услугам. Вам девушку, мужчину?

– Мне девушку.

– Брюнетку, блондинку?

– Мне татарку.

– Худенькую, полненькую?

– Мне бы подешевле.

– У нас час стоит 1200 рублей. Устроит?

– Устроит, – дидем.

Анаңны сатыйм! 1200 тәңкә! Ләкин инде артка чигенергә мөмкинлек юк иде.

– Адрес назовите ваш.

Әйттем адресымны.

– Ждите в течении часа, – диделәр миңа.

Кыюлык өчен тагын йөз грамм өстәсәм дә, йөрәгем, бугаз тирәсенә менеп, кушаяклап тибә башлады. Ничек каршы алырга, үземне ничек тотарга? Чишенеп үк ятаргамы, әллә башта сөйләшеп утырышлы микән? Аңа да аракы салып бирешле микән? Аны чишендерергә кирәк микән, әллә үзе чишенә микән ул?

Катып беткән простыняны кабаланып карават өстеннән тартып алдым да бөгәрләп ванна бүлмәсенә тондырдым. Чиста простыняны үтүкләнмәгән килеш җәеп куйдым, мендәрләрне як-яктан кагып күперткән булдым.

Утырып тынычланып карыйм дигән идем, кая ул – тагын әрлебирле йөрергә тотындым. Каушата бит, зараза! Әгәр берни дә килеп чыкмаса?.. Кешегә сөйләп йөрмәс әле... Акчасы түләнгәч... Акча түләгән килеш булдыра алмый калу да әйбәт түгел. 1200 бит ул!

Ишек кыңгыравы зыңгылдагач, җилкәм салкын тир белән лыч булды. Чыраема елмаю төсе кертергә тырышып, ишекне барып

ачтым. Ачтым да тораташ булып катып калдым. Сагыштан чак кына саргайган йөзеннән ягымлы нур сибеп минем хатыным Гөлүсә басып тора.

– Нихәлләр бар?

– Бер көе.

– Нишләп төсең ап-ак? Эчкәниең мәллә?

– Эчкәнием.

Гөлүсә өйне җыештыра башлады. Мин кыбырсыйм. Хәзер теге чакырткан кыз килеп керсә?

– Мин кайтканга шат түгел бугай син? – ди хатын.

– Шат, шат, – дигән булам. – Мин кумадым бит сине, үзең чыгып киттең.

– Мине үпкәләтмәскә идең. Гафу үтенергә җыенмыйсыңмы соң?

– Гафу ит!

«Иртәгәгә хәтле анаңда гына кун», – дип әйтсәң тагын үпкәләр инде. Хатын белән дә аерылышасы килми. Менә үзе кайтты бит әле. Димәк, аралар рәтләнергә тора.

Ләкин теге кыз килә бит хәзер! Харап булуым ихтимал!

Ишек кыңгыравы зыңлагач, әле күптән түгел эчкән ике йөз грамм аракының бер шаукымы да калмады. Мин шундук егылып үләргә әзер идем.

Хатын ишекне ачарга җыенгач:

– Тукта, ачмый тор! – дип кычкырдым.

– Ник? – диде ул, аптырап.

Хатынга дөресен әйтергә булдым. Рас инде хатын үзе кайтып минем белән татулашырга риза икән, минем дә вөҗданым дөресен ихластан сөйләп, тәүбә итеп, ярлыкау сорарга кушты.

– Карчык, – дидем мин аңа. – Синең алдыңда, тезләнеп, үземнең нинди пычрак кеше икәнемне әйтергә телим.

– Беләм мин синең нинди хәшәрәт икәнеңне, – диде хатын тыныч кына.

– Юк, әле син барысын да белмисең. Минем синең алдыңда зур гаебем бар, хыянәтем дип әйтсәм буладыр.

– Мин белгәннәреннән тыш тагын нинди зур гөнаһың бар икән синең, ә?

– Мин «досуг»тан кыз чакырткан идем, – дидем һәм бөтенләй хәлсез калганымны тойдым. – Кичер мине, карчык, зинһар, ярлыка!

– Ярар, кабахәт, шул фахишәң белән кал. Киттем мин.

Мин тезләнеп сөекле хатынымның ике аягын кочтым:

– Юк! Миңа беркем, берни кирәкми, миңа, карчык, син генә кирәк! Ачма ишекне. Хәзер китеп барыр ул.

Шулай да хатын ишекне ачып җибәрде.

Менә сиңа мә! Бусагада хатынның сеңлесе Фирая пәйдә булды. «Әллә «досуг»та эшли микән хатынның сеңлесе? Мондый

кыяфәт белән сәгатенә 1200 алырга мөмкинме соң?» – дигән ике уй каткан башымда чыңлап алды.

– Тезләнәсеңме? – ди Фирая, авызын кыйшайтып.

– Гафу үтенә, – диде хатын. – «Досуг»тан кыз чакырткан да гафу үтенә.

Кинәт болар икәүләшеп рәхәтләнеп көләргә тотындылар. Мине ачуланасы урынга ихластан шатландылар.

Мин бер урында шәлберәеп басып торганда, алар миңа ситуациянең хикмәтен аңлатып бирделәр.

Болар мине тикшерер өченме, мыскыл итү нияте беләнме, юри почта тартмасына «досуг» номеры дип Фираяның эш телефоны номерын язганнар. Мин тиле шунда шалтыратканмын. Ә телефоннан Фирая белән бергә эшләүче хатын сөйләшкән булган.

Ну хатын-кыз мыскыл итә белә!

Ярар, 1200 сум расход тотылмады. Хатын белән татулаштык, әйбәт кенә яшәп ятабыз.

Шуны әйтәсем килә – «досуг» номерын күрсәгез, шалтыратырга ашыкмагыз. Башта утырып уйлагыз, берәрсе шаяртмый микән?!

2007

КҮРШЕ-КҮЛӘН

(Күрше подъездда яшәүче бер хатын сөйләгәннәрдән)

Күршең үзеңнән яхшырак булсын, ди.

Ну түлке, ну түлке, булмады бәхетләрем! Кайларда гына яшәсәм дә, күршеләрдән һич кенә дә уңмыйм.

Бу фатирымда да менә инде алты ел яшим, әлегәчә җан тынычлыгына ирешкәнем юк.

Бер этажда ремонт тәмамлана, икенчесендә башлана. Нинди генә тавышлар яңгырамый: «Гыр-р-р, гыр-р-р! Гыж-ж-ж, гыж-ж-ж! Даң-доң, даң-доң! Шарт-шорт, шарт-шорт! Тыкы-тыкы, тыкы-тыкы! Лок-лок-лок! Выж-ж-ж-ж, выж-ж-ж-ж! Вьюж, вьюж, вьюж! Чиж-ж-ж-ж, чиж-ж-ж!»

Акыллардан язарга мөмкин, билләһи!

Мин ялгыз хатын. Минем нервылар, ирсез яшәп, болай да какшаган. Миңа бит тынычлык кирәк.

Җыен б...тан көрәк булган кешеләр евроремонт дип, пластик тәрәзәләр дип, теге дип, бу дип кылтайган булалар. Әле кайчан гына кышкы салкыннарда хаҗәтне башкарырга тыштагы уборныйга чыгып йөргән халык чит илләрдәге кебек яшәргә омтыла. Ярый ла ул баеган саен әйбәт якка үзгәрсәләр. Көннән-көн әшәкеләнә кеше.

Ну түлке, ну түлке! Булмады бәхетләрем!

Минем нервы нык беткән. Мин Адаротский урамындагы базарда колбаса сатам. Әллә ничә төрле колбаса сатам, ә үземә андый әйбер ашарга ярамый – врач кушмый. Ничек нервы таушалмасын. Врачы да юньле кеше булып чыкмады. Бер тапкыр приемга баргач, миңа болай ди: «Сездә ачу, үпкә, нәфрәт күп, шул сәбәпле үт куыгыгыз кирәгеннән артык үт эшкәртеп чыгара. Шуңа күрә сезнең гел саруыгыз кайный, ашказаныгыз да шуңа авырта». Нишләп соң ул миннән ачу-нәфрәтемнең сәбәпләрен сорамый? Күрше-күлән әшәке булмаса, мин болай авырмас идем.

Уң як күршеләрем ниндидер бизнес белән шөгыльләнәләр. Соң гына кайталар да, таңнар атканчы кухняларында быр-быр сөйләшеп утыралар. Мин үземнең кухняда аларның бөтен сөйләшкән сүзләрен аермачык ишетеп торам. Панельный йорт бит – күрше-күләннең һәр тавышы күрше бүлмәдәгедәй яңгырый. Кайвакыт күрше хатынның эче быгырдаганына кадәр ишетелә. Ире иртән кырынганда бритваның сакалын кетердәткәненә кадәр ишетәм. Миңа врач галлюцинация галәмәте ул сезнең, дигән була. Нишләп мин үз колагыма ышанмаска тиеш. Уңмадым участковый терапевттан!

Ну түлке, ну түлке! Булмады бәхетләрем!

Сул як күршеләр болай карап торуга тыныч кына, ыспай киенеп йөрүче, эчми-тартмый торган кешеләр. Ну ишекне каты ябалар. Инде гел әйтеп торам. Көненә дүрт-биш тапкыр әйтәм. Соңгы вакытта бөтенләй эндәшмиләр миңа. Беркөнне игътибар иттем: аякларын минем коврикка сөртәләр шикелле. Мин ялгыз хатын, минем туфлидән ул хәтле пычрак коелмый. Димәк, болар мин күрмәгәндә-сизмәгәндә тиз-тиз генә аякларын минем моннан утыз дүрт ел элек заводта эшләгәндә яшереп алып чыккан резин коврикка ышкыйлар. Әйттем: мәйтәм, гафу итегез, бу хәтле үк кешедән көлмәгез. Мин ялгыз хатын, Алла каргаудан курыкмыйсызмыни, дидем. Тыныч кешеләр астыртын булалар, аларның яман эшләре бөтенләй көтмәгән яктан килеп чыгарга мөмкин. Коридордагы агач әрҗәдә бәрәңгеләрем саклана. Нишләп әле минем бәрәңгем тиз арада, күзгә күренеп, шулкадәре кими, ә? Мин ялгыз хатын, шулхәтле күп бәрәңге ашыйммы? Әйттем күршеләргә: җәмәгать, дидем, болай ярамый, дидем. Урламагыз бәрәңгемне, дидем.

Ну түлке, ну түлке! Булмады бәхетләрем!

Уңмадым күршеләрдән. Җитмәсә, беркөнне аерылган иремне очраттым. Соңгысын. Ул да, кабахәт, йөрәкне ярсытып авыр сүз әйтте. «Иргә чыкмадыңмы?» дип сорагач, «юк» дигән идем, «син җүләрне кем алсын» ди. Ә үзе! Өч тапкыр өйләнеп аерылган кеше. Авызында юньле сүз юк. Гадәттәгечә, салмыш. Шаяруларының атасы-анасы юк. «Син үзең өч тапкыр өйләнеп аерылган кеше, синең белән хатын түгел, дуңгыз да тормаячак» дидем. Әле шаяртып маташа, «Хәзер, яңа закон буенча, өч тапкыр өйләнеп

аерылган кеше участник войныга приравниваться итела. Министерство соцобеспечениядән миңа льготалар положено» ди.

Ярар, ул диванны әллә нигә бер күрәм. Ә бит күршеләр көн саен янәшә.

Ну түлке, ну түлке! Булмады бәхетләрем!

Астагы күршеләрдән ничек туйганнарымны белсәгез иде сез! Аларның музыкальный центр колонкалары өстә, минем идәнгә терәлеп диярлек урнаштырылган. Шулар аркасында бөтен попмузыканы яттан беләм хәзер.

Моңарчы аларның кызлары музыка уйната иде. Бөтен җырлары мәхәббәт турында иде. Шушы арада төрмәдән уллары кайтты. Гел башка төрле җырлар яңгырый башлады. Блатной җырлар. Беркөнне орышырга дип төшкәнием. Кая ул! Төрмәдән кайткан егет мине үзе әллә нинди аңлашылмый торган жаргон белән эт урынына сүгеп ташлады. «Че те надо, ты, корова иорданская?! Ты на меня батон не кроши! Я только что откинулся, я гужбанить хочу. Ты, короче, порожняк не гони, иди, канай отсюда! И чтобы я твое рыло в нашем дверном проеме больше не видел. Сука чердачная!»

Ул көнне нервыланып төне буе йоклый алмадым. Янә төрмәгә утыртуларын көтәсе кала инде.

Анысын кире утыртырлар, ә бит минем өстәге күршеләрем дә бар. Алар турында ничек әйтергә дә белмим инде. Миннән өстә әле яңа гына өйләнешкән пар яши – молодоженнар. Төне буе караватлары шыгырдый. Лифтта очрагач, турыдан-туры әйттем: «Ичмаса, караватыгызны майлагыз», – дидем. Бер көн үтте, ике көн, өч көн үтте, ә караватлары җан биздергеч тавыш чыгарып шыгырдый да шыгырдый. Тагын бер очрагач, яшь ир әйтә: «Апа, эзләдем, караватның кайсы төше шыгырдаганны һич тапмадым, аңламадым», – ди.

Ну түлке, ну түлке! Булмады бәхетләрем!

Рәзве ялгыз хатын өстендә караватшыгырдарга тиеш?!

Таяныр кешем юк. Яклаучы кирәк. ЖЭУ начальнигы да кабахәт кеше булып чыкты. «Апа, гел жалу белән йөрмә, күршеләрең белән тату яшәү мәслихәт», – ди. Бик тату яшәр идем! Ник соң тату яшәмиләр минем белән? Бер тапкыр лифт туктап, мин шунда бикләнеп калгач, бөтен подъезд белән сөенделәр. Нинди начарлык эшләгән мин аларга?

Ну түлке, ну түлке! Булмады бәхетләрем!

Көз көне «скорый» чакырткач та бөтенесе сөенделәр. Сөенегез! Мин әле бөтен кеше үлеп беткәч тә бер атна-ун көн йөриячәкмен. Минем ирсез яшәгәнгә генә нервы какшады. Мин әле сезгә устрою птичий базар!

Ничек тату яшисең мондый күршеләр белән?

Миннән берничә кат өстәрәк бер кыз бала пианинода уйнарга өйрәнә. Ике ел инде бер үк күнегүләрне кылтый-пылтый пикылдата да пикылдата. Кулларын төяр идем шуның! Музыкант бул-

маячагы ишетелеп-күренеп тора бит югыйсә, ник интектерәләр баланы да, күршеләрне дә.

Ә 134 нче фатирда чын профессиональ музыкантлар гаиләсе яши. Әле саксофон, әле торба тавышы ишетелә, әле гармун, әле скрипка тавышы яңгырый. Аталары – үзе музыкант, үзе фашист. Инде әллә ничә мәртәбә менеп ачуланыштым. Соңгысында музыкаль гаилә башлыгы әйтә: «Апа, тагын бер монда менсәң, похороныңда торбада уйнаячакмын», – ди. Фашист!

Ну түлке, ну түлке! Булмады бәхетләрем!

Ничекләр яшәмәк кирәк мондый йортта. Бөтенесе бер умартада – интеллигенты да, уголовнигы да, музыканты да, бизнесмены да, карагы да, молодоженнары да. Ничек нервы чыдасын!

Милициянең минем ишеләрдә хәбәре юк. Прокуратурада тыңларга да теләмиләр. Төрле гәҗит редакцияләренә әллә ничә тапкыр язып карадым. Мин язганны бастыру түгел, хәтта гәҗитләрдән җавап хаты да алганым юк.

Ну түлке, ну түлке! Булмады бәхетләрем!

Ярар. Ичмаса, бүген тыныч булмасмы. Бүген җомга. Кайсы дачага, кайсы авылга, кайсы кая тарала торган көн. Мин үземнең дачамны саттым. Бакча күршеләрем начар кешеләр иде. Ике як күршемнең дә помидорлары әллә каян ук светофорның кызыл төсе сыман күренеп эре-эре булып җитлегәләр, ә минем помидор вак һәм соң җитлегә иде. Алар качып кына бер-бер нәрсә сипмәгәннәр дисезме әллә минем түтәлләремә?! Кайсыбер елны чиям уңмый, ә ике як күршенең дә чияләре мөлдерәп пешә торган иде. Чия агачларым төбенә берәр нәрсә сипмәгәннәрдер дисезме? Сөйләр нәрсә күп. Ярар, котылдым инде.

Ял көннәренә йорт бушабрак кала. Ичмаса, бүген тынычлап йокымны туйдырырмын. Теге өстәге молодоженнар да аналарының дачасына киттеләр, ахрысы, бүген. Астагы тюремщик та, шорты гына киеп, зонада ясаткан шәмәхә татуировкаларын күрсәтеп, дуслары белән каядыр чапты. Уң як күршеләрем авылда бүген. Сул як күршеләрем Чаллыга плимәнникләренең туена барырга җыеналар иде. 134 нче фатирдагы музыкантлар җылы якка ук очтылар бугай. Их, шунда төпләнеп калсалар иде. Калмаслар инде алар, кайтырлар. Андый музыкантлар дөнья тутырук, җылы якта бигрәк тә. Кемгә кирәк алар анда!

Яратам җомга белән шимбәне. Күрше-күләннән ял итеп, тын ала торган көннәрем.

Йа Ходам! Сөенергә ашыкканмын икән. Өстәге молодоженнар дуслары белән азык-төлек, эчемлекләр күтәреп кайтып киләләр түгелме?.. Әйе, билләһигазим, шулар. Берәрсенең туган көнедер инде. Уф, бар икән күрәселәрем! Үтерәләр болар мине. Әле караватн шыгырдатып, әле музыка акыртып. Бүген әле биергә дә җыеналар бугай.

Ну түлке! Ну түлке! Булмады бәхетләрем!

2007

САНТЕХНИК МОНОЛОГЫ

Мин сантехник. Идем. Алга таба ул вазифамда калырмынмы-юкмы – әйтә алмыйм. Гомумән, эшли алсам ярар иде әле.

Базар икътисады булгач, мин дә үземчә баемакчы идем. Барып чыкмады. Чак кына бәреп үтермәделәр.

Мин сантехник. Идем.

Бер яңа төзелгән йортка смеситель рәтләргә чакырдылар. Бардым. Кердем. Затлы фатир. Әүкатле кешеләр яшәгәне борынга бәрелгән истән дә, күзгә чалынган купшы җиһазлардан да аңлашыла. Түрдәге көрсидә, аягын аякка атландырып, зиннәтле халат астыннан алагаем озын шома ботларын ялтыратып, бер япьяшь ханым утыра.

Кем икәнемне әйттем. Чибәр хатын ымлап ванна бүлмәсенә күрсәтте дә, пульт кнопкасына басып, ниндидер ыңгырашулы тавышлар чыгарган эротик фильм карарга тотынды. Маташа торгач, эшнең бүген тәмамланмасын аңладым. Махсус прокладка да кирәк иде.

Мин бу турыда чибәркәйгә әйттем дә, краннарны әлегә бормаска кушып, иртәгәгә кадәр саубуллашып чыгып киттем.

Икенче көнне, кирәкле әйберләрне һәм прокладканы табып, көн урталарында әлеге дә баягы фатирга юнәлдем.

– Кичә яңа прокладка алып килергә вәгъдә иткән идем, – дидем мин килеп кергән уңайдан. – Мин әйткәнчә краннарны бормадыгызмы?

Хатын миңа сәерсенеп карады.

– Чәчегезне бу төскә буяп дөрес эшләгәнсез, сезгә бик килешә, – дидем мин, хатынның кичәге прическасы сары төстә икәнне искә төшереп.

– Мин гомергә брюнетка булдым, беркайчан чәчемне буятканым юк, – диде бу.

– Кичә бит сез блондинка идегез... – дидем дә телемне тешләдем. Ләкин соң иде инде.

– Мин бүген иртән генә ял йортыннан кайттым, – ди бу хатын.

Димәк, кичә теге яшь чибәркәй моның иренең сөяркәсе булган. Күпне күргән кеше буларак, мин шундук:

– Сеңлегез булгандыр, – дип куйдым.

Әмма бу ханым да шактый тәҗрибәле зат булып чыкты. «Сеңлегез» дигәч, бу хатын өлкәнрәк була бит инде. Ачуы шундук чыраена чыкты.

– Минем бернинди сеңлем юк, – ди бу, борын тишекләрен киңәйтеп.

– Ярар, гафу итегез, баш буталган, – дип, мин ванна бүлмәсенә юнәлдем.

Эшемне тәмамлагач, бу хатын миңа краннарны рәтләгән өчен

2000 акча түләде. Аннары тагын 5000 не минем кытыршы учыма тыкты да:

– Кичә монда булган хатынны тасвирлап бир әле?! – диде.

5000 бит ул, 5000! 5 сум түгел бит ул, 5000! Кичәге чибәркәйнең төс-битен хәтерләгәнчә тасвирлап бирдем.

– Ә-ә-ә, беләм мин ул себеркене! – диде ханым, авызын чалышайтып. Ул урыныннан атылып торды. – Сучка! Ну все! Хватит!

Икенче көнне иртүк ЖЭУның коридорында наряд көтеп утырганда, янымда кичәге фатирның хуҗасы – чалбар-кәчтүм кигән, ялтыравыклы галстук таккан урта яшьләрдәге ир пәйда булды. Ул калтыранган куллары белән бумажнигын ачты. Аннан алып бер мең акча бирде дә болай диде:

– Краннарны тикшерергә дигән сәбәп белән фатирыбызга барып хатыныма әйт, башка фатир белән бутаганмын, диген, сездә бер хатын да юк иде, дип әйт.

Аз бирде ул миңа. Хатыны 5000 бирде. Ә бу гаиләсенең нык-лыгын 1000 гә генә бәяли икән. Ярар, акча акча инде ул, алып тыктым да тагын боларның адресы белән киттем.

Подъездларына җитәрәк күрәм, моның хатынын джип белән китереп куйдылар. Номерын танып калдым – өч тугызлы.

Шунда башыма бер уй сукты: туктале, мәйтәм, миңа да яшәргә кирәк бит, гомергә акчага туенмадым. Акча эшләү хәзер безнең үзмаксатыбыз лабаса! Акча хәзер ул безнең идеологиябез! Базар икътисады булгач, нишләп мин читтә калырга тиеш? Информациянең бәясе коточкыч кыйммәт бит хәзер.

Бу хатынга тоттым да әйттем:

– Ирегез миңа сезне алдарга кушты. Башка фатирда күргәнмен дип әйт, диде. Сезгә шуны килеп әйткәнем өчен миңа бераз акча төртмәссез микән?

Бирде бу миңа. Ире кебек саран түгел. Әйбәт хатын. Күп бирде. Мин шунда оятсызланыбрак киттем дә әйттем:

– Өч тугызлы номер таккан машинаның хуҗасын мин яхшы беләм, – дидем. – Ирегезгә барып әйтмәс өчен, тагын өстәмәссез микән, – дидем.

Өстәде. Кыска гына вакыт эчендә шулкадәр акча керсен әле! Инде акчаны ничек тотарга, нәрсәләр алырга дип уйлап йөри башладым, берәр җиргә ял итеп кайтырга да бераз калдырып булыр.

Болай акча эшләү ошап китте. Моның иренең эш урынын белдем дә барып әйттем:

– Хатыныгыз өч тугызлы машина белән китереп куйганны мин сезгә әйтмәсен өчен акча түләде. Шуны сезгә килеп әйткәнем өчен бераз түләмәссезме? – дидем.

Ике дә уйлап тормады, бумажнигын чыгарды да түләде.

Салкын сыра эчеп бераз күләгәдә утырганнан соң, тагын бер

күркәм уй башыма килде – беренче көнне фатирда очраган сөяркә янына барырга булдым. Бу ирнең хатыны «ул себеркене беләм» дигән иде бит. Барып эш урынын сорадым да шунда киттем.

– Чибәркәй, хәлләр мөшкел! Коточкыч скандал кубарга тора. Мин генә коткара алам, минем күрсәтмәләрем генә бу чуалышны чишә ала, – дидем. – Шәп иттереп түләсәң, сине ул фатирда күрмәдем дип әйтермен, – дидем.

Бу чибәркәй акчага кытлык кичерми, күрәсең, 3000 доллар бирде дә «Ты меня никогда не видел» диде.

Ул көннәрне мин гүя һаваларда очтым, аяк астымдагы җирне тоймадым. Менә бит, Алла бар ул. Болай барса, затлы машинага да акча җыелыр, мөгаен. Бер караганда, матур кәсеп түгел инде, әлбәттә. Мондый ысул белән баю дөрес тә түгелдер, бәлки. Ә икенче яктан урап чыгып караганда, бөтенесе гаделсез вә кагыйдәсез баеганда, нишләп әле мин хәерче булырга тиеш?!

Шулай бер алты-җиде круг ясадым. Кичләрен кат-кат акча санап утыра башладым. Алгы тешләремә яхшы коронкалар кигерттем. Германский ботинка алдым. Күн плащым юк иде, «Снежная королева» кибетеннән шуны алып кайттым. Берничә тапкыр ресторанга кердем. «Досуг»тан кызлар чакырткалый башладым.

Беркөнне тагын акыллы уй башыма килде: теге өч тугызлы машина хуҗасыннан да берәр пачка акча сорарга кирәк. Мин аның адресын беләм, чөнки сантехник буларак, минем ул йортта эшләгәнем бар иде.

Фатирын тиз таптым. Звонок кнопкасына бастым. Ишек ачылды, хуҗа миңа урам этенә караган сыман өстән генә карады. Мин аңа ситуацияне аңлаттым. Кәнәтил килеп чыкмасын өчен, акча түләвен сорадым.

– Ни өчен? – ди бу.

– Сөяркәңнең иренә барып әйтмәгәнем өчен, – дигән булдым. – Хатыныңа да әйтмәгәнгә.

Подъездан ничек чыгып очканымны хәтерләмим. Күпме вакыт ятканмындыр подъезд төбендә, анысын да әйтә алмыйм. Алдагы ике тешемне бик озак тротуардан эзләдем. Тапмадым. Тешләрне эзләмәс идем, аларга бит коронка кигертелгән иде, ә коронка ул хәзер кыйммәт нәрсә. Йотканмындыр инде.

Күрәчәкне күрмичә, гүргә кереп булмый, ди. Бу әле афәтнең башы гына булган икән.

Биргән акчасын даулап башта фатир хуҗасы килде. Аннары хатыны. Иң соңыннан теге сөяркә. Болар бер-берсен гафу итеп татулашканнар да миннән акчаны кире алырга тотындылар. Бирмәдем.

Мине алты тапкыр кыйнадылар. Дүрт кабыргам сынды, биш тешемне сугып төшерделәр. Башым ике җирдән тишек, сул колагым ертылды, уң кулым тайды. Бил сызлый, бер аягымны гел

көзән җыера. Бер күзем кан сауган килеш тора, һаман төзәлми. Барыбер бирмәдем. «Тотып бетердем мин ул акчаны» дидем.

Инде бәйләнми башладылар.

Хәзер аларны террорлап җыйган акчамны дәвалануга һәм савыгуга гына тотам.

Мин сантехник. Идем.

Аякка баскач бер утырып уйлармын әле. Алга таба бу рәхимсез, авыр һәм рәхмәтсез эштә – сантехник вазифасында эшләргәме-юкмы?!

2007

ЯЛГЫЗ ИР МОНОЛОГЫ

Ялгыз ирнең хәлен икенче бер ялгыз ир генә беләдер, мөгаен. Хатыным белән аерылышуымның сәбәбен әйтеп-сөйләп тормыйм, чөнки, беренчедән, бу гайбәт сөйләүгә керер иде, икенчедән, гаеп үземдә күбрәк шикелле һәм, ниһаять, өченчедән, кемгә кызык минем хатын белән төрле тарафларга китүебезнең сәбәбе.

Минем сезгә ялгыз ир хакында берничә сүз катасым килә.

Әйе, ялгыз ирнең хәлен болай гына аңлатып, тасвирлап бирү мөмкин түгел. Аның халәтен анык аңлар өчен үзеңә дә буйдак булу зарур.

Подъездга кергәч, теге яки бу фатирдан аңкыган аш исе ялгыз ирнең аңын, зиһенен ничек томалаганын нинди сүзләр, нинди төсмерләр белән аңлатмак кирәк. Берәр фатирдан кыздырылган бәрәңге исе аңкыса, табада башта суган белән кишернең майлап кыздырылганы, аннары гына бәрәңге салынганын аңлыйсың. Шул тәмле эш белән мәшгуль булган зифа буйлы, ромашка чәчәкле халат кигән, чәчен матур итеп җыеп башына яулыгын чөеп бәйләгән хатын күз алдына килеп баса. Бәлки, ул зифа буйлы да түгелдер, халаты да искергәндер, бәлки, хатын үзе дә таушалгандыр, әмма вәләкин подъездда ризык исе борынны кытыклагач, хатын-кыз күз алдына илаһи зат булып килә дә баса.

Кайвакыт эштән кайтып подъездга керәсең... аһ, авызыңны корт чаккыры, нинди ис! Кемдер балык пешерә. Нерафинированный көнбагыш мае белән. Бәлки әле, ул ахырга таба балык өстенә йомырка сытадыр.

Ә мин үземнең шыксыз, салкын буш фатирыма керәм дә, моннан уналты ел элек алынган ике камералы «Мир» суыткычын ачып, андагы яртылаш бушаган аджика банкасы кырыенда бөрешеп беткән ярты лимонны, тешләгәннән соң теш эзләре калган сыр кисәген (ташларга кызганып инде), атна-ун көн яткан селедка койрыгын күрәм. Ярый әле чүп чиләге янындагы пакетта үрә башлаган дүрт-биш бәрәңге калган. Мин аны юып әрчим дә

кәстрүлгә салып пешерәм, аннары теге селедка койрыгы белән ашыйм. Кем әйтмешли: «...Ач йөрәккә ачы юа, чукындыра да куя...» Аннары үтереп эчәсе килә. Чәйнек кайнап чыккач, өйдә чәй беткәнлеген беләсең. Бер литрлы банкадагы карлыган вареньесының өстендәге бозылып гөмбәләнгән өлешен кашык белән сыдырып түгәсең дә вареньеның ашардай җирен теге кайнап чыккан суга болгатып эчәсең.

Кайвакыт иртән лифт көткәндә, кеше фатирыннан коймак исе чыга. Шул коймакны пешерүче хатынның ире алай-болай үлеп китсә, шул хатынга йортка керер идем. Холкына да түзәр идем, «җаным» дип кенә торыр идем, гаиләне таркатмаска барлык көчемне куяр идем. Коймак хакына, хуш исле ризык хакына беркем җимерә алмаслык, беркем бетерә алмаслык мәхәббәт тудырыр идем. Лифтта төшеп барганда такмак искә төште:

Табадагы коймагымны
Яндырмадым, көйдердем.
Әкрен басып, вак-вак атлап,
Сөймәс җирдән сөйдердең.

134 нче фатирдан еш кына борщ исе чыга. Эштән арып кайтып килүче ялгыз иргә нинди җәза бу борщ исен иснәү. Ул вакытта гомереңнең бер елын кисеп ташлау бәрабәренә «бер тәлинкә борщ бирәбез» дисәләр, мөгаен, килешер идем.

Борщ куе. Аның ите дә бар. Кашык белән каерып каймак саласың. Кара борыч сипкәннән соң, уч белән яңакның бер ягын каплап, читкә карап төчкереп куясың. Тәлинкә кырында ап-ак ипи телеме. Ипи өстенә сарымсак ягылган. Өстәл уртасында бер шешә аракы тора. Борщны болгаткалап алгач, бер рюмка салып эчәсең. Икенче рюмканы ярты тәлинкә ашаганнан соң. Каш өсләрендә, муен тамырында бөрчек-бөрчек тир бәреп чыга – рәхәт тир, организмның рәхмәт әйтү билгесе бу.

Шуннан соң, ятып торам дип, диванга авасың да йокымсыраганыңны сизми дә каласың. Ярты сәгать черем итеп алганнан соң, кырыеңда хатыныңның ятуын күрәсең. Ул телевизор караган булып ята. Уе башкада. Шундый рәхәт. Бер кайгы юк. Тамак тук.

Сандугачлар су дип эчә
Яфрактагы чыкларны.
Уйлама, жаныем, юкларны,
Уйла бергә йоклауны.

Минем хатыным бик тәмле пешерә иде. Хәер, хәзер дә пешерәдер. Тик менә кемнәргә пешерә икән ул хәзер пилмәннәрен, бәлешләрен, шулпаларын, өчпочмакларын, дучмакларын, кыстыбыйларын?

Аның белән бергә яшәгәндә, безнең фатирдан да тәмле исләр

аңкып ялгыз ирләрнең аңын томалагандыр. Инде ничә тапкыр үтереп ашыйсы килгәндә йә подъездда пешкән аш исен иснәгәндә үземә сүз биргәнем бар: Можгага барып хатыным белән мөнәсәбәтләрне җайга салам да кире кайтырга күндерәм. Берәр җирдә капкалап алгач, тамак туйгач тагын ялкауландыра.

Хатын Можгадан минем, шунда кайтып китте ул. Бер ач вакытта ничек тә барырга кирәк анда. Ирдә микән? Баруын барырмын да... Йонлы күкрәкле әзмәвердәй ир ишекне ачып сиңа вокзал янындагы бомжга караган сыман җирәнеп караса?..

Нишләп ир кешегә пешерү осталыгы бирмәгән Ходай? Нишләп хатын-кыз пешергән ризык тәмлерәк була икән? Дөрес, поварлар арасында ирләр күп, ләкин ул бит рестораннарда, кафеларда. Анда начар пешерсәң дә ярый.

Беркөнне пилмән исе килә торган фатирдан почык борынлы, чепи күзле бер ир чыкты. Төс-биткә шөкәтсез булса да, кыяфәте, үзен тотышы вәкарьле моның. Тәмле ашаганнан бу. Шунда аның канәгать чыраена кизәнеп берне тартасым килеп китте. Тамак тәмугка кертә, ди. Төрмәгә кертүе дә бик ихтимал. Көчкә үземне тыеп калдым.

Их, бәлеш ашамаганга биш-алты ел бар бит инде! Чын бәлеш турында сүз бара – татар бәлеше, шулпалы, ярмалы бәрәңге белән, тана итеннән пешерелгән бәлеш турында.

Шул бәлешнең төбеннән дә тәмлерәк нәрсә бар соң бу сәер дөньяда?!

Шул бәлешне пешерүче хатын-кыздан да гүзәлрәк кем бар соң бу вәхши дөньяда?!

2007

БҮЛӘККӘ ҖЫР!

Мин FM радиосында музыкаль сәламләүләр тапшыруын алып барам. Аллага шөкер, тузанлы эш түгел. Элегрәк эшләмичә генә җиңел яшәргә теләүчеләр йә милициягә эшкә керәләр, йә, синтезатор кнопкаларына басарга өйрәнеп, сәхнәгә җырчы артына чыгып басалар иде. Хәзер инде аларга тагын бер кавем кушылды – FM радиосында эшләүчеләр һәм шул радиодан җырлаучы бихисап күп җырчылар.

Мөмкинлектән файдаланып, FM радиосының сәламләү тапшыруына килгән берничә хатны укып үтәсем килә.

«Минем бертуган апамның иртәгә туган көне. Аңа ныклы сәламәтлек, бәхет телим, – дип яза бер радиотыңлаучы ханым. – Шулай ук җизнинең абыйсының уртанчы улының хатынының классташы Зәйтүнәнең дә иртәгә туган көне. Аны да чын күңелдән кот-

лыйм, сәламәтлек, бәхет, эшендә һәм тормышында зур уңышлар телим.

Бу җырны шулай ук гаиләбезнең якын дусты, иремнең армиядәге хезмәттәше Шәүкәтнең оныгы тууы белән котлап ишеттерәсе килә. Чын күңелдән котлыйм! Аның хатыны Нәҗибәгә улыбыз Радикны финансово-экономическийга кертергә ярдәм иткәне өчен олы рәхмәтемне белдерәм.

Шулай ук машинабыз белән авариягә эләккәч ике мең доллар урынына бер мең генә доллар түләткәне өчен, Мицубиси Паджеро шоферы Мостафин Закирга тирән рәхмәтебезне белдерәбез. Шуларның барысы хөрмәтенә яшь җырчы Вәзи Мәзиев башкаруында «Шофер җыры» дигән җырны тапшырсагыз иде».

Әй шофер, тот рульне, тот туры,
Яңгырасын әйдә шат хезмәт җыры,
Тот рульне, тот туры,
Юлларыңа бәхет яугыры.

Кадерле дуслар! FM радиосының сәламләү тапшыруы аша туганнарыгызны, якыннарыгызны котлап, аларга җыр бүләк итә аласыз. Чаллы каласыннан килгән хатны укыйм.

«Исәнмесез! Чаллыдан сезгә кайнар сәлам! Сезгә инде унбиш ел буе беркайда да эшләмәүче Хәниф Ибраев яза. Минем гаиләм шактый зур: аяклары кәкре булса да, шактый чибәр хатыным, «икеле»гә укыса да, үз ягына яхшы уйлый торган ундүрт яшьлек улым, мине бигүк яратмаса да, үзем аны бик ярата торган унике яшьлек кызым, бер файдасы булмаса да, хаҗәтен тиешле урында башкаручы песиебез, болай күп ашамаса да, инде үзәкләремә үтеп җанымны нык ашаган тещам, инде йөрми торган булса да, тәрәзәдән карап аның ишегалдында торуын күреп сөенер өчен «Москвич»ым бар.

Җыр сорарга дип язуымны аңлагансыздыр инде. Гаиләм өчен түгел. Аларга җыр кирәкми, аларга акча кирәк. Җырны мин башка кешеләр өчен сорыйм. Штатлар кыскартылу сәбәпле, мине унбиш ел элек заводтан чыгардылар. Бу минем өчен зур кайгы булды. Шунысы гына куандыра – заводтан куылучылар бер мин генә түгел, без бик күп. Менә шул сокращениегә эләккән коллегаларыма багышлап җыр тапшырсагыз иде. Без эшсезләргә алтмышынчы елларда популяр булган «Таң ату белән, эшкә йөгерәм» дигән җырны тапшырсагыз, рәхмәтле булыр идек. Бу җырны шулай ук Чаллы шәһәренең Автозавод районы хокук саклау органнары, прокуратурасы, суд хезмәткәрләре хөрмәтенә дә юлласагыз яхшы булыр иде. Чөнки безне кыскартып эштән чыгаручы завод директорын күптән түгел дүрт елга ирегеннән мәхрүм иттеләр – дәүләт милкен үзләштергән өчен. С конфискацией, диделәр. Менә бит, кайгы килсә, аның артыннан шатлыгы да килә».

Шулай итеп, Хәниф Ибраевка һәм аның коллегаларына, аларны җәберләүчене төрмәгә утыртучыларга һәм төрмәдәге теге завод директоры хөрмәтенә без эфирда җыр яңгыратабыз:

Таң ату белән, эшкә йөгерәм,
Дәртләнәм сине уйлап, бергенәм.
Яле, иркәм, әйтче дөресен –
Тугансыңмы син гел минем өчен?

Безнең тапшыруга бихисап күп хатлар килә. Укып бетерерлек түгел. Менә шуларның тагын берсе.

«Минем хәтерем начар, – дип яза Халидә апа Әгерҗедән. – Хәтерем шул такмак, такы-токы җырлар аркасында бетте дип саныйм. Җырга гашыйк кеше буларак, яңа чыккан җырчыларны, аларның җырларын истә калдырырга тырышып зиһенем чуалды. Дәвалаучы табибым әйтмешли, психикам чалышайды. Һич савыгып булмый, чөнки дәвалаучы врачым да үзешчән композитор һәм җырчы булып чыкты. Күрәчәкне күрмичә, гүргә кереп булмый, ди. Үзебезнең авылда да хәзер җырчылар күп. Җырчы булмаган кешеләр авылыбызда хәзер дүртәү генә калдык. Мин хәтерем булмаганга җырлый алмыйм. Гарифә әби – туксан дүрт яштә, ул хәзер җырлау түгел, елый да алмый инде. Гакыйф малае Рәсим – тумыштан телсез. Тагын Самат абый җырчы түгел, ул совет заманында палитический җыр җырлап биш ел төрмәдә утырган булган, аны хәзер үтерсәң дә җырлата алмыйсың. Безнең өчен – җырламаучылар өчен – «Җырланмаган әле безнең җыр» дигән җыруны тапшыра алмассыз микән».

Тапшырдык, ник тапшырмаска!

Безнең сүзләр әле әйтелмәгән,
Җырланмаган әле безнең җыр.

Чираттагы хатны укыйм. Монысы Катлаулы авылыннан килгән, кайсы район икәне язылмаган.

«Менә хәзер бездә җыр багышланмаган шәһәр калмады, – дип яза Катлаулы авылыннан Габбас агай. – Инде авылларның да бөтенесенә диярлек җыр багышлап яздылар. Нишләп хәзер авылның урамнарына, чатларына яки тыкрыкларына багышлап җыр язмаска?! Мәсәлән, мин яши торган урам Габбас тыкрыгы дип атала. Мондагы табигатьнең матурлыгын күрсәгез иде сез! Инде хәзер бакча артында җыр багышланмаган чәчәкләр, үләннәр калмагандыр, мөгаен. Ә менә безнең тыкрыкта әллә нинди сез күрмәгән үләннәр үсә. Композиторларны, шагыйрьләрне безгә чакырып тыкрыгыбызны күрсәтеп булмас микән», – дип тәмамлый Катлаулы авылыннан Габбас абый үзенең хатын.

Бик шәп идея. Димәк, эстрадабызда иҗат офыгының тагы да киңәюе ихтимал. Габбас абый өчен без «Авылым урамнары» дигән җырны бирергә булдык.

Оныта алмыйм, онытмыйм
Авылым урамнарын,
Хәтер буйлап еракларга
Сузыла торганнарын.

Зәй шәһәреннән безгә бала караучы Хәнифә түтәй язган.

«Карт җырчылар күп чыга, яшьрәкләрне җырлатыгыз, – дип яза ул безгә. – Мөмкинлектән файдаланып, Казанда яшәп Вьетнам базарында Төрек курткалары сатучы кызым Гөлфидәгә, шул ук Казанда яшәп Прибалтика аша Польшадан Герман машиналары алып кайтучы киявебез Габделбәргә сәламемне җиткерегез. Уллары Айрат инде зур булып үсте. Калдырып киткәннәренә дүрт ел бит инде. Шушы җыр аша баланың тиздән мәктәпкә укырга барырга тиеш икәнлеген берәр ничек хәбәр итү мөмкин булмас микән? Бәлки, онытканнардыр».

Хәнифә түтәйгә бала җанлы булганы өчен сәламәтлек, озын гомер теләп, Гөлфидә белән Габделбәр өчен Ходайдан намус сорап, уллары Айрат сентябрьдә мәктәпкә барып «бишле» билгеләренә генә укый башлар һәм үзен тәрбияләгән Хәнифә әбисен мәңге онытмас дигән өмет белән шушы җырны тапшырдык:

Хәтерлим мин әле бүгенгедәй
Сентябрьнең бере җиткәнен.
Хәтерлим мин әле бүгенгедәй
Ашыга-ашыга чыгып киткәнем.

Кадерле дуслар!

Шалтыратыгыз, языгыз! FM радиосында җырлар җырлап бетергесез – кайгы килсә дә, шатлык килсә дә, эфирдан җыр сорап алырга мөмкин. Җанга ятардай җыр сайлап алып, сезләргә тапшырырга мин фәкыйрегез һәрвакыт әзер! Эфирда киләсе очрашуларга кадәр!

Җырла, җырла, дип әйтәсез,
Сезгә нинди җыр кирәк?
Җырла, җырла, дип әйтәсез,
Сезгә нинди җыр кирәк?
О-о-ой, сезгә нинди җыр кирәк?

2006

ҖЫРЧЫЛАР ТУРЫНДА...

Ай-һай, җырчылар күп хәзер! Элегрәк эшлисе килмәгән кеше милициягә эшкә керә иде, хәзер инде җыен әтрәк-әләм, әрәмтамак сәхнәгә менә.

Кемнәр генә күренми хәзер телевизор экраныннан, кемнәр генә чыкмый сәхнәләргә.

Өлкәнрәкләр, хәтерлисездер, перестройкага кадәр телевизордан теләсә кем чыгыш ясый алмый иде. Кыяфәткә, телгә, үзеңне тотышка, киемгә, дикциягә таләпләр зур иде. Демократия дип, сүз иреге, тегесе-монысы дигән булып, экраннардан кылый, сакау, тыңкыш, шадра кешеләр күренә башлады. Күренү генә түгел, алар әле сөйлиләр, фикер әйтергә, акыл өйрәтергә маташалар. Кайберләре хәтта җырлыйлар, бииләр.

Бездә хәзер 500 җырчы бар, ди. Хәер, аларның 5 – 6 сы гына җырчы, калганнары җырчылар түгел, җырлаучылар гына. Шуңа да карамастан, 500 җырчының барысы да үзен йолдыз дип саный, һәм дә бу факттан беркая да киталмыйсың.

500 җырчының репертуарында ким дигәндә 10 лап җыр була. 500 не 10 га тапкырлыйбыз... Һәм нәтиҗәдә бүгенгесе көндә безнең моңга сусаган җаннарыбызны иркәләргә 5000 җырның мөмкинлеге бар.

Бүгенге эстрадада 5000 җыр арасыннан миңа үзәкне өзәрдәй 5 җырны атый аласызмы?

...Без авыл баласы, без авыл баласы,
Без авыл баласы, авыл баласы...

Менә шушы «бала-бала», җырның кушымтасы буларак, сарулар кайнаганчы кабатлана да кабатлана.

Нәрсә бу? Җырмы? Моны җыр дисәгез, мине шушы баскан урынымда бәреп үтерегез.

«Бир, Ходай», – дип җырлау модага кереп китте. «И Ходай, исәнлек бир безгә!» – дип, ирле-хатынлы чыгып җырлыйлар. Әдәп саклап исәнлекне ата-анаңа, якыннарыңа телисең бит аны. Ә болар үзләренә сорыйлар. «Аллага шөкер, Алла ярдәм бирсен» дип җибәрәләр. Перәме бигрәкләр дә диниләнеп киттеләр җырчылар. Элегрәк җырларда якын кешеләреңә игелек, мәрхәмәт, яхшылык телиләр иде, хәзер исә оят та бәрәкәт тә бетте, үзләренә сорыйлар: «Ходай, озын гомер бир безгә!» дип җырлыйлар. Гомумән, Ходайга «бир» дип эндәшү модада. Ходай бирергә генә тиеш боларга.

«Кәккүкләр бар парлыларга гомер юрасын» дип җырлыйлар. Ә парсызларга? Ялгызларга гомерне юрамасынмыни? Җырдагы сүзләрнең мәгънәсенә төшенергә кирәк башта, аннары гына чыгып җырла син аны.

Безнең җырчы кызлар хәзер трусик-лифчик белән чыгарга

яраталар. Ник аны бөтенләй шәрәтән чыкмаска. Җырласын шулай. Бер уңайдан бөтен яктан да күрер идек – ни форма икән теге төше, бу төше.

Җырлар шулкадәр бер-берсенә охшаган ки, әйтерсең лә шул бер үк көйгә төрле такмак язып кына чыгаралар.

Җырчыларның исем-фамилияләре истә калмый. Кыяфәтләре дә бер-берсенекенә охшаган. Җырлары да, кыяфәтләре дә, көйләре дә, тавышлары да гел бертөсле.

Берничә җырчы бергә чыгып җырлау модада. Берничә тавышы-ние булмаган кеше чыгалар да, күмәкләшеп җырлагач, хәйран җырлаганга охшый. Төркемнең санын арттырырга кирәк. Кырык биш кеше берьюлы чыгып җырласа, көчлерәк чыгачак.

Концертка килгән тамашачыны кул чаптырып интектерү модада. Җыр ошаса, халык үзе кул чаба бит ул. Ә кылтый-пылтый бер җырчы чыга да, келтер-келтер җыры башланмас борын үзе чәп-чәп кул чабып, халыкны котыртырга тотына. Җыр тәмамланганнан соң, ким дигәндә 18 тапкыр рәхмәт әйтә. Кул чапканнары өчен рәхмәт әйтәме ул, шундый пүчтәк җырны тыңлаганнары өченме, әллә үзен кешегә санап сәхнәгә менгергәннәре өчен кемгәдер рәхмәтлеме?..

Җырчының артында һәм әйләнә-тирәсендә биючеләргә игътибар итегез. Подтанцовка дип атала. Кайберләренең биюе бөтенләй җырга туры килми, тәңгәл түгел, кайвакыт бу биючеләр төркеме ялгыш үтеп барышлый килеп чыккан да шушы җыр көенә төрле хәрәкәтләр ясыйлардыр дип уйлыйсың.

Мәчет ачканда эстрада җырчыларын чакыру да модага әйләнеп китте. Мәчет ачканда эстрада җырчысы җырларга тиешмени? Озакламый зиратта кеше күмгәндә дә эстрада җырчыларын чакыра башларлар, мөгаен.

Җырчылар турында бик күп, озын-озак итеп сөйләргә була. Вәләкин сару кайный, күңел болгана.

Сүземне түгәрәкләгәндә, Бауман урамында урнашкан йолдызлар мәйданчыгы хакында әйтәсем килә. Бу идеяне уйлап чыгарган кешенең үзен шул бетон астына күмеп куяр идем. Бөтен халык шуны таптап йөрсен иде аннары. Без США түгел. Анда бөтендөнья легендаларына аллея ачтылар. Анда ул чын аллея. Ә безнең менталитет та башка, үз дәүләтебез дә юк һәм йолдызлар мәйданы да безнең мәшһүр җырчыларыбызга лаеклы итеп эшләнмәгән.

Бөек җырчыларыбызны данлыйсыгыз килсә, минем бер тәкъдимем бар: Бауман урамында көн саен, көн буена мәшһүр җырчыларыбызның башкаруында халкыбызның иң матур җырлары яңгырап торсын. Моны оештырып буламы? Була!

Сүз ахырында бик җитди темага кереп киттем. Тизрәк тәмамларга кирәк. Туйган инде бу җитдилектән!

2007

БАШ

Баш – кешегә бик кирәк әйбер. Фән инде тәмам исбатлады – аның эчендә ми бар. Шул мидә уй-фикерләр бар икән... Кызык бит чынлап та!..

Баш ию – бу органның иң гүзәл сыйфатларыннан берсе. Баш июең белән тугрылыгыңны, куркаклыгыңны, ялагайлыгыңны, наданлыгыңны берьюлы күрсәтеп була.

Баш, гадәттә, шар формасында була. Әгәр дә баш дүртпочмаклы яисә күпкырлы булса, бик күп уйлар почмакларда посып башта кайнаган саташуда катнаша алмас иде.

Башның тышкы ягында чәч үсә һәм вакыты җиткәч коела. Бик күп еллар буе башның эчендәге процесслар белән аның тышкы ягында кавыкланып үсеп утырган чәчләр арасында тыгыз бәйләнеш бар дип саналды. Ләкин хәзерге вакытта бу нәрсәгә караш үзгәрде. Пеләш депутат белән куе чәчле депутат арасында алай искитәрлек аерма юк. Пеләш башка сугасы килә, ә куе чәчлесен чәченнән тотып сөйрәп йөрисе килә.

Шунысы гаҗәп – баш һәр кешедә бар. Һәркемнең башы эшли. Нишлидер ул – белгән юк. Ләкин ул эшли! «Аның башы эшли...» диләр. Тик менә нинди эш башкара икән соң ул?.. Ярый әле кешедә ике баш түгел... Әллә ниләр эшләнеп бетәр иде.

Башның проектында бер җитешсезлек сизелә. Кызганычка каршы, ул салына торган түгел. Аны резьбалы яисә болтлар белән беркетелә торган итеп ясап булмады микәнни... Без инде күптән алга киткән булыр идек. Мәсәлән, шул ук депутатлар ызгышканда, берәрсе мәгънәсез сүз сөйли башлау белән, тотасың да аның башын борып алып куясың... Башы бераз суынгач, яңадан урынына урнаштырасың. Ләкин аның өчен парламентта слесарьлар бригадасы тотарга кирәк булыр иде. Элегрәк ул эшне НКВД бик яхшы башкарган, ди.

Тарихтан укып беләбез: элек башны балталар, гильотиналар белән чабып өзә торган булганнар. Бүген инде без аңлыйбыз – андый җәза бер дә матур түгел. Матур да түгел, дөрес тә түгел, чөнки башны яңадан гәүдәгә ябыштырып булмый.

Аллаһы Тәгалә башны дуңгызга да биргән... Бу кешене бераз кимсетә шикелле. Шундый затлы әйберне дуңгызга биреп соң инде... Мөгаен, шуңа күрәдер кайбер кеше белән дуңгыз арасында аерма бик күзгә ташланмый.

Бәлки, шуңадыр башны бигүк хөрмәт итеп бетермиләр. Аңа сугалар: йодрык белән дә, күсәк белән дә, балта түтәсе белән дә... Егылсаң, башка тибәләр.

«Башны кая куярга белмим» диләр. Чөнки баш кешегә тынгылык бирми, кешене гел бимазалап тора. Баш үзен капларга

кыйбатлы бүрек сорый... Үзе өч тиенлек кенә булса да. Махмырдан ул үзен төзәтүне көтә. «Баш төзәтү» – аерым бер тема. Бу хакта әле язасылар бар. Баш шулай ук сабын, шампунь, тарак, лосьон сорый. Ә хатын-кызның башынаниләр кирәген яза башласаң, кәгазь дә, түземлек тә җитмәс.

Баш булмаса, яшәү алай ук кызык тоелмас иде. Ул бит әле сугыш коралы да – сугышканда баш белән бирү бар. Шунысы кызык: боксерларга билдән түбән сугу тыела, а башны уникешәр раунд буе төяргә рөхсәт ителә. «Җенес органнары башка караганда әһәмиятлерәк микәнни?» дигән сорау туа. Һич тә алай түгел. Баш ул бик чыдам нәрсә. Баш түзә ул!

Баш кешегә бик кирәк!

Ишекләрдән иң беренче булып баш тыгыла. Күз, колак, авыз, борыннарның баш шарында урнашуы аның әһәмиятен тагын да арттыра. Аннары, күккә иң якын торган да – баш! Тикмәгә генә гәүдәнең иң өске өлешенә урнашмаган ул.

Башны әле аны өйрәнәсе бар. Һәрбер баш үзенчәлекле. Башларның размерлары төрле булу юкка түгелдер бит. Һәрбер баш үзен акыллы дип саный. Бу да тикмәгә түгел. Юләр кешенең башы, кайвакыт, президентның башына да килмәслек акыллы фикер уйлап чыгара. Ә президент кайвакыт юләр кешенең башына сыймаслык нәрсәләр эшләп ташлый. Бәлки, президент башы белән янәшә дивана кешенең башы да булырга тиештер. Элек корольләр, патшалар тикмәгә генә үзләре янында тиле шутларны, шамакайларны тотмаганнардыр. Шуңа күрә дәүләтебез җитәкчеләре янына акылга зәгыйфь кешеләрне дә сайлыйк. «Алар анда болай да җитәрлек инде» диярсез сез. Анысы да дөрес. Ләкин без аларны халык арасыннан, үзебезнең арадан күрсәтик.

Җитәкчеләребез янында теләсә нәрсә сөйләшеп йөрүче тиленләр булса, җитәкчеләрнең диваналыгы да алай бик күзгә ташланмас иде.

Мин бу сүзләрне аптыраганнан әйтәм инде. Миндә дә бит баш бар. Димәк, миндә дә әллә нинди уй-фикерләр йөри. Минем башым да башкаларныкыннан ким-хур түгел. Шуңа күрә минем башымда да хәйран акыллы фикерләр белән беррәттән тузга язмаган нәрсәләр тууы гаҗәп түгел. Нишләтим соң инде мин ул мескен башымны?!

1991

ЯШӘСЕН ЮМОР!

Моңа кадәр кешене кеше итүче, аны хайваннан аерып торучы фактор булып аң саналды.

Ләкин бик күп эзләнүләр, күзәтүләр һәм тәҗрибәләр нәтиҗәсендә мин зур ачыш ясадым: кешенең башындагы аң – өч тиенлек тә түгел! Ә уйлап тапканы аның үзенә зыян гына китерә.

Сөйләшә алу, теле булу да кешене хайваннан өстен итә алмый. Телнең аңга караганда да зыянлырак икәнлеге һәркемгә мәгълүм. Тел – кешенең дошманы һәм, ул булмаса, бәлки, кеше бәхетлерәк хис итәр иде үзен.

Өстенә кием киеп йөрү дә кешене хайваннар алдында матурламый. Чөнки кешенең оятсызлыгы тун аша да бернинди каршылыксыз якты дөньяга бәреп чыгып тора.

Мәхәббәт сәләте адәми затка гына түгел, хайванга да хас.

Нәфрәт хисен дә Ходай кешегә генә түгел, шулай ук хайванга да бүләк иткән.

Кешене хайваннан аерып торучы бердәнбер сыйфат кала – юмор хисе. Көлә белү кешене бераз кеше итә кебек. Хайваннар көлә белми, чөнки алар дөньясында көләргә сәбәп тә һәм көлү объекты булырлык нәрсә дә юк. Ә үзеннән-үзе көлүгә хайван мохтаҗ түгел.

Кеше исә бөек сәләткә ия – ул үзенең хайванлыгыннан көлә. Дөресрәге, көлгән булып кылана. Әлбәттә, ул моңа карап хайванлыктан арына алмый... Ләкин аның кызыгы шунда ки – ул хайванлыгыннан арына алмаудан көлә. Ә хайван үзенең хайванлыгыннан көлми, ул аның белән горурлана гына.

Кеше дә үзенең хайванлыгы белән горурлана, ләкин ул хайванлыгы белән горурлануыннан ихлас күңелдән көлә.

Шулай итеп, аерма шунда: хайван хайванлыктан көлми, кеше исә үзенең хайванлыгыннан көлә.

Яшәү шартларын үзгәртеп, халыкны тиз арада сарык көтүенә әйләндереп була. Бу очракта да кеше үзенең сарыклыгыннан кычкырып көләчәк. Ул үзенең яңа халәтеннән шулкадәр каты көләчәк ки, хәтта сарыклыктан яңадан кеше дәрәҗәсенә күтәрелерлек хәле калмаячак.

Дуңгызга әверелгәч, кешегә үзенең бу үзгәреше шундый кызык тоела. Дуңгыз булу аны елатканчы көлдерә, нәтиҗәдә кеше элекке кыяфәтенә кайтырга көч табалмый.

Үзенең ерткычлыгыннан кеше шулай ук көлеп туя алмый. Көлеп туя алмагангадыр инде, ул ерткыч булып кала.

Ә менә дөньяга сарык, дуңгыз яисә ерткыч җанвар булып туган хайваннар үзләренең язмышларыннан көлүдән мәхрүм. Ходайның юмор хисе артыбрак китеп, бермәлне дуңгызны кешегә әвереддереп куйса, бәлки, дуңгыз да бер рәхәтләнеп көләр

иде. Ләкин бу очракта дөньяның кызыгы бетәчәк. Дуңгыз үзенең кешелегеннән көлә башласа, кеше моңа, мөгаен, үпкәләр иде. Ул чагында инде адәми затның юмор хисе юкка чыгасын көт тә тор.

Шуңа күрә ничек бар – шулай калсын!

Дуңгыз дуңгызлыгы белән горурланып пычракта ятсын!

Кеше: «Карале, мин дуңгыз бит?!» – дип, үзеннән-үзе көлгән булып кылансын!

Яшәсен юмор – кешене хайваннан аерып торучы бердәнбер сыйфат!

1991

ЭЧТӘЛЕК

Роман

Легионер 4

Повестьлар

Курку 146
Баян турында бәян 200

Хикәяләр

Наркокурьер. 270
Тын океанда көрәш 280
Мәгънәсез низаг 284
Гонорар 286
Контра 289
Кызык заманда яшибез! 295
Ахырзаман 297
Ельцин трамвайга утырды... 298
Колорадо коңгызы 299
Һәйкәл 301
Вирус 303
Кышкы интервью 305
Нурулланың эмигрант Сөнгатуллага язган хаты 310
Төнге мажаралар 312
Беренче мәхәббәт 314
Телевидение шаукымы 319
Ышанырга кирәк 323
Чын ярату 325
Каргыш 328
Бөрек урлау 337
Саташулы йокы 339
«Алга киткән» алкаш монологы 343
Җирәнү 345
«Досуг»тан кыз чакырттым 345
Күрше-күлән 348
Сантехник монологы 352
Ялгыз ир монологы 355
Бүләккә җыр! 357
Җырчылар турында... 361
Баш 363
Яшәсен юмор! 365

9 785298 021265

Литературно-художественное издание

Хаким Зульфат
(**Хакимханов** Зульфат Зуфарович)

ЛЕГИОНЕР

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Хәким Зөлфәт
(**Хәкимханов** Зөлфәт Зөфәр улы)

ЛЕГИОНЕР

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Р.Н.Нуриева, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 11.10.2011.
Форматы 60×90 $^1/_{16}$. Шартлы басма табагы 23,0.
Тиражы 3000 д. Заказ Р-1561.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс:(843) 519-45-22

http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча
сатып алырга мөмкин:

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.